«ЯР ЧАЛЛЫ ДӘҮЛӘТ ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ»
ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МУСА ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ “1 НЧЕ ГИМНАЗИЯ” МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын

Түбән Кама
2024

**УДК 37.01**

Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе карарлары белән басыла

Төзүчеләр:

1. Мухаметшин Азат Габдулхакович, педагогика фәннәре докторы, профессор, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» беренче проректоры
2. Хәзрәтова Фирүзә Вакильевна, педагогика фәннәре кандидаты, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы мөдире
3. Хөснетдинова Резидә Рөстәмовна, психология фәннәре кандидаты, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» психолого-педагогик һәм мәхсус дефектологик белем бирү кафедрасы доценты
4. Шәрәфетдинова Зимфира Габдрахмановна, филология фәннәре кандидаты, Федераль бюджет югары белем бирү учреждениесенең «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү теориясе һәм методикасы кафедрасы доценты
5. Хабибуллин Ильнур Ильдарович, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең директоры
6. Хайруллина Гульназ Рашитовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
7. Хайруллина Гульнара Илсуровна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең информатика укытучысы
8. Сөнгатуллина Ләйлә Мөхәмәтовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
9. Әгълиуллина Фәйрүзә Фазыловна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Муса Җәлил исемендәге "1 нче гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныф укытучысы

**Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын** = Жизнь люби, люби отчизну, всё чем жив родной народ: (Укытучылар һәм укучыларның эзләнү-тикшеренү, проект һәм иҗади эшләре Бөтенрәсәй Форумы материаллары=Материалы всероссийского форума)/ - Түбән Кама, 2024. – 377 б.

Җыентыкта “Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын” Бөтенроссия форумында катнашучы укытучы һәм укучыларның доклад тезислары урын алды.

Җыентык материаллары гомуми белем бирү укытучысының инновацион эшчәнлегендәге төп аспектларны үз эченә ала: мәгарифкә яңалык өстәү, яңа педагогик технологияләр һәм методикалар кертү, укучыларның интеллектуаль-иҗади эшчәнлеген оештыру, инновацион педагогик проектларны һәм программаларны тормышка ашыру, мәктәп имиджын булдыру һәм уңай тәрбия мохите тудыру өстендә эшләү. Искәрмә: язмаларда автор орфографиясе һәм пунктуациясе саклана.

Автор редакциясендә басыла

**УДК 37.01**

Эчтәлек

**Беренче бүлек. Укытучылар чыгышы.** 7
Аменова Эльмира Зөфәр кызы, Аменова Диләрә Ильнар кызы. Татар теле һәм инглиз теле дәресләрендә мнемотехника алымнарын куллану 7
Ахунова Гульнур Габдулловна. Башлангыч мәктәп укучыларына туган телне өйрәтүнең заманча стратегияләре 12
Әхмәтова Миләүшә Индус кызы, Әхмәтҗанова Тәскирә Фатыйх кызы. Татар теле дәресенең технологик картасы(5 нче сыйныф) 16
Вагыйзов Фарит Яхъяевич. Топонимик атамаларның милли мәдәният һәм традицияләр белән бәйләнеше 29
Гайнутдинова Зальфира Рашид кызы, Шарифуллина Алсу Ильнур кызы. Бишек җырларның яшь буынны тәрбиятләүдәге роле 32
Галеева Рәфилә Рәкыйп кызы. Башлангыч сыйныфларда проект эшчәнлеге 35
Галиева Энҗе Илһам кызы, Юнысова Гөлназ Рамир кызы. Тормыш яме - яшәүдә, Яшәү яме - гаиләдә 39
Ганиева Рузиля Фавазис кызы, Алтынова Гульнара Закир кызы. Фразеологизмнар дөньясында 42
Гараева Магинур Абрамовна. Минем гаиләм – минем бәхетем 44
Гарипова Лилия Рауфовна. Әдәбиятның якты йолдызлары 46
Гимранова Ильсеяр Гарафутдин кызы, Аглиева Айгуль Магфуряновна. Укучыларның фәнни-тикшеренү эшен оештыру 50
Гиниятуллина Алсу Рафисовна. Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә сөйләмне үстерү чарасы буларак театр уеннары 53
Гобәйдуллина Илгизә Хәниф кызы. Башлангыч сыйныф укучыларында функциональ грамоталылык формалаштыру чаралары 55
Гыйлфанова Гульназ Рашит кызы, Мингәрәева Гульсара Минрахимовна. Татар әдәбияты дәресләрендә модельләштерү алымын куллану 57
Егорова Гүзәлия Әбрар кызы. Сыйныфтан тыш чаралар аша татар теленә һәм әдәбиятка карата кызыксыну уяту 59
Жуковская Руфинә Касыйм кызы, Сәгыйдуллина Ранизә Зәлиф кызы. Татар теле дәресләрендә функциональ грамоталылык формалаштыру алымнары 61
Зарипова Әнисә Газизуловна. Укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыруда эш алымнары 63
Кашипова Наиля Задитовна. Дәресләрдә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә вакытлы матбугат чараларыннан файдалану 68
Локманова Алисә Өлфәт кызы. Диалогик сөйләмне үстерү уеннары 70
Махиянова Рузиля Миргазиян кызы. Муса Җәлил шигърияте ярдәмендә яшь буынга патриотик тәрбия бирү 74
Набиуллина Резедә Хәйдәр кызы, Ильина Зоя Евдоким кызы. Инновацион технологияләр кулланып татар теле һәм әдәбияты дәресләренә укучыларда кызыксыну уяту 76
Нәбиуллина Ландыш Илдус кызы, Нәбиуллина Карина Рамил кызы. Туган тел дәресләрендә синквейн алымын куллану 80
Нуриәхмәтова Римма Закирян кызы. "Сәлам" дәреслегенең үзенчәлекләре, аның белән эшләүнең төп һәм әһәмиятле моментлары 84
Нуртдинова Гульсиня Асхатовна. Халык авыз иҗатын өйрәнү юлында (Тарих эзләре буйлап...) 86
Садриева Аниса Хусаиновна. Коммуникатив уеннар аркылы,рус телле укучыларның сөйләм телен үстерү 89

Садыкова Лидия Хәмдегали кызы. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә “Фишбоун” методик алымын куллану 90
Сәлимҗанова Алсу Илдар кызы. Татар теле дәресләрендә грамматик уеннар (яңача уеннар) 92
Сиразиева Лениза Шакирьяновна. Туган тел дәресләрендә нейрогимнастика күнегүләрен куллану 97
Хайруллина Лилия Аркадьевна. Рус телле балаларны телгэ кызыксындыруда проект методынын роле ( мастер-класс) 99
Хайруллина Лилия Миннефаязовна. Формирование коммуникативных технологий на уроках татарского языка 104
Хакимова Рамзия Рифовна. Безнең гаилә традицияләре 113
Халикова Нурсина Далифовна, Фатхуллина Гузял Фагимовна. Индивидуаль якын килеп белем бирү 115
Халиуллина Альфия Ахметовна, Нуртдинова Гульсиня Асхатовна. Халык авыз иҗатын өйрәнү юлында 117
Хасанова Миляуша Кашбетдиновна, Газыймова Гузель Рафисовна. Укучыларда укый белү һәм укыганны аңлау грамоталылыгын формулаштыру ысуллары (читательская грамотность) 120
Хусаинова Энже Абрамовна. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә уен технологиясен куллану 125
Шарафеева Рамия Анасовна, Хазиева Лилия Джаудатовна. Туган (татар) теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның уку грамоталылыгын үстерү 128
Якупова Венера Бәдертдин кызы. Әдәбият дәресләрендә Муса Җәлил әсәрләре аша туган якка мәхәббәт тәрбияләү 132
Ялалова Зөлфия Фаел кызы. Туган тел дәресләрендә интерактив алымнар куллану 134
**Икенче бүлек. Укучылар чыгышы.** 138
Абдульманов Демид. Бөек Ватан сугышы – минем гаиләм хәтерендә 138
Архипова Сафия. Халкыбызның гореф-гадәтләре 140
Әһлиуллина Язилә. Укытучым – күңел кояшым 147
Галактионова Регина. Ахуновлар шәҗәрәсе 148
Галимова Айназ. Каенсаз авылы Йолдызлы урамының исеме тарихы 152
Галимуллин Илькам. Әлмәт шәһәре “Ризаэддин Фәхреддин” исемендәге җәмигъ мәсҗиденең эшчәнлеге 158
Гиззатуллина Алисә. Бетсә иде җирдә барган сугыш 164
Гыйлемханова Инзилә. Балык Бистәсе районы Биектау авылының тарихын, гореф-гадәтләре. Татар халкының милли бәйрәме Сабантуй традицияләре 171
Гыйләҗев Раил. Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк 179
Гыймаев Рәмис. Газымова Динә. Авылымның күренекле шәхесләре 185
Еремеева Ильвина. Кызыл Чапчак авылы тарихы 191
Җиһагирова Сабина. Дары исен вакыт оныттыра алмый 197
Залялиев Разиль. Татар һәм инглиз телләрендәге кош атамалары кергән фразеологизмнар 203
Зиганшин Билал. Киез –итекләр-байлык чыганагы 213
Идиятуллина Ильвина. Исемең матур, кем куйган? 224
Карамов Гадел. Шагыйрь иҗатында һөнәр атамалары 229
Каримов Айнур. Абдула Алиш батыр да, язучы да 237
Мингәрәев Рияз. Халкыбызның батырлыгы мәңгелек! 242
Мусина Камилә. Үргәагарым –газиз туган җирем 248
Низамова Диана. Туган җирем – изге җирем 263
Сабурова Аделя. Татар сәхнә әсәрләрендә Муса Җәлил образы 269

| | |
|---|---|
| Талипова Мәликә, Малыгина Злата. Чалып чигү-крест белән чигү-безенең гаиләнең традициясе | 276 |
| Усманова Мәликә, Алиева Айгөл. Акча дигән хикмәт бар | 281 |
| Фәзуллина Илина. Шигъри язмыш | 293 |
| Фәсхетдинова Диләрә Айдар кызы. Чәкчәкле сәйлән | 299 |
| Фәйзуллина Лилия. Укытучым- сезгә рәхмәтем (хикәя) | 311 |
| Хәбибуллина Әминә. Фатих Кәрим –рухы сынмас шагыйрь | 314 |
| Хайруллина Ясмина. Үткәннәргә күз салып, тарихны барлыйбыз | 319 |
| Хәйретдинова Әлфинә. Ташбилге авылы –изге җир | 329 |
| Хәсәнова Асылъяр. Кушамат - ябышкак исем | 337 |
| Хасаншина Азалия. Заманча татар модасы – нәрсә ул? | 346 |
| Хөрмәтуллина Айзилә. "Язучы-педагог Галимҗан Вәлиев иҗатында хат җанры-"өчпочмаклы солдат хатлары" | 354 |
| Шәйхетдинова Ләйсән Габдулла Баттал. Акланган исем | 363 |
| Яковлева Карина. Модалы чалбар (М.Җәлилгә ияреп) | 371 |

## Беренче бүлек. Укытучылар чыгышлары.

*Аменова Эльмира Зөфәр кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «22 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Аменова Диләрә Ильнар кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Муса Җәлил исемендәге 1 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең инглиз теле укытучысы*

### Татар теле һәм инглиз теле дәресләрендә мнемотехника алымнарын куллану

«Мнемотехника» яки «мнемоника» терминнары – хәтердә калдыру техникасы дигәнне аңлата. Мнемотехника – ул мәгълүматны хәтердә саклауны яхшырту һәм аны вакытында тергезеп, күрсәтү өчен кабул ителгән алымнар һәм системалар җыелмасы.

Мнемотехника бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Бу терминны Пифагор уйлап тапкан (б.э.к.  VI гасыр).

**Мнемотехника – истә калдыруны җиңеләйтә торган махсус ысуллар тупланмас** Аның алымнары хәтерне яхшыртырга, балаларның сөйләмен камилләштерергә һәм алган белемнәрен озак вакыт сакларга ярдәм итә.  Ул - җиңел юлдан авырга таба төзелә.

Мнемотехника үз эченә 3 аспектны тәшкил итә: тәэсир көче, кабатлау һәм ассоциация. Тәэсир көче – ул нинди дә булса күренешне (ул фильм, спектакль, тормыш ситуациясе, китап һ.б. булырга мөмкин) бер башка нәрсәгә дә игътибар бирмичә, хис-кичерешләр аркылы уздыру дигән сүз.  Кабатлау: алган мәгълүматны өлешләп 15 минут саен кабатлау тулы текстны өйрәнгәннән соң кабатлауга караганда күпкә эффективрак. Ассоциация – бер сүзне яки күренешне башка әйбер белән чагыштырма планда истә калдыру. Үзең уйлап тапкан ассоциацияләр күпкә көчлерәк. Татар теле һәм инглиз теле дәресләрендә укучылар сүзләрне күбрәк истә калдырсын өчен без дәресләребезне балаларга тәэсир итәрлек итеп, өйрәнелгән теманы блокларга бүлеп, 15 минут саен кабатлатып, балаларда ассоциацияләр уйлап табарлык иҗади фикерләүне үстерергә тиешбез.

**Беренче алым ул- Мнемашакмак** бер сүз яки сүзтезмә булырга мөмкин. «Төсле кәгазьдә уку» алымы. Кайбер сүзләрне укучылар икенче сүз итеп укыйлар. Иң күп очрый торган хата:

урам сүзен урман дип яки киресенчә уку. Моннан котылу өчен ике сүзне ике төстәге кәгазьгә язып аңлатырга мөмкин.

«урман сүзен яшел кәгазьгә, « урам» сүзен көрән кәгазьгә. Бу игътибар биреп укуны көчәйтә һәм күрү хәтерен үстерә. Сүзнең мәгънәсен аңларга ярдәм итә.

Кош һәм кыш сүзләре.

Төш һәм теш сүзләре.

**Икенче алым- Мнемоюллар** – ул бер җөмлә, шигырьнең бер юлы, мәкаль, табышмак та булырга мөмкин.

Юрган ябып куйган төсле

К-рга яткан ап-ак к-р.

Юрган,кыр, кар.

Бигрәк тәмле инде әбиемнең к-ймагы

Өстәлендә тора тагын тәмле, майлы к-ймагы.

Тәмле,Әби,коймак, майлы, каймак, өстәл.

Килеп җитте салкын к-ш,

Капкага кунды бер к-ш.

Салкын, кыш, капка, кош.

Кулны юдым, күл суында озак итеп

Сагынып торам баруымны тагын көтеп.

**3нче алым -мнемотаблицалар.**

Мондый таблицаларга тулы бер шигырь, я әкият, текст керергә мөмкин. Шигырь ятлаган вакытта алар аеруча нәтиҗәле: һәрбер сүз, сүзтезмәгә рәсем уйланыла, шул рәвешле шигырь тулысынча схемага салына. Әлбәттә, балага, бу схемага карап, шигырьне истә калдыру, сөйләү җиңелләшә. Әлеге схемалар монолог төзү өчен үзенчәлекле күргәзмә план булып тора, балаларга хикәянең төзелешен, эзлеклелеген, лексик-грамматик тулылыгын күзаллауга зур өлеш кертә, бәйләнешле сөйләм телен үстерүдә ярдәм итү чарасы булып кала.

Без үз дәресләребездә мнемотехника алымнарын актив кулланабыз.

Чөнки, мнемотехниканы куллану:

- истә калдыруны җиңеләйтә һәм хәтер мөмкинлекләрен арттыра;
-сөйләм һәм фикерләү эшчәнлеген үстерә;
-уку грамоталылыгын үстерә;
-текст өстендә эш вакытында укучыларда универсаль уку гамәлләре формалаша;
- балаларның иҗади белемен үстерә.

Мнемотаблицалар беренче чиратта башлангыч мәктәптә кулланыла дип санала, ләкин бу ысулны югары сыйныфларда да кулланырга мөмкин. Бүгенге көндә аны куллану өчен рәсемнәр

җыелмасы, техник чаралар, таблицалар, схемалар кулланырга мөмкинлекләр бар. Балалар рәсемнәрне җиңел һәм тиз истә калдыралар һәм текст белән эшләгәндә, сөйләм вакытында аларны искә төшерәләр.

Ахунова Гульнур Габдулловна,

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “инглиз телен тирәнтен өйрәнү белән 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесеңберенче категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы

Башлангыч мәктәп укучыларына туган телне өйрәтүнең заманча стратегияләре

Мәкалә укучыларны баланың сөйләм үсеше һәм башлангыч звенода педагогик процесс оештыру нигезләре белән таныштыра. Эштә төп төшенчәләр, балалар сөйләменең төрле яклары үсеше үзенчәлекләре, бурычлар, эшнең эчтәлеге һәм методикасы ачыла.

Сөйләм үсеше, сөйләмдә аралашу күнекмәләре, сүзлек запасы, аваз әйтелеше, монологик сөйләме, коммуникатив компетентлык, методик алымнар.

Туган телне үзләштерү һәм сөйләм үсеше башлангыч сыйныфларда бала өчен иң мөһим урында тора. Үз эшемдә мин баланың сөйләм үсеше логикасын һәм башлангыч звенода педагогик процесс оештыруны төзергә тырыштым. Эштә төп төшенчәләр, балалар сөйләменең төрле яклары үсеше үзенчәлекләре, бурычлар, эшнең эчтәлеге һәм методикасы ачыла.

Балаларның сөйләм үсеше методикасы педагогика фәннәре составына керә. Ул бер үк вакытта рус теле методикасы һәм мәктәп дидактикасы тармагы булып тора, шулай ук гамәли фәннәргә карый, чөнки балаларны үстерү һәм тәрбияләүнең гамәли мәсьәләләрен хәл итә. Аның өйрәнү предметы булып балаларның туган телне һәм сөйләм аралашу күнекмәләрен үзләштерү процессы тора. Ул башлангыч звенодагы балаларда дөрес сөйләм һәм сөйләм аралашу күнекмәләрен формалаштыруга юнәлдерелгән педагогик эшчәнлек закончалыкларын өйрәнә.

Татар телен укытуның заманча стратегиясе һәм тактикасы.

Сөйләм үсеше аң үсеше, әйләнә-тирә дөньяны танып белү, гомумән шәхес үсеше белән тыгыз бәйләнгән. Башлангыч белем бирү учреждениесендә балаларны укыту һәм үстерү буенча төп урыннарның берсен биләп тора. Бу эшнең актуальлеге балачак педагогикасы һәм психологиясенең әйдәп баручы нигезләмәләре белән раслана, аларда кече мәктәп укучыларының яше, сөйләм үсеше өчен үз әһәмияте буенча уникаль, чөнки баланың башлангыч звенода вакытында сөйләм үсеше аның шәхесенең уңышлы үсеше өчен нигез булып тора.

Башлангыч сыйныф укучыларында татар телен үстерү бурычлары.

Сүзлек запасын баету

Башлангыч сыйныфларда телнең төп сүзлек фондыннан мәктәпкәчә учреждениеләрдән алынган сүзләр үзләштерелә. Аларны сайлап алу тирә-юньдәгеләрнең сүзлегенә, баланың әйләнә-тирә дөньяда ориентирлашуына һ.б. бәйле. Һәр сыйныфта сүзлек эше программасы бар, ул укытучыны иң беренче чиратта баланың тирә-юньдәгеләр белән нормаль аралашуы өчен кирәк. Татар телен өйрәнү аерым сүзләрне истә калдырудан, дөрес әйтүдән һәм аларны җөмләдә куллана белүдән башлана. Материал күрсәтмә материал (рәсемнәр, уенчыклар, муляжлар), күзаллау әсбаплары, мимика, ишарәләр һәм тән хәрәкәтләре ярдәмендә аңлатыла.

Сөйләмнең грамматик ягын формалаштыру

Сүзлек тел өчен төзелеш материалы булып тора. Грамматика сүзләрнең үзгәрү нормаларын һәм аларның җөмләдә тоташу ысулларын билгели. Моннан тыш, ул телнең конструктив модельләрен билгели (сүз ясагыч, сүз үзгәртүче). Бала тирә-юньдәгеләрдән грамматик яктан бизәлгән сөйләм ишетә. Ишеткәннәрен аңлап, ул грамматик төзелешне үзләштерә, тел модельләрен белә. Мин балаларның төрле сөйләм практикасын оештырам, шул исәптән телне өйрәтү системасына балаларның игътибарын алар өчен иң катлаулы һәм кирәкле конструкцияләргә җәлеп итә торган, туган телнең морфологиясе һәм синтаксисының билгеле кагыйдәләрен ныгыта торган күнегүләр кертәм (хыялланабыз, ...күз алдына китерегез, нәрсә булыр иде..., нәрсә җитми?, исемнәрне килешләр белән төрләндерү күнегүләре; мин башлыйм, ә син тәмамла!" киң таралган җөмләләрне куллану күнегүләре һ.б.).

Балаларны яңа грамматик формалар белән таныштырам, иң авыр формаларны дөрес куллануны ныгытам, ахыр чиктә грамматик яктан дөрес сөйләү гадәтен үстерәм.

Сөйләмнең тавыш культурасын тәрбияләү

Беренчедән, бала телнең тавыш төзелешен, дөрес тавыш әйтелешен үзләштерергә тиеш. Бала, үрнәк алып һәм өйрәнеп, максатчан рәвештә (Өлкәннәр тәэсирендә) сүзләрдә басым системасын, туган телнең интонацион төзелешен, сүзләрнең әйтелешен үзләштерә. Баланы сөйләм аралашу процессында үз-үзен тотыш культурасына өйрәтү, дөрес сөйләм манерасын тотрыклы итү (кунакчыл тон, игътибар позасы һәм әңгәмәдәшкә юнәлтелгән караш, үзеңне яңа җәмгыятьтә тоту осталыгы һ.б.) бик мөһим.

Сөйләшү (диалогик) сөйләм формалаштыру

Балаларның үзләренә мөрәҗәгать ителгән сөйләмне тыңлау һәм аңлау, сөйләшүне дәвам итү, сорауларга җавап бирү һәм сорау бирү күнекмәләре. Бәйләнешле сөйләм дәрәҗәсе баланың сүзлеге торышына һәм аның телнең грамматик төзелешен никадәр үзләштерүенә бәйле. Сөйләшү сөйләме, әңгәмәдәш белән аралашу буларак, шулай ук әңгәмә вакытында мәдәни яктан үз-үзеңне тота белүне, тактик, тыйнак булуны күздә тота. Мин балаларның сөйләшү эчтәлегенә тәэсир итеп, бер-берсеннән яңа нәрсә белергә теләкләрен уятам. Балаларга, өлкәннәрдән аларның хезмәте, ял итүләре һ.б. турында сорасаң, күп кызыклы нәрсәләр белергә мөмкин, дип әйтәм.

Сөйләүгә (монологик сөйләмгә) өйрәтү

Монологик сөйләмне үзләштерү бик мөһим. Бәйләнешле сөйләм фикерләү формалашуга ярдәм итә. Моннан тыш, баланың хикәясе аның сүз запасын, фразалар төзү, эчтәлекне композицион рәвештә рәсмиләштерү осталыгын ачыкларга ярдәм итә. Балаларда һәрвакытта да күрсәтелмәгән сөйләм хикәяләрен тыңлау, аларны аңлау, тыңланганны кабатлау осталыгы формалашам. Коммуникатив компетентлыкларны үстерү - “актив тыңлау һәм сөйләү күнекмәләрен үстерү”, диалог аралашу күнекмәләрен, сөйләм, хикәя күнекмәләрен үстерү, бәхәскә керү, үз карашыңны яклау, нәтиҗәләр ясау һәм мәгълүматны гомумиләштерү. Коммуникатив технологияләр нигезендә төрле дәресләр формаларын кулланам: уен – дәресләр, рольле, эшлекле, ярыш дәресләре; текстны комплекслы анализлау, аның белән иҗади эшләү, үз текстларын булдыру дәресләре; билгеле бер тема буенча вербаль карта төзү дәресләре; лэпбуклар төзү дәресләре, проектларны яклау дәресләре, виртуаль экскурсия дәресләре. Укучыларга дәресләрдә эшчәнлекнең төрле формалары ошый.

Нәфис әдәбият белән танышу

Башлангыч сыйныфларда балалар әдәбиятының иң яхшы әсәрләре белән таныштырам. Укучыларда кайбер элементар күнекмәләрне формалаштырам: сәнгать әсәрләрен тыңлау һәм аңлау, төп геройлар турында фикерләрләү. Балалар эчтәлеге буенча кечкенә булган шигырьләрне ятларга һәм аңлаешлы итеп укырга өйрәнергә тиеш. Бу бурычларның барысы да балаларның әхлакый һәм эстетик хисләрен тәрбияләү белән тыгыз бәйләнгән.

Балаларны урта звенога әзерләү

Башлангыч сыйныфларда баланың сөйләмен үстерү буенча педагогик эш аны урта звенода укырга әзерли, анда дөрес сөйләм, башкаларны тыңлау, аларның сөйләменең эчтәлегенә керү, кирәк булганда иптәшенең җавабын тулыландыру яки төзәтү кирәк. Сөйләм балаларның анализы предметы булып тора, бу аларга зур кыенлык тудыра. Алга таба мәгълүматлар аңлашылсын өчен түбәндәге сыйфатлар зур әһәмияткә ия: педагог әйткәннәрне ишетү, үз фикерләрен киң таралган җөмләләрдә, кечкенә бәйләнешле хикәяләрдә ачык, төгәл, грамматик яктан дөрес белдерү. Бу күнекмәләр 3-4 сыйныфларда формалаша.

Шулай итеп, сөйләм үсешенең төп бурычларын белү формаль таләп түгел, ул башлангыч сыйныфларда эшне дөрес оештыру өчен кирәк. Һәр бирем эчендә коммуникатив-сөйләм күнекмәләре формалашу нигезендә яткан төп моментлар аерылып тора. Сүзлек үсешендә-сүзнең мәгънә ягы өстендә эш, монологик сөйләмдә-сөйләмнең эчтәлеген сайлап алу, сүзләрне, җөмләләрне тоташтыру ысулларын үзләштерү; диалогик сөйләмдә – әңгәмәдәшне тыңлау һәм аңлау, тирә-юньдәгеләр белән аралашу, гомуми сөйләшүдә катнашу күнекмәләре. Башлангыч сыйныфлар программасы урта звенодагы балалар үсеше өчен перспективалар тудыра. Ул югары сыйныфларда рус һәм туган тел программасы белән дәвамлы бәйләнешләргә ия. Башлангыч

сыйныф балаларында сөйләм сыйфатлары формалаша, алар урта звенода алга таба үсеш ала. Бай сүзлек, үз фикерләрен ачык һәм төгәл белдерә белү, тел чараларыннан сайлап һәм аңлы рәвештә файдалану татар телен уңышлы өйрәтү һәм барлык уку фәннәрен үзләштерү өчен төп шарт булып тора. Бүгенге көндә "Ак Бүредән татар телен өйрәнәбез" анимацион сериалы алдынгы һәм традицион укыту методикаларын, шулай ук заманча мультипликацион һәм компьютер технологияләрен берләштерде. Мультфильмның төп герое кечкенә бүре Ак Бүре һәм аның дуслары балаларны татар сүзләренә һәм әйтемнәренә өйрәтә.

Балаларны татар һәм рус телләренә өйрәтүнең тел киңлеген оештыруның заманча дәрәҗәсен тәэмин итү өчен яңа буын мультимедия ресурслары эшләнде: татар язучылары әсәрләре буенча татар телендә яңа мультфильмнар татар теленә тәрҗемә ителде.

Баланың иҗади һәм социаль-шәхси үсеше, татар телен, татар халкының милли традицияләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә кызыксыну уяту максатларында мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен татар телендә “Әкият иленда” (Әкиятләр дөньясында), “Шаян” телевизион тапшырулар циклы эшләнде.

Кулланылган әдәбият.

1. Замалетдинова З.И. Мәдәни белем бирү мөхитендә кече мәктәп укучыларының этникара толерантлыгын формалаштыру: Казан, 2015г.

2. Харисова Ч.М. Татарча әйтелешкә өйрәтү буенча күнегүләр: Казан:
Мәгариф, 1999.

Ялалов Ф.Г. Милли белем бирүнең барлыкка килүе һәм үсеше: Казан: Мәгариф, 2002.

*Ахунова Гульнур Габдулловна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “инглиз телен тирәнтен өйрәнү белән 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы*

**Башлангыч мәктәп укучыларына туган телне өйрәтүнең заманча стратегияләре**

Мәкалә укучыларны баланың сөйләм үсеше һәм башлангыч звенода педагогик процесс оештыру нигезләре белән таныштыра. Эштә төп төшенчәләр, балалар сөйләменең төрле яклары үсеше үзенчәлекләре, бурычлар, эшнең эчтәлеге һәм методикасы ачыла.

Сөйләм үсеше, сөйләмдә аралашу күнекмәләре, сүзлек запасы, аваз әйтелеше, монологик сөйләме, коммуникатив компетентлык, методик алымнар.

Туган телне үзләштерү һәм сөйләм үсеше башлангыч сыйныфларда бала өчен иң мөһим урында тора. Үз эшемдә мин баланың сөйләм үсеше логикасын һәм башлангыч звенода педагогик процесс оештыруны төзергә тырыштым. Эштә төп төшенчәләр, балалар сөйләменең төрле яклары үсеше үзенчәлекләре, бурычлар, эшнең эчтәлеге һәм методикасы ачыла.

Балаларның сөйләм үсеше методикасы педагогика фәннәре составына керә. Ул бер үк вакытта рус теле методикасы һәм мәктәп дидактикасы тармагы булып тора, шулай ук гамәли фәннәргә карый, чөнки балаларны үстерү һәм тәрбияләүнең гамәли мәсьәләләрен хәл итә. Аның өйрәнү предметы булып балаларның туган телне һәм сөйләм аралашу күнекмәләрен үзләштерү процессы тора. Ул башлангыч звенодагы балаларда дөрес сөйләм һәм сөйләм аралашу күнекмәләрен формалаштыруга юнәлдерелгән педагогик эшчәнлек закончалыкларын өйрәнә.

Татар телен укытуның заманча стратегиясе һәм тактикасы.

Сөйләм үсеше аң үсеше, әйләнә-тирә дөньяны танып белү, гомумән шәхес үсеше белән тыгыз бәйләнгән. Башлангыч белем бирү учреждениесендә балаларны укыту һәм үстерү буенча төп урыннарның берсен биләп тора. Бу эшнең актуальлеге балачак педагогикасы һәм психологиясенең әйдәп баручы нигезләмәләре белән раслана, аларда кече мәктәп укучыларының яше, сөйләм үсеше өчен үз әһәмияте буенча уникаль, чөнки баланың башлангыч звенода вакытында сөйләм үсеше аның шәхесенең уңышлы үсеше өчен нигез булып тора.

Башлангыч сыйныф укучыларында татар телен үстерү бурычлары.

**Сүзлек запасын баету**

Башлангыч сыйныфларда телнең төп сүзлек фондыннан мәктәпкәчә учреждениеләрдән алынган сүзләр үзләштерелә. Аларны сайлап алу тирә-юньдәгеләрнең сүзлегенә, баланың әйләнә-тирә дөньяда ориентирлашуына һ.б. бәйле. Һәр сыйныфта сүзлек эше программасы бар, ул укытучыны иң беренче чиратта баланың тирә-юньдәгеләр белән нормаль аралашуы өчен кирәк. Татар телен өйрәнү аерым сүзләрне истә калдырудан, дөрес әйтүдән һәм аларны җөмләдә куллана белүдән башлана. Материал күрсәтмә материал (рәсемнәр, уенчыклар, муляжлар), күзаллау әсбаплары, мимика, ишарәләр һәм тән хәрәкәтләре ярдәмендә аңлатыла.

**Сөйләмнең грамматик ягын формалаштыру**

Сүзлек тел өчен төзелеш материалы булып тора. Грамматика сүзләрнең үзгәрү нормаларын һәм аларның җөмләдә тоташу ысулларын билгели. Моннан тыш, ул телнең конструктив модельләрен билгели (сүз ясагыч, сүз үзгәртүче). Бала тирә-юньдәгеләрдән грамматик яктан бизәлгән сөйләм ишетә. Ишеткәннәрен аңлап, ул грамматик төзелешне үзләштерә, тел модельләрен белә. Мин балаларның төрле сөйләм практикасын оештырам, шул исәптән телне өйрәтү системасына балаларның игътибарын алар өчен иң катлаулы һәм кирәкле конструкцияләргә җәлеп итә торган, туган телнең морфологиясе һәм синтаксисының билгеле кагыйдәләрен ныгыта торган күнегүләр кертәм (хыялланабыз, ...күз алдына китерегез, нәрсә

булыр иде..., нәрсә җитми?, исемнәрне килешләр белән төрләндерү күнегүләре; мин башлыйм, ә син тәмамла!" киң таралган җөмләләрне куллану күнегүләре һ.б.).

Балаларны яңа грамматик формалар белән таныштырам, иң авыр формаларны дөрес куллануны ныгытам, ахыр чиктә грамматик яктан дөрес сөйләү гадәтен үстерәм.

**Сөйләмнең тавыш культурасын тәрбияләү**

Беренчедән, бала телнең тавыш төзелешен, дөрес тавыш әйтелешен үзләштерергә тиеш. Бала, үрнәк алып һәм өйрәнеп, максатчан рәвештә (Өлкәннәр тәэсирендә) сүзләрдә басым системасын, туган телнең интонацион төзелешен, сүзләрнең әйтелешен үзләштерә. Баланы сөйләм аралашу процессында үз-үзен тотыш культурасына өйрәтү, дөрес сөйләм манерасын тотрыклы итү (кунакчыл тон, игътибар позасы һәм әңгәмәдәшкә юнәлтелгән караш, үзеңне яңа җәмгыятьтә тоту осталыгы һ.б.) бик мөһим.

**Сөйләшү (диалогик) сөйләм формалаштыру**

Балаларның үзләренә мөрәҗәгать ителгән сөйләмне тыңлау һәм аңлау, сөйләшүне дәвам итү, сорауларга җавап бирү һәм сорау бирү күнекмәләре. Бәйләнешле сөйләм дәрәҗәсе баланың сүзлеге торышына һәм аның телнең грамматик төзелешен никадәр үзләштерүенә бәйле. Сөйләшү сөйләме, әңгәмәдәш белән аралашу буларак, шулай ук әңгәмә вакытында мәдәни яктан үз-үзеңне тота белүне, тактик, тыйнак булуны күздә тота. Мин балаларның сөйләшү эчтәлегенә тәэсир итеп, бер-берсеннән яңа нәрсә белергә теләкләрен уятам. Балаларга, өлкәннәрдән аларның хезмәте, ял итүләре һ.б. турында сорасаң, күп кызыклы нәрсәләр белергә мөмкин, дип әйтәм.

**Сөйләүгә (монологик сөйләмгә) өйрәтү**

Монологик сөйләмне үзләштерү бик мөһим. Бәйләнешле сөйләм фикерләү формалашуга ярдәм итә. Моннан тыш, баланың хикәясе аның сүз запасын, фразалар төзү, эчтәлекне композицион рәвештә рәсмиләштерү осталыгын ачыкларга ярдәм итә. Балаларда һәрвакытта да күрсәтелмәгән сөйләм хикәяләрен тыңлау, аларны аңлау, тыңланганны кабатлау осталыгы формалашам. Коммуникатив компетентлыкларны үстерү - “актив тыңлау һәм сөйләү күнекмәләрен үстерү”, диалог аралашу күнекмәләрен, сөйләм, хикәя күнекмәләрен үстерү, бәхәскә керү, үз карашыңны яклау, нәтиҗәләр ясау һәм мәгълүматны гомумиләштерү. Коммуникатив технологияләр нигезендә төрле дәресләр формаларын кулланам: уен – дәресләр, рольле, эшлекле, ярыш дәресләре; текстны комплекслы анализлау, аның белән иҗади эшләү, үз текстларын булдыру дәресләре; билгеле бер тема буенча вербаль карта төзү дәресләре; лэпбуклар төзү дәресләре, проектларны яклау дәресләре, виртуаль экскурсия дәресләре. Укучыларга дәресләрдә эшчәнлекнең төрле формалары ошый.

**Нәфис әдәбият белән танышу**

Башлангыч сыйныфларда балалар әдәбиятының иң яхшы әсәрләре белән таныштырам. Укучыларда кайбер элементар күнекмәләрне формалаштырам: сәнгать әсәрләрен тыңлау һәм

аңлау, төп геройлар турында фикерләрләү. Балалар эчтәлеге буенча кечкенә булган шигырьләрне ятларга һәм аңлаешлы итеп укырга өйрәнергә тиеш. Бу бурычларның барысы да балаларның әхлакый һәм эстетик хисләрен тәрбияләү белән тыгыз бәйләнгән.

**Балаларны урта звенога әзерләү**

Башлангыч сыйныфларда баланың сөйләмен үстерү буенча педагогик эш аны урта звенода укырга әзерли, анда дөрес сөйләм, башкаларны тыңлау, аларның сөйләменең эчтәлегенә керү, кирәк булганда иптәшенең җавабын тулыландыру яки төзәтү кирәк. Сөйләм балаларның анализы предметы булып тора, бу аларга зур кыенлык тудыра. Алга таба мәгълүматлар аңлашылсын өчен түбәндәге сыйфатлар зур әһәмияткә ия: педагог әйткәннәрне ишетү, үз фикерләрен киң таралган җөмләләрдә, кечкенә бәйләнешле хикәяләрдә ачык, төгәл, грамматик яктан дөрес белдерү. Бу күнекмәләр 3-4 сыйныфларда формалаша.

Шулай итеп, сөйләм үсешенең төп бурычларын белү формаль таләп түгел, ул башлангыч сыйныфларда эшне дөрес оештыру өчен кирәк. Һәр бирем эчендә коммуникатив-сөйләм күнекмәләре формалашу нигезендә яткан төп моментлар аерылып тора. Сүзлек үсешендә-сүзнең мәгънә ягы өстендә эш, монологик сөйләмдә-сөйләмнең эчтәлеген сайлап алу, сүзләрне, җөмләләрне тоташтыру ысулларын үзләштерү; диалогик сөйләмдә – әңгәмәдәшне тыңлау һәм аңлау, тирә-юньдәгеләр белән аралашу, гомуми сөйләшүдә катнашу күнекмәләре. Башлангыч сыйныфлар программасы урта звенодагы балалар үсеше өчен перспективалар тудыра. Ул югары сыйныфларда рус һәм туган тел программасы белән дәвамлы бәйләнешләргә ия. Башлангыч сыйныф балаларында сөйләм сыйфатлары формалаша, алар урта звенода алга таба үсеш ала. Бай сүзлек, үз фикерләрен ачык һәм төгәл белдерә белү, тел чараларыннан сайлап һәм аңлы рәвештә файдалану татар телен уңышлы өйрәтү һәм барлык уку фәннәрен үзләштерү өчен төп шарт булып тора. Бүгенге көндә "Ак Бүредән татар телен өйрәнәбез" анимацион сериалы алдынгы һәм традицион укыту методикаларын, шулай ук заманча мультипликацион һәм компьютер технологияләрен берләштерде. Мультфильмның төп герое кечкенә бүре Ак Бүре һәм аның дуслары балаларны татар сүзләренә һәм әйтемнәренә өйрәтә.

Балаларны татар һәм рус телләренә өйрәтүнең тел киңлеген оештыруның заманча дәрәҗәсен тәэмин итү өчен яңа буын мультимедия ресурслары эшләнде: татар язучылары әсәрләре буенча татар телендә яңа мультфильмнар татар теленә тәрҗемә ителде.

Баланың иҗади һәм социаль-шәхси үсеше, татар телен, татар халкының милли традицияләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә кызыксыну уяту максатларында мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен татар телендә “Әкият иленда” (Әкиятләр дөньясында), “Шаян” телевизион тапшырулар циклы эшләнде.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Замалетдинова З.И. Мәдәни белем бирү мөхитендә кече мәктәп укучыларының этникара толерантлыгын формалаштыру: Казан, 2015г.

2. Харисова Ч.М. Татарча әйтелешкә өйрәтү буенча күнегүләр: Казан:
Мәгариф, 1999.

3. Ялалов Ф.Г. Милли белем бирүнең барлыкка килүе һәм үсеше: Казан: Мәгариф, 2002.

*Әхмәтова Миләүшә Индус кызы,*
*Әхмәтҗанова Тәскирә Фатыйх кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесең туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## Татар теле дәресенең технологик картасы(5 нче сыйныф)
## КЕРЕШ

Икенче буын федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре мәгариф системасы алдында яшь буынга белем бирү эчтәлегенә, аның  гына түгел, ә дәресне планлаштыруга, дәрес структурасына, аны формалаштыруга   да үзгәрешләр кертә.

Бүгенге укытучылар дәресне планлаштырган вакытта, оештыру этапларына нык игътибар биреп, аларны төрләндерү ягында торалар. Бу – бер яктан караганда, куанычлы хәл, икенче яктан исә дәреснең структур өлешләренең конкрет билгеләнгән тәртибе, калыбы булмау шактый буталчыклыкка китерә. Әлеге күренеш заманча дәреснең технологик картасын төзүдә дә чагылыш таба. Шуңа күрә бу эштә билгеле бер кагыйдәләрне истә тотып, технологик картаның дөрес һәм нәтиҗәле, уңышлы дип саналган калыбына тукталып, уңай бер вариантын сайлап алу сорала. Бигрәк тә татар теле һәм татар әдәбияты дәресләре буенча эшләнгән технологик карта үрнәкләренең аз булуы мәсьәләнең актуальлеген арттыра.

**Максат һәм бурычлар.** Проект эшебезнең төп максаты булып проблеманы теоретик яктан өйрәнеп, 5 нче сыйныфның татар төркемендә татар теле  буенча “Омонимнар” темасына дәреснең технологик картасын төзү һәм гамәлгә кертү тора.

**Проектның бурычлары.**

1. Тема буенча фәнни-методик әдәбиятны уку, анализлау, кирәкле өлешләрне сайлап алу.

2. 5 нче сыйныфның татар төркемендә “Омонимнар”  темасына дәреснең технологик картасын төзү һәм гамәлгә кертүгә әзерләү.

3. Курсларда алган белемнәрне гомумиләштерү, тема буенча ФДБС таләп иткән планлаштырылган нәтиҗәләр, укучы һәм укытучы эшчәнлеген технологик картада күрсәтү.

**Тикшеренү объекты** – дәресләр оештыруда технологик карта.

**Тикшеренү предметы** – дәреснең технологик картасы

**Метод һәм алымнар**. Өйрәнелә торган материалның характерына карап, тикшеренүнең төп методы булып эзләнү методы сайланды. Әлеге метод үз эченә фәнни һәм методик әдәбиятны туплау һәм анализлау, фактик материалны өйрәнү, педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, классификацияләү кебек эш алымнарын берләштерә.

**Проектның фәнни-гамәли әһәмияте.**

Проект эшендә федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә нигезләнеп укыту-тәрбия процессын оештыру, бу эшләрне оештыруның яңа формалары, төрле чаралар куллану турында мәгълүмат тупланган, методик күрсәтмәләр китерелгән. Тикшеренү барышында җыелган кайбер материаллар укытучылар өчен методик кулланма язганда ярдәм итәргә мөмкин. Шулай ук хезмәтнең фәнни-гамәли әһәмияте китерелгән нәтиҗә һәм күзаллауларның татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы курслары буенча семинар дәресләргә әзерләнүче студентларга чыганак булып торуы белән аңлатыла. Хезмәттә тупланган материалларны мәктәп укытучыларына дәресләрне оештыру буенча методик ярдәмлек буларак тәкъдим итеп була.

**Проектны гамәлгә ашыруда катнашучылар:** татар теле һәм әдәбияты укытучылары.

**Проект эшеннән көтелгән нәтиҗә:**

1. Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче балаларга “Омонимнар” темасын өйрәтү өчен технологик карта төзү.
2. Гамәлгә кертү өчен әзерләү.
3. Сынап карау.
4. Уку-укыту эшчәнлегендә омонимнарның әһәмиятен ачыклау.
5. Күнегүләр системасын булдыру.
6. Мөстәкыйль рәвештә технологик карталар язу күнекмәсе булдыру.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### Дәресләрнең технологик картасы – дәресне сыйфатлы һәм нәтиҗәле итеп укытуны тәэмин итәрдәй методик эшчәнлекнең заманча формасы

Федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә кертү гомуми белем бирү программасының үзләштерелүенә юнәлтелгән. Бүгенге укытучы һәр дәрескә әзерләнгәндә үз алдына яңа бурыч куя, ягъни планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү өчен ул тиешле шартлар тудыра. Федераль дәүләт белем бирү стандартында планлаштырылган нәтиҗәләр өч төрле бирелә: шәхескә кагылышлы, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләре. Бөтен уку эшчәнлеге системалы-эшчәнлекле юнәлешкә корылырга тиеш. Бу - Федераль дәүләт белем бирү стандарты

таләбе. Укучы шәхесенең үсешендә универсаль уку гамәлләренең үзләштерелүе нигез итеп алына. Укучы уку материалын пассив кабул иткәндә үсә алмый. Укучының шәхси эшчәнлеге - киләчәктә аның мөстәкыйльлеге формалашуның нигезе. Димәк, белем бирүнең бурычы булып баланы эшчәнлеккә җәлеп итәрлек шартлар оештыру тора.

Федераль дәүләт белем бирү стандарты яңа төшенчә кертә – ул уку ситуациясе. Яңа таләпләр буенча укытучы алдына түбәндәге бурыч куела: уку эшчәнлегенең структур берәмлекләре буларак, уку ситуацияләрен тудырырга өйрәнү, уку бурычларын уку ситуацияләренә күчерә белү.

Уку ситуациясен тудыру өчен түбәндәге алымнар кулланылырга мөмкин: каршылыклы фактлар, теоретик белемнәрне укучы алдына кую; яшәеш турында күзаллауны ачып салу һәм фәнни фактларны кую; “якты тап”, “актуальлек” алымнарын куллану. Уку ситуациясе булып таблицалар, укылган текстның эчтәлеге буенча диаграмма яки графиклар, билгеле кагыйдәләр буенча алгоритм төзү; төрле биремнәр үтәү; практик эшләр тора.

Заманча дәрес структурасы хәрәкәтчән булырга, анда максатчан эшчәнлеккә берләштерелгән эш төрләре тупланырга тиеш. Мөһим момент – укытучы укучының кирәкле юнәлештәге инициативасын хуплый һәм укучының үз эшчәнлеген оештыруына өстенлек бирә.

“Технологик карта” төшенчәсе педагогика фәненә төгәл, техника җитештерү өлкәләреннән килеп керә. Технологик карта – җитештерелгән эшләнмәнең эшкәртелү процессын, составын, чималын, технологик режимын, коралларын, җитештерелү вакытын, җитештерүченең квалификациясен һәм башкаларны тасвирлаган технологик документациянең бер формасы. Дәреснең технологик картасы – дәресне сыйфатлы һәм нәтиҗәле итеп укытуны тәэмин итәрдәй методик эшчәнлекнең заманча формасы, дәрес сценариенең гомуми-график формадагы бирелеше, аны проектлаштыруның нигезе, укытучының аерым эшләү методларын тәкъдим итү чаралары, Федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләре буенча төп белем бирү программасында каралган нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеге, укучы белән укытучының планлаштырылган педагогик хезмәттәшлеге. Технологик карта – нинди дә булса эшне үтәргә кирәк булган мәгълүмат һәм җитәкче күрсәтмәләрне үз эченә алган стандартлаштырылган документ. [14]

Дәреснең технологик картасы:

дәресне әзерләү-эшкәртү шартларын, аны үткәрүгә этәргеч булган сәбәпләрне; дәрес үткәрү өчен кирәк булган укыту чараларын;

укытучы һәм укучыларның эшчәнлек төрләрен;

теманы, дәрес тибын, максатларны, җиһазлауны, метод һәм алымнарны;

Федераль дәүләт белем бирү стандарты буенча планлаштырылган нәтиҗәләрне үз эченә алган өлешләрдән торган схема-таблицаны тәшкил итә.

Икенче төрле әйткәндә, технологик карта ул – дәрес барышының гомуми-график чагылышы. [6,14-16.]

Технологик карта:

теманың исеме (сәгатьләр саны белән);

уку-укыту эчтәлеген үзләштерү максаты;

планлаштырылган нәтиҗәләр;

метапредмет бәйләнешләр һәм аларны оештыру киңлеге (эш формалары һәм ресурслар);

теманың төп төшенчәләре;

теманы өйрәнү технологиясе (һәр дәрес этабында максат, көтелгән нәтиҗәләр, гамәли һәм диагностик биремнәр);

көтелгән нәтиҗәләргә ирешү дәрәҗәсен ачыклау өчен каралган контроль биремнәрдән тора.[5, 44-45 б.]

Дәреснең технологик картасы таблица рәвешендә төзелә. Дәрес этаплары вертикаль буенча языла:

1. Оештыру. Эшкә кызыксыну тудыру.
2. Актуальләштерү. Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру .
3. Уку мәсьәләсен кую.
4. Уку мәсьәләсен чишү.
5. Яңа белемнәрне ныгыту.
6. Яңа белемнәрне мөстәкыйль куллану һәм тикшерү.
7. Йомгаклау.

Горизонталь буенча һәр этапның бурычлары, методлар, формалар, укучы һәм укытучы эшчәнлеге, формалаштырылырга тиешле универсаль уку гамәлләре языла, шуңа күрә ул яңа стандартларга туры китерелеп, дәреснең билгеле бер моделе, схемасы, планы рәвешен ала. Укытучы үзенә җайлы форманы сайлап ала һәм аны эш тәҗрибәсендә куллана.

**ФДББС буенча дәрес структурасы (төзелеше)**

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары кысаларында дәрескә әзерләнгәндә укытучы нәрсәләрне исәптә тотарга тиеш соң? Иң беренче дәрес этапларының конструкциясен төзү мөһим.

-  Уку материалының темасын
-  Теманың дидактик максатын
-  Дәреснең дидактик максатының тибын
-  Дәрес тибын ачыклау:

A. Яңа белемнәрне өйрәнү һәм беренчел ныгыту

B. Яңа белемнәрне ныгыту

C. Белем, осталык һәм күнекмәләрне комплекслы куллану

D. Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру

E. Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләрен тикшерү, бәяләү, төзәтмәләр кертү.

- Дәрес структурасын уйлау
- Дәресне җиһазлау
- Уку материалының эчтәлеген сайлау
- Укыту методларын сайлау
- Педагогик эшчәнлекне оештыруның формаларын сайлау
- Белем, осталык һәм күнекмәләрне бәяләү
- Дәреснең рефлексиясе.

Һәр дәреснең үз структурасы бар.

***Яңа тема өйрәтү дәресенең якынча структурасы***

1) Тема, максат, бурычлар билгеләү. Ике тема бирү үзен аклаячак: теоретик материал өйрәнү буенча һәм тәрбияви, үстерүче максатлардан чыгып лексик тема алына. Мәсәлән, сыйфат дәрәҗәләре. Кешедә барысы да матур булырга тиеш.

2) Оештыру моменты (эшчәнлеккә әзерлек).

Максаты: укучыларны төп эшчәнлеккә җәлеп итү. Сыйныфта уңай эмоциональ атмосфера булдыру.

Эш алымнары: укытучының изге теләкләре, бүгенге эш өчен кирәкле сыйфатларны билгеләү, девиз, эпиграф белән таныштыру, үрнәк буенча өй эшен мөстәкыйль тикшерү h.б. (1, 2 минут).

3) Белемне актуальләштерү.

Максат: бүгенге темага нигез булырлык итеп, үтелгәнне кабатлау, уку чыларга авыр тоелган урыннарны ачыклау (4, 5 минут).

4) Проблемалы ситуация булдыру. Уку мәсьәләсен кую.

Максат: авырлыкларны ачыклау (Ни өчен шундый сорау килеп туды? Без әле нәрсәне белмибез?), дәрес максатын я теманы төп сорау кебек итеп билгеләү (4, 5 минут).

Уку мәсьәләсен кую буенча проблеманы ачыклауга юнәлтелгән, темага алып килгән әңгәмә үткәрү.

5) Яңа тема өйрәнү.

Максат: мәсьәләне телдән чишү юлларын бергәләп эзләү, анализлау (7, 8 минут).

Эш төрләре: төрле фикерләр тудырган, проблеманы хәл итүгә юнәлтелгән әңгәмә, төркемләп, парлап эшләү.

6) Ныгыту.

Максат: бергәләп, чиратлап яңа белемне кабатлау, терәк сигнал формасында теркәү (4, 5 минут).

Эш төрләре: фронталь эш, парлы эш, продуктив күнегүләр башкару.

7) Үзаллы эш.

Максат: һәр укучыны теманы аңлавына, күнегүләр башкара алуына ышандыру (4, 5 минут).

Эш төрләре: 2, 3 зур булмаган язма эш башкару, укучыларның өлге буенча үзләрен тикшереп барлавы.

Яңы теманы кабатлау, ныгыту.

Укучыларга яңа тема буенча эш тәкъдим ителә (1 күнегү), алга таба шушы ук күнегү алдан үтелгән темалар белән бәйләп ныгытыла (7, 8 минут).

8) Рефлексия (дәрес нәтиҗәсе).

Максат: укучыларның үз уку эшчәнлеген, сәләтләрен дөрес бәяләү, башкаларның эшчәнлеген күрә һәм дөрес анализлый белүе (2, 3 минут).

Сораулар: Нинди максатлар куйган идек? Максатларга ирештекме? Ничек? Нәтиҗәләр нинди? Тагы да нәрсәләр эшләргә тиешсез? Бүгенге белемне тормышта кайда һәм ничек кулланырга мөмкин? Синең бигрәк тә кайсы эшең уңышлы килеп чыкты? Алга таба нәрсә өстендә эшләргә кирә

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының 5 нче сыйныфында “Омонимнар” темасына технологик карта (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен)

### 2.1. Укыту-тәрбия процессында технологик карта куллануның әһәмияте

Технологик карта ул дәрес проекты түгел, ә проектлаштыруның нигезе генә. Ул яңа стандартлар белән бәйле түгел. Ул ФДББС кергәнче үк файдаланылган. Бүгенге технологик картага ФДББСтан алынган планлаштырылган нәтиҗәләр, универсаль уку гамәлләре кертелә. “Шуңа күрә ул яңа стандартларга туры китерелеп, дәреснең билгеле бер моделе, схемасы, планы рәвешен ала”,- дип яза үзенең мәкаләсендә Мөхәрләмова Г.Н. [6,14-16.]

Технологик карта ярдәмендә белем бирү укыту-тәрбия процессын нәтиҗәле итеп оештырырга, Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә предмет, метапредмет һәм шәхси осталыкларының үсешен тәэмин итәргә, укытучының дәрескә әзерләнү вакытын җитди дәрәҗәдә киметергә ярдәм итә. Технологик картаның үзенчәлекләреннән интерактивлыкны, алгоритмлыкны, төзеклелекне, мәгълүматларның гомумиләшүен билгеләргә була. Технологик карта түбәндәге мәсьәләләрне хәл итәргә ярдәм итә:

- укытучы белән укучы эшчәнлеген системага сала
- укучыларда УУГ формалаштыра

- эш төрләрен ничек, нинди эзлеклелектә һәм ешлыкта үтәү кирәклеген билгели
- һәрбер эшкә күпме вакыт кирәк буласын алдан кисәтә
- эшне башкарып чыгу өчен кирәк булган тел һәм сөйләм материалын, кулланыласы принциплар, метод-алымнар һәм чараларны алдан планлаштырырга булыша
- һәр үтәлгән эшкә нәтиҗә ясый.

Технологик карта түбәндәге мөмкинлекләрне тудыра:

- стандартта планлаштырылган (көтелгән) нәтиҗәләрне гамәлгә ашыра;
- уку материалын done бербөтен итеп күзалларга һәм шуның нигезендә планлаштырырга ярдәм итә;
- нәтиҗәнең  белем бирү сыйфатын һәм аларның үзара мөнәсәбәтен билгели;
- теманы үзләштерүне максаттан алып соңгы нәтиҗәгә кадәр планлаштыра (күзаллый);
- укучының мөстәкыйль эшчәнлеген оештыра;
- укытучы белән укучы эшчәнлеген килештереп алып бара;
- сыйфатлы белем бирүне тәэмин итә;
- теманы, аерым бүлекне, чиреккә һәм уку елына каралган тел һәм сөйләм материалын үзләштерү вакытында универсаль уку гамәлләрен булдыра.

Универсаль уку гамәлләре составында белем бирүнең төп максатларына ярашлы дүрт блок аерып күрсәтелә:

1. Шәхескә бәйле гамәлләр
2. Юнәлеш алуга караган гамәлләр
3. Танып белү гамәлләре
4. Коммуникатив гамәлләр

Шәхескә караган универсаль гамәлләр укучыга әхлак нормаларын белергә, эш-кыланышларны һәм вакыйгаларны кабул ителгән тәртип нормалары белән чагыштырырга, тәртибеңә бәя бирергә өйрәтәләр. Монда өч төрле гамәл аерып күрсәтелә:

1) шәхси, һөнәри, тормышта үзбилгеләнү;

2) мәгънә барлыкка китерү: укуның нәтиҗәсе белән этәргече арасында мөнәсәбәт урнаштыру;

3) әхлак, этика нормалары кысаларында үз урыныңны билгеләү, юнәлеш ала белү, үзләштерелгәнгә бәя бирү.

Юнәлеш алуга (регулятив) караган гамәлләр балаларга үзләренең уку эшчәнлеген оештыру мөмкинлеге бирә. Мондый гамәлләргә түбәндәгеләр керә:

- максат кую – үзләштерелгән белән таныш булмаганны чагыштырып, хәл ителергә тиешле уку бурычын кую;

- планлаштыру – азаккы нәтиҗәне күз алдында тотып, ике арадагы максатларның эзлеклелеген билгеләү, план төзү, эш тәртибен билгеләү;
- прогноз кую – көтелгән нәтиҗәне сиземләү;
- тикшерү – бирелгән үрнәктән тайпылыш яки аермалык булу-булмавын ачыклау максатыннан эш алымын һәм аның нәтиҗәсен бирелгән үрнәк белән чагыштыру;
- коррекция – башкарылган эш, аның нәтиҗәсе үрнәк белән туры килмәгәндә, планга өстәмәләр һәм төзәтмәләр кертү;
- бәяләү – үзләштерелгән һәм үзләштереләсе белемнәрне аера белү, үзләштерелгәннең сыйфатын һәм белү дәрәҗәсен аңлау;
- үзрегуляция – көч һәм энергияне туплау, ихтыяр көче кую (дәлилләр бәрелеше булган очракта кирәклесен сайлау), каршылыкларны җиңеп чыгу сәләтенә ия булу.

Танып белүнең универсаль гамәлләре гомумуку, логик, проблема кую һәм аны чишү гамәлләрен берләштерә.

Гомумуку универсаль гамәлләре:

- танып белү максатын мөстәкыйль рәвештә аерып алу һәм әйтеп бирү;
- кирәкле информацияне эзләп табу, компьютер чараларын куллану;
- белемнәрне структуралау, ягъни тәртипкә салу;
- уй-фикерне сөйләмә һәм язма формада аңлап һәм ирекле оештыру;
- бурычларны үтәүнең нәтиҗәле ысулларын сайлау;
- рефлексия – эш-хәрәкәтләрнең алымнарын һәм шартларын, эшчәнлекнең барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп бару;
- текст укуның максатын аңлап һәм уку төрен шул максаттан чыгып сайлау нәтиҗәсендә аңлап укуга ирешү;

Танып белүнең универсаль гамәлләре арасында аерым бер төркем – тамга-символик гамәлләр бар:

- модельләштерү
- әзер модельне үзгәртү.

Логик универсаль уку гамәлләре:

- анализ – төп һәм мөһим булмаган билгеләрен аерып алу өчен, объектны тикшерү;
- синтез – аерым кисәкләрдән бер бөтен төзү, кирәк булганда, җитмәгән компонентлар өстәү;
- объектларны чагыштыру, төркемләү өчен нигез һәм критерийлар сайлый белү;
- төшенчәгә китереп җиткерү, нәтиҗә чыгару;
- сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләрне ачыклау;
- фикер йөртүнең логик чылбырын тезү;

- исбатлау;
- гипотеза әйтү һәм аны дәлилләү.

Проблема кую һәм аны чишү:

- проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтү;
- иҗатка һәм эзләнүгә корылган проблемаларның чишелеш алымнарын мөстәкыйль табу.

Коммуникатив гамәлләргә түбәндәгеләр керә:

- укытучы һәм сыйныфташлар белән хезмәттәшлекне планлаштыру;
- сораулар кую – информация эзләү, туплауда хезмәттәшлек;
- конфликтларны чишү;
- әңгәмәдәшнең тәртибенә җитәкчелек итү;
- үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү.

Укытучы дәрескә үзанализ ясаганда, дәреснең барышын сөйләп чыга. Эчтәлекне сайлаганда нәрсәгә нигезләнүе, нинди методлар куллануы, белем бирүнең нинди формада оештырылуы турында сөйләгәндә кыенлык кичерә. Традицион планда, нигездә, дәреснең эчтәлеге языла, һәм ул системалы педагогик анализ ясарга булышмый. Дәрес барышын технологик карта формасында язу әле дәресне әзерләгәндә үк һәр этапта уку эшчәнлегенең төрләре, чаралары, методлары, эчтәлегенең ни дәрәҗәдә дөрес һәм төгәл сайланганлыгын бәяләргә мөмкинлек бирә. Алдагы адым – дәреснең һәр этабын бәяләү, эчтәлекне дөрес сайлауны, кулланылган метод һәм формаларның төгәллеген бәяли.

Системалы-эшчәнлекле юнәлешне гамәлгә ашырганда технологик карта әйдәп баручы рольне үти:

1. Белем бирүнең нәтиҗәлелегенә яңача якын килү.
2. Планлаштырган шәхси, метапредмет һәм предмет белем бирү нәтиҗәләренә ирешү.
3. Универсаль уку гамәлләре нигезендә, метапредмет нәтиҗәләренә ирешү мөмкинлегенә төшенү.

### 2.2. Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының 5 нче сыйныфында “Омонимнар” темасына технологик карта

**(татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен)**

**Тема: Омонимнар.**

**Укытучы эшчәнлегенең төп максаты:** Омоформа, омограф, омофон төшенчәләренә аңлатма бирү. Укучыларда омонимнарның төрләрен аера белү осталыгы формалаштыру.

**Белем бирү максаты**: 1. Укучыларда омонимнар турында белемнәрен системалаштыру, омоформа, омофон, омографлар төшенчәләрен формалаштыру.

2. Үз фикерләрен әйтә, дәлилли, шулардан чыгып нәтиҗә ясый белүләренә ирешү.

3. Укучыларның уйлау сәләтен, мөстәкыйль активлыкларын, фикерләрен дәлилләргә өйрәнү күнекмәләрен үстерү.

**Фикер сәләтен үстерү максаты:** яңа укыту алымнарын кулланып, укучыларның аралашу күнекмәләрен, логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып-белүне үстерүгә ярдәм итү.

**Тәрбияви максат** – аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен, кешелеклелек, ярдәмчеллек сыйфатларын тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗәләр**

**Предмет**: омоним сүзләрне таный һәм куллана белү; омонимнарның төрләрен аера белү.

**Универсаль уку гамәлләре**

**Танып белү:** төп билгеләрне аерып күрсәтү, логик фикерләү чылбырын булдыру, үз карашыңны дәлилли белергә өйрәтү.

**Регулятив**: кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу, үзконтроль, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү.

***Коммуникатив*:** классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү, тыңлый белү, диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу, мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү, иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү.

**Шәхси үсеш:** үзмаксат кую, күршеңә ярдәм итүдә танып белү инициативасы күрсәтү, үз уңышларыңның, уңышсызлыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртү, телдән һәм язма сөйләмнең камиллегенә ирешү.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне үзләштерү дәресе.

**Төп төшенчәләр:** туры мәгънәле, күчерелмә мәгънәле, омоним, омоформа, омограф, омоформа.

**Предметара бәйләнеш:** татар әдәбияты, тел белеме

**Эшне оештыру төрләре:** фронталь, индивидуаль, парлап эшләү, төркемнәрдә эшләү.

**Чыганаклар -** төп: дәреслек, эш дәфтәре;

өстәмә: ноутбук, проектор, презентация, индивидуаль карточкалар, күнегүләр җыентыгы.

Технологик картаның бүлекләре. (Технологик карта тулысынча кушымтада бирелә)

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Укучының универсаль уку эшчәнлеге (УУГ) |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. Оештыру, мотивлаштыру Максат: уку эшчәнлегенә уңай мохит тудыру, укучыларны төп эшчәнлеккә җәлеп итү. (1-2 мин.) | Хәерле көн, укучылар! Кәефләрегез ничек? Уңай психологик халәт тудыру. Дәресне башлыйбыз. Кем юк? | Исәнләшү. дәрескә әзерлекләрен күрсәтү. | РУУГ. Эшчәнлек өчен эш урыны әзерләү. ШУУГ: Белем алуга үңай мохит тудыру, уку теләге булдыру |

**ЙОМГАК**

Федераль дәүләт белем бирү стандарты системалы эшчәнлек юнәлешендә белем бирүне таләп итә һәм укучыларны иҗади үз-үзенә ышанган, заман таләпләренә җавап бирүче, физик, интеллектуаль, рухи-әхлакый, эмоциональ, иҗтимагый үзүсешкә ия булган шәхес итеп тәрбияләү бурычын үзәккә куя. Болар универсаль уку гамәлләрен (УУГ) булдыру аркылы тормышка ашырыла. Бу сыйфатларга ия булган укучы белем, осталык һәм күнекмәләрне мөстәкыйль үзләштерергә сәләтле була.

Билгеле булганча, белем һәм тәрбия бирүнең төп формасы – дәрес. Ул яңа федераль дәүләт белем бирү стандарты  һәм заман таләпләреннән чыгып оештырылырга тиеш. Дәреснең төп максаты – белем алу аша укучының акыл, рухи, физик үсешен тәэмин итү һәм өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксынуын көчәйтү. Эш ысуллары бергәләп эзләнү, әңгәмә, дәрес-диспут,  укучы һәм укытучы арасындагы эшчәнлек. Эш төрләре укучыларның мөстәкыйль мәгълүматны эзләп табу, проблемалы сорау куеп, аңа җавап бирү, иҗади күнегүләр үтәү, эшне шәхси, төркем белән һәм парларда оештыру. Максат һәм бурычларның, принцип, метод һәм чараларның дөрес билгеләнүе, планлаштырылган нәтиҗә һәм белемнәрне тикшерү төрләренең булуы дәреснең эчтәлеген тәшкил итә.

Федераль дәүләт белем бирү стандарты буенча укытучы – укучыларга юнәлеш бирүче. Аның төп максаты - уку мәсьәләсен чишү барышында куелган максатка ирешү өчен, укучыга тиешле ярдәм күрсәтү.

Дәреснең төп нәтиҗәсе - укучының белемне мөстәкыйль үзләштерергә омтылуы, аны куллана, үз-үзен бәяли, хаталарын күрә, эшчәнлекккә нәтиҗә ясый белүе.

Укытучы, аның укыту процессына мөнәсәбәте, иҗадилыгы һәм профессиональлеге, һәр баланың сәләтен ачарга теләге – бу төп чыганак. Мәктәптә укыту-тәрбия процессын оештыруга федераль дәүләт белем бирү стандартының яңа таләпләре укытучыдан башка яши алмый. Күп

нәрсә укытучының характерыннан, аның профессиональ әзерлегеннән тора. Әгәр дә кеше яңалык өчен ачык, үзгәрешләрдән курыкмый икән, аз вакыт эчендә дә яңа шартларда беренче ышанычлы адымнарын ясый башлый.

Технологик картаның төзелешен өйрәнү, төрле вариантлары белән танышканнан соң, берсен сайлап алып гамәлдә эшләп карау бүгенге көндә актуаль санала.

Проект эшебезнең темасы - "ФДГББСны гамәлгә ашырганда, 5 нче сыйныфта татар теле дәресенең технологик картасы". Проектның төп максаты проблеманы теоретик һәм практик яктан өйрәнеп, татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен 5 нче сыйныфта "Омонимнар" темасына дәреснең технологик картасын төзү һәм гамәлгә кертү иде. Дәрес этапларын якынча дөрес бүлеп, уку эшчәнлеге төркемнәрдә оештырылып, укытучы-укучы хезмәттәшлеге; мәгълүмат җыю һәм эзләүдә инициативалы хезмәттәшлек; иптәшеңнең тәртибе, үз-үзен тотышы белән идарә итү; укучының тыңлый, ишетә, үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә җиткерүен формалаштырып, дәреснең һәр этабына универсаль уку гамәлләрен күрсәтеп технологик карта төзелде. Проект эшенә куелган максатка ирешелде.

Әлеге хезмәтне язу барышында түбәндәге нәтиҗәләр ясалды:

Дәреснең технологик картасын таблица рәвешендә ясау бик уңайлы: дәреснең һәр этабының вакыты, максатлары, эшчәнлек төрләре, ул этапта кулланылачак чаралар, күрсәтмәлелек күз алдында.

Дәрескә анализ ясаганда да бу картадан файдалану отышлы.

Дәрес ничек кенә оештырылмасын, ул балага авырлык китермәскә, аннан бала шатлык, канәгатьләнү хисе алып чыгарлык итеп планлаштырылырга тиеш. Моны бары тик яңача фикерләүгә омтылган укытучы гына булдыра ала. Ул укучысын үз фикере, бәясе, үзенә генә хас тормыш тәҗрибәсе булган, иҗади сәләткә ия шәхес итеп кабул итә ала.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

*Норматив* документлар

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 7 нче сентябрендә чыгарылган "Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында"гы 12138/13 санлы хат.

Фәнни-методик хезмәтләр

1. Әсәдуллин А.Ш. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту методикасы нигезләре / А.Ш.Әсәдуллин, Р.А. Юсупов. – Казан: Мәгариф, 1998. – 151 б.
2. Әхәтов Г.Х. Хәзерге татар теле лексикологиясе. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1979. — 132 б.
3. Вәлиева Ф.С., Саттарова Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы / Ф.С.Вәлиева, Г.Ф.Саттарова.- Казан: Раннур, 2000. – 455 б.

4. Галиуллина Г.Р. Татар теле. Лексикология: таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр, сүзлекчә. – Казан: Мәгариф, 2007. – 95 б.

5. Камаева Р.Б., Мөхәммәтҗанова А.Х. Федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм/төз.-Казан: ТРМҮИ, 2015.-110 б.

6. Мөхәрләмова Г. Технологик карта: дәреснең оештыру өлеше / Г. Мөхәрләмова. – Мәгариф. – 2016. - № 4. – Б.: 14 -16.

7. Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М. Татар теленең омонимнар сүзлеге (Русчага тәрҗемә белән). – Казан: Хәтер, 1997. – 96 б.

8. Сәлимов Х.Х. Татар лексикологиясе. – Алабуга: АДПИ, 2002. – 38 б.

9. Татар теленең омонимнар һәм антонимнар сүзлеге.- Төзүче һәм редактор Рахматуллина А.Ш. - Яр Чаллы: Иҗат төркеме “Рәхмәт”, 2015. - 76 б.

10. Татар лексикологиясе/ ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ИЯЛИ, 2015. Т. 1. 352 б.

11. Татар теле дәреслекләренә электрон кушымталар. Методик ярдәмлек/ Шәмсетдинова, А.А. Башарова. - Казан: ТРМҮИ, 2015. – 68 б.

12. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар теленнән күнегүләр һәм тестлар. – Казан: Яңалиф, 2006. – 184 б.

13. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Ф.Ф. Харисов. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015. - 302 б.

14. Харисов Ф.Ф. Татар теле: укыту теориясе һәм практикасы. Монография. - Казан: “Ак бүре” нәшрияты, 2018. – 448 б.

15. Шәкүрова М.М., Йосыпов А.Ф. Татар телен укыту методикасы: теория һәм практика. - Казан: КДУ, 2009.

Электрон ресурслар:

1. Нуруллина Л.Х. Использование современных инновационных подходов к преподаванию татарского языка и литературы [Электронный ресурс]: режим доступа: // conf.knitu.ru: VШ респуб. научно-методическая конференция педагогов общеобразовательных учреждений, преподавателей учреждений среднего и высшего профессионального образования «Интеграция школы и вуза как эффективный инструмент формирования актуальных компетенций учащихся» Казань, 2015. URL: // http://www.conf. knitu.ru рус телендә.

2. Требования к научно-исследовательской работе. [Электронный ресурс]: режим доступа: http://www.vsoh1.ru.

*Вагыйзов Фарит Яхъяевич,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет белем бирү учреждениесеӊ, беренче категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы*

**Топонимик атамаларның милли мәдәният һәм традицияләр белән бәйләнеше**

Безнеӊ тормышыбызның беренче елларыннан ук географик атамалар көндәлек һәм даими рәвештә безнеӊ аңыбызга керә. Беренче чиратта шәһәр һәм авыл исемнәреннән башлап, туган йортыбыз урнашкан урамнардан башлап. Язучы Константин Паустовский әйткәнчә: «Исемнәр халыкның характеры, аның тарихы, һәвәслеге һәм көнкүреш үзенчәлекләре турында сөйли». Географик атамаларның килеп чыгышын ачыклау, аларның формасы, мәгънәви озату белән шөгыльләнүче фән «топонимика» дигән грек сүзе белән күрсәтелә, аның нигезендә топо -«урын» һәм оним - «исем» сүзләре ята. Татарстанда узган ел Милли мәдәният һәм традицияләр елы дип игълан ителде. Мәдәни традицияләрне торгызу төбәкне өйрәнүдән башка мөмкин түгел, ә аның юнәлешләренеӊ берсе - топонимика.

Борын заманнарда Актаныш районы урнашкан җирләрдә кара урманнар булган. Аю (аю), Бурсык (барсук), Кабан, Куян (куян), Еланово (җылан - елан), Әтәс (әтәч), Түке (күке) авылларында бүгенге көнгә кадәр сакланып калган атамалар моны раслый. Такталачык авылның барлыкка килүе турында түбәндәге риваять сакланган. Башта күчмә башкортлар кечкенә елга янындагы зур аланлы урманга килеп урнашалар. Алар урман кисү белән шөгыльләнгәннәр һәм башта үзләре өчен кечерәк кенә корылма: алачык яки шалашлар төзегәннәр. Алар такталардан - берничә өлешкә ярылган бүрәнәләрдән була. Бу урынны "Такта алачык" дип атый башлыйлар.

Такталачык авылы Агыйдел ярыннан 4 чакрым биеклектә урнашкан. Бу елганың исеме ике киң таралган - Ак һәм Агыйдел. Башкортлар аны Агыйдел дип атыйлар («ак елга», «ак Идел»). Бер версия буенча елга көньяктан, кояштан аккан атаманы алган, шуңа күрә "якты", "ак". Икенче версия буенча анда эретелгән известь күп булу сәбәпле ак төстәге су дип атыйлар.

Шәбез - Агыйдел елгасының сулъяк кушылдыгы. Озынлыгы 35 километр. Агыйдел елгасына Такталачык авылыннан 3 км көньяк-көнчыгышта килеп кушыла."Шәбез" гидронимы “чишмә башлангычы” сүзтезмәсе белән бәйләнгән. “Ыштанчык елгасы” гидронимының килеп чыгышы халык риваятенә нигезләнгән. Авылдашлар сөйләве буенча, бик күптән инде, су буенда коенганда, җирле крестьян чалбарын югалткан һәм яр буенда озак кына “ыштан, чык!” дип кычкырып йөргән.

“Күпер колагы” гидроним да Шәбез елгасы белән бәйле. Исеме «күпернең колагы» дип тәрҗемә ителә. Элек аулак урында урнашкан, печәнлек вакытында гына кулланылган зур булмаган агач күпер су басу зонасына эләккән һәм хәзер су астына яшерелгән.Шәбез тамагы гидронимы конкрет географик урынны - Шәбез елгасы тамагын аңлата. Ягъни Агыйдел белән кушылу урыны.

Иске Идел (гидроним) дип Агыйделнең зур утрау белән аерылып торучы елга култыгы атала.

Шарлама - Шәбез елгасы тугаендагы ермак, «шарлама» төркичә «шарлама», ул «шарпад, агым» дигәнне аңлата.

Такталачык авылының тирә-ягында күлләр бик күп. Кәрге күле - Агыйдел елгасыннан 500 метр ераклыкта, Бурсык авылыннан ерак түгел сазлыклы урында урнашкан. Төрки теленнән «карга» сүзе 1.карга (кош); 2. Урман, күл, топь; фин –угор телләреннән “сазлык”, “сазлык арасындагы калкулык” дип тәрҗемә ителә.

Киндер күле күптәнге заманда киндер тукыма (татар телендә киндер) әзерләгәндә, чималны сулыкларда чылатып эшкәрткәннәр. Картларның сөйләүләре буенча, бу күл бик тирән, урыны-урыны белән 7-8 дилбегә (15-20 метрга) җиткән.

Бәкелде күле күленең исеме “бакылдый” фигыль сүздән килеп чыккан. Борынгы заманнардан бирле бу күлдә бик күп кыргый үрдәкләр яшәгән.

Чәйлекүл исеменең килеп чыгуыда бик гади. Тирә-юньдә камышлар күп булганлыктан, мондагы сулыкның төсе һәрчак коңгырт төстә. Шунысы кызыклы, күл тирәсендә җирле халык чәйгә өстәргә яраткан хуш исле үләннәр(зәңгәр һәм сары мәтрүшкәләр) бик күп үсә. Мүкле күл: бу күлдә элек агач буралар төзегәндә кулланыла торган мүк табалар.

Авыл җирлегендә җир кишәрлекләренең исемнәрен - сөрүлекләрне, кырларны һәм башка җирләрне билгеләү өчен агроонимнар бар.

Чәбе болыны . Исеме татар телендәге «чабу» фигыленнән килеп чыккан, бу – печән чабу дигән сүз. Түбән Кама районында да шуңа ошаш топоним бар. Әмма галимнәр “Чабья” сүзенең удмурт телендәге «чабей» - бодай сүзенә катнашы бар дип фаразлыйлар, шулай ук бу сүз удмуртларның нәсел шәҗәрәсенә барып тоташа.

Әҗмәт болыны - Әҗмәт болыны, күрше авыл исеме белән. Уразай болыны шул җирләрнең элеккеге хуҗасы исеме белән аталган. Чатлыкай болыны - «чат» сүзе татарча икегә аерылучы юл чаты дигәнне аңлата. Уразай таллыгы - авылга нигез салучыларның берсенең исеме буенча.

Лыпыды болыны – Агыйделнең уң ягында урнашкан, янәшәдә шул ук исемле күл дә бар. XVIII нче гасырдан сакланган җир документлары нигезендә Уфа профессоры Әнфәр Закирович Әсфандияров болай дип яза: “...озеро Липада упоминается в 1701 году в «Оберегательной памяти башкир Такталачукской Тюбы Кузея Биккинина и Ишкини Темкеева с товарищы», которым

велено владеть состоящими в их вотчине озерами Липадой, Емадой, Чутлеем, а по-русски Чекаево, Шабизо-Казыем, Кариным [27]". В мари телендә "лап", "лапита" сүзләре "түбән", "түбәнлек" мәгънәләрен аңлата икән. Ә удмуртча "лап" дигән сүз "сай, тирән булмаган" һәм "түбән түшәм" [29] мәгънәләрендә кулланыла.

Такталачук авылы тирәсендә түбәндәге атамалар тау темасы белән бәйле: Кашлак тавы - зур булмаган калкулык, җиләк урыннар; Бурсык тавы – бурсыклар күп яшәгән урын , анда элек аучылык җирләре булган. Нүрек тавы - алтмышынчы елларда Актаныш юлында барлыкка килгән зур булмаган калкулык. Ул елларда СССРда Нурек ГЭС ы төзелде, бәлки, җирле атама бу вакыйга хөрмәтенә барлыкка килгәндер (Россиянең барлык шәһәрләрендә дә, шул исәптән Түбән Камада да, ерак торак районнарны "БАМ", "Тында" дип атый башлаганнар).

Гайшә күпере. Бу урын узган гасырның егерменче елларында булган Такталачук авылы тарихында булган фаҗигале вакыйгаларның берсе белән бәйле. 1920 елда Совет хакимиятенә каршы сәнәк күтәреп күтәрелгән крестьяннар бу җирдә авыл активистларын, шул исәптән авыл мөгаллимнәрен дә үтергәннәр.

Әбугали баткаклыгы. Бу топоним шулай ук тарихи вакыйгага нигезләнгән. 1910 нчы елны авылда земство больницасы төзелә башлагач, Агыйдел буенча баржалар белән кызыл кирпеч алып киләләр. Ярга бушатылган кирпечләрне ат арбаларына төяп ташыйлар. Ул елны ташу көчле була, Әбугали исемле бер кеше аты белән адашып сазлыклы урында батып үлә.

Без бу эштә топонимнарның никадәр киң тикшерелүен, аларны өйрәнү һәм системага салу алымнарының төрлелеген, шулай ук Актаныш районы Такталачык авылы топонимиясен төрле яктан анализларга тырышып карадык. Башкарылган эшкә нәтиҗә ясап, куелган бурычлар үтәлде дип әйтергә мөмкин: 1.Билгеләп үтелгәнчә, авыл һәм аның тирә-ягындагы атамалар очраклы рәвештә генә сайлап алынмаган, алар бу урыннарның географик һәм башка үзенчәлекләрен аңлаталар.

2. Топонимик атамалар авылыбызның барлык халкы өчен бик зур әһәмияткә ия, чөнки аларда якын һәм бөек кешеләр турында, күңелгә якын җирләр, кече Ватаныбызның бөеклеге турында истәлекләр яшәвен дәвам итә.

Авылдагы топонимнарга һәм микротопонимнарга лингвистик анализ ясаганда, тарихи документларны, шулай ук кайбер географик объектларны өйрәнгәч, исемдә халыкның якты һәм үзенчәлекле тарихы чагылган дигән нәтиҗәгә килдем. Киләчәктә туган якның микротопонимнарын өйрәнү эшен дәвам итәргә планлаштырам, чөнки барлык мәсьәләләрне дә хәл итеп булмады, күп кенә исемнәрне аңлату үз чишелешен көтәләр. Алга таба «Такталачык авылының һәм аның тирәлегенең топонимик сүзлеген» төзүне дәвам итәргә, шулай ук топонимнар һәм микротопонимнар мәгълүматлары буенча табигать объектларының фотоальбомын төзергә планлаштырам.

Авылның топонимик характеристикасын төзү кече Ватан тарихы буенча белешмәләр өстәргә, кыйммәтле материалны язып алырга һәм сакларга мөмкинлек бирде. Топонимнар – туган якны комплекслы өйрәнергә мөмкинлек бирә торган төп юнәлешләрнең берсе. Хәзер үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәсендә нинди дә булса географик атамалар, Такталачык авылы топонимнары югалган дип курыкмаска мөмкин. Бу эшне дәвам итеп, топонимнар сүзлеге төзергә уйлыйбыз.Минем тикшеренү эшендә җыелган материалларны тарих, география һәм туган якны өйрәнү дәресләрендә кулланылырга мөмкин.

1.Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше (белешмәлек) / Татарстан Республикасы Премьер-министры Р.Н. Миңнеханов редакциясендә. Казан: Инновацион технологияләр үзәге, 2005. 2.Әсфәндияров А. З. Минзәлә башкортлары. - Уфа: Китап, 2009. - 410-421. - 3. .Гарипова Ф.Г. Татарстан гидронимиясе буенча тикшеренүләр. М.: Фән, 4. 4.Суперан А. В. Нәрсә ул топонимика? М.: Наука, 1985. 182 б.

*Гайнутдинова Зальфира Рашид кызы,*
*Шарифуллина Алсу Ильнур кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбият, тарих һәм җәмгыять белеме укытучылары*

**Бишек җырларның яшь буынны тәрбиятләүдәге роле**

Җырларның туу тарихы ерак үткәннәргә барып тоташа. Җыр – ике сәнгать чишмәсе: шигърият һәм музыка кушылудан туа. Бишек җырларының иң беренче чаткылары мең еллар элек яшәгән хатын-кызларның “ә-ә,!ә-ә,ә!” дип бала юату, бала иркәләү авазларында ук яңгыраган. Ана теле сабый күңеленә җыр булып иңә; бишек тибрәткәндә дә, аны елавыннан юатканда да ана үзенең газизенә әйтәсе сүзләрен җыр-моңга төреп җиткерә һәм, ни гаҗәп, сабый аларны тыңлый, ишетеп юана, кайвакыт хәтта елавыннан да туктый!.. **[** 9, б. 3**].** Бала багу иҗаты сабыйның бишектән алып үз күңелен үзе күрә һәм үзлегеннән иҗат итә башлауга кадәрге чорын эченә ала. Баланың физик үсеше, теле, дөньяга күзе ачылуга багышланган иң тәүге фольклор үрнәкләре һәм иң беренче уен күнекмәләре әлеге иҗатның иҗтимагый-педагогик асылын, төп эчтәлеген тәшкил итә. Бишек җырларының төп вазифасы – баланы йокыга талдыру, йоклату. Әлеге жанрның борынгырак үрнәкләрендә тирә-яктагы явыз мифик көчләрнең сабыйга бәла-каза китерүеннән яки йокысына комачаулавыннан качарга тырышу эзләре дә сизелә сыман.

Әлли-бәлли бәй итә,

Балам йокыга китә,

Балам йокыга китмәсә,

Бүкәйләр алып китә.

Мәхмүд Кашгарый сүзлегендә күрсәтелгәнчә (XI йөз), борынгы төрки телдә “бүкә” зур елан дигән мәгънәне белдергән. Соңрак чорларда иҗат ителгән яки импровизация белән чыгарылган бишек җырларында исә куян, кәҗә, песи, этәч, тавык кебек тыныч табигатьле хайваннар һәм кош-кортлар телгә алына. Һәм иң характерлысы: ата-ананың үз баласының сау-сәламәт үсүенә һәм киләчәгенә бәйләнешле теләкләре, өмет-хыяллары шактый киң чагыла.

Әлли-бәлли итәр бу,

Йокыларга китәр бу.

Бәү-бәү итеп,күз йомып,

Изрәп кенә китәр бу [4, б. 3 ].

Бала багу поэзиясенә янә кендек әби такмаклары, юаткычлар һәм мавыктыргычлар дип йөртелә торган тагын өч жанр керә [11, б. 337].

Бишек җырлары ана белән бала икәүдән-икәү калган вакытта башкарыла. Ана ул мәлдә күңеле белән баланың рухи дөньясына якынаерга, уй-фикерләрен нәниләр кабул итәрлек гади, самими итеп әйтергә омтыла. Шуның өчен бишек җырларында катлаулы стилистик һәм лексик сурәтләү чаралары очрамый. “Әлли-бәлли”, “алла-һу”, “чү-чү” кебек аваз ияртемнәре, ымлык сүзләр бишек җырларына салмаклык, тынычлык төсмере бирәләр, еш кабатлана торган “карлыгачым”, “былбылым”, “багалмам”, “гөлием”, “сачәгем” кебек эндәш сүзләр дә аларга үзенчә бер назлылык, ягымлылык, йөрәк җылысы өстиләр [10, б. 8].

Кульязма рәвешендә сакланган китапларда бишек җырлары да очрый. Текстлар 1868 нче елда төзелгән язмада теркәлгән. Китапны Казан дәүләт университетының гыйльми китапханәсенә 50 нче елларда татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укытучы булып эшләгән галимебез мәрхүм Җәвад Алмаз тапшырган [1, б. 20].

Габдулла Тукай кечкенәдән җыр ярата. “Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем: мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атна кичләрдә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә мине дә онытмыйлар иде” [8, б. 191]. ”Габдулла өенә кайтып кергәндә түр башына кабык бишек эленгән, җырлый торган җырлары да бар” [8, б. 192]. Габдулла Тукай Кырлайдагы Сәгъди абзыйларда торганда бишек җырлары ишетә. Бу җырларны Сәгъди абзыйның хатыны улына, ә Саҗидә апасы энесенә багышлап җырлый торган була. Тукайның күңелендә дә бишек җыры туа.

Әлли-бәлли итәр бу,

Мәдрәсәгә китәр бу,

Тырышып сабак укыгач,

Галим булып җитәр бу [3, б. 9].

Көнчыгыш халыкларының усал хан турындагы әсәре бар. Усал ханның бишек җырын ишетүе була, ул кешелекле, яхшы күңелле кешегә әйләнә. Ул канкойгыч сугышларны туктата, кечкенә балаларга бишекләр ясарга, аларга бишек җырлары җырларга куша [7, б. 72]. Заманча әти-әниләрне авторлар язган бишек җырлары битараф калдырмый. Бишек җырларын күп кенә шагыйрьләр: Дәрдемәнд, Муса Җәлил, Нәби Дәүли, Ләбиб Айтуганов, Мәхмүт Хөсәен, Ренат Харис, Гөлшат Зәйнашева,Фирая Зыятдинова, Резеда Вәлиева, Сәйдә Зыятдинова, Мөдәррис Әгъләмов, Әхмәт Ерикәй, Нәкыйп Каштан, Хәкимҗан Халиков иҗат иткән. Бу җырларга композиторлар: Җәүдәт Фәйзи, Алмаз Монасыйпов, Ренат Еникеев, Резеда Ахиярова, Луиза Батыр-Болгари, Шамил Тимербулатов, Риф Гатауллин, Ренат Салихов, Мәсгут Имашев, Рамил Курамшин, Зиннур Гыйбадуллин, Фәрид Шәрифуллин, Гөлчәһрә Байкина, Ильяс Гыйләҗетдин, Рөстәм Яхин, Разыя Еникеева тарафыннан матур көйләр чыгарылган. Мәсәлән:

Т. Миңнуллинннның **“**Әниләр һәм бәбиләр**”** (1984) драмасында тамашачы күңелендә аптыраулы гаҗизлек катыш кызганулы нәфрәт уяткан образ – Дилемма. Баш табибның “иманыгыз бармы сезнең?”, “бишек җырын беләсезме?” дигән сорауларына яңа гына баладан котылган яшь хатынның “мин ул сүзне аңламыйм”, безгә аны өйрәтмәделәр” дип җавап бирүе Дилемма кебекләрнең бу тормышта очраклы күренеш түгеллеген, аларның барлыкка килүләренең сәбәпләре бик тирәндә икәнлеген күрсәтә [13, б. 115].

Бишек җырларының әһәмияте зур. Һәркем аны, сабый чакның якты истәлеге итеп, гомеренең соңгы көннәренә кадәр күңел түрендә саклый. Ул җырлар газиз ана, туган ил, туган тел кебек изге төшенчәләр белән бергә йөри. Ана бала йоклатканда җырлаган җыр тормыштагы авырлыкларны җиңәргә көч бирә, заманча кешеләргә җитмәгән уңай кешелек сыйфатлары булдырырга ярдәм итә.

Миңа әнием гел бишек җырлары җырлый иде.

Әлли-бәлли бәү итә,

Милена йокыга китә.

Милена йокыга киткәч,

Бар да тынычлап китә.

Халык иҗатын, бишек җырларын онытмау өчен төрле юллар кулланырга була:

1. Гаиләдә һәм җәмгыятьтә буыннар алмашын ныгытырга, сакларга кирәк.

2. Балалар иҗаты әсәрләрен мәктәптә, балалар бакчасында, музыка мәктәпләрендә өйрәтергә, бишек җырларын аерым бүлек буларак хәзерге яшьләргә өйрәтүне татар әдәбияты дәресләрендә максат итеп куярга кирәк.

Әйдәгез, бишек җырларына югалырга ирек куймыйк, үзебез өйрәник, якыннарыбызга җырлыйк.

**Файдаланылган әдәбият исемлеге**

1. “Азат хатын” журналы. №10. 1990. – 20 б.

2. Бишек җырлары. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 1993. – 3 – 45 б.

3. Бишек җырлары. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000. – 5 – 101 б.

4. Б алалар фольклоры.-Казан:Татарстан китап нәшрияты,1984.-5 б.

5. К. М. Миннулин, Ф. И. Урманче. Татар халык иҗаты. – Казан:Мәгариф, 2001.– 183 б.

6. Милли тәрбия – милләт яшәешенең нигезе. – Түбән Кама: 2010. – 8 б.

7. “Мәгариф” журналы. №3, 2013. – 74 б.

8. М. Гайнуллин, М. Мәһдиев. Татар әдәбияты. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 197. – 191 – 192б.

9. Татар халык җырлары. К. М. Миңнуллин, Җ. Х. Кәлимуллин, Ф. И. Урманче- Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2001. – 3 – 4б.

10. Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры. – Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1993. – 8 – 9б.

11. Татар фольклоры. М. Х. Бакиров. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2008. – 337–339 б.

12. Хрестоматия. Татар халык иҗаты. – Казан: “ Мәгариф”, 2004. – 479 б.

13.Туфан Миңнуллин.Әниләр һәм бәбиләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1985. – 115 б.

*Галеева Рәфилә Рәкыйп кызы,*

*Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы "Күзкәй урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*

**Башлангыч сыйныфларда проект  эшчәнлеге**

Син сөйлә- мин онытырмын, күрсәтсәң- хәтерләп калырмын, эшләп карасам- аңлармын. Яңа белем бирү стандартлары башлангыч мәктәп каршына яңа бурычлар куя. Хәзер башлангыч мәктәп укучыларны укырга, язарга,  санарга , исәпләргә генә өйрәтми.   Федераль дәүләт белем стандартлары керү белән мәгарифтә белем алуга булган таләпләр тамырдан үзгәрде. Бу шартларда укучылар да үзгә, укытучыга булган таләпләр дә бөтенләй башкача.

Балага белем бирергәме, әллә аны белем алырга өйрәтергәме?! Белем алырга өйрәнгән бала, агымсу кебек, һәркайда юлын табар. Югалмас, яңа үрләр яулар. Ә моңа ничек ирешергә?

Укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын үзләштерүнең иң уңышлы вариантын кулланып эшләү.

Укучылар белән эшләгәндә проектлар методын куллану отышлы. Проектлар методы укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Бу метод белән эшләгәндә, укучылар актив рәвештә уйлау, фикерләү эшчәнлегенә тартылалар. Методик яктан караганда, проект эше фәнни һәм гамәли проблемалы-юнәлешле тикшеренү эшчәнлегеннән гыйбарәт. Ул, теге яки бу проблеманы тирәнтен өйрәнү максатында, укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш. Компьютер технологияләреннән уңышлы файдалану, төрле фәннәргә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Укучыларны ул һәрьяклап үстерә, шәхес итеп тәрбияли.

Проект методы XX йөз башында Америка педагогы, психологы, фәлсәфәчесе Джон Дьюи (1859 - 1952) тарафыннан уйлап табыла. Аның фикере буенча, белем бирү ул - "балаларның шәхсән кызыксынуларына, максатларына тәңгәл килгән максатчан эшчәнлеккә нигезләнеп төзелгән процесс".

Эзләнү эшчәнлеге, балада шатлану, кызыксыну хисләре уяту белән беррәттән, аның әхлакый, акыл, физик сыйфатларын да үстерүгә мөмкинлекләр тудыра. Мондый эшчәнлек яңа (инновацион) технологияләрнең бер төре булган ПРОЕКТ МЕТОДЫ ярдәмендә оештырыла.

Проектлар методы – укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән укыту системасы ул. Проект методының бер төре – эзләнү эше. Эзләнү методы булганда укучы яңа белемнәр үзләштерә, билгесезне эзли . Ул- фәнни эш. Ә проект эше ул-иҗади эш. Аның нигезендә иҗади танып-белү күнекмәләрен, критик фикерләү сәләтен үстерү ята. Проект эзләнү эшенең нәтиҗәсен рәсмиләштерү формасы да булып тора.

Проект эшчәнлеге – төпле фикере булган балалар тәрбияләү технологияләреннән берсе. Проект эшен индивидуаль, группаларда уздырырга мөмкин.

Аның максаты: укучыларның шәхси, метапредмет нәтиҗәләре эшчәнлеген бәяләү, уңышлы аралашуларына ирешү, аларны һәртөрле эшчәнлеккә иҗади якын килергә өйрәтү.

**Башлангыч сыйныфларда проект эшчәнлегенең бурычлары шәхесне үстерүгә нигезләнгән**

Проект эшчәнлеге барышында:

-укучыларның танып- белү сәләте үсә;

- бала иҗади фикерләргә өйрәнә;

-аларның сәламәтлегенә һәм психологик хәләтенә уңай тәэсир итә;

-иҗади һәм логик фикерләү сәләте үсә;

-укучыларның коммуникатив күнекмәләре арта.

Проект эшчәнлеге нәтиҗәсендә укучыларда түбәндәге белем- һәм күнекмәләр барлыкка килә:

-үз фикереңне төгәл әйтә белү;

-проект эшчәнлеге вакытында укучылар бер-берсен тыңларга, иптәшләренең фикерләре белән килешергә өйрәнәләр;

- максат куеп, аның нәтиҗәсен күрү;

- үз эшеңнең нәтиҗәсен тыныч кына (адекватно) бәяли белү;

-информация белән эшләргә: чагыштырырга,берләштерергә, логик фикерләү чылбыры төзергә, иң кирәклесен генә аерып ала белү;

-эш нәтиҗәсен файдалы итеп күрсәтергә;

-Интернетта кирәкле материалны табып ала белү .

Проект эшчәнлеге укучыларда да, укытучыда да зур кызыксыну тудыра. Ул фикерләүне, сөйләмне, үз уйларыңны формалаштыра белү сәләтен үстерә. Проект эшчәнлеге барышында укучы коллективта эшләргә, үзенә бирелгән эшкә җаваплы карарга, куелган сорауларга җавап табарга өйрәнә.

**Проект эшчәнлегенең төрләре**

1. **Эзләнү проектының** стуктурасы уйланылган, теманың актуальлеге, тикшерү объектының проблемасы, максаты, гипотизасы һәм бурычлары, эзләү методлары, күзәтү, тәҗрибә, эксперимент, нәтиҗәләрне тикшерү, нәтиҗәләр ясау булырга тиеш. Бу эшчәнлеккә лаборатор эшләр, доклад, чыгышлар, күзәтү көндәлеге һ.б..керә.

2. **Иҗади проектның** билгеле бер структурасы булмый. Ул ахыргы нәтиҗәгә карап ниндидер таләпләргә туры килергә тиеш. Бу-стена газетасы,бәйрәм сценарие, видеофильм, плакат, күңелле эшләр журналы булырга мөмкин. Иҗади проект проблемасын чишүдә автор ирекле эш алымнарын куллана.

3. **Маҗаралы-уен** проекты зур әзерлекне таләп итә. Чишелешне уен ситуациясе вакытында чишәргә мөмкин.

4. **Рольле –уен** проекты – укучылар әдәби геройларның рольләрен кабул итеп алалар, проблемаларны чишәләр.

5. **Информацион проект-** ниндидер объект, күренеш турында мәгълумат туплау, аны анализлау, фактларны берләштерү.(СМИ статьялары, Интернет информацияләре)

Проект методы ярдәмендә укучыларның фантазиясе үсә, балачак хыяллары тормышка аша. Уен барышында укучы өлкәннәр шикелле эшен планлаштыра, аны чишә, аның дөреслеген, кирәклеген раслый. Ә укытучы яшерен генә укучы белән идарә итә.

**Монопроектлар-** конкрет уку предметы юнәлешендә була**.**

Монопроектлар өстендә эшләү барышында проблемаларны чишүдә төрле өлкәләрдә алган белемнәрне дәрестә кулланырга мөмкин.

**Предметара (интегрированный)** –берничә предметның темаларын берләштерә һәм дәрестән тыш вакытта берничә җитәкче белән эшләнә. Болар- 2-3 фәнне берләштерүче бик зур булмаган яки күләмле проектлар булырга мөмкин. Мондый проектлар баланы мәктәптә өйрәнгән предметлар буенча алган белемнәр белән генә чикләнмичә, тормышта була торган ситуацияләр белән дә бәйли.

Проект эшчәнлегендә әзерлеге нинди булуга карамастан, барлык укуыларда катнаша ала. Кемгәдер инвидуаль проект эшләү көченнән килсә, кемдер үзенең талантын группа белән эшләү вакытында ачарга мөмкин. Иң кирәклесе- балага үзенең көченә ышанырга ярдәм итәргә. Ә бу бурыч өлкәннәр җилкәсенә төшә.

Башлангыч сыйныф укучысы өчен проект эшчәнлеге шактый катлаулы. Шуңа күрә башлангыч сыйныфтан ук укучыларны проект эшенә күнектерә башларга кирәк.

Укучылар белән барлык фәннәр буенча да проект эшчәнлеге оештырырга мөмкин. Ә иң беренче проектның проблемасы яки идея барлыкка килергә тиеш.

**Проект өстендә ничек эшләргә?**

Проект эшчәнлеге түбәндәге этаплардан тора.

1.Әзерлек этабы.(группаларга бүлү)

2.Темасын уйлап табу.

3. Нәрсә эшлибез: плакатмы, презентацияме?

4. План төзү(Кирәкле информацияне җыябыз. Моның өчен китап, газета, журналлардан файланабыз,сүзлекләр, мәкаль, табышмаклар, кызыклы фактлар, интернет кулланабыз, компьютерда яза алабыз)

5.Проектны эшләү. (Кирәкле инструментларны алдан әзерләп куябыз.)

6. Проект эшенең күрсәткече (презентация, сценарий, китапчык, рәсем, газета , плакат һ.б.).

7. Проектны яклау.

8. Бәяләү.

Эшнең уңышлы килеп чыгуы аның дөрес оештырылуына бәйле. Монда укытучы, укучы һәм ата-ана хезмәттәшлеге бик әһәмиятле. Башлангыч сыйныфларда укытучы – киңәшче, юнәлеш бирүче, төзәтмәләр кертүче, рухландыручы, илһам өстәүче. Укучы – эзләнүче, идеяне тормышка ашыручы, мәгълүмат җыючы, фикерләүче, күзәтүләр нигезендә модель төзүче, барлыкка килгән нәтиҗәләрне анализлаучы, тәҗрибәләр үткәрүче, интернет материалларын кулланучы һәм проектны яклаучы. Ә ата-аналар укучыга кирәкле мәгълүматне табарга ярдәм

итүче, идеяләрне тулыландыручы, иҗади бала белән бергә кызыксынучы, бала белән көндәлек аралашучы ролен үти.

Проект эшенә ата-аналарны да җәлеп итү бик отышлы, чөнки ата-ана бала тормышында актив катнаша башлый.

Бу метод укытучы һәм укучыларның яхшы әзерлеген, сыйныфның һәм иҗади төркемнәрнең үзара килешеп эшләүләрен таләп итә. Проект турында сөйләшүдә катнашып, укытучы да тигез хокуклы фикердәшкә, ярдәмчегә әйләнә. Проектны гамәлгә ашыру барышында укучылар әйләнә-тирәдәгеләр белән уртак тел табып эшләргә, фикерләрен дәлилләргә өйрәнә. Шулай ук бу метод укучыларны компьютер белән эшли белергә, электрон почтадан һәм интернеттан файдаланырга өйрәтә.

Укучылар белән проект эшләре эш программаларына кертелгән. Проект эшләрен компьютерда эшләү , презентация төзү укучыларда кызыксыну уята. Укучылар үзләренә кирәкле материалны, рәсемнәрне интернеттан алырга өйрәнәләр.

Проект эшчәнлеге укытучы һәм укучыдан зур түземлек, сабырлык, күп вакыт сарыф итүне сорый. Тиешле нәтиҗәгә ирешү өчен, эш барышында әдәби китаплардан, сүзлекләрдән, интернет аша күп мәгълүмат тупларга, иҗади фикер йөртергә кирәк. Гомумән, проект методы - баланың интеллектын, иҗади сәләтен, логик фикерләвен үстерүдә, кызыксынучанлыгын арттыруда нәтиҗәле алымнарның берсе булып тора.

*Галиева Энҗе Илһам кызы, Юнысова Гөлназ Рамир кызы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «36 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче һәм югары категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучылары.*

**Тормыш яме - яшәүдә, Яшәү яме - гаиләдә!**

Мәктәп һәм гаилә... Психологик статуслары буенча алар капма-каршы. Гаиләдә бөтен нәрсә эмоциональ бәйләнешләргә нигезләнгән.

Мәктәпнең функцияләре башкачарак. Аның максаты балага туган йортын алыштыру түгел, ә баланы укыту, танып-белү сәләтен үстерү, талантын ачыклау һәм ачу.


Шулай булуга карамастан, икесе дә бала өчен иң мөһим урыннар. Баланы тәрбияләүнең эффектлылыгы мәктәп белән гаиләнең нинди бәйләнештә торуына бәйле. Укытучылар һәм ата – аналарның бердәмлеге - куәтле тәрбия көче. В. А. Сухомлинский гаиләне күздә тотып: «Гаиләсез без көчсез булыр идек» дип әйткән.


Туган телебезгә өйрәтүдә укытучы, ата-ана һәм бала арасында бәйләнеш булдыру безнең, туган тел һәм әдәбияты укытучыларының, төп бурычларыннан берсе булып тора.

Туган телне, дәүләт теле буларак татар телен  өйрәнгәндә иң беренче темаларның берсе ул “Гаилә” темасы. Бу бала өчен аеруча мөһим, чөнки аның өчен гаилә —  ул бөтен бер дөнья. Шуңа күрә укучылар белән әлеге теманы үткәндә без дәресләребездә “Нәсел агачы” дип аталган проект өстендә эшлибез. Чөнки һәр кеше үзенең әби-бабаларын, туганнарын белергә тиеш. Башлангыч сыйныфларда әлеге проектны укучыларның үзләренә генә башкарып чыгу бик авыр. Шунлыктан безгә ярдәмгә эти-әниләр килә. Бергә, гади генә гаилә агачларын төзеп, балалар гаилә темасына кагылышлы лексиканы тагын да яхшырак истә калдыралар, аларда үз гаиләләре өчен горурлык хисләре дә уяна, бала һәм ата-аналар арасындагы җылы мөнәсәбәтләр тагы да яхшырак ныгый. Әлеге эшнең аерым мизгелләрен сезгә дә тәкъдим итәсебез килә.




Өлкән сыйныф укучылары алдында исә, үз ата-бабаларыңны белү һәм алар турында истәлекләрне хөрмәт белән искә алу  максаты тора. Нәтиҗәдә, нәсел шәҗәрәсен өйрәнү гаилә әгъзаларының якыннан аралашуына ярдәм итә. Сезгә 10 нчы сыйныф укучылары башкарган проект эшеннән дә өзекне тәкъдим итәбез.







Туган телне өйрәнгәндә укучыларны иң кызыксындырган темаларының берсе  - ул “Татар халкының милли ашлары”. Ата – аналарны уку-укыту процессында актив катнаштыру- мәктәпнең төп бурычларының берсе булуын күздә тотып, без дәресләрдә бу турыда сөйләшкәндә дә эшне әти-әниләр белән берлектә алып барабыз. Башлангыч сыйныфларда өй эш итеп гаилә белән берлектә бер милли ризыкны пешерергә һәм шуның фотосүрәтен алып килергә бирелә. Ә өлкәнрәк сыйныфларда “Без бергәләп милли ашлар пешерәбез” дигән темага видеоролик ясарга тәкъдим ителә. Мондый биремнәр балалар һәм әти-әниләр, әби-бабайлар арасындагы туганлык мөнәсәбәтләрен якынайта, әбиләр әниләргә, әниләр балаларга аш-су осталыкларын җиткерәләр, милли ашлар пешерү үзенчәлекләре белән таныштыралар. Әйдәгез хәзер балаларның өй эшләре белән танышып китик.

Ата-аналар мәктәп тормышында укытучы таләп иткәнгә генә түгел, ә балаларның үсеше өчен кирәклеген аңлап катнашырга тиешләр. Бу очракта ата-аналар һәм балаларның күмәк эшчәнлеген оештыру зур урын алып тора.






Әти-әниләр белән бергә үткәрелгән тематик кичәләр, милли йолаларны сәхнәләштерү, экскурсияләрнең әһәмияте бик зур. Мондый чаралар вакытында балаларда җаваплылык хисе дә арта, үзләрен күрсәтү теләге дә көчәя. Безнең мәктәбебездә дә бик күп бәйрәмнәр әти –әниләр ярдәме белән үтә. Бигрәк тә һәр елны уздырыла торган “Халыклар дуслыгы” фестивале, “Сөмбелә”, “Каз өмәсе” бәйрәмнәре.  Бу чаралар гаилә белән берлектә туган телне кызыксынып өйрәнү максатыннан чыгып эшләнелә. Сезгә дә “Каз өмәсе” йоласыннан өзекне тәкъдим итәбез.






Күргәнегезчә, туган телне, татар телен өйрәнү берьяклы гына була алмый. Әлеге процесста әти-әниләр дә катнашса, эшебезнең нәтиҗәсе дә югарырак була. Ә нәтиҗәгә ирешү өчен мәктәп белән гаилә бер юнәлештә эшләргә тиеш.

*Ганиева Рузиля Фавазис кызы ,*

*Алтынова Гульнара Закир кызы,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «адымнар - Түбән Кама "полилингваль гимназиясе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныф укытучылары.*

**Фразеологизмнар дөньясында**

«Тел ул буыннан- буынга ана сөте белән күчә килгән

һәм күчәчәк мөкатдәс бер мирас. Тел, ниһаять, туган ил,

туган җир ул.» (Х. Сәрьян)

Туган телләрне саклау һәм үстерү Россия алдында торган дәүләт бурычларының берсе, бу күпмилләтле Татарстан өчен аеруча актуаль. Татарстанда 130 милләт вәкиле яши, аларның һәрберсенең үз туган теле бар. Республика халкының яртысыннан артыгы - татарлар, аларның ана теле – татар теле. Милли үзенчәлекне формалаштыруда нәкъ менә туган тел зур роль уйный да инде.

Туган тел дип кешенең балачакта тирә-юньдәге өлкәннәрдән һәм балалардан ишетеп өйрәнгән телен атыйлар, ул кешенең милләтен билгели. Балачактан алып олы яшькә кадәр кешенең бөтен тормышы тел белән тыгыз бәйләнгән. Бала әле сөйләшергә өйрәнмәгән, ләкин ул әнисененең бишек җырларын тыңлый, әкиятләрне, төрле мавыктыргыч сүзләрне ишетә. Еш кына без кеше турында аның эшләре буенча хөкем итәләр дип әйтәбез, әмма кайвакыт сүзнең дә гамәл булуын онытабыз. Кешенең сөйләме - аның көзгесе. Һәр милләтнең дәвамы – балаларда. Әгәр балаларда милли мәдәният юкка чыкса, бу чын фаҗига булачак, чөнки бу халыкның югалуына китерә.

Милләт турында аның мәдәнияте, башкарылган эшләре, язылган әсәрләре, төзелгән корылмалары, уйлап табылган ачышлары буенча хөкем итәләр. Шуңа күрә балаларны халкыбызның гореф-гадәтләрен кулланып, милли үзенчәлекләребезгә нигезләнеп тәрбияләргә кирәк. Үз халкыңның, милләтеңнең мәдәниятен истә тоту, аны ярату гына җитми, аның белән яшәргә кирәк. Шул чакта без тарихта юкка чыкмаячакбыз.

Халык теле – аның үткәнен һәм бүгенгесен күрсәтә торган көзге, анда гасырлар дәвамында милләтебез кичергән иҗтимагый, социаль күренешләр чагыла. Соңгы елларда Татарстанда тел

процесслары шактый деформацияләнгән. Бу, кызганыка каршы, халыкның бер өлеше туган телләрен югалтуга китерә. Шәһәрләрдә яшәүчеләр, үзләре дә сизмәстән, туган телләреннән читләшәләр, аны онытала, чөнки аралашу күбесенчә рус телендә бара. Күп гаиләләрдә ата-аналар балалар белән рус телендә генә аралаша, еш кына алар балаларының мәктәптә туган телләрендә укуларын теләмиләр. Рус, инглиз, кытай телләрен өйрәнәләр, ә туган телне юк. Бу яшь буынның мәдәниятне, традицияләребезне, халыкның данлы үткәнен онытуына, рухи тамырларыннан баш тартуына китерә.

Әйткәнебезчә, балаларга туган телне өйрәтү гаиләдә башлана. Бигрәк тә бу эштә әни кеше әһәмиятле роль уйный. Гаиләдә ана теленә ихтирам булмаса, нинди генә талантлы укытучы укытмасын, баланың туган телен өйрәнүенә ирешү авыр. Шуңа күрә бу проблеманы хәл итүдә гаиләнең ролен арттыру турында уйланырга кирәк. Әгәр шәһәр шартларында гаиләдә туган телгә мәхәббәт тәрбияләмәсәк, без телсез калачакбыз. Ата–аналарның бурычы, иң беренче чиратта, туган телнең матурлыгын һәм байлыгын ачу, үзләре аңлау, өйрәнү, ә аннары балага җиткерү.

Буыннар бәйләнеше – әби-бабайларыбыз туплаган тәҗрибәне киләчәк буыннарга тапшыру, халкыбызның гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен үтәү, ата-бабаларыбыз башлаган эшне дәвам итү, үсеп килүче балаларны милли мәдәнияткә, гореф-гадәтләргә, традицияләргә җәлеп итү ул. Бары тик гаиләдә һәм әйләнә-тирә мохиттә туган телдә аралашу гына телгә, гаилә традицияләренә, милләткә кызыксыну һәм ярату тудыра. Гаилә һәм мәктәп кенә балага үз халкының мәдәни мирасын белергә һәм аңларга, сакларга һәм арттырырга ярдәм итәчәк. Әлбәттә, баланың туган телне өйрәнүгә кызыксынуын уяту өчен, дәресләр, беренче чиратта, кызыклы булырга, уңай эмоцияләр уятырга тиеш.. Ә моның өчен укытучы иҗади эшләргә һәм яңа концепцияләргә таянырга, үз халкының гореф-гадәтләре, традицияләре аша балаларда милли аң формалаштырырга тиеш. Мәктәпләрдә, балалар бакчаларында халык традицияләре белән сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүче чаралар оештырылырга, әңгәмәләр үткәрелергә тиеш. Балачактан ук милли мәдәният, тел кыйммәтләренә ия булырга кирәк. Без барыбыз да үз тамырларыбызны, яшәгән урыныбызны, үткәннәребезне белергә тиеш. Үткәнсез киләчәк юк бит.

Туган тел ул мәдәниятнең бик киң һәм бик үзенчәлекле өлеше, чөнки туган телне белмичә мәдәниятне үзләштерү мөмкин түгел. Милли мәдәният туган тел белән бергә, газеталар, театрлар, телетапшырулар, язучылар, гореф-гадәтләр һәм традицияләр аша үзләштерелергә мөмкин.

Туган телдән баш тарту милли мәдәниятнең юкка чыгуына китерергә мөмкин, туган телнең үсеш дәрәҗәсе - халыкның рухилык күрсәткече. Шулай итеп, һәрберебезнең бурычы - туган телне белү һәм саклау. Ана телен өйрәнгән һәм белгән кеше бернәрсә дә югалтмый, киресенчә, үз халкының тарихын, мәдәниятен һәм милли кыйммәтләрен аңлаган хөрмәтле бер вәкиле була.

Алда язылганча, туган тел - бүгенге һәм үткәнне, үткән һәм киләчәк буынны бербөтен итеп берләштерүче иң мөһим, иң бай, иң зур хәзинә. Хакыйкатькә, игелеккә, матурлыкка һәм бөеклеккә юл Туган тел аша уза икәнен һәрвакыт истә тотыйк.

*Гараева Магинур Абрамовна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "2 нче Кама Аланы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең укытучысы*

## Минем гаиләм – минем бәхетем

**Максат:** Укучыларда әти-әниләребезгә, әби-бабаларыбызга, ярату, кадерләү хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** презентация, компьютер; хәрефләр язылган шарлар (г а и л ә с е м ь я); тәҗрибә үткәрү өчен: су, шикәр комы, вак ташлар; ромашка таҗлары һәм үзәге; өчпочмак пешерү өчен кирәк булган савыт-саба һәм ашамлыклар.

**1. Оештыру өлеше.**

СЛАЙД 1 Укытучы. Исәнмесез,балалар. Хәерле көн!

- Әйдәгез, танышабыз. Минем исемем Маһинур Абрамовна. Мин сезгә "Хәерле көн" дим, ә сез минем янга чыгып үз исемегезне әйтегез. (Укучылар исемнәрен әйтәләр, түгәрәккә басалар. Укытучы берәр шар бирә бара).

- Сезнең кулларда шарлар гадәти генә түгел. Игътибар иткән булсагыз, аларда – хәререфләр язылган. 2 сүз яшеренгән. Берсе русча, берсе татарча. Шарларыбыздан шул сүзләрне төзик әле. (2 төркем булып утыралар. Шарларны өстәлдәге вазаларга утырталар)

**2. Теманы билгеләү**

- Димәк, без бүген нәрсә турында турында сөйләшәчәкбез. (Гаилә турында).

СЛАЙД 2- Бүгенге чарабызның исеме дә "Минем гаиләм-минем байлыгым" дип атала.

**3. Тема өстендә эш.**

1. - Нәрсә соң ул гаилә? Гаилә сүзенең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? (Гаилә – ул сине яратучылар өе, туганнар яши торган өй). - Бик дөрес әйттегез. Бер гаилә кешеләре ул бергә яшәүчеләр, ял итүчеләр, кайгыда да, шатлыкта да бердәм булучы кешеләр.

СЛАЙД 3 ТР тел һәм әдәбият, сәнгать институты карары нигезендә төзелгән аңлатмалы сүзлектә нинди аңлатма бирелгән икән, бергә укыйк әле. - Гаилә - бергә яшәүче ир, хатын,

балалар һәм якын туганнардан торган кешеләр төркеме; С.И. Ожегов төзегән русча аңлатмалы сүзлектә Семья - группа живущих вместе близких родственников, диелгән

2. - Балалар, безнең һәрберебезнең гаиләсе бар. Ничек уйлыйсыз, кешегә гаилә ни өчен кирәк? (гаиләдә бер-берсен аңлыйлар, яраталар, хөрмәт итәләр, бер-берсенә булышалар).

- Сез гаиләгез белән бергә нәрсәләр эшлисез? Ял вакытларын ничек уздырасыз? СЛАЙД 4 Төркемнәрдә эшләп алабыз. Сезнең алда шөгыльләр язылган тасмалар бар. Кайсылары сезнең гаиләләргә туры килә? Сайлап алыгыз ( телевизор карау, чаңгы шуу,бакчада эшләү, китап уку, туган көн бәйрәмен уздыру, әби-бабайга кунакка бару ).

- Балалар, мин дә үземнең гаиләм белән булган шөгыльләремне яздым. (Тактага эләм. Төркемнәр  чиратлап укыйлар. Мин үземнекен карап, билгеләп барам. Төркемнәрдә туган көн юк.)

- Ә сезгә кирәкме ул? Ә бу матур бәйрәмдә сез нәрсәләр эшлисез? (биибез, җырлыйбыз, уеннар уйныйбыз). Нинди уеннар уйныйсыз?

- Әйдәгез без дә сезнең белән “Ак калач” җырлы -уенын искә төшереп уйнап алыйк әле.

- Җырдан күренгәнчә, элек бәйрәмнәрдә ак калач пешергәннәр. Хәзер нәрсә пешерәләр?

- Гомумән, сезнең гаиләдә инди ризыклар-ашлар  пешерәләр? (Санап китәләр).

Нинди генә бәйрәм булса да, һәр гаиләдә әти- әниләләр кунакларны бәйрәм табыны белән каршы ала. Ә инде өстәлләр төрле тәм-том белән тула. Әйдәгез кайберләрен атап китик әле.СЛАЙД 5

- Бу ризыкларга тагын бер тапкыр карагыз әле. Аларны нәрсә берләштерә? (Татар халык ашлары).

- Балалар, бу ашларны сезнең гаиләдә кем пешерә соң? Ә кемнәр булыша?  - Миңа калса, монда нәрсәдер җитми, шулай түгелме? (Өчпочмак). Ә сез аны пешергәндә дә булышасызмы?

- Әйдәгез бергәләп өчпочмак әзерлик әле. Өстәл янына үтәбез. Эшкә тотынганчы кайбер кагыйдәләрне искә төшереп китик. Укучылар әйтәләр. (Башлык, алъяпкычларны кияләр, кулларны юалар).

- Әйдәгез башта өчпочмакның нәрсәләрдән торганын, ягъни рецептын искә төшерик (сөйлиләр). Монда ул әйберләрнең барысы да бармы? Иң беренче эшне нәрсәдән башлыйбыз? Әзер камырны кул белән генә йомшартып түгәрәк ясыйбыз. Бәрәңге суган, итне бергә болгатабыз һәм түгәрәгебезгә салып өчпомак формасында читләрен ябыштырабыз. (Бер-берсенә булышыалар. Эшлиләр. Табаны майлап, өчпочмакларны төзәләр.)

- Менә булды,  бик матур килеп чыкты. Аларны алып куйыйк. Сез әти-әниләрегезнең бик тә уңган кыз һәм уллары булып чыктыгыз. Аш бүлмәсендә аларның менә дигән булышчылары.

- Элек-электән күмәк эшләрне җырлар җырлап эшләгәннәр. Сездә бармы андый күренеш? Нинди җырлар җырлыйсыз?

- Әниләр турында җырлар беләсезме?СЛАЙД 6 (“Кояш гомере” җырын җырлау) Өстәлне сөртәләр, аляпкычларын салалар һәм урыннарына утырылыр.

- Димәк, сез бергә эшлисез, бергә ял итәсез, бәйрәмнәр үткәрәсез. Бу нинди гаиләдәге күренешләр? (дус, тату). Сезнеңчә, тату гаиләгә тагын нинди сыйфатлар хас? СЛАЙД 7

- Татулыкның нигезендә бер-береңне аңлау, бер-береңә юл кую, җитешсезлекләрне, хаталарны кичерә белү, авыр сүзләр әйтмәү ята.

- Тәҗрибә. Төркемнәрдә эшлибез. 1 стакандагы суга шикәр салыгыз. Болгатып җибәрегез. Ә 2 стакандагы суга вак ташларны салыгыз, болгатыгыз. Нәрсә күрдегез? (шикәр эреде, таш су төбендә калды).

- Шикәр комын, бу вак ташларны сүзләр итеп күз алдына китереп, ясаган тәҗрибдән чыгып, нәрсә әйтә аласыз? (Җаваплар)

СЛАЙД 8 - Балалар, ягымлы, матур сүзләр дә менә шушы шикәр сыман кеше күңеленә эреп тарала. Ә начар сүзләр каты таш сыман кеше күңеленә төшеп утыра да тырнап тора. Начар сүз әйтеп, өлкәннәрнең хәтерен калдыргансыз икән, гафу үтенегез. Үз гаебеңне таный белү, гафу үтенә белү – бик кирәкле сыйфат.

- Инде өчпочмакларыбызны мичкә тыккан булсак, алар менә шундый булып пешкән булырлар иде. Мин сезнең өчпочмакларыгызны алып кайтып пешерермен, ә сез минекннән авыз итеп карарсыз. (Тәлинкә белән пешкән өчочмаклар чыгарып, балаларга өләшә)

**Рефлексия**

- Балалар, үзегезнең гаиләләрегезгә нәрсәләр теләр идегез? Өстәллләрдәге ак таҗларга теләкләрегезне язып, тактага беркетәбез. Мин үземнең гаиләмә иминлек телим. (Ромашканың сары үзәгенә язып тактага беркетәм, балалар-таҗларны) Менә шундый матур ромашка чәчәге ясадык без теләкләребездән. СЛАЙД 9 Гаиләгә аның нинди катнашы бар соң? (Гаилә символы, 8 июльдә Гаилә көне бтлгеләп үтелә)

- Шуның белән чарабыз тәмам. Мин барлык гаиләләргә бәхет, шатлык, сәламәтлек, бердәмлек телим.

*Гарипова Лилия Рауфовна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Каенлы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбият укытучысы*

**Әдәбиятның якты йолдызлары**

Рус әдәбиятын Александр Сергеевич Пушкиннан башка, татар әдәбиятын Габдулла Тукайдан гайре күз алдына китереп булмый. Г. Тукай яңа татар әдәбиятына нигез салган, милли үзаңны раслаган, ныгыткан, шуның белән үзенең исемен мәңгеләштергән.

Ни өчен бу ике шагыйрь дә милли шагыйрь югарылыгына күтәрелә алган. Моның сере нәрсәдә?

**Шагыйрьлекнең югары баскычы**

Тукай турында сүз чыктымы, еш кына күңелгә бер сорау килә: ничек итеп гади генә бер авыл ятиме санаулы еллар эчендә күп гасырлык, бай тарихлы татар әдәбияты күгендә балкып янучы йолдызга әйләнгән һәм замандашларын да, киләчәк буынны да үзенә берьюлы җәлеп итә алган?

Моның сере , иң беренче чиратта, табигать биргән сәләтендә. Талантлы шәхес тарих мәйданына чыксын, күренсен өчен, билгеле бер иҗтимагый шартлар кирәк. Тукай өчен бу:

1) 1905 елгы инкыйлаб

2) Әйләнә- тирә, мохит. Тукайның мохите – Кырлай, Мотыйгия мәдрәсәсе, әдәбиятка ихтирамы булган яңа фикерле кешеләр- аның шагыйрь булып үсеп китүенә зур этәргеч бирә.

3) Рус әдәбияты белән танышу, аның аркылы көнбатыш классик әдәбияты вәкилләре – Гете, Гейне, Шиллер, Байроннарның эстетик фикерләрен өйрәнү дә аның иҗади үсешендә хәлиткеч роль уйный.

Тукай иҗаты турында сүз алып барганда, аның эшчәнлеген рус әдәбиятында А. С. Пушкин башкарган хезмәткә охшаган.

Беренчедән,Тукай да, Пушкин да халык авыз иҗатына мөрәҗәгать иткәннәр, күп кенә әсәрләрен халык иҗатына нигезләнеп язганнар.

Г. Тукай халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, аларны фәнни яктан эшкәртүгә зур өлеш кертә. 1910 нчы елда “Халык әдәбияты” дигән темага доклад укый, “Халык моңнары” исемле иң яхшы татар җырларыннан торган җыентык чыгара, халык иҗатын нигезләнгән әсәрләр иҗат итә. Пушкинның да Рус мәдәнияте турында язылган хезмәтләре бар.

Икенчедән, Тукай да, Пушкин да милли телне үстерүгә зур өлеш кертәләр. Г. Тукай туган тел мәсьәләсен иҗади якын килеп чишәргә омтыла. Халык сөйләменә нигезләнгән милли әдәби телне үстереп җибәрә. “халык әдәбияты” дигән мәкаләсендә: “ Чын халык телен, чын халык рухын бары тик халык җырларыннан гына табып була”, - дип яза ул. Тукай татар теленең хәзинәсе белән оста эш итә. Бер үк сүз аңарда күптөрле мәгънә төсмерләрен белдерә. Ул күчерелмә мәгънәдәге сүзләр, сәнгатьчә сурәтләү алымнарын һәм төрле символик чараларны куллана.

Өченчедән, Г. Тукай әдәби тәнкыйтькә нигез салучыларның да берсе. “Шигырьләребез”, “Тәнкыйть кирәкле шәйдер” дигән тәүге тәнкыйди мәкаләләре аеруча игътибарга лаек. Шагыйрь

татар әдәбиятында тәнкыйть булырга тиеш дип карый. Аның фикеренчә, башка хезмәт белән шөгыльләнгән кеше басылып чыккан барлык әсәрләрне дә укып бара алмаска мөмкин. Безнең өчен аларны әйбәтләп укып, җитешле- җитешсез якларын аңлатып баручы махсус укымышлылар- тәнкыйтьчеләр кирәк. “Тәнкыйтьче булу өчен, - ди Тукай, - тәҗрибәле вә әхлаклы адәм булу кирәк. Һәр язучы, иң әвәл, үз- үзенә, шәхси иҗатына карата тәнкыйть белән карарга тиеш.”

А.С. Пушкин А. С. Грибоедовның “ Горе от ума” әсәре турында “ Пушкин- Вяземскому” дигән тәнкыйть мәкаләсен яза.

Дүртенчедән, Тукай иҗатында рус һәм Көнбатыш Европа әдәбияты үрнәкләрен тәрҗемә итү яки алардан файдаланып язу шактый урын алып тора. Пушкин, Лермонтов, Толстой, Крылов, Кольцов, Жуковский, Майков, Плещеев әсәрләре белән беррәттән шагыйрь Көнбатышның күренекле язучылары Гейне, Байрон, Моппасан, шекспир, Гете иҗатына да мөрәҗәгать итә. Тукайның һәм әлеге язучыларның әсәрләре арасында кайбер эчтәлек, сюжет, фикер якынлыгы күсәтелсә дә, аларның күбесен бер үк әсәр рәвешендә тәңгәл куеп булмый.

Шагыйрьнең тәрҗемә әсәрләрендә милли характер тудыруы күренә. Мәсәлән, Крыловның “Два мальчика” әсәрендәге Сеня һәм Федя исемле малайларны Гариф һәм Зариф дип ала.

Пушкин да тәрҗемәнең матур үрнәкләрен тудыруга үз өлешен кертә. Мәсәлән, Боржурның “ Муж волокита” әсәрен бик уңышлы тәрҗемә итә.

**Тукай һәм Пушкинның иҗатындагы уртак мотивлар**

Һәр ике шагыйрьнең иҗатында түбәндәге темаларны очратырга була:

1) Шагыйрь һәм халык
2) Фәлсәфи шигырьләр
3) Мәхәббәт лирикасы
4) Табигать лирикасы
5) Шагыйрь һәм шигърият
6) Шагыйрь һәм туган як
7) Дуслыкка мөнәсәбәт
8) Дингә мөнәсәбәт
9) Милләтләр дуслыгы

Берничәсе белән танышабыз

Тукай һәм Пушкин икесе дә гаилә бәхете, ата- ана мәхәббәте татымаганнар. Бу уртаклык аларның иҗатында ачык чагыла. Тукайның бала чактагы истәлекләре, туган ягына мәхәббәте “Шүрәле”, “Туган җиремә”, “ Исемдә калганнар” әсәрләрендә күрсәтелә. Пушкинның лицей

елларына багышланган  “Царское село”, “Пирующие студенты”, “ Товарищам” шигырьләрендә яшүсмер шагыйрьнең рухи халәте, тормышка карашы тасвирлана.

Бу ике шагыйрь дә, төрле чор шәхесләре булсалар да, данлы көрәш елларында яшиләр. 1905 нче ел инкыйлабы тукай иҗатына юл ача.  Тукай инкыйлаб  дулкыны белән авыл малае, мәдрәсә шәкерте дәрәҗәсеннән шагыйрь, зур көрәшче, хөр авазлы, иҗтимагый эшлекле дәрәҗәсенә күтәрелә. Шагыйрьлек бурычын ул, беренче чиратта, хезмәт халкы өчен иң мөһим мәсьәләләрне күтәрү дип карый, үз чорының иң әһәмиятле мәсьәләләренә аваз биреп бара. Мәсәлән, 1905 елның 17 октябрь манифесты белән халыкка кайбер азатлыклар вәгъдә ителә. Шул уңайдан Тукай халык кәефен чагылдырган шигырьләр яза. “ Дустларга бер сүз”, “Хөррият хакында”, “ Яз галәмәтләре”.

Пушкин яшәгән чорда декабристлар восстаниясе була. Турыдан- туры катнашмаса да, шагыйрь аларга теләктәшлек итә. Аның күп кенә дуслары сөргенгә озатыла: Рылеев, Кюхельбекер, Пущин, Раевский. Бу вакытта Пушкин үзе дә патша тарафыннан җәберләнә: Михайловское авылында 1824 елдан 1926 елга кадәр полиция һәм дин күзәтүе астында тора. Бу елларда ул үзенең язмышын чагылдырган “ Узник”, “ К морю”, “ Арион” кебек әсәрләрен яза.

Тукай -  рус реалистик поэзиясен кабул иткән беренче көнчыгыш шагыйре.  Ул әдәбият мәйданына хәзерләнгәндә, рус классикларыннан байтак кына исемнәрне күздән кичерергә өлгергән. Әмма болар арасында аеруча Пушкин поэзиясе аны үзенә нык җәлеп иткәнлеге, искиткеч рухландырганы бәхәссез.  Тукайның беренче әдәби тәҗрибәләрендә үк, “ шагыйрь һәм халык” кебек теманың, яки үзенең шагыйрьлек миссиясен, урынын аңлау тирәсендәге мәсьәләләрнең сизелә башлавында да теге яки бу күләмдә Пушкин һәм Лермонтовка бәйләнеш бар.( “ Көзге җилләр”, “ Үз- үземә”)

Пушкин да, халыкка мөрәҗәгать итеп, “ К Чаадаеву”, “ Анчар” кебек шигырьләрен иҗат итә.

Тукайның Ватанга мәхәббәте- туган як табигатенә, туган теленә, әкият- җырларына мәхәббәт ул.  Аның туган җирне яратуы, бигрәк тә, “Шүрәле”, “Туган җиремә”, “ Пар ат” шигырьләрендә чагыла.

Пушкин шау-гөр килеп торган баллар, кичәләр үзәгендә кайнаса да, күңел тынычлыгын авылда, ялгызлыкта таба. “Деревня”, “Домовому” шигырьләрендә шул чактагы кичерешләре аеруча тулы чагыла.

Габдулла Тукай Казанга килгәч, якын дуслар таба. Алар арасында Ф. Әмирхан, Г. Камал, С. Рәмиев,С. Сүнчәләй, Х. Ямашевлар бар.

А.С. Пушкин да Царскосельский лицейда укыган дусларына тугры кала. Аларның күбесен сөргенгә җибәргәндә дә, күңеле белән алар арасында була.    Дусларына тугрылыгы “ К Чаадаеву”, “ Товарищам» шигырьләрендә күрендә.

Г. Тукай үзенең җиде буын мулла нәселеннән килүен бик яхшы белә, үз дәрәҗәсен беркайчан да төшерми. Мәдрәсә тәрбиясе ала. Күп кенә шигырьләрендә Коръән мотивлары яңгырый, мәсьәлән, " Таян Аллага", "Ана догасы", "Тәэссер", "Кадер киче". Габдулла Тукай өчен дин- яшь буынны тәрбияләү, гыйлем һәм мәгърифәт чарасы. Шуңа күрә ул динне пычратучы, диннән бары тик керем- файда эзләүче рухани- түрәләрне тәнкыйтьләгән шигырьләр яза.

А. Пушкин да көньякта сөргендә булганда коръән китабын тәрҗемәдә укый. Бу Бөек китап аны шул дәрәҗәдә үзенә тарта, рухландыра, нәтиҗәдә, иҗади җәүһәрләренең берсе булган " Коръәнгә иярүләр" ( "Подражания Корану") исемле шигырьләр бәйләме туа.

Әйе, Г. Тукай һәм А.С. Пушкин - чын мәгънәсендә үз халкын, аның гореф- гадәтләрен, тел һәм мәдәниятен, шатлык һәм хәсрәтен, теләе һәм өметләрен һәркемгә караганда яхшырак белүче милли шагыйрьләр. Алар халкының хөр тормышта яши алмавына сызлана һәм аны иректе, бәхетле итеп күрергә тели.

Бөек шагыйрь булу- бөтен дөньяга танылу, олуг мәртәбә, дәрәҗә. А.С. Пушкин һәм Г. Тукай- нәкъ менә инде ике халыкның тиңдәшсез, бер биеклектә торырга лаеклы шагыйрьләре! А.С. Пушкин һәм Г. Тукай - әдәбият күгенең ике якты йолдызы!

Файдаланган әдәбият исемлеге.

1. Башуров Р. Тукай һәм рус әдәбияты. – Казан, Тат. кит. нәшер., 1993
2. Нуруллин И. Тукай.- Казан, Тат. кит. нәшер., 1979
3. Рәсүлева З. Тукай эзләреннән.- Казан, Тат. кит. нәшер., 1985
4. Халит Г. Тукай иҗаты. .- Казан, Тат. кит. нәшер., 1986

*Гимранова Ильсеяр Гарафутдин кызы,*
*Аглиева Айгуль Магфуряновна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районын "аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 27 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең, татар теле һәм әдәбият укытучылары*

## Укучыларның фәнни-тикшеренү эшен оештыру

Белгечләр исбатлавынча, сәләтле балаларның нәрсәгә сәләтле булулары билгеле бер шартларда ачыклана. Бу нәселдәнлеккә генә бәйле түгел, монда баланың тирә-ягындагы

кыйммәтләр системасы да зур әһәмияткә ия. Билгеле бер шартлар булдырганда, укучыларның күбесендә теге яки бу сәләтне үстерергә мөмкин.

Без, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, һәр укучының туган телен, халкының тарихын тирәнтен өйрәтү, аларга карата мәхәббәт нисләре тәрбияләү максатынна, үз каршыбызда иҗади бурычлар куябыз.

Сәләтле укучылар белән эш формалары: сәләтле укучылар белән группалап эш: факультативлар, кызыксынуына карап түгәрәкләр; конкурслар; электив курслар; индивидуаль план буенча эш...

Һәр сыйныфта фәнгә карата нык кызыксыну, күп белергә теләү хисләре белән янган укучылар бар. Аларның сәләтен тагын да үстерү, фәнгә карата кызыксыну максатыннан, мин дә укучылар белән төрле юнәлештә эшләр алып барам. Шуларның берсе – укучыларны фәнни-эзләнү конфенецияләрен әзерләү.

Фәнни-эзләнү конференцияләренең бурычлары:

1. Укучыларның эзләнү эшчәнлеге белән кызыксынуларын һәм һәвәскәрлекләрен иртәрәк ачыклау, аларның иҗади потенциалларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру.

2. Укучыларга һөнәри юнәлеш билгеләргә ярдәм итү.

3. Балаларны мөстәкыйль эзләнү эшләренә әзерләү, фикерләргә өйрәтү.

4. Гамәли әһәмиятле булган тикшеренүләр, эзләнүләр үткәрү, эзләнү-тикшеренү проектларын эшләү һәм аларны тормышка ашыру.

5. Фән, техника культура казанышларны пропагандалау.

Фәнни-тикшеренү эшенә керешкәнче, әзерлек эшләре алып бардым, аннан соң фәнни-тикшеренү эшчәнлеге башланды. Шундый бер эшемнең тәҗрибәсен тәкъдим итәм.

Беренчедән, мин фәнни-тикшеренү эшен башкару юлларны, кайбер кыен якларын (мәсәлән, чыганаклар эзләп табу), үз фикереңне ачык итеп аңлата белү һәм башка кешеләрне (галимнәрнең) фикерен үзеңнеке итеп тәкъдим итүнең (плагиатлыкның) фән этикасы нормаларына каршы килүе турында төшендердем. Чыганакларны туплау, системага салу юлларын аңлаттым.

Икенчедән, әдәби, тарихи характердагы темаларны тәкъдим иттем. Мәсәлән, “Г.Ибраһимов әсәрләренең теле” темасын сайлаганнан соң, төп эш – чыганаклар эзләп, материаллар туплау эше башланды.

Өченчедән, укучыларны картотека, журнал төпләнмәләре белән эшләргә өйрәттем. Теманы ачу өчен кирәк булган төп маериалларны таптык. “Яз башы”, “Көтүчеләр” хикәясендә төрле әдәби сурәтләү чараларының бирелешен табуны “Кызыл чәчәкләр” повестендә образларның төрле поэтик бизәкләр белән сурәтләнешен ачуны максат итеп алдык.

Дүртенчедән, фәнни эшнең планы төзелде һәм материаллар белән танышу башланды. Укучылар моңа кадәр Г.Ибраһимов хикәя, повесть ларын укып чыктылар.

Бишенчедән, фәнни хезмәтнең кереш өлеше язылды: актуальлек, төп максатлар, бурычлар билгеләнде: бу өлкәдә эшләгән галимнәр, аларның хезмәтләре күрсәтелде. Мәсәлән, кереш өлеш. Фәнни-тишеренү эшемнең максаты: Г.Ибраһимовның әсәрләренең телен өйрәнү, “ Яз башы”, ”Көтүчеләр”, “Кызыл чәчәкләр” әсәрләрендә сурәтләү чараларын табу.

Фәнни-тишеренү эшемнең бурычлары:

1) Г.Ибраһимовның табигать күренешләрен зур уйланулар аша җанландыруын билгеләү.

2) Язучының хикәяләрендә әдәби-сурәтләү чараларының төрлелеген раслау.

3) Г.Ибраһимовның зур тел остасы булуын күрсәтү.

Төп өлештәге эзләнү эшеннән өзек:

“Яз башы” хикәясендә табигать күренешләрен тасвирлаучы чагыштырулар:

1. Бу киң вә дулкынлы үлән диңгезенең нәкъ уртасыннан *назлы кыз йөреше кеби* боргаланып-боргаланып аккан *елга* үзенең көмештәй ялтыраган төсе белән бөтен тирә-якның күркен әллә ничә кат арттырып җибәрә (Хикәяләр, 7).

2. Бар да *хәтфәдәй үлән белән* түшәлеп, сары, кызыл, ал чәчәкләр белән матурлаганнар (Хикәяләр, 7).

3. Болар өстенә *тау-таш җимерелердәй булып күк күкри,* бер минут бөтен дөньяны *утка чолгардай* күренгән коточкыч *яшен* яшьни башлады (Хикәяләр, 13).

4. ...шул минутта *яшен* башыңа тиеп, бөтен *гәүдәңне* яндырып ташлар *кеби* тоела иде (Хикәяләр, 13).

Эпитетларның бирелеше:

1. Яңа гына чыга башлаган балтырган көпшәләре (Хикәяләр, 11).

2. *Йомшак вә җылы* суда бик рәхәт булып калды (Хикәяләр, 11).

3. *...уҗымнардан чыккан җылы һава* чәчәк исләре белән бергә кушылган... (Хикәяләр, 12).

4. Кояш баеша ягыннан *кара куе болыт* чыгуы безне тагын борчый башлады (Хикәяләр, 12).

5. Тагы ныграк *калыная да, карала* да төшә (Хикәяләр, 12).

Метафоралар:

Алар *телләренә* салыштылар (Хикәяләр, 12).

Ләкин *күңел сүнгән* иде (Хикәяләр, 12).

“Йә*, сыерланмагыз,* тизрәк булыгыз (Хикәяләр, 13).

Әзер хезмәтнең кереш, төп һәм йомгаклау өлешләреннән төп фикерләрне кыска гына итеп язып алырга туры киләчәк, моны абзацларга бүлеп эшләгәндә тагын да җиңелрәк булачак икәнлеген аңлаттым.

Гомумән, фәнни хезмәт язарга алынган укучы белән эшләгәндә укытучыдан тактлылык, осталык һәм, әлбәттә, эрудиция таләп ителә.

*Гиниятуллина Алсу Рафисовна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «35нче лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияте укытучысы*

**Мастер-класс**

**Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә сөйләмне үстерү чарасы буларак театр уеннары**

- Хәерле иртә, хезмәттәшләр! Мин Гиниятулина Алсу, туган тел һәм әдәбияты укытучысы.

- Коллегалар, уң кулыгызны күтәрегез, хәзер сул ягыгызга карагыз. Башыгызны уңга, аннары сулга борыгыз. Бу эшләрне башкару кыен булдымы? (Җаваплар тыңлана).

- Хәзер кан тамырларын киңәйтергә, йөрәк тибешен тизләтергә, канга адреналин җибәрергә тырышыгыз. Сез моны эшли алдыгызмы? (Җаваплар тыңлана). Чынлыкта, сез барысын да эшли аласыз! Нинди очракта? Уйлап карагыз. (Җаваплар).

- Көтелгән җавап: бу хисләр һәм тойгылар аша эшләнә.

- “Кеше акыллырак булсын өчен, аны эмоциональ яктан селкетергә кирәк. Сез аны кайгы – шатлык үлчәвендә генә селкетә аласыз: Башка үлчәүләр юк,”- ди Дмитрий Йемец - балалар фантастик язучысы. **(***На экране: «Чтобы человек стал мудрее, его надо эмоционально раскачать. А раскачать его можно только на весах: огорчение — радость. Других весов нет. (Дмитрий Емец-детский писатель-фантаст).)*

- Әйе, мин риза, бу дөрес. Хисләр кешеләрне югары үсеш дәрәҗәсенә күтәрә. Укучылар ничек эмоциональ, көчле хисләр кичерә? Бу максатка ирешү өчен мин дәресләрдә театр уеннарын кулланам. Мин сезгә аларның берничәсен тәкъдим итәм. Минем хөрмәтле хезмәттәшләрем миңа булышырлар дип уйлыйм.

3 фокус төркемгә 3әр кеше чакырам. Һәм һәр төркемгә биремнәр бирәм.

1нче төркемгә бирем. Сезгә, хезмәттәшләр, "Утыр" сүзен берничә семантик күләгә белән әйтергә кирәк булачак.

1) сорау, үтенеч

2) каты, үткен

3) курку белән кушылган борчылу хисләрен белдерү

2нче төркемгә бирем. Сез үзегезне хастаханәдә стоматолог кабинетында итеп күз алдына китерегез. "Сез тешләрегез белән хушлашырга тиеш!" - ди теш табибы. Бу сез курыккан иң начар кичереш! Монда сезгә ярдәм итә алган якын кешегез белән килдегез. Ул сезнең янда утыра, сезне тынычландыра, кулыгызны ала. Ләкин бу вакытта аның телефоны шалтырый. Ул урыныннан торып, аңа шул секундта китәргә кирәк. Бу очракта “Утыр” сүзен тиешле мәгънә белән әйтегез. 3нче төркем төрле рольләр уйнап, әсәрдән өзек укыгыз. 1) Шагыйрь. 2) Солдат 3) Рэп артисты. 4) Сәясәтче.

***Кызыклы шәкерт (1910 г.)***

***Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор;***

***Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!***

Театр уеннарын куллану сөйләмнең яхшыруына зур йогынты ясый, чөнки персонажларның сүзләрен һәм үз сүзләренең экспрессивлыгы өстендә эшләгәндә, укучының сүз байлыгы арта, сөйләм осталыгы шомара.

3 төркемнең дә чыгышларын тылыйбыз.

Театр могҗизалар башкара: ул мәктәп укучыларының күңелен ачу, тәрбияләү, иҗади сәләтләрен үстерү, эмоциональ үсешкә ярдәм итү, балаларның сөйләм һәм ораторлык сәләтен үстерү, аларга үз-үзләренә ышаныч бирә, халык алдында сөйләү осталыгын арттырырга ярдәм итә.

Сез караган уеннарны дәреснең белемнәрне яңарту, системалаштыру этабында кулланылырга мөмкин.

Фокус төркеме үз урыннарын ала.

2017нче елдан башлап татар телен өйрәнү ата-аналар сайлавы буенча укытыла. Вакыт таләпләренә туры китереп, укучыларны татар теле дәресләре белән кызыксындыру өчен, уңышлы методик алымнар эзләргә, төрле кызыклы, яңа технологияләр һәм техниканы кулланып эшләргә кирәк. Шул вакытта гына без үз максатыбызга ирешә алырбыз һәм укучылар зур теләк, кызыксыну белән туган татар теле дәресләрен өйрәнерләр.

Минем үз тәҗрибәм белән уртаклашасым, әкияттән өзекләр күрсәтәсем килә. Без укылган әсәрләрне, әкиятләрне сәхнәләштерү өстендә 5 сыйныф белән эшләдек һәм быел аның өстендә эшләвебезне дәвам итәбез.

*Гобәйдуллина Илгизә Хәниф кызы,*
*Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы "Калмия төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*

**Башлангыч сыйныф укучыларында функциональ грамоталылык формалаштыру чаралары**

Максат:

1. Белем сыйфатын арттыру чарасы буларак укытучының функциональ грамоталылыгы буенча белемнәрне тулыландыру;

2. Тыңлаучыларны кулланма биремнәрнең төрләре белән таныштыру,

Бурычлар:

1. Мастер-класс темасы буенча эш тәҗрибәсен тәкъдим итү.

2. Укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыруга юнәлтелгән Кейс – технология кулланып, катнашучыларның практик эшчәнлеген оештыру.

3. Практик эшчәнлектә аларны куллануның максатка ярашлы булуына инандыру

Нәтиҗә: катнашучылар функциональ грамоталылыкны формалаштыруга системалы якын килү мәсьәләләре буенча яңа мәгълүмат алачаклар, төрлелечә эшләү төрләрен практикада кулланачаклар.

Ресурслар: презентация ,компьютер, проектор, экран, күрсәтмә материаллар

Төп олеш

Билгеле булганча, функциональ грамоталылык 6 юнәлешне үз эченә ала:

1. математик;

2. табигый-фәнни;

3. финанс грамоталылыгы;

4. иҗади фикерләү;

5. глобаль компетенцияләр;

6. уку грамотлылыгы.

Укытучы эшендә, функциональ грамоталылыкны формалаштыру процессында, төп юнәлешләрнең берсе-фикерләү сәләтен үстерү, визуаль-күренештән абстракт-логикага ничек тәрҗемә итәргә, аналитик-синтетик сәләтләрне, хәтерне һәм игътибарны ничек үстерергә ктрәклеге күрсәтелә.

Практик өлеш

Хөрмәтле укытучылар! Бүген мин сезгә башлангыч сыйныф дәресләрендә предметны өйрәнү мисалында функциональ грамоталылык формалаштыру өчен төрле бирем вариантларын карарга тәкъдим итәм. Шулай итеп, без «Ничек дөрес тукланырга кирәк? Әйләнә-тирә дөнья фәне комплексны, (интеграцияләнгән) фән булганлыктан, алты юнәлеш буенча да функциональ грамоталылык формалаштырырга мөмкин.

Хәзер сезгә берничә очрак тәкъдим итәм. Ике командага бүленеп эшләргә туры килер. Без сезнең белән кибеткә барырбыз, кибеткә баргач, беренче команда кәрҗинне файдалы азык-төлек белән, ә икенче команда кәрҗинне организм очен зарарлы булган азык-төлекләр белән тутырырга тиеш. Ике команданың да кәрҗиндәге азык-төлек бәяләрен куар код ярдәмедә санарбыз. Кайсы кәрҗиндәге ризыклар отышлырак?

Әдилә белән Алия күршедә генә яшәүче дус кызлар. Алар күп вакытларын бергә уйнап үткәрәләр. Кайвакыт аларны игезәкләр дип тә йөртәләр икән. Кызлар яши торган гаиләләр дә үзара тату яшиләр икән.

Беркөнне алар мәктәптән кайтышлый, үзләре җыйган акчага тәмле азык-төлек алырга кибеткә юнәләләр. Шунда гына кызлар үзләрендә булган аерманы беләләр. Әдилә файдалы ризыклар белән туклануга өстенлек бирә икән бит, ләбаса. Ә Алия киресенчә,аны төрле тәм-томнар кызыктыра икән. Шуңа күрә Әдилә банан, кишер, әфлисун һ.б. ала. Ә Алия суши, көнҗетле күмәч, роллы һ.б. сатып алалар. Әйдәгез, кызларга ярдәм итик. Кемнең кәрҗинендәге ризыклар ничә сум булды икән. Кибеттән алганда файдалы ащык-төлекләр кыйммәтрәк микән, әллә инде киресенчә зыянлылары микән?

Рефлексия

– Без сезнең белән бергә куелган максатка ирештекме?

– Мастер-класс барышында сезнең өчен нәрсә ачылды?

– Яңа алынган мәгълүмат белән бәйле нинди сораулар туды?

Мин бу мастер-класста уку грамотлылыгы, математик һәм финанс грамотлылыгын файдаландым.

Мастер-класска йомгак ясап, шуны әйтәсем килә: башлангыч сыйныфларда функциональ грамоталылык формалаштыру кейс-технологияне куллану нигезендә төрле мәгълүмат чыганаклары һәм формалары белән эшләү процессында гамәлгә ашырыла. Ул таблицалар, иллюстрацияләр, һ.б. буларак күрсәтелергә мөмкин. Шуңа күрә мондый системалы эш укучыларда инструкцияләрне аңларга, үз эшчәнлекләрен планлаштырырга, үз фикерләрен әйтә белергә ярдәм итә.

Мастер-классны мин Алексей Алексеевич Леонтьев, лингвист, психолог, психология һәм филология фәннәре докторы сүзләре белән тәмамлыйсым килә: «Функциональ яктан белемле кеше – ул кеше эшчәнлегенең, аралашуның һәм социаль мөнәсәбәтләрнең төрле өлкәләрендә

тормышта өзлексез алына торган барлык белемнәрне, күнекмәләрен куллана ала торган кеше». Бу сүзләр укучыларыбызга да, педагогларыбызга да яхшырак аралашырга ярдәм итә!

*Гыйлфанова Гульназ Рашит кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "28 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесең югары категорияле,*
*Мингәрәева Гульсара Минрахимовна,*
*беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Татар әдәбияты дәресләрендә модельләштерү алымын куллану**

**Максат:** 1) Модельләштерү алымы белән таныштыру.

2) Эш тәҗрибәсе белән уртаклашу.

Бу максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны куябыз:

1)Модельләштерү алымын тормышка ашыру, алгоритмын күрсәтү. 2)“Катнашучылар” һәм “эш - гамәлләр” төшенчәләрен аңлату.

Чыгышыбызны профессор Әхмәт Зәки улы Рәхимовның сүзләре белән башлыйсы килә. “Иҗадилык – үз шәхесеңне, фикерләвеңне, аң һәм интеллектыңны даими камилләштерү. Иҗади эшчәнлектә кеше үсә, махсус тәҗрибә туплый, үзенең табигый сәләтен һәм мөмкинлеген ача, ихтыяҗын канәгатьләндерә”.

Без дәресләрдә Әхмәт Зәки улы Рәхимовның “Иҗади үсеш технологиясе алымын” актив кулланып киләбез. Бигрәк тә педагогика фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты хезмәткәре Мозаффарова Мингаян Гаяз кызының хезмәтләре зур ярдәмлек булып тора.

Бүген өйрәнеләчәк алым – модельләштерү алымы, ул – иҗади эш, укучыларда әдәби әсәрне тизрәк аңларга ярдәм итә. Әсәрне өйрәнүгә зур кызыксыну уята.

Ә хәзер Ф.Кәримнең 4 нче сыйныф дәреслегендәге “Яз җитә” шигыренә модель төзибез.

Дәрескә уку мәсьәләсен куябыз.

1) Ф.Кәримнең “Яз килә” шигырен өйрәнү.

2) Язгы табигать һәм яз билгеләре белән таныштыру.

Бу әдәби әсәр белән ничек эшлибез соң? Шуны укучылар белән искә төшереп узабыз.

Әдәби әсәр өстендә эшләү алгоритмы:

1) Тиз йөгерек, сәнгатьле итеп шигырьне укыйбыз.

2) Авторны истә калдырабыз.

3) Аңлашылмаган сүзләрне табабыз, алар өстендә эшлибез.

4) Катнашучыларны, ягъни төп геройларны һәм аларның эш-гамәлләрен билгелибез.

5) Модель төзибез.

6) Модельгә нигезләнеп, шигырьнең эчтәлеген сөйлибез.

7) Темасын ачыклыйбыз.

Алгоритмны искә төшергәч, укучылар белән эшне дәвам итәбез:

- шигырьне сәнгатьле укыйбыз (шигырьне укыйлар)

- аңлашылмаган сүзләр өстендә эш

чыелдашалар – чирикует

сыерчыклар – скворцы

чыпчыклар –воробьи

- катнашучыларны, ягъни төп геройларны билгелибез:

1) Кояш көлеп карый.

2) Тамчылар тып-тып итәләр.

3) Бозлар агалар.

4) Чыпчыклар чыелдашалар.

5) Сыерчыклар җырлашалар.

6) Ак каен яфрак ярыр.

7) Май ае чәчәкләр алып килер.

- модельне төзибез;

- модельгә нигезләнеп, шигырьнең эчтәлеген сөйлибез, яз билгеләрен санап китәбез;

- темасын ачыклыйбыз. Ф.Кәрим “Яз җитә” шигырендә яз билгеләре һәм табигатьтә яз көне булган үзгәрешләр белән таныштырып үтә.

Шулай итеп, укыту процессында инновацион технологияләр куллану укучыларда туган телне тагын да ныграк үзләштерүгә кызыксыну уята. Әлеге модель укучыны дөрес итеп җөмлә төзергә, үз фикерен белдерергә өйрәтә.

Укучыларның иҗади активлыгы үсә, оештыру сәләте формалаша, фикерләү эшчәнлеге хәрәкәткә китерелә.

Нәтиҗәдә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен иң уңышлы вариантын табу. Укучыларда уку процессына кызыксыну уяту өчен стандарт методлар белән генә чикләнергә ярамый. Укыту процессын информатизацияләү мәгариф өлкәсендә гаять зур

мөмкинлекләр тудыра, чөнки аны белем бирүдә бик нәтиҗәле итеп кулланып була. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа технологияләрне урынлы куллану - укучыларның шәхси үзенчәлекләрен искә алырга, укытучы белән укучыларның бердәм эш алымнарын камилләштерергә, белем бирүнең сыйфатын күтәрергә мөмкинлек тудыра.

**Кулланылган әдәбият**


1. Рәхимов Ә.З. Укучыларның иҗади фикерләвем үстерү технологиясе. М., 1993. – [43 б.]

2. Мозаффарова М.Г. Әдәбият предметын укыту үзенчәлекләре. Татар әдәбияты буенча төп, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куя торган педагогик хезмәткәрләр өчен тәкъдимнәр. Казан: ТРМҮИ, 2014.

3. Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗәнова Г.М..Татар телен һәм әдәбиятын укытуда яңа технологияләр. Яр Чаллы, 2011. [61 б.]



*Егорова Гүзәлия Әбрар кызы,*

*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы "Адымнар-Әлмәт" полилингваль гимназиясе“ муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


**Сыйныфтан тыш чаралар аша татар теленә һәм әдәбиятка карата кызыксыну уяту**

Хәзерге заман таләпләре укытуга карата өч төрле мәсьәлә куя:

1.Кемне укытырга?

2. Нәрсәгә өйрәтергә?

3.Ничек өйрәтергә?

Беренче сорауга без озак уйламыйча җавап бирә алабыз. Икенче сорауга мин, татар теле укытучысы буларак әйтә алам : татарча матур итеп сөйләшергә, дөрес язарга өйрәтергә тиешмен.

Шуңа ирешер өчен укучыларны нәрсә белән кызыксындырырга соң? Ничек һәрбер баланың татар теленә карата игътибарын юнәлдерергә?

Балалар сыйныф бүлмәсенә теләк белән керергә һәм теләк белән дәрес буе эшләргә тиеш.Әгәр балаларның татар теленә өйрәнүгә теләкләре булмаса, аларның белем күрсәткечләре түбән булачак. Уку сыйфатларын арттыру өчен без яңадан-яңа эффектив ысуллар эзлибез. Минемчә, бу вакытта безгә сыйныфтан тыш чаралар ярдәм итә.

Сыйныфтан тыш чара ул-уку процессының бер өлеше. Сөйләм телен һәм иҗади фикерләү дәрәҗәсен үстерүдә дәресләр белән бергә сыйныфтан тыш чараларны оештыруда мөһим эшләрнең берсе булып кала. Алар укыту-тәрбия эшен оештыруда зур роль уйный.

Сыйныфтан тыш чаралар үз алдына түбәндәге максатларны куя:

1.Балаларның иҗади сәләтләрен үстерү,индивидуаль кызыксынуларын тормышка ашыру.

2.Фәнгә карата кызыксыну уяту, уй һәм фикерләү эшчәнлеген арттыру.

3.Телгә карата мәхәббәт тәрбияләү.

**Мәктәптә татар теленә бәйле сыйныфтан тыш эшләрнең төрләре:**

1.Туган тел түгәрәге , тел бәйгесе, татар теле атналыгы, айлыгы, әдәби- музыкаль кичәләр, викторина, конкурс, диспут, КВН, брейн-ринг, олимпиада, тел сөючеләр клубы, иҗат күргәзмәләре оештыру һ.б;

2.Әдәби газета, журналлар чыгару, кулъязма альбом төзү, рефератлар язу һ.б;

3.Өстәл уеннары: грамматик лото, домино уйнау, башваткычлар чишү һ.б.

Дәрестән тыш эшләр планлы рәвештә алып барыла.Мондый эшләрне планлыштыруда директор урынбасары, укытучы һәм китапханәче катнаша. План төзегәндә республикага, әдәбият һәм сәнгать әһелләренә бәйле истәлекле көннәр исәпкә алына. Алар, нигездә, белем һәм тәрбия бирү максатыннан чыгып эшләнелә, дәреснең дәвамы буларак, укучының кызыксынулары исәпкә алып үткәрелә.

Бу чараларны әзерләгәндә укучыларны кызыксындыра белергә кирәк. Әйткәнемчә, бәйрәмнәргә әзерләнгәндә беркем дә читтә калмый:

1.Укытучы кирәк булган материалны таба.

2.Китапханәче укытучыларга булыша. Ул укучылар мөстәкыйль укырга тиеш булган китаплар исемлеген төзи. Күргәзмәләр оештыра.

3.Әти-әниләрнең бурычы –костюмнар, декорацияләр ясау.

4. Ә иң зур бурыч, билгеле, укучылар өстендә. Алар- башкаручылар. Төрле интелектуаль уеннар балаларның белемнәрен үстерә, уку сыйфатын арттыруга китерә. Туган тел түгәрәге, тел бәйгесе, татар теле атналыгы, әдәби-музыкаль кичәләр сөйләм телен үстерә. Балалар кызыксынып сыйныфта, мәктәп күләм чараларында, хәтта район күләм чараларында да катнаша. Кечкенә балаларны иң кызыксындырганы —ул төрле кызык әкиятләр күрсәтү. Әкиятләрне яратып укыйлар һәм ошаганнарын сәхнәләштерәселәре килә. Бу бик мөһим. Бу вакытта алар үзләре дә сизмәстән белем иленә кереп китәләр. Әкиятләрне сәхнәләштергәндә үзләре өчен бик кирәкле мәсьәләләрне чишәләр.

Йомгаклап әйткәндә, уңыш түбәндәгеләрдән күренә:

1.Балаларның үз эшчәнлеге белән канәгать булуы, туган телне өйрәнүгә кызыксынулары арту.

2.Укучыларның эш нәтиҗәләрен күтәрелү (конкурсларда җиңү, уку күрсәткечләре яхшыру, еллык өлгереш һәм белем сыйфаты күтәрелү)

3.Алган белемнәрне тормышта куллана белү, тормышка яраклашу белү, иҗадилык, конкурент булырга сәләтлелек.

*Жуковская Руфинә Касыйм кызы,*
*Сәгыйдуллина Ранизә Зәлиф кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесең башлангыч сыйныф укытучылары*

**Татар теле дәресләрендә функциональ грамоталылык формалаштыру алымнары**

Һәр чорда да укытучылар алдында укучыларның иҗади фикерләү сәләтен үстерү бурычы торды. ФДБС буенча да укучыларны төрле эшкә җәлеп итү аша, аларның фикерләвен, сөйләмен, рухи үсешен тәэмин итү бурычы билгеләнде. Без укучыларга әзер белем бирү белән шөгыльләнмичә, белемне укучыларның үзләреннән таптырту алымнарын күздә тотып эшләргә, алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтергә тиеш. Шул очракта гына безнең укучылар яңа тормыш шартларына яраклашкан, гомуми мәдәни үсешкә ирешкән, үз фикере булган һәм җәмгыятькә файдалы шәхесләр булып үсәчәкләр. “Кешегә бетмәс –төкәмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, иреккә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта урынын табарга булышырга, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк “, - дип язган моннан күп еллар элек Л.Н.Толстой. Бүгенгесе көндә дә бу фикерләр белән килешми мөмкин түгел. Яңача укыту технологиясенең нигезендә укучы һәм укытучы арасында яңача мөнәсәбәт тора. Дәрес балага авырлык китермәскә, киресенчә, шатлык – бәхет алып килергә, дәрестән бала нинди дер ләззәт, канәгатьләнү хисе алып чыгарга тиеш. Ә иң мөһиме – укучылар дәреснең һәр этабында логик яки иҗади фикер йөртсен өчен шартлар тудырырга кирәк.

Бу бурычларны туган тел һәм әдәбияты укытучысы нинди юллар белән тормышка ашыра ала соң? Педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерүгә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, укытуның һәр этабы өчен уку материалын үзләштерүнең иң уңышлы вариантын кулланып эшләү, укучыларга алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтү.

Заманча мәктәпнең иң мөһим бурычларыннан берсе - функциональ белемле шәхес формалаштыру.

Нәрсә соң ул “функциональ грамоталылык”?

Функциональ грамоталылык – кешенең тышкы мохит белән мөнәсәбәтләргә керү, тиз җайлашу һәм анда эшләү сәләте. Функциональ грамоталылык нигезләре башлангыч мәктәптә салына, анда сөйләм эшчәнлегенең төрле төрләренә – язуга, укуга, сөйләшүгә һәм тыңлауга интенсив өйрәтү бара.

Функциональ яктан белемле шәхес - ул:

– дөньяда ориентлашкан һәм иҗтимагый кыйммәтләргә, өметләр һәм мәнфәгатьләргә туры китереп эшли торган, аерым алганда, үз гамәлләрен башка кешеләрнең гамәлләре белән яраштыра һәм координацияли белүче кеше;

– сайлау һәм карарлар кабул итү ситуациясендә мөстәкыйль булырга сәләтле кеше;

- заманча мәгълүмати технологияләргә ия булган кеше.

Укытучының максаты - баланы үстерү.

Иң беренче чиратта, укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру әһәмиятле. Укучыларда татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә бу максаттан чыгып, төрле алым һәм формаларга таянабыз, Интернет-чыганаклардан файдаланабыз.

Безнең төп максатларыбызның берсе – укучыларның алган белемнәрен тормышта кулланырга өйрәтү.

Уку грамоталылыгы – функциональ грамоталылыкның иң мөһим өлеше. Уку грамоталылыгын формалаштыруда текст белән эшли белүгә игътибар итәргә кирәк, чөнки текст уку ул – белем бирү генә түгел, тәрбияви бурычлар үтәүне дә үз эченә ала. Шәхеснең рухи-әхлакый сыйфатларын формалаштыруда текст белән эшләүнең роле зур. Дәрестә текст белән эшләүне укучыларга кызыклы да, аңлаешлы да булырлык итеп оештырырга кирәк. Язма текстлар белән эшләгәндә дәресләрдә түбәндәге эш алымнары кулланыла:

– текстның исеменә игътибар итү, «Ни өчен текст шулай дип аталган?» соравына җавап эзләү, темасын билгеләү;

– төп сүзләрне аерып алу һәм язып кую;

– текстган ачыктан-ачык бирелгән мәгълүматны яки фактларны таба белү, аларны тормыштан алынган мисаллар белән ныгыту;

– текстны кисәкләргә бүлү, планын төзү;

– тексттан төп вакыйгаларны аерып ала белү;

– тәкъдим ителгән рәсем һәм иллюстрацияләрнең текстның кайсы өлешен ачу өчен кулланылуын әйтү;

– текст нигезендә зур булмаган монологик яки диалогик сөйләм төзү;

– укылган текст эчтәлеге буенча дискуссияләр, дебатлар оештыру һ.б.

Дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда проектлар төзү һәм яклау, электрон презентацияләр төзү һәм аларны тәкъдим итү кебек алымнар куллану да отышлы.

Критик фикерләү технологиясе элементларын куллану укучыларда уку грамоталылыгын формалаштыруның өстенлекле бер алымы булып тора. Фикерләү күнекмәсе укучыларга уку дәверендә генә түгел, алдагы тормышларында кирәк булачак. Критик фикерләү технлогиясе кысаларында түбәндәге алымнарны кулланырга була:

– «Тукталышлар белән уку» алымы. Дәрес башында укучыларга текст исеменнән чыгып сорау куела, укучыларның фикерләре тыңланыла. Төп өлешендә текст фрагментларга бүленеп укыла, һәр өзектән соң укучылардан алга таба ни булачагы турында җаваплар тыңланыла;

– «Сораулык белән эш» алымы. Әлеге алымны дәреслек белән эш вакытында кулланырга була. Укытучы укучыларга сораулар тәкъдим итә. Сораулар туры җавап бирерлек итеп тә, уйлану-фикерләүне таләп итәрлек итеп тә куела;

– «Беләм, белдем, белергә телим» алымы. Бу алымны яңа материалны аңлату һәм алынган материалны ныгыту этабында да кулланырга мөмкин. Өч графадан торган таблица бирелә, укучылар үз фикерләрен, җавапларын язалар;

– «Почмаклар» алымы. Әсәр геройларына характеристика биргәндә кулланырга ярый. Сыйныф ике төркемгә бүленә. Беренче төркемдәге укучылар, текст эчтәлегеннән һәм тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, геройның уңай сыйфатларына дәлилләр әзерлиләр. Икенче төркем исә, цитаталарга таянып, геройның тискәре сыйфатларын ачыклый;

Гомумән алганда, укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру максатында кулланыла торган алымнар бихисап. Шулай итеп, текст яки мәгълүмат белән эшләү уку процессы структурасында мөһим урын алып тора. Дәрестә генә түгел, дәрестән тыш чараларда да текст белән эшләүнең мөмкинлекләре күп.

Функциональ грамоталылыкны формалаштыру - катлаулы, күпкырлы, озак вакытлы процесс. Төрле заманча белем бирү технологияләрен кулланып кирәкле нәтиҗәләргә ирешергә була.

*Зарипова Әнисә Газизуловна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Бакый Урманче исемендәге “2 нче гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыруда эш алымнары**

Уку грамоталылык - көндәлек проблемаларны чишү өчен мәктәптә алган белемнәрне куллану сәләте. Укучының иҗади сәләтен үстерү – бүгенге мәгариф системасында иң мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора. Чөнки иҗади фикерли белү, иҗадилык - шәхес өчен иң кирәкле

һәм бүгенге җәмгыятьтә иң кыйммәт бәяләнә торган сыйфатларның берсе. Иҗади үзләштерелгән белемнәр генә бала шәхесен формалаштыруга йогынты ясый. Ә.З.Рәхимов: ”Иҗади шәхес - милләт һәм Ватан байлыгы,”- ди. [4]. Чөнки иҗади шәхес башкалардан үзенең әхлаклы, кешелекле, хисле һәм ихтыярлы булуы белән аерылып тора. Шул ук вакытта без укучыларны мәктәптә алган белемнәрен көндәлек тормышта куллана алырлык, күпмедер дәрәҗәдә дөньяны танып белүче, тормыш ситуацияләренә җайлаша, яраклаша белә торган шәхес тәрбияләргә тиеш.

Функциональ грамоталы шәхес үстерү, ягъни белем, күнекмә, осталык ярдәмендә төрле тормыш мәсьәләләрен чишүгә сәләтле шәхес тәрбияләүдә татар теле, әдәбият фәннәре мөмкинлекләрен куллану укытучының зыялылыгына, актив тормыш позициясенә гомуми компетентлылыгына бәйле булу бәхәссез.

5-9 сыйныфларда «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметы яңа ФДББСлары таләпләренә туры китереп эшләнелә. Яңа буын ФДБС буенча укучыларны төрле эшкә җәлеп итү аша, аларның фикерләвен, сөйләмен, рухи үсешен тәэмин итү бурычы билгеләнде [5]. Без укучыларга әзер белем бирү белән шөгыльләнмичә, белемне укучыларның үзләреннән таптырту алымнарын күздә тотып эшләргә, үзләштерелгән материалны тормышта куллана алу күнекмәсен үстерергә тиеш. Шул очракта гына безнең укучылар яңа тормыш шартларына яраклашкан, гомуми мәдәни үсешкә ирешкән, үз фикере булган һәм җәмгыятькә файдалы шәхесләр булып үсәчәкләр.

Бүгенге цифрлаштыру гасырында укучыларда уку грамоталылыгын үстерү аеруча әһәмияткә ия дип уйлыйм. Аңлап уку, укылган текстттан кирәкле мәгълүматны аера белү, әдәби текстны шәрехләү, анализлау һәм аңлату күнекмәләрен үстерү кирәк. Текст уку ул – белем бирү генә түгел, тәрбияви бурычлар үтәүне дә үз эченә ала. Димәк, шәхеснең рухи-әхлакый сыйфатларын формалаштыруда текст белән эшләүнең роле зур.

Татар әдәбияты дәресләрендә музыка, сынлы сәнгать өлкәсендә белем- күнекмәләрен барлау максатыннан “Лото” уены оештыру уңай нәтиҗә бирә. Укучыларга уен башланыр алдыннан әзер таблица таратыла, анда күренекле сәнгать эшлекләренең, язучыларның исем фамилияләре язылган була.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Абдулла Алиш | Кәнәфи Нафыйков | Салих Сәйдәшәв | Кәрим Тинчурин |
| Муса Җәлил | Сара Садыйкова | Рөстәм Яхин | Фатих Кәрим |
| Бакый Урманче | Габдулла Тукай | Әмирхан Еники | Байназар Әлмәнов |
| Шәүкәт Галиев | Роберт Миңнуллин | Галиәсгар Камал | Нәби Дәүли |

Укучылар сорауга туры килгән җавапны сыза баралар. Ахырдан 2 яки 1 фамилия генә калырга мөмкин. Ул дәрестә өйрәнеләчәк язучы да булырга мөмкин.

1. Татар рәссамнарын атагыз
2. Балалар язучыларын уеннан чыгарыгыз
3. Театр үсешенә зур өлеш керткән драматургларны атагыз.

4. Бөек Ватан сугышында катнашкан язучыларны карап сызыгыз

5. Татар композиторларларын атагыз

<u>Калган фамилия – сезнең җавабыгыз.</u>

Табышмакларның җавапларын тап, мәгънәсен аңлат. Җавапларга сорау куй. Сүз төркемен билгелә. Планлаштырылган нәтиҗәләр: сүзнең лексик мәгънәсен дөрес итеп аңлау һәм куллана белү, исем сүз төркемен кергән сүзләрне тану.[3]

1.Аягы юк, кулы юк, үзе сурәт төшерә. (Суык)

2. Күктән килде, җиргә иңде (Болыт, яңгыр)

3. Лампа түгел – яктырта, мич түгел – җылыта. (Кояш)

4. Агач бөгә – кулы юк, йөри торган юлы юк. Ачуланса – сызгыра, тузаннарны туздыра. (Җил)

5. Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач. (Йолдызлар һәм ай)

Иптәшең белән киңәшләшеп хаталарны тап, күчереп яз. Планлаштырылган нәтиҗәләр: дөрес язу һәм бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Хава, дикать, ихтибар , шөгель, кәләм, хәтирә, көняк, ашяулык. Бер сүз белән җөмлә төзе.

Функциональ грамоталылыкның мөһим өлеше - уку грамоталылыгы. Укучының грамоталылыгы - уку текстларын уку һәм аңлау сәләте, тексттан мәгълүмат алу, аны төрле мәсьәләләрне хәл иткәндә куллану сәләте.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысының төп бурычы - укучыларны татар әдәбияты, язучылары белән таныштыру. Ә соңгы вакытта укучыларның телефонда, планшетларда төрле интернет челтәрләрендә утыруы, уеннар белән мавыгулары китап укуга булган ихтыяҗны нык киметте.

Менә шундый шартларда балаларны ничек итеп милли рухи хәзинәбезгә йөз белән борырга? Сүз сәнгатебезнең матурлыгын, байлыгын күрсәтергә? Алай гына да түгел, укучыларны ничек итеп аңлап укуларына ирешергә? Менә шундый шартларда укучылар ничек итеп төп дәүләт имтиханын тапшырырга тиеш, чөнки имтиханда текст белән эшли алу гына түгел, ә укылган текста күтәрелгән проблеманы табу һәм чишеләсе мәсьәләне раслау, укылган тестан яки тормыштан мисаллар китереп дәллиләү кирәк. Шулай ук ишетеп тыңланган тестның тулы эчтәлеген барлык микротемалары сакланган хәлдә язуда чагылдыру да сорала. Шуңа күрә бүгенге имтихан тапшыручы укучы алдында текст белән эшли алу күнекмәсе өстендә эшчәнлек алып бару сорала. [2]

Укучыларның уку грамоталылыгын арттыру өстендә түбәндәге эш төрләре кулланам.

**Уку күнекмәләре:**

-мәгълүматны табу һәм аны аерып алу;

-мәгълүматны интеграцияләү һәм интерпретацияләү;

-фикерләү һәм бәяләү;

-тексттагы мәгълүматны тормышта куллану;

–текстның исеменә игътибар итү, «Ни өчен текст шулай дип аталган?» соравына җавап эзләү, темасын билгеләү;

– төп сүзләрне аерып алу һәм язып кую;

– тексттан ачыктан-ачык бирелгән мәгълүматны яки фактларны таба белү, аларны тормыштан алынган мисаллар белән ныгыту;

– текстны кисәкләргә бүлү, планын төзү;

– тексттан төп вакыйгаларны аерып ала белү;

– тәкъдим ителгән рәсем һәм иллюстрацияләрнең текстның кайсы өлешен ачу өчен кулланылуын әйтү;

– текст нигезендә зур булмаган монологик яки диалогик сөйләм төзү.

Укучы текстны аңлап укыган очракта гына, көтелгән нәтиҗәгә ирешеп була. Эзләнү нәтиҗәсендә нәтиҗәле (продуктив) уку технологиясе кулланам. Укучыларны әсәрне кабул итәргә әзерләү, укучыларда теләк, мотивация булдыру. Әсәрне укыр алдыннан иң элек укучыларның игътибарын әсәрнең исеменә, язылган елына, автор яшәгән чорга юнәлтәм.

Укылган әсәр буенча рәсем бирелгән. Укучылар әлеге рәсем буенча укылган әсәрнең сюжетының бер өлешен сөйлиләр, укучы әсәр эчтәлегенә бәйле рәвештә бирелгән рәсемнәр буенча вакыйгаларны әйтә белергә тиеш.

Текст белән эш итүнең нәтиҗәле формасы булып ***текст белән диалог*** стратегиясе тора. Укучылар укылган текстның эчтәлегенә карата үзара бер- берсенә сорауларга җавап бирәләр.

1) текстта аңлашылмаган әйберне табу һәм *сорау кую;*

2) туган сораугa җаваплар эзләү яисә текстның дәвамын *фаразлау;*

3) үзенеңнең җавапларыңны текст буенча *тикшерү*.

Текстны уку этабында максатчан рәвештә ***тукталышлар белән уку*** стратегиясе кулланыла. Бу стратегия теләсә нинди мәгълүматка игътибарлы карарга, вакыйгаларның үсешен фаразларга өйрәтә, иҗади күзаллауны үстерә, укуны дәвам иттерергә этәргеч булган интриганы саклый (алга таба нәрсә булыр, минем фаразларым акланырмы һ.б.). Укучыларга сорау, гипотеза яисә фикер туган мөһим урыннарда тукталышлар ясау кирәклеген искәртәбез, аларны истә калдырырга киңәш итәбез. Укыганнан соң анализ ясыйбыз: тексттагы нинди сигналлар укучыны фикерләргә этәргән. Алга таба, текст белән мөстәкыйль эшләгәндә, мондый «тукталыш» укучы өчен табигый эшкә әйләнә.[1]

***«Укуны бүлдерү»*** **стратегиясе** *алга таба әңгәмәне дәвам иттерүне таләп итми торган сораулар* биреп («Аңладыгызмы, ни өчен?») *укучыларның күзаллауларын* «*кабызу*», *мөһим фактларга игътибар иттерү максатыннан* кулланыла («*Күз алдыңа китер*», «*Күрдегезме?*»).

Әгәр уку барышында таныш булмаган сүз очраса, шунда ук сүзлектән карау өчен тукталырга кирәкми, укучыларга сүзнең мәгънәсен контексттан чыгып билгеләргә дә мөмкинлек бирергә кирәк. Пауза текстны эмоциональ кабул итүне бозарга да мөмкин.

***Аңлатмалы (комментарий биреп) уку*** стратегиясе – фикерләүгә өстенлек биреп уку ысулы. Ул күбрәк текстны кабаттан уку барышында кулланыла. Укучылардан киңәйтелгән җаваплар таләп итәргә, текстта булмаган әйберләрне аңлатырга тырышырга кирәкми, комментарий кыска булырга тиеш. Ул әңгәмәгә әйләнмәсен. Ләкин, әгәр укучылар уку барышында кызыклы фикерләр әйтсә, бу идеяләрне игътибарсыз калдырырга ярамый, укучыларның әдәби әсәр эчтәлегенә эмоциональ мөнәсәбәтләрен хупларга кирәк.

*«Иҗади эш язу» алымы.* Бу алымны өйрәнелгән теманы ныгыту этабында куллану уңай. Укучыларга яки әсәрне дәвам итәргә, яки үзгәртеп язарга, яисә үзләренә әкият, хикәя, шигырь язарга тәкъдим итәргә була. Әлбәттә, мондый эш биргәндә укучыларның сәләтен күз уңында тотарга кирәк.

Бүгенге көндә функциональ белемлелек иҗтимагый иминлекнең мөһим индикаторы булып тора, ә укучыларның функциональ грамоталылыгы – белем бирү сыйфатының мөһим күрсәткече. Функциональ грамоталылыкны формалаштыру – катлаулы, күпкырлы, озак вакытлы процесс. Төрле заманча белем бирү технологияләрен берләштереп, оста итеп, кирәкле нәтиҗәләргә ирешеп була.

Кулланылган әдәбият

1. Абрахимова Я. Х. Әдәбият дәресләрендә бәйләнешле сөйләм үстерү: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-6 нчы сыйныфларында эшләүче укытучылар өчен кулланма. -Казан: Мәгариф, 2007. -111 б.

2. Галиуллина Г.Р., Денмөхәммәтова Э.Н., Йосыпова Н.М., Мөгътәсимова Г.Р., Фәтхуллова К.С. Төп дәүләт имтиханына әзерләнү өчен биремнәр. - КАЗАН 2020.

3. Җамалетдинова З.И. Татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә башлангыч сыйныф укучыларының функциональ грамоталылыкларын формалаштыру үзенчәлекләре: методик тәкъдимнәр — Казан: ТРМҮИ, 2021. — 48 б.

4. Рахимов А. З. Формирование творческого мышления школьников: автореф. дис. … канд. психол. наук : 19.00.07. — М., 1993. — 43 с.

5**.** 5-9 нчы сыйныфларда «Туган (татар) телдәге әдәбият», Туган (татар) тел фәнен федераль белем бирү программаларына нигезләнеп укыту буенча методик тәкъдимнәр. Татарстан Рреспубликасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайты.

*Кашипова Наиля Задитовна,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре*
*МАГББУ “17нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбият укытучысы*

**Дәресләрдә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә вакытлы матбугат чараларыннан файдалану**

Бүгенге заман мәктәпләре алдында торган төп бурычларның берсе – ике дәүләт телен дә камил белгән, мөстәкыйль фикерли, шул фикерләрен башкаларга җиткереп, аларның фикере белән дә санлашып, коллективта эшли алырлык шәхесләр тәрбияләү.

Әлеге бурыч һәм максатларны тормышка ашыру максатыннан дәресләрдә бик күп төрле укыту технологияләре, эш төрләре, чаралар кулланыла. Дәреслек белән генә эшләү укучыны ялыктырырга, аның кызыксынуын киметергә, белем алуга теләген сүндерергә мөмкин. Шуңа күрә дә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә, дәрестән тыш чараларда без бик күп мөмкинлекләрдән файдаланырга тырышабыз: интерактив технологияләргә мөрәҗәгать итү, кызыклы сайтлар эшчәнлеге белән танышу, алардан файдалану һ.б. Шулар арасында кызыклы эш төрләренең берсе булып укучыларны вакытлы матбугат чаралары белән эшләргә өйрәтү дә тора.

Бүгенге көндә татар вакытлы матбугатында газета-журналлар бихисап. Аларның төрлесе төрле яшь үзенчәлекләренә нигезләнеп, укучыларның мөстәкыйль һәм иҗади фикерләвен, сөйләм телен баетуга юнәлтелә. Дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларга әзерләнгәндә вакытлы матбугат чаралары белән эшләү зур нәтиҗәләргә китерә дип, ышанып әйтергә мөмкин.

Безнең мәктәптә татар теле һәм әдәбияты кабинетларында мәктәп һәм укытучыларның үз шәхси китапханәләреннән алынган  гәҗит-журналлар тупланган. Һәр сыйныф укучысы, яшенә карап, алар белән таныша, кирәкле мәгълүмат туплый, проектлар яклый, конференцияләргә чыгышлар әзерли ала.

5-8 нче сыйныфлар, бик теләп, “Ялкын” журналы белән эшлиләр. Биредә басылган язмалар балаларга дәреслектә бирелгән материалны баетырлык өстәмә белем тупларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, “Алтын каләм” рубрикасы аша укучылар үз яшьтәшләренең иҗаты белән таныша, шул ук вакытта, “Куен дәфтәре”, “Шигърият” рубрикаларында үзләрен язучы буларак сынап карау мөмкинлегенә дә ия булалар. Ел саен берничә укучыбыз  “Илһам канатында” исемле зона ярышында үз шигырьләре белән чыгыш ясап, призлы урыннарга ия булдылар. Бу, үз чиратында, укучыларны канатландырып, яңадан-яңа әсәрләр иҗат итәргә,

әсәрләрен журналга басмага әзерләргә, алдагы еллардагы ярышларга тырышыбрак әзерләнергә стимул бирә.

Р.З.Хәйдәрова һәм Р.Р.Нигъмәтуллина дәреслекләрендә укучылар өчен бик кызыклы текстлар бирелә. Алар укучыны диалогик һәм монологик сөйләмгә чыгаруга корылган гади генә текстлар. Мәктәп тормышы, гаилә, туган җир, дуслык һәм башка бик күп темалар яктыртыла әлеге текстларда. Аларның һәркайсы укучы өчен актуаль. Менә шундый темаларны тулыландыру максатыннан да укучылар “Ялкын” журналына мөрәҗәгать итәләр. Биредә алар үз яшьтәшләренең тормышы, хоббилары, киңәшләре белән танышалар, үзләрен борчыган сорауларга җаваплар табалар. Мәсәлән, “Мин һәм минем яшьтәшләрем” бүлеген өйрәнгән вакытта укучылар “Ялкын” журналының “Тышлыкта кем?”, “Синең яшьтәш”, “Хобби” рубрикаларындагы язмалар белән танышалар. Алар арасында якташлары, кумирларының исемнәрен күрү - укучылар өчен икеләтә сөенеч. Мондый язмалар укучыларның шәхес буларак формалашуында зур әһәмият уйный. Аларны уйланырга, ниндидер яңалыкларга, иҗадилыкка, үз өсләрендә эшләргә илһамландыра дип әйтсәк тә ялгыш булмас.

Югары сыйныф укучылары күбрәк “Идел” һәм “Гаилә учагы” журналлары белән эш итәргә ярата. Бу журналлар кабинетта тупланып барыла, хәтта укытучы тәкъдим итмәгән очракта да, балалар әлеге журнал битләрен актаралар, әкренләп, үзләренә кирәкле материалны табарга өйрәнәләр. “Идел”журналында “Уңыш казаны”, “Сәхнә”, “Еракка китеп кара” рубрикалары укучыларның игътибарын үзенә җәлеп итә. Биредә урын алган язмалардан алар конференция, олимпиадаларга әзерләнгәндә, төрле темаларны яктырткан проектлар эшләгәндә файдаланалар. Әлеге гамәлләр эшчәнлекне үстерә, укучыларны мөстәкыйльлеккә, конкурентлыкка әзерләү чараларының берсе булып тора.

10 нчы сыйныфларның татар төркемендә белем алучы укучылар борынгы һәм урта гасыр әдәбиятын өйрәнә. Тарихи чор, андагы вакыйгалар, шәхесләр, аларның эшчәнлеге турында өстәмә материал “Мирас”, “Казан”, “Гасырлар авазы”(Эхо веков”) журналларында бик мавыктыргыч, аңлаешлы тел белән басылган. Мәсәлән, Г.Исхакый, Г.Кутуй иҗатын өйрәнгән вакытта укучылар “Гасырлар авазы” журналына нигезләнеп, аларның шәхси хатлары, татарларда басма һәм кульязма китаплар тарихы, Татарстандагы коточкыч ачлык еллары турында язылган бик күп кызыклы мәкаләләр белән танышалар, сыйныфташлары белән дискуссияләр оештыралар. Һәркем үз фикерен яклап, аның дөреслеген дәлилли торган мисалларны укып күрсәтә. Укучылар үзләре өчен интернетта да, дәреслектә дә булмаган мәгълүматны алалар, алга таба инде журналның һәр бите кызыксыну тудыра.

Дәрестән тыш чаралар уздырган вакытта укучылар шулай ук “Мәйдан”, “Идел” журналларына мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, “Туган телләр” айлыгын, Г.Тукай, М.Җәлил, Р.Фәхреддин атналыкларын үткәргәндә, “Идел” журналында укучылар тарафыннан яратып

кулланыла торган рубрикалар: “Танышу”, “Телем-байлыгым”, “Еракка китеп кара”. Әлеге рубрикалар аша укучыларда туган илгә, туган телгә, татар милләтенә мәхәббәт, хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләнә. Әлеге язмалар сценарийлар төзегән вакытта да бик отышлы. Бердән, укучы эзләнә, чагыштыра, икенче яктан, рус мәктәбендә укучы төрле милләт балалары алдында татар булуы белән горурланып чыгыш ясый. “Менә, күрегез, татарлар арасында нинди күренекле яшьтәшләрем бар минем” дигән сүзләрне укырга мөмкин аларның күзләреннән.

“Гаилә учагы” журналын укучылар яраткан җырчыларының, артистларының тормышы белән танышып бару максатында кулланалар. Игътибар иткәнебез бар: кабинетта бу журналның яңа санын булдыру белән, ул сан кулдан-кулга йөри. Бигрәк тә кызлар күп укыйлар аны. Барысын да яраткан артистларының тормышындагы яңалыклар кызыксындыра. Алар үрнәгендә чәч кистерү, зәвыклы итеп киенергә, бизәнергә, дөрес һәм аһәңле итеп татар телендә аралашырга өйрәнү – һәммәсе мактауга лаек гамәлләр.

Соңгы вакытта кабинетка “Сәхнә” журналын алып кереп калдыра торган булдык. Күзәтәбез, берәрсе булса да кызыксынып ачып карар микән? Һәм ялгышмыйбыз: “Сәхнә” журналлары белән танышу укучыларда театр сәнгатенә мәхәббәтне арттыра, аларны театрларга йөрергә, артистлар белән очрашу кичәләре оештырырга, яшьтәшләре һәм әти-әниләре алдында кыска гына сюжетлы спектакльләр уйнауга илһамландыра. Татар балалары белән янәшә рус балалары да активлашып китәләр. Билгеле бер аудитория алдында чыгыш ясау укучыларның сөйләм телен баета, сәнгатьле итә, үз фикерләрен ярып әйтә белүдән курыкмаска өйрәтә.

Гомумән, газета-журналлар белән танышып бару укучыларның дөньяга карашын киңәйтә, мәгълүмати хәбәрдарлыгын баета, сөйләм культурасын үстерергә ярдәм итә. Әлбәттә, хәзерге заман укучысының тормышын компьютердан башка күз алдына китереп булмый. Алар бик актив рәвештә “Матбугат.ру”, “Белем.ру” сайтларыннан файдаланалар. Яшьләрне матбугат чараларыннан файдалана белми дип гаепләргә ашыкмыйк. Бары тик аларны кызыксындыра, эшләү юнәлешен күрсәтә белергә генә кирәк.

*Локманова Алисә Өлфәт кызы,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының "Адымнар-Әлмәт" полилингваль гимназиясе " муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы*

**Диалогик сөйләмне үстерү уеннары**

Билгеле булганча, уку-укыту бик катлаулы һәм һәрдаим үзгәреп торучан системаны тәшкил итә. Шуның нәтиҗәсендә, белем бирүдә, шул исәптән телгә өйрәтүдә дә һәрвакыт

яңалыклар барлыкка килеп тора. Шуңа күрә белем бирү технологияләрен, яңа методларны өйрәнү, камилләштерү эше өзлексез булырга һәм эзлекле рәвештә алга таба да дәвам ителергә тиеш. Белем бирүнең иң кызыклы һәм нәтиҗәле методларыннан берсе – уен технологиясен кулланып, татар теленә өйрәтү.

Диалогик сөйләм – телнең коммуникатив функциясенең ачык чагылышы. Аның үзенчәлеге – сөйләм һәм әңгәмәдәшне тыңлауның чиратлашып баруы. Балаларны сүзләр белән үз үтенечләрен, башкаларның сорауларына җавап бирергә өйрәтергә кирәк. Диалогик сөйләм вакытында кыска итеп һәм тулы җаваплар бирергә күнектерү дә мөһим.

Коммуникатив компетенциягә ия шәхес тәрбияләү өчен, иң беренче чиратта, укучыларны диалогик сөйләмгә өйрәтү мөһим. Башлангыч сыйныфларда, укучыларны татар теленә өйрәтү өчен, уеннар куллану аеруча уңышлы, чөнки уен вакытында белемнәр һәм биремнәр балаларга эш буларак тәкъдим ителми, ә уен эченә яшерелә. Бу вакытта алынган белемнәрне төрле шартларда практикада кулланып карау мөмкинлеге дә туа. Иптәшләре янында нәрсәдер эшләргә омтылып, укучыда шулай ук мөстәкыйльлек тә тәрбияләнә.

Укыту процессында, шул исәптән татар теленә өйрәткәндә дә, уеннарның күп төрләрен һәм формаларын кулланырга мөмкин. “Уеннарны эшчәнлек төре буенча да берничә зур төркемгә бүлеп карарга була: хәрәкәтле уеннар, интеллектуаль уеннар, психологик уеннар, иҗтимагый уеннар.

Педагогик эшчәнлеккә бәйле рәвештә түбәндәге уен төрләрен аерып күрсәтергә була: дидактик уеннар (бу уеннар укучыларда белем-күнекмәләр формалаштыруга һәм камилләштерүгә, танып-белү эшчәнлеген киңәйтүгә юнәлтелгән), тәрбияви уеннар, иҗади уеннар, коммуникатив уеннар.

Үткәрү методикасы буенча уеннар бик күп төрләргә бүленә: предметлы уеннар, сюжетлы уеннар, рольле уеннар, эшлекле уеннар һ.б.” [1: 12].

Башлангыч сыйныфларда татар теленә өйрәтү өчен, педагогик эшчәнлеккә бәйле рәвештә бүленгән төркемнән дидактик уеннар һәм коммуникатив уеннар актив кулланыла.

Дидактик уеннар – балаларны уйланырга, эзләнергә, фикер тупларга, берләштерергә, күнекмәләрне, гадәтләрне тормышта кулланырга өйрәтүче һәм тәрбия бирүче көчле чараларның берсе. Аларны үз эчендә берничә төргә бүлеп йөртәләр: 1) предметлы уеннар; 2) өстәл уеннары; 3) сүзле уеннар [2].

Мисал өчен, “Ватык телефон”, “Очты-очты” сүзле уеннарын уйнаганда, укучыларда нәкъ менә ишетеп аңлау сыйфатын яхшыртуга ирешеп була.

Татар теленә өйрәтүдә беренче бурыч – аралашырга өйрәтү булганлыктан, коммуникатив уеннар куллану аеруча яхшы нәтиҗәләр бирә. “Коммуникатив уен – уйланылган ( шартлы), проблемалы ситуацияләр барлыкка китерү һәм аларны уйнау (чишү) дигән сүз.

Ситуация сөйләмгә этәргеч була. Мондый уеннарда укучыда фикерләү процессын активлаштыру нәтиҗәсендә нәрсәдер әйтү ихтыяҗы барлыкка килә. Образлы фикерләү логик фикерләү белән бергә алып барыла. Эш-хәрәкәтләр белән әйтелгән сүзләр хәтердә ныграк сеңеп кала. Хәрәкәтләр белән башкарылган сөйләм әйтелгән, уйланылган образны (сурәтне) җанлырак итеп күз алдына китерергә ярдәм итә. Коммуникатив уеннар сөйләмне үстерү, камилләштерү өчен баланы җанлы сөйләмгә (диалог) яки күмәк сөйләмгә (полилог) тарту максатыннан үткәрелә" [3].

Уен процессында бала мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәнә, аның игътибарлылыгы арта, белем алуга омтылышы көчәя. Уеннар балаларда җитезлек, зирәклек сыйфатлары тәрбияли, физик яктан чыныктыра.

"Танышу" уенын парталар артында утырга килеш яисә түгәрәкләнеп басып уйнарга мөмкин. Уенны укытучы башлый. Ул беренче укучыга килә һәм "Минем исемем..., ә синең исемең ничек", ди. Укучы җавап бирә һәм янында утырган иптәшенә шул ук сорауны бирә. Уен шулай дәвам итә. Әлеге уенны уку елы башында беренче дәресләрдә куллану аеруча отышлы була.

Телгә уеннар аша өйрәтү турында сөйләгәндә, В. Н. Мещерякова методикасы турында да әйтеп китәргә кирәк, чөнки аның методикасы үз эченә бик күп дидактик уеннарны ала. Шул исәптән, диалогик сөйләмгә өйрәтү өчен кулланыла торганнарны да. Мисал өчен, "Домино" уены. Уен өчен махсус карточкалар (доминолар) ясала. Турыпочмаклы карточканың яртысында бер, икенче яртысында икенче төрле рәсем. Уен түбәндәгечә бара:

- Әйдәгез "Домино" уйныйбыз. *(карточкаларны таратабыз)* - Бу сиңа, ал.
- Карточка бирегез әле (зинһар).
- Бу сиңа, ал.
- Рәхмәт.
- Башлыйбыз. Ә кем башлый. Мин башлыйм *(укытучы домино куя).* Синең "китап" бармы?
- Бар. Бу – китап. Бу да – китап. (Бу – китап, ә бу – алма).
- Куй.*( Икенче укучыга мөрәҗәгать итеп)* - Хәзер син йөрисең.
- Бу – базар. *(Өстәлдә аерым артык калган карточкалар – доминолар ята).* Базарга бар.
- Мин базарга барам *(бармаклар белән күрсәтә).*
- Син базарга барасың. Сайлап ал. Китап бармы?
- Китап юк.
- Кызганыч. Хәзер син йөрисең (син йөрмисең). Чиратлап.
- Бетте. Син – беренче. Кем икенче? Хәзер карыйбыз. Син – җиңүче.

Бу уен вакытында укучылар үз доминоларындагы һәм башка кешеләр тезгән доминодагы сүзләрне кабатлыйлар, шул ук вакытта бер-берсе белән дә әңгәмәгә керәләр. "Домино" уенын

теләсә кайсы теманың лексик материалын кабатлау һәм диалогик сөйләмне камилләштерү өчен үткәрергә була.

Балаларның танып белү сәләтен үстерү, бәйләнешле диалогик сөйләм күнекмәләре булдыру максатыннан, “Фокусчы” уенын да теләсә кайсы темадан соң үткәрергә мөмкин. Уен өчен катыргыдан матур тартма, картон фигуралар ясала, фокусчы башлыгы алына

*Уен барышы.* Балаларның үз теләге яки санамыш дәмендә “фокусчы” билгеләнә. “Фокусчы” тартмадан төрле фигуралар тартып чыгара.

*Бер укучы*. Нәрсә тоттың?

*Фокусчы*. Куян.

*Укучы*. Куян нинди?

*Фокусчы*. Куян куркак.

*Укучы*. Куян нәрсә ярата?

*Фокусчы*. Ул кишер ярата.

Уен шулай дәвам итә.

“Татарстан шәһәрләре” темасын өйрәнгәндә куллана торган уен – “Почта”. Бу уен балаларга бик ошый. Аны сүздә авазны ишетеп аеру, сорау бирү һәм тулы җөмлә белән җавап бирү күнекмәләрен үстерү; хәтерне ныгыту; игътибарлылык, тапкырлык тәрбияләү максатыннан уйныйбыз. Уен өчен  шәһәр исемнәренең баш хәрефләре язылган карточкалар әзерләнә.

*Уен барышы.* Балаларда хәреф язылган карточкалар. Бер бала “хат ташучы” була. Һәр хәреф бер шәһәр исемен аңлата: А – Алабуга, Ә – Әлмәт, Т – Түбән Кама, К – Казан, М – Мәскәү һ.б. “Хат ташучы” берәр бала янына килә һәм мондый әңгәмә кора:

- Исәнмесез!

- Исәнмесез!

- Сез кайсы шәһәргә күчтәнәч җибәрергә телисез?

- Мин Казанга күчтәнәч җибәрәм.

- Ә сез күчтәнәчкә нәрсә җибәрәсез?

- Мин Казанга каз, кыяр, кабак, конфет җибәрәм *([к] авазы кергән сүзләр әйтә).*

“Хат ташучы” “к” хәрефле башлык кигән бала янына килә. Исәнләшәләр. “Хат ташучы” кайсы шәһәрдән күчтәнәч җибәрелгәнен һәм нәрсәләр икәнен әйтә.

Уен дәвам итә.

“Тиз әйт” уенын исә предмет һәм аның билгесен әйтүдән тыш, башкачарак та үзгәртергә мөмкин. Бу уен антоним сүзләр, сүзләрне күплек санда әйтүне һ.б. грамматик категорияләрне кабатлаганда да отышлы була.

“Рәсемне өйрән” уенын аеруча яратып кулланабыз. Әлеге уен 2 команда арасында сорау-җавап рәвешендә дә үткәрелә ала.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: башлангыч сыйныф укучыларын диалогик сөйләмгә өйрәтү һәм ныгыту өчен, күптөрле уеннар уйлап табарга мөмкин. Алар сыйныфтагы бөтен укучыларның активлыгын үстерә, әңгәмәгә кушылырга этәрә. Иң мөһиме, уеннар укучылар өчен аңлаешлы, кызыклы булырга, теманы аңлауга һәм ныгытуга, диалогик сөйләмне камилләштерүгә юнәлдерелергә тиеш.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Камаева Р. Татар теленә өйрәтүдә заманча педагогик технологияләр / Р. Камаева // Мәгариф. – 2014. - №12. – Б.12.
2. Р. Р. Халимова Балалар бакчасында дидактик уеннар. – Керү режимы: http://nsportal.ru/detskiy-sad/raznoe/2013/09/29/balalar-bakchasynda-didaktik-uennar
3. 37 Ф. Вафин Тел өйрәтүдә коммуникатив уеннар. – Керү режимы: http://vafin.ucoz.ru.



*Махиянова Рузиля Миргазиян кызы,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре "17 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


**Муса Җәлил шигърияте ярдәмендә яшь буынга патриотик тәрбия бирү**

Минемчә, безгә, яшь буынга, әхлакый, патриотик тәрбия бирүдә матур әдәбият әсәрләренең әһәмияте гаять көчле. Бүгенге катлаулы заманда яшь буынга патриотик тәрбия бирү тормышыбызның мөһим өлкәләренең берсе булып тора.

Һәр халыкның үлемсез шагыйрьләре, патриотлары була. Патриот сүзе үз Ватаныңны ярату дигән мәгънәне аңлата. Безнең илебез, аның данлы тарихы патриотларга бик бай. Без патриот дип атаган кешеләр үз тормышларын, туган ил язмышыннан башка күз алдына да китерә алмыйлар: гомерләрен туган халкына, Ватаны азатлыгы, иминлеге һәм матур тормышы хакында хезмәткә яки көрәшкә багышлыйлар. Алар үлгәннән соң да халык йөрәгендә яшәүләрен дәвам итәләр.Татар балалар әдәбиятында әхлаклылык, патриотизмның югары ноктасы – Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты, дип уйлыйм мин. Шагыйрь М.Җәлилнең шигырьләре, күпме генә вакыт үтсә дә, үзенең кыйммәтен югалтмый. Ул- үзенең бөтен гомерен туган иленә, туган халкына багышлый. Аның бөтен тормышы — героик тормыш. Муса Җәлил шигырьләрендә туган халкының азатлыгы өчен көрәштә үзен корбан итәргә әзер торган көрәшче образы тудыра, үзе дә халык эше өчен соңгы сулышына кадәр аяусыз көрәшә.

Дәресләрдә без Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗатына багышланган проектлар, презентацияләр әзерлибез, укылган шигырь һәм поэмаларына нигезләнеп рәсемнәр, иншалар конкурсы оештырабыз. Ел да мәктәп һәм шәһәр күләмендә шагыйрьнең туган кон уңаеннан бик күп чаралар үткәрелә. Әлмәт шәһәрендә Муса Җәлилгә багышланган һәйкәл һәм аның исемендәге урам бар. 15 нче февраль конне ел саен һәйкәл янында герой- шагыйрьне искә алу кичәсе үткәрелә. Шәһәребезнең язучылары, драмтеатр артистлары, мәктәптә Муса Җәлил шигырләре бәйгесендә җиңгән укучылар аның шигырьләрен сөйли, үлемсез батырлыгын искә алабыз, горурланабыз. Быел 27 нче гыйнвар конне Әлмәт шәһәрендә Муса Җәлилнең оныкчыгы Татьяна Михаил кызы белән эчтәлекле, бик матур очрашу булды. Укучылар үзләрен кызыксындырган сорауларны биреп, шагыйрь турында тагын да күбрәк мәгъүлүмат белделәр. Бу очрашу аларда җылы хәтирәләр һәм горурлану хисләре калдырды дип уйлыйм.

Бүгенге көн шартларында гражданлык, патриотик тәрбия бирү чарасы буларак, милли үзаңның формалашуында, фашизмның чын йөзен, кешелексезлеген ачуда Бөек Ватан сугышы турындагы әсәрләр аеруча әһәмиятле. Билгеле инде, моны тасвирлап бирүдә тоткынлыкта яшәгән, фашистларның ни икәнен үз җилкәсендә татыган шагыйрьдән дә үтемлерәк итеп язып булмаячак. Мәктәп дәреслекләрендә бирелгән “Вәхшәт”, “Кошчык”, “Бүреләр”, “Катыйльгә”, “Җырларым”, “Кызыл ромашка” һ.б. әсәрләр - укучыларга патриотик тәрбия бирүдә әдәбият иң кулай әсәрләр.

Палач балтасы астына “ башын куйган килеш” тә мәхәббәт , балалар, туган илнең киләчәге турында аңлый алыр өчен никадәр олы йөрәкле, кешеләргә карата никадәр мәхәббәтле булырга кирәк. Җәлил үзенең талантын ачкан саен, халык күңелен ача бара. Чөнки һәр әсәре белән аның күңел түрендә йөргән иң изге хисләрен әйтеп бирә.

Үлем куркынычы астында да Туган иленә, халкына тугрылыклы булып калган М. Җәлил үзенең батырлыгы белән генә түгел, ә каләме белән дә фашизмга каршы аяусыз көрәшкән. Фашизмга каршы көрәштә катнашу - Муса Җәлилгә иҗат өчен бик күп материал бирә. Кыска гына вакыт эчендә ул дистәләрчә шигырьләр язарга өлгерә.

Галимнәр, шагыйрьнең фронт лирикасы иҗатының яңа биеклекләргә күтәрелүен күрсәтте, дип саный.

Фронттагы шагыйрьне нинди хисләр били соң? Аның өчен, ут астында яшәгәндә, нинди төшенчәләр кадерле?

«Окоптан хат”, “Каска”, “Госпитальдән”, “Кыз үлеме”, “Тел”, “Европада яз”, “Хуш, акыллым”, “ Тупчы анты”... Бу шигырьләр сугыш елъязмасы дип аталырга да хаклы. Без алар аркылы солдатның яшәү рәвешен күз алдына китерәбез, кичерешләре белән танышабыз.

“Хуш, акыллым” шигыре шагыйрьнең хатыны Әминәгә багышланган. Монда дошман явын җиңеп кайтырга киткән совет солдатының вәгъдәләре бер-бер артлы тезелә. Көрәш, үлем

турында язса да, җанны өтәрлек моңсулык юк. Һәр юлда җиңүгә өмет яшеренгән шикелле. Шагыйрь-солдат ил хакына бирелгән гомер өчен дә үкенмәс кебек.

Патриотик тәрбия бирүдә мин дәреслектә булмаган бик күп өстәмә материаллар тәкъдим итәм. Әлеге материалларга нигезләнеп, без Муса Җәлилнең сынмас рухлы, үз Ватанына, халкына, гаиләсенә тугрылыклы булуы татар халкын гына түгел, дөнья халкын баш иярга, горурланырга мәҗбүр иткәнлеген дәлиллибез. Мәсәлән, беларус халык шагыйре Петрусь Бровка Мусаның батырлыгы турында мондый сүзләр әйтә: " Палач балтасы астында шундый зирәк, ялкынлы, Туган илне чиксез ярату һәм кеше каны эчүчеләргә – фашистларга үтергеч нәфрәт хисе белән сугарылган шушындый юллар язу өчен тимердәй нык ихтыярлы, аек акыллы, олы җанлы, кайнар йөрәкле кеше булырга кирәк. Болар – Муса Җәлил тудырган юллар. Ул җиңүгә тирән ышанды, һәм без җиңүгә ирештек. Туган ил өчен иң кадерле нәрсәләрен – гомерләрен биргән каһарманнар арасында Муса Җәлил исеме һәрвакыт мәңге сүнмәс йолдыз булып янып торыр...".

Мисалларны бик күп китереп булыр иде, чөнки татарның герой шагыйре Муса Җәлил образы һәр ил вәкиле өчен үрнәк булып тора. Муса үзе генә түгел, аның белән янәшә атлаган А.Алиш, Г.Кормаш, А.Баттал һ.б. җәлилчеләрнең каһарманлыгы да бездә ихтыяр көче, туган илгә тугрылык, ватанга бирелгәнлек хисләре тәрбияли.

Безнең арабызда да Муса Җәлил, Газинур Гафиятуллиннар батырлыгын кабатлаучылар аз булмас дип уйлыйм. Яшь буынны әлеге адымнарга, һичшиксез, милләттәшләребезнең батырлыгы илһамландырыр. Мусаның үлемсез җырлары безгә фашистлар җәзалаган миллионнарча көрәшчеләрнең васыятьләре булып килеп җитте, алар үтәлергә тиеш.

*Набиуллина Резедә Хәйдәр кызы,*
*Ильина Зоя Евдоким кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең, татар теле һәм әдәбият укытучылары*

## Инновацион технологияләр кулланып татар теле һәм әдәбияты дәресләренә укучыларда кызыксыну уяту

**(Слайд 1)** Исәнмесез, хөрмәтле коллегалар, жюри әгъзалары! Без, Ильина Зоя Евдоким кызы һәм Нәбиуллина Резедә Хәйдәр кызы, Түбән Кама шәһәренең 31 нче мәктәбендә татар теле

һәм әдәбияты укытучысы булып эшлибез. Шушы матур минутларда бер-беребезгә шат елмаюлар бүләк итик әле. Менә хәзер бүлмәбез тагы да матурланды, яктырып китте.

**(Слайд 2) Минем методик темам: “Инновацион технологияләр кулланып татар теле һәм әдәбияты дәресләренә укучыларда кызыксыну уяту”.**

Мин темамны уңышлы сайладым дип уйлыйм. Чөнки әлеге тема мине заманнан артта калмыйча, яңалыкларны эш тәҗрибәмдә актив кулланып, яңа педагогик эзләнүләргә һәрвакыт өндәп тора. Ләкин, мин, методик темамны тормышка ашыру юлында түбәндәге каршылыкларга очрыйм: **(Слайд 3)**

1. Мәгълүматның күплеге. Еш кына телевизор экраннарыннан, радиодан хаталы, коры сөйләм ишетергә туры килә. Шунлыктан, дөрес сөйләм юкка чыгып барганда, бу тема аеруча актуаль.

2. Баланың аз укуы. Бүгенге заман баласы күбрәк үз вакытын интернет челтәрендә үткәрергә ярата. Ә бу исә үз чиратында танып – белү активлыгын сүндерә, алга таба омтылу эшчәнлеген куып чыгара.

3. Укучыларның күзгә -күз аралашуының бик түбән дәрәҗәдә булуы. Алар буш вакытлары булды исә, кулларына кәрәзле телефон алып, бөтен игътибарын шунда юнәлтә, шулай ук смс, интернетта утыру да аралашуны нык киметә.

**(Слайд 4) Ә менә балаларда үз фәнеңә ничек кызыксыну уятырга соң?** Миңа эшемдә **инновацион технологияләр** ярдәм итә (игътибарны экранга юнәлтү). Дәресләремдә тәнкыйди фикерләү технологиясенең мнемотехника алымын яратып кулланам.

**(Слайд 5)** Мастер-классның максаты: ***Төрле биремнәр аша мнемотехника алымын аңлап куллануга шартлар тудыру.***

**(Слайд 6)** Мнемотехника – грек теленнән тәрҗемә иткәндә, «истә калдыру, хәтер үстерү» дигәнне аңлата, башкача әйтсәк, истә калдыруны җиңеләйтә торган махсус ысуллар тупланмасы. Аның асылы шунда: һәр сүз яки кечкенә сүзтезмәгә аерым рәсем (картина) уйлана; шулай итеп текст схематик рәвештә «языла», әлеге схема-рәсемгә карап, бала информацияне җиңел генә истә калдыра.

Мнемотехника барлыкка килгәнгә 2000 елдан артык.

Мнемотехника алымын уйлап табучылар – Пифагор, Аристотель, Александр Македонский. Мнемотехника җиңел юлдан авырга таба төзелә.

**Мнемотехниканың структурасы:**

Мнемошакмак Мнемоюл Мнемотаблица

**(Слайд 7) Мнемошакмак** бер сүз яки сүзтезмә булырга мөмкин (мәсәлән, кояш нинди? сары, түгәрәк, якты, нурлы).

**(Слайд 8-12) Мнемоюл** – бер җөмлә яки шигырьнең бер юлы. Мәкаль, табышмак булырга мөмкин.

Табышмак. Печән ашый, май ташый. (Сыер)

**(Слайд 13-14) Мнемотаблицалар**. Тулы бер шигырь, я әкият керергә мөмкин.

Эчтәлекне сөйләгәндә мнемотаблицаларга таянып сөйләү. Укучылар барлык катнашучыларны күрәләр, җөмләне дөрес итеп төзеп, билгеле бер эзлеклелекне саклап сөйлиләр. (Мәсәлән, Әминә Бикчәнтәеваның «Туп» шигыре.)

**(Слайд 15)** Ә хәзер иҗади төркем белән биремнәр эшләп карыйбыз. Сезнең каршыгызда “Өмет” аланы сурәтләнгән (А3 форматта тактага беркетелә). Ләкин ул буш, без аны бергәләп бизәрбез. Алдыгызда рәсемнәр бар, сез бу рәсемгә бер сүз белән генә бүгенге мастер-класстан нәрсә көтүегез турында языгыз. (Үзара аңлашу.)

**(Слайд 16) 1 нче бирем.** Бирелгән табышмаклардан мнемотаблицалар төзергә.

–Минем кулымда ике конверт, аларның эчендә табышмаклар һәм шул табышмакларның эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр бар. Сез, өстәлдәге ак кәгазьләргә шушы рәсемнәрне ябыштырып, мнемотаблицалар төзисез. Төзеп бетергәч, шушы мнемотаблицаларга таянып, табышмакны укыйсыз, җавабын әйтәсез.

**1 нче табышмак**

Түгәрәк – ай түгел,

Сары – май түгел,

Койрыгы бар – тычкан түгел. *(Шалкан)*

**2 нче табышмак**

Кош түгел, оча,

Ябалактан курка,

Чикләвек ярата,

Сызгырса, урманны яңгырата. *(Тиен)*

Ә хәзер эшебез авыррак. Мнемошакмаклар белән эшләрбез.

**(Слайд 17) 2 нче бирем**. Мнемотаблица буенча сөйләргә.

Мин сезгә әзер мнемотаблицалар бирәм. Бирелгән схема буенча шигырьне сөйләп күрсәтәсез.

**1 нче шигырь**

**Яратам**

Яратам мин өемне,

Әти белән әнине,

Абый белен энемне,

Бишектәге сеңлемне.

Яратам мәктәбемне.

Укытучы апамны,

Дусымны, иптәшемне,

Уйнап йөргән бакчамны.

*(Шәйхи Маннур)*

**2 нче шигырь**

**Әни кирәк**

Көннәр якты булсын өчен,

Әни кирәк.

Йокы татлы булсын өчен,

Әни кирәк.

Җил-яңгырдан саклар өчен,

Әни кирәк.

Усаллардан яклар өчен,

Әни кирәк.

Ашлар тәмле булсын өчен,

Әни кирәк.

Дөнья ямьле булсын өчен

Әни кирәк. *(Роберт Миңнуллин)*

**Укытучы.** Ә хәзер иҗади төркемне тыңлап карыйбыз.

**Төркемнәргә сорау.** Шулай итеп, Мнемотехника алымын нинди эш төрләрен эшләгәндә куллана алабыз? Бу эш алымы нинди нәтиҗә бирәчәк?

**(Слайд 18) Мнемотехника:**

– истә калдыруны җиңеләйтә, хәтерне арттыра, гомумән, балаларның уйлап сөйләү эшчәнлеген үстерә;

– сөйләм телен үстерү буенча дидактик материал булып тора;

– аларның сүзлек запасын баетканда һәм сөйләм телен үстергәндә кулланырга мөмкин;

– хикәя төзегәндә һәм эчтәлек сөйләгәндә шигырь ятлаганда һәм табышмакларга җаваплар эзләгәндә кулланырга мөмкин.

**Укытучы.** Мастер-классыбызның ахырында Өмет аланына әйләнеп кайтыйк. Сезнең алдыгызда рәсемнәр бар, шул рәсемнәргә сез мастер-класс башында язган өметләрегезнең аклану-акланмавын яздыгыз. Сез нәрсә көттегез, шул булдымы? Сездә нинди хисләр,

тәкъдим, киңәшләр туды? Шулар турында язып, фикерләрегезне безгә дә җиткереп, рәсемнәрне әлеге алангаябыштыруыгызны сорыйм. *(Фикерләр тыңланыла.)*

**Укытучы.** Татарстаныбыз – күпмилләтле дәүләт. Туган телебезне саклау өчен, укучыда өйрәнә торган фәнгә кызыксыну уяту, аның танып белү активлыгын үстерү һәм укучының иҗади мөмкинлекләрен камилләштерү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар.

**(Слайд 19)** Әйдәгез, бергәләп экранда яшеренгән җыр юлларын искә төшерик әле.

**Мин яратам сине, Татарстан**

Мин яратам сине, Татарстан,
Ал таңнарың өчен яратам,
Күк күкрәп, яшен яшьнәп яуган
Яңгырларың өчен яратам.
Мин яратам сине, Татарстан,
Тугайларың өчен яратам,
Тукайларың, Сәйдәшләреӊ өчен,
Җәлилләреӊ өчен яратам.

*(Бергәләп әлеге җырны башкаралар.)*

*Нәбиуллина Ландыш Илдус кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*
*Нәбиуллина Карина Рамил кызы,*
*Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре "25 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Туган тел дәресләрендә синквейн алымын куллану

Без үзебезнең мастер-классыбызны “Тел – белемнең ачкычы, акылның баскычы” дигән татар халык мәкале белән башлап китәсебез килә.

Телне белү, аның белән дөрес эш итү – сүз байлыгына ия булу дигән сүз. Кеше тел ярдәмендә фикерен үтемле, төгәл, мавыктыргыч, тәэсирле итеп белдерә ала, күп төрле

фәннәр үзләштерә, гыйлем туплый. Тел – белемнең ачкычы, акылның баскычы – дип юкка гына әйтмәгән халкыбыз. Димәк, тел кешенең гыйлем дәрәҗәсен, интеллектын гына билгеләп калмый, акыл дәрәҗәсен һәм фикерләү сәләтен дә күрсәтә.

Һәр укытучы һәм тәрбияче үзенең дәресләрен яхшы сыйфатлы, нәтиҗәле итеп үткәрергә, төрле методик алымнарны файдаланырга, укучыларга төпле белем бирергә тырыша. Моңа ничек ирешергә? Татар телен укытуның методик базасын ничек киңәйтергә? Телгә балаларның кызыксынуын ничек булдырырга? Шушы сораулар иҗади эшләүче укытучыларны һәм тәрбиячеләрне бик тә борчый.

Хөрмәтле коллегалар! Без Сезне бүгенге мастер класста балаларның сүзлек запасын баета, эчтәлек сөйләүгә әзерли, идеяне билгеләргә өйрәтә, бала үзен шагыйрь итеп хис итә һәм барлык балалар да башкарып чыга ала торган эш төрләренең берсе — сиквейн алымы белән таныштырасым килә.

Нәрсә соң ул синквейн?

Синквейн фразцуз теленнән кергән сүз, 5 дигәнне аңлата. Ул рифмалашмаган бишьюллык шигъри формада язылган кыска әдәби әсәр. Билгеле план буенча языла, предметны (төшенчәне) ачыклый.

Синквейнны язу тәртибе:

1нче юл. Теманы ачыклаучы сүз, исем. Яки Нәрсә? *Соравына җавап бирә торган сүз.*

2нче юл. Теманы сурәтли торган ике сыйфат. Нинди?

3нче юл. Синквейн темасына хас булган 3 фигыль. Нишли?

4нче юл. Теманың эчтәлеген ачучы фраза, җөмлә. Ул баланың темага мөнәсәбәтен күрсәтә.

5нче юл. Баланың темага карата үз фикерен бер сүз белән чагылдырган нәтиҗә, ассоциация. (резюме).

Хөрмәтле коллегалар! Мин сезне үземнең укучыларым татар теле дәресләрендә төзегән сиквейн белән таныштырып китәсем килә.

Синквейнның темасы төрле булырга мөмкин.

Көз

Сары, яңгырлы.

Коела, ява, салкыная.

Агачлардан алтын яфраклар коела.

Матурлык.

Кыш

Салкын, карлы.

Туңдыра, шатландыра, бүләк итә.

Кыш бабай бүләкләр алып килә.

Яңа ел.

Матур, чиста,

Үсә, яхшыра, яши.

Мин туган шәһәремне яратам

Ватан.

Каюм Насыйри

Белемле, күпкырлы

Укыткан, белгән, өйрәнгән

Мин К. Насыйридан үрнәк алам

Галим.

Хөрмәтле коллегалар! 1нче сыйныфларда синквейн алымын ничек кулланырга була соң?

- Уенчык ярдәмендә.
- Рәсем ярдәмендә.
- шартлы билгеләр белән.

Шулай итеп, Синквейн алымы иҗади сәләтләрне үстерергә, дөрес бәяләргә, үз карашыңны булдырырга өйрәтә. Зур күләмле информацияне гомумиләштерергә, катлаулы мәсьәләләрне гадиләштерергә булыша. Синквейнны язуның төгәл тәртибе укучының фикерен дөрес формалаштырырга, төп фикерне билгеләргә ярдәм итә. Мондый иҗади эш башкару – җиңел, күңелле, файдалы. Сөйләм теле камилләшә, авыр төшенчәләр үзләштерелә. Һәм иң мөһиме халык мәкалендәгечә "Сөйләсәң, сүзнең маен чыгар" дигәндәй Синквейн төзү укучыдан, баладан уку материалында иң мөһим элементларны табуны, йомгак ясауны һәм шуны берничә сүз белән (кыска итеп) әйтеп бирүне таләп итә.

Хөрмәтле коллегалар! Бүгенге мастер классымның темасы итеп "Туган теле дәресләрендә синквейн технологиясен куллану" ны алдым. Минем максатым сезне шул технология белән таныштыру һәм үз дәресләрегездә дә синквейн технологиясен кулланырга өйрәтү.

Һәм бүгенге сөйләшүебезне Нажар Нәҗминең "Татар теле" шигыре белән дәвам итәсе килә.

Татар теле.

Туган җиреңИдел буе,

Һәр телнең бар Туган иле.

Туган җиреңкебек назлы,

Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,

Өзелеп тора кызлар биле.

Кызлар кебек шат чырайлы,

Ачык йөзле татар теле.
Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.
Ассалар да, киссәләр дә
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.
Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй, мөкатдәс Тукай теле.
Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.
Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле!

- Сездә Татар теле нәрсә белән ассоцияләнә? Җилкәдәш партнерларыгыз белән сөйләшеп алыгыз.
- Беренче номерлы коллегаҗавап бирә
- ….
- Карагыз әле, Татар тел – ул …
- Хөрмәтле коллегалар, әйдәгез эш нәтиҗәбез итеп Татар теле темасына синквейн төзик.
- Сезнең алда ватманнар, концтоварлар. Сез шигырь юллары белән бер рәттән иҗадилыгыгызны да җигеп, рәсемнәр куллана аласыз.

Сүзебезне йомгаклап , синквейн алымының өстен якларын санап китәсебез килә:

- Тема буенча лексик материал үзләштерелә, сүзлек байлыгы арта
- Эчтәлекне кыскача сөйләүгә әзерли
- Тәнкыйди һәм креатив фикерләүне камилләштерә

- Ассоциацияләр ярдәмендә алган белемнәр ныгытыла
- Катлаулы информация гомумиләштерелә
- Укучы үзен шагыйрь итеп хис итә
- Бөтен укучы да яза ала.

Балаларны матур, дөрес, төгәл итеп сөйләргә өйрәтү татар теле дәресләренең төп бурычларыннан санала. Бер яктан, сөйләм аң, фикерләү үсеше белән тыгыз бәйләнгән, сөйләм ярлылыгы фикер үсешен тоткарлый. Икенче яктан, телне яхшы белми торып сүз сәнгате булган әдәбиятны да аңлап, тоеп, кичереп булмый. Минемчә, бу метод укучыларны кызыксындырып кына калмас, ә уйландырырга, фикер йөртергә мәҗбүр итәр.
Игътибарыгыз өчен рәхмәт, сезгә авыр әмма ләкин, игелекле, изге эшегездә иҗади уңышлар телибез.

*Нуриәхмәтова Римма Закирян кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "38 нче Лицей" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## “Сәлам” дәреслегенең үзенчәлекләре , аның белән эшләүнең төп һәм әһәмиятле моментлары

Хәерле көннәр.

Мин сезне бүген “Сәлам” дәреслегенең үзенчәлекләре , аның белән эшләүнең төп һәм әһәмиятле моментлары белән таныштырып китәсем килә.

Бүгенге көндә рус телле балаларга татар теле укыту зур проблема булып тора, шуңа күрә дә без татар теле дәресләрен хәзерге заман балалары өчен кызыклы итеп үткәрергә тиешбез. Ә без беләбез, 21 гасыр балаларының ин кызыккан әйберләре – ул заманча технологияләр. Шушы проблемаларны чишү максатыннан мәгариф һәм фән министрлыгы заказы буенча “ сәлам” дигән дәреслек эшкәртелде, бастырылды. Кайбер мәктәпләр уңышлы гына эшләп киләләр.

Аның әһәмиятле үзенчәлекләре бар: бу дәреслек инглиз теле дәреслеге нигезендә төзелгән.

Сәлам дәреслеге тулы комплекттан тора: дәреслек,эш дәфтәре, укытучыларга ярдәмгә килү өчен укытучы китабы,өстәмә эш алып бару өчен стикерлар, лексик материаллар белән карточкалар, диск һәм максус интерактив такта белән куллану өчен сайты бар.

1 сыйныфта өйрәнү өчен 15 модуль бар. Шушы модульлар аша укучылар 1 сыйныфта 160 сүз, 30 сөйләм калыбын өйрәнергә тиеш булалар.

**Электрон дәреслек( интерактив форматта да бар), эш дәфтәре.**

Укытучы сайтны ачып , дәрестә электрон дәреслекне куллана ала. Күнегүләр күп түгел, чөнки дәрес укытучы китабында бирелгән уеннар белән узарга тиеш дип әйтәләр, дәреслек авторлары. Интерактив рәвешкә күчеп аудио күнегүләр эшләп була.

Укытучы китабы шулай ук электрон вариантта бирелә. Андагы уеннар 60 минутка бирелә, укытучы үзе балаларның белем дәрәҗәсенә карап уенны сайлап ала, барысында дәрестә кулланмый. Һәрбер модуль ахырында тикшерү форматы бар. Уен формасында, билге куймыйча укытучы балаларның белемнәрен тикшерә ала.

**Җырлар**

Балалар җырлар аша телне тизрәк, кызыксынып өйрәнәләр. Караоке режимында, сүзләрне яшереп җырлату мөмкинлеге бар

Уеннар

Рәсемле карталар

Тикшерү эшләре

Шулай итеп, “Сәлам” дәреслегендә хәзерге заман балалары өчен дәресне кызыклы итеп үткәрү өчен барлык мөкинлекләр дә бар. Телне өйрәтүгә кызыксыну уятырга дигән максат куелган.

Мин бу дәреслекләр белән үзем эшлим. Р.З. Хәйдарова дәреслекләре белән чагыштырып карадым. “ Сәлам” дәреслекләре белән балаларга телне өйрәнүе күпкә җиңелрәк дигән фикер туды. Балалар татарча җырлар, мимикалар аша лексиканы тизрәк истә калдыралар. Дәрестә уеннар аша татарча аралашалар. Өйдә дә сайтны куллану мөмкинлеге бар.

**«Сәлам!» татар теле дәреслегенең төп үзенчәлекләре нидә?**

1. Төп максатлары – укучыларны татарча җиңел аралашырга өйрәтү.

2.Диалогка урын күп бирелгән.

3. Дәреслектә төрле уеннар, гади сүзләр кергән җырлар күп.

4. Алсу, Азат, Артур, Маша – дәреслекнең төп геройлары.

5. Китапта 160 сүз һәм 30 фраза кулланыла.

6. «Сәлам!» дәреслегенең үз сайты бар - http://selam.tatar/

7. Өй эшләре – иҗади характерда.

*Нуртдинова Гульсиня Асхатовна, Халиуллина Альфия Ахметовна ,Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Халык авыз иҗатын өйрәнү юлында (Тарих эзләре буйлап...)**

(Чыгыш ясаучы укытучы аңлатма бирә. Таныштыру. Чыгышның темасы, максаты.). Фольклор сүзе –инглизчәдән, (халык хикмәте) XIX йөз ахырында таралып, төрле илләрдә киң кулланышка кергән халыкара атама.

Татар фән дөньясында да “фольклор” атамасы узган йөзнең 20 нче елларында гамәлгә керә һәм аңа кадәрге “халык мосаннәфаты” (гарәпчәдән, “әсәрләре”) дигән төшенчәләр урынына йөри башлый. “Фольклор” терминына синоним булып хәзерге вакытта янә “халык әдәбияты” , “халык сүз сәнгате”, “халыкның поэтик иҗаты (тел)”, “халык авыз (тел) иҗаты” дигән атамалар кулланыла.

Сүз сәнгате буларак фольклор халыкның электән чыгарылып килгән традицион һәм хәзерге авыз-теле иҗатын иңләп ала,димәк, чәчмә –прозаик әсәрләрне дә, шулай ук шигъри текстларны да үз эченә берләштерә. Аның язма әдәбияттан аермасы, үзенә хас үзенчәлекләре, асыл сыйфатлары бар.

Ачыктан-ачык сизелмәсә дә, халык авыз -теле иҗаты даими рәвештә иҗади бәйләнештә тора торган тагын бер сәнгать төре бар. Анысы инде-язма әдәбият. Үзенә туу һәм үсеп китү өчен беренче җирлек хезмәтен үтәгән халык иҗаты белән язма әдәбият элек-электән үк инде “кан алмашынып” яшәгән һәм халыкчанлыкка , миллилеккә, тел байлыгына, образлылыкка ирешүдә фольклор казанышларын киң файдаланган. Әлеге процесс, әлбәттә, татар әдәбиятына да хас булган һәм халык иҗатында эшләнгән мифологик һәм традицион символик образларны, мотивларны, сюжетларны, прогрессив идеяләрне үзләштерү һәм ары таба үстерү рәвешендә барган. Халыкның сурәте фикерләвенә хас алымнарны үзләштерү әдәбиятының образлы егәрлеген һәм эмоциональ –эстетик тәэсир көчен бермә-бер куәтләндерүгә , традиция белән яңачалыкның гармоник берлегенә нигезләнгән әдәби әсәрләр тууга китергән. Моңа мисал итеп Г. Тукайның “Шүрәле”, “Су анасы”, “Печән базары”, “Яхуд Яңа кисекбаш” , Х.Такташның “Җир уллары трагедиясенең”, М.Фәйзинең “Галиябану”, Н. Исәнбәтнең “Хуҗа Насретдин”, М.Җәлилнең

“Ана бәйрәме”, “Сандугач һәм чишмә”, Г.Бәшировның “Туган ягым –яшел бишек”, Г.Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” кебек классик әсәрләрен телгә алу да җитә.

Билгеле, ике арадагы бәйләнеш ике яклы булган, ягъни язма әдәбият үзе дә халык иҗатында шактый гына йогынты ясаган. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәрендәге образларның халык җырларына үтеп керүе, китабый “Тахир белән Зөхрә” дастанының сөйләмә вариантлары да барлыкка килүе, Г.Кандалый тарафыннан иҗат ителгән бик күп шигъри юлларның, киң таралып, халык лирикасы белән үрелүе яки шулар үрнәгендә яңа текстлар чыгарылуы, йә булмаса заманында профессиональ шагыйрьләр язган “Минзәлә”, “Бөдрә тал”, (Ә.Ерикәй), “Таң атканда” (С.Хәким), “Кошлар кебек”(Ф.Бурнаш), “Аккош” (Ә.Фәйзи) кебек уннарча җыр текстларының , халыклашып, өстәмәләр һәм яңа строфаларбелән тулылануы менә шуны раслап тора.

Фольклор белән әдәбиятның үзара бәйләнеше аеруча көчле булып, ике арада торучы аерым жанрларда гәүдәләнә. Андый жанр икәү-бәетләр һәм мөнәҗәтләр. Ошбу әсәрләр әдәбият белән халык иҗаты традицияләренә бердәй дәрәҗәдә таяналар һәм язма рәвештә, телдән дә иҗат ителәләр.

Тел-авыз иҗатының күп гасырларга сузылган тарихы бар. Ул үзенең тамырлары белән бик ерак заманнарга –борынгы ташгасыр чорына ук барып тоташа.

Халык әдәбиятын җыю, классификацияләү, әдәби эшкәртү белән әдәбиятыбызга зур өлеш керткән шәхес –Нәкый исәнбәт. Галимнең “Татар мәкальләре” , “Татар табышмаклары” исемле китаплары, 1958 елда “Совет әдәбияты” журналының беренче һәм унберенче саннарында басылган “Татар мәкалҗләрененңшигүри үлчәмлеге” һәм “Татар мәкальләренең шигъри бер үзенчәлеге –рифмалары турында” дигән мәкаләләре татар авыз иҗаты әдәбиятын өйрәнү юлында мзур әһәмияткә ия булган гыйльми хезмәтләр булып санала. Шулай ук махсус балалар өчен дип әдәби эшкәртелеп чыгарылган “Ни өчен ни булган яки утыз ялган” исемле китапта яшь буынны халкыбыз иҗатының кыйммәтле гәүһәрләре белән таныштыру юлында мактаулы хезмәт диясе килә. Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, Н.Исәнбәт нәни дусларын да онытмый, аның махсус балалар өчен язылган байтак шигырьләреннән башка “Елан патшасы”, “Аю белән төлке” , “Мыраужан ага” кебек шигырь белән язылган кызыклы экиятләре дә бар.

Нәкый Исәнбәтнең әдәбият теориясенә караган мәкаләләре арасында “Совет әдәбияты” нурналының 1952 елгы 6 нчы номерында басылган “Драма әсәрләрендә конфликт, уңай һәм тискәре образ мәсьәләләре” исемле мәкаләсе конфликтсызлык “теориясенең” драматургиягә китергән изарарлы йогынтысына анализ ясау һәм драматургия өлкәсендәге хаталарны төзәтү юлында конкрет чаралар күрсәтү ягыннан зур әһәмияткә ия. Тагын “Татар теленең аңлатмалы сүзлеген” төзү өстендә дистәләрчә еллар

буена гыйлҗми эш алып баруын да әйтми булмый.Шуның өстендә күренекле рус язучылары, дөнья классиклары әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү белән дә әдәбиятыбызны баету юлында уңышлы хезмәт итә.

Фидакарь галимнең киң колачлы иҗатына үз чорында югары бәя бирелә: ул 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уңае белән Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә һәм Ленин орденына лаек була.

Нәкый ага Исәнбәтнең гаять олы хезмәт җимеше булган мәкальләре җыентыгында “Хөрмәт сөйсәң, хезмәт сөй! ” дигән мәкаль дә бар. Ул үз гомере буе шушы мәкальнең эчтәлегенә туры килерлек итеп эшли һәм яши.

Әгәр без аның зур мирасының затлылыгы турында да сүз алып барабыз икән, бу, барыннан да элек, әлеге иҗатның халыктагы күңел җәүһәрләре –фольклоры, мифологиясе белән тыгыз бәйләнештә булуы белән аңлатыла. Н.Исәнбәт әлеге хезмәтне гомере буе җыйный. Ул бу эшкә унбер-унике яшендә туган авылы Малаязда керешә. Башкортстан, Татарстаннан тыш, Бараба, Тара, Ишелетамак, Тубыл якларында йөри. Ул туплаган бихисап бәетләр, җырлар, такмак-таймазалар, табышмаклар, мәзәкләр, мәкаль-әйтемнәр халкыбызга билгеле бер системага салынып, фәнни аңлатмалар белән баетылып кире кайтарылалар. Бу эш 1928 елда “Әйдә җырлыйк!” дигән җыентык белән башланган була. Шуннан соң дистәләрчә тупланмалар дөнья күрә. Өч томлык мәкальләр җынтыгы, татар әдәбияты һәм фәнендә генә түгел, гомумән, төрки халыкларда тиңе булмаган олы хезмәт иде. Әдәбиятчы -галим бу эштә бер төп принциптан тайпылмады: фольклор ңанрларының тарихын халыкның ерак һәм якын үткәннәре, аның язмышы белән бәйләнештә үреп карады. Нәкъ менә шул аңа фәннең төрле тармакларында кызыклы ачышларга юлыгу мөмкинлеген тудырды.

Нәкый Исәнбәт-шагыйрь дә, драматург та, фольклорчы да, тел белгече дә, тәрҗемәче дә, тарихчы да, публицис та, гомумән, аның эшчәнлегенең юнәлешләрен билгеләп бетерүе дә шактый кыен. Шунысы гаҗәп: кайсы өлкәдә генә эшләмәсен, ул аларның һәрберсендә олы сүз әйтә алды, шул тармакларның әйдәүчесенә әйләнде.

Йомгаклау сүзе. Күрсәтмәлелек.

Әдәбият


1. Галиуллин Т. Утызынчы еллар әдәбияты/ Т.Галиуллин / Мәгариф.1994ел.
2. Ганиева Р. Урта гасыр татар әдәбияты/ Р. Ганиева / Мәгариф 1997/ 2015
3. Мусин Ф. Милли яңарышның алгы сафында: татар әдәбияты тарихы/ 2005/2016
4. Исәнбәт Н. Мәкальләребез турында: фольклор/Мәгариф/Казан утлары/1999/2004

*Садриева Аниса Хусаиновна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "29нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияте укытучысы*

**Коммуникатив уеннар аркылы,рус телле укучыларның сөйләм телен үстерү**

- Хәерле көн, хөрмәтле коллегалар!
- Сез бала вакытта уйнарга ярата идегезме?
- Нинди уеннар уйнарга ярата идегез?
- Ә нәрсә соң ул уен? (Уен — көнкелгә куаныч, юаныч бирә торган шөгыль.)
- Уйнаганда без нишлибез? (сөйләшәбез, аралашабыз)
- Татар телен чит тел буларак өйрәтү – ул укучыларны бу телдә аралаша белергә өйрәтү дигән сүз. Минемчә, әлеге процесста уеннардан файдалану укучыны белем алуга, укуга дәртләндерә, анда фән белән кызыксыну уята. Чөнки балалар уены чын тормышны чагылдыра. Уен һәрвакыт сүзләр белән бәйләп алып барыла. Бала бер ялгызы гына уйнаганда да курчагы белән сөйләшеп, әллә никадәр җөмлә әйтеп бетерә. Ә дәрестә балага күп вакыт ике- өч сүзне кушып әйттерү дә бик кыен була. Шушы хәлдән чыгу юлын эзләп , мин дәресләремдә коммуникатив уеннарны куллана башладым һәм үземнең методик темам итеп “Коммуникатив уеннар аркылы, рус телле укучыларның сөйләм телен үстерү”не сайладым.
- Әйдәгез әле без дә сезнең белән фикер алышыйк, аралашыйк, уеннар уйнап алыйк.

**« Тыелган хәреф» уены.**

- Бу уенны уйнар өчен, алып баручыны билгелик.
- Без хәзер “Ашханәдә” циклын үтәбез. Димәк, сорауларны да шушы темага карап бирәчәкбез. Уенның кагыйдәсе буенча кемгә сорау бирелә, ул шунда ук җавап бирергә һәм җавабында тыелган хәрефне әйтмәскә тиеш. Әйдәгез шул тыелган хәрефне билгелибез.
- Кем җавап бирә алмый тора, яки « А» хәрефе кергән сүз белән җавап бирә, шуның үзен алып баручы итеп куярбыз.

***« Ике сүздән- өченче сүз» дигән уен-бирем.***

***Бу уенны төрле кичәләргә, бәйрәмнәргә килгәндә үткәреп була. Бары кирәк кадәр күләмдә язылган табличкалар әзерләп куярга кирәк. Табличкалар ишектән кергән һәр***

***укучының киеменә беркетелә. Табличкаларга язылган сүзләрдән өченче, яңа сүз ясалырга тиеш. Мәсәлән « күл», «мәк» « күлмәк». Үз парларын иң беренче табып яңа сүз әйтә белүчеләргә бүләкләр бирелә. Уен өчен түбәндәге сүзләрне язарга мөмкин: « аш-яулык» , « төн- боек» , « озын- борын», « боз-ваткыч» , « бар- мак» , « теле-фон» һ.б.***

***Бу уенны кушма, парлы, тезмә сүзләрне белү максатыннан үткәрергә мөмкин.***

***Уенның икенче варианты.***

***Түбәнрәк сыйныф яки телне авыр үзләштерүчеләр белән болайрак итеп үткәрелә.***

***1нче укучыга « күл», 2нче укучыга « мәк», өченчесенә « күлмәк» дигән табличкалар беркетелә. Карточкалар уенда катнашучылар саны буенча әзерләнә. 3 укучы бер-берсен табып, бер төркемгә берләшергә тиешләр. Команда биргәч, алып баручы янына беренче булып килеп баскан биш пар җиңүче була.***

**« Нәрсә ашыйм, шуны әйт» уены. (***монологик сөйләм телен, хәтерләрен үстерәбез)*

- Мин сезгә рәсемнәр ясалган карточкалар таратам. Бу карточкаларны сез күршеләрегезгә күрсәтмәгез. Анда ясалган ризык буенча кечкенә хикәя төзеп сөйләргә тиеш буласыз. Ә калганнар сөйләү буенча, аның нәрсә ашавын белергә тиеш. Сөйләгәндә ризыкны ашау кыяфәтләрен дә күрсәтергә мөмкин.

***« Хикәя төзү». (Сөйләм үстерү уены)***

***Алып баручы үзе яки бер укучы хикәяне сөйли башлый. Ул алдан әйтелгән берәр тема буенча яки ирекле булырга мөмкин. Мәсәлән, Петя сөйли башлый:***

***- Мин шундый кызык кино карап утыра идем. өйдә берәү дә юк. Кинәт ишек шакыдылар. Мин барып ачтым һәм күрәм … .***

***Шуннан икенче укучы сөйләп китә. Аннан башкалар. Соңыннан алып баручы үзе төгәлли.***

Күргәнегезчә, коммуникатив уеннар- сөйләмне үстерүгә, камилләштерүгә, баланы җанлы сөйләмгә ( диалогка) яки күмәк сөйләмгә тартуга этәргеч булып тора.

*Садыкова Лидия Хәмдегали кызы,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы*

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә “Фишбоун” методик алымын куллану**

Төркемнәрдә уку эшчәнлеген рефлексияләү өчен кулланыла торган методик алымнарның берсе - Фишбоун алымы. Фишбоун сүзгә-сүз «Балык сөяге» яки «балык скелеты» дип тәрҗемә ителә. Әлеге методик алымның асылы - анализ объекты һәм аңа тәэсир итүче факторлар арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү.

Балыкның һәр өлеше билгеле бер функция башкара:

Баш өлеше - дәрес проблемасын аңлата. Проблеманы дәрес башында ук әйтәбез, балалар аны үзләре теләгән формада язып куялар.

Скелетның аскы өлешендә өйрәнелгән тексттан фактлар китерелә.

Ә өске өлешендә фактларга китергән **сәбәп**ләр языла.

Балык койрыгы ул – нәтиҗәләр, ягъни уку эшчәнлегенең рефлексиясе. (Эш барышында балык рәсемен үрнәк буенча укучылар үзләре дә тиз арада ясый ала, укытучы әзер рәсем дә бирә ала)

Үрнәк итеп бер дәрес мисалын китерергә телим. 5 нче сыйныфның рус телле төркемнәрендә «Ни өчен бүген Олегның кәефе юк?” дигән текст бар. Укучыларга парларда яки төркемнәрдә эшләп, Олегның кәефсезлегенең сәбәпләрен ачыклау бурычы куела.

Баш өлешенә укучылар проблема язалар. Җаваплар кыска һәм төгәл булырга тиеш.

Мәсәлән: Олегның кәефе юк.

Алга таба алар Олегның ни өчен кәефе юклын фактлар аша раслыйлар, аны скелетның аскы өлешенә теркәп куялар. Бу очракта: математикадан «2”ле, контроль эше «3” ле, чиреккә «3”ле чыга кебек фактлар китерелә.

Скелетның өске өлешенә бу фактларга китергән сәбәпләр языла. Мәсәлән: өй эшен эшләмәгән, урамда йөргән, сүзендә тормаган һ. б.

Балыкның койрыгына нәтиҗәләрне язып куярга кирәк. Алар да төрле булырга мөмкин. Бу очракта балалар Олегка киңәшләр бирәләр. Мәсәлән: Олег, өй эшләрен эшлә! Урамда озак йөрмә! Сүзендә тор! Телевизор карама! Һ.б.. Эшне төгәлләгәннән соң, укчылар скелетны тоташтырып, “алтын балык” ясап куярга да мөмкиннәр.

Менә шундый кызыклы һәм файдалы да, күңелле дә итеп әлеге Фишбоун алымын дәресләрдә кулланырга мөмкин. Тагын татар телен яхшы белгән укучылар белән әдәбият дәресләрендә Ә.Еникинең “Әйтелмәгән васыять”ен, Г.Камалның “Беренче театр” комедиясен дә анализларга мөмкин.

*Сәлимҗанова Алсу Илдар кызы,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы "Адымнар-Әлмәт" полилингваль гимназиясе" муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Татар теле дәресләрендә грамматик уеннар (яңача уеннар)**

Укырга-язарга өйрәтү, дөньяны танып-белү, тәҗрибә туплау, тәҗрибә уртаклашу, фән-техника, сәнгать яңалыклары белән танышу, иҗат итү тел ярдәмендә генә була ала. Тел кешенең барлык иҗтимагый эшчәнлеген оештыра.

Шуңа күрә дә борын заманнан ук һәр халык балаларын ана теленә ныклап өйрәткән, аның телен шомартуга, сүзлек хәзинәсен арттыруга, сөйләгәндә һәм язганда аннан оста файдалануга бик нык игътибар иткән. Һәр ана баласына “тел ачкычы” бирү өчен, бишек җыры җырлаган, сүзле уеннар оештырган, үсә төшкәч, такмаклар, тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар өйрәткән.

Педагогика һәм психология өлкәсендә укыту методы буларак, уен XX гасырның 70 нче елларында киң тарала. Укыту процессында уен технологиясе максатчан булуы белән гомуми уен эшчәнлегеннән аерылып тора.

Кече яшьтәге балалардан башлап, югары сыйныф укучылары өчен белем һәм тәрбия уен аркылы бирелә. Уйнаган вакытта бала күп нәрсә таный, күнекмәләр ала. Шуның өчен укытучы белем һәм тәрбия бурычын алда тотып, тел дәресләрендә балаларның уеннарын максатка ярашлы итеп оештырырга тиеш. Мин үз эшчәнлегемдә түбәндәге бурычларны куйдым:

- укучыларда татар телен өйрәнүгә уен методикалары аша кызыксыну уяту;
- уен-карточкалар аша татар телендә сүзләрнең дөрес язылышын истә калдыру һәм сөйләм телен үстерү;
- укучыларның танып белү сәләтләрен үстерү һәм мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен формалаштыру.

Уен баланың фән белән кызыксынуын көчәйтә, мөстәкыйльлеген, ихтыяр көчен, акыл эшчәнлеген, зирәклеген үстерә, аны коллективлык рухында тәрбияли, билгеле бер максат куеп эшләргә өйрәтә. “Уен – әйләнә-тирә мөхит төшенчәләрен баланың рухи дөньясына алып керүче зур якты тәрәзә ул. Уен-кызыксыну һәм белемгә омтылу утын кабыза торган учак ул”, - ди Василий Александрович Сухомлинский.

Уеннар укучыларда ана теленә мәхәббәт тәрбияли, тирән кызыксыну уята. Педагогик эшчәнлеккә бәйле рәвештә Герман Константинович Селевко уеннарны түбәндәге төркемнәргә бүлә:

дидактик (белем дәрәҗәсен, танып белү эшчәнлеген киңәйтү, белем һәм күнекмәләрне гамәли эшчәнлектә куллану, гомумуку күнекмәләрен үстерү һ.б.);

тәрбияви (мөстәкайльлек тәрбияләү, билгеле бер юнәлешләр, дөньяга караш тәрбияләү һ.б);

үстерелешле (игътибар, хәтер, сөйләм, фикерләүне, уку эшчәнлеген үстерү һ.б.);

социальләштерүче (аралашу өйрәтү һ.б) .

Үткәрү методикасы буенча уеннар бик күп төрләргә бүленә: предметлы уеннар, сюжетлы уеннар, рольле уеннар, эшлекле уеннар һ.б.

“Һәрбер уенның нигезендә барыннан да элек, хезмәт тырышлыгы, фикер тырышлыгы бар,”- дигән бөек педагог Антон Семенович Макаренко.

Дәрестә уен элементларын куллану укытучыдан методик әзерлек һәм тәҗрибә сорый. Укытучы педагогик уенның төп асылын аңлаганда гына уку белән уенны аралаштыру процессы уку-укыту эшчәнлегендә уңай нәтиҗәләргә китерә.

Уенны дәреснең төрле этапларында кулланырга мөмкин, яисә дәресне тулаем уен формасында үткәрергә була. Мондый дәресләр традицион булмаган дәрес формалары дип атала (дәрес-диспут, дәрес-викторина, дәрес-КВН)

Рус телле балаларга татар теле өйрәтү – бик катлаулы һәм җитди эш. Шуңа күрә дә, дәрестә яңа сүзләрне актив сөйләмгә кертү, сүзләрнең дөрес язылышын истә калдыру балаларның сүзлеген тулыландыру эше уеннар ярдәмендә алып барыла. Дәрестә кулланылган дидактик уеннар алган белемнәрне ныгытырга, сүзләрнең дөрес язылышын истә калдырырга, сүз байлыгын арттырырга мөмкинлек бирә. Өстәл уеннары балалар өчен кызыклы шөгыль. Алар күп төрле: парлы рәсемнәр, лото, домино һ.б. Дәрестә сүзле уеннар уйнаучыларның сүзләренә һәм хәрәкәтләренә корыла. Бу уеннарда башлыча авазлар дөрес әйтергә өйрәтелә, сүзлек баетыла һәм активлаштырыла, бәйләнешле сөйләм үстерелә. Аралашуга өйрәнү теләге уятыла. Мисал өчен, үзем ясаган брошюраны тәкъдим итәм. Брошюра Ә хәрефен сүзләрдә дөрес куллану, Е хәрефе белән бутамау һәм яңа сүзләрне истә калдырып, аларны дөрес язу максатыннан ясалган. Әлеге брошюра ярдәмендә, укучылар ә хәрефе кергән, рәсем, әби, бәби, эти, әни, әкият, кәҗә, шикәр, рәхмәт, дәфтәр, сәгать, сәлам, әҗәт, мәктәп, әйбәт, әлифба һ.б. сүзләрне китереп чыгара һәм аларның язылышын истә калдыра алалар.







Татар теле дәресләрендә укытучы баланың югары сөйләм культурасын формалаштырырга, ишетеп аңлау, уйлау, фикер йөртү, аралашу осталыгын, иҗади сәләтен үстерергә, мөстәкыйль эшләү омтылышын уятырга тиеш. Укучыларның белем һәм күнекмәләрен арттыруда, аларның үз фикерләрен язмача яки сөйләмә рәвештә формалаштыра белергә өйрәтүдә, үзара аралашу осталыгына ирешүдә, шулай ук балаларны тел фәне белән кызыксындыруда уеннарның әһәмияте зур.

Татар теле дәресләрендә, аерым тел фактын өйрәнгәндә, сөйләү һәм язу күнекмәләре биргәндә, мавыктыргыч уеннар белән читенлек ситуациясе тудырылырга, уен элементлары кертеп, проблемалы сорау һәм мәсьәләләр куелырга тиеш. Аларны чишү балада үз көченә ышану тойгысы уята, аннан зуррак эшләрне башкаруга, катлаулы күнегүләрне эшләүгә дәртләндерә, максатка ирешүдә бернинди киртәләр алдында да тукталып калмау сыйфатын формалаштыра. Тагын бер мисал итеп, дәресләрдә актив кулланган уенымны китерәсем килә. Төрле яшьтәге укучылар бик яратып “Крестики-Нолики” уенын уйныйлар. Шул уенга таянып, туган (татар) тел дәресләренә яраклаштырып, татарча “Сузыклар һәм Тартыклар” уенын әзерләдем.  Бер укучы сузык, ә икенче укучы тартык хәрефләрне яза. Бу уенның кагыйдәсе “Крестики-Нолики” кебек, ләкин бирелгән хәрефләрнең чиратын бозарга ярамый. Әлеге уен ярдәмендә укучылар татар телендә генә булган хәрефләрнең дөрес язылышын истә калдыралар.



Уен күнегүләре туган телне өйрәнү белән укучыларны мавыктыру, сыйныфта грамматика дәресләрен җанлы, кызыклы итү, балаларның дөрес сөйләү һәм язу күнекмәләрен аңлап һәм җиңел үзләштерү булдыру теләгеннән чыгып эшләнде. Дәресләрдә үзем куллана торган берничә грамматик уенны тасвирлап китәм. Тел өйрәнүдә актив кулланылган уеннар – **“Филворд”** һәм “Сүзләр эзләп табу”**.** Дәресләрдә яңа сүзләрне танып белү, белгән сүзләрнең язылышын истә калдыру максатыннан уйналына. Һәр укучыга карточкалар бирелә. Хәрефләр арасыннан бирелгән сүзләрне тиз арада эзләп табырга кирәк. Тагын шундый уеннарның берсе – **“Дөрес җавапны билгелә”.** Укучыларга рәсемнәр һәм төрле сүзләр бирелә. Шул рәсемгә туры килгән сүзне эзләп табырга тиеш була. Мисалга, әтәч рәсеме һәм “тавык, чеби, әтәч” сүзләре язылган. Укучы дөрес җавапны билгеләргә тиеш. Шулай ук, тактада магнит белән урнаштырылган рәсемнәр һәм сүзләр куелган. Укучы әлеге сүзләрне һәм рәсемнәрне дөрес урнаштырырга тиеш. Бу методика безгә синоним, антоним һәм омонимнарны өйрәнгәндә ярдәм итә.














“Тамырдаш сүзләр” темасын өйрәнгәндә үзем ясаган китап ярдәмгә килә. Сүзнең тамыры китапта инде бирелгән, ә кушымчаны эзләп табып, “липучкалар” ярдәмендәябыштырып куярга кирәк. Әлеге уен укучыларга сүзләрнең дөрес язылышын истә калдырырга, сүз байлыгын киңәйтергә ярдәм итә.










Мәгълүмати-коммуникатив технологияләрдән уңышлы файдалану, тел һәм әдәбият фәненә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә миңа. Укучыларда ана телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли, аның байлыгын, матурлыгын, фикер тирәнлеген ачып бирә, аны мәдәниятле итә, һәрьяклап үстерә, шәхес итеп тәрбияли. Укытучы укучыга тормышта үз урынын табарга ярдәм итүче төп ышанычы булып кала.

Шәхси эшчәнлек баланың тормыш кыйммәтләрен, әйләнә-тирәсендәге барлык нәрсәгә шәхси карашы формалашуны аңлауга юнәлгән. Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре укучыларның шәхси, әдәп-әхлак нормаларын үзләштерүен, тиешле карар кабул итә белүен, үзен тормышта лаеклы шәхес итеп куюын үз эченә ала.

Кулланылган әдәбият

1. Вагыйзов С.Г. Кызыклы грамматика. – Казан: Татарстан китап нәшрияты.- 1970.- 168 б.
2. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар. – К(И)ФУ АФ нәшрияты, 2012. – 137 б.
3. Селевко Г.К. Современные образовательные технологии.- М.: Просвещение, 1998, - 275 с.

*Сиразиева Ленизa Шакирьяновна,*
*Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре "53 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Туган тел дәресләрендә нейрогимнастика күнегүләрен куллану**

Заманча белем бирү киңлегендә укытучының инновацион эшчәнлегенә нейрогимнастика күнегүләре дә кирә. Чөнки нейрогимнастика күнегүләре ярдәмендә укучыларнын белемен арттырырга, яхшыртырга була. Нейрогимнастика ул – ике кул яки ике аякның бер үк вакытта синхрон рәвештә төрле күнегү эшләве. Бу очракта баш миенең ике як ярымшары да килешеп эшли. Нейрогимнастиканың түбәндәге өстенлекләре бар: хәтер һәм фикерләү эшчәнлеге, энергия арта; арыганлык кими; эре һәм вак моториканың эшчәнлеге яхшыра; язу һәм уку сыйфаты яхшыра; нәтиҗәлелек арта. Баланың мәктәптә уку вакытында миенең сул як ярымшары күбрәк эшли. Минең уң як ярымшарын эшләтеп җибәрү өчен нейрогимнастика күнегүләре ярдәмгә килә.. Иң мөһиме – нейрогимнастика күнегүләренең файдасы булсын өчен һәр көн 5-7 мин. шөгыльләнергә кирәк. Мәсәлән, беренче күнегү. *Кызыл* түгәрәк – кул белән өстәлгә сугарга яки аяк белән идәнгә. Яшел квадрат – ик кулны уүтәрергә, аякны аерып басарга. Зәңгәр өчпочмак – кул чукларын кушарга, аякны кушып басарга. Сары дүртпочмак – кулларны чалыштырырга яки аякларны чалыштырып басарга. Күнегү башта куллар белән генә эшләнә, берничә дәрестән сон аяклар белән дә.

Чираттагы күнегү “Йодрык-уч төбе” дип атала. Йодрыкка йомарланган кулның баш бармагы белән икенче кулның уч төбенә төртергә кирәк. Кулларны чиратлаштырып 8-12 тапкыр кабатларга. Тагын бер күнегү – кул чукларын әйләндереп баш белән имән бармактан фоторамка ясыйбыз.

Киләсе күнегү –чалыштыру. Баш бармагы аска , сул кулның уч төбе үзеңә юнәлтелгән уң кул йодрыкта, куллар чалыштырылган.Сул һәм уң кулны чиратлаштырып кабатлыйбыз.

Тагын бер күнегү- “Окей –ике”. Уң кул белән окей , сул кулда ике санын күрсәтәбез. Кулларны чиратлаштырып 8-12 тапкыр кабатларга. Катлауландыру очен 2 саны урынына 3 санын күрсәтәбез. Темага бәйләп катлауландырсак, мәсәлән, төсләр өйрәнгәндә, төсләрне атыйбыз, күнегү күрсәтәбез. Ак, кара, яшел, кызыл зәңгәр.

Һәм чираттагы күнегү. Йодрыкка йомарланган ике кулның баш бармаклары белән, синхрон рәвештә әйләндерү хәрәкәтләре ясарга кирәк. Һәм иң күңелле күнегүләрнең берсе барлык органнар өчен дә файдалы гимнастика. Бергәләп эшлибез. 8-12 тапкыр кабатларга кирәк. Күрсәтелгән әлеге күнегүләрне туган тел дәресләрендә хәтер һәм фикерләү эшчәнлеге, энергия арту, арыганлыкны киметү,эре һәм вак моториканың эшчәнлеге яхшырту, язу һәм уку сыйфатын яхшырту өчен кулланырга була.

*Хайруллина Лилия Аркадьевна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "2 нче Кама Аланы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Рус телле балаларны телгэ кызыксындыруда проект методынын роле ( мастер-класс)**

Югары квалификацион категорияле укытучы, ТР Түбән Кама муниципаль районының “ Кама Аланы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнче 2 нче урта мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары (ФДБС) шартларында укытучы эшчәнлегенең нәтиҗәле юнәлешләреннән берсе булып проектлар методы санала.

Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану - яңа метод һәм алымнарны үстерергә, яңача эшләргә ярдәм итә. Без, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, дәрестә өйрәнгән теманы җиңел юл белән үзләштерә торган, белем сыйфатын күтәрүгә файдалы булган проектлар методын куллану уңай күренеш дип саныйбыз.

**Проект методы** - нинди дә булса проблеманы өйрәнү һәм гамәли нәтиҗәсен күрсәтү өчен укучыларның мөстәкыйль эшчәнлегенә нигезләнгән укыту методы.

**Проект методын куллану түбәндәге бурычларны үти:**

- Эш барышы телне өйрәнүгә теләк уята.
- Проект эшен оештыру барышында укучылар үз - ара аралаша, укытучы тикшерүче ролен түгел, киңәшче ролен үти.
- Укучыны билгеле бер тема өстендә иҗади эшләргә, төрле чыганакларны кулланып, үзаллы мәгълүмат табырга өйрәтә, уку эшчәнлеге активлаша.
- Бөтен уку процессы укучыга юнәлтелә, аның кызыксынуы, тормыш тәҗрибәсе, шәхси сәләтләре искә алына.

Укучылар эшчәнлегенә карап, **проект төрләре бишәү:**

1. **Эзләнү проектлары**. Бу проектның төгәл структурасы булырга тиеш. Нинди дә булса проблеманы чишүгә, эзләнүгә нигезләнгән. Күпмедер дәрәҗәдә ул фәнни-эзләнү эшләре белән дә тәңгәл килә. Ахырда нәтиҗәләр чыгарыла һәм киләчәктә дәвам итү өчен яңа проблемалар яктыртыла.

**Үземнең эш тәҗрибәсеннән түбәндәгеләр:**

- берәр язучының иҗаты буенча проблемалы сораулар куеп, эзләнү эшләре алып бару;( Илдар Юзеевның – мәхәббәт җырчысы, икәнен дәлилләү.)

- язучының берәр әсәренә лингвистик анализ ясау;

- балалар газетасы яки журналына күзәтү ясау.

Рус төркемнәрендә укучылар белән 5 сыйныфта теманы өйрәнгәннән соң әдәбият дәресендә бик яратып " Салават күпере", " Көмеш кыңгырау" газета - журналлары буенча проект эшләре башкарабыз.(журнал тарихы, аның рубликаларын өйрәнү, үз иҗатлары шул журналларга җибәрү өстендә эшлибез, нинди рубрикага туры килүен тикшерәбез,һ.б ).

Сыйныфтан тыш вакытта (түгәрәк вакытында) милли йолаларны торгызу максаты белән " Туй йолалары: үткәне һәм бүгенгесе" темасы буенча эзләнү проекты өстендә эшләдек. Проект барышында укучылар туй тарихын, аңа бәйле йолаларны өйрәнеп, бүгенге көнгә кайсы йолаларның килеп җитүен тикшерделәр.Республиканың төрле районнарында туй белән бәйле йолаларның сакланышын билгеләделәр.Бигрәктә укучыларны " Яшь киленгә су юлы күрсәтү" йоласы кызыксындырды, шул йола буенча эзләнү эше башкардылар. Нәтиҗәдә," Яшь киленгә су юлы күрсәтү йоласы" буенча сценарий төзелде.Эшне дәвам итү өчен яңа максатлар куелды.

**2. Иҗади проектлар**. Структураның төгәллеге таләп ителми. Алдан якынча гына төзелә, ә эш барышында киңәйтелә. Эш нәтиҗәсе -продукт - бергәләп иҗат ителгән газета, буклет, инша, видеофильм, спектакль (инсценировка), бәйрәм.

Безнең мәктәптә Аулак өй, Карга боткасы, Нәүрүз, Яңа ел бәйрәмнәре үткәрелә. Бу уеннар үзенә бер проект эшчәнлеккә әйләнә. Балалар проблемалы сорау куеп, проектның эш планын төзиләр. Башта алар бу бәйрәм турында мәгълүмат туплыйлар.Тупланган белемнәрен уртаклашалар һәм гомумиләштерәләр. Проектны яклау эше итеп, шушы бәйрәмнәрнең берсен үткәрү алына. Соңыннан рефлексия ясала, бәйрәм турында фикер алышына.

Рус төркемнәрендә дәрестә инценеровкага урын бирәбез."Тавык,тычкан һәм көртлек", " Койрыклар" әкияте белән дәрестә танышканнан соң, проект эше билгеләнә. Нинди рус әкиятенә ошаган, нинди аермалы яклары бар тикшерелә, геройларга характеристика бирелә, рольләргә бүленеп, төркемнәр чыгыш ясарга әзерләнә.

Югары сыйныфлар белән "Һөнәр сайлау" бүлеген тәмамлагач, проект эше башкарабыз.Укучылыр өчен "Ин куркыныч һөнәрләр" "Заманча һөнәрләр", " Онытылып баручы һөнәрләр","Иҗади һөнәрләр", һ.б темаларга бүленеп төркемнәрдә, парларда эш башкарыла.Проектны яклаганда укучылар формасын үзләре сайлый, кемдер презентация рәвешендә, кемдер буклет рәвешендә эшләрен яклый,укучылырга бу эш төре бик ошый, эшне кызыксынып башкаралар.

**3.Уенлы (рольле) проектлар.** Шулай ук структурасының төгәл булуы мәҗбүри түгел, эш ахырына кадәр ачык булып кала. Мондый очракта балалар үзләренә нинди дә булса роль алалар. Ул әдәби персонаж да, уйлап чыгарылган герой яки әкият герое да, ситуациядән чыгып, эшлекле мөнәсәбәттә булган һөнәр иясе дә булырга мөмкин.

Мәсәлән, 4 сыйныфта Вахит Монасыйповның “Шифалы табиблар” хикәясен өйрәнгәннән соң укучыларда шифалы үләннәр турында күбрәк белү теләге уянды. Балаларга рольләр бүленеп бирелде: энциклопедист, табиб, журналист, рәссам. Энциклопедист үләннәрнең кайда үсүе, буе, озынлыгы, ничә ел яшәвен тикшерә. Табиб медицинада нинди урын алып торуы, текст буенча нинди авыруларны дәвалавын өйрәнә. Ә журналист халыкның көнкүрештә ничек файдалануы турында мәкалә яза.Рәссам дару үләннәрен рәсемгә төшерү биремнәре ала.

**4. Мәгълүмати проектлар.** Факт һәм статистикага нигезләнеп, берәр күренеш яки объект турында мәгълүмат җыюга корылган. Эзләнү проектындагы кебек төгәл структурасы булырга тиеш. Бу проект күп очракта эзләнү проекты элементлары белән үрелеп тә китә. Эш нәтиҗәсе-продукт итеп мәкалә, реферат, чыгыш, видео, презентацияләрне алырга һәм аны киң аудиториягә тәкъдим итәргә мөмкин.

Мәсәлән, берәр язучының тормыш юлы буенча эш оештырам.

**Язучы иҗаты буенча проект эше:**

- Портрет характеристика бирү;
- Бөек кешеләрнең язучы турында әйткән сүзләре;
- Язучының тормышы һәм иҗаты буенча презентация ясау ;
- Викторина төзү;
- Әсәрләре буенча иллюстрацияләр;
- Язучы һәм сәнгать ( музыка, сынлы сәнгать);
- Буклет чыгыру,

Үзебезнең төбәктән чыккан артистлар һәм аларның театр сәнгатенә керткән өлешләре темасына проект эше башкарылды.

**5. Гамәли проектлар.** Проект өчен тема сайлаганда, укучылар фикерен искә алу әһәмиятле. Моның өчен аларның кызыксынуларына (хоббиларына) игътибар итәргә кирәк. Эш нәтиҗәсе-продукт алдан ук күзаллана һәм аның киләчәктә гамәли файдасы, ягъни кулланучысы булу шарт итеп куела.

***Мәсәлән түбәндәге эшләр үтәп була:***

- үзең төшергән фотосурәтләрне өстәп, сыйныф, мәктәп яки шәһәр тормышын яктырткан журнал чыгарып тарату;

- татар теле атналыгын яктырткан газета чыгару;

- берәр татарча видеодәресләр төшереп, Интернетка урнаштыру;

- әсәрләрне тәрҗемә итеп, китапханәгә китапчык тәкъдим итү.

- билгеле бер тема билгеләп мәкальләр туплау, аны китапчык итеп бастыру.

Рус төркемнәре яратып “ Дүрт аяклы дусларыбыз” темасы буенча проект эшләре үти, видеопрезентацияләр әзерли.

7 сыйныфта(рус төркемнәре) “Милли киемнәр һәм бизәнү әйберләре” темасын өйрәнгәннән соң, мини -проект эшен башкарабыз.Һәр укучы үзенә ошаган милли киемне сайлап, аның тарихын, кулланышын, үзенчәлеген тикшереп, өйрәнеп, теләгән формада яклап чыга. (презентация, кул эшләре һ.б).

***Укучыларның проект эшләрен бәяләү:***

| Бәяләү критерийлары. Анкета | Билге. Җаваплар. |
|---|---|
| 1. Презентацияне бәяләү<br>• Кызыклы материал<br>• Матур бизәлеш<br>• Материалның бирелеше ( логик яктан)<br>• Презентацияне күрсәтү | |
| 2. Укучыларның телдән чыгышы:<br>• Аңлаешлы сөйләм<br>• Материалны дөрес аңлату<br>• Эмоцианальлек,сәнгатьле сөйләм | |
| 3.Публикацияне бәяләү<br>• Дизайн<br>• Статьялар сайланышы | |
| 4.Мондый эш төре ошадымы | |
| 5.Тагын нинди темага проект эше эшләр идең | |
| 6.Проект буенча синең сорауларың | |
| 7.Бәяләү нәтиҗәләре | |

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә**

**проект методын куллану.** *(мастер класс)*

**Проектның темасы:** "Сибгат Хәким – туган як җырчысы".(Сибгат Хаким тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү – шагыйрьнең юбилее уңаеннан).

**Проектның төре**: эзләнү – тикшеренү характерындагы эшчәнлек.

**Проектның максаты:** Сибгат Хакимнең тормыш һәм иҗат юлын тирәнтен өйрәнү.

**Проектның бурычлары:**

- Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү күнекмәләре формалаштыру;
- Укучыларның ораторлык сәләтләрен үстерү;
- Аларда югары әхлакый сыйфатлар тәрбияләү;
- Балаларга патриотик тәрбия бирү.

**Проектның эчтәлеге**

Проект тулысы белән Сибгат Хакимнең тормышын, иҗатын өйрәнүгә, укучыларда татар әдәбиятын өйрәтүгә кызыксыну уятуга юнәлдерелгән. Проект өстендә эш шагыйрьнең музеена видео- экскурция ясау белән төгәлләнә.Проект укучыларны мөстәкыйль рәвештә информация табарга, аны анализларга, кирәк урында куллана белергә өйрәтә.

**Кирәкле җиһазлар:** Сибгат Хәким иҗаты һәм тормышы турында материаллар, Сибгат Хакимнең шигырь җыентыклары, язучы турында альбом, папка, файллар, принтер, диск, презентация, компьютер.

**Нәтиҗәсе**: эзләнү-тикшеренү эшләрен папкага туплау, презентация әзерләү, тыңлаучылар каршында чыгыш ясау.

**Проектны башкаручылар:** 11 нче сыйныфның ике төркем укучылары

**Проект өстендә эшләү этаплары:**

1. Сибгат Хакимнең тормыш һәм иҗаты турында тирәнтен өйрәнү .

Шагыйрь турында үстәмә материал туплау һәм презентация әзерләү.

2.Сибгат Хаким иҗатын тематикаларга бүлү, эзләнү – тикшерү эшенең юнәлешен билгеләү.

3. "Сибгат Хаким -туган як җырчысы" икәнен дәлилләү,шигырьләрен сайлау.

4. Эш бүлешү (чыгышлар, шигырьләр, компьютерда бастыру, презентация әзерләү).

5. Проектны яклау.

Проект эшендә катнашып, укучылар үзләрен кызыксындырган өлкәдә белемнәрен арттыру белән бергә

- үзләренә максат куярга, аңа ирешү юлларын планлаштырырга;
- мөстәкыйль мәгълүмат табарга, аны аерырга һәм гомумиләштерергә;

- үз эшләренә төзәтмәләр кертергә, контрольдә тотарга, бәя бирергә;
- бер-берсе белән килешеп, төркемнәрдә эшләргә;
- үз фикерен әйтү өчен тел чараларын кулланырга;
- аудитория алдында сөйләргә;
- башланган эшне ахырына кадәр җиткерергә өйрәнәләр.

Шулай итеп, уку-укыту эшчәнлеге ФДГББСның фундаменталь үзәген тәшкил итүче универсаль уку гамәлләре белән кораллана. Шундый эш алымнары ярдәмендә үткәрелгән дәресләр укучыларда телгә, әдәбият дәресләренә кызыксыну, сөю тәрбияли. Гомумән, иҗади дәресләр генә эзләнүчән, бай рухлы, зирәк, сәләтле шәхесләр тәрбияләүгә булышлык итә. Проект эшчәнлеге, минемчә, сүз тәрбиясеннән күчеп, тормышның үзендә һәм тормышның үзенә тәрбияләү юлын ача.

*Хайруллина Лилия Миннефаязовна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «26нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әбәияты укытучы*

**Формирование коммуникативных технологий на уроках татарского языка**

Наш мир сегодня подвержен постоянным изменениям, в числе которых глобализация, ускорение темпов развития общества, переход к постиндустриальному, информационному обществу, значительное расширение масштабов межкультурного взаимодействия, возникновение и рост глобальных проблем, возрастание роли человеческого капитала. В связи с этим миру необходимо такое общество, которое сможет не только выдержать подобный темп развития, но и неустанно ставить перед собой и решать все новые и новые задачи. Образование играет важнейшую роль в формировании общества нового уровня. Цели, парадигмы, методы, которые были актуальны десять лет назад, должны уступить место новым целям, парадигмам и методам.

В настоящее время школа, так же как и образование в целом, повернулась к личности ученика и пытается создать все условия для становления его как субъекта жизни.

Если ранее результатом обучения являлся ученик, владеющий всеми знаниями, умениями и навыками, которым научили его учителя, то сегодня результатом обучения является личность, компетентная в конкретной области знаний.

Основным результатом своей деятельности, я считаю, получение детьми прочных знаний, умений, навыков по татарскому языку и литературе. Умение их применять на практике. Обучение будет успешным, если знания, умения, навыки усваиваются учащимися в строгой последовательности, постепенно в порядке возрастающей трудности и сложности, чтобы школьник поднимался по ступеням.

При изучении любого языка мира человек старается научиться его коммуникативной деятельности. Поэтому работаю над проблемой: «Индивидуальный подход в формировании коммуникативной и языковой компетенции на уроках татарского языка и литературы».

Компетенция включает совокупность взаимосвязанных качеств личности (знаний, умений, навыков, способов деятельности), задаваемых по отношению к определённому кругу предметов и процессов и необходимых для качественной продуктивной деятельности по отношению к ним. Выходит, что компетенция для ученика – это образ его будущего, ориентир для освоения.

Лингвистическая (или языковая) компетенция предполагает владение системой сведений об изучаемом языке по его уровням: фонетика, лексика, состав слова и словообразование, морфология, синтаксис простого и сложного предложения, основы стилистики текста. Учащийся обладает языковой компетенцией, если он имеет представление о системе изучаемого языка и может пользоваться этой системой на практике. На качество языковой компетенции в изучаемом языке влияет не только степень владения им, но и уровень компетенции учащихся в родном языке. Языковая компетенция предполагает знание самого языка, его устройства и функционирования, языковых норм, в том числе орфографических и пунктуационных.

Коммуникация – акт общения, связь между двумя и больше индивидами, основанная на взаимопонимании, сообщение информации одним лицом другому или ряду лиц.

Коммуникативная компетенция включает знание необходимых языков, способов взаимодействия с окружающими людьми и событиями, навыки работы в группе, владение различными социальными ролями в коллективе. Ученик должен уметь представить себя, написать письмо, анкету, заявление, задать вопрос, вести дискуссию.

Ученики должны уметь решать реальные коммуникативные задачи, которые возникают на уроке татарского языка в процессе реального общения «ученик – учитель», «учитель – ученики», «ученики – ученик», «ученик – ученики». Причем решать эти задачи нужно так:

- поздороваться, попрощаться с учителем / одноклассником;
- поблагодарить за урок / за помощь;

- поздравить с праздником;
- попроситься выйти, ответить на вопрос, пересесть;
- попросить ручку;
- уточнить домашнее задание / оценку / содержание грядущей контрольной работы;
- вызваться к доске;
- спросить о разнице между словами, понятиями;
- попросить объяснить правила;
- восхититься / порадоваться оценке, каникулам и т.д.

Именно языковая и коммуникативная компетенции способствуют формированию умений и навыков речевого общения. А для этого необходимо создавать на каждом уроке условия речевого общения. Речевая деятельность формируется во всех её видах – чтении, говорении, письме, аудировании. "Обучать общению, общаясь" – без этих условий нет урока.

Формирование коммуникативных и языковых компетенций.

| Компетенции | Общепредметные компетенции | Татарский язык |
|---|---|---|
| Коммуникативная компетенция | Устный диалог | Задавание вопросов собеседнику.<br>Конструирование ответа на вопрос. |
| | Диалог в письменной форме | Самопрезентация в форме резюме. |
| | Полилог (коллективная дискуссия) | Ролевая форма представления текста произведения. |
| Языковая компетенция | Письмо | Орфографическая и пунктуационная грамотность.<br>Составление документации. |
| | Речь | Орфоэпические нормы. |
| | Чтение | Выразительность, эмоциональность, чёткость. |

Процесс преподавания татарского языка и литературы в школе носит не только образовательный характер, но и направлен на воспитание успешной личности, ориентированной на общечеловеческие и национальные ценности.

На уроках татарского языка и литературы, также на внеклассных мероприятиях мною ведется работа, направленная на всестороннее развитие личности. Подготавливаю подрастающее поколение к жизни, труду, учу детей, любить Родину, уметь трудиться, быть чуткими и заботливыми по отношению к людям и животным.

Я вижу свое место в школе, и как учитель, обязан формировать творческие способности детей, развивать логическое мышление и умение адаптироваться в жизни, и, наконец, я должна быть не просто источником информации, а капитаном, указывающим цель, задающим верный курс, отправляя своих воспитанников на новые открытия.

## Цели и задачи

Основная **цель** моего педагогического опыта: формирование коммуникативной и языковой компетенции учащихся на уроках татарского языка и литературы.

Для достижения поставленной цели мною определены следующие **задачи:**

1. Изучить индивидуальные особенности учащихся .
2. Подобрать индивидуальные формы и методы для повышения мотивации учащихся к изучению татарского языка.
3. Проанализировать результаты внедрения данных форм и методов работы и скорректировать в дальнейшем их эффективное применение.
4. Приобщать учащихся к нравственным ценностям; воспитывать толерантность и чувство принадлежности к своей национальности.

## Условия реализации изменений.

Что надо, чтобы стать интересным детям и увлечь их своим предметом? Прежде всего, нужно до тонкостей разобраться в том, что несешь им, понять их мир, пропустить через себя и найти в ребячьих сердцах все лучшее. Надо любить свою профессию, постоянно работать над повышением своего профессионального уровня. А чтобы быть творческой личностью, необходимо постоянно изучать опыт других и анализировать свои достижения и неудачи. Кроме этого, я должна обладать мастерством изобретателя, талантом артиста, аргументированностью оратора.

Работу с детьми веду на принципах открытости и доверия и предполагаю овладение как коммуникативной, так и межкультурной компетенциями. Учащиеся организовывают свой досуг творчески и учатся сотрудничеству . Поэтому на уроках я часто применяю различные методы и приемы, вовлекаю детей в разнообразную деятельность, чтобы ребенок мог сам добывать знания, наблюдая, делать выводы. Между мною и моими

учениками должна царить атмосфера уважения и взаимопонимания, доверия и сочувствия. На всех уроках стараюсь создать непринужденную обстановку, настроить детей на урок, дать им почувствовать себя его хозяевами, посоветоваться, каким получился урок, что им понравилось, каким они хотят видеть последующие уроки.

**Средства, методы, организационные формы, ресурсы.**

Важнейшей характеристикой коммуникативного обучения для меня является использование связного текста в качестве дидактической единицы учебного материала.

На основе связных текстов мои ученики наблюдают факты языка, усваивают готовые выражения, формируют навыки порождения текста.

Опора на текст помогает мне объединить процессы формирования языковой и коммуникативной компетенции. В учебной деятельности придаю значение общению с учеником. Через общение презентую новую информацию; через общение учащиеся усваивают новый материал.

Главным средством общения на моих уроках является специальная система ситуативных упражнений.

Это:

- коммуникативные целевые установки, требующие от учащихся умения выражать согласие, поддерживать сказанное, присоединиться к сказанному, дополнять собеседника (согласитесь, продолжите сказанное);
- установки, формирующие у учащихся умение выражать свое отношение к явлениям, событиям, фактам (выразите радость, огорчение, сомнение, удивление);
- установки, требующие уточнения, выяснения предмета разговора (поправьте меня, объясните, возразите мне).

При этом внимание учащихся направляю не только на содержание высказывания, но и на то, что соотносится с их жизненным опытом, с окружающей их действительностью. Все это стимулирует учеников не только на речевую, но и на познавательную деятельность.

Речевая ситуация побуждает учащихся к высказыванию, вызывает потребность в общении.

Преподавание татарского языка в русскоязычных классах с использованием технологии коммуникативно-развивающего обучения по учебникам Р.К.Сәгъдиева, Г.И.Хәйруллина Татар теле, Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина Татар әдәбияты даёт возможность повышать практическую направленность уроков, развивать разговорную речь учащихся.

В последние годы все чаще поднимается вопрос о применении новых технологий в средней школе. Это не только технические средства, но и методы преподавания, новый

подход к процессу обучения. Основной целью обучения татарскому языку как иностранному, является формирование, развитие коммуникативной деятельности школьников и обучение практическому овладению языком.

В своей практике я использую современные технологии: личностно-ориентированные технологии, компьютерные технологии, игровые технологии, здоровьесберегающие технологии. Это повышает продуктивность обучения, вызывает стойкую мотивацию к изучению татарского языка и литературы.

Индивидуальный подход к школьнику предполагает создание положительной мотивации к изучению татарского языка и литературы. В этой связи учитель должен знать и учитывать природные возможности ученика, его интересы, так как учащиеся имеют разные способности. Некоторым детям нужно уделять больше внимания, постоянно контролируя их действия, другим для получения желаемого результата достаточно объяснить один раз. Например, рассказ, объяснение, описание; толкование понятий, беседа; демонстрация и иллюстрация; самостоятельное наблюдение; упражнения (устные и письменные); объяснение фактов и явлений природы, труда, общественной жизни; творческие письменные работы, аудирование, диалоги; разные игры и другие. Провожу различные типы уроков: урок-аукцион, урок-игра, урок-беседа, урок-экскурсия, урок-путешествие, урок-выставка, урок-викторина и т.д.

Например, уроки-аукционы наиболее эффективны при прохождении тем: «Ашамлыклар кибетендә», «Киемнәр кибетендә», «Ашханадә». На аукционе продаются предметы, относящиеся к той или иной теме. В качестве платы за товары можно считать постановку вопросов, перевод слов, составление словосочетаний и предложений с ними, описание свойств, качеств, размера предметов, составление реплик, диалогов, рассказа. Такие занятия вызывают у детей большой интерес и повышают их активность на уроках.

Обучение будет успешным, если знания и умения усваиваются учащимися в строгой последовательности, постепенно, в порядке возрастающей трудности и сложности с тем, чтобы школьник поднимался по ступеням. Каждый новый урок базируется на предыдущих. Своеобразие педагогического сотворчества состоит в том, что организуется единство деятельной и эмоциональной основы учебного процесса, которое осуществляется в совместных действиях учебных, познавательных, поисковых и других, а учитель выступает как консультант – наставник.

Сегодня можно с уверенностью сказать, что компьютер как основное техническое средство, которое активно внедряется во все сферы преподавания татарского языка как иностранного, меняя свои функции в зависимости от целей, задач, этапа обучения и др.

Эффективность применения информационных технологий на уроках татарского языка не подлежит сомнению. В числе преимуществ их использования в качестве средств обучения можно назвать субъектную ориентацию, гибкость и вариативность.

Я использую информационно-коммуникативные технологии обучения, как на уроках, так и во внеурочной работе. Для этого я применяю текстовый редактор, создаю презентации по изучающим темам, пользуюсь услугами Интернет, использую различные тесты на бумажных носителях и тестовые задания на компьютере для оценки знаний учеников. Компьютер помогает повысить уровень преподавания, обеспечивая наглядность, контроль, большой объем информации, являясь стимулом в обучении. Освоение компьютерных технологий позволяет реально индивидуализировать учебный процесс, усилить положительную мотивацию обучения, активизировать познавательную деятельность, усилить творческую составляющую работы, как ученика, так и учителя.

В старших классах ребята с большим интересом занимаются проектной деятельностью по теме "Татарские (русские) обрядовые праздники". Класс делится на группы. На первом уроке даю общую информацию про народные обычаи и праздники. Каждая группа выбирает себе один праздник и начинает собирать материал. Потом под моим руководством продумывают, как сделать презентацию праздника. Две группы сделали презентацию в программе Microsoft Power Point.

Работая в группах над этими проектами, дети изучают этнографию, культуру своего народа, археологию, фольклор, впитывая и погружаясь в народное творчество. В дальнейшем, это способствует развитию чувства национальной гордости за свой народ.

Опыт показывает, что в процессе обучения татарскому языку как иностранному, компьютер может выполнять функции, которые должны обеспечивать формирование языковой или коммуникативной компетентности:

1. осуществлять обучение и тестирование в режиме диалога;
2. моделировать реальные речевые ситуации с помощью графики, мультипликации и видео, создавать эффект контакта с языковой средой;
3. наглядно представляя речевую ситуацию, использовать её как стимул, опору в процессе учебного диалога;
4. обеспечивать общение на изучаемом языке с помощью компьютерных линий связи.

Неоспорима польза электронных учебных изданий. Например, на уроках использую диски (Татар теленнән презентацияләр, авторы Р.К.Сәгъдиева, Д.Х.Хөснетдинов), для 5-9 классов диски (Татар әдәбияты, авторы Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина).

При изучении нового материала применяю методы наблюдения и анализа, которые дают ученику ощущение самостоятельности открытия.

В процессе предметно-умственной деятельности учащиеся приходят к усвоению и пониманию теоретического материала, к открытию общего и выделению частного.

С целью мотивации к изучению предмета использую игровые моменты. Это способствует активизации учебной деятельности. Учащиеся активно работают, развиваются. Они высказывают свои мнения смело, используют в речи фразы: «По-моему», «Я считаю», «Я думаю», «По моему мнению» и т.д.

Развитие интереса к предмету глубоко связано и с развитием индивидуальных способностей учащихся. В классе есть одаренные дети, которые стремятся получить высокий процент ЗУН, имея высокий потенциал к обучению. Наряду с ними есть и слабоуспевающие учащиеся. Учитывая эти особенности, широко применяю технологию уровневого обучения.

Суть технологии сводится к следующему: для ученика отводится то время, которое соответствует его личным способностям и возможностям, что позволяет ему усвоить учебную программу. При этом учебные группы в классах, где я веду уроки татарского языка, формируются по темпу (высокий, средний, низкий) обучения; в процессе каждого обеспечивается переход обучающихся с одного уровня на другой. Я становлюсь как бы дирижером оркестра, где у каждого ученика своя партия.

Такое разделение учащихся облегчает их обучение. Но индивидуальные задания на своих уроках не превращаю в средство дискриминации отдельных учеников, наоборот, они способствуют укреплению веры учащихся в свои силы, в возможность преодолеть трудности. Поэтому в моих классах нет неуспевающих. Индивидуализируя задания, имею в виду не только слабых учеников. Ведь в каждом классе есть учащиеся, которые быстрее и успешнее усваивают материал по данному предмету. Я не ограничиваю их работу выполнением лишь заданий среднего уровня, а включаю систему индивидуальных заданий повышенной трудности, олимпиадных заданий, которые способствуют дальнейшему развитию познавательных интересов.

Между тем даже трудный материал запомнится без особого труда, если при его объяснении на уроке использовать принцип занимательности и разнообразные игровые моменты, вызывающие положительную мотивацию к изучению татарского языка. Различные опорные схемы, таблицы, видеофильмы, занимательные истории, рассказы и сказки благотворно влияют на отношение учащихся к татарскому языку как учебному предмету.

В своей работе я создаю условия для гармоничного развития личности. При проведении уроков учитываю психологические особенности учащихся. На уроках провожу физкультминутки, зарядки, подвижные и развивающие игры. Проведение подвижных игр способствует укреплению здоровья детей. Интересны рифмовки песен с движениями. Четверостишия о животных, природе, о детях легко запоминаются и делают физкультпаузы увлекательными и полезными. Тексты, звучащие на физкультминутках, сопровождаются движением рук и туловища.

Уроки литературы помогают воспитывать. Обращаю внимание на уроках выразительному чтению, правильному и полному ответу учащихся. Учащиеся переводят прочитанный текст, выражают свою оценку, учатся применять готовые выражения из текста в своем ответе.

Большое значение придаю выразительному чтению учащихся, работе учащихся по группам, составлению диалогов - воспитываю в них дружелюбие, взаимопомощь.

Внеурочная работа по татарскому языку и литературе стимулирует мотивацию к учению; расширяет сферы применения татарского языка в качестве средства социального взаимодействия; развивает чувство патриотизма, толерантности у учащихся.

В творческой лаборатории имею дифференцированные задания в форме компьютерных тестов и дидактический материал по темам и классам. А также имеются методические пособия, сборники упражнений и контрольных диктантов, программы по татарскому языку и литературе; словари, газеты-журналы, фонотека с записями произведений татарских писателей и поэтов, аудио-видео кассеты, диски с музыкальными произведениями татарских композиторов и детских песен, компьютерные диски с обучающими программами по татарскому языку, мультфильмы, творческие работы учащихся и т.д.

Дети с увлечением посещают уроки татарского языка, активно участвуют в совместной деятельности по изучению истории родного края, культуры татарского народа и традиций. С родителями налажено тесное сотрудничество и взаимопонимание.

Мои ученики чувствуют мою любовь и на уроках всегда радуют меня знаниями. Могу уверенно сказать, что мои ученики любят татарский язык.

Главное, найти индивидуальный подход к каждому, относиться к детям с пониманием и любовью.

*Хакимова Рамзия Рифовна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Безнең гаилә традицияләре**

Гаилә -нәрсә ул? Гаилә-ул йорт, әти һәм әни, якын туганнар. Монда уртак кайгылар да бергә, шатлыклар да бергә, эшләр дә бергә-күмәк эшләнә. Бу мәһәббәт һәм бәхет, бере-береңне аңлау, ярдәм итү.

Гаиләдә иң мөһиме нәрсә?

Бу сорауга төгәл җавап бирү авыр. Мәһәббәт? Үзара аңлашу? Кайгырту һәм тормышта катнашу? Бәлки, гаилә хоббиы?

Мавыгу-безнең сәләтләребезне ачу, яки шәхесебезне күрсәтү, гадәти әйберләргә үзенчәлек өстәү. Бергәләп гаилә белән нәрсә дә булса эшләү, шөгыльләнү гаиләнең барлык әгъзаларын бер максат һәм уртак кызыксыну белән берләштерә, һәрберебезнең яшерен сәләтләрен күрсәтә.

Бергәләп шөгыльләнү ата-аналарга балаларына тормышта кирәкле сыйфатларны сеңдерергә һәм файдалы сыйфатларны үзләштерергә ярдәм итә.

Әйтик, әни яки әти пешерергә бик яраталар. Башка илләрдән тәлинкәләр, стаканнар, сувенирлар җыялар. Ә сәяхәт сөючеләр гаиләләре белән диңгез янында, урманда, паркта вакыт үткәрү мөмкинлегеннән файдаланалар.Алар балык торалар, учак янында утыралар. Һәм шул рәвешле табигатькә мәхәбәт тә тәрбиялиләр

Гаиләнең искиткеч мавыгуы спорт булырга мөмкин. Ата –аналар балалары белән бергә хоккейга, бассейнга, спорт залына, тренажер залына, ял базаларына бара алалар, бергә фотога төшә алалар. Ә өйгә кайткач, тагын бер тапкыр түгәрәк өстәл артында бәхетле секундларны, бу йөрүдән алагн шатлыклы минутларны искә төшерәләр.

Ә иҗади мавыгу балаларны шулкадәр кызыксындыра,алар үәтта тегү,чигү бәйләү ,конструкторлар белән дә мавыгып китәләр. Әниләре белән беррәттән утырып чигүгә дә тотыналар. Ә этиләре уллары белән бергә ашарга да әзерли башларга мөмкиннәр. Хәтта машинаны бергәләп юу да малайлар өчен чисталык һәм тырышлык үрнәге булачак.

Менә минем әнием юри генә өстәлдә төймәләр,җепләр калдыра иде. Ә әти балык тотарга җәтмә бәйли иде. Мин башта бу җепләр белән уйный идем. Аннары әкеренләп әниемнең эшен карый башладым.Элек әбиләр кич утырырга йөриләр иде. Бер көнне

берсендә,икенче көнне икенчесендә кич утырып бәйлиләр иде,самавардан чәй эчәләр, матур,озын көйләр сузалар иде. Соңыннан мин дә бәйли,тегә,чигә башладым. Инде 3 нче сыйныфта йон оекбашны бер үзем утырып бәйли идем инде. Әбиләр шаккатып карап торалар иде. Шулай ук 3 нче сыйныфта зур баянны күтәреп, Актанышның зур сәхнәсендә “Көзләр җитә диеп моңсуланма” җырын уйнап җырладым. Әтинең балык тотарга ау бәйләгәнен дә күргәнем бар иде. Кечкенә чакта бәйләп карамасам да, 40 яшемдә ау бәйләп карадым...һәм килеп чыкты бит!

Гаилә традицияләрен мин дә саклыйм. Минем әбием һәм әнием кебек, кайвакыт мулине сатып алам, матур мендәр тышлары алам, мозаикалар сатып алам, шулай итеп кызымның игътибарын җәлеп итәм. Ул да миннән күреп, баянда бер генә булса да көй уйный белә, шулай ук курайда уйный белә. Минем белән утыра, кайвакыт крючок белән, кайвакыт энәләр белән бәйли, кайвакыт чигә. Икебез сөлгеләр чигәбез.

Без барыбыз да киптергеч сыман. Якындагы нәрсәләрне үзебезгә сеңдерәбез, үзләштерәбез. Шуңа күрә без бөтен җирдә үрнәк булырга тиеш! Бездән үрнәк алсыннар.

Мин 2023 елда «Семьедение» буенча ТИСБИ университетының югары белем бирү учреждениесендә читтән торып курслар үттем, Анда безнең фәнни җитәкчебез Карцева Лидия Валерьевна иде!

Карцева Лидия Валерьевна - «Россия гаиләсе» НОКның Татарстан төбәк бүлеге җитәкчесе, социология фәннәре докторы, профессор.



Без атна саен онлайн конференция тыңладык, сорауларга җавап бирдек, дәресләрнең конспектларын яздык. 25,26 гыйнварда безнең МБОУ СОШ 10 мәктәбе базасында «Гаилә белеме»курсы буенча конференция узды. Без класс сәгатьләре бирдек, тәҗрибәләребез белән уртаклаштык.

Гаиләкыйммәтләре-ул кешенең гаилә коруы, аның төп максаты, гаилә яшәячәге һәм артачагы. Бу мәхәббәт һәм үзара аңлашу, ышаныч һәм якынлык, җәмгыять һәм шәхес хисе, хөрмәт, шәхес һәм рухи үсеш, бәхетле балалар, икътисади тотрыклылык һәм куркынычсызлык, һәм бу көнкүреш һәм торак. Без гаиләне сакларга, гаиләнең кадерен белергә тиеш!

*Халикова Нурсина Далифовна, Фатхуллина Гузял Фагимовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## Индивидуаль якын килеп белем бирү

Һәрбер җәмгыятькә сәләтле кешеләр кирәк.Җәмгыятьнең бурычы булып аның барлык вәкилләренең сәләтләрен белү һәм үстерү тора. Кызганычка каршы, һәр кеше дә үз сәләтләрен тормышка ашыра алмый. Күп нәрсә гаиләгә дә, мәктәпкә дә бәйле. Нәкъ менә мәктәптә фән һәм техниканың төрле өлкәләре белән кызыксынучыларны ачыклау, аларның максат - планнарын тормышка ашырырга ярдәм итү, укучыларны фәндә, тормышта эзләнү юлына чыгару, үз сәләтләрен тулырак ачуда ярдәм итү мөһим.

Педагог буларак, шундый нәтиҗәгә килдек: бала өчен укыту процессында уңайлы шартларның берсен тәэмин итүче ышанычлы һәм эффектив форма- индивидуаль якын килеп белем бирү. Чөнки бу технология укучыларның шәхси үзенчәлекләрен, аларның социаль һәм академик тәҗрибәләрен, шулай ук интелектуаль үсешләрен, танып-белү

кызыксынуларын, социаль дәрәҗәләрен, тормыш-көнкүреш режимнарын исәптә тотып укыту процессын оештыруны күздә тоткан дидактик принципларның берсе ул.

Индивидуаль якын килеп эшләүнең **максаты:** укучының белем дәрәҗәсен күтәрү, җитәрлек дәрәҗәдә үзләштерелмәгән уку күнекмәләрен формалаштыру буенча индивидуаль эш алып бару, уку процессын шәхеснең индивидуаль үзенчәлекләрен, ягъни аның мөмкинлек һәм сәләт дәрәҗәсен исәпкә алып оештыру.

**Төп бурычлары:** укучының шәхеслеген күрү һәм аны саклап калу, балага үз көченә ышанырга булышу, аның максималь үсешен тәэмин итү, һәр укучыны эшкә җәлеп итү, «көчсезләргә» ярдәм итү, «көчлеләрнең» сәләтләрен үстерү.

Индивидуаль якын килү-дифференциаль якын килүнең конкретлаштырылуы.

Ул һәр баланың индивидуаль үсешүзенчәлекләрен исәпкә алып, уңайлы уку шартлары булдыруга юнәлдерелгән.

Бүген без, укытучылар, укучыларны укыту һәм тәрбияләүнең яңа, нәтиҗәлерәк алымнарын, чараларын һәм формаларын эзләүдә. Уку процессының уңышлы булуын күп факторларга бәйле дип саныйбыз, алар арасында баланың сәләтләренә һәм мөмкинлекләренә карап өйрәнү дә зур роль уйный.

Хәзерге укытучы укучыларның шәхси сәләтләрен, аларның тирән, оригиналь, ирекле һәм эмоциональ фикерләү сәләтен ачыкларга омтыла.

Һәм мәктәптә без ел саен мондый максатка ирешүнең чын юлы уку процессын оештыруда индивидуаль-дифференциаль якын килү булуына ныграк инанабыз.

Укучыларга индивидуаль якын килү принцибы психологик - гуманистик принцип булып тора. Индивидуаль алым, аларның уңышларына, уңышсызлыкларына карамастан, барлык укучыларга карата башкарылырга тиеш. Укучының шәхси үзенчәлекләрен белеп кенә, аның һәрьяклап формалашуына ирешергә мөмкин.

Безнең педагогик эшчәнлегебездә индивидуаль -дифференциаль алым эш принципларыбызның берсе булып тора, анны практикада зур кызыксыну белән кулланабыз, чөнки нәкъ менә бу юнәлеш укучыларның психологик һәм физик сәламәтлеген сакларга ярдәм итә.

Бу системаны кулану һәр укучының психологик үзенчәлекләрен белүне күздә тота. Укучыларны яхшы белү, аларга үз шәхесләрен, иҗатларын күрсәтергә, аларны курку хисеннән коткарырга һәм үз көчләренә ышаныч уятырга мөмкинлек бирә.

**Укучыларның үзенчәлекләре һәм алар белән эшләү бурычлары**

1)югары уңышларга ирешкән, белеем дәрәҗәсе җитәрлек, танып –белү активлыгы югары дәрәҗәдә булган укучылар.

• Укытуның максаты – бу төркем балаларында тырышлык һәм үз эшләренең нәтиҗәләренә югары таләпчәнлек тәрбияләү.

2) уку мөмкинлекләре урта булган укучылар. Бу төркем белән эшләгәндә төп игътибарны аларның танып – белү активлыгын үстерүгә, проблемалы ситуацияләрне хәл итүдә катнашуга, үз-үзеңне танып белү мөмкинлекләренә ышаныч тәрбияләүгә бирергә кирәк.

• Укытуның максаты - укучыларның сәләтләрен үстерү, мөстәкыйльлек, үз көчләренә ышаныч тәрбияләү.

3)түбән сәләтле булу нәтиҗәсендә уңышлары түбән булган укучылар.

• Укуның максаты - аерым игътибар бирү, материалны үзләштерүдә ярдәм итү, берникадәр вакыт дәрестә алар белән генә эшләү.

*Халиуллина Альфия Ахметовна, Нуртдинова Гульсиня Асхатовна, Татарстан Республикасы Түбән Кама иуниципаль районы “Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе” муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенең югары категорияле туган тел укытучылары*

## Халык авыз иҗатын өйрәнү юлында

(Чыгыш ясаучы укытучы аңлатма бирә. Таныштыру. Чыгышның темасы, максаты.). Фольклор сүзе –инглизчәдән, (халык хикмәте) XIX йөз ахырында таралып, төрле илләрдә киң кулланышка кергән халыкара атама.

Татар фән дөньясында да “фольклор” атамасы узган йөзнең 20 нче елларында гамәлгә керә һәм аңа кадәрге “халык мосаннәфаты” (гарәпчәдән, “әсәрләре”) дигән төшенчәләр урынына йөри башлый. “Фольклор” терминына синоним булып хәзерге вакытта янә “халык әдәбияты” , “халык сүз сәнгате”, “халыкның поэтик иҗаты (тел)”, “халык авыз (тел) иҗаты” дигән атамалар кулланыла.

Сүз сәнгате буларак фольклор халыкның электән чыгарылып килгән традицион һәм хәзерге авыз-теле иҗатын иңләп ала,димәк, чәчмә –прозаик әсәрләрне дә, шулай ук шигъри текстларны да үз эченә берләштерә. Аның язма әдәбияттан аермасы, үзенә хас үзенчәлекләре, асыл сыйфатлары бар.

Ачыктан-ачык сизелмәсә дә, халык авыз -теле иҗаты даими рәвештә иҗади бәйләнештә тора торган тагын бер сәнгать төре бар. Анысы инде-язма әдәбият. Үзенә туу һәм үсеп китү өчен беренче җирлек хезмәтен үтәгән халык иҗаты белән язма әдәбият элек-

электән үк инде “кан алмашынып” яшәгән һәм халыкчанлыкка , миллилеккә, тел байлыгына, образлылыкка ирешүдә фольклор казанышларын киң файдаланган. Әлеге процесс, әлбәттә, татар әдәбиятына да хас булган һәм халык иҗатында эшләнгән мифологик һәм традицион символик образларны, мотивларны, сюжетларны, прогрессив идеяләрне үзләштерү һәм ары таба үстерү рәвешендә барган. Халыкның сурәте фикерләвенә хас алымнарны үзләштерү әдәбиятының образлы егәрлеген һәм эмоциональ –эстетик тәэсир көчен бермә-бер куәтләндерүгә , традиция белән яңачалыкның гармоник берлегенә нигезләнгән әдәби әсәрләр тууга китергән. Моңа мисал итеп Г. Тукайның “Шүрәле”, “Су анасы”, “Печән базары”, “Яхуд Яңа кисекбаш” , Х.Такташның “Җир уллары трагедиясенең”, М.Фәйзинең “Галиябану”, Н. Исәнбәтнең “Хуҗа Насретдин”, М.Җәлилнең “Ана бәйрәме”, “Сандугач һәм чишмә”, Г.Бәшировның “Туган ягым –яшел бишек”, Г.Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” кебек классик әсәрләрен телгә алу да җитә.

Билгеле, ике арадагы бәйләнеш ике яклы булган, ягъни язма әдәбият үзе дә халык иҗатында шактый гына йогынты ясаган. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәрендәге образларның халык җырларына үтеп керүе, китабый “Тахир белән Зөхрә” дастанының сөйләмә вариантлары да барлыкка килүе, Г.Кандалый тарафыннан иҗат ителгән бик күп шигъри юлларның, киң таралып, халык лирикасы белән үрелүе яки шулар үрнәгендә яңа текстлар чыгарылуы, йә булмаса заманында профессиональ шагыйрьләр язган “Минзәлә”, “Бөдрә тал”, (Ә.Ерикәй), “Таң атканда” (С.Хәким), “Кошлар кебек”(Ф.Бурнаш), “Аккош” (Ә.Фәйзи) кебек уннарча җыр текстларының , халыклашып, өстәмәләр һәм яңа строфаларбелән тулылануы менә шуны раслап тора.

Фольклор белән әдәбиятның үзара бәйләнеше аеруча көчле булып, ике арада торучы аерым жанрларда гәүдәләнә. Андый жанр икәү-бәетләр һәм мөнәҗәтләр. Ошбу әсәрләр әдәбият белән халык иҗаты традицияләренә бердәй дәрәҗәдә таяналар һәм язма рәвештә, телдән дә иҗат ителәләр.

Тел-авыз иҗатының күп гасырларга сузылган тарихы бар. Ул үзенең тамырлары белән бик ерак заманнарга –борынгы ташгасыр чорына ук барып тоташа.

Халык әдәбиятын җыю, классификацияләү, әдәби эшкәртү белән әдәбиятыбызга зур өлеш керткән шәхес –Нәкый исәнбәт. Галимнең “Татар мәкальләре” , “Татар табышмаклары” исемле китаплары, 1958 елда “Совет әдәбияты” журналының беренче һәм унберенче саннарында басылган “Татар мәкалҗләрененңшигүри үлчәмлеге” һәм “Татар мәкальләренең шигъри бер үзенчәлеге –рифмалары турында” дигән мәкаләләре татар авыз иҗаты әдәбиятын өйрәнү юлында мзур әһәмияткә ия булган гыйльми хезмәтләр булып санала. Шулай ук махсус балалар өчен дип әдәби эшкәртелеп чыгарылган “Ни өчен ни булган яки утыз ялган” исемле китапта яшь буынны халкыбыз иҗатының кыйммәтле

гәүһәрләре белән таныштыру юлында мактаулы хезмәт диясе килә. Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, Н.Исәнбәт нәни дусларын да онытмый, аның махсус балалар өчен язылган байтак шигырьләреннән башка “Елан патшасы”, “Аю белән төлке” , “Мырауҗан ага” кебек шигырь белән язылган кызыклы әкиятләре дә бар.

Нәкый Исәнбәтнең әдәбият теориясенә караган мәкаләләре арасында “Совет әдәбияты” нурналының 1952 елгы 6 нчы номерында басылган “Драма әсәрләрендә конфликт, уңай һәм тискәре образ мәсьәләләре” исемле мәкаләсе конфликтсызлык “теориясенең” драматургиягә китергән изарарлы йогынтысына анализ ясау һәм драматургия өлкәсендәге хаталарны төзәтү юлында конкрет чаралар күрсәтү ягыннан зур әһәмияткә ия. Тагын “Татар теленең аңлатмалы сүзлеген” төзү өстендә дистәләрчә еллар буена гыйлҗми эш алып баруын да әйтми булмый.Шуның өстендә күренекле рус язучылары, дөнья классиклары әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү белән дә әдәбиятыбызны баету юлында уңышлы хезмәт итә.

Фидакарь галимнең киң колачлы иҗатына үз чорында югары бәя бирелә: ул 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уңае белән Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә һәм Ленин орденына лаек була.

Нәкый ага Исәнбәтнең гаять олы хезмәт җимеше булган мәкальләре җыентыгында “Хөрмәт сөйсәң, хезмәт сөй! ” дигән мәкаль дә бар. Ул үз гомере буе шушы мәкальнең эчтәлегенә туры килерлек итеп эшли һәм яши.

Әгәр без аның зур мирасының затлылыгы турында да сүз алып барабыз икән, бу, барыннан да элек, әлеге иҗатның халыктагы күңел җәүһәрләре –фольклоры, мифологиясе белән тыгыз бәйләнештә булуы белән аңлатыла. Н.Исәнбәт әлеге хезмәтне гомере буе җыйный. Ул бу эшкә унбер-унике яшендә туган авылы Малаязда керешә. Башкортстан, Татарстаннан тыш, Бараба, Тара, Ишелетамак, Тубыл якларында йөри. Ул туплаган бихисап бәетләр, җырлар, такмак-таймазалар, табышмаклар, мәзәкләр, мәкаль-әйтемнәр халкыбызга билгеле бер системага салынып, фәнни аңлатмалар белән баетылып кире кайтарылалар. Бу эш 1928 елда “Әйдә җырлыйк!” дигән җыентык белән башланган була. Шуннан соң дистәләрчә тупланмалар дөнья күрә. Өч томлык мәкальләр җынтыгы, татар әдәбияты һәм фәнендә генә түгел, гомумән, төрки халыкларда тиңе булмаган олы хезмәт иде. Әдәбиятчы -галим бу эштә бер төп принциптан тайпылмады: фольклор ңанрларының тарихын халыкның ерак һәм якын үткәннәре, аның язмышы белән бәйләнештә үреп карады. Нәкъ менә шул аңа фәннең төрле тармакларында кызыклы ачышларга юлыгу мөмкинлеген тудырды.

Нәкый Исәнбәт-шагыйрь дә, драматург та, фольклорчы да, тел белгече дә, тәрҗемәче дә, тарихчы да, публицис та, гомумән, аның эшчәнлегенең юнәлешләрен билгеләп бетерүе

дә шактый кыен.  Шунысы гаҗәп: кайсы өлкәдә генә эшләмәсен, ул аларның һәрберсендә олы сүз әйтә алды, шул тармакларның әйдәүчесенә әйләнде.

**Йомгаклау сүзе. Күрсәтмәлелек.**

**Әдәбият:**


5. Галиуллин Т. Утызынчы еллар әдәбияты/ Т.Галиуллин / Мәгариф.1994ел.
6. Ганиева Р. Урта гасыр татар әдәбияты/ Р. Ганиева / Мәгариф 1997/ 2015
7. Мусин Ф. Милли яңарышның алгы сафында: татар әдәбияты тарихы/ 2005/2016
8. Исәнбәт Н. Мәкальләребез турында: фольклор/Мәгариф/Казан утлары/1999/2004



*Хасанова Миляуша Кашбетдиновна, Газыймова Гузель Рафисовна, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мөслим гимназиясе» МББУ (мәктәп-электрон белем бирүдә компетенция үзәге), башлангыч сыйныф укытучылары*


## Укучыларда укый белү һәм укыганны аңлау грамоталылыгын формулаштыру ысуллары (читательская грамотность)

Кереш өлеш

Укый белү һәм укыганны аңлау грамоталылыгы (читательская грамотность) – бу кешенең укыган материалны аңлый һәм язма текстларны куллана белү осталыгы. Кеше укыганны аңлап кына калмый, аның эчтәлегеннән чыгып, уйлана белергә, аны тормышта булган төрле ситуацияләрдә куллана да белергә тиеш. Бөек педагог К.Д.Ушинский әйткәнчә: “Укый белү ул – “”үле” хәрефләрдән “тере” мәгънә тудыру”.

Укыганны аңлый белү грамоталылыгы югары дәрәҗәдә булган укучының түбәндәге сыйфатлары формулашкан була:

- Тиешле информацияне табу һәм кирәкле нәтиҗә ясый белү:
- Автор тарафыннан әйтелергә тиешле, ләкин туп-туры әйтелмәгән

фикерне, ачып бирү.

**Максат:**Укучыларда укый белү һәм укыганны аңлау грамоталылыгын формулаштыру ысуллары өйрәнү, тәҗрибә уртаклашу

**Өйрәнү материалы:** шигырьләр, әсәрләр, әкиятләр.

Югарыда әйтелгән укый белү һәм укыганны аңлау грамоталылыгы булдыру өчен, безнең алда бик зур бурыч: укыган материалны аңлый һәм язма текстларны куллана белүне өйрәтү тора һәм бу безнең белем бирү системасының актуаль проблемасы.

**Төп өлеш.**

**1.1. Сөйләм проблемасы каян чыга?**

Бүген әти-әниләрнең дә, бигрәк тә укытучыларның, зур проблемасы – ул балаларны замана гаджетларыннан аерып ала алмау. Чөнки, зур яшьтәге укучылар гына түгел, хәтта сөйләшә белмәүче бишектәге сабыйлар да, телефонга мөкиббән китә. Галимнәр исәпләве буенча, 2 яшьлек бала 50 дән алып, 200 гә кадәр сүз белергә тиеш булса, 7 яшьлекләр 4000 гә якын сүзне әйтә белергә һәм аңларга тиеш. Ә бүген безнең аралашу дигән төшенчә, җәмгыятьтән бөтенләй юкка чыгып барадыр кебек тоела миңа. Бер мисал: моннан 30 ел элек якыннарыбызны туган көннәре, бәйрәмнәр белән, почта бүлекчәләреннән алынган “СССР открыткаларына” матурлап котлаулар язып, котлый идек, бер-беребез белән хат алыша идек. Күрше-тирә, якын туганнарга йөрешеп, кич утырулар оештырыла иде.Кешенең сөйләм теле дә, язма теле дә камил үсә иде. 90 нчы елларда бу аралашу чарасы онытылды, шулай да китапханәләрдән китап алып укулар үз сыйфатын югалтмады. 2000 нче елларда мәктәпләрдә беренче компьютерлар барлыкка килде, без тырыша-тырыша клавиатурада хәреф җыярга өйрәндек. Һәм кеше тәүлегенең 5-6 сәгатен компьютер алдында уздыра башлады. Аралашу, бер-береңнең хәлен белү, бәйрәмнәр белән котлау өчен кесә телефоннары пәйдә булды. Ләкин, елдан ел кешеләр үз эчләренә бикләнә башладылар, күп вакытларын телефон, компьютер алдында уздыру “мода”га кереп китте. 2016 елларда барлыкка килгән “WhatsApp” халыкны бөтенләй телсез калдырды. Кешеләр язышып кына аралаша башлады. Язу – грамоталылыкны үстерә диелсә дә, бу “язышу” киресенчә грамоталыкка сикереп чыга алмаслык кыя-таш өйде. Чөнки күпләр телефоннарына татар клавиатурасы йөкләмичә генә язып, телебезгә хас ң, җ, һ, ө, ә, ү, хәрефләре кергән сүзләрнең дөрес язу кагыйдәләрен үтәмиләр. “Сәлам” диясе урынга “сэлэм”, “һәм” урынына “хэм” кебек бик тупас хаталар ясала, нәтиҗәдә кеше бу гадәткә өйрәнеп, калган очракта да хата белән сөйләшә һәм хата белән яза башлады. Шулай ук “WhatsApp”та язышуда сүзләрне кыскарту очраклары еш күзәтелә: “хәзер” дип язып тормый, “хэ” генә ди, “ярар” дими “яра”. Мондый очраклар санап бетергесез.

Безнең киләчәк – балалар. Ә балаларыбызда укый белү һәм укыганны аңлау грамоталылыгы бөтенләй юк дәрәҗәсендә, чөнки җәмгыять, бүгенге заман торышы балаларда “сукырларча” шуны тәрбияли. Мисал өчен , без кечкенә чакта дәрестә әсәрнең 1 нче бүлеген укысак, ахыры ничек бетәр икән дип, өйгә бирелмәсә дә, яшерә-яшерә укый

идек. Ә бүген балалар телефон уеннарын, затсыз персонажлар белән тулган мультфильмнарны кулайрак күрәләр.

Югарыда санап кителгәннәрне исәптә тотып, мин “җиң сызганып” эшкә тотындым. Дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда, тәрбия сәгатьләрендә укучыларның укый белү һәм укыганны аңлау грамоталылыгын булдыру өстендә эшли башладым. Үзем кулланган ысулларның берничәсен сезгә дә тәкъдим итәм.

**1.2. Укучыларда укый белү һәм укыганны аңлау грамоталылыгын формулаштыру ысуллары (читательская грамотность)**

**“Син ышанасыңмы?” ысулы.**

Бу ысулны һәр дәреснең, чараның мотивация өлешендә кулланырга була. Укылачак әсәр эченнән булырдай һәм булмастай вакыйгаларны сайлап аласың да, укучыларны гаҗәпләндерерлек “Син ышанасыңмы шуңа? - дип сорау бирәсең. Укучылар төрле фикерләр белән бәхәскә керә. Берничә фикер тыңлангач, укытучы укучыларны әсәр белән таныштыра башлый. Дәрес ахырында, “бәхәс” дәвам итә һәм нәтиҗә ясала. Бу ысул, баларны уйланырга, хыялланырга өйрәтә, шул ук вакытта бер-береңнең фикерен тыңларга өйрәтә.

Мисал 1. Айдар Хәлимнең “Самавырга көч керде...” [7, б. 32] шигыре.

- Укучылар, самавыр төчкерәме? Сез шуңа ышанасызмы?

Мисал 2. Бари Рәхмәт, “Ничек өйрәнергә? [4, б.38].

- Укучылар, бик-бик зур пычак алып, җир шарын икегә ярып, эчен карап буламы? Сез моңа ышанасызмы?

**“Мозаика” ысулы (текстны реконструкцияләү).**

Бу ысул белән группаларда 3-5 минут эшләргә була. Әлбәттә, укытучының ярдәме кирәк. Таныш булмаган әсәр алынган очракта бу ысул, бигрәк тә кызык килеп чыга, чөнки өлешләп бирелгән текстны укучылар җыярга тиеш булалар. Бу ысул татар теле дәресләрендә бер-берсенә бәйләнешле җөмләләрне берләштерү биреме белән эшләтелә. Ә менә әдәби уку дәресләрендә “язучының” әсәрен “үзеңчә” җыю, бөтенләй икенче нәрсә. Зур күләмле әсәрләр алынмый, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу - бик мөһим мәсьәлә.

**1 нче сыйныфлар өчен гадирәк ысул.** Укытучы әсәр белән таныштыра һәм укучылар әзер сюжетлы рәсемнәрне тәртип белән урнаштырып куялар.

Мисал 1. Мәсәлән, Абдулла Алишның “Куян кызы” әкияте өстендә эш.

2 нче сыйныфлар өчен текстны өлешләп җыюны тәкъдим итәргә мөмкин. Хәтта, укучыларга логик фикерләүләрен үстерү өчен, әсәрнең өлешләрен Салават күпере төсендәге кәгазьләргә беркетергә була.

Мисал 1. “Батыр этәч” [2, б.22], татар халык әкияте**.**

3-4 нче сыйныфлар өчен әзер план буенча эшләүне тәкъдим итәргә мөмкин. Укучыларга әзер план таратыла, шул план буенча өлешләргә таркатылган әсәрне укучылар җыярга тиеш.

Мисал 1. Рафис Гыйззатуллин, “Язгы моң”, [6, б.17] .

**“Нечкә һәм юан сораулар” ысулы.**

Бу ысул әсәр укылгач кулланыла. Биредә укучылар әсәр эчтәлегеннән чыгып, бер-берсенә сораулар бирәләр. Бу ысул әсәр эчтәлен аңларга, хикәя җөмләне сорау җөмләгә әйләндерергә өйрәтә.

“Нечкә сорау” га җавап, бары тик бер сүздән генә торырга тиеш.

Мисал 1.

- Бу әсәрне кем язган?
- Төп герой кем?
- Әсәрдә уңай герой кем?

“Юан сорау” га җавапны берничә сүз яки җөмлә белән аңлатырга кирәк.

Мисал 1.

- Бу әсәр безне нәрсәгә өйрәтә?
- Әсәрдә ни өчен .........шулай эшли?
- Әсәр ничек тәмамлана?

**“Тишек хат” ысулы.**

Бик үзенчәлекле ысул. Бу ысул укучыларның узган дәрес материалын аңлауларын тикшерү өчен уңайлы. Беренче дәрестә әсәр белән танышалар, сорауларга җавап бирәләр. Ә икенче дәрестә укытучы шушы ук әсәрнең сүзләрен төшереп калдырылган өлешләр язылган карточкалар әзерли. Карточкалар бер генә төрле булырга да, төрле дә булырга мөмкин. Шулай ук, сүзләрнең грамматик мәгънәсенә карап, тишекләрне төрле төсләр белән рамкаларга да мөмкин. Мәсәлән, предметны белдерсә, кызыл; предметның билгесен белдерсә, сары; предметның хәрәкәтен белдерсә, зәңгәр төс.

Мисал 1.

Н.Исәнбәт “Өч матур сүз” [4, б.38].

— Әйт миңа син өч матур сүз,<br>
Уйлап әйт син, бәбкәем!<br>
— Мин яраткан иң матур сүз,<br>
Иң якын сүз — «Әнкәем»!<br>
— Калмый аннан бер матурсүз,<br>
Һәрвакыт син әйткәнең.

— Бергә әйткән ул матур сүз —

«Әткәем»дә «әнкәем»!

— Бар өченче бер матур сүз —

Ул матур сүз — «Илкәем»!

Анда бу йорт, төп бабамнар,

Илкәем — үз җиркәем.

**Йомгаклау**

Мин тәкъдим иткән әлеге ысуллар нәрсәсе белән уңайлы һәм бу ысулларны дәресләрдә куллану отышлымы? Үз тәҗрибәмнән чыгып, мин аны бик кирәкле методик алым дип исәплим. Әсәрләр өйрәнгәндә генә түгел, гади аралашкан вакытта да, физминуткаларда да, тиз генә файдалану өчен уңайлы алар. Мәсәлән, мин үзем һәр дәрес башында укучыларыма кош, хайван, агач һ.б. рәсемнәре күрсәтәм. Укучылар исемнәрен атарга тиешләр, ә кайбер дәрестә, кошларның исемнәрен үзем үк әйтәм дә: "Сез бу кошның чыпчык булуына ышанасызмы?" – дип сорыйм. Нәтиҗә нәрчә бирә соң, укучылар уйланырга мәҗбүр булалар. Гадәттә, укучы балалар, бигрәк тә, башлангыч сыйныфлар, укытучының һәр әйткәненә ышана. Ә менә мин, карганы чыпчык дисәм, бу инде укучыга уйланырга бер этәргеч була.

Бу ысуллар әсәрне күрә, ишетә, тоя белергә өйрәтә. Сөйләм хәтерен яхшырта. Сүзлек запасын баета. Эстетик зәвык тәрбияли. Үз фикерен әйтергә һәм аны исбатларга өйрәтә.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Сафиуллина Г.М., Әдәби уку, 1 кл., Казан, нәшрияты, 2011.
2. Сафиуллина Г.М., Әдәби уку, 3 кл., 1 кисәк, Казан, нәшрияты, 2013
3. Сафиуллина Г.М., Әдәби уку, 3 кл., 2 кисәк, Казан, нәшрияты, 2013.
4. Сафиуллина Г.М., Әдәби уку, 3 кл., 3 кисәк, Казан, нәшрияты, 2013.
5. Сафиуллина Г.М., Әдәби уку, 4 кл., 1 кисәк, Казан, нәшрияты, 2014.
6. Сафиуллина Г.М., Әдәби уку, 4 кл., 2 кисәк, Казан, нәшрияты, 2014.
7. Сафиуллина Г.М., Әдәби уку, 4 кл., 3 кисәк, Казан, нәшрияты, 2014.
8. Хәлим А., Биктырыш, Казан, 2008.

*Хусаинова Энже Абрамовна,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "2 нче Кама Аланы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең укытучысы*

**Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә уен технологиясен куллану**

Слайд 1. -Исәнмесез, хөрмәтле коллегалар.

Слайд 2 Бар нәрсәне дә белүче бер акыл иясе булган. Аның бер укучысы моның киресен исбатларга теләгән һәмн шулай кулына күбәләкне алган да учлары белән каплаган. Укучы укытучысыннан сораган "Әйт әле,укытучым, минем кулымда күбәләк үлеме, тереме?" –дигән. Ә үзе, тере дисә – үтерәм, үле дисә, очырам, дип уйлаган. Ничек уйлыйсыз, акыл иясе нәрсә дип җавап биргән? ("Барысы да синең кулыңда.")

Ә безнең сезнең белән, хөрмәтле коллегалар, кулларыбызда – балалар язмышы. Укчыларның безнең кулларда үзләрен яраткан, кирәкле, уңышлы итеп тоюлары бик мөһим. Безнең бурычыбыз баланың кечкенә генә булса да алга китешен күрү, аның уңышларына сөенү һәм баланы да сөендерә белү.

- Әйдәгез, кечкенә генә "көн-төн" уенын уйнап алыйк әле.(Тактадагы күбәләкләр саны кими)

Менә шундый кечкенә генә дә, катлаулырак уеннар да минем дәресләремдә еш урын алалр. Ботканы май бозмаган кебек дәресләрне дә уен боза алмый. Бигрәк тә башлангныч сыйныфларда.

Мастер классыма, чыгышыма СЛАЙД 3 "УЕН ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНЫП, РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАРНЫҢ КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯСЕН ҮСТЕРҮ" дигән тема сайладым. Компетенция - нинди дә булса өлкәдә осталык. Мин дәресләремдә аралашу осталыгын уеннар аша үстерәм, шуңа зур игътибар бирәм.

СЛАЙД 4. Уен -балалар өчен уку да, хезмәт тә, уен – ул җитди тәрбия формасы да.

Рус телле балаларны татар теле белән кызыксындыру зур көч сорый. Аларның телне өйрәнүгә теләген сүндермәү, дәрескә кызыксыну һәм стимул булдыру өчен, дәрестә уеннар куллану нәтиҗәле. Уен вакытында укучының иҗат мөмкинлеләре ачыла, мөстәкыйльлеге арта, оештыру сәләте үсә. Уен кайбер балалар өчен хыяллану, кайберләренә күңелле ял итү чарасы да булып тора. Ә укытучы өчен уен – балаларны яхшырак аңлау, аларга тагын да ныграк якынаю чарасы да. Чөнки нәкъ менә уен вакытында укытучы һәр баланың нәрсәгә сәләтле булуын, аның оештыру мөмкинлекләрен яхшырак күрә ала, холкын, гадәтләрен яхшырак аңлый. Уен ярдәмендә оялчан, үз эченә бикләнгән балаларны да уятырга мөмкин.

Уендагы текстка, җырга кушылып, аның кагыйдәләрен үтәп, я булмаса, ниндидер роль башкарып, бала үз көченә ышанырга, эшләгән эшенә бәя бирергә өйрәнә, анда ярдәмләшү, игътибарлылык кебек сыйфатлар тәрбияләнә.

Әйткәнемчә, мин үз дәресләремдә уеннарның төрлесен һәм дәреснең төрле этапларында кулланам.

СЛАЙД 5,6 Смайликлар ярдәмендә кәефләребезне, дәрескә булган мөгаләмәбезне күрсәтүне мин һәр дәресемнең оештыру өлешендә кулланам. Кечкенә генә бу уен төре дәрес башында ук балаларны җыя, уңай психологик халәт тудыра.(Смайликлар күрсәтәм).

Фонетик күнегү үткәрү өчен фонетик уеннар кулланам : "Әйтеп бетер", "Сүз уйлау", "Исем уйлау".

- Мәсәслән, кисмә хәрефләр белән конвертлар бирелә. Сузык аваз белдергән хәрефләрне аерып алыгыз әле. (Ул Ә) Шушы аваз кергән сүзләр уйлау. Бергәләп кабатлау. Ә авазы кергән сүз ишетсәләр, кул да чабалар. (әни, күбәләк, үрдәк, мәктәп, күлмәк, бүре).

Бу уеннарны мин авазларны, сүзләрне дөрес әйтү күнекмәләре формалаштыру, игътибарлылык өчен кертәм. Фонетик уеннар сөйләм органнары артикуляциясенең дөрес куелышын тәшкил итә.

Алган белемнәрне актуальләштергәндә "Нәрсә югалды", "Кар өеме" кебек уеннар бик отышлы. Уйнап алабыз. Укучы сүзен бер кар бөртеге итеп күз алдына китерегез. Җөмләләр төзибез һәм кар өеме ясыйбыз.(Укучы. Бу укучы. Укучы укый. Укучы мәктәптә укый. Укучы икенче мәктәптә укый. ...) Бу уен грамматик формаларны, җөмләдә сүзләр бәйләнешен һәм җөмлә төзү күнекмәләрен ныгыта. Актуальләштергәндә яңа информацион технологияләр дә кулланам. Укытучылар өчен булган белем бирү ресурслары битендәге тема буенча булган уен формасындагы биремнәр укчыларда татар теленә кызыксыну уята.

- Уку мәсьәләсен куйганда, яңа тел материалын презентацияләүдә дә күп төрле уен элементлары кулланам. Мәсәлән, кроссвордлар чишү, мультфильмнан, җырдан өзек тыңлау. Рәсемнәрне күрсәтәм, сез аны татарча әйтергә һәм беренче хәрефләр табып рәттән төзеп барыгыз. (Мәк, әтәч, китап, туп, әфлисун, песи). Нинди сүз барлыкка килде? (Мәктәп) Димәк, без бүген дәрестә мәктәп турында сөйләшәчәкбез.

Яңа теманы аңлатканда русча табышмаклар да кулланам. Слайд Уенның бу төре дә укучыларның логик фикерләү дәрәҗәсен үстерә, игътибарлылыкны арттыра, лексик материалны эшкәртүгә зур өлеш кертә.

Ял минутлары уздырганда балаларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып тыныч уеннарга да, хәрәкәтле уеннарга мөрәҗәгать итәм. Мәсәлән, күзләр өчен булган бу күнегү язу дәресләрендә урынлы кулланыла. СЛАЙД 10,11,12 Видео СДАЙД 13

Үтелгән лексик һәм грамматик материалны ныгыту һәм активлаштыруда “Кайтаваз” (Укытучы акрын гына сүзне әйтә. Укучыларның бурычы – аны ишетү һәм кабатлау), “Акыллы попугай” (Укытучы нинди дә булса предметны белдергән рәсем күрсәтә, сүзне атый, укчылар дөрес булса гына кабатлыйлар.)уеннары бик отышлы. Шулай ук “Әйтеп бетер”, Рифмалаштыру” уеннары өйрәнелгән лексиканы ныгытырга ярдәм итә.

“Иреннән укы” дигән уенда исә, тавышсыз гына сүзләр әйтелә.Укучылар аны ирен артикуляциясе буенча аңларга тиешләр. Бу уен өйрәнелгән лексиканы ныгыту өчен кулланыла.

- Игътибарыгызны экранга юнәлтсәгез, без сезнең белән бу сүзләрне тагын бер тапкыр кабатларбыз һәм укучыга мәктәпкә бару өчен портфель җыярбыз. Слайд ”Портфель җыябыз”.

Шулай ук укчыларның күзәтүчәнлеген үстерү өчен, уку-язу әсбапларын яңадан да таратам. Моның өчен алар ахырдан кергән тәртиптә предметларны әйтергә тиеш булалар. Бу максат белән “Нәрсә бар?” (әйләнә-тирәдә мөмкин кадәр күбрәк әйбернең исемен атыйлар) “Кем күбрәк күрде” уеннарым да дәресне җанландырып җибәрәләр.

Рус телле балаларны татар теленә өйрәтүдә рольле уеннар актив кулланыла. Аларның өйрәтү мөмкинлекләре зур һәм тәкъдим ителгән ситуацияләрдә укучылар аның белән иркен эш итәләр. Балаларда табигый рәвештә нәрсәдер әйтү, сорау ихтыяҗы яки әңгәмәдәшенә җавап бирү теләге туа. Рольле уеннар диалогик сөйләмне үстерүдә бик нәтиҗәле чара булып тора.

Һәр уен укучының танып белү эшчәнлеген активлаштыра. Уен аша өйрәнелгән материал тиз үзләштерелә һәм күпкә ныклы була. Дәресләрдә уен алымнарын куллану укучыларның белем дәрәҗәсен генә күтәреп калмый, телебезгә тирән мәхәббәт тә тәрбияли.

Рефлексия вакытында да минем укучыларым үзләренең дәрескә булган мөнәсәбәтләрен, үзләренең эш нәтиҗәләрен, үзләренең кәефләрен күрсәтеп дәрес башында өләшенгән смайликлардан файдаланалар. Темадан чыгып синквейн яки модель төзиләр. Слайдта МӘКТӘП сүзенә синквейн

Ә хәзер, хөрмәтле коллегалар, нәрсә соң ул уен дигән соравына җавап итеп синквейн төзик һәм тактага беркетик.

Мастер классымны Конфуцийның сүзләре белән төгәллисе килә “Укытучы белән укучы бергә үсәләр”. Дәресләребездә уен технологиясе кулланып укучылар белән бергә үрелеп үссәк иде.

*Шарафеева Рамия Анасовна, Хазиева Лилия Джаудатовна,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Туган (татар) теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның уку грамоталылыгын үстерү**

Заманыбыз укучыларның белем сыйфатын күтәрүдә мөгаллимнәр алдында яңа бурычлар куя. Гомуми белем бирү системасында функциональ грамоталылыкны формалаштыру өстенлекле максатларның берсе булып тора. Заманча мәктәпнең төп бурычларыннан берсе – функциональ грамоталы шәхес тәрбияләү.

Функциональ грамоталы шәхес – гомере буе алган белем, күнекмәне тормышта төрле өлкәләрдә килеп чыккан проблемаларны, мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген киң кулланып, социаль мөнәсәсбәтләр урнаштыра һәм аралаша алучы шәхес.

Функциональ грамоталы шәхес формалаштыруда укучыларның уку грамоталылыгын үстерү аеруча әһәмияткә ия. Чөнки уку грамоталылыгы – функциональ грамоталылыкның төп компоненты.

Уку грамоталылыгы – кешенең текстларны аңлау һәм куллану, алар турында уйлану һәм үз максатларына ирешү, үз белемнәрен һәм мөмкинлекләрен киңәйтү, социаль тормышта катнашу өчен уку сәләте.

Укучыларның уку грамоталылыгын үстерү буенча эшнең иң нәтиҗәле методик системалары булып продуктив уку технологиясе һәм тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясе тора.

Продуктив уку технологиясе – уку эшчәнлеге законнарына таянып, укучының текстны тулы мәгънәдә кабул итүен һәм аңлавын, текстка һәм аның авторына карата актив укучы позициясен тәэмин итүче белем бирү технологиясе.

Укучылар эшчәнлеге структурасы позициясеннән эшләнгән технология текст белән эшләүнең өч этабын (һәр укучы өчен табигый) күздә тота: текстны укуга кадәр, текстны уку һәм текстны укыганнан соң.

1. Текстны укуга кадәрге эш (ориентирлау һәм планлаштыру) – уку процессын оештырганчы укучыларга күрсәтелә торган уку биремнәре.

• Сезнең алда текст фрагменты. Бүгенге дәрестә аны укуның максаты нинди булыр?

• Максатка ирешү өчен тиешле уку стратегиясен сайлагыз.

• Текстның исемен укыгыз. Аның эчтәлеген фаразлагыз.

• Текст нинди жанрда язылган?

• Текст авторы турында сез нәрсә беләсез?

• Текстны аңлар өчен сезгә нинди фән буенча (өстәмә) мәгълүмат кирәк? Бу мәгълүматны кайдан алырга?

• Текст турында ... әйткән сүзләр белән танышыгыз. Сезнең текстны укырга теләгегез тудымы?

Текст белән эшнең беренче этабында түбәндәге УУГ формалаша: укытучы ярдәмендә дәрестә эшчәнлекнең максатын билгеләү һәм формалаштыру, дәреслек иллюстрациясе белән эшләү нигезендә үз фаразыңны әйтергә өйрәнү, үз фикерләреңне телдән һәм язма формада белдерү, башкаларның сөйләмен тыңлау һәм аңлау. Түбәндәге алымнарны кулланырга мөмкин:

- антиципация (алдан күрү, булачак укуны алдан күрү) – текстның мәгънәви, тематик, эмоциональ юнәлешен билгеләү, аның геройларын әсәр исеме, автор исеме, төп сүзләр, иллюстрация буенча укучы тәҗрибәсенә таянып күрсәтү;

- иллюстрацияләр белән эш – чорны чагылдырган, әмма әлеге әсәргә иллюстрация булмаган картиналарның репродукцияләре белән эшләү;

- лексик эш – укучыларга аңлашылмаган сүзләр белән эшләү, аларны аңлату, бу сүзләр кулланылган чорны, әсәрнең эчтәлеген билгеләү;

- ассоциатив рәт – сүз төркеме буенча дәрес темасын, әсәрнең исемен билгеләү;

- «идеяләр кәрзине» – дәрес темасына төп сүз бирелә, укучылар аның белән бәйле булган һәр нәрсәне искә төшерергә, дәреснең темасын һәм максатларын формалаштырырга тиеш;

- деформацияләнгән текст – текстны төзү, дәреснең темасын һәм максатларын формалаштыру.

Бу этаптагы эшнең нәтиҗәсе – дәреснең темасын, максатларын һәм бурычларын билгеләү, алар укучылар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә формалаштырыла.

2. Текст өстендә эш (эшчәнлекне башкару, планны тормышка ашыру, мәгънәле уку) – уку процессын оештыру вакытында укучыларга күрсәтелә торган уку биремнәре.

• Текстны өлешләп укыгыз. Аерым өлешләргә аңлатма бирегез.

• Сез вакыйгаларның дөрес барышын алдан әйттегезме?

• Текстның өлешләрен авторның нияте белән бәйләгез.

• Контекстка таянып, … сүзенең мәгънәсен, ... фразаның мәгънәсен, … персонажның ролен аңлатыгыз.

• Сөйләшүдә катнашучылар бер үк яки төрлечә уйлыйлармы?

Бу этапның УУГ: текстны эмоциональ рәвештә «яшәү», үз хисләреңне белдерү; башка кешеләрнең хисләрен аңлау, кызгану; укыган әсәрләрнең геройларына, аларның гамәлләренә үз мөнәсәбәтеңне белдерү, дәреслектә ориентлашу; сорауларга җавапларны текстта, иллюстрацияләрдә табу; текстны аңлаешлы итеп уку һәм сөйләү. Текст белән эшләгәндә, уку вакытында түбәндәге алымнар кулланыла:

- укучылар көндәлеге, ул әсәрне үзлегеннән укыганда тутырыла, ул мәгълүмати, стимуллаштыру һәм контроль функцияләрен башкара;

- ике өлешле көндәлек, ул әсәрне укыганда тула, эш барышында укучылар тексттан цитаталар язып алалар һәм аларга үз аңлатмаларын бирәләр;

- текстны аннотацияләү (төсле маркер яки ассызыклау ярдәмендә аерып кую, текстның төп фикерләрен яки бүлекләрен махсус билгеләр ярдәмендә аерып кую, сораулар кую);

- автор белән «диалог»;

- аңлатмалы уку;

- кластер;

- инсерт.

Бу этаптагы эш нәтиҗәсе – текстны җентекләп өйрәнү һәм аңлау.

3. Укудан соң текст белән эшләү – текст өстендә эшнең соңгы этабы. Түбәндәге биремнәр тәкъдим ителә.

• Сез уку максатына ирештегезме яки ирешмәдегезме? Юк икән, нигә?

• Текст ярдәмендә сез нинди сорауларга җавап алдыгыз?

• Текстның эчтәлеген чагылдырган аннотацияне сайлагыз.

• Текст турында рецензия әзерләгез.

• Текст геройлары белән проблеманы тикшерүдә катнашыгыз.

• Текстка туры килгән иллюстрацияләрне сайлагыз.

• Таблица рәвешендә персонажларның чагыштырма характеристикасын төзегез.

• Сез алган мәгълүматны ничек кулланасыз?

Бу этапта УУГ формалаша: башка кешеләрнең хисләрен аңлау, кызгану; укыган әсәр геройларына, аларның гамәлләренә үз мөнәсәбәтеңне белдерү, сыйныф һәм укытучының бергә эшләве нәтиҗәсендә нәтиҗәләр ясау; парда, төркемдә эшләргә өйрәнү; төрле рольләр башкару, укытучы белән диалогта бәяләү критерийларын эшләү һәм үз эшеңнең һәм башкаларның эшләренең уңыш дәрәҗәсен билгеләү. Текст белән эшләүнең бу этабында түбәндәге алымнар кулланыла:

- Блум шакмагы;

- Блум ромашкасы;

- әңгәмә;

- иҗади биремнәр;

- синквейн.

Бу этапның эш нәтиҗәсе – өйрәнелгән материалны гомумиләштерү, дәрес темасы буенча нәтиҗәләр ясау.

Критик фикерләү технологиясе элементларын куллану укучыларда уку грамоталылыгын формалаштыруның нәтиҗәле алымы булып тора. Фикерләү күнекмәсе укучыларга уку дәверендә генә түгел, алдагы тормышларында кирәк булачак (килеп туган мәсьәләне дөрес чишү юлларын табу, күпсанлы мәгълүмат белән эшләү, анализлау). Критик фикерләү технологиясе кысаларында түбәндәге алымнарны кулланырга була:

- «Тукталышлар белән уку» алымы. Дәрес башында укучыларга текст исеменнән чыгып сорау куела, укучыларның фикерләре тыңланыла. Төп өлешендә текст фрагментларга бүленеп укыла, һәр өзектән соң укучылардан алга таба ни булачагы турында җаваплар тыңланыла;

- «Сораулык белән эш» алымы. Әлеге алымны дәреслек белән эш вакытында кулланырга була. Укытучы укучыларга сораулар тәкъдим итә. Сораулар туры җавап бирерлек итеп тә, уйлану-фикерләүне таләп итәрлек итеп тә куела;

- «Беләм, белдем, белергә телим» алымы. Бу алымны яңа материалны аңлату һәм алынган материалны ныгыту этабында да кулланырга мөмкин. Өч графадан торган таблица бирелә, укучылар үз фикерләрен, җавапларын язалар;

- «Почмаклар» алымы. Әсәр геройларына характеристика биргәндә кулланырга ярый. Сыйныф ике төркемгә бүленә. Беренче төркемдәге укучылар, текст эчтәлегеннән һәм тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, геройның уңай сыйфатларына дәлилләр әзерлиләр. Икенче төркем исә, цитаталарга таянып, геройның тискәре сыйфатларын ачыклый;

- «Иҗади эш язу» алымы. Бу алымны өйрәнелгән теманы ныгыту этабында куллану уңай. Укучыларга яки әсәрне дәвам итәргә, яки үзгәртеп язарга, яисә үзләренә әкият, хикәя, шигырь язарга тәкъдим итәргә була. Әлбәттә, мондый эш биргәндә укучыларның сәләтен күз уңында тотарга кирәк.

Укучыларның уку грамоталылыгын үстерү уку материалын яхшырак һәм тизрәк үзләштерергә ярдәм итә, ә уку процессы кызыклы һәм мавыктыргыч була.

Укучыларның уку грамоталылыгын үстерү максатында кулланыла торган технологияләр, алымнар бик күп. Алардан уңышлы файдалану – хәзерге заман укытучысының изге бурычы.

*Якупова Венера Бәдертдин кызы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы « 29нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Әдәбият дәресләрендә Муса Җәлил әсәрләре аша туган якка мәхәббәт тәрбияләү**

Шәхси тәҗрибәләремнән чыгып, М.Җәлил иҗатын өйрәнү эшенең мөһим үзенчәлеге бар, дип саныйм. Патриот шагыйрьнең күп шигырьләре сугыш темасы белән бәйле. Без – шәһәр балаларына белем бирүче укытучылар. Сүзне шуннан башлыйсы килә. Урман-кырда, табигать кочагында үскән бала тирәнрәк хисле һәм кешелеклерәк була. “Табигать аша тәрбия, экологик тәрбия” сүзтезмәләре – педагогик термин буларак кулланылышы белән генә яңа юнәлеш. Халкыбызның милли педагогикасында буыннан-буынга мондый төр тәрбия бирелгән.

5-6 нчы сыйныф дәреслекләрендә М.Җәлил иҗаты бик уйланылган тәртиптә тәкъдим ителә. Җәлил иҗатын өйрәтү сугыш чоры әсәрләреннән түгел, ә “Алтынчәч” либреттосы белән таныштырудан башлана. Төрки халыкларның уртак дастанына нигезләнүенә басым ясала. Әсәрдәге “Кара урманда үстем мин, атам минем – Кара тау, анам минем – Агыйдел” дигән өзекләргә нигезләнеп, Җик мәргәннең табигать баласы булуына аерым игътибар бирелә. Алтынчәч ариясен укыганда, Алтынчәчнең дә табигать баласы булуы дәлилләнә. Алтынчәчнең кояшка мөрәҗәгате, Иделгә сыенуы, табигатьтән көч алуы аерып күрсәтелә. Әлеге күренешләр белән беррәттән, туган як, төбәк табигатенә игътибар юнәлтелә: “Ә безнең туган җиребездә шундый урманнар, елга-күлләр, сулыклар бармы? Ни өчен кешеләр арыгач, ял итәр өчен табигатькә чыгалар?” – дигән сорау куела.

Уку елының икенче яртысында “Алтынчәч” либреттосын киңрәк өйрәнү мөмкинлеге тудырылган. Аерым бүлекләрдән өзекләр бирелгән. Әлеге эштә укучыларга җиткерәсе төп фикерләрем түбәндәгеләргә нигезләнә: Җик мәргән туганда ук, табигатьтән көч алып туа, чөнки, аның якыннары, ыруы бала туганда табигатьтән көч сорап , теләкләр телиләр. Җик мәргән ятим калып урманда үсә. Бар тере табигать аны яклый, саклый, гомер буе ярдәм итә. Кеше табигать белән бергә гармониядә яшәгәндә генә бик көчле була, табигать үзенең ярдәменнән калдырмый, дигән төп фикер үткәрелә. Бу урында милли асылыбызга тукталу да урынлы, төрки халыклар белән беррәттән, татар кешесе үзен табигатьнең бер кисәге дип хис иткән, табигать белән гармониядә яшәгән. Туган шәһәребездәге урманнарда, Чулман буйларында, Кызыл Чишмәдә ял итүчеләр, көч-куәт җыеп, табигать белән хозурланып йөрүчеләр бик күп. Шәһәребездә табигать кочагында спорт белән шөгыльләнеп,

сәламәтлекне арттыру өчен яхшы шартлар булдырылган. Дастаннардан башланып, Җәлил иҗатында урын алган табигать белән гармониядә яшәү зарурлыгы менә шул рәвешле туган ягыбыз табигате, аның мөмкинлекләреннән дөрес файдалану, саклау мәсьәләләре белән тоташа алды.

Хәзерге заман баласының психикасы һәм психологиясе, тирә-юньне кабул итү шартлары М.Җәлил иҗат иткән сугыш чоры кешеләренекеннән нык аерыла. Сугыш фаҗигаләрен тасвирлаган әсәрләрне өйрәткәндә укучының фикер агышларына дөрес юнәлеш бирү кирәк. Сүз дә юк, күп балалар бик акыллылар. Кызганыч, хәзерге буын балаларыбыз арасында начар шартларда яшәп, таушалган психикалы яисә, компьютерда уеннар уйнап, виртуаль дөнья тулган кешелексез сыйфатларны: үтереш, кансызлык кебек вәхшилекләрне гадәти күренештәй кабул итә башлаган балалар да бар. Моның шулай икәнен яшерү – мәгънәсезлек. Кызганычка каршы, бу безнең тормышыбызның кырыс реальлеге. Менә шундый шартларда, сугыш сурәтләнгән әсәрләрне укучылар күңеленә дөрес йогынты ясарлык итеп өйрәтүне үземнең бурычым итеп тоям.

“Алтынчәч” либреттосы белән беррәттән, 5 нче сыйныфта “Ромашка”, шигыре өйрәнелә. “Ромашка” шигырен өйрәнү барышында беренче ике строфадагы табигатьнең тыныч тормыш символы булуына игътибар юнәлтелә. Табигать тыныч тормышта гына табигыйлеген саклап кала ала. Ә сугыштан кешеләр генә түгел, бар җиһан, бар җанлы табигать тә зур афәт күрә. Чукларына кан тамып кызарган ромашка образы аша табигать белән кеше гармониясенә дә тукталу зарур. Әдәбиятта, халык авыз иҗатында калыплашкан традициягә таянабыз: кешегә шатлык килгәндә, табигатебез дә куана, кайгы килгәндә – бар табигать аваздаш була. Һәр жанр әсәрләрендә пейзаж күренеше ярдәмгә килә. М.Җәлил иҗаты да искәрмә түгел, яралы солдат фаҗигасе өчен табигать тә өзгәләнә. Шуның белән беррәттән, яудагы сугышчыларның батырлыгы өчен бар табигатьне горурлык хисе дә били.

М.Җәлил иҗатын өйрәнгәндә, “Сандугач һәм чишмә” балладасы мөстәкыйль уку өчен тәкъдим ителә. Укучыларны китап укуга тарту эше җиңел түгел. Төрле ысулларны кулланырга туры килә. Мин “Сандугач һәм чишмә” китапларының берничә елгы басмаларын китапханәдән алып, укучыларга күрсәтәм. Иллюстрацияләрен карап, урта мәктәптә укучы балада китапның эчтәлеген белүгә омтылышы туа. Әлеге алымны кулланганда . укучылар күбрәк укыйлар.

Иллюстрацияләргә килгәндә, тагын бер кызыклы алым белән уртаклашасым килә. Моннан берничә ел элек. Ижау шәһәрендә. Россия рәссамнары арасында М.Җәлил әсәрләренә ясалган иллюстрацияләр конкурс-күргәзмәсе оештырылган иде. Шул күргәзмәдә тәкъдим ителгән берничә рәсем миңа дәресләрдә ярдәм итә. Казан рәссамы Алсу Йосыпованың “Сандугач һәм чишмә” балладасына багышланган әлеге рәсемне китап

укырга кушканда ук күрсәтәм. “Укып килегез, һәм менә бу рәсемгә туры килердәй юлларны билгеләгез” дигән гади генә бирем дә дәреслеккә һәм укылган китапка кермәгән иллюстрация күрсәткәч, өстәмә этәргеч булып тора.

“Сандугач һәм чишмә” балладасы хакында фикер алышканда, сүзне туган шәһәребездәге Кызыл чишмә бистәсендәге Изгеләр чишмәсе белән бәйләп дәвам итәм. Чишмә, кош образларына бәйлелеккә тукталам. Халык җырларында, шигырьләрдә, шул исәптән, Җәлил балладасында да чишмә тирәсендә барган вакыйгаларда нинди дә булса символга ия кошлар да катнаша. Ул сандугач, былбыл булырга мөмкин. Укучыларга, “Безнең шәһәрдәге Изгеләр чишмәсе янында агачтан ясалган сәнгать әсәре бар. Анда нинди кош сурәтләнә?” дигән сорау бирәм. Укучылар бу сынны беләләр, әмма, аның ябалак икәнен дөрес әйтә алмаучылар да була. Ә.Фәтхетдинов иҗат иткән әлеге сын турында мәгълумат биреп узам.

Әдәбият дәресләрендә Муса Җәлил әсәрләре аша туган якка мәхәббәт тәрбияләүне нәтиҗәле итеп оештыру укытучыдан иҗади эш, киңкырлы эзләнүләр таләп итә. Мин бу юнәлештә эшләүнең тагын бер эчтәлекле ягын билгеләп китәр идем. Укучы, аеруча, 5-6нчы сыйныф баласы әдәбиятның тормыш белән бәйлелеген төшенә башлый, китапта язылганнарның әкият яки уйдырма түгел, ә тормыш күренешләре икәнен тагын да аңлый башлый.

*Ялалова Зөлфия Фаел кызы ,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «адымнар - Түбән Кама "полилингваль гимназиясе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## Туган тел дәресләрендә интерактив алымнар куллану.
## (мастер-класс)

**I.**1. - Хәерле көн, хөрмәтле жюри әгъзаләре, хөрмәтле укытучылар!

Тышта кыш, ә җәй шуның кадәр сагындыра. Карагыз әле, бу кечкенә генә күбәләк җәйне хәтерләтә. Учыгызда күбәләк кунган дип хис итегез. Ә мин сезгә бер риваять сөйлим:

“Борын-борын заманда тауларда бер бөек акыл иясе яшәгән, ул барлык сорауларга да җавапларны белгән һәм барысы да аның янына киңәш сорап килә торган булганнар, чөнки ул беркемне дә ярдәмсез калдырмаган.

Ә бер укучысы моның киресен дәлилләргә тырышкан. Укыучы бер күбәләкне алган да: “Остазым әйт әле, минем учымда нинди күбәләк: тереме , әллә үлеме?” – дип сораган.

Ә үзе: “Тере дисә, мин аны тиз генә кысып үтерермен, әгәр дә инде үле дисә – мин аны очырып җибәрермен һәм шулай ялгышуын дәлилләрмен” – дип уйлаган.

- Ә сез ничек уйлыйсыз? Акыл иясе нәрсә дип җавап биргән икән? (җавап юк) Мастер-класс ахырында мин бу сорауга җавап табарбыз дип уйлыйм.

**II.** Хөрмәтле укытучылар, игътибар белән экранга карагыз әле.

1) - Хөрмәтле укытучылар, сез күчерелмә мәгънәгә ия булган нинди тотрыклы сүзтезмәләрне исегездә калдырдыгыз.

**Чиләгенә күрә капкачы....**

Әйе, димәк, бу сүзләрне без нинди сүзләр дип атыйбыз?

**Фразеологизмнар.**

Татар теле – гаҗәеп гүзәл, камил төзелешле, бай тел. Аның гасырлардан-гасырларга күчеп килүче кыйммәтләренең берсе-фразеологизмнар бар. Халык аларны “телебезнең җәүһәрләре” дип атый. Бу тел байлыклары киләсе буыннарга да барып җитәрме? Без аларны саклый алырбызмы? Әлеге сораулар үзен чын татар кешесе дип тойган һәркемне борчыйдыр, минемчә.

«Фразеологизмнар» темасы рус телендә дә, татар телендә ныклап өйрәнелмәгән темаларның берсе булып тора: ә аны бик күп төрле интерактив алымнар кулланып, кызыклы итеп өйрәнергә була. Бүген сезне шул алымнар белән таныштырып китәрмен.

Димәк, мастер-классыбызның темасы: «Эзләнүләр һәм табышлар (туган тел дәресләрендә интерактив алымнар куллану)» дип атала.

Максатыбыз: Укучының танып-белү һәм иҗади эшчәнлеген активлаштыру максатыннан интерактив дәфтәр алымнарын куллану.

Бурычларны сез экранда күрә аласыз.

**III.** Хөрмәтле укытучылар, минем яныма килегез әле, миңа сездән бер киңәш кирәк иде. Минем сыйныф укучылары арасында бер күңелсез хәл килеп чыкты бит әле: Халыклар дуслыгы фестивалены әзерләнгәндә минем бер кызымны үпкәләткәннәр: җыр җырлап күрсәткәч, синең колагыңа аю баскан, бүре булып уласаң да җырчы чыкмый, биегәндә аю табан, бии белмисең дигәннәр, сөйләп күрсәткәч, әзерләнмәгәнсең, трай тибеп кенә йөргәнсең, акыл сатма дигәннәр. Мондый әзерлек белән, безгә мәңге беренче урын булмый, тот капчыгыңны дип тә өстәгәннәр. Аның хәзер балтасы суга, төшкән, катнашмыйм дип авызын турсайтып утыра. Миңа нишләргә икән, нинди генә сүзләр әйтеп юатыйм икән?

- Син минем уң кулым дип әйтегез, кәефе күтәрелер.
- Бер яхшы билге куегыз. Башы күккә тияр.
- Килмәгән җирең юк, матур җырлыйсың диегез.
- Күзнең явын алырлык чибәр дип әйтегез.

- Баскан җирдән ут чыгарасың.
- Әйе, матур биисең дип әйтегез.

Бик зур рәхмәт, укытучылар, җанга якын киңәшләрегез өчен!

Хөрмәтле укытучылар, алмагачка игътибар иттегезме сез? Аның бит тылсымлы алмалары юкка чыккан. Безгә сезнең белән бүген үк тикшеренү эшен башларга, алмагачка тылсымлы алмаларны кайтарырга кирәк.

Яшерен полиция агенты мин үзем булырмын. Миңа ярдәмчеләр: язучылар, рәссамнар һәм актерлар кирәк булыр:

1. Иң беренче биремне актерлар эшләр: сезгә шушы кубик-рубиклардан фразелогизмнарны табып, пантомима ысулын кулланып, сүзсез генә уйнап күрсәтәсез, рәссамнар сүзнең нәрсә турында барганын әйтергә тиеш.
2. Ә рәссамнар кара тартмадагы рәсемнәрне табып, шушы алмаларга ябештереп куярлар.

*(актерлар чыга һәм рәссамнарга пантомима ысулы белән фразеологизмны аңлатып күрсәтә)*

Димәк, рәссамнар рәсемне тапты, аларны алмаларга ябештереп куйдылар, язучыларга да чират җитте.

3. Язучылар яшел тартмадагы кәгазьләрне алып, төшеп калган сүзләрне язып, аңлатма биреп китегез әле, бу фразеологизмнар нәрсәне аңлата. Нәтиҗәдә, нинди фразеологизм килеп чыкты?

Хөрмәтле укытучылар, булдырдыгыз, афәрин. Сез тылсымлы алмаларны урыннарына кайтардыгыз. Рәхмәт сезгә!

Бүген сез «Фразеологизмнар» темасы аша дәрестә интерактив алымнар кулланырга да өйрәндегез. Бу интерактив алымнарны сез дәрестә төрле темаларны өйрәнгәндә куллана аласыз.

**IV.** Информацион технологияләр үсеше чорында яшәгән балалар, үткән буыннан бик нык аерыла. Ә замана баларын татар теле белән ничек итеп кызыксындырырга соң?

Бу сорауга җавап бирү өчен миңа, татар теленнән укучылар арасында үткәрелгән, сораштыру ярдәм итте.

«Татар теле дәресләрендә сиңа нинди эш төре ошый дигән сорауга?» алар кызыклы биремнәр, проект эшләре һәм төркемнәрдә эшләү кебек эш төрләренә күбрәк тавыш биргәннәр. Димәк, бу эш төрләре заманча, кызыклы, сыйфатлы булырга тиеш. Бу очракта миңа, туган телдән интерактив дәфтәр ярдәмгә килә.

Интерактив дәфтәр-укучыларга дәресләрдә актив катнашырга, анализларга һәм яңа мәгълүмат белән танышырга мөмкинлек бирүче заманча дәфтәр формасы. Интерактив

элементлар булу сәбәпле, мондый дәфтәрнең тышкы күренеше гадәти дәфтәрдән шактый аерылып торганлыктан, интерактив дәфтәр укучыларның игътибарын һәм кызыксынуын җиңел җәлеп итә. Ләкин интерактив дәфтәрләр тышкы кыяфәтләре белән генә аерылып калмый, аларның бик күп уңай яклары бар:

(*презентация слайды*)

Биология фәне белән бәйләнештә караганда да, кеше миенең уң як ярымшары сүзләрне, схемаларны, саннарны күбрәк истә калдырса, сул ягы төсләр, формалар, образ, күзаллауларны истә калдыра.

XXL гасыр укытучысы менә шундыйрак кыяфәттә  күз алдына китерәм мин, аңа бик күп эшләргә, эзләнергә туры килә, дәресемне кызыклы итеп үткәрүдә, интерактив дәфтәргә материаллар җыйганда миңа менә бу сайтлар ярдәмгә килә.

**V.** Хөрмәтле укытучылар, бала күңеле күбәләк кебек. Татар теленә мәхәббәт, нәфрәт уяту да, без, укытучылар кулыннан тора. Әгәрдә без, туган тел укытучылары, милләтебезнең киләчәген, йөзек кашларын тәрбияләүчеләр, бал кортлары төсле, дәресләргә кызыклы, төрле алымнар кулланып әзерләнсәк, рус гаиләсендә яшәгән балалар да, татар телен яратып өйрәнерләр. Бер төрле генә үткән, кызыксыз дәресләр алар күңелендә нәфрәт уятыр. Димәк, хөрмәтле укытучылар, укучысына остаз нәрсә дип әйткән?

Барысы да синең кулыңда!

Дөрес, барысы да безнең кулдан тора.

Бердәм булыйк, бергә булыйк, телебезне саклыйк, аралашып яшик.

## Икенче бүлек. Укучылар эшләре.

*Абдульманов Демид, 6 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы “Инглиз телен тирәнтен өйрәнү белән 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе " муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Ахунова Гөлнур Габдулла кызы, татар теле әдәбияты укытучысы*

### Бөек Ватан сугышы – минем гаиләм хәтерендә

### Кереш өлеш

Быел илебез Бөек Ватан сугышындагы Җиңүнең 77 еллыгын билгеләп үтте. Бу зур җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егет-кызлары иде: минем әбием, синең бабаң, анықы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш капка-ишекләрен какмаган гаилә калдымы икән илдә - көндә? Менә шушы сорауга җавап табарга дип үземә максат куйдым һәм үзенең тамырларын истә тотып яшәүче гаилә турында эзләнеп, язарга булдым. Укытучы апам Гөлнур Габдулла кызыны мөрәҗәгать иттем. Миңа ул үзенең әбисе турында сөйләде. Мактау кәгазәләрен һәм күп кенә медалҗ орденнарын күрсәтте. Мин сезне дә батыр, курку белмәс “Боевой” әби белән таныштырам.

Мин бу конференциядә бик теләп катнашам. Хөрмәтле укытучыбыз, Гөлнур Габдулла кызының әбисе турында сөйләве буенча”- язарга булдым. “Тамырларны истә тотып яшәү...”- исеме нәкъ менә шушы гаиләгә хас.

“Минем әтием Зиатдинов Габдулла Ширәмәт районы (бүген Түбән Кама) Кызыл Чапчак авылында туган, балачак гомеремнең күп вакыты шунда узгач, мин табигатьнең бу гүзәл почмагын үземнең туган җирем дип саныйм. Авылның нәкъ уртасында истәлек булып, сугыштан әйләнеп кайтмаганнарга, безнең бәхетебез өчен газиз башларын салганнарга, хәзер инде бу изге яуда катнашкан, сугыштан исән кайтып туган җирендә вафат булганнарга һәйкәл - обелиск торгызылды. Һәрдаим исәннәргә, бигрәк тә без - яшь буынга сугыш афәтен исебезгә төшереп тора кебек ул. “Әй син, Балам, онытма минем. Дөньяда без дә бар идек, син шуны онытмадыңмы? Дөньяның, җир шарының тыныч яшәешенең кадерен беләсеңме?” - дип искәртә кебек ул һәйкәл” – дип сөйли укытучыбыз.

“Әлеге һәйкәлнең “Сугышта катнашып, исән кайткан авылдашлар” исемлегендә бердәнбер хатын - кыз сугышчы - ветеран- минем газиз әбием Шәмсекамал Зиятдин кызының исем фамилиясе дә мәңгелеккә теркәлгән”- ди ул.

“Сугыш һәм хатын - кыз” мәңге тәңгәл килә алмый торган, берничек тә янәшә торырга тиеш булмаган төшенчәләр! Шулай булса да, сугыш афәтендә хатын - кызларга да катнашырга туры килгән. Хатын - кыз язмышлары, әбием язмышы... Уйландыра, тетрәндерә, җаннарны айкап күздән яшь китерә... Батырлыгың, түземлегең каршында баш иям, Әбием!”- дип дәвам итә ул.

**Төп өлеш**

...Әбием Шәмсекамал Зыятдин кызы Зыятдинова 1916 елның 7 октябрендә дөньяга килә. Ирләр сугышка китү сәбәпле, бөтен ир - ат эшләре хатын - кызлар җилкәсенә төшкән, әбиемә тракторчы һөнәрен үзләштерергә туры килгән. Бик тырыш, чырыш була әбием, көнне-төнгә ялгап җир сөрә, тырмалый, чәчә, ура. Ирләр өчен дә күтәргесез булган әлеге хезмәтнең хатын - кыз өчен никадәр авыр булганлыгын үз башыннан үткәннәр генә белә...Барысына күнеп, ил өчен, фронт өчен кирәк, дип, көнне-төнгә ялгап эшләп йөргәндә, әбием  үз теләге белән яу кырына китә. Бу ил язмышы хәл ителгән 1943 ел була. Әбием Волхов фронтының 44 укчы дивизиясендә сугышчан юлын башлый. Яу кырында да аңа ирләр эше башкару насыйп була: ул- машина (үзе полуторка дип атый иде) йөртүче булдым”- дигән.

“Әбием Бөек Ватан сугышының алгы сызыгында көн саен үлем белән очрашкан. Яңгыр явамы- кармы, бомбалар шартлыймы, кара төнме ул, шомлы урманмы - мөһим түгел,сугыш кирәк- яраклары кушылган җиргә, фронтның алгы сызыгына вакытында барып ирешергә тиеш. Баш очында, тирә - юньдә машинага тиеп диярлек бомбалар, миналар шартлый, ә әбием кеп-кечкенә кулларының сөякләре агарганчы чатырдап машина руленә ябышкан, тиешле урынга барып җиткәч, сугышчылар әбиемнең кулларын көчкә аерып ала торган булалар...”- икән дип сөйли торган булган.

“Сугыш кырында күрсәткән батырлыклары өчен, сугышчан биремнәрне һәрчак җиренә җиткереп үтәгәне өчен ул “За боевые заслуги” медале, II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән, күп санлы медальләр, мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. Әбием дошманны илебез җирләреннән куып чыгарып, Польша җирләрендә сугыша, Польшаның Млава, Дзялдев, Грудзянз, Тчев, Гнев шәһәрләрен азат итүдә катнаша. Әбиемнең сугышчан бүләкләре - гаиләбезнең иң кадерле ядкяре, һәм алар әбиемнең истәлеге булып, буыннан-буынга күчеп бара” – дип горурлана укытучыбыз.

“Ничек кенә авыр булмасын, тормыш дәвам иткән, узенең ошатып йөргән, ягъни минем бабам белән яшьлек хисләре, мәхәббәт хисләре кабынган һәм этиемне дөньяга

китерү өчен әбием демобилизацияләнеп туган авылы Кызыл Чапчакка кайта. Дөньяга Зыятдиновлар нәсел җебен дәвам итеп, этием Габдулла килә, әбием аны бик кадерләп, яратып үстерә. Әтием,  үз авылы кызы, әнием Рәзинә белән гаилә кора, һәм алар ике кызга гомер бирәләр.  Әбием соңгы көннәренә кадәр,  безнең гаиләдә гомер кичерде, без әбиемне тәрбияләп, соңгы юлга озаттык”- дип сөйләгәндә Гөлнур Габдулла кызының күзләренә яшь килә.

“ Әбием сугыш турында сөйләргә бер дә яратмый иде. “Сугыш турында сөйлә инде, әбекәй!” - дип бик аптыраткач, “И, балалар, сезгә аны күрергә язмасын!” - дип кенә әйтә иде” - ди укытучым. Әбиебез һәр яшәлгән көнне Ходайдан зур бүләк итеп кабул итте. Бары: “Фронт кырында, әллә үләм, әллә исән калам, дигән көннәр аз булмады” - дип кенә искә ала иде. Сәламәтлеге мөмкинлек биргән чорда, ул мәктәп укучылары белән очрашуларда еш була иде, туган илнең, туган җирнең кадерен белергә, сакларга, һәр тыныч көнгә сөенеп яши белергә өнди иде.

**Йомгаклау**

Һәр елны, горурлык  хисләре белән без әбиемнең зур фотосурәтен тотып “Үлемсез полк” акциясендә катнашабыз. Моның белән аның исемен мәңгеләштерү өлкәсендә үз өлешебезне кертәбез, дип саныйм.

Әбием 1998 елның 8 сентябрендә вафат булды. “Урының оҗмах түрләрендә булсын, Әбием, без синең белән чиксез горурланабыз!”

**Файдаланылган әдәбият**

1. “Туган як” газетасы “Әбием-минем горурлыгым” №33 (4213) 8.05.2020
2. Гарипова Ф. “Авылларны сөям җаным тәнем белән”- Казан-1994.

*Архипова Сафия, 6 нчы сыйныф ,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы "Адымнар-Әлмәт" полилингваль гимназиясе" муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Егорова Гүзәлия Әбрар кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Халкыбызның гореф-гадәтләре**

**Кереш**

Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган.

Тормыш–көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык милләтләргә дә хас. Ул әлеге милләт мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Гореф-гадәтләр борын-борыннан халык тарафыннан үтәлеп килә торган бәйрәмнәрне, йолаларны үз эченә ала. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә, алардан башка халык тулы кыйммәтле тормыш белән яши алмый.

**Проектның максаты:** туган телебезне, тарихыбызны, рухи байлыкларыбызны, гореф-гадәтләребезне өйрәнеп, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, бөек милләт булып яшәвебезне дәвам итү.

**Бурычлар**

- татар халкының милли мәдәниятенә, сәнгатенә, йолаларына, уеннарына карата кызыксыну тәрбияләү;

-үзебезнең кече Ватаныбызга – авылыбызга, туган җиребезгә, өебезгә, гаиләбезгә карата мәхәббәт һәм ярату хисләре тәрбияләү;

-татар халкының йолаларын,көнкүрешен өйрәнүләрен үстерү;

**Проекттан көтелгән нәтиҗәләр**

Әхлаклылык, әдәплелек сыйфатлары тәрбияләү. Балаларның ана телендә дөрес һәм матур итеп аралашырга өйрәнүе.

Татар халкының электән килгән гореф – гадәтләре, йола уеннарытурында күзаллауларын киңәйтү.

Әлеге проект бүгенге көндә бик актуаль, чөнки үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең, туган җиренең тарихын белергә, шуның аша халыкка якынаерга тиеш. Һәр милләт үз җирлегендә барлыкка килгән һәм буыннан-буынга күчә торган гореф-гадәтләрен, кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган. Алар буш җирлектә тумаган, арасында елның төрле вакытларына, дини йолаларга, тормыштагы үзгәрешләргә бәйле барлыкка килгәннәре дә бар.

Сулар аккан кебек, чорлар, еллар үткән. Татар халкы бик күп тормыш сынаулары үтеп, бүгенге көнгә дә килеп җиткән. Кайчандыр югалуга дучар ителгән милләт туган телен саклап, алга таба атлаган. Гасырлардан-гасырга, буыннан-буынга, әби-бабайдан әти-әнигә, әти-әнидән балага үзләренең борынгы бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын

югалтмыйча тапшырып килгән, һәм алар, күпмедер дәрәҗәдә үзгәреп, югалып бетә язып, безнең көннәргә дә килеп җиткән.

Татар халкының элек-электән килгән гаилә йолалары да бар. Мин шуларның берничәсенә тукталып үтәсем килә.

## Төп өлеш. I бүлек

## Туй йолалары.

### 1.1 Кыз ярәшү һәм кодалау

XX йөз башына кадәр татар халкына яучылап-димләп өйләнешү хас булган. Егетнең туганнары кызны кияүгә сорап аның әти-әнисенә яучы җибәргән. Яучы кызны кияүгә бирергә күндергән, өйләнү шартларын ( калым күләмен,туй вакытын һ.б) ачыклаган.

Шуннан кыз ярәшү һәм килешү йолалары башланып киткән. Әлеге йолалардан соң ике якның бүләкләр алмашуы һәм туганнар белән аралашу мәҗлесе үткәрелгән.

Кыз ярәшү, килешү һәм туй йоласы төрлечә булган,ләкин бик озак түгел. Бу вакытта бер як- калым, икенчесенә бирнә, булачак туганнар өчен бүләкләр әзерләгән.

### 1.2 Төп туй

Төп туй йолалары калымның бер өлеше түләнгәч, кыз йортында уздырылган: шәригать кушканча никах укылган һәм никах мәҗлесе үткәрелгән.

Мәҗлес көннәрендә туганнарны килен белән таныштыру – кыз күрсәтү, кыз сөю, килен котлау йоласы үткәрелгән. Соңыннан бүләкләр алмашканнар һәм килен һәммәсен дә чәй табынына чакырган.

Кыз йортында кияү 4 көн кунак булган, кәләшнең туганнарына бүләк өләшкән (никах түшәге, яшь килен мунчасы һ.б. өчен йолым түләнгән). Иң кыйммәтле бүләкне хатынына тапшырган.

Кияү бүләкләренә каршы яшь килен үзе тукыган-чиккән бүләкләрне биргән. Шул рәвешле «кияүләп йөрү» башланып киткән: кияү атнага 1 тапкыр (һәр пәнҗешәмбе) кәләше янына килеп йөргән, әлеге йөрүләр калым түләнеп беткәнче дәвам иткән. Гадәттә аны өлешләп түләгәннәр, кайвакыт ул шактый озакка сузылырга мөмкин булган.

Ярлы крәстиян гаиләләрендә, кагыйдә буларак, әлеге йола үтәлмәгән. Гадәттә өйләндерүне әти-әниләр, яңа эшче куллар алу өчен, җәйге авыл хуҗалыгы эшләре башланган көннәргә туры китергәннәр; кәләшне шунда ук каената йортына алып кайтканнар.

Зур туй яшь киленнең кияү йортына төшүе һәм кияү туганнарында туй мәҗлесләре уздыру белән тәмамланган.

### 1.3 Килен төшерү

Кияү йортында яшьләрне каршы алу да йола буенча башкарылган (әлеге традиция хәзер дә кайбер якларда давам итә): киленнең аяк астына мендәр яки эче тышка әйләндерелгән тун салганнар (яңа йортка керү җиңел булсын өчен), кулларын онга батырганнар (өйдә яхшы аш-су әзерләүче булсын өчен), бал-май каптыралар (теле татлы булсын өчен), нинди дә булса терлек бүләк иткәннәр, су юлы күрсәткәннәр.

Килен багу йоласына киленнең үзе чиккән, тукыган әйберләре белән өйне бизәү – өй киендерү дә кергән.

Татар халкында ябышып чыгу яисә кыз урлау сирәк хәл булган. Җәмәгатьчелек андый юл белән өйләнешүне хупламаган.

Хәзерге чорда туй йолалары төзелеше һәм эчтәлеге ягыннан нык үзгәрә, никах гадәттә ЗАГС органнарында теркәлә, ләкин 1990 еллар ахырыннан, күпчелек очракта, шәригать кушканча, башта никах укыла.

## II бүлек

### 2.1 Бала туу.

Гаиләгә шатлык, өмет һәм куанычлар өстәп, бала дөньяга килә. Бәби туе башлана. Халкыбызда бәби туу белән бәйле йолалар күп булган һәм хәзер дә саклана. Язмамда шуларга тукталып үтәм.

Иң беренчесе **исем кушу**. Исем ул кешенең язмышын билгели торган нәрсә дип каралган. Элек-электән мәгънәле эчтәлеккә ия булган исемнәр кушканнар. Мулла килеп азан әйтеп, исем куша, балага бәхет теләп, дога кыла. Исем кушуга хәзер халык бик игътибар итә. Әти-әни баласының бәхетле, озын гомерле, игелекле булуын тели, шуңа күрә сүзлекләрдән карап, укып исем сайлыйлар. Безнең өйдә дә Г.Саттарның “Татар исемнәре” сүзлеге бар. Интернетка кереп тә бик җиңел генә исемнәрнең мәгънәсен белеп була. Соңгы вакытта төрки, гарәп-фарсы исемнәре еш кушыла. Бу халкыбызның дингә, миллилеккә битараф булмавын күрсәтә.

**Минем исемем –Сафия. Үземнең исемемне бик яратам. Саф, катышсыз, чын, эчкерсез дигәнне аңлата. Барлык мөселман халыкларында очрый.**

Бәби тугач, икенче бер мөһим эш – ул **чәч алу**. Кайбер якта бу эшне хатын-кыз башкарган. Аны “Чәч-әни” дип йөрткәннәр. Икенче бер якларда сакал-мыеклы кеше алсын, баланың чәче куе булып чыгар, дип уйласалар, кайбер якта иң карт кеше алсын, дигәннәр.Имеш, бала да аның кебек озын гомерле булыр, дип юраганнар. Ә юраган – юш килә, ди халык.

Беренче чәчне бөти итеп тагу йоласы бүген дә халык арасында яши..Чәчне алгач, үлчәп, көмеш яки алтын бәясе белән исәпләп, авылның иң мохтаҗ кешесенә сәдака илтеп биргәннәр.

**Бәби мунчасы**... Татар авылларында мунчалар су буенда, йорттан ерак урнашкан булган. Судан ерак торган урамнарда яшәүче хәлсезрәк кешеләрнең мунчасы бөтенләй дә булмаган. 20 гасырның 50-60 елларында авылга 7-8 мунча булып, чираттан ягып кергәннәр.

Бәби мунчасы якканда бер чиләк-көянтә су кертсәң, саваплы саналган. Чөнки яңа гына бала тудырган анага су китерергә ярамый. Бөтен авыл халкы бу мунчага су китереп, савап ала торган булган. Бәби мунчасына ялгыз карчыкны керткәннәр, атна саен диярлек. Чөнки аның мунчасы юк, ягып керерлек мөмкинлеге дә чамалы. Ялгыз карчыкны мунчага кертү бу гаиләгә бик зур савап. Гел яхшылык эшләп яшәгән борынгылар. Хәзер су краннан гына килә. Шулай да мунчага йөрү гадәте бенең авылда яши әле. Туганнар, күршеләр бер-берсенә мунчага йөриләр.

Бала тугач тагын бер гамәл – **Гакыйка корбаны чалу**. Ир бала туса ике, кыз бала туса берне. Гакыйка корбаны чалу - шулай ук пәйгамбәребездән калган сөннәт гамәл. Яшь парлар бу сөннәтне дә бик теләп башкаралар. Корбан ите туганнарга, күршеләргә, ятимнәргә таратыла.

Безнең халкыбызда матур бер йола – “Бәби чәе” үткәрү сакланып килә. Коръән укыла, балага, гаиләгә бәхет теләп, туганнар дуслар бүләкләр бирәләр.

## III бүлек

## 3.1 КАЗ ӨМӘСЕ БӘЙРӘМЕ

Көзге кышкы күмәк йолалар һәм бәйрәмнәр арасында өмә аерым бер урын тота. Безнең борынгы әби-бабайлар казны бик яратканнар. Беренчедән,аның мамыгыннан мендәр, түшәк, ястыклар ясаганнар. Билгеле булганча, мендәр өеменнән башка татар йортын күз алдына китереп тә булмый. Икенчедән, каз итеннән аш-су өчен бик әйбәтләп файдалана белгәннәр, шулпасын да яратып ашаганнар. Күп төрле каз ашлары турында әйтәсе дә түгел; каз бәлеше, каз коймагы, каз тәбикмәге, каклаган каз... Каз маен хәтта дәвалау өчен саклаганнар: кышкы суыкларда бит ,колак очлары өшесә, каз мае сөрткәннәр.

Инде борынгыдан калган йолаларга килсәк, анда каз билгеле бер урын алып торган. Улы яки кызының үз тормышын корыр вакыты җитсә, ана кеше берничә казын туйга дип саклап тоткан. Чөнки пар каз-ул туйның хөрмәтле күчтәнәче. Матур табакка салып казны туй мәҗелесенең түренә чыгарганнар.

Каз күтәреп килгән “күчтәнәчле кунак” башка вакытта да, гадәттә, аерым хөрмәткә лаек саналган**.**

Яшьләр өмәгә бик теләп барган, авыр эшләрне дә бәйрәм кебек итеп башкарып чыга белгән. Йолкыган казларны көянтәгә асып кызлар чишмәгә, су буена юл тотканнар. Анда барып казларны салкын чишмә суында чайкый-чайкый юганнар. Чишмәгә бару-үзе бер

йола белән бәйле. Кызлар, гадәттә, гармуннарын алып,егетләр иярә торган булган. Монда да җыр, такмак әйтү, чишмә буенда биюләр башкарылган.

Казларны юып кайтуга хуҗабикә каз маенда бик әйбәтләп коймак, я тәбикмәк пешереп, чәй әзерләп көтеп тора. Ә аш-бәлешләр кич белән була. Кичке мәҗелес тәмамлануга, шул йортта төрле уеннар оештырылган.

**IV бүлек.**

## 4.1 Сабан туе

Бик күп төрле уеннарны, йолаларны үз эченә алган, татар халкының ел буе көтеп алына торган иң матур бер бәйрәме бар. Ул – Сабан туе. Бу бәйрәм – бик борынгыдан килгән бәйрәм.

Элек ул кыр эшләре башлануга багышлана торган булган. Ә хәзер Сабан туе язгы кыр эшләре беткәч, буш вакытта үткәрелә.

Элек-электән татар кызы үзенә бирнә әзерләгән. Сөлгене үзе чиккән. Иң матур сөлгене ул Сабан туе өчен әзерләгән. Бу йола хәзерге көнгә кадәр дәвам итә.

Сабантуй бәйрәме ‒ татар халкының иң олы бәйрәмнәренең берсе. Иң элек Сабантуй үткәрү өчен мәйдан әзерлиләр. Иртәгә Сабантуй буласы көнне авыл яшьләре, урам буйлап гармуннар уйнап, җырлап-биеп, хуҗабикәләрдән, яшь киленнәрдән Сабан туе өчен махсус әзерләнгән бүләкләр җыеп, халыкны бәйрәмгә чакырып йөриләр. Бу «Сөлге җыю» дип атала.

Икенче көнне матур итеп бизәлгән мәйданга бәйрәмчә киенгән халык җыела. Бәйрәмнең иң күңелле һәм дулкындыргыч өлеше – ат чабышы. Атларның һәрберсенә дә чиккән сөлге бәйлиләр. Сабан туенда үзәк урынны, әлбәттә, татарча көрәш алып тора. Көрәштә батыр калган кешегә зур тәкә бүләк ителә. Капчык сугышы, чүлмәк вату, капчык киеп һәм кашык кабып йөгерү – болар барысы да Сабан туенда гына уйналганнар. Мәйданда артистлар да чыгыш ясый. Алар бииләр, җырлыйлар. Балалар да күңел ачалар, төрле уеннарда катнашалар. Ярышлар һәм уеннар беткәч, кешеләр өйләренә кайталар. Һәр йортта табын әзерләнә, бәйрәм ашлары пешерелә.

**V бүлек**

## 5.1 Сөмбелә

Татар халкының онытыла башлаган матур бәйрәмнәренең берсе – Сөмбелә бәйрәме. Ул көзге бәйрәм, уңыш бәйрәме.

Көз көне халык мул уңыш җыеп ала һәм көн белән төн тигезлшкән чакта – 21-23 сентябрь көннәрендә Сөмбелә бәйрәме уздырыла.

“Сөмбелә” – башак дигән сүз, шуңа күрә бәйрәмнең төп атрибутлары – башак һәм Сөмбелә исемле кыз.

Бәйрәм башында бәйрәмнең хуҗабикәсен сайлаганнар. Ул чибәр, уңган кыз булган. Аны Сөембикә дип атаганнар. Сөембикәне башаклар белән бизәлгән тәхеткә утыртканнар.

Бу көнне мул итеп ризык пешерелгән, кешеләр өйдән-өйгә йөреп, җырлап-биеп күңел ачканнар. Сөмбелә итеп киендергән кызны мәйданга чыгара торган булганнар. Сөмбеләне төрле биремнәр, сораулар белән сынаганнар. Бергәләп күңел ачканнар.

**Йомгаклау**

Туган ягыбызның, борынгы бабаларыбызның үткәнен, милли гореф-гадәт, йолаларыбыз хакында өйрәнеп шуны төшендем:гаҗәеп бай күңелле, тырыш, изге җанлы икән безнең милләтебез. Горурланып сөйләрлек үткәне, төрледән-төрле йолалары ,матур бәйрәмнәре – үзе бер рухи байлык.Тарихыбызның гыйбрәтле һәм сокландыргыч сәхифәләренең, халкыбызның рухи мирасының бәяләп бетергесез кыйммәткә ия булуын аңлаганда гына күңелдә милләтең өчен горурлык хисе туарга мөмкин шул.Милләтебезнең саф, иманлы, горурланырлык шәхесләре хакында өйрәнү тагын да зур ләззәт бирде күңелгә.

«Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», - диләр. Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребезне, йола, гореф-гадәтләребез яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәрелә башлады. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә, әби-бабайларыбыз югары уку йортлары тәмамламаган, ә гореф-гадәтләр, йолалар, дини белемнәр аша тирән белемле, әхлаклы, иманлы, мәдәниятле булып яшәгәннәр. Без, яшь буын, шул кануннарны тәрбиябезгә, яшәешебезгә нигез итеп алып,  алга атлыйк.

**Кулланылган әдәбият**


1. Ф.С.Баязитов “Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары”.
2. К.В. Закирова, Р.Ә.Кадыйрова “Әхлак нигезе – матур гадәт”.
3. Нәкый Исәнбәт “Балалар фольклоры”.

4.Уразманова Р.К. Свадебные обряды // Татары. М., 2001.

5.Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа: историко-этнограф. исслед. Казань, 1984.

6. Р.Ф.Ягъфаров “Татар халкының уен фольклоры”.


**ИНТЕРНЕТСАЙТЛАР**


1.http://www.musical-sad.ru/forum/10-63-4

2. http://www.numama.ru/blogs/kopilka-detskih-stihov/stihi-o-varezhkah.html

3. http://www.maaam.ru

4. http://dohcolonoc.ru/

5.https://tatarica.org/tat/razdely/narody/tatary/obryady-i-prazdniki/gail-jolalary/tuj-jolalary Онлайн - энциклопедия Tatarica

*Әһлиуллина Язилә, 6 нчы сыйныф,*
*Татарстан республикасы Әлки муниципаль районы Нәби Дәүли исемендәге Базарлы Матак гимназиясе муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе*
*Җитәкче: Әһлиуллина Лилия Шәүкәт кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Укытучым – күңел кояшым**

Мәктәбемә ашкынамын һәркөн,
Уйларымда якты хыяллар.
Укытучым, беләм һәм тоямын
Мине анда көткән  кеше бар.
Һәрбер иртә көнем башланадыр
Синең сихри, назлы караштан.
Укытучым, киңәшләрең белән
Гомер юлларында адашмам.
Өйрәтәсең тормыш серләренә
Бик җентекләп, тирән аңлатып.
Укытучым, алгы көннәремне
Сабакларың торыр яктыртып.
Укытучым, син күңел кояшым,
Яктыртасың барыр юлымны.
Күзалларга мине өйрәтәсең
Киләчәкне, алгы көнемне.

**Мәктәбем**

**(җыр тексты)**

Мәктәбем – белем йорты
Балкый нурың еррактан.
Ашкынып киләм сиңа
Һәм шатланып һәр иртән
Кушымта:
Мәктәп – гөлбакча

Мәктәп – туган йорт

Шуны онытма,

Син исеңдә тот.

Чыңлый көмеш кыңгырау

Дәрескә туплый безне.

Мәктәптә өйрәнәбез

Табарга үзебезне.

Кушымта:

Мәктәп – гөлбакча

Мәктәп – туган йорт

Шуны онытма,

Син исеңдә тот.

Кеше күң(е)лендә мәктәп

Аерым урын тота.

Картайгач искә алып

Һәркем күңел юата.

Кушымта:

Мәктәп – гөлбакча

Мәктәп – туган йорт

Шуны онытма,

Син исеңдә тот.

*Галактионова Регина, 9 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Фәрхетдинова Фәнирә Гарәф кызы, Сәлимова Гүзәлия Рәшит кызы*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## **Ахуновлар шәҗәрәсе**

### **КЕРЕШ**

Олы диңгез елгалардан җыелса, ә халкыбыз тарихы, нәсел җепләре ,нәкъ шулай ук, эре һәм вак берәмлекләрдән, чыганак һәм фактлардан җыйналып, чын олы тарихка әйләнә.

Казан ханлыгы калалары җиме релгәннән соң, тарихның икътисады, мәдәнияте һәм әдәбияты нигездә авылда формалаша. Күп кенә  тарихи язмалар да монда туа. Алар арасында авыл тарихлары, анда теркәлгән яисә аерым сакланган шәҗәрәләр зур урын алып тора. Әйе, татарда элек-электән бик күркәм вә кирәкле бер гадәт яшәп килгән: һәр авылның диярлек үз тарихчысы, көндәлек вакыйгаларны кәгазьгә теркәп баручы изге заты булган. Аларның кулъязмалары буыннан - буынга мирас булып күчкән. Аларда халкыбызның олуг тарихын тулыландыра алырдай күпме мәгълүмат һәм истәлекләр тупланган!

Ахуновлар нәселе – безнең гаиләнең нәсел шәҗәрәсе шуннан башлана инде. Әниемнең нәсел ботакларына килгәндә, ул Арслановка барып тоташа.  Нәселебез турында күбрәк мәгълүмат туплау өчен төп **максат** итеп  үз нәселеңнең  тарихын,  гореф - гадәтләрен өйрәнүне, нәсел агачын төзүне һәм аны киләчәк буынга  тапшыруны куйдым. Максатны ачыклау өчен  түбәндәге **бурычларны** билгеләдем**.**

1. Нәсел агачына кергән нәселдәшләрем, туганннарым турында мәгълүмат җыю.

2 Тарихи материаллар, биографияләр,фоторәсемнәр җыеп, иң күренекле туганнарым турында сөйләү.

3. Исән булган иң олы туганнар белән очрашу.

4. Шәҗәрәләр төзергә өйрәнү

5. Туганнарыма карата мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

**Актуальлеге.** Без, хәзерге заман балалар, үткән буын әби- бабаларыбыз турында аз беләбез, ә борынгы бабаларыбыз моны тугыз буынга кадәр белергә тиеш дип санаганнар, һәм мин шуның өчен дә үз нәсел агачымны төзү белән шөгыльләнә башладым.

Практик үзенчәлеге. Факультатив шөгыльләрдә укучыларны нәсел агачы төзергә өйрәтү.

**Эзләнү методы**

1. Әти- әнидән, әби- бабайдан сорашу.

2. Гаилә документларын , фотоларын карау,өйрәнү.

3.Туганнар турында матбугатта басылган  мәкалә- язмаларны өйрәнү.

4.Анкета үткәрү.

Эксперимент предметы. Ахуновлар гаиләсе. **Гипотеза.** Әгәрдә мин әти – әнием белән фотосүрәтләр, архив документлары ярдәмендә гаилә хроникасын өйрәнсәм, без нәсел агачы төзиячәкбез.

## 1 БҮЛЕК. ТАРИХ ОЗАККА БАРА УЛ, ТАРИХ МӘҢГЕГӘ КАЛА.

### 1.1. ТАРИХ НИ СӨЙЛИ?

Мине һәрвакытта да туган ил, гаиләм, туган нәселдәшләрем тарихы кызыксындыра.Туган як тарихыннан читкә китеп тә, үз нәселеңне белмичә яшәп, туган ил тарихын өйрәнү мөмкин түгел.

Минем туганлык җепләрем кайсы яклардан сузылган соң?

Исеме җырларга әйләнгән, борма-борма юллар ясап тыныч кына агып ятучы Зәй елгасының бер куенына урнашкан, урманнарының тигезлеге, йортларның төзеклеге, халкының тырышлыгы белән сокландыра торган Каенлы авылы ул!

Түбән Кама районындагы Каенлы дип йөртелгән авылның Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр ике исеме була: Җирекле (яки Татар Җиреклесе) һәм Каенлы. Бу авылдан ике километр гына ераклыкта икенче бер авыл да шул ук Җирекле исеме белән аталганлыктан, авылларның исемнәре алдында сыйфат куеп, берсен - хәзерге Каенлыны – Татар Җиреклесе дип, ә икенчесе Керәшен Җиреклесе дип атап йөрткәннәр. Элек Зирекле, Каенлы, ә хәзер бары тик Каенлы гына дип йөртелгән бу авыл кайдан һәм кайчан барлыкка килгән соң?

Хәзерге көндә Каенлы авылы Татарстан Республикасына керсә дә, Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр ул административ бүленеш буенча Уфа губернасына кергән. Уфа губернасы, Минзәлә өязе, Сухрау волосте, Каенлы авылы - авылының тулы һәм төгәл адресы шундый булган. Каенлы кешеләре Мамадыш районының Кече авылыннан күчеп килгән. Каенлы – Зиреклегә беренче булып төпләнүчеләр Сәмикол, Рәхимкол, Миңлебай, Бикбау, Сиражетдиннәр белән бергә, бер чирмеш тә (мари) була. Соңрак күчүчеләр арасында да була алар. Чирмешләрне өлҗәдән килделәр, дип сөйләгәннәр. Беренче булып урнашкан чирмешнең җиде кызы булган. Авыл зираты ике өлешкә бүленгән була, аның авыл ягына (Зәй елгасына) караган өлешенә – татарлар, ә көньяк – көнбатышка караган өлешенә чирмешләр күмелгән. Хәзерге вакытта бу милләт кешеләрен чирмешләр, дип түгел, ә марилар, дип кенә йөртәләр. Бер үк авылда татарлар да, марилар да тату яшәгәннәр. Бу инде ике милләт кешесенең ныклап аралашуына, гаилә коруга кадәр китереп җиткергән. Тора – бара чирмешләр ислам динен кабул итәләр, тик аңа кадәр чирмеш буларак ничә буын яшәгәнлеге генә билгесез.

Авылга башта берничә генә хуҗалык килеп урнашкан булса, килүчеләр саны арта бара. Чирмеш нәселеннән булган Зөбәер улы Гыймади бай бик усал, кире беткән сәүдәгәр була. Ул сәүдә белән ерак – ерак авылларга, чит өязләргә чыккан. Берничә айлар йөреп кайткан. Берсендә ул гаҗәеп бер әйбер – ялтырап торган җиз самавыр алып кайта. Бу самавырны күрү өчен авылның аягында йөри алучы һәр кеше килгән. Авылдашлары кунак килгәндә, туйлар уздырганда бу самавырны сорап ала торган булалар. Самавыр бар, ләкин чәйнеге юк. Беркадәр вакыттан соң Гыймади бай чәйнек тә алып кайта.

Авылга беренче тимер сабанны Юлдаш нәселеннән килүче Исхак улы Хәмидулла 1894 елда Зәйдән 26 сум 15 тиенгә алып кайткан. Сабан "Зингер" маркалы була. Ләкин ул вакытта сабаннар ике ат тартышлы, ике калаклы итеп эшләнгән була. XX нче гасырга чыккач, бу тирәдә Ширәмәт тимерчеләре бертуган Смышляевлар бер ат тартышлы берле сабаннар эшләүне үзләштерәләр Һәм, бу як крестьяннары махсус заказ биреп, алардан берле сабаннар эшләтеп ала башлыйлар. Соңга таба мондый сабаннарны заводларда җитештерәләр.

1850 елда, халык теле белән әйткәндә, рәбиз була, ягъни ревизия – ир җенесеннән булганнарның санын алу үткәрелә. Җир бары тик ирләргә генә бирелгәнлектән, халык санын алу да ирләр белән чикләнгән. Ревизия күрсәткәнчә, Каенлыда ирләр саны 242 була. Шул елда булган барлык чәчүлек җирләрен һәм болыннарны 242 гә тигезләп бүлгәннәр. Шуннан соң озак еллар буена җир бүленми торган. Ул 12 елга бер мәртәбә бүленергә тиеш. Үлгән ирләрне сызып, 12 ел эчендә туган ир балаларны кертеп, җирне бүлик, диючеләргә каршы үзләрен "рибизни", дип йөртүче халык, җир хуҗалары, ирләр: "Без имананы түләп бетердек, бүлмибез - дип приговорга тамга салмыйлар һәм шунлыктан озак еллар буе җир бүленми торган. Җир өләшенгәннән соң, кешеләрнең аерылып чыккан улларына кырдан йорт салу өчен җир мәйданы бирү булмаган. Чөнки басу капкасын чыгуга ук җир инде кемгә дә булса бирелгән, ул берәүнең билгеле бер вакытка кадәр шәхси милеккә әверелгән. Шуңа күрә аерылып чыгучы кеше йорт урыны бөтен булган башка берәү белән сөйләшеп,аның ярты пуҗымына гына урнаша ала. Шуның аркасында күпләрнең йорт урыннары бик тар.

## 2 БҮЛЕК. АХУНОВЛАР НӘСЕЛ АГАЧЫ ШӘҖӘРӘСЕН БАРЛЫЙ.

### 2.1. АХУНОВЛАРНЫҢ НӘСЕЛ АГАЧЫ - ШӘҖӘРӘСЕ.

Бу эшемне язганда ярдәм итүче Саимә әби булды.Ул Гамир бабамның бертуган апасы. Хәзерге вакытта Каенлы авылында яши. Нәсел турындагы төшенчәне бозмас өчен,шәҗәрә ирләр ягыннан төзелде. Метрика кенәгәләреннән һәм ревизия сказкаларыннан чыгып, иң элек беренче буынны- төп бабайны Ишмөхәммәт Арслановны билгеләдем. (1759-1834елга кадәр). Ул –беренче буынның һәм шәҗәрәдәге бөтен буыннарның һәм кешеләрнең бабасы.

Икенче буынга. Ишмөхәммәтнең ике малае була: Бикҗан һәм Хәлимҗан. Бикҗанның 5 хатыны, 3 улы, ә инде Хәлимҗанның 2 хатыны, 8 малае булганы билгеле.

Өченче буында Гобәйдулла бабай 1803- 1844 нче елларда яшәгән.Хатыны әби (1843 ел).

Гобәйдулла бабай 4 нче буынга кергә. 1829 нчы елны Әхмәтҗан бабай туа. Аның ике хатыны- Хөббелниса (1825-1866) һәм Бибифатыйма була. Бишенче буын бабам –

Ахунҗанны 1868 нче елда Бибифатыйма таба. Ахунҗан бабайлар гаиләдә 7 малай булганы билгеле.

Алтынчы буын бабам- Сабирҗан 1895 елда туа. Аның әнисе Таифә Хисаметдин кызы. Ул 1875 елда Каенлы авылында туа. Әбием Таифә бабам Ахунҗан 1894 елда никахлашканнар. Сабирҗан бабайның Хуҗаҗан, Ибраһим, Гарифҗан, Габделәхәт, Габделҗәмил исемле энеләре була. Җиденче буын балаларын Ташлык кызы Миңлеһәдия дөньяга тудыра. Алар : Гамир, Хазим, Саимә, Икълимә, ә Гамир минем бабам. Ул әниемнең бабасы

Сабирҗан бабайның Хуҗаҗан, Ибраһим, Гарифҗан, Габделәхәт, Габделҗәмил исемле энеләре була. Шунысы билгеле, 20 нче августның 2015 елында Габделҗәмилнең 100 яшьлеге билгеләп үтелде.

Бу мәҗлесне Җәмилнең улы – Дамир оештырды.Дамир абый Чаллы шәһәрендә гомер итә.Каенлы зиратына барып, ташларына Ахунов фамилиясе язылганнарга чәчәкләр салды.

Менә 1942 елның 14 апреле. Сабирҗан бабайга повестка килгән көн .Авыл халкы җыйнаулашып Сабир бабайны армиягә озата. 23 нче март көне Сабирҗан бабай немец пулясыннан үлә. Кабере-Кенигсберг, Польша, Пруссия, Гданск 7нче каберлек

## ЙОМГАКЛАУ

Фәнни эшемне тәмамлап шуны әйтергә кирәк, милләтебезнең киләчәге өметле, әгәр дә һәр нәсел гаилә төзеп, сау -–сәламәт балалар тәрбияләсә .

Нәсел агачлары корымасын алар гел тармакланып торсын.

## КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. “Әй, Каенлым, Каенлым” Саимә Сөләйманова Казан “Милли китап”нәшрияты 2009.

2. Каенлы авылы тарихы Фәхри Шәрәфиев Казан “Сүз” 2009.

3. “Зәй сулары ага тора ...”. Саимә Сөләйманова . Татарстан Республикасы, Түбән Кама.”Гүзәл” НПҮ ААҖ. 2013 ел.

4.Кульъязмалар, архив материаллар,гаилә фотолары.

*Галимова Айназ, 7 нче сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Мөслим гимназиясе» МББУ (мәктәп-электрон белем бирүдә компетенция үзәге)*

*Җитәкчесе: Ирина Владимир кызы Латыпова*

*башлангыч сыйныф укытучысы*

## «Каенсаз авылы Йолдызлы урамының исеме тарихы»

## Кереш сүз

Туган якны өйрәнү белән кызыксынучылар саны арта бара. Әлеге тема популярлаша да кебек. Ул – укыту һәм тәрбияләүне тормыш белән бәйләүче иң мөһим чараларның берсе, бу белемнәр илнең һәм кече Ватанның мәдәни мирасына кушылырга мөмкинлек бирә. Туган якны өйрәнү эшенең максаты үз халкын, җирне, төбәкне, Ватанны яратырга, хөрмәт итәргә өйрәнү. Туган якны өйрәнү үткән замана белән тыгыз бәйле, шуңа күрә без, мәктәп укучылары, үз тамырларыбызны белеп, лаеклы киләчәк булдыра алабыз. Туган якның тарихын белү туган якка, Ватаныбызга, аның рухи мәдәниятенә мәхәббәтле булырга, тамырларны белүгә җәлеп итә.

Әлеге тикшерү проектының объекты – Мөслим муниципаль районы Каенсаз авылындагы Йолдызлы (Звездная) урамы. Проект өстендә эш башлаган вакытта урамның исеме ниндидер вакыйга белән бәйле дигән гипотеза каралды. Бу теория фәнни әдәбиятта ачыкланмаган, безнең проект эше авылның өлкән халкы белән шәхси аралашу нигезендә төзелгән. Тема очраклы гына сайланмаган. Анкета аша Каенсазда яшәүче дусларым өчен дә теманың актуальлеге тикшерелде. Сораштыру нәтиҗәсе буенча, үсеп баручы буынның да әлеге тема белән кызыксынуы һәм төрле фактлар белүе ачыкланды. Йолдызлы урамында яшәүче өлкәннәр белән әңгәмәдә урамның төзелеше, авылда урнашу тарихы һәм исеменең тарихы белән бәйле сорауларга зур игътибар бирелде. Интернет-чыганаклар аша авыл тарихы турында шактый мәгълүматлар табылды. Проект эше барышында сораштыру, әңгәмә, гаилә архивлары, интернет чыганаклар белән эшләү кебек ысуллар кулланылды. Нәтиҗәдә, гипотеза расланды: Йолдызлы урамының исеме, хактан да, тарихи вакыйга белән бәйле. Тикшеренү интернет чыганакларыннан алынган фотолар һәм шәхси архивлардан алынган фотолар белән бергә барды. Минемчә, тикшеренү нәтиҗәләре укытучыларга да, ата-аналарга да, шулай ук кечкенә Ватанын яраткан, аның киләчәге хакында кайгырткан һәм үткәннәрне хәтерләгән һәркемгә дә кызыклы булачак. Проектның материаллары белән танышу да, һичшиксез, минем дусларымда кызыксыну хисе уятачак.

Урам исемнәре – тарихи мирасыбызның мөһим өлеше. Урам исемнәре аларның “визит карточкасы” гына түгел, ә шул чорның үзенчәлеге, борынгы заманнардан сакланып калган һәйкәле дисәк тә, ялгышмасбыз. Урам исемнәре тиз арада барлыкка килмәгән, аларның тарихы вакыт тирәнлегеннән килә, безнең ата-бабаларыбызның тарихларын өйрәтә. Каенсаз авылы, башка авыллар кебек үк, үз тарихы, үз халкы белән уникаль, әмма мин әбием яшәгән урамның исемен, Йолдызлы урамның килеп чыгышын белергә теләдем.

## Теманың актуальлеге

Без, үсеп килүче буын, җирлегебезне белергә һәм өйрәнергә, үткәннәрне истә тотарга һәм хөрмәт итәргә тиеш. Без кызыксынган тема безнең өчен һәм авылдашларыбыз өчен дә актуаль. Дөньяда яшәүче һәр кешенең язмышы ул – тарих, ә урамның барлыкка килүе – буыннар тарихы. Авыл һәм авыл урамнары тарихыннан ил тарихы языла. Әлеге эш нәтиҗәсендә, туган якны өйрәнү буенча материаллар архивы әкренләп барлыкка килә.

Шулай итеп, "Каенсаз авылы Йолдызлы урамының исеме тарихы" темасы зур тарихны өйрәнүгә кызыксыну тудыра.

**Эшнең максаты:** Каенсаз авылының Йолдызлы урамының барлыкка килүе һәм төзелеш тарихын өйрәнү.

**Бурычлар**

– авыл тарихы буенча төрле чыганаклардан мәгълүмат туплау;

– әлеге урамда яшәүче өлкән буын вәкилләре белән әңгәмә булдыру һәм урамның барлыкка килүе турында материал җыю;

– Каенсаз авылында яшәүче дусларыма анкета тутырту, сораштыру үткәрү.

**Гипотеза:** Йолдызлы урамы исемендә авыл тарихы чагыла.

**Тикшерү ысуллары**: анкеталау; өлкән буын вәкилләре белән очрашулар һәм әңгәмәләр алып бару; туган якны өйрәнү, музей материаллары белән танышу, интернет чыганаклары, гаилә архивлары белән эшләү.

**Төп өлеше**

Каенсаз... җир шарындагы кечкенә генә нокта. Аны һәр картада таба алмыйсың, ул кырлар һәм урманнар, таулар һәм чокырлар арасында югалган авыл... Монда минем әби-бабайларым туган, монда минем балачагым уза.

Каенсаз авылы Мөслимнән 25 километр ераклыкта урнашкан. Ул 1902 нче елда барлыкка килгән. Каенсаз авылының барлыкка килүе турында төрле аңлатмалар ишетергә туры килде. Өлкәннәр авыл территориясе элек каен урманнары һәм сазлыклар белән капланган булган, дип сөйлиләр. Иң элек, бу урынга бары тик берничә гаилә генә күченгән, шул вакытта авылга Каен-Саз исемен биргәннәр (каен-каен, саз-болын).

Вакытлар уза бара бу авылда ике урам барлыкка килә. Хәзерге вакытта җирлектә бер генә урам калган. Ул – Йолдызлы исемен йөртә. Электән үк, исемнәр очраклы гына бирелмәгән дигән фикерләр булды. Әлеге фикернең дөреслеген мин сезгә хәзер исбатлармын.

Йолдызлы урамына авыл янында төшкән метеорит хөрмәтенә исем кушканнар. 20 нче гасырның 90 нчы елларында авыл урамнарына исемнәр бирелә башлый. Авылда бер генә урам булса да, аның исеме булырга тиеш. Бу хакта без авыл советының элеккеге секретаре Галимова Зәйтүнә Сабировнаның сөйләгәннәреннән белдек. Авыл советларының

башкарма комитетларына урамнарга исемнәр бирү бурычы куелган. Алар бу вакыйганы искә алып урамны Йолдызлы дип атаганар.

87 ел элек, 1937 нче елның 13 нче сентябрендә, Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы (ТАССР) территориясендә, Мөслим районының Каенсаз авылы янында, 15 сәгать 15 минутта, пирамида формасындагы метеорит төшә. Болытсыз күктән төшкәндә кыска утлы койрыгы һәм томанлы эзе булган кабат бүленгән болид күзәтелә. Шаһитлар очучы самолет тавышына охшаган тавыш ишеткәннәр, аннан тыш, 5-6 шартлау да ишетелгән төсле тоелган. Метеоритның кайбер фрагментлары җиргә бәрелгән вакытта 10 метрга кадәр тузан болыты күренгән. «Каинсаз» исемен алган метеорит яңгыр астында калган. Бүгенге көндә әлеге метеоритның 15 элементы табылган, аларның гомуми авырлыгы 210 килограммнан артык (һәр элементның авырлыгы 8 граммнан алып 102,5 килограммга кадәр).

Энциклопедияләрдән алынган мәгълүматлар буенча, метеоритлар – планеталар арасыннан Җиргә төшүче җисемнәр. «Известия» газетасы 1937 нче елның 27 нче октябрендә болай дип язган: *«13 сентябрьдә Татарстанның Мөслим һәм Калинин районнары чигендә урнашкан «Каинсаз» колхозының басуында һәм урманда эре метеорит кисәкләре төште. Аларның берсе, илле дүрт килограмм авырлыкта, басуда эшләгән колхозчы Мәүлидә Бәдриеваны чак кына үтерми. Һава дулкыны шулкадәр көчле була, метеорит төшкән урыннан дүрт-биш метр ераклыкта булган Бадриева аяктан егылып контузияләнә. Йөз бер килограмм авырлыктагы зур кисәк урманга төшеп, агачларның ботакларын сындырган. Бу метеорит, төшү урыны буенча “Каинсаз” дип аталган. Ул СССР Фәннәр Академиясенең метеорит комиссиясенә китерелгән. Бу таш кисәк СССР Фәннәр академиясе коллекциясендә метеоритлар арасында иң эресе булып тора. Метеоритның өлешләрен эзләүдә җирле колхозчылар актив катнашкан.*

Шуңа өстәп, 1937 елның сентябрендә, «Каинсаз» метеоритын эзләгән һәркемнең исеме РФА метеоритлар коллекциясенең мактау тактасына кертелгән. 16 исемлектән торган документны Мөслим отряды начальнигы (ни өчендер исеме күрсәтелмичә) җитәкли. Эчке эшләр халык комиссарлыгы җитәкчесе Алтынбаев, Каенсаз авылыннан Бәдриева Мәүлидә, Галимов Гали, Нугумалов Баян һәм Мәрданов Шәйхәрдан; Мөслим районы Ташъелга авылыннан Багаев Мориәхмәт; Мөслим районы хезмәткәрләре Горяев һәм Кузьмин (исемнәре күрсәтелмәгән); Яңа Карамалы авылы Мөслим районыннан  Гатин Шакир һәм Максутов Рәшит (мәктәп укучысы); Мөслим мәктәбе директоры Халитов Мансур; мәктәп укучысы Королева Елена; Ташлыяр авылы Мөслим районыннан Фәтхуллин Мәхмүт; Смальков авылы, Куйбышев өлкәсе Исаклы районыннан Дагаев Н.; Мөслим районы Михайловка авылыннан Горбунова Клавдия һәм Богуруслан шәһәрендә яшәүче Афанасьев

Григорий. Аларның язмышларында тагын нинди хәлләр булганын мин белмим. Аларның смартфоннары, интернеты булса, алар бу коточкыч һәм гаҗәеп вакыйганы бәлки төшергән булырлар иде, без бу хакта күбрәк мәгълүмат туплар идек.

Метеоритка кире кайтыйк. Аны тапкач ук "Каинсаз" метеоритын өйрәнгән галимнәр әлеге матдәнең Кояш системасына яшьтәш булуы белән гаҗәпләнә: аның токымы 5 миллиард елдан артык булуы ачыклана. "Каинсаз" таш метеориты – күмерле хондрит, планетабызда сирәк очрый торган химик матдә (хондритлар үз атамаларын күбесенчә силикат составындагы сфероидаль формацияләр булу сәбәпле алганнар). Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, күмерле хондритларда («С» хәрефе белән билгеләнә) силикатларда булган күп тимер бар. Алар караракк, мондый төсне күмерле хондритларга минерал магнетит (Fe3O4), аз күләмдә графит, сажа һәм органик кушылмалар бирә. Күмерле хондритны газ хәленә җиткерсәң, гаҗәеп зур күләмдә энергия тупларга мөмкин (галимнәр фикеренчә, бер килограмм эретелгән метеориттан чыккан энергия гидроэлектростанциянең бер ел дәвамында булдырган электр энергиясе белән тигез). Космос тикшеренүләре чорына кадәр метеоритлар лаборатория анализы өчен ачык булган бердәнбер космик матдәләр булган. Хәзерге вакытта Казан дәүләт университетының Александр Штукенберг исемендәге Геология музеенда 52,375 килограмм һәм 27 килограмм авырлыктагы ике «Каинсаз» метеориты фрагменты саклана.

Хәзерге Татарстан территориясендә барлыгы 5 метеорит табылган, һәм аларның барысы да таштан килеп чыккан.

Каенсаз метеориты 20 нче гасырның иң куркыныч 10 метеоритына карый. Бу исемлеккә Калифорния, Аргентина, Индонезия, Кытай, Башкорт, Тунгус, Сихотэ -Алинь, Төрекмән кебек танылган метеоритлар кергән.

"Каинсаз" метеориты Татарстанның табигый тарих музееның «Җир һәм Галәм» залында урнашкан. Шулай ук, алдан әйткәнемчә, Казан федераль университетының геология музеенда да әлеге метеоритның элементлары саклана.

Кызык нәрсә.

Фиджи утраулары 2013 нче елда космик шарлы яшеннәр сериясендәге метеоритның кечкенә өлешләре белән ике яңа тәңкә чыгарды. Тәңкәләрдә Фиджи гербы һәм “FIJI, 10 DOLLARS 2013” язуы бар. Тәңкәнең аскы өлешендә метеорит фрагментлары белән капсулалар бар. Фиджиның 10 доллар номиналлы тәңкәләре 999 проба көмештән ясалган, авырлыгы 20 грамм, диаметры 40 миллиметр Тәнкәләрнең бер төре – “Каинсаз” исемен йөртә.

Вакыт үтә, авылдагы халык үзгәрә, ә «Йолдызлы» урамының исеме белән һаман да һәркем горурлана. Топонимик исемнәр тарих турында хәтерне саклый, үсеп килүче буынга үз торак пункты тарихының нечкәлекләрен белергә мөмкинлек бирә, горурлык хисе уята.

**Практик өлеш**

**Каенсаз авылында яшәүче яшьтәшләрдән анкета алу.**

Минем тикшеренү эшем Каенсаз авылында яшәүче яшьтәшләремә анкета бирү белән башланды. Мин аларга берничә сорау тәкъдим иттем (1 нче кушымта), аларга җавап бирүләрен сорадым .

Анкета нәтиҗәләре буенча мин түбәндәге нәтиҗәләргә килдем:

1. Авылда урамның Йолдызлы дип аталуын һәркем белә.
2. Күпчелек егет-кызлар Йолдызлы урамының тарихын белми.
3. Дусларымның һәркайсы үз урамының тарихын белергә тели.

**Нәтиҗә**

Халык үз белдеге белән һәм бик дөрес эзлекле рәвештә үз авылларының исемнәрендә килгән табигый-географик пейзаж үзенчәлекләрен чагылдыра.

Минем тикшеренү эшем практик әһәмияткә ия, чөнки системалаштырылган материалларны туган якны өйрәнү дәресләрен үткәргәндә, тематик сыйныф сәгатьләрендә, иҗади эшләр язганда кулланырга мөмкин.

Киләчәктә мин туган як топонимикасын өйрәнү эшен дәвам итәчәкмен: брошюра һәм фотоальбом ясыйчакмын...

**Мәгълүмат чыганаклары**


1.1 http://mv-toponim.narod.ru/toponimika.html

1.2 https://ru.wikipedia.org/wiki/

1.3 http://gruzdoff.ru/wiki/

2. Авыл халыкның хатирәләре:

2.1 Гусманова Гатифа 1925 елда туган

2.2 Варисов Суфиян,1930 елда туган

2.3.Варисов Идрис, 1928 елда туган.

2.4 Галимова Зәйтүнә 1943 елда туган

2.5 Нуриәхмәтова Мөглифә, 1927 елда туган

*Галимуллин Илькам, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы "Адымнар-Әлмәт" полилингваль гимназиясе" муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Сәлимҗановановa Алсу Илдар кызы, туган тел һәм әдәбият укытучысы*

## Әлмәт шәһәре “Ризаэддин Фәхреддин” исемендәге җәмигъ мәсҗиденең эшчәнлеге

### Кереш өлеш

Татар милләтенен язмышы ислам дине белән турыдан-туры бәйле. Дин безнең күп гасырлар дәвамында дәүләтле халык булып яшәвебездә зур роль уйнады, җәмгыятьтә әхлакый нормалар тәрбияләде, гомумән, татарны татар итеп саклап калуга узенең зур өлешен кертте. Мәчетләр турында язылган китаплар, төшерелгән фильмнар, архив материаллары күп. Бу материаллар белән танышу миңа кызыклы тоелды, шуңа күрә мин фәнни-тикшерү эшемнең темасы итеп “Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең мәчет тарихын” алдым.

Мин бу теманы бик актуаль дип саныйм. Чөнки соңгы елларда динебез, телебез, гореф-гадәтләребезгә карата игътибар арта бара, дини уку йортлары ачыла, мәчеткә халык елдан ел күбрәк тартыла. Туган ягыбызның мәчет тарихын белү – безнең бурычыбыз.

Мин материалларны туплап, моңарчы ачыкланмаган магълүматларны тикшереп нәтиҗәләр чыгаруны эшемнең проблемасы итеп куйдым.

Фәнни тикшерү эшемнең объекты: Әлмәт мөхтәсибәте һәм Ризаэддин Фәхреддин исемендәге җәмигъ-мәсҗиденең эшчәнлеге.

Максат: Әлмәт шәһәре “Ризаэддин Фәхреддин” мәчетенең тарихын тирәнтен өйрәнү.

Бурычлар:

- бүгенге көндә безнең арада булган өлкән буын кешеләре белән аралашып мәчетнең тормышы турында материал туплау;

- мәчет тарихын, имамнар язмышын архив материалларыннан һәм төрле чыганаклардан өйрәнү;

- газета-журналларда басылып чыккан мәкаләләрне файдалану,

- фотоматериаллар туплау.

Проект эшем: кереш өлештән, төп бүлектән, йомгаклаудан, библиографик исемлектән тора . Бу эш киләчәктә практик кулланыш табар дип уйлыйм.

Һәр авылның, шәһәрнең тарихы аерылгысыз рәвештә андагы мәчетләр Һәм дин тарихы белән бәйләнгән. Кызганыч ки, узган дәвердәге динне юк итү, милләтне җәберләү сәясәте барган вакытта мәчетләр җимерелгән, иң асыл затлар, укымышлы кешеләр һәм имамнар төрмәләргә ябылганнар, сөргенгә озатылганнар. Күп кенә җимерелгән мәчетләрнең тарихы югалган диярлек. Анда эшләгән имамнарның фаҗигале язмышы турында да мәгълүматлар бик аз һәм таркау хәлдә. Проект эшебезне башкару өчен үз алдыбызга шундый бурыч куйдык: дин һәм мәчетләр тарихын, дин әһелләре эшчәнлеген җентекләбрәк өйрәнеп, тулырак яктырту. Үзебездән соң килгән буыннарга тулырак мәгълүмат туплап калдыру. Проект эше һәм тупланган хезмәт моның белән генә чикләнмәс, тагын да ныграк тулыланып һәм баетылып югалмыйча, киләчәктәдә дәвам ителер.

## Төп өлеш

### 2.1. Мәчет турында мәгълүмат.

Әлмәттә Ризаэддин Фәхреддин исемендәге Үзәк мәчет, элекке исеме-мөселман дини-мәгърифәт үзәге. Р. Г. Галиева («Ринат» мәчете);

2002 елдан Р. Фәхреддин исемендәге җәмигъ мәчете.

Мәчет Әлмәтнең үзәк өлешендә урнашкан һәм әйләнә-тирә ландшафтка яхшы туры килгән. Карар Әлмәт татар иҗтимагый үзәгенең гомумшәһәр җыелышында кабул ителгән иде. Төзелешкә рөхсәт 1989 елның 14 апрелендә алынган.

Булачак мәчетнең нигезенә беренче таш 1990 елның 21 июнендә салынган. Аның төзелешенә беренче взносны Россия һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте кертелгән. Әмма акча җитмәгән һәм ТОЦ лидерлары (М.Зиннәтуллин, Ә.Сафуанов) шәһәр халкына, предприятиеләргә ярдәм сорап мөрәҗәгать иттерелгәннәр. Башта 4 кат (бинаның түбәсез тартмасы) төзелгән. 1990 еллар башында мәчет төзелеше туктатылган. 1995 елда генераль директор Р.Галиев җитәкчелегендәге «Татнефть» ААҖ ярдәме белән мәчет төзү процессы яңадан торгызылган. А. Л. Монасыйпов җитәкчелегендә дирекция төзелгән. 1998 елның 16 июнендә мәчетнең төп манарасын урнаштырганнар. Ачылу тантанасы 1998 елның 20 июнендә булган. Ачылу тантанасында Р.Г.Галиев тарафыннан аның төзелешенә керткән зур өлеше өчен мәчетне аның исеме белән атарга карар кылынган иде. Шул ук вакытта истәлек тактасы да урнаштырганнар (2002 елда ул яңасына алыштырылган иде).

Мәчет төзелешенә шулай ук әлмәтлеләр, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе шәһәрләрендә яшәүчеләр дә үз акчаларын кертелгәннәр. 1998 елның декабрендә мәчет каршында Әлмәт ислам мәдрәсәсе ачылган.

Әлмәт архитекторлары Җамалиев проекты буенча (идея авторы, проектның баш архитекторы) төзелгән. Мәүлетова (идеяне эшләүче), Ишукова (проект җитәкчесе)-барысы да «Татасельхозпроект» институтыннан; инженерлар – Абдуллин (проектның баш инженеры), Маслова, Гәрәев. Төзелеш инициаторы булып Әлмәт мөселманнары берләшмәсе рәисе С. Хәбибуллин чыгыш эшләнгән.

Мәчет дини корылма буларак кына түгел, ә заманча мәдәни архитектура һәйкәле буларак та кызыксыну уята. Традицион йоладан тыш, ул дини - мәгърифәт үзәге функциясен башкара, аңа конференц - зал, мәдрәсәнең уку класслары һәм башка бүлмәләр кергән. Аның архитектурасы түбәдәге манаралы мәчетләрнең коену биналарының типына карый.

Мәчеткә үзәк керү юлы зур портал рәвешендә хәл ителгән, аңа киң мәрмәр баскыч алып бара. Бинаның архитектура күләме ике тигез Кубадан гыйбарәт, ул аерым свай нигезләренә таяна; стеналар монолит билләр белән ныгытылган, 3-4 катлы бина кирпечтән төзелгән. 18 метр диаметрлы Авыш язылышбиек гөмбәз, нитрид титан өслекле нержавеющей корыч белән тышланган (алтын төсе-24 карата). Гөмбәз астында 24 һәм 24 метрлы икеветлы намаз залы урнаштырылган, ул 1200 намазга исәпләнгән. Бинаның фасадлары 2 каттагы биек вертикаль буенча атучы урыннар белән бүленгән. Бинаның Көньяк ягыннан чыгыш ясаучы михраб күләме тирән урын һәм чәчәк полосалары белән аерылып торачак. Бинаның стеналары штукатурланган. Мәчетнең манарасы бинаның Төньяк ярымыннан күтәрелә, ярымай астындагы алтын гөмбәз белән мәңгеләштерелә. Аның биеклеге 53,5 метр. 8 граняда тәрәзәләр киселгән һәм югары ярусада балконцик чыгыш ясый. Манара 20-23 метр тирәнлектәге аерым фундаментка таяна. Гөмбәзнең дүрт ягыннан төп манарасыннан тыш, мәчетнең квадрат метр күләме почмаклары буенча, манараларның зурлыгы буенча, 35,2 метр биеклектәге, чатырлы һәм балконлы 8 мирлы манаралар урнаштырылган. Фасадларның тыйнак төсле карары качак, кирпеч - Кызыл, алтынсу, Яшел (балконнар һәм манаралар чатырлары) һәм Ак (манаралар кыры һ.б. детальләр) чәчәк төсләрен үз эченә ала. Бинаның төньяк өлешендә 2 катта конференц - заллар һәм ярдәмче бүлмәләр (югары һәм цоколь катларында) урнашкан. Беренче катта 120-140 укучыга исәпләнгән мәдрәсә сыйныфлары урнашкан. Декор буенча күпертелгән мәчетнең гыйбадәт залы интерьеры Көнчыгыш төсләренә хас булган бизәкле майолик плиткалар белән бизәлгән. Михраб

тимерпанның бай бизәлгән турыпочмаклы формасы булган урын рәвешендә ясалган. Ул гарәп Коръән язуларын кулланып, майолик плитәләре белән тышланган. Гөмбәз барабанындагы тәрәзәләр һәм аның астында төсле витражлар белән бизәлгән.

## 2.2. Әлмәт мөхтәсибәте һәм Ризаэддин Фәхреддин исемендәге җәмигъ-мәсҗиденең эшчәнлеге

1998 елның 20 июне чын мәгънәсендә халкыбыз тарихында лаеклы урын алачак. Бу көнне татар милләтенең, мөселманнарның озак еллар түземсезлек белән көткән хыялы тормышка аша. Әлмәт каласында Татарстанда гына түгел, Россиядә тиңе булмаган Диния, мәгърифәт һәм мәдәният мәркәзе ачыла. Ул бик авыр һәм мәшәкатьле төзелә. "Татнефть" оешмасы матди ярдәм күрсәтмәсә, бу изге йортны төзеп бетерү мөмкинлеге, бәлки, табылмас та иде. Әлеге бинаны төзүдә йөзләгән оешма, меңләгән кешенең өлеше керә. Мәркәзнең сафка басуы – күмәк эш нәтиҗәсе.

Беренчеләрдән булып мәчет төзелешенә "Татнефть", "Татжилстрой", Миңлебай газ эшкәртү заводы, "Әлмәтнефть", "Сөләйнефть", "Елховнефть", "Ямашнефть" идарәләре, "Радиоприбор" заводы, "Агропромхим" идарәсе һәм башкалар өлеш кертә. Мәчетнең ачылу көне аның нигезенә таш салу (1990 елның 21 июне) вакытына туры китерелә. Төзелеш барышында бинаны бизәкләү һәм архитектура корылышы һәрдаим үзгәртелеп тора. Архитекторлар аны бөтен көчләрен куеп камилләштерергә тырыша. Диния мәркәзе Бөек Болгар иленең гыйбадәтханәләренә, Истамбул мәчетләренә охшатып төзелә.

Бина беренче карашка censors бербөтен булып күренсә дә, ул бертигез ике кубтан тора, алар исә аерым субай нигезгә терәлгән. Диварлары монолит пута белән ныгытылган. 53,5 метр биеклектәге төп манара да тирәнлеге 20-23 метрлы аерым нигезгә урнаштырылган. Баштагы чорда проект буенча манараның биеклеге 57 метр каралган була, аның кыскартылуы бик тә кызганыч, әлбәттә. 18 диаметрлы гөмбәз 24 каратлы алтын төсе йөгертелгән титан нитриды белән капланган тутыкмас корыч белән тышланган. Гыйбадәт кылу залына 1200 кеше урнаша ала. Уку бүлмәләре, таһарәтханәләр һәм башка максаттагы бүлмәләр бик иркен итеп эшләнгән. Шәрык стилендә бизәлгән, идән-басмаларына кадәр мәрмәр ташы җәелгән шушы мәчет мөэминнәрнең күңелләрен үзенә җәлеп итә.

Мәчет ачу тантанасы уңаеннан мәйданга ике мең чамасы кеше килә. Бәйрәмдә Россиядән, Бәйсез Дәүләтләр Берлегеннән, республиканың төрле төбәкләреннән, Иорданиядән, Кувейттан, Берләшкән гарәп әмирлекләреннән, Төркиядән бик күп кунаклар катнаша.

Бәйрәм театрлаштырылган "Тутыкмас ядкарь" дигән тарихи-драматик күренеш белән башлана. Ул халкыбызның рухи тормышын бик ачык итеп күрсәтә. Вакыйга 922 елның 13 маенда изге Болгар җирендә Ислам дине кабул ителүнең онытылмас бер мизгеле турында бара.

Тамашаны Әлмәт драма театры артистлары сәхнәләштерә. Алып баручыны – Илһам Мөхәммәтов, Алмыш ханны – Камил Вәлиев, ханбикәне – Венера Сафина, баш вәзирне – Рафыйк Таһиров, Багдад илчесе Сәһсән әр-Рәсибине – Марсель Зиннәтулла, илчелекнең сәркатибе Әхмәд ибн Фазланны – Фоат Зарипов һәм башкалар уйный. Күренештә мәчет төзүне башлап йөргән Сибгатулла Хәбибуллин һәм бинаны төзүдә зур өлеш керткән "Татнефть" җитәкчесе Ринат Галиев исемнәре дә еш ишетелә. Тамаша Багдад илчесе Сәһсән әр-Рәсибинең сүзләре белән: "Менә сезгә Коръән Кәрим! Аның кушканнарыннан тайпылмагыз. Менә сезгә кылыч! Иманыгызны, дәүләтегезне, халкыгызны мәңгегә саклагыз".

Татарстан Диния нәзарәте рәисе мөфти Госман хәзрәт Исхакый, мәчет төзелеше дирекциясе рәисе Әнгам Монасыйпов, Татарстан республикасы вице-премьеры Илгиз Хәйруллин (президентның сәламен җиткерә), район һәм шәһәр хакимияте башлыгы Илдус Гәрәев, Татарстан христианнары архиепископы Анастасий атакай, әлеге мәчетне төзүдә катнашкан Төркиянең "Ерда" бизәкләп кору компаниясе директоры Ирул Инҗан, Әлмәт мөхтәсибе Наил хәзрәт Сәхибҗан, “Татнефть” җитәкчесе Ринат Галиев мөселманнарны олуг бәйрәмнәре белән тәбриклиләр.

Ринат әфәнде Наил хәзрәткә мәчетнең символик алтын ачкычын тапшыра. Чыгышлар өлешен "Хәзинә" газетасы мөхәррире, шагыйрь Нур Әхмәди алып бара. Мәчеткә мәселманнар соравы буенча Ринат хаҗи Галиев исемен кушалар. Истәлек такталарын Госман хәзрәт Исхакый ача. Анда мондый юллар бар: "Татар халкын, динебезне киләчәк буыннарга саклау өмете белән Ринат хаҗи Галиев". Язулар татар, урыс, инглиз телләрендә бирелә.

Азан әйтелгәннән соң халык ташкыны, тәкбир әйтеп, мәчеткә ашыкса да, намаз укучылар сирәк була. Халыкның күбесе тамаша карарга гына килгән була. Мәчет янәшәсендә концерт куялар. Монысын да шәригать кануннарына килештереп булмыйдыр. Шулай да гаҗәеп дәрәҗәдә матур итеп төзелгән мәркәзебездән милләттәшләребезнең, мөселманнарның сукмагы өзелмәсен, ул халыкка нәтиҗәле хезмәт итсен, аны хак юлга бастырсын иде. Бәйрәм вакытында татар халкының тарихын язу буенча "Рухият" фонды каршындагы аерым фондка иганә акчасы кабул ителә. Беренче акчаны 10 мең сум күләмендә Ринат Галиев сала.

"Җәмигъ” мәчете ачылып, бер атна узуга 26 июньдә "Татнефть" акционерлары җыелышы алдыннан Татарстан президенты Минтимер Шәймиев Диния, мәгърифәт һәм мәдәният мәркәзендә булып, аның эшчәнлеге белән таныша. Үзәктә төзелеш рәисе Әнгам Монасыйпов, имам-мөхтәсиб Наил хәзрәт Сәхибҗан, "Татнефть" җитәкчесе Ринат Галиев, Әлмәт хакимияте башлыгы Илдус Гәрәев президент белән мөселманлыкның киләчәге турында әңгәмә кора.

Шушы бинада төбәгебезнең дин эшләре башлыгы Наил Әхмәд улы Сәхибҗан резиденциясе урнашкан була. Ул 1957 елда Әлмәттә туа. Бохарада "Мир-араб" мәдрәсәсендә (1987), Согуд Гарәбстанында имам Мөхәммәд бин Сауд исемендәге университетта укый (1996). СССР Диния нәзарәтендә техник секретарь (1976-1981), Пермь, Киров өлкәләре һәм Удмуртия республикасы имам-мөхтәсибе (1987-1993), Башкортстандагы Октябрьск шәһәре "Нурул-ислам" мәдрәсәсе проректоры (1993-1996), Әлмәт мөхтәсибе (1996), Татарстан республикасының көньяк-көнчыгыш төбәге буенча казый, Татарстан мөфтие урынбасары (1996). Җәмигь мәчетенең беренче имамы итеп Наил хәзрәт билгеләнә, икенче имам-хатыйб – Нәзир Галәветдин улы Әүһәдиев, Р.Фәхреддин исемендәге Ислам мәдрәсәсе ректоры – Җәмил Камил улы Халирахманов.

2011 елда Татарстанның көнчыгыш төбәге казые һәм Әлмәт районының имам-мөхтәсибе итеп Рәфыйк Минәхмәтов сайлана. Ул 1970 елда Башкортстанның Илеш районы Кадер авылында туа. Башкорт дәүләт университетының география-икътисад факультетында белем ала. "Нурул-Ислам" мәдрәсәсендә укып, чакыру буенча Гарәбстанда Мәдинә Ислам университетында гыйлем туплый. Укуын тәмамлагач, Чаллыда "Тәнзилә" хатын-кызлар мәдрәсәсенә укытучы һәм ректор урынбасары итеп билгеләнә. Бүген Әлмәт районы мөхтәсибәтенең эшчәнлеге күпкырлы, социаль яктан да бик әһәмиятле, мәсәлән: мәсҗидләр төзү һәм реконструкцияләү; дәгъват эшен башкару (җомга намазларында, массакүләм мәгълүмат чаралары аша, мәҗлесләрдә, бәйрәмнәрдә, очрашуларда, лекцияләрдә, әңгәмәләрдә).

Истәлек итеп калдыру өчен бу эшнең башкарылуын 38 градус эсселек булуына карамастан биш сәгать буена күзәтteләр һәм максатларына ирештеләр дә. "Знамя Труда" газетасы мөхәррире И.Гыйматов, фотохәбәрче Г.Буторин, "Әлмәт таңнары" газетасының мөхәррир урынбасары Д.Таҗи, "Татнефть” хәбәрләре"н алып баручы И.Мингәрәев һәм башкалар ошбу вакыйганың чын шаһитлары булдылар.

Гөмбәзне һәм манара очын күтәрүче кранчы, механикалаштырылган идарә хезмәткәре Рәмзилә Газизованың, монтажчы егетләрнең ыспай һәм җайлы эшләүләренә сокланмый мөмкин түгел иде. Гөмбәз астында алты мәртәбә куфи стилендә икенче "Аллаһу әгбәр" дип язылган.

Манараны куйганда кардәшебез Габделәзәл Ибраһимов булышты, Ул монда берничә еллар сантехник, эретеп ябыштыручы, каравылчы хезмәтен башкарды. Агропоселокта мөселман мәхәлләсе оештырып, яңа мәчеткә нигез салучыларның берсе ("Әлмәт таңнары" газетасыннан).

**IV. Кулланылган әдәбият.**


1. Әлмәт краевед һәм җәмәгать эшлеклесе Д.Таҗиевның кулъязмалары
2. Диннәр тарихы
3. Россия халыкларының рухи-әхлакый мәдәнияте нигезләре.



*Гиззатуллина Алисә, 6 нчы сыйныф,*

*Татарстан республикасы Тубэн Кама муниципаль районы “Инглиз телен тирэнтен ойрэну белэн 33 нче урта гомуми белем биру мэктэбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирю учреждениясе*

*Житэкчесе: Нургатина Раиля Раифовна, татар һәм әдәбияты укытучысы*


**Бетсә иде җирдә барган сугыш**

Өебездә иң зур ядкәр:
Муса абыйның сыны.
Илгә мәхәббәт җырлаган
Тамганда соңгы каны.
Муса абый, янныраңа килеп,
Бар моңнарымны сөйлим.
Җырга салып, зарларымны
Мин бары сиңа көйлим.
Бетсә иде җирдә барган сугыш,
Исән кайтса иде әтиләр.
Улларының шат йөзләрен күреп,
Тынычланса иде әниләр.

**Җавапсыз сорау**

Сеңлем мине йөдәтә,
Көнгә мең сору бирә.
Аңа җавап тапмыйча

«Котылам бик тиз», - димә.
Балык ник суда йөзә,
Дуңгыз сазлыкны сөзә,
Кошчыклар нигә оча,
Әни кызчыгын коча?
Кәҗәләр печән ашый,
Сыер нигә май ташый,
Күбәләк төрле төстә,
Самолет оча өстә?
Нигә сарык йөзә(а)лмый,
Бәти артыннан калмый,
Көне-төне эсседә
Ничек көтүче талмый?
Гөлләр ник чәчәк ата?
Сораудан башлар ката.
Мәктәптә ник укыйлар,
Казлар мине чукыйлар?
Диңгезләр нигә тозлы,
Елгалар кышын бозлы,
Чишмә суы ник тәмле,
Җәй айлары бик ямьле?
Кар нигә ап-ак була,
Өч яшьтән соң дүрт тула,
Кайнатма нигә татлы,
Чәк-чәк тә була баллы?
Менә шушы сорауларга
Мин көн дә җавап эзлим.
Журналлардан да укыйм,
Китап битләрен күзлим.
Ләкин әле берсенә дә
Җавап бирә алмадым.
Сорауларны тыңлый-тыңлый,
Аз гына да талмадым.

## Балыкчы

Әтиемә ияреп ,

Балыкка барам әле.

Мин дә балыкчы кебек

Зур кармак алам әле.

Тамак ачса, ашарбыз дип,

Кыяр, помидор алдык.

Итсез әбәт булмас диеп,

Казылык та без салдык.

Биштәребезне тутырып,

Киттек без су буена.

Бала-чага чыр-чу килеп,

Елгада су коена.

Куе үскән талларны

Аралап, эчкә үттек.

Әкрен генә әти белән

Кармак җепләрен сүттек.

Чү! Тынлык! Дәшмәгез!

Балык чиртә күрегез!

Әйдәгез танышабыз!

Балыкчы мин белегез!

## Без – табигать баласы

Шаян җилкәй биттән сөя,

Туймый һич тә шатланып.

«Ял ит, әйдә, чык урамга,

Уйныбыз», - ди куанып.

Җәен рәхәт, өч ай буе

Ял итәбез туйганчы.

Кояш та нурларын сибә,

Ямьле итә дөньяны.

Рәхәт тә соң җәй көннәре,

Бар тереклек уяна.

Табигать кочагында без,

Шуңа кояш куана.

Табигать балалары без
Яратабыз урманны.
Иртәдән кичкә чаклы
Гөрләтәбез аланны.

**Газ белән сак бул!**

Алсуны өйдә калдырып,
Китте әнисе эшкә:
«Озак тормам, кызым, түз
Кайтырмын, - диеп, - төшкә.»
Сәгать уннар тулуга
Ашыйсы килде кызның.
Кичәге токмач ашын
Өстенә куйды газның.
Аннан ишектә шалтырау,
Дусты Айдар килгән бит.
Авырып яткан Алсуның
Хәлен белеп кайтыйм дип.
Телевизор кабыздылар,
Аннан уйнап алдылар.
Аш бүлмәсендәге төтенгә
Аптыраушта калдылар.
Тиз генә, газны сүндереп,
Тәрәзәне ачтылар.
Әниләре кайтып кергәч,
Почмакка да постылар.
Ачуланды соң әнисе:
«Уен эш түгел бит ул.
Газ белән дә, ут белән дә
Һәрвакыт, балам, сак бул!»
Ярый әле бәхетебез:
Ашсыз гына калганбыз.
Ялкын чолгап алган булса,

Баш түбәсез калабыз.

**Шәп ташлама!**

Бүген безнең ял көне,
Кибеткә барыйк әле.
Әни белән бергәләп
Күлмәкләр алыйк әле.
Бар җирдә дә ташлама,
Уңган юлга чыкканбыз.
Ташлама дип, кием җыеп,
Кесәгә нык сукканбыз.
Әнием дә киенде,
Миңа да күлмәк алдык.
Бакчадагы кәҗә кебек
Акчаны суга салдык.

Өйгә кайткач, әтиемә:
«Акчабыз бетте», - дидем.
Ачуланганчы диеп,
Матур күлмәкне кидем.
Ярый әле әтием бар
Безне сөендерергә,
Әниемне һәм мине
Матур киендерергә.

**Мең рәхмәт**

Синең куллар безгә шифа бирә,
Синең куллар өмет уята.
Яшәүгә ямь бирә, тормышка – гамь,
Гомер мизгелләрен уйлата.
Яшәү белән үлем арасында
Көрәшкәндә авыру кешелек,
Ходасына догасын пышылдап,
Җылы сүзен көтә тилмереп.
Изге эшләреңдә иман белән
Гомер өстәп Аллаһ колына,
Савыктырган, ярдәм иткән өчен,

Мең кат рәхмәт яусын юлыңа.

**Көтеп алынган сеңел**

Күңелсез икән гаиләдә
Бердәнбер бала булу.
Иң шатлыклы мизгел иде –
Сеңлем дөньяга туу.
Күптән көтеп алган сеңел
Нык яраттырды башта.
Бу кадәр елак туганны
Сорамамын мин башка.
Көн дә дими, төн дә дими,
Акыра да, бакыра.
Аңа игътибар җитми,
Үз янына чакыра.
Әнине дә биетә,
Әтине дә биетә.
Тыныч кына яшәүгә
Эх, дускаем, ни җитә.
Миңа да эш күп хәзер,
Чүпрәк-чапрак юасы.
Эх, бик тә килә шул сеңелне
Кире өйдән куасы.
«Шешәне ю, Алисә,
Киемнәрен үтүклә!»
Әйтерсең лә, патша сеңел,
Ә үзе бер кәтүк лә.
Аптырагач, киңәш бирдем:
«Илтегез шул сеңелне,
Ятсын тудыру йортында,
Борчымасын күңелне!»

**Бүләк**

Минем туган көнемә
Бүләк иттеләр көчек.

Аны күрмичә мәктәптә

Уздырыйм көнне ничек?

Дәрестә утырганда,

Гел аны гына уйлыйм.

Этем белән уйнап, көлеп,

Һич кенә дә мин туймыйм.

Йоклаган вакытта да

Яныма аны салам.

Ашатып нәниемне,

Мәктәпкә соңга калам.

Көчек янында уйларым,

Апаны да тыңламыйм,

Дәфтәремә дә язмыйм,

Дәресләрне уйламыйм.

“5” легә укый идем,

“3”леләр алып кайтам...

“Сагындым, сине дустым,”- дип

Көчек яныма ята.

Әнием аңлап алды да,

Көчегемне озатты...

Авылымны, әбине

Минем этем ошатты.

Хәзер каникулда гына

Аның белән очрашам.

Кочагыма алам да,

Хәл-әхвәлләр сорашам.

Көчек дия-дия һаман,

Акылдан гел язганмын.

Бик күп дәресләремне

Аңламыйча калганмын.

*Гыйлемханова Инзилә, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Садыкова Лидия Хәмдегали кызы, туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Балык Бистәсе районы Биектау авылының тарихын, гореф-гадәтләре. Татар халкының милли бәйрәме Сабантуй традицияләре**

1. **КЕРЕШ ӨЛЕШ**

Мин Татарстан Республикасында яшим. Татарстан – бай һәм киң республика.

Татарстан – күпмилләтле республика. Анда татарлар, руслар, төрекләр, чуашлар, марилар, үзбәкләр, удмуртлар һәм башка милләт халыклары бер-берсенең гореф-гадәтләрен хөрмәт итеп, тыныч һәм тату яшиләр. Әйе, алар барысы да төрле: игелекле, матур, елмаючан, әдәпле. Аларның барысының да үз мәнфәгатьләре бар: кино, спорт, музыка, бию. Әмма аларның барысын да бер нәрсә – туган якка мәхәббәт берләштерә.

Һәр халыкның үз милли бәйрәмнәре бар. Бу бәйрәмнәрнең күбесе берничә гасыр, хәтта мең ел элек туган. «Елга үз юлы белән аккан кебек, халык та үз гореф-гадәтләре белән яши», - ди халык зирәклеге.

2023 нче ел Татарстан Республикасында “Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы” дип игълан ителде. Татарстан елдан-ел уңышлы үсә, тирә-юнь үзгәрә, әмма традицияләр, гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр һәм йолалар яшәвен дәвам итә. Әйе, күңелле, зирәк Сабантуй да - татар халкының тиңдәше булмаган табышы. Гасырлар тирәнлегендә барлыкка килгәч, ул безнең көннәргә бәйрәм буларак килеп җитте. Сабантуй һәр кешегә, нинди милләт һәм ничә яшьтә булуына карамастан, күңел ачу, уеннарда катнашу, яшьлеккә, балачакка кайту чарасы.

**Минем проектымның темасы:** Балык Бистәсе районы Биектау авылының тарихын, гореф-гадәтләре. Татар халкының милли бәйрәме Сабантуй традицияләре.

**Әлеге эшнең актуальлеге шунда:** тарихны һәм гореф-гадәтләрне белү безнең күзаллауларыбызны киңәйтә, гаилә мөнәсәбәтләрен яхшырта, аралашуга этәрә, төрле һөнәр, милләт һәм иман ияләрен берләштерә. Яшьләрне өлкән буыннарның хезмәт традицияләренә, үзешчән сәнгать иҗатына, милли спорт төрләре белән шөгыльләнүгә тартырга ярдәм итә.

**Эшнең максаты:** Сабантуй традицияләре аша Балык Бистәсе районы Биектау авылының тарихын, гореф-гадәтләрен өйрәнү

**Бурычлар:**

1. Биектау авылының тарихын өйрәнү;
2. Авыл сабантуенда үткәрелә торган милли уеннарны барлау.
3. Биектау авылы корәшчеләрен ачыклау.
4. Халык-аваз иҗаты белән кызыксыну, аңа хөрмәт белән карау

**Эзләнү объекты**: Сабантуй бәйрәме

**Кулланылган алымнар:**

1. Фәнни чыганак белән эшләү, интернеттан эзләнү, авыл картлары, туганнарым белән аралашу;
2. Бәйрәмдә үткәрелә торган уеннарны, сабантуй батырларын барлау.

**Көтелгән нәтиҗә**: Татар халкының электән килгән бәйрәмнәрен, йолаларын барлап, авылым тарихын өйрәнү.

**Гипотеза:** Минемчә, проект өстендә эшләү миңа авылым тарихын, анда сакланып калган гореф-гадәтләрне Сабантуй традицияләре аша яхшырак белергә ярдәм итәчәк.

## 2. ТӨП ӨЛЕШ

Бүген без, минем әтиемнең туган авылы Балык Бистәсе районы Биектау авылында үткәрелә торган иң якты һәм иң яраткан милли бәйрәмнәрнең берсе - сабантуйга бергәләп экскурсия ясарбыз. Ә иң элек мин сезне бу авылның кыскача тарихы белән таныштырырга телим. Чөнки “Тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк,” – ди халык.

Биектау авылы – элек-электән ул Балгузино, Болын хужасы, Балынгуз, Көчек Чаллысы дип тә йөртелгән. Тарихи мәгълүматларга караганда, авылының төп халкы - Урта Идел һәм Чулман буйларына, безнең эраның 3-нче гасырында ук Алтай тирәләреннән күчеп килгән төрки телле “суас” кабиләләре булырга мөмкин дип санала. Алар, фәндә “Имән-Кискә кабиләләре” буларак билгеле булганнар һәм зур сулыклар тирәсендә яшәгәннәр. Чөнки зур сулыклар хәрәкәт итүенең төп юлы булган. Шул сәбәпле, “суас” кабиләләре дә гел тыныч тормышта гына яши алмаганнар. Әлеге сәбәпләргә бәйле алар, соңрак, зур елгалар буеннан китәргә мәҗбүр булып, эчкәрәк кереп, кечерәк елга буйларына урнашканнар. Бу вакытта Урта Идел буена башка төрки телле кабиләләр дә (бортаслар, болгарлар, сөннәр һ.б) дулкын-дулкын булып күчеп килгәннәр. Алар җир эшкәртеп, иген иккәннәр. Мал-туар асраганнар. Савыт-саба ясау, кием тегү кебек төрле һөнәрләрне үзләштергәннәр. 7-8 нче гасырларда, Азов диңгезе тирәсеннән төрки телле болгарлар күченеп килгәч, бу төбәктә аңынчы ук тереклек иткән төрки телле башка кабиләләр дә, Идел буендагы “Боек Болгар” дәүләтен төзүдә актив катнашканнар.

Авылының тарихы бик катлаулы. Аның тарихында аянычлы вакыйгалар да куп булган. 1556 нчы елда, авылдан 2-3 чакырым ераклыкта гына урнашкан борынгы Чаллы шәһәренә урыслар сугыш белән киләләр һәм аны җимереп, яндырып юк итәләр. Шәһәр яндырылганда тирә-яктагы авыллар да юкка чыгарылган. Бу - хәзерге Биектау авылы биләмәсенә кергән борынгы авылларның да язмышы.

Әлеге тема – аерым игътибарга лаек дип саныйм мин һәм киләчәктә, бу тарихи тема өстендә эшемне дәвам итәргә телим…

### 2.1. Сабантуй - халык бәйрәме.

Чыннан да, татар халкының үткәненә күз салсаң, исең китә. Ниләр генә күрмәгән дә, ниләр генә кичермәгән безнең халык. Аның тыныч, мул тормыш даулап кына түгел, ә үзен-үзе саклап һәм яклап яшәмәгән көне булдымы икән? Ә шуңа да карамастан, үзенә-үзе ял да оештырган, күңел дә ачкан безнең әби-бабаларыбыз. Авыр хезмәттән соң бушанып, иркенәеп алыр өчен төрле бәйрәмнәр уйлап тапканнар. Җәй көннәрендә болынга кичке уеннарга җыелганнар, анда төрле түгәрәк уеннар уйнаганнар, җыр-бию яңгыраган. Җыр - минем халкымның аерылмас юлдашы булган. Кайгы-хәсрәтне, сагыну-сагышны алар җыр белән басканнар. Кыш көннәрендә исә кич утырганнар, йон эрләгәннәр, оек-бияләй бәйләгәннәр, чигү чиккәннәр. Бергә-бергә сагышлар да җиңеләйгән. Ә кызлар-егетләр исә аулак өйләргә җыелганнар. Яшьлек һәрвакыт үзенекен иткән, юклык дип тормаган. Кызлар һәм егетләр төрле уеннар ярдәмендә бер-берсен сайлаганнар һәм сынаганнар. Нинди генә кызыклы уеннар булмаган ул вакытта: тукмак тәгәрәткәннәр, йолдыз санаганнар, арка сугышлы уйнаганнар. Кыскасы, ничек тә үз күңелләрен үзләре күргәннәр.

Шундый кызыклы ярыш, уеннарны бергә туплаган бәйрәмнәрнең берсе – Сабан туеның тарихы да борынгы – мәҗүсилек чорына ук барып тоташа. Бәйрәм Болгар ханлыгы ислам динен кабул итүгә кадәр үк, VIII-IX гасырларда башланган дип исәпләнелә. Бу борынгы бәйрәмне әле 921 елда ук Болгарга Багдад илчесе булып килгән атаклы тикшерүче Ибн Фадлан үз хезмәтләрендә тасвирлаган.

Хәзерге көндә Сабантуй - милли кысаларда гына туктап калмый, киң масштабта үткәрелә, бөтен милләт халыклары бәйрәменә әверелеп бара. “Сабантуй – чын мәгънәсендә милли рух җәүһәре, татар халкының үзенчәлекле мәдәниятының бетмәс-төкәнмәс чишмәсе, аның рухи торышы, һәм талантларны ачу өчен бик яхшы мөмкинлек, җитезлектә, тапкырлылыкта көч сынашу.... Сабантуй турында бөтендөньяга билгеле булыр һәм ул Бөтендөнья мирасы исемлегендә лаеклы урынны алыр дип ышанасы килә»... - дип язган иде Татарстан Республикасының беренче Президенты М.Ш. Шәймиев 1998 нче елда. Ә 2003 елның июнендә ЮНЕСКО генераль директоры К.Мацуура Казанга визиты вакытында Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиевнең тере традиция булып торучы һәм халыкның чын

күңелдән яратучы «Сабантуй» милли бәйрәмен ЮНЕСКО телдән һәм матди булмаган мирас шедеврлары исемлегенә кертүгә дәгъва кылучылар арасына тәкъдим итүе турындагы инициативасын хуплады. Әйе, аны хәзер хезмәт һәм шатлык бәйрәме дип кенә түгел, ә халыклар дуслыгы бәйрәме дип тә әйтә алабыз. Чөнки, бу бәйрәмдә, күпмилләтле Россиянең бар милләт вәкилләре дә бик теләп катнашалар.

## 2.2. Сабантуй бәйрәменең тарихы

Сабантуй бәйрәменең тарихына күз салыйк. Ул элек яз көне кар беткәч тә, чәчүгә чыкканчы үткәрелгән. Анда хәзерге сабантуйларының барлык чаткылары да булган. Ләкин бер үзенчәлеге – бу бәйрәмдә кырда йомырка, ботка пешереп, җиргә күмгәннәр. Шуның белән игенче елны уңышка юраган. Бу мәҗүсилек чорыннан килгән бер йола булган.

Ә менә минем әбием сөйләвенчә, ул яшәгән чорда бу бәйрәм чәчкән игеннәр тишелеп чыгып, печәнгә төшәр алдыннан, июнь урталарында уздырылган. Авыл халкы аны Җыен дип атап йөрткән. Җыен көнен, кагыйдә буларак, авыл картлары киңәшеп хәл кылганнар һәм бәйрәмне үткәрү көне турында базар көнне (хәзергечә - ял көне) игълан иткәннәр. Шуның белән бергә, бер төбәктәге авыллар ярышларны төрле көнне үткәрергә омтылганнар. Бу башка авыл кешеләре дә күршеләренең бәйрәмендә катнаша алсын өчен эшләнгән. Ләкин сабантуй ул шул авыл халкының үз бәйрәме исәпләнгән һәм аны һәр авыл үзенчәлекле итеп, үзенчә үткәрергә омтылган. Ул бик күңелле һәм атна-ун көн дәвамында үтә торган була. Халык бер авылдан икенчесенә җигүле атларга төялеп, тальян гармуннарда уйнап, күрше авылда көн күреп ятучы туганнарында, дусларында кунак булып рәхәтләнеп ял итеп кайта торган була. Икенче көнгә аларны үз авылы җыенына кунакка чакырганнар.

Ә хәзер Татарстан Республикасында Сабантуй, кагыйдә буларак, июнь аенда, өч этапта уза. Язгы чәчү тәгәлләнгәннән соң беренче шимбәдә бәйрәм республика авылларында һәм районнарында, бер атнадан Татарстанның эре шәһәрләрендә үткәрелә, ә тагын бер атнадан соң республика башкаласында Казанның төп Сабантуе уза. Шәһәрнең барлык административ районнарында ярышлар уздыру өчен мәйданнар, Татарстан мәдәният һәм сәнгать осталары чыгышлары өчен мәйданнар, халык күңел ачулары оештырыла. Шәһәрнең үзәк ипподромында ат чабышлары үткәрелә.

## 2.3. Сабантуйга әзерлек. Сөлге, яулык җыйнау йоласы.

Әйткәнемчә, татар халкы — бик борынгы халык. Ул элек-электән терлек асраган, җир сөргән, иген иккән. Безнең халык — искиткеч тырыш, эшчән халык. Бу — татарның борынгыдан килгән гүзәл сыйфаты. Ирләр тормыш-көнкүреш өчен кирәк-яраклар ясау белән шөгыльләнгәннәр: итек басканнар, кәрзин, бишек үргәннәр, бау ишкәннәр, чабата ясаганнар. Ә уңган кызларыбыз һәм киленнәребезнең кулларыннан нинди генә эшләр килмәгән?! Үзләре тукыган киндердән сугылган сөлге-ашъяулыклар, чыбылдыклар, энҗе-

мәрҗән белән чиккән калфаклар, күзләрнең явын алырлык чигү үрнәкләре. Бу — халкымның күңел байлыгы, аның рухи хәзинәсе.

Сабантуй якынлашкач, хатын-кызлар өй җыештырганнар, бөтен нәрсәне чистартканнар. Ирләр исә ишегалдын, урам тирәләрен себергәннәр, чүп-чарларны җыештырганнар Һ.б. Сабантуй көнне иртән иртүк балалар өйдән өйгә кереп, манган йомырка һәм башка тәм-том җыйганнар, Аннары авылның ир-атлары, егетләре иңнәренә колгалар салып, бүләк җыярга чыкканнар. Бүләкләр җыю һәркайда бер төрле булган. Былтыргы сабан туеннан соң кияүгә чыккан яшь киленнәрдән алган сөлге иң кыйммәтлесе булып саналган. Килен аны шушы йоланы күздә тотып алдан әзерләгән. Башкалар ситсы, баш яулыклары, чиккән кульяулыклар, сөлге һ.б. бүләкләр биргәннәр. Моннан тыш, һәр хуҗа хатын бер-ике йомырка да бирә торган булганнар. Аның бер өлеше кибеткә тапшырылган, акчасына бүләкләр алынган. Ә калганнары мәйданда файдаланылган – аны җиңүчеләргә биргәннәр, көрәшчеләр чи йомырка эчкәннәр. Бүләк җыючылар бүләкне мул бирүчеләрне мәйдан каршында мактап телгә алганнар. Бүләкне яшьләр җыйган, анда җыр, моң яңгырап торган. Бүләкләр җыелып беткәч, бәйрәм башланган. Сабантуен үткәрү өчен махсус урын билгеләнгән. Ул болын җир, аланлык булып, агачлар белән әйләндереп алынган тигез һәм уңайлы җирдә урнашкан. Бу урын мәйдан дип аталган. Мәйданда бүләкләрне аерым төр ярышлар өчен атап, билгеләп куйганнар.

### 2.4. Сабантуй бизәкләре – уеннар

Мин – замана баласы булсам да Сабантуй бәйрәмен бик яратам. Монда нинди генә тамашалар юк: бәйрәмнең күрке булган атлар узышы, көрәшчеләр, йөгерүчеләр, күз бәйләп чүлмәк ватучылар, багана башыннан бүләк алучылар, капчык киеп йөгерүчеләр, гер күтәрүчеләр, агач аякта йөрүчеләр, кузла өстендә капчык белән сугышучылар. Башын тыгып катык эченнән көмеш акча эзләүчеләр, көянтә-чиләк белән су ташучылар, аркан тартучылар. Минемчә, бу уеннар һәркайсы үзара дуслыкны ныгыта, кардәшлек тойгыларын уята, катлаулы тормыш ыгы-зыгысы белән зәгыйфьләнгән туганлык тамырларына дәва бирә.

Ярышлар гасырлар буена килгән тәртип буенча үткән. Аларны ат чабышы башлап җибәргән. Кайчандыр, бик күп заманнар элек көчле, зифа, сылу кыяфәтле елкыны кеше үзенә дус, иптәш ясый. Ихтимал, елкының инстинкты да бөтен ерткычлардан көчлерәк булган адәм баласы канаты астына сыенуның яхшырак, уңайрак булуын тойгандыр. Ир-егет үз гомерен ат белән бәйләгән, елкыны үзенә ияләштергәннән соң, алар бер организм кебек яшәгәннәр. Юкка гына борынгы рәсем сәнгатендә ир белән ат бер бөтен организм итеп ясалмагандыр. Безнең халыкта тулпар диләр андый атны. Бу, әлбәттә, сабантуйның дәртләндерә, шаукым бирә торган өлеше.

## 2.5. Ат чабышы

Ат чабышы турында әбием сөйләгәннәрдән: “Сабантуйның беренче кызыгы ат чабышлары. Чөнки борынгыдан авыл кешесенең мотоциклын, җиңел машинасын, тракторын да ат алыштырган. Игенченең яхшы чаптары булу аңа мәртәбә өстәгән, ул аның белән чиксез горурланган. Чабыш артыннан фәкать хезмәттә генә файдаланган.

Ат - бик акыллы хайван ул, алар безнеңчә сөйләшә генә белмиләр. Уңышлыксызлыкка юлыкса, кеше кебек күз яшьләре белән елый да алар. Чабыш аты сабан туе, җыен җиткәнен сизенә, борчыла, ярсый ук башлый. Ярыш сызыгына барып баскач та, очып китәр кебек чаптарлар. Ничек тә беренче булырга, уздырмаска тырышалар, хәтта егылып үләргә дә әзер бит алар, малкайлар”. Әбиемне тыңлагач, Г.Ибраһимовның “Алмачуар” әсәрендәге Закир образы һәм аның ярсу аты – Алмачуар искә төште. Ул да хуҗасы беренче урынга чыгарып җан биргән хайван. Ләкин, җиңүнең андый фаҗигале юллар аша килүе акланырлык хәл микән соң? Минемчә –юк! Бәйрәмдә бер генә уен да фаҗига белән тәмамланырга тиеш түгел.

Сабантуйда ат чабышлары “программаның кадагы” булып тора. Сабантуй бәйрәмен атлар чабышыннан башка күз алдына да китереп булмый. Халыкта хәтта ат чабышыннан башка узган Сабан туе – гармунсыз туй кебек дигән әйтем дә бар. Биектау якларына бу әйтем бер дә ятмый, чөнки һәр авылның Сабан туенда ат чабышы үткәрелмичә калмый. Соңгы елларда ат чабышына игътибар бермә-бер артты. Иң матур сөлгеләрнең берсен ат чабышында җиңүчегә биргәннәр. Кайчакта иң ахырдан килгән атка махсус атап бирелгән сөлгене такканнар. Шул ук вакытта көрәш тә башланган.

Атлар әле еракта булганда, майданны буш тотмас өчен, халыкны ярышка кыздыру өчен **йөгерү ярышлары** оештырыла. Аларны малайлар яки картлар башлап җибәрәләр: катнашучылар һәрвакыт яшь буенча төркемләнә. Йөгерүчеләргә юл күрсәтер өчен, җайдак алдан бара. Ярышларны оештыру принцибы чабышлардагы кебек: старт еракта урнаштырыла, финиш сызыгы майданда була.

## 2.6. Милли көрәш.

Авыл тарихыннан...Сабантуйларын нинди генә чаралар белән бизәргә, кызыграк итәргә тырышмасыннар - милли көрәш – милли көрәш инде ул... Биектау авылы зур авыл булганлыктан, аның көрәшчеләре дә күп була. Көрәшне кечкенә малайлар башлап җибәргән, аннары яшүсмерләр, егетләр һәм ир-атлар көрәшкәннәр. Көрәштә җиңүчегә иң зур бүләк – сарык тәкәсе бирелгән.

Мин үзем, кыз бала булсам да, көрәш карарга яратам. Еш кына бабам һәм әтием белән шул темага сөйләшәбез, көрәш батырларын барларга яратабыз. Бабам истәлекләреннән: “Күрше Сатлыган авылында җыен – Сабантуйлар бөтенләй булмый иде.

Аның халкы янәшә күрше авылларына бара. Менә шул авылдан Гарәф Низамов мәйданны бизи иде. Ул Биектау егетләре белән бил алышып чыныкты. Авылның төп баш батыры булып озак еллар Нәҗип абый Хәйриев та торды.

Кайсы елны баш батыр булып, озак еллар колхозда тимерче булып эшләгән Сафин Нурмый абзыйның Түбән Кама шәһәреннән кайткан кияве кала, ул тәкәне алып китә иде.

Соңрак яшь буын үсеп чыкты. Бертуган Нәфигуллиннар күңелле сөендерерлек иде. Бертуган Нәҗмиевлар да Сабантуйларга ямь өстәде. Дамир Хәйриев 6 сыйныфта укыган чакта ук зурлар белән көрәште һәм күбесен сыртына салып барды. Беренче елны аңа малай-шалайга караган кебегрәк карадылар, ә инде икенче елны сөлгеләрен чорнабрак, ныграк тоттылар. Ник дигәндә, берсенең дә ансат кына сыртка төшәселәре килми инде.

## 2.7. Дамир батыр

Дамирга каршы тору авыр. Ул батыр, чын батыр, баш батыр.

Сабантуе мәйданыны чыккан көрәшче уч төбендәге кебек. Йөзләгән күз аңа сынап карый. Һәр адымын, алымын, кыланмышын әйткән сүзен бизмәнгә сала. Хәрәмләшкән, тик томалга кызып китеп бәхәсләшкән көрәшчеләрне сөйми халык. Ә менә Дамир Хәйриев елмаеп чыга мәйданга, елмаеп көрәшә, елмаеп җиңә. Чын көчле ир-егетләргә генә хас сабырлык, куәт бөркелә аңардан. Тамырларында көрәшчеләр каны тургый. Аның бабасы Гыйльметдин, әтисе Якуб та күрше-тирә авылларында мәйдан тотканнар. Якуб аганың “Яңа Сала, Биектау батыры” дигән даны  бар. Улларын да көрәшчеләр итеп күрәсе килә аның, шуңа да, бераз үсә төшүгә чыныктыра, билләренә сөлге сала башладылар.

Биектау мәктәбендә, танылган көрәшче Нәгыймулла Нәфигуллин физкультура укыта башлагач, Дамир милли көрәш белән чынлап торып шөгыльләнә башлый. Табигатьтән көч- куәтле, сәләтле егет Нәгыймулла кебек көрәш остасы кулына эләгүе белән бәхетле.  15 яшендә үк туган авылында батыр асты кала. Икенче елны аңа каршы торырдай көрәшче табылмый  Биектауда - Котлы Бөкәш Сабан туенда атаклы көрәшче Григорий Абрамовтан җиңелеп кенә икенче батыр кала. 18 яшендә Түбән Кама шәһәре Сабан туенда көрәшеп мини трактор белән бүләкләнә. Бу бүләккә, үзеннән бигрәк, әтисе сөенә.

1999, 2000, 2006, 2010, 2012 нче елларда Балык бистәсең обсолют батыры булып кала Дамир. Моннан тыш республикабызның шәһәр, районнарында да җиңүләр яулый. Ул елларда Сабантуйларны дер селкетә Биектау батыры. Бүләкләрен санау да җитәр: ике машина, 20 гә якын мотоцикл... Ә тәкәләрнең, телевизор, суыткыч ише призларның, чутына да чыгармын димә. Бер елгы Сабан туйларда 12 тәкә, ике ат алып кайта”.

Хәзер инде Дамир абый сабантуйларда көрәшми, кызганыч, әлбәттә. Бик күп көрәш сөючеләр, Дамир абый кебек көрәшчеләрне карарга бара бит Сабан туена...

## 2.8. Милли уеннар

Ат чабышы, йөгерешчеләр ярышы, милли көрәштән башка да сабантуйда, яшь үзенчәлекләренә карап, бик күп кызыклы уеннар оештырыла. Шуларның берсе - **чүлмәк вату.**

Сигнал булуга, уенчы 10—12 адым алга атлый һәм, 180 градуска борылып, чүлмәккә таяк белән бәрә. Ватса — җиңүче була.

Бу уенның икенче варианты да бар. Күзләре бәйләнгән һәм кулына таяк тоткан уенчыдан 15—18 метр алда җиргә чүлмәк куела. Катнашучыны бер урында өч тапкыр әйләндерәләр. Аннан соң ул алга атлый һәм, үзенчә кирәкле ара узгач, чүлмәккә өч тапкыр суга. Ватса — бүләк ала.

**Капчыклар белән көрәш.**

Ярышта катнашкан ике кеше, кулларына салам тутырылган капчык тотып, бер-берсенә каршы бүрәнәгә утыра. Судьялар сигналы буенча, уенчылар бер-берсен капчыклар белән кыйный башлый, көндәшләрен җиргә бәрергә омтыла. Җиңелгән кеше уеннан чыга. Ә җиңгәне әле тагын да үзе кебек җиңүчеләр белән кыйнашырга тиеш була. Бу уенда баш батыр калганчы, шулай дәвам итә. Һәр уенчы үз бүләген алып мәйданнан чыга, яки башка уенга барып кушыла.

**Аркан тартыш**

Берничә метр озынлыктагы аркан мәйдан уртасында куела. Аркан уртасы төсле тасма белән билгеләнә. Уйнаучылар ике командага бүленә, уенчылар саны һәм көче буенча тигез. Уенчылар, арканның уң һәм сул ягына басалар да арканнын икенче башындагы команданы үз якларына тартыртып алырга тырышалар. Берәр команда үз ягына тартып ала алса, көрәш туктый. Арканны үз ягына тарта алган команда җиңә.

## 3. ЙОМГАКЛАУ

Йомгаклап, шуны әйтәсем килә: Сабантуй – элек-электән олы бәйрәм булган, аңа хәзерлек үзенә бер күңеллелек белән ел буена дәвам иткән.

Гасырларны ярып, утлар, сулар кичеп бүгенге көнгә килеп җиткән милли бәйрәмнәр төрле милләт кешеләре тормышында аерым урын алып тора. Безнең сабантуй - хезмәт, көч, җитезлек, сәламәтлек бәйрәме. Төрле ярышлар, уеннар, җырлар һәм биюләр белән үрелеп баручы халыкның күңел ачу чарасы. Ул борынгы халык традицияләрен саклап калды һәм яңаларын үзенә туплады.

Минемчә, проект өстендә эшләү миңа Сабантуй традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен бәйрәм тарихы аша яхшырак белергә, бу вакыйганың татар халкы өчен мөһимлеген аңларга ярдәм итте. Алынган мәгълүматларны мин гомумиләштердем, сыйныфташларым алдында да чыгыш ясадым. «Татар бәйрәме - Сабантуй» мультимедиа презентациясенә иң кызыклы һәм танып белү өлешләрен керттем. Проектны эшләгәндә

миңа укытучым Садыкова Л.Х., әти-әнием һәм әби-бабам ярдәм итте. Алар белән аралашу минем туган халкыма, туган телемә карата мәхәббәтемне тагын да арттырды. Мин үземнең татар халкының киләчәге булуым белән горурланам. Киләчәктә, милли традицияләрне, телемне, гореф-гадәтләрне яшь буынга җиткерә алырмын дип ышанам.

## 4. КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. Гильманов Р., Гариф Н. “Биектау авылы тарихы” 2017

2. ru.wikipedia.org

3. www.culture.ru

4. tatarstan.ru

5. tatculturesurs.ru

6. udmddn.ru



*Гыйләҗев Раил, 8 нче сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы "Адымнар-Әлмәт" полилингваль гимназиясе муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкче: Тамасова Язгөл Ильяс кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


**Кереш**

## Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк

Үткәнне белү, синең киләчәгең
Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәненне онытма син!
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Ни иккәнен, ни чиккәнен,
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.

Гаилә, нәсел, киләчәгең, токым... Әлеге сүзләр безгә бик кечкенә вакыттан, балачактан таныш. Гомер дәвамында кешеләр күренми торган җепләр, туганлык белән бәйле. Ә безне, бер-беребез белән нәрсә берләштерүе турында уйланып караганыбыз бар микән? Мөгаен, юктыр. Әйе, «илен белмәгән - игелексез», «халкын белмәгән - холыксыз», «нәселен белмәгән - нәсәпсез» дип, юкка гына әйтмәгән халкыбыз. Кеше туган иленең,

туган төбәгенең, туган йортының үткәнен, үз халкының чыгышын белергә тиеш. Әлеге сорау белән генеология фәне өйрәнә. Генеология – ул кешеләрне һәм аларның килеп чыгышын өйрәнә торган тарихи фән.

Кызганычка каршы, күп кеше гаиләсенең тарихын, шәҗәрәсен, килеп чыгышын белми. Үз нәселеңне өйрәнер өчен бөтен мөмкинчелекләр дә тудырылган, югыйсә. Архивлар, эзләнү методлары, махсус әдәбият....

Борынгы заманда һәр кеше үзенең җиде буын бабасын белергә тиеш булган, үз нәселен белгән кеше абруйлылардан саналган. Минемчә, гаиләңнең тарихын өйрәнү кызыклы һәм файдалы. Минем әби – бабам кем булган, ничек яшәгән һәм шөгыльләнгән, кешеләр өчен файдалы эшләр башкарганнармы, әллә киресенчәме? Минем уйлавымча, безнең бабаларның яшәү рәвеше безнең тормышта да уз урынын алган, үз нәселеңне белергә һәм хәтерләргә тиешбез.

Бүгенге көндә буыннар арасында тарихи бәйләнеш юк дисәң дә була. Балалар өлкән буын кешеләреннән үрнәк алу мөмкинлегеннән мәхрүм. Шуңа күрә һәр кеше үз гаиләсендә буыннан буынга килгән истәлекләрне белеп, аларны саклап, киләчәк буынга тапшырырга тиеш.

Минем сайлап алган темамның актуальлеге шик тудырмый. Бүгенге көндә гаиләнең тарихын өйрәнү проблемасы иң мөһим проблемаларның берсе булып тора.

Фәнни-эзләнү тикшеренүнең төп объекты булып Гыйләҗевлар гаиләсе тора - Бөек Ватан сугышында Әмирҗан бабайның илне саклауга керткән өлешен өйрәнү, әби-бабайларның язмышы.

Еллар уза, дөньяга яңа буыннар килә. Кешелек дөньясына кайгы-хәсрәт китергән Бөек Ватан сугышы тәмамлануга жиде дистә елдан артык вакыт узса да, сугыш дип әйтүгә, күз алдына җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә. Япь-яшь егетләр, кызлар туган җирләрен саклау өчен фронтка китәләр. Тылда калганнар да солдатлар өчен җылы оекбашлар, бияләйләр бәйлиләр. Җиңү өчен дип, бар тырышлыкларын куялар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китерә. Я ире, я уллары, я этиләре Ватан өчен яу кырларында мәңгегә ятып кала. Бер кайтмасак, бер кайтырбыз, дип китсәләр дә, күпме ватандашларыбыз туган туфрагын күрү бәхетенә ирешә алмады. Алар еракта мәңгелек йокыга талдылар. Туган җирләре өчен башларын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк. Алар безнең белән, безнең арада. Ил азатлыгы өчен изге сугышта һәлак булучыларның исемнәрен мәңгеләштерү эше бүген дә дәвам итә. Бу эштә һәркем үзеннән өлешен кертергә бурычлы. Бүгенге тыныч тормышта яшәвебез

өчен без аларга бурычлы. Өлкән буынның сугыш һәм сугыштан соңгы героик тормышы безнең өчен һәрчак үрнәк.

## Төп өлеш

## Бөек Ватан сугышы – ил, гаилә фаҗигасы

1941 нче елнын 22 нче июнь иртәсе искиткеч матур, күк йөзе ап-аяз. Менә шундый матур күк йөзе кинәт самолётлар гөрелтесе, шартлаулар, янгын төтене каплап кала. Бу көнне, фашистлар Германиясе хыянәтчел төстә һөҗүм итеп, илдә Бөек Ватан сугышы башлана. Сугыш! Никадәр кайгы-хәсрәт, югалту, бәхетсезлек китердең син тыныч халыкка. Син аның бәхетен урлап, рухын сындырырга, юк итәргә, колга әйләндерергә, кешеләрне тезләндереп, алар өстеннән явызларча хакимлек итәргә теләгәнсеңдер. Безнең илнең көчсез, әле ныгып җитмәгән булуыннан файдаланырга теләгәнсеңдер. Ләкин бер хакыйкатьне син аңламагансың. Безнең илебез яшь, көчсез булса да, аның горурланып сөйләрлек, курку белмәс, җиңелмәс батыр уллары һәм кызлары, шундый батыр йөрәкле балалар үстергән бөек аналары бар. Аларга бәхет төшенчәсе туганда ук ана сөте белән керә, әнә шуны чын мәгънәсендә аңлау аларга бетмәс-төкәнмәс көч, туган илгә кайнар саф мәхәббәт бирә, әнә шул көч җиңүгә алып килә. Безнең илебез зур сынаулар, авыр юллар, чиксез күп югалтулар белән җиңү таңын каршылады. Без бәхетле яшәсен өчен егерме миллион кеше яу кырында ятып калды. Аларның чиксез батырлыгы турында без кинолардан карап, тарих дәреслекләреннән укып, язучыларыбыз сугыш темасына иҗат иткән әдәби әсәрләр белән танышып беләбез. Миллионнарча гаиләләр сугышта һәлак булган, хәбәрсез югалганнарның язмышын белә алмады.

Бөек Ватан сугышының 78 еллыгы узды. Сугыш хатирәләрен, җиңелмәс батырларыбызны искә төшереп торучы тере һәйкәлләр – ветераннарыбыз бар. Шунысы кызганыч, аларның сафы елдан-ел сирәгәя. Бүгенге көндә, күкрәк тутырып көмеш медальләрен чыңлатып, Җиңү көнен каршылаучы авылдаш ветераннарыбыз бармак белән санарлык кына калып бара. Шул ветераннар арасында минем карт бабам Гыйләҗев Әмирҗан Гыйләҗ улы да булырга тиеш тә, ләкин аның турында җирлектә дә, районда да, хәрби комиссариатта да мәгълүмат юк. Әмирҗан бабай һәм анын гаиләсе тарихын беләсем, өйрәнәсем, кешеләргә җиткерәсем килде. Бу гаиләнең тормышы – меңләгән гаилә тормышына охшаган да, үзенчәлекле дә; бу зур тарихның бер күзәнәге.

## Бөек Ватан сугышы Әмирҗан бабай гаиләсе тарихында

Минем карт бабам Гыйләҗев Әмирҗан 1916 елда Атлас авылында туган була. Әтисен белмәгән, ә әнисе кияүгә икенче иргә киткән, ә малайны әби-бабасы карап үстерә. Картлар үлгәч, 1934 нче елда аны Югары Табыннан мулла кызы Фатыймага димләп өйләндергәннәр. Өйләнеп аз гына торуга, Әмирҗан бабай армияга киткән. Хезмәт срогы

вакытында Фин сугышы башланган һәм бабай бу сугышта катнашырга мәҗбүр була. Ул армиядә чакта кызы Мәгърифә туа. Армиядән кайтып, Һәр туган көнгә сөенеп, матур гына яши башлыйлар. Тик мондый бәхетле көннәр озакка сузыла алмый. Бөтен дөньяны тетрәткән Бөек Ватан сугышы башлана. Илгә килгән кара кайгы, бу гаиләне дә читләтеп үтми. Әмирҗан бабай тагын сугышка, илебезне сакларга китә, ә берничә ай узгач, бабам Занур туган. Әти белән малай шулай итеп, бер-берсен күрми кала.

Ә Атлас  авылында Фатыйма әби ике баласы белән иске салам түбәле, сәмән кирпичле, дүрт почмаклы өйдә ялгыз кала.

Нуретдин кызы Фатыйма әби  «Барысы да фронт өчен!  Барысы да Җиңү өчен!» лозунгы астында, тылда хезмәт куя. Җир сөрә, урак ура, сугышчылар өчен кич утырып оекбаш-бияләйләр бәйли. Шулай ук җәйге чиләләргә туры килгән уразасын да калдырмый.

**Әмирҗан бабайның сугыш юллары**

Әмирҗан бабай Мөслимдә чакта ук егетләрне “солдат уйнатып” йөргән (военрук булган). Сугышка киткәч тә аның бу һөнәрен белеп, аны “солдат өйрәтергә” Мәскәүдә калдыралар.

Мәскәүдә, авылдашы Шәймәрдан бабайны, ат илтергә барган җирендә очратып, “Гаиләм килсә, мине сугышка кертмәсләр, шушында “солдат өйрәтергә” калдыралар”, - дигән. Шәймардан бабай Атласка кайткач, иң беренче эш итеп, Фатыйма әбигә кереп, иренең исәнлеген, сәламнәр җибәрүен һәм Мәскәүдә көтеп калуын әйтә. Ләкин Фатыйма әбием авылдан чыгып китәргә курыккан. Шулай итеп, Әмирҗан бабамны сугышка керткәннәр.  Ул сугышта атлы разведчик булып хезмәт иткән, төрле хәрби чараларда актив катнашкан. Ә 1943 елның 27 нче мартында Смоленск өлкәсе Лопешки һәм Горки авыллары өчен барган сугышта яшеренгән пулеметчикны эзләп табып, аны юк иткән өчен һәм көчле дошман минаметлары уты астында хәрби боерыкны алып килгәне, яуда күрсәткән батырлыклары өчен “Батырлык өчен” (“За отвагу”) медале белән бүләкләнгән. Соңрак, август аенда яраланып, госпитальгә эләгә һәм алган яраларыннан 1943 нче елның 4 сентябрьдә вафат була.

Алда әйтеп узганымча, бу турыда бер мәгълүмат та юк иде. Без әнием белән башта Сарман районы хәрби комиссариатына, аннан соң Россия Федерациясе Хәрби Министрлыгының Хәрби архивына хат язып салдык. Аннан килгән архив справкасына гына канәгать булмыйча, без интернет сәхифәләрдә эзләнә башладык. Ул вакытта “Ватаным Татарстан” гәҗитендә Михаил Черепанов белән әңгәмә басылып чыккан иде. Ул Бөек Ватан сугышында югалган, кайтмаган кешеләрне ничек эзләргә кирәклеген аңлаткан иде. Шулай итеп, аның ярдәме белән без “obd-memorial.ru”  сайтыннан бабабыз турында мәгълүматлар таба алдык. Ә “Подвиг народа” сайтыннан кереп, бабабызның батырлыклары турында

белдек. Киләчәктә бабайның исемен Мөслим районы Тойгелде авыл җирлегебездә куелган “Сугышчан Дан” һәйкәлендә дә күрербез дип ышанып калабыз. Бу безгә – оныкчыкларга түгел, ә үзенең бөтен гомерен “әти” сүзен әйтергә тилмереп яшәгән балалары – Мәгърифә әби белән Занур бабайга зур бүләк булыр иде.

Әмирҗан бабайның якты хәтирәсе безнең күңелләрдә мәңге калыр! Җир йөзендә анын балалары, оныклары, оныкчыклары - аның дәвамы. Башкаларга терәк һәм үрнәк булып, тормыш сикәлтәләрендә егылып калмыйча яшәгәннәр алар. Үзеннән соң игелекле балалар, матур эшләр калдырганнар.

**Бабам истәлекләре**

“Атлас  авылында Фатыйма әни ике баласы белән иске салам түбәле, сәмән кирпичле, дүрт почмаклы өйдә тол калган. Шушы кечкенә генә өйдә язын, җәен, көзен генә торып була алган, ә кышкылыкка  каравыл өенә яшәргә күченә торган идек, чөнки өйне җылытырга утын юк, лесник урманнан утын бирми. Ә кышкылыкка өебезгә корчаңгы атларны ябалар иде. Яз көне, әни өйгә кайтып, атларның тиресләрен чыгарып, өйне тазарткач, безне кире үз нигезебезгә алып кайта иде. Ашарга булмагач, мине Югары Табынга–Нуретдин бабайларга илтә торган иде. Әле хәзер дә “Кутка аш бушат” (“Кружкага аш бушат”) дип елап йөргәнем хәтердә. Анда бабай булгач азрак ашарга бар иде. Шунда илтеп кенә әни мине үлемнән алып калды. Шулай ачлы – туклы яшәп, 9 яшемдә генә укырга керә алдым, чөнки укырга киеп барырга киемем юк иде. Кыш көне аякларга бияләйне апа белән чиратлашып киеп, укырга да бара идек, уйнарга да чыга идек. Яңа ел бәйрәмнәрендә күчтәнәч конфет-печенье урынына укытучыбыз Әнисә апа йомры күмәч пешереп алып килә иде. Ул күмәчләрне телемләп балаларга яңа ел күчтәнәче итеп тарата, аның тәме шулкадәр тәмле, исе әле дә борын очларында тора. Ләкин андый тәмле күмәчне яңадан минем авыз иткәнем булмады. Дәфтәр, каләмнәр дә юк, гәҗитнең ак кырларына, юл араларына кара белән язарга өйрәндек. Әле бүген дә мәктәптә ятлаган шигырьләрне хәтердән сөйләп шаккатыра алам. Авылда туганнар булмагач, мин кечкенәдән үк бар эшләрне дә үзем эшләргә өйрәндем. Безнең  кәҗәләр бар иде, кәҗә бәтиләрен суярга күрше бабайга әйтә идек, чөнки авыл бәләкәй, ир-атлар сугышта үлеп калаганнар, ир-ат – шушы бабай гына. Миңа  9-10 яшьләр тулгач, карт бабай: “Улым, хәзер үзең эшкә өйрән, мин – карт, хәлсез, үлсәм сине эшкә өйрәтүче булмас”, - дип, миңа кәҗә бәтиләре, сарыклар суярга өйрәтте. Шулай итеп, “зур егеткә” әвереелдем, авылдашларга да терлекләр суя башладым һәм шушы һөнәремне гомерем буена ташламыйча, авылда да терлек суеп йөрдем.

Сез бәхетле, уйнарга уенчыкларыгыз, ашарга ашамлыклар, кияргә киемнәрегез, яшәргә җылы өйләрегез бар. Безгә боларның берсе дә эләкмәде. Газиз әтиемнең йөзен дә

күрә алмадым, карточкасы да юк. Тормышның кадерен белеп, яхшы укыгыз, эшне яратыгыз,” – дип безгә үгет–нәсихәт бирә бабай безгә.

**Йомгаклау**

Тиздән - Бөек Җиңү көне. Аның быел 79 еллыгын бәйрәм итәбез. Совет солдаты бирешмәде! Туган ил хакына, аның бердәм халкы, туганнары, дуслары, сабый чаклары куркыныч сугыш елларына туры килгән газиз балалар хакына алар барлык авырлыкларга да түзде һәм җиңде! Аларга дан һәм чын күңелдән рәхмәтебез! Безнең буынны саклап калган кешеләрнең батырлыгы беркайчан да онытылмас! Дөньяда яшәүче барлык кешенең бер теләге бар – туган илдә тынычлык булсын! Аларга мәңгелек дан һәм мәңгелек хөрмәт! Ә безнең бурычыбыз – ул еллардагы халыкның батырлыгын үзебездә онытмыйча, бездән соң килгән буыннарга да тапшыру.

Сугыш һәйкәлләре һәр урында:
Ишетәсезме, авылдашлар!
Безне беркайчан да
Начар яктан искә алмагыз,
Һәр ел Җиңү бәйрәме көнендә
Һәйкәлгә чәчәк куймый калмагыз!

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм фаҗигале көннәре елдан-ел ераклаша бара. Ләкин халкыбыз кичергән ул кайгы-хәсрәтләр һичкайчан онытылмас... Бөек Ватан сугышы тәмамланганга, никадәр вакыт үтсә дә, аның хәтирәләре күңелләргә тирән сеңеп калган. Язлар җитү белән Җиңү бәйрәмен билгеләп үткәндә бу вакыйгалар кабат искә төшә.

Сугышлар булмый корбансыз.
Ансыз – юк Җиңү туе.
Ә без үлгәннәр алдында
Бурычлы гомер буе!

**Әдәбият исемлеге**


1. Гаилә архивындагы фотосурәтләр.
2. Мемориал Великой Отечественной войны – obd-memorial.ru
3. Книга памяти. Хәтер китабы. – Казань: издательство «Книга Памяти»,1995г.
4. Россия Федерациясе Хәрби Министрлыкның Үзәк архив справкасы.
5. “Подвиг народа” сайты материаллары.

*Гыймаев Рәмис, 3 нче сыйныф,*
*Газымова Динә, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Мөслим районы Баланлы төп гомуми белем бирү мәктәбе,*
*Җитәкче: Газымова Г.Р., башлангыч сыйныф укытучысы*

## Авылымның күренекле шәхесләре

### Кереш

Туган як, туган җир, туган авыл...Һәркем өчен изге, газиз, кадерле ул. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас, кабатланмас истәлекле урыннары, горурланырлык күренекле шәхесләре була. Туган төбәгебезнең һәр агачы, һәр сукмагы, һәр кешесе безгә таныш һәм якын. Шуңа күрә без аның тарихын яхшы белергә, табигатен сакларга, кешеләре белән горурланырга тиеш. Ә андый шәхесләргә авылыбыз бай.

Татарстанның атказанган укытучысы Расих Нурулла улы Сафин, Алтын Барс иясе, TMTV премиясе лауреаты, күп конкурслар җиңүчесе, җырчы Гибадуллина Лилия Наил кызы(Чәчкә), I һәм II дәрәҗә Дан ордены кавалеры Кәримов Сәгадәт Вахит улы, Социалистик Хезмәт Герое, Бөек Ватан сугышы ордены кавалеры Кашапов Зәкәрия Кашап улы, Казан дәүләт университетының Алабуга филиалы доценты, кафедра мөдире, филология фәннәре кандидаты Даутов Гомәр Филгиз улы кебек шәхесләр белән авылыбыз хаклы рәвештә горурлана. Алар Татарстанның гади генә бер татар авылын дөньяга таныталар. Үз хезмәтебездә шундыйларның берсе – сирәк һөнәр иясе, сынчы Илисәй Имаметдин улы Имамовның тормыш юлын һәм эшчәнлеген чагылдырдык.

### Эшебезнең максаты:

Авылыбызда яшәгән, эшләгән һәм үзеннән соң якты эз калдырган атаклы шәхесләрне барлау; шуларның берсе - сирәк һөнәр иясе Илисәй Имаметдин улы Имамов эшчәнлеген өйрәнү.

### Бурычлар:

- милләтебезгә, мәдәниятебезгә, туган төбәгебезгә, хезмәткә мәхәббәт, кешелеклелек, мөстәкыйльлек тәрбияләү;
- гаилә һәм күренекле кешеләр тарихын өйрәнү, гаиләнең гореф-гадәтләренә ихтирам тәрбияләү;
- авылыбыз горурлыгы булган сынчы Илисәй Имамовның тормыш юлын, эшчәнлеген өйрәнеп, аның турында бүгенге яшь буынга мәгълүмат бирү.

## Эшебезнең актуальлеге

Һәр җирдә авылы горурлыгы булырдай, шул авылны таныткан шәхесләр яши. Алар бик тыйнак һәм үзләрен күрсәтергә яратмыйлар. Бу хезмәтебездә тасвирланган шәхес тә нәкъ шундыйлардан. Ул – җирлегебездә генә түгел, ә ил күләмендә танылган шәхес. Аның хезмәтләре бүген Татарстан һәм Рәсәй күргәзмәләрендә лаеклы урын алган. Илисәй Имамов исеме белән рәттән Баланлы атамасы да янәшә йөри. Мондый шәхесләр булганда, авыл яшәячәк. Үзен хөрмәт иткән һәр кеше алар турында белергә, мәгълүмат тупларга тиеш. Безнең бу хезмәтебезнең максаты да шуңа юнәлтелгән.

Максатыбызга ирешү өчен, Мөслим муниципаль районы “Туган якны өйрәнү” музее һәм Баланлы төп гомуми белем бирү мәктәбе музей документлары белән таныштык, китаплардан, интернеттан мәгълүмат алдык, фотолар тупладык, авылыбыздагы өлкән кешеләр белән очраштык. Авылымның, чыннан да, бай тарихлы булуына һәм бу тарихны тудыручы кешеләре булуына инандык.

Кызганычка каршы, бүгенге буын мондый шәхесләрен белеп бетерми, өйрәнми. Бу хезмәтебез горурлыгыбыз булган авылдашыбыз турында бүгенге буынга сөйләү һәм киләчәк буынга калдыру өчен эшләнде. Аны класс сәгатьләрендә, класстан тыш чараларда, тарих, әдәбият, география, технология дәресләрендә кулланырга була. Хезмәтебезне районыбызның “Туган якны өйрәнү” музеена һәм мәктәп музеена да тапшырачакбыз.

**Хезмәтебез өч өлештән тора:**

I. Кереш өлеш. Авылымның күренекле шәхесләре. Бу бүлектә авылыбыз горурлыгы булган шәхесләр - Татарстанның атказанган укытучысы Расих Нурулла улы Сафин, Алтын Барс иясе, TMTV премиясе лауреаты, күп конкурслар җиңүчесе, җырчы Гибадуллина Лилия Наил кызы(Чәчкә), I һәм II дәрәҗә Дан ордены кавалеры Кәримов Сәгадәт Вахит улы, Социалистик Хезмәт Герое, Бөек Ватан сугышы ордены кавалеры Кашапов Зәкәрия Кашап улы, Казан Дәүләт университетының Алабуга филиалы доценты, кафедра мөдире, филология фәннәре кандидаты Даутов Гомәр Филгиз улы турында кыскача мәгълүмат бирелде.

II. Төп өлеш. Авылымны дөньяга таныткан шәхес. Бу бүлек тулысы белән үз куллары белән күпләрне таң калдырырлык шедеврлар иҗат иткән авылдашыбыз – сынчы Илисәй Имаметдин улы Имамовның тормыш юлы һәм иҗатына багышланды.

III. Йомгаклау. Сирәк очрый торган талант иясе бүген дә хезмәттә. Бу бүлектә авылны данлап яшәүче Илисәй Имамовның бүген дә халкына кирәкле булып яшәве, авылның киләчәге булуда зур өлеше турында тасвирланды.

## Төп өлеш

## Авылымны дөньяга таныткан шәхес

Табигатьнең иң матур почмагына урнашкан Баланлы авылы. Ерак бабайларыбыз кушкан бу исемне халкыбыз горур йөртә. Бүген дә авылыбызны тирә-яктан баланнар урап алган. Ул баланнар язларын бөтен тирә-якны ап-ак чәчәкләргә күмә, ә көзләрен кып-кызыл баланнары белән күзләрне иркәли. Ел тәүлеге һәр йортта тирә-якта тиңе булмаган балан бәлешләре пешә. Исемен җисеменә туры китереп, табигате белән дә, уңган-булган халкы һәм күренекле шәхесләре белән дә горурланып яши авыл.

Туган туфрагыннан аерылмыйча, үз җиренең табигатенә, кешеләренә сокланып иҗат итүче, чын сәнгать әсәрләре тудыра алучы шәхесләр бар авылда. Шундыйларның берсе - Татарстанда гына түгел, илебез горурлыгы булырдай шәхес – Имамов Илисәй Имаметдин улы. Бик мөлаем, сөйкемле һәм аз сүзле. Үз куллары белән могҗизалар тудыручы гап-гади татар егете кешеләрне таң калдырырдай шедеврлар иҗат итә.

Имамов Илисәй Имаметдин улы 1932нче елда Мөслим районы Баланлы авылында гап-гади крестьян Имаметдин һәм Фатыйма гаиләсендә төпчек бала булып дөньяга килә. Үз көчләре белән көн күреп, гаиләсен мул яшәтә белгән Имаметдин абыйны да, кулаклар рәтенә кертеп, авылдан кумакчы булалар. Ләкин Имаметдин абыйның алтын куллары гаиләне коткарып кала. Авылның комсомол оешмасы секретаре аңа В.И.Ленинның сынын ясап бирүен үтенә. Имаметдин абый аны бик оста итеп башкарып чыга. Район җитәкчеләре дә, аның хезмәт җимешен күреп, тел шартлаталар. Кечкенә Илисәй дә әтисе янында бөтерелә. Кирәк коралларын алып килеп бирә, эш урынын үзенчә җыештырып куя. Әтисе хәтта аңа сынның кайбер урыннарын шомартуны да ышанып тапшыра. Мондый хезмәте үсеп кенә килүче малайга хисапсыз зур шатлык китерә, киләчәк тормыш юлына бер юнәлеш булып формалаша. Мәктәпне тәмамлауга, Илисәй абый Лаеш авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә. Хезмәт юлын шофер булып башлый, хисапчы була, күп еллар умартачы булып эшли. Һәр эшне җиренә җиткереп башкара. Хезмәте үзенең җимешләрен дә мул бирә. Бу турыда аның күпсанлы бүләкләре, Мактау грамоталары сөйли. Ул - хезмәт ветераны.

Авылыбыз уртасында чәчәкләргә күмелгән һәйкәл бар. Күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп иткән бу һәйкәлне Илисәй абый иҗат иткән.

Каян килгән икән аңа һәйкәл ясау фикере? Соравыбызга җавап табу өчен, бөтен кыюлыгыбызны җыеп, аның өенә барабыз. Илисәй абый безне, иң кадерле кунагы килгәндәй, ачык йөз белән каршылый. Сорауларыбызга рәхәтләнеп җавап бирә, шаяртып та ала.

Балачагы каһәр суккан сугыш елларына туры килгән икән Илисәй абыйның. Сабый килеш шул елларның ачысын-төчесен күп татый ул. Әтисе, сугышның бөтен авырлыкларын күреп, Берлинга кадәр барып җитә. Абыйсы Закирҗан фронтта һәлак була. Үсмер малай шуларның барысын да күңеле, йөрәге аша үткәрә. Бар күңелләрне тетрәндерерлек һәйкәл ясыйсы килә аның. Еллар үткән саен, бу хыялы һич тынгылык бирми. Тик моны ничек башкарып чыгарга? Эшне нидән башларга?

Дөрес, кечкенә чакта ул балчыктан кошлар, куяннар әвәләргә, төрле сурәтләр ясарга ярата. Бераз агач эше белән дә шөгыльләнә. Илһамланып китеп, киндергә зур рәсемнәр ясаган чаклары да була. Вакытында Ленин бабайга һәйкәл ясаган әтисе янында бөтерелгән Илисәй, тәвәккәлләп, эшкә тотына.

Иң элек һәйкәл өчен материал табарга кирәк була. Сарман районы Мортыш Тамагы авылы янындагы карьердан таш алып кайталар. Кирәклесен Илисәй абый үзе сайлап ала. Ташны уяр өчен, кирәкле коралны тимерчелектә ясыйлар. Корычны чыныктырып, кискечләрнең эресен-вагын - төрлесен үз куллары белән әзерли. Ул арада аның күңелендә булачак һәйкәл дә торган саен ачыграк күзаллана бара.

Бу эшкә ул февраль аенда керешә. Көнне төнгә ялгап эшли Илисәй абый. Йокламаган чаклары да, хәлдән таеп арыган вакытлары да күп була. Андый вакытларда маңгаеннан аккан тирләрен сөртеп ала да тагын эшкә керешә. Тырыш хезмәт нәтиҗәсен дә бирә: өч ай дигәндә, һәйкәл әзер була. Бөек Җиңү бәйрәме алдыннан, бишенче май көнне, һәйкәлгә соңгы нокта куела! Җиңү көнендә бөтен авылдашлар, кунаклар җыелып, һәйкәл ачу тантанасы үткәрелә. Бу 1970 нче елның 9 нчы мае була. Авылым тарихына кызыл хәрефләр белән языла бу көн.

Авылыбызның уртасында балкып торган һәйкәл әнә шулай калкып чыга. Һәр көнне мәктәпкә барганда, без аңа карап, батырларыбызга рәхмәт йөзеннән, башыбызны иеп үтәбез. Баланлының йөрәге булган бу һәйкәлне авылдашыбызның ясавы бездә зур горурлык хисе уята. Һәйкәлгә булган соклануыбыз тагын да арта. Һәр штрихына, һәр рәсеменә игътибар белән карыйбыз...

Уң кулына автомат тоткан сугышчының сул беләгендә сабый бала. Сабыйның кулында – икмәк. Сугышчының да, баланың да карашы еракка – киләчәккә төбәлгән. Димәк, киләчәк бар, килер буын үсеп килә. Алар әле җиребезне чәчәккә күмәчәк. Алар бүгенгене киләчәккә алып барачак. Ә матур киләчәкне безгә, сугышның бөтен михнәтләрен күреп, гомерләре хисабына җиңү яулаган әтиләребез, бабайларыбыз бүләк иткән. Баланы күкрәгенә кыскан сугышчы ул – сугыш кырында ятып калган авылдашларыбыз. Һәйкәл әнә шул хакта сөйли, үткәннәрне онытмаска куша. Онытмый халкыбыз. 128 авылдашыбызның

исеме кызыл хәрефләр белән уелган монда. Һәйкәлгә карап, һәркем үзенең газиз кешесен искә ала. Исемлектән якын кешесен эзләп таба, бармаклары белән хәрефләрен сыйпап үтә.

Югары сәнгать таләпләреннән чыгып караганда, бу сын бик үк камил булып җитмәгәндер, ләкин аңа карагач, авыл кешеләренең һәркайсы үзенең сугышта һәлак булган газиз кешесен искә төшерә. Илисәй Имамов иҗат иткән бу һәйкәл – хәтер, авыл тарихы. Аның тирәсендә хәзер ут кебек якты кызыл гөлләр чәчәк ата, төз наратлар тезелешеп үсәләр – боларны без, мәктәп балалары карап, тәрбияләп үстерәбез.

Илисәй Имамовтан ул чакта совхоз үзәге булган Михайловка авылына да һәйкәл ясавын үтенәләр. Хәзер Михайловка авылы уртасында да сугышчы сыны тора: андагы солдат үзенең яралы командирын ут эченнән алып чыкканда тасвирланган.

Һәйкәлләр һәр авылда, һәр шәһәрдә бар, ләкин мондыйлары бүтән беркайда да юк, фәкать шушы авылларда гына.

Шуннан башлап, ул бу эшнең бик тә, бик тә кирәк икәнлеген аңлый һәм агачтан бер-бер артлы сыннар уя башлый. Илисәй Имамовның “Студент кыз”, “Ана сагышы”, “Шүрәле һәм Былтыр”, “Герой”, “Көрәшчеләр”, “Әлмәндәр карт”, “Йөзембикә”, “Су анасы” дип аталган эшләре зур урын биләп тора. Хәзерге вакытта бу сыннар район мәдәният йорты күргәзмәләр залында урнаштырылган. ”Ана сагышы” дип аталган эшкә аерып тукталып үтәсебез килә, чөнки аның үзенең бер тарихы бар. Илисәй Имамовның иҗаты хакында белеп, Баланлыга журналистлар килә башлый. Ул ясаган сыннарның рәсемнәре ил буйлап тарала торган журналларда басылып чыга. Шулай бервакыт Илисәй абыйга Житомир өлкәсеннән хат килеп төшә. Бу хатта: ”Безнең авылда фашистлар 480 өйне яндырып, кешеләрне һәлак иттеләр, шулар истәлегенә берәр әсәр иҗат итә алмассызмы? ”- дип язылган була..

Бар күңелләрне тетрәндерерлек “Ана сагышы” дигән сынны Илисәй Имамов шуларның үтенечен күздә тотып эшли. Аның фотосын Житомир өлкәсенә җибәрә. Аннан: “Бу эшегез безгә бик ошады, инде сынның үзен җибәрергә җай таба алмассызмы? “- дип язалар.

Үтенечне үти алмый Илисәй абый. Сын авыр булганга, почтада алмыйлар, ә башкача җибәрү чарасын ул таба алмый. Бүген үзенең хезмәт җимешләрен музейларда күреп, халкына файда китерә алуына сөенеп яши күренекле авылдашыбыз.

## Йомгаклау

### Туган авылын дөньяга таныткан шәхес бүген дә хезмәттә

Илисәй Имамов – сирәк очрый торган, гаҗәеп талант иясе. Шул ук вакытта, талант ияләренең күпчелегенә хас булганча, ул үзенең хезмәтләре турында кычкырып, үзенә игътибар таләп итеп йөри белми.

1977нче елда Имамов үзешчән рәссамнар республика күргәзмәсендә катнаша һәм **лауреат** исемен ала. 1997 нче елда **II Бөтендөнья татар конгрессында да**, аның эшләрен карап, зур бәя бирәләр. 1999нчы елда ул **"Ел ир-егете" призына** лаек була һәм Татарстан президенты М.Ш.Шәймиев белән очрашуда кунак булып катнаша.

Соңгы елларда Илисәй абый картиналар ясау белән шөгыльләнә. Аның һәр иҗат эше таң калырлык. Бүген дә әле аның эшләре Казан, Мәскәү күргәзмәләрендә йөри.

Эшебездә куйган максатыбызга ирештек дип уйлыйбыз. Максатка ирешер өчен, музей документлары белән таныштык, китаплардан, интернеттан мәгълүмат алдык, фотолар тупладык, авылыбыздагы өлкән кешеләр белән очраштык. Хезмәтебезнең – төп герое Илисәй абый Имамов белән берничә тапкыр очрашуда булдык. Аның иҗат җимешләре тарихын белдек. Авылымның, чыннан да, бай тарихлы булуына һәм бу тарихны тудыручы гаҗәеп талантлы кешеләре булуына инандык. Авылыбыз турында шактый күп белешмә алдык. Башкалар сокланырлык матур якларын: данлыклы, эшчән кешеләрен, гүзәл эшләрен күрсәтергә тырыштык. Еллар үткән саен, шактый сандагы авылларның юкка чыгуларын беләбез. Ләкин безнең авылыбыз яшәячәк, чөнки буыннар чылбыры өзелмәгән. Киләчәгенең матур буласына ышанып, үткәннәрне онытмыйча, шөкер итеп яши белә халкыбыз. Шулардан чыгып, без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Милләтне яшәтүче көч ул – татар авыллары һәм аның халкы.
2. Авылның киләчәген аның күренекле шәхесләре, талантлы кешеләре, уңган-булган халкы тәэмин итә.
3. Сирәк очрый торган һөнәр иясе Илисәй Имаметдин улы Имамов – авылыбызны дөньяга таныткан шәхес, халкыбыз горурлыгы.

**Файдаланылган әдәбият**

1.Мөслим төбәге. Әхмәтгалиев Ә.Ә. "Яр Чаллы типографиясе"2003.

2.Мөслим – безнең йөрәкләрдә. Әхмәтҗанов М.З. "Ихлас" Казан. 2018.

3. Без – Мөслим балалары. Баһаутдинов Ф.Н. "Идел-Пресс" Казан.2006

Эшне башкарганда, түбәндәге материаллар кулланылды:

1. Мөслим муниципаль районы "Туган якны өйрәнү"музее, Баланлы төп гомуми белем бирү мәктәбе музееннан алган мәгълүматлар;
2. Хезмәтебезнең төп герое Илисәй абый Имамов белән очрашу материаллары;
3. Илисәй Имамовның тормыш иптәше Илгизә Шәйхетдинова, укытучылар Сафин Ф.Н., Сафина Г.К., Газымова Г.Р. истәлекләре.

*Еремеева Ильвина,  9 нчы сыйныф,*
*“Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен 18 нче Түбән Кама мәктәбе” дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Гөлсара Минрәхим кызы, Гыйлфанова Гөлназ Рәшит кызы татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## Кызыл Чапчак авылы тарихы

### I.Кереш өлеш

Туган җир... Туган авыл... Туган йорт...

Алар безгә күз карасыдай кадерле һәм газиз. Аларда безнең нигезебез, тамырларыбыз һәм киләчәккә өметебез. Авыл көннән – көн матурая. Авылдашларыбыз әби – бабай нигезендә барлык уңайлыклары булган яңа йортлар сала. Туганнарың йортына кайтып керү – иң зур бәхет бит ул.

Хәзерге Кызыл Чапчак авылы янәшәсендәге тауда X-XII гасырларда Болгар дәүләтенең көнчыгыш чикләрен саклаучы ныгытма – кала урнашкан булган. Авыл картлары әйтүенчә, бу тауның биеклеге 110 метрлап булыр. Кала Тауга унынчы гасырда нигез салынган дип әйтәләр. Монда хуҗалык корылмалары урнашкан булгандыр. Шушы җирдән пычак, кадак, йозак - бик һәм башка әйберләр табып алганнар. Табылган керамика калдыкларыннан чыгып, биредә болгарлар һәм угырлар бергә яшәгән дип әйтә галимнәр.

Кала Тау XII гасыр азагы – XIII гасыр башында яшәүдән туктаган дип әйтәләр. Кала Тауны җимергәннәрме – юкмы – анысы хәзергә сер булып кала.

Кала Тауның тирәсендә болгар авыллары да күп булган. Шәңгәлче авылы янындагы эзләнүләр барышында табылган керамика калдыклары, келәтле һәм Шәңгәлче авыллары арасындагы Алтын Урда чорына караган борынгы кабер ташлары, Кызыл Чапчак белән Түбән Чаллы арасындагы изгеләр каберлеге әнә шуңа дәлил.

Тарихын белгәннең генә киләчәге бар дип юкка әйтмиләр. Чыннан да тарих үзен хөрмәт иткәнне ярата. {Мофаздалова Фирая. Монда Кала Тау булган, диләр...// Туган як. – 2005.- 30 июль. – Б.1-2.}

**Фәнни  эшнең максаты**: Кызыл Чапчак авылының тарихын өйрәнү. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

1) Бу өлкәгә караган әдәбият белән танышу;
2) Кызыл Чапчак авылына кунакка кайту;

Өйрәнү **объекты**: туган як тарихы.

Тикшерү **предметы**: Кызыл Чапчак авылы.

Тикшерү **гипотезасы**: һәр кеше үз иленең тарихын белергә тиеш.

Тикшерү **методикасы.**

Эш барышында төрле чыганаклардан файдаланылды.

1) Авыл китапханәсенә бару.

2) Авылның өлкән кешесе - Галимов Зәкәрия абый белән очрашып фикер алышу.

**II.1. Кызыл Чапчак авылы турында мәгълүмат**

Кызыл Чапчак авылы Түбән Кама шәһәреннән - 33, Югары Чаллы авылыннан 6 чакрым ераклыкта урнашкан. Ни өчен Чапчак һәм кызыл соң ул? Авыл халкы кисмәк ясап саткан. Ә кисмәкне “чапчак” дип йөрткәннәр. “Чапчак” атамасы шуның нигезендә барлыкка килгән дигән фикер яши. Авыл Чапчакка кадәр “Кыпчак” дип йөртелгән, ә “кызыл” сүзе аңа соңыннан тагылган, чөнки авылдан ерак түгел иңкүлекләрдә зирек агачы үскән, ә ул агачтан безнең авылда кисмәк ясаганнар. Ул чорда бу тирәләрдә хәзерге кисмәкне “чапчак” дип атаганнар. Зирек агачы, кисеп согы акканнан соң, кызыл төс ала, шуңа күрә авылга “Кызыл Чапчак” дип исем кушканнар.

1970 нче елда Кызыл Чапчакта 103 йорт булып, аларда 372 ир – ат һәм 364 хатын - кыз яшәгән, анда бер мәчет һәм мәдрәсә булган. Авыл халкы умартачылык белән шөгыльләнгән. Кызыл Чапчак авылында яшәгән күренекле шәхесләр дә билгеле. Күренекле шәхес Таҗетдин Ялчыгол башта Кече Сөндә, соңыннан Җирекле, Кызыл Чапчак, Мәлем авылларында балалар укыта, халык арасында табиблык итә һәм әдәби иҗат белән шөгыльләнә.

Кызыл Чапчак авылы халкы элек Сары айгыр җыены үткәргән. Җыенда иң кызык мизгел - ат чабыштыру.

Авыл аша А.С. Пушкин да сугылган. “Капитан кыз” ын язар алдыннан, Оренбургка барышлый, 1833 елның сентябрендә тукталган. Казаклар авылына бара торган юлны хәзер дә “Пушкин юлы” дип йөртәләр. Авылда сәүдәгәр - миллионер Стахеевлар кибетләр тоткан. {Гарипова Фирдәвес. Авыллар һәм калар тарихыннан.- Казан, 1997.- 225-228 б; Татарстан яшьләре.- 2008.-16 сентябрь.- 3 бит.}

**II.2.Авылның тарихы исем-атамалары. Басулар**

Авылны чыгып, Үчкә авылына киткәндә, сул яктагы басу “Бүре басуы” дип атала. Сартамактан алып, Олы Сазга кадәр Бүре басуының урталыгында өч нарат утыра иде. Хәзер алар юк инде – яшен сугып янып беттеләр. Элекке елларда бу урын бик шомлы урын була. Ул турыда мондый риваятьләр йөри: Нурый Җәләе төнлә кайдандыр кайтып килгәндә, шушы өч нарат турына килеп җиткәч, нараттан алтын коела башлый. Бу алтыннарны

кесәсенә, алъяпкычына тутырып кайтырга чыккач, кемнәрдер алтыннарын талап качалар. Өенә кайтып кергәч, хатыны берәр алтыны эләгеп калмады микән дип, киемнәрен дә актарып карый, әмма таба алмый. Бу нарат турында Өлфәт Миңнехановның Үчкә авылы тарихында язылган.

Бүре басуының көньяк-көнбатышында, Олы Сазның көньяк очында, Сары Айгыр печәнлеге бар. Бу урында сары төстәге айгыр чабышта үлә. Шул очрактан соң безнең авыл җыенын - "Сары Айгыр җыены" дип йөртәләр.

Бүре басуы белән Үчкә авылы арасындагы үзәнлек Олы Саз дип йөртелә. Бу сазлыкны күтәртеп юл төзегәнче, яз-көз моннан турыга йөрешле булмый. Элегрәк, бу араның юлы өч нарат яныннан "Пушкин юлына" менеп, Үчкә авылының зират очыннан йөрешле була.

Олы Сазның Үчкә авылы янындагы иңкүлеге "Акчарлак" дип йөртелә. Акчарлактан төньякта, Зәй буенда, "Имән тау" дип атала торган атау бар иде. Аннан авылга таба Олы болын, болын эчендә – Аты күле (Атыдан төшкән су элек шуннан аккан). Болын уртасында Мулла тавы (муллага бүлеп бирә торган печәнлек) – "биш кибән" биләмәсе.

Болын белән күпердән түбән өлеше "Бәләкәй басу" дип йөртелә.

### II.3.Таулар

Авылыбызның символы булган, ерактан күренеп торган беренче тау - Кала Тау – бик күркәм урын. Авылда туып-үскән һәр бала, яшьләр арасыннан анда менеп сокланмаган кеше юктыр. Тау өстеннән якын-тирәдәге 14 авыл күренә. Зәй елгасы, басу-кырлар, көньяк горизонтта тоташ урман, арткы якта – Фазлый урманы (сугыш чорында һәм аннан соң озак еллар урманчы хезмәтен Фазлый исемле кеше башкарган).

Болгар ханлыгы чорларында тау башында ныгытма төзелә. 2008-2010 елларда археологлар казу эшләре алып барып, күп кенә экспонатлар – көнкүреш кирәк-яраклары таптылар, ныгытманың чикләрен билгеләделәр.

Икенче тау – Туры юл тавы.

Өченче тау – Мөсәгыйт тавы. Мөсәгыйт (Мозаффар, Хәбибулла муллаларның аталары) сәүдәгәр була. Чургат ягыннан товар алып кайтканда, аны үтереп ташлыйлар. Авыл муллалары, исереп үлгән дип, зиратка керттермиләр, шунда күмәләр. Бу – телдән-телгә күчкән хикәят.

Дүртенче тау – "Мордый", Морзахан исеме белән йөртелә.

Аның янәшәсендә "Мозаффар чишмәсе", "Мозаффар чүнниге" дигән урманлык бар, "йөрәк" дип тә йөртәләр. Хәзер ул урынны авыл яшьләре матурладылар. Чишмә улактан ага, кереп ял итәргә кечкенә генә өй ясалган, утыргычлар куелган.

Мозаффар (Саттар, Япбар, Ханнан, Мәннән, Хәбибуллаларның аталары) умартачылык белән шөгыльләнгән.

Бишенче тау - Җәрәмәй, аннан китә Яктый һәм соңгысы – Тирән-сыза (Үчкә авылы басуы чигендә).

### II.4. Җуелмас хатирәләр. Галимов Зәкәрия абый язмалары

Авыл халкы иген игү белән шөгыльләнә. Күбесенчә безнең авыл халкы Ширәмәт җирләренә "боярларга" иген игәргә йөри. Хәзерге "Трудовой" совхозы җирләре "Бикә бояры" җирләре була. Андагы урман хәзер дә "Бикә урманы" дип йөртелә. Авылда игенчеләрдән кала оста һөнәрчеләр дә була. "Салахи яргычы" белән Салахиның Борһан исемле улы колхозлашу чорына кадәр тары, солы ярдыра торган була. Шул ук Салахи картның ике улы – Зиатдин абый белән Гыйлаҗетдин абыйлар - оста тегүчеләр. Нуруллина Җүәйрә, Шәфыйкова Тәнвирә, Нәфыйкова Нәфисәләр авыл халкына кием-салым тегәләр.

Сугыш алды елларында безнең авыл халкы чагыштырмача яхшы яши башлый. Күмәк хуҗалык булгач, бар халык эшкә чыга, өйдә ялкауланып ятмый. Бөтен халык күз алдында булгач, урлашу да булмый, басуларны да саклый торган булалар. Мал-туардан, ят кешеләрдән урмандагы чикләвекне дә саклыйлар. Чикләвек өлгергәч, авылдагы бөтен кешегә чикләвек җыярга бер көн ял бирелә.

Халык белән эш алып барыла, патриотик тәрбия үткәрелә.

1939 елда авылда котычкыч хәл була. Көз көне кичен бар кеше тау башында иген җыйган вакытта, янгын чыгып, ярты авылның өен, каралты-курасын көлгә әйләндерә. Мәчет һәм аның кырындагы керосин складлы гына исән кала.

1941 елда игеннәрне, шул исәптән яшелчәләрне һәм печәнне җыю бик озакка сузыла, күбесе кар астында кала. Халык ачка интегә башлый. Аның өстенә кыш бик салкын килә. Декабрь, гыйнвар айларында температура – 43 градуска җитә. Утын әзерләү бик авырлаша. Менә шулай сугышның беренче кышын ач-ялангач, салкын өйдә чыгарга туры килә.

Аның өстенә фронтка ярдәм кирәк, һәр йорка бәрәңге, суган киптереп тапшырырга йөкләмә бирәләр. Малы булган кеше ит, сөт, йомырка, йон тапшырырга бурычлы була. Мәҗбүри йөкләмәдән тыш, авыл халкына ирекле йөкләмә дә салына: фронттагы сугышчыларга җылы бияләй, оекбаш, шарф бәйләп җибәрергә кушалар. Колхозның яхшы атларын, булган йөк машиналарын һәм башка техниканы фронтка озаталар. Кышын өй җылыту өчен, урманнан, тау буеннан, әрәмәлектән, чана тартып, корыган куак, чыбык-чабык ташып яга торган булалар.

### II.5.Дин вә йола

Совет вакытында динне ничек кенә кыссалар да, халык гореф-гадәтләрне саклап кала. Мәчетләрне япканнан соң да балага исем кушу, никахлашу, җеназа озату, Коръән ашлары уздыру кебек дин йолалары үтәлә. Ураза, Корбан гәетләрен я зиратта, я берәр кешенең ишек алдында, лапасында яшертен уздыра торган булалар. Җомга намазларын берәр кешенең өенә җыелышып укыйлар.

1990 нчы елда авыл картлары Сәхбетдин улы Гыйлметдин, Мортаза улы Мөхәммәтгариф, Әхмәтҗанов Исмәгыйль җитәкчелегендә мәктәпкә алынган иске мәчет бинасын кире кайтаралар. Урман алып, кайбер искергән урыннарын яңартып, мәчет төзү эшен 1991 нче елның язында башлыйлар. Мәчетне ачу тантанасы бер мең тугыз йөз туксан бишенче елның 4 мартында була. Бүгенге көндә дә әлеге мәчет авылдашларыбызны сөендереп тора.

### II.6.Мәктәп тарихы һәм укытучылар

Авылда 1900 нчы елда Казан байлары ярдәме белән беренче мәдрәсә салына. Авылда беренче хәлфә Шәрәпов Мөхетдин була, ул 40 ел буе балалар укыта.

Таш мәдрәсәдә башка авылдан килгән балалар да укыган. Революциягә кадәр бары тик дини фәннәр генә укытылган.

1917 нче елда укытучы булып Латыйпов Салих һәм Хисаметдиновлар эшли.

1919 нчы елдан 1927 нче елга кадәр Хәбибуллин Фатыйх, Хәбибуллина Гайшә, Сөендикова Зифа, Ситдыйковалар укыткан. Бу иптәшләр авылда беренче тапкыр театр оештырып, авыл яшьләренең тормышын күңелле итәргә тырышканнар. Алар арасында Зәкирә Якупова, Гариф Мортазин, Исмәгыйль Әхмәтҗанов, Габдулла Галиевлар иң активлары булган.

1932 нче елның көзендә мәктәп җидееллык колхоз яшьләре мәктәбенә әйләнә. Бу елларда Аксар, Шепкә авылларыннан укучылар килеп укыган. Директор булып Хәйруллин Мөбарәк эшләгән.

1935 нче елда яңа мәктәп бинасы төзелә башлый. 1938 нче елны җидееллык мәктәп яңа бинага күчә.

1932-1939 нчы елларда мәктәптә балаларга белем биргән укытучылар: Хәйруллин Мөбарәк, Хәйруллина Мәрхәбә, Байчурин Газиз, Сөнгатуллина Зәкия, Һидиятуллин Сәгадәт, Шаталина Анна, Сафин Хәйрулла, Шәрипов Хәйдәр, Фәррәхова Җәннәт, Шәйхнурова Кифая, Якупова Рәйсә, Хәлиуллин Габдрахман.

1939 нчы елның беренче сентябреннән җидееллык мәктәп урта мәктәпкә әйләнә. Мәктәпне ачып җибәрүче Миңнебаев Хуҗа була. 75 ел эчендә мәктәптә бик күп директорлар эшли. Алар бар да мәктәпне яхшырту, укучыларга һәм укытучыларга уңайлыклар булдыру өчен көчләрен кызганмыйлар.

Хәзерге мәктәп бинасын салдыруга үзенең бөтен көчен директор Яковлев Иван Яков улы куя. Үзе төзеткән мәктәптә эшләргә генә туры килми аңа. 2017 нче елда бу мәктәп ябыла, ә 2022 нче елда сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен төзекләндерелгән мәктәп яңадан сафка баса. Хәзерге көндә мәктәп директоры - Мөниров Рәмзин Рәфис улы.

### II.7.Мәдәният учагы. Клуб

Кызыл Чапчак клубының ачылу вакыты авылда колхозлашу чорына туры килә. Колхозлашу вакытында халык җыелышлары “пожарный өе”ндә уза торган була. Беренче киноны лапаста күрсәтәләр.

1933-1934 нче елларда авыл советы, колхоз идарәсе, клуб, китапханә төзелә. Клубның беренче мөдире булып, Идрисов Миңневәли эшли. Ул елларда клублар авыл халкын яңа тормышка өндәү өлкәсендә зур роль уйный. Авыл активистлары, яшьләр, мәктәп укытучылары мәдәни чаралар уздыралар. Ул чорда, ил үсешендәге яңалыкларны белеп тору өчен, яшьләр кичләрен клубка җыела, чөнки авылда радио, телевидение булмый. Ай саен өлкә комитетыннан, районнан лекторлар килеп, дөнья сәясәте турында лекцияләр укыганда, клуб шыгрым халык белән тула.

Сугыштан соң авыл өчен иске клуб кечкенә булып кала. 1973 нче елда агачтан зур клуб салына. 1987 нче елда агач клуб янганнан соң, 1990 нчы елны клуб һәм китапханә өчен бина төзелә. Бүгенге көндә Кызыл Чапчак авылы китапханәсе бөтен уңайлыклары булган махсус проект белән төзелгән. Якты, җылы, авыл мәдәният йорты тулы көченә эшләп килә. Китапханәгә килеп керүгә, гөлләрнең күплеге, зәвык белән бизәлеше сокландыра. Китапханәгә олылар да, балалар да яратып йөриләр. Китапханәчебез Нугалиева Зөбәрҗәт Миннәхмәт кызы үз эшен яратып, тырышып, бирелеп һәм белеп эшли .

## III. Йомгаклау

Фәнни эшкә Кызыл Чапчак авылының тарихын өйрәнүне максат итеп куйдым.

Әлеге максатка ирешү өчен, бу өлкәгә караган әдәбият белән танышу, авылның атаклы кешеләре белән очрашу бурычлары куелды.

Авылның тарихын өйрәнгәннән соң, түбәндәге нәтиҗәгә киләбез.

Кызыл Чапчак авылы искиткеч матур табигатьле урынга урнашкан. Бөек Тукаебыз тикмәгә генә: “Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява,”- димәгән. Әлеге сүзләр минем авылыма тулысынча туры килә. Авыл атаклы кешеләре белән дә аерылып тора һәм көннән-көн үсә, матурлана, зурая.

Минем фәнни эшем укучыларга, студентларга, укытучыларга методик әсбап булыр дип ышанып калам.

## IV. Әдәбият исемлеге

1. Чапчагым, син яшь чагым! / Р. Ә. Гыйльманова, Р. Ә. Борһанова. – Түбән Кама:2016.- 456 б

2. Буыннар чылбыры өзелмәсен / Гакиф Борһанов. – “Гүзәл” шәшрият- полиграфия үзәге. Түбән Кама . Март, 2016 ел

3. Гарипова Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан. – Казан, 2001.- 449 б

*Җиһагирова Сабина, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "20 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкче: Ләйсән Әнәс кызы Гарифуллина*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

## Дары исен вакыт оныттыра алмый

Максат: Чечен сугышы, Ватан сакчылары турында төшенчә бирү; Чечен сугышында хәрби бурычын үтәгән,Түбән Кама шәһәренең 20 нче мәктәп укучысы, батырларча һәлак булган герой Алексей Луговойның биографиясе белән танышу, киләчәк буыннарга аның батырлыгын таныту, ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү; Чечен сугышының илебез халкына алып килгән югалтулар турында төшендерү.

Эзләнү объекты: Герой Алексей Луговойның Түбән Кама шәһәре тарихында тоткан урыны. Аның батырлык тарихын мәңгеләштерү.

Эзләнүнең предметы: Түбән Кама шәһәренең 20 нче мәктәп тарихында Алексей Луговойның тоткан урыны.

Тикшерү ысуллары:

-сораштыру ысулы

-20 нче мәктәпнең “Сугышчан дан” музееның материалларын өйрәнү

- Алексей Луговойның кызы Екатерина Луговая, аның хезмәттәш дуслары, сыйныфташлары белән әңгәмә

-тарихи фактларны анализлау

Фәнни яңалык: тикшеренү эшенең яңалыгы шунда ки, тикшеренү материалы Чечен сугышының тарихи әһәмиятле вакыйгалары фонында Алексей Луговойның язмышын күзәтергә, биография материалларын системалаштырырга һәм эш өчен кулланырга мөмкинлек бирә.

Эшнең актуальлеге: патриотизмны сайлаган яшь буынлы дәүләтнең генә киләчәге бар!

**Кереш**

Халык массаларының күңелендә элек- электән үк Туган илгә мәхәббәт хисе яшәп килгән. Авыр сынау елларында, чит ил яулары һөҗүм иткән вакытларда патриотизм хисе халыкларны Ватанның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшкә күтәргән. Патриотизм, Ватаныңа, халкыңа, иң яхшы милли традицияләреңә карата мәхәббәт, ди В.И.Ленин, - “аерымланган ватаннарның гасырларча һәм меңелларча яшәве дәвамында ныгыган иң тирән хисләрнең берсе.

Батырлык ул – рухи матурлык... Әнә шуңа күрә халкыбыз кеше күңеленең рухи бөеклеген югары бәяләгән. Батырларның кылган изге гамәлләре, данлы исемнәре әкиятләргә күчкән, җыр- дастаннарга кергән. Каһарманлык, чорлар аша кичеп, бүгенге көннәргә килеп җиткән. Халкыбыз улларының һәм кызларының төрле сугыш чорларында күрсәткән тиңдәшсез фидакарьлекләре дә күңелдән мәңге җуелмас. Шул Олуг Батырлыклары алдында безнең дәвер кешеләре генә түгел, киләсе гасырларда яшәүчеләр башларын иярләр әле...

Күз яшьле, кан коюлы рәхимсез сугышларның соңгы бәрелешләреннән соң күп вакытлар аерып тора. Төрле сугыш еллары бездән никадәр ерагая барса, халык батырлыгының бөеклеге, җиңүнең дөнья күләмендәге тарихи әһәмияте безнең күңелләргә шулкадәр якыная бара.

Батырларыбызның күп булуы күңелле күренеш, әлбәттә. Өченче меңьеллыкның ишеген шакыганда : “Сугышларсыз гына яшәсәк иде киләсе елларда!”- дигән изге теләк уяна. Алдагы гасырларда яу кырында һәлак булган батырлар бөтенләй булмасын иде. Безгә, моңа кадәр булган каһарманнарыбызны данлап һәм хөрмәтләп, сабан тургайлы ямьле тормышта рәхәтләнеп гомер итәргә язсын иде!..

Россия тарихында күп сугышлар язылган. Аларның күбесе Азатлык өчен көрәш аркасында башланган. Ләкин ике төрле халыкның каршылыгы булган сугышлардан да начаррак нәрсә юк. Мондый сугышта кем дөрес, кем юк икәнен табуы бик авыр. Россия тарихының шундый кайгылы битләренең берсе -Чечен сугышы. "Бөтенләй бәйсез Чечня" тарихы болай башлана. «Перестройка» башлану белән Советлар Союзының төрле республикаларында, шул исәптән Чечен -Ингушетиядә дә, төрле милләтче хәрәкәтләр активлаша. Мондый оешмаларның берсе 1990 елда төзелгән Чечен халкының гомуммилли конгрессы була, аның максаты СССР составынан чыгу һәм бәйсез дәүләт булып калу. Конгрессны совет хәрби -һава көчләренең элекке генералы Джохар Дудаев җитәкли. Дудаев ил территориясендә хәрби хәрәкәт кертә һәм Ичкерия бәйсезлеге рәсми рәвештә

танылганчы Кремль белән сөйләшүләр алып барудан баш тарта. Шулай ук республика көчләре аның территориясендәге Россия гаскәрләренең хәрби базаларын басып ала.

1991 елның сентябрь башында Дудаевның Кораллы милли гвардиячеләре көч белән Министрлар Советы, радио һәм телеүзәк бинасын басып алалар, ә аннары, 6 сентябрьдә, Югары Совет утырышы барган бинага бәреп керәләр һәм революционерларга тиешле булганча, аны штурм белән алалар. Шулай итеп, Чечняда дәүләт түгәрәге оештырыла. Аның Югары Советы таратыла, һәм РСФСР Конституциясенең кайбер статьяларын бозып, 1991 елның 27 октябрендә Чечен Республикасы Президентын һәм Югары Совет депутатлары законсыз сайлаулар үткәрәләр.

Шул вакыттан башлап республикада социаль һәм икътисади хәл начарлана бара. Республика әкренләп криминаль дәүләткә әверелә.

1993 нче елда Ичкериядә оппозицияләр формалаша, алар режимны бозарга тырышалар.1994 нче елда республикада гражданнар сугышы башлана.

Россия армиясе 1994 нче елның 11 нче декаберендә сепаратистларга каршы сугыш хәрәкәтләре башлый. Шулай итеп, хәзерге Россия  тарихында иң каты сугыш башлана. Россия ягыннан бик күп солдатлар, хәрбиләр һәлак булган.

1996 елның 31 августында 1 нче чечен сугышы Хасавюртов килешүенә кул кую белән тәмамлана.

Икенче чечен сугышы 1999 нчы елда башлана һәм 2009 нчы елның апреленә кадәр бара. Чынлыкта ул 2000 нче елга кадәр Россия кораллы көчләре тарафыннан актив алып барыла.

Соңыннан, республика өстеннән контроль урнаштырылгач, банда төркемнәрен юк итү белән җирле хакимиятләр шөгыльлләнә башлый.

Ике чечен сугышында 600 меңнән артык солдат катнаша һәм берничә
меңе, кызганычка, әйләнеп кайтмый.

**Төп өлеш:**

Матурлыгы өчен бу көннәрнең
Кемнәр генә корбан булмаган!
Исемнәрен тарих безгә узе
Саклап килә ерак еллардан.

Чечен сугышы тарихы турында мин сәбәпсез генә язмадым. 9 декабрьдә  илебез Ватан Геройлары көнен билгеләп үтте. 2022 елда бу көнне, бәйрәм хөрмәтенә,Түбән Камада Төньяк Кавказда хәрби биремне үтәгәндә һәлак булган Алексей Луговойга мемориаль такта ачылды. Алексей Евгеньевич укыган 20 нче мәктәп фасадына аның исеме

язылган истәлек тактасы урнаштырылды. Тантаналы чарада Татарстан Республикасының икътисад министрының беренче урынбасары Олег Пелевин, Түбән Кама мэры урынбасары Марина Камелина, Түбән Кама муниципаль районының башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Айзат Мәхмүтов, Түбән Кама муниципаль районының ветераннар советы рәисе Григорий Китанов  Алексей Луговойның туганнары, аның курсташлары, дуслары, шулай ук мәктәп укучылары, локаль сугышларда булган интернационалист солдатлар һәм шәһәребезнең яшь юнармиячеләре төркеме  катнашты.

Чара Алексей Евгеньевичның туган көнендә узды.  Быел, 9 декабрьдә, аңа быел 51 яшь тулган булыр иде. Аны якыннан белгән кешеләр Алексей Луговойның тыйнаклыгын һәм намуслылыгын, максатчанлыгын искә алдылар.

Алексей Луговой 1973 елның 9 декаберендә Санкт- Петербург шәһәрендә туган. Әтисе һәм әнисе белән Красное селода яшәгән. Алексейга 7 яшь тулгач, гаиләләре белән Түбән Кама шәһәренә күченәләр. 1 нче сыйныфны ул 2 нче мәктәптә, 2нче һәм 4нче сыйныфларны  16 нчы мәктәптә, ә 5 тән алып 11 сыйныфка кадәр 20 нче мәктәптә белем һәм тәрбия ала. 20 нче мәктәпне Алексей бик яраткан, моны дуслары һәм гаиләсе дә искә алды. Дәресләрдән соң Алексей төрле түгәрәкләргә йөри. Ул тарих фәнен бик ярата, Вяткина Вера Петровна аның иң яраткан тарих укытучысы булган.  Алексей да тарих укытучысы булырга хыяллана. 20 нче мәктәпне тәмамлагач, Алабуга дәүләп педагогия институтына юл тота, имтиханнар тапшыра, тик конкурстан уза алмый.

1992 нче елда ул Россия Федерациясе эчке эшләр министрлыгының Санкт-Петербург университетына укырга керә, аны уңышлы гына тәмамлый. Юрист дипломы һәм лейтенант званиесы ала. Шушы уң университетта ”Гадәттән тыш хәлләр районында хәрбиләрнең гамәлләре” дип аталган диссертация дә яклый.

1997 нче елда  ул бүленеш буенча Кострома шәһәренә хәрби  хезмәткә жибәрелә. Костромага киткәндә, Алексей луговой гаилә корып китә. Юлия исемле бик матур кыз белән очрашып йөргән булалар. Юлия Луговая да иренә ияреп китә. 2 ел хезмәт иткәннән соң Алексей Луговой Костромадан кире Сантк- Петербургка кайта, анда  Лебяжьев бистәсендә 35-26 номерлы хәрби частьтә хезмәт итә.  Анда 1 ел хезмәт итә. 1998 нче елда аның кызы Екатерина туа.

1999 нчы елда Алексей Луговойны Чечняга  Гудермес шәһәренә 2 айга  хәрби командировкага озаталар. 8 гыйнвар көнне ул хатыны Юлиягә шалтрата, аның өчен борчылмаска куша. Ул вакытта аңа нде старший лейтенант звание биргән булалар. 8 нче гыйнварда  ул Грозныйга китәргә тиеш була, тик ниндидер сәбәпләр чыгып, үз урынына Михаил исемле хәрби егетне җибәрәләр.   9 гыйнварда Грозныйда урынсызлану(дисклокация) башлана. Иртәнге  сәгать 10 да 6 колоннадан торган

машиналар белән алар Грозныйга кузгалалар, тик Аргон тарлавыгында алар тозакка эләгәләр. Ике яктан аларны “Дошманнар” пулеметлардан ут ачалар. Бер- бер артлы машиналар яна башлый, ул иптәшләренә булышыр өчен машиналарны алар ягына борырга әмер бирә.Шул арада гранотометтан атып бензобакка тидерәләр, Алесекй Луговой машинасы шартлый һәм батыр егет янып үлә. Аның белән 38 хәрби солдат янып хәлак булалар. Алексей Луговой Батырлык ордены белән мәңгегә бүләкләнә.

Олег Пелевин билгеләп үткәнчә, Алексей Луговойның Ватанга мәхәббәте һәм сугышлардагы батырлыгы Татарстанлыларның күп буыннары өчен батырлык һәм батырлык үрнәге булачак: «Аның исеме алтын хәрефләр белән Түбән Кама, Татарстан һәм Россиянең тарихи елъязмасына язылды. Аның һәм аның батырлыгының якты истәлеге безнең йөрәкләрдә мәңгегә калды. Марина Камелина үзенең чыгышында Алексей Евгеньевичның кыска, әмма бик якты тормыш алып баруын ассызыклады: «Алексей Луговой- искиткеч кеше иде. Ул Ватанга хезмәт итүне сайлады, Ватанны яклады һәм чын ир-ат буларак үз бурычын ахырына кадәр үтәде. 20 нче мәктәпкә рәхмәт, алар үз укучыларын онытмыйлар һәм ел саен аның хөрмәтенә спорт һәм патриотик юнәлештә ярышлар үткәрәләр. Инициатива күрсәткән сыйныфташларыма рәхмәт, һәм бүген без истәлек тактасын ачтык. Барлык кешеләргә тынычлык теләр идем, илләребез имин булсын!”.

"Без үз батырлыклары белән Түбән Кама җирен данлаган кешеләрне искә төшердек. Алекей Луговой кебек егетләрнең Түбән Камада укыганнары һәм яшәгәннәре белән горурланабыз. Без аларны һәрвакыт истә тотарбыз», – дип өстәде Григорий Китанов. Алексей Луговой истәлегенә бер минут тынлык игълан ителде, шуннан соң хөрмәтле кунаклар, укучылар һәм барлык катнашучылар истәлекле мемориаль тактага чәчәкләр салдылар.

Санкт - Петербургтан Алексей Луговойның кызы Екатерина Луговая да кайткан иде. Ул әтисе үлгәндә нибары яшь ярымлык сабый гына булган. Ул хәтирәләре белән уртаклашты, әтисен онытмаулары белән горурлануын әйтте. Митингта Алексей Луговойны искә алырга сугыш кырыннан кайткан исән шәһәрдәш солдатлар, Әфган таулары арасында мәңгегә ятып калган, гүәдәләре кургаш табутта туган җир куенына кайткан яудашларның әниләре дә килгән иде. Солдат сугышны сайламый һәм аны игълан итми. Ул бары тик Ватан алдындагы бурычын үти. Алексей Луговой ил каршында биргән антына тугры калды!

Һәйкәл булып баса җиңүчеләр,  
Һәйкәл булып баса батырлар,  
Ә батырлар ике тапкыр үлми,

Җирдә алар мәңге балкырлар.

Һәйкәлләрне җансыз дия күрмә,

Һәйкәлләрнең җаны таш түгел.

Һәр һәйкәлдә күпме солдат җаны,

Һәйкәлләргә сыкрау хас түгел.

Җир йөзендә сугышлар башка кабатланмасын. Яшь егетләрнең гомерләре вакытсыз өзелмәсен, ата-аналар кайгы яше түкмәсен иде. Кеше җиргә яшәү өчен яратылган. Ә сугышлар алар безнең йөрәк яралары, мәңге төзәлмәс йөрәк яралары.

**Йомгаклау**

Ир- егетләрне патриотик рухта тәрбияләү безнең республикада күптәннән алып барыла һәм күркәм нәтиҗәләре белән тирә – юньдә дан тота. Казандагы Александр Суворов исемендәге хәрби училище, артиллерия, танк училищесында укып- белем алучылар да зур уңышларга ирешеп, илнең төрле почмакларында, төрле һөнәрләр буенча эшлиләр. Илнең оборонасын ныгытуда, яшь буынны тәрбияләүдә мөһим эш алып баралар.

Түбән Кама шәһәр һәм районының сугышчан хезмәткәрләре (солдатлар) төрле гаскәрләрдә уңышлы хезмәт итеп, үзләренең Ватан алдындагы бурычларын намус белән үтәп киләләр. Шул исәптән 654 солдат Әфганстан Демократик Республикасында намуслы хезмәт иттеләр. Төрле сугышчан бәрелешләрдә, низагларда катнашып, 107 кеше дәүләт бүләкләренә лаек булды. Алар арасында 2 офицер да бар.

Чернобыль атом электр станциясендә авария булганнан соң, 1986-1990 нчы елларда 214 түбәнкамалы ярдәмгә җибәрелде, алар анда да сынатмадылар, кушканны зур җаваплылык тоеп башкардылар.

Төньяк Кавказдагы бәрелешләрдән соң безнең хәрби сугышчылар читтә калмады. Анда барлыгы 951 кеше катнашты, алар арасыннан 19-ы һәлак булды, шул исәптән 2 офицерның да гомере шунда өзелде.

Замана үзгәрә тора, вакыт агышы хәрби комиссариатка да яңалыклар, бик күп катлаулы мәсьәләләрне башка төрле юл (цифралаштыру) белән хәл итүне алып килде.

Шәһәрнең хәрби комиссариаты тарихы Ширәмәт район хәрби комиссариатыннан нигез алган алган, аның тарих җепләре ерак сугыш елларына бәйләнгән.

1938 нче елда ук оешкан хәрби оешма бик катлаулы һәм тәҗрибәле сугышкан юл үтә. Бөек Ватан сугышы елларында иң җаваплы, кирәкле вазыйфаларны намус белән үти. Аның беренче җитәкчесе итеп II ранг техник- интендант Дмитрий Тетичкин санала. 1941 нче елның сентябрендә СССРның район һәм өлкәләреннән Ширәмәт авылына бик күп эвакуацияләнгән халык күчә, аларны урнаштыруны, хәрби исәпкә алуны штаб җиренә җиткереп башкара.

Сугыш елларында әлеге районнан гына 7833 кеше мобилизацияләнә (районның 17% кешесе!). Аларның нибары 2010ы гына әйләнеп кайту бәхетенә ирешә. Хөкүмәт бүләкләрен 1884 кешегә тапшыралар. Яралану һәм контузия алу аркасында 290 кеше инвалид булып кала.

Бүгенге көндә шәһәрдә яшьләрне сугышчан- патриотик рухта тәрбияләү тулы көченә эшли. Аның үрнәге булып шәһәрнең 14 нче юридик лиөеенда ачылган полиөия класслары, 31 нче гомуми белем бирү мәктәбендә ачылган янгын сүндерүчеләр класслары, Гани Сафиуллин иремендәге кадет- интернат мәктәбен китерергә була.

Гомумән, шәһәребездә һәм республика күләмендә хәрби- сугышчан тәрбия югары дәрәҗәдә. Илебезнең иминлеген, аның чикләрен саклаучы лаеклы алмаш үсә дияргә тулы нигез бар.

**Кулланылган әдәбият**


1.Айдаева Ю.А. Чеченцы: история и современность.- Москва: Издательство “Время”, 2009.

1. Гыйлманов Җ.И. Советлар Союзы Геройлары – якташларыбыз: Әдәби- документаль очерклар һәм язмалар.- Казан: Татар.кит.нәшр.,1990.

2. Гыйлманов Җ.И. Без сугышта юлбарыстан көчлебез... Татарстан халкы Бөек Ватан сугышында (1941-1945 еллар). Русчадан Хәмидуллин тәрҗемәсе.- Казан: Татар.кит.нәшр.,1989.

3. Хәйруллин И.К. Батырлар китабы. Татарстан китап нәшрияты, 2000.

4. Шаһиев Рәфкать. Соңгы һөҗүм: Татарстанның көньяк- көнчыгыш төбәге фронтовик- язучылары әсәрләре. – Казан: Рухият, 2015.

5. Шәфыйкова М.С. Милли тәрбия- милләт яшәешенең нигезе. Отпечатано в ООО “ИПЦ “Гузель

Интернет чыганаклар:

www.un.org/law

www.crimesofwar.org

www.hro.org/docs

http://www.voinent.ru



*Залялиев Разиль, 9 нчы сыйныф,*

*Казан шәһәре Авиатөзелеш районы "Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 62 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе*

*Җитәкчеләр: Ибрагимова Эндже Салимовна татар теле укытучысы, Гиниятуллина Ландыш Ильдановна инглиз теле укытучысы*

## Татар һәм инглиз телләрендәге кош атамалары кергән фразеологизмнар

### *Кереш*

Татар һәм инглиз телләренең фразеологиясен чагыштырып өйрәнү, шул телдә сөйләшүче халыкларның дөньяны күзаллауларын, аларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә ярдәм итә.

**Тикшеренүнең өйрәнү предметы**: татар һәм инглиз телләре фразеологиясендә кош атамасы компоненты булган тотрыклы сүзтезмәләр, фразеологизмнар.

**Эшнең максаты** татар һәм инглиз телләренең дөнья сурәтендә кош атамалары кергән фразеологизмнарны чагыштырмача тикшерү

Халык тарихы никадәр бай булса, фразеологик берәмлекләр дә шул кадәр мәгънәле һәм кызыклырак.

Татар фразеологиясен саклау һәм үстерүгә Н.Исәнбәт гаять зур өлеш керткән. “Татар халык мәкальләре” 3 томда, “Татар теленең фразеологик сүзлеге” 2 томда.

Инглиз тел белемендә Уоллес Чейфның “Meaning and the Structure of the Language” (Тел структурасы һәм әһәмияте), Аддам Маккейның “Америка идиомалары сүзлеге”, Франтишек Чермак һ.б. хезмәтләре фразеологияне өйрәнүгә багышланган

### Төп өлеш

### 1. Кошларга атама бирү принциплары

Татар һәм инглиз телләрендә кошларны атауда берничә принцип бүлеп чыгарырга мөмкин:

1. <u>*Тавыш охшашлыгы буенча*</u>: бу юл белән барлыкка килгән кош атамалары ике телдә дә шактый урын алып тора. Мәсәлән, хәзерге татар телендә еш кулланыла торган кош атамалары: ***карга*** – “кар-кар”, ***чыпчык*** – “чик-чик”, ***кәккүк*** – “күк-кү”, ***күркә*** – “корк”, ***торна*** – “торыйк-торыйк”, һ.б. Мондый орнитонимнар, билгеле булганча, кошлар чыгарган тавышны кабатлау юлы белән, (***ләкләк*** **–** ләк+ләк һ.б.), яисә шул тамырга аффикслар ялгау юлы белән (***кар+га, тор+на*** һ.б.) ясалалар.

Инглиз телендә: cuckoo – күке, owl – ябалак һ.б. атамалар.

2. <u>*Яшәү урыннары буенча*</u>: тат. - ***урман күгәрчене, урман тавыгы, тау карлыгачы, чүл козгыны, болын тургае, кыр тавыгы, яр песнәге*** һ.б.; инг**. - *rock-pigeon*** – кыя күгәрчене, ***field lark*** – кыр тургае, ***sea-gull*** – акчарлак һ.б.

3. *Тышкы кыяфәте, төсе буенча*: тат. - ***аккош, ак торна, кара тилгән, сары чыпчык, кызыл үрдәк*** һ.б.; инг. - ***green peak*** – яшел тукран, ***redbreast*** – кура җиләге чыпчыгы һ.б.

4. *Хәрәкәтләре буенча.* Кошлар, хәрәкәтчәнлекләре белән башкалардан аерылып торалар: алар оча гына түгел, алар шулай ук йөзәләр дә, йөгерәләр дә, сикерәләр, агачларга менәләр һ.б. Бу үзенчәлекләргә бәйле кошларны берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин – *"куак-агачларга үрмәләүче кошлар", "куаклыкта, җирдә сикергәләп йөрүче кошлар", "йөгереп йөрүче кошлар", "йөзүче кошлар"* һ.б. Мәсәлән: тат. - ***үрмәкош, үрмәләч(поползень)*** һ.б.; инг. - ***windhover*** – пустельга, ***wagtail*** – чәперчек.

Гомумиләштереп шуны әйтергә мөмкин, кошларга исем бирү аларның тышкы кыяфәтләре, чыгарган тавышлары, яшәү урыннары, шулай ук төрлечә хәрәкәт итүләренә бәйле булырга мөмкин.

**2. Кош атамалары кергән җөмләләрнең һәм ирекле сүзтезмәләрнең фразеологизмнарга әйләнү мәсьәләсе.**

1) Беренче булып без кошларның тышкы кыяфәте һәм яшәү рәвешләре нигезендә барлыкка килгән фразеологизмнарны аерып чыгарабыз:

- Сайраулары буенча***:***

тат. ***кыйкылдак каз*** - көлеп әйтү. Ата казның корыга тавыш биреп, мактанып кыйкылдап йөрүе күп булса да, сүзе эшкә ашмавы белән мисал китереп әйтү;

инг. ***sing like nightingale*** - сандугач кебек сайрау;

***as hoarse as a crow*** – ачы тавыш белән кычкыру,

- Йөрешләре буенча:

тат. ***тавык кебек артка тырнау*** - эшләп-эшләп тә эшенең үрчемәве, алга бармавына мисалдан;

***тавык сыман кирегә тырмый*** - тискәрегә эшли, кирегә сөйли;

инг. ***strut like a turkey*** – күркә кебек кабарыну,

- Гәүдә төзелешенә карап:

тат. ***каз канаты, карлыгач мыек*** - карлыгач койрыгы кебек, очлы мыек;

***кикрикле тавык*** - ирләшкән, иренә командир булган кайбер хатын-кызга карата әйтем;

***тавык баш*** - мисез, фикерсез, аңгыра, зиһенсез;

инг. ***pigeon-breasted*** – тар күкрәкле кеше,

***hawk-nosed*** – кәкре борынлы( горбоносый),

***eagle-winged*** – бөркет канатлы, бөркет сыман күктә очучы;

- Кошларның төсенә карап:

тат. ***кара карганы сабын белән юу*** - төрле каралыкка батып пычранган кешенең табигатен төзәтәм дип азаплану;

***кара карга*** - аңсыз, кара надан;

инг, ***as black as raven –*** карга кебек кап-кара***,***

***peacock blue*** – павлин төсе, зәңгәр төс,

- Яшәү урыннарына һәм яшәү рәвешенә карап:

тат. ***әтәч белән тору*** - иртән иртүк, таңга кычкырган әтәч тавышына йокыдан тору;

***беренче карлыгач*** - беренче хәбәр

***токымсыз күке -*** өйләнмәүче, дөньяда яшәп тә үзеннән нәсел калдырмаучы; ***кычыткан чыпчыгы*** - кечкенә гәүдәле, тиктормас, кыбырсык кеше, бала-чага турында;

***тәкәббер күркә*** - тәкәберлегеннән күркә кебек кабарып масаючы*;*

инг, ***rise up with the lark*** – бик иртә тору,

***night owl*** – төнге ябалак, төннәрен йокламыйча, күңел ачып йөрергә яратучы.

**3. Татар һәм инглиз фразеологизмнары составында символик мәгънәдә килгән орнитонимнар**

Кошлар һәрвакыт кешенең игътибарын җәлеп иткән, ә аларның һавада очуы гадәттән тыш һәм сихри булып тоелган. Күп очракта кошлар уңай образ буларак каралган. Кайбер мәдәниятләрдә кошлар авыру турында хәбәр итүче булып торганнар (каргалар, грифлар. Борынгы кешеләр өчен кошлар Алла хәбәрләрен җиткерүче күзалланган булган. Төрле әкиятләрдә, кошлар, әкият каһарманнарына үз киңәшләрен биреп торганнар.

Алга таба татар һәм инглиз фразеологизмнарында бирелгән кош образларын карап китәбез.

ЧЫПЧЫК (SPARROW) –Соры төстәге, кечкенә, гел бер урыннан икенче урынга сикереп йөри торган кош күп кенә татар һәм инглиз фразеологизмнарында кулланылган:

тат. *чыпчык тезеннән* - гыйлеме бик сай, аз булуга мисалдан.

инг. *eat like a sparrow* – чыпчык кебек ашый, аз ашый;

КАРГА (RAVEL, CROW) – күп кенә илләрдә бу кошны үлем, сугыш белән бәйләп карaганнар: инг. *A crow on the thatch, soon death lifts the latch* – Түбәгә карга утырса, бу гаиләгә кайгы килә; Татарларда өй тирәсендә карга тавышы ишетелсә кайгы көтелә дип, ышанганнар. Татар һәм инглиз фразеологизмнарында карга образы аша кире бәя бирелә:

*кара карга* - аңсыз, кара надан;

инг. *Crows do not pick the crow's eyes.*

*карга чукырлык та ите калмаган* - үтә ябык, арык тәнле, бетерешкән кеше;

инг. *as black as crow* – карга кебек кап-кара;

Карга образы предметны, төрле күренешләрне, урын һәм вакытны белдерү өчен кулланыла:

тат. *карга бураны* - кара каргалар килер алдыннан була торган язгы җепшек буран;

инг. *as the crow flies* –карга очкан кебек, турыга йөрү;

*crow's nest* – карга оясы (мачтада)

Төрки халыкларда булган йолалардан чыгып *карга боткасы* (яз ахырларында, сабан туе һәм яңгыр теләү көннәрендә балаларның халыктан май, ярма җыеп, елга буенда казан асып, уен-бәйрәм корулары) фразеологик берәмлеге барлыкка килгән.

КҮГӘРЧЕН (DOVE, PIGEON) – күгәрчен һәрвакыт тынычлык, мәхәббәт, чисталык һәм өмет символы булып килә. Бу инглиз телендә түбәндәге фразеологизмнар барлыкка килүдә ярдәм иткән: *as harmless as a dove* – күгәрчен кебек тыныч; *as innocent as a dove* – күгәрчен кебек бер катлы; Шул ук вакытта күгәрченнәр хат ташучылар дип саналган.

Пар күгәрченнәр мәхәббәт символы булып торалар:

тат. *бәхет күгәрчене* - насыйп яр*;*

Төрки халыкларда күгәрченнәрне изге кошка санап йөргәннәр, Шул ук вакытта кайберәүләр аны яратып та бетермәгән, күгәрчен оя корган йортка хәвеф-хәтәрләр алып килә дип санаганнар.

КАЗ (GOOSE) – Борынгы Римда исә, каз сугыш алласы белән бәйләп каралган, казлар турындагы билгеле вакыйгадан соң уяулык символы булып та килә.

Казларның тышкы кыяфәте һәм үз-үзләрен тотышы түбәндәге фразеологизмнарда чагылыш тапкан:

тат. *Оясын пычраткан каз кебек* - кая утырырга уңайсызланып аяк өстендә торучыга карата әйтелә;

инг. *goose pimples* – каз тиресе;

*goose step* – каз атлавы;

*beat goose* – җылыныр өчен үз-үзеңне суккалау;

Фольклорда каз күп сөйли торган, бераз акылы саерак кош булып сурәтләнә. Шуннан чыгып татар һәм инглиз телләрендә шушы фразеологизмнар барлыкка килгән:

тат. *Әҗем казы* - суда йөзә белмәгән кешегә әйтәләр;

инг. *as silly as goose* – каз кебек ахмак;

Күп кенә татар фразеологизмнарында казны башка кошлар белән чагыштырып карыйлар:

тат. *каз урынына карга - әйбәт нәрсә көткәндә начары эләгү;*

Инглиз фразеологизмнарында исә, каз образына башкалар белән чагыштырылганда тискәре бәя бирелә:

инг. *all one's geese are swan* – казны аккошка әйләндерү, арртырып сөйләү.

КӘККҮК (CUCKOO) – эшсезлек, ялкаулык символы. Шул ук вакытта күкегә карата уңай бәя дә бирелә, бу очракта аны яз, җәй һәм байлык кошы дип кабул итәләр. Төрки халыкларда күке образы ялгызлык белән бәйле:

тат. *токымсыз күке* - өйләнмәүче, дөньяда яшәп тә үзеннән нәсел калдырмаучы;

*дуадак күке төсле* - йомыркасын башка кош оясына салып, баласын ояга ташлап, ямьсез баш моңаеп йөргән күке кебек. Баласыз тол яки буйдак кешегә мисалдан*;*

ТАВЫК (HEN) – Европада тавык тиктормаслык, ана назы символы булып килә. Татар фразеологизмнарында тавык кеше үз-үзен тотышын, тышкы кыяфәтен сурәтли:

тат. *Сукыр тавык* - белемсез, аңгыра, надан кеше турында;

*Кыртланган тавык* - чебиле тавык, чеби анасы. Кайбер ананың баласына якын килергә дә ярамыйча, керт-керт килеп чәбәләнеп торуы;

*Карчыгадан калган тавык шикелле* - кыяфәте калмаган, хәчтерүш, сәләмә.

Татар телендәге *Һавадагы тургайны тотам дип, кулыңдагы чыпчыгыңны җибәрмә* һәм инглиз телендәге *Better an egg today than a hen tomorrow* тулы аналоглар булып тора.

КАРЛЫГАЧ (SWALLOW) – традицион яз хәбәрчесе. *Бер карлыгач килеп яз булмый* (Бер кеше генә нәрсә дә булса эшләсә, ул зур нәтиҗәләргә ирешә алмый) фразеологизмы шушыннан килеп чыккан.

ӘТӘЧ (COCK) – батырлык, ышанычлылык символы; таң хәбәрчесе, кояш билгесе. Әтәчкә хас шушы сыйфатлар тәккәберлек, үзен башкалардан өстен тоту сыйфатларына караганда күбрәк таралган.

тат. *Беренче әтәч* - ярты төн булганда кычкырган әтәч тавышы. Элек авылларда төнге сәгать хисабын әтәч кычкыруы белән санаудан. Төн уртасыннан таң атканчыга кадәр – 3 әтәч. Шуңа карап төнлә сәхәргә торганнар;

*йомыркадан чыкканчы әтәч булган* - "мин" дип кычкырырга ашыгучы яшь кешеләргә карата әйтелә;

инг. *Every cock crows on its dunghill* – Һәр әтәч үз чүплегендә батыр, ягъни күп вакытта кеше үз танышлары арасында гына батыр булып кылана, чит җирдә исә сүз дә әйтә алмый.

ҮРДӘК (DUCK) – гаилә бәхете, тугрылык билгесе. Фразеологизмнарда күбрәк үрдәкләрнең тышкы кыяфәте һәм үз-үзләрен тотышлары чагылыш тапкан:

тат. ***сертотмас үрдәк***- сер тотмый торган;

*башчы үрдәк алдан очар* – гел беренче булырга яраткан яисә кешеләрне үзе артыннан ияртә торган кеше гел алда бара;

инг. *a lame duck* – "аксак үрдәк", мескен, берни дә булдыра алмаган кеше.

***Татар һәм инглиз телләрендә кош атамалары кергән фразеолгизмнарны классификацияләү***

**1. Кешене атаучы фразеологизмнар:**

тат. ***Калай әтәч – 1***. Көче җитмәсә дә үзеннән көчле кеше өстенә ташланучы, бәйләнчек, сугышырга яратучы;

***Бүрекле тавык*** - ирдәүкә хатын-кыз хакында;

***Чыпчык йөрәк*** - бик куркак, бичара җан;

инг. ***be no chicken –*** урта яшьтәге кеше;

***the early bird –*** иртә торучы кеше;

***birds of feather –*** одного поля ягоды;

а) кешенең иҗтимагый хәлен белдерүче фразеологизмнар:

тат.: ***аның әтәче дә күкәй сала -*** бәхете алга киткән, баерга керешкән кеше турында.

б) кешенең яшен һәм тышкы кыяфәтен белдерүче фразеологизмнар:

тат. ***Каз муен булу*** - салкын тиепме, ипсез ятыпмы муен каерылып, кыегаеп сеңере кату, муенны бора алмау;

***торна вәли*** - бик озын гәүдәлелек типажы булып киткән, гомуми таралган бер кушамат;

инг. ***swan-neck –*** каз муены;

в) кешенең характерын, әһлакый якларын белдерүче фразеологизмнар: тавык ~ coot- надан кеше; cock ~ sparrow ~ әтәч – сугышырга яратучы; күп сөйләшүче– magpie ~ үрдәк h.б.

**2. Предметны атаучы фразеологик берәмлекләр:**

а) урынны белдерүче фразеологизмнар:

тат. ***каз оясы*** - тузган өй*;*

***ябалак үлгән урын*** - бетүгә йөз тоткан авыл турында;

инг. ***pelican crossing –*** юл чыгу урыны (пешеходный переход),

***eagle nest –*** аэродром;

б) вакытны белдерүче фразеологизмнар:

тат. ***каз казык какканда, әтәч азан әйткәндә*** - әкият алымы, беркайчан да булмый торган, әкияттә генә була торган эшләр;

***карга җимгә төшмәс борын*** - иртән иртүк, бик иртә;

***кәккүк ае*** - май ае;

инг. ***eagle-day –*** акча алу көне,

***cock-shut ligh –*** эңгер-меңгер,

***cock crowing*** – таң аткан вакыт һ.б.

в) төрле предмет һәм вакыйгаларны белдерүче фразеологизнар:

тат. ***ата каз боткасы*** - махорка, яфрак тәмәке;

***тавык аягы*** - чукынган булучылык билгесенә муенга тагылган кечкенә тәрене белдерә;

***торна мамыгы*** - булмый торган нәрсә;

***сандугач йокысы*** - аз йоклау турында;

инг. ***chicken feed*** – акча аз булу,

***owl car*** – төнлә йөри торган трамвай яки такси;

**3.Процессны белдерүче фразеологизмнар**

1) кеше эшчәнлеген белдерүче, 2) кешенең халәтен белдерүче .

*Кеше эшчәнлеген* белдерүче фразеологизмнар:

тат. ***сандугач телле*** - бик назлы сөйләшү;

***саташкан күке кебек сөйләшү*** - кеше сүзен кабатлап, мәгънәсез сөйләшүгә карата;

инг. ***talk turkey*** **–** турыга бәреп әйтү;

***chatter like magpie*** **–** саескан шикелле күп сөйләшү;

***sing like a bird*** **–** сандугач кебек сайрау;

б) акыл эшчәнлеге (ике телнең фразеологиясендә дә кешенең зирәклеге, тапкырлыгы мактала, хыялыйлыгы, тормышка реаль карамавы тәнкыйть ителә):

тат. ***чыпчык тезеннән*** - гыйлеме бик сай, аз булуга мисалдан;

***тавык бәкәленнән йөзә*** - сай йөзә, тирән уйлый алмый торган кеше;

инг. ***learn smth like a parrot*** **–** тутый кош сыман, кирәкмәгән нәрсәләрне ятлау;

***know a hawk from a handsaw*** **–** тапкыр кешегә карата әйтелә;

в) кешенең үз-үзен тотышын сыйфатлаучы фразеологизмнар (бу төркемчәгә кергән фразеологик берәмлекләр кеше тормышының төрле якларын күрсәтә: акыл белән эш итү һәм наданлык, уңыш яки уңышсызлыклар, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен сыйфатларга мөмкин):

тат. ***ике әтәч*** - бер-бере белән гел талашып яши торган ике кеше;

***әтәч белән ятып, сыер белән тору*** - күп йоклау: иртә ятып соң тору;

***карга санап йөрү*** - юк эш белән мавыгып, юкка исе китеп, авыз ачып йөрү, кирәкне кулдан ычкындыру, бардан коры калу, ачык авыз булу;

***торна йомыркасын тоттыру*** - юк вәгдә белән алдау;

инг. ***pluck a pigeon*** **–** алдау, соңгы тиененә кадәр тартып алу;

***can’t say boo to a goose*** **–** бик оялчан булу;

***go to bed with the chicken –*** тавыклар белән йокларга яту, иртә йокларга яту; ***eat like a sparrow –*** чыпчык кебек ашау, бик аз ашау;

***swell like a turkey cock –*** күркә шикелле кабарыну, кыланып йөрү;

***keep the bird in one's bosom –*** сохранить верность.

**Кош *атамалары* кергән мәкаль һәм әйтемнәр**

Кешеләрне үзгәртеп булмый, дигән мәгънәләр салынган:

тат. *Карга ни хәтле канатын кыеп очса да, карчыга булмас;*

*Саескан сайрау белән сандугач булмас;*

инг. *An ill bird lays an ill egg* – чирле тавык начар йомырка сала;

*A stunted hen remains a chicken* – бөрешкән тавык чебеш булып кала;

Бөтен әйбер дә үз сыйфатын үзгәртә, кеше дә башкалар йогынтысында үзгәрергә мөмкин:

тат. *Күгәрчен баласы, күрексез булса да, үскәч күгәрчен була, ди;*

*Т*ышкы кыяфәт кешенең күңелен чагылдыра:

тат. *Тутый кош каурыена төренгән карга;*

*Тавис – каурые белән матур;*

*Үзең кара карга булгач, кая барсаң да кара йомырка саласың;*

Тышкы кыяфәт алдаучан:

тат. *Сандугач кечкенә булса да, мактаулы кош;*

*Һәр йомыркадан чебеш чыкмый;*

инг. *Little pigeons can carry great massages* – Кечкенә күгәрченнәр зур хатлар ташый ала;

*A black hen lays white egg* – кара тавык ак йомырка сала.

Яшь буын олылардан өйрәнә, тәҗрибә ала:

тат. *Ала карга гына ата анасына ошый;*

*Атаң козгын, анаң козгын, син кемнән узгын;*

инг. *As the old cock crows, so doth the young* – Карт әтәч ничек кычкырса, яше дә шулай кычкыра;

Бертөрле кешеләр һәрвакыт бергә туплана:

тат. *Ике кара карга бер-берсенең каралыгына гаҗәпләнгән;*

*Каз - каз белән, үрдәк – үрдәк белән очар.*

инг. Birds of a feather flock together – Каурыйлары бертөрле кошлар бергә оча;

Үз-үзенекен сатмый (җинаятчеләр турында):

тат. *Карга карга күзен чыгармас.*

инг. *Crows do not pick crow's eyes* – Карга карганың күзен чокымый;

Бердәмлек:

тат. *Аерылган каз тупланган каргага җим булыр.*

*Каз бергә, козгын аерым очар.*

Үзеңнеке начар, читнеке әйбәт:

тат. *Күрше авылның күркәсе – үз авылыңның үрдәге;*

*Кеше тавыгы каз кебек, йомыркасы баш кебек;*

Булганы белән канәгать булган кеше, күбрәк файда ала:

тат. *Һавадагы торнага авызыңны ачып торма;*

*Һавадагы тургайны тотам дип, кулыңдагы чыпчыгыңны җибәрмә;*

*Тере сандугач үле арысланнан яхшырак.*

инг. *Better an egg today than a hen tomorrow* – Бүген булган йомырка иртәгә буласы тавыктан яхшырак;

*A bird in the hand is worth two in the bush* – Кулдагы кош куактагы ике коштан яхшырак;

Язмышыңа ни язылган, шул була:

тат. *Сандугач туры очса да, кыек яшәр;*

*Күрәсең булса күркә талап үтерер;*

**Йомгак**

Тел төрле мәгълүматларны һәм халык тәҗрибәсен саклау урыны булып тора. Телнең бу функциясе сүзләрдә, фразеологизмнарда аеруча зур чагылыш тапкан. Вакыт барлык нәрсәләрне дә, шәһәрләрне, халыкларны юк итәргә мөмкин, әмма тел боларны барысында саклап кала.

Халыкларның тормыш итү рәвешләре, гореф-гадәтләре белән кызыксыну күптәннән килә. Төрле халыкларны бер-берсенең дөнья сурәте белән таныштыру, алар арасында охшаш һәм аермалы якларны күрсәтү өчен телләрне чагыштырма планда өйрәнү зарур.

**Әдәбият исемлеге**


1. Бәйрәмова. Л. Русча-татарча тематик фразеологик сүзлек / Бәйрәмова Л. – Казан: тат. кит. нәшр, - 1991.

2. Голденков М.А. Осторожно! Hot dog! Современный активный English. – М., 2004 г.

3. Исәнбәт, Нәкый Татар халык мәкальләре: I том / Н.Исәнбәт. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. – 914 б.

4. Исәнбәт, Нәкый. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда / Н. Исәнбәт. – Казан: Татар китап нәшр., 1989. – 495 б.; 1990. - 365 б.

5. Кунин А.В. Фразеология современного языка. - М., 2003 г.

6. Кунин А.В. Англо-русский фразеологический словарь. – 4-е изд., переработанное и дополненное. – М., 2006 г.

7. Сафина Э. И. Названия птиц в татарском языке и их лексикографирование. – Казан: Дом печати, 2006 г.

8. Сафиуллина Ф.С Татарча-русча фразеологик сүзлек / Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Мәгариф, 2001. - 335 б.

9. Сафиуллина Флера Садриевна, Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен). – Хәтер нәшрияты, 1999.

10. Longman dictionary of English Idioms, Longman. 2005.

11. https://yaznanie.ru/a/mDSO21oW

*Зиганшин Билал, 9 нчы сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «24 нче лицей-интернат» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Егорова Рәсимә Хәмит кызы, Әхмәдиева Динара Хамиз кызы, татар теле укытучылары*

**Эчтәлек**

Кереш

Төп өлеш

1.1 Проектны теоретик яктан нигезләү

1.2 Проектның гамәли өлеше

1.3. Проектның киләчәк үсеше (фаразлар)

Нәтиҗә

Әдәбият исемлеге

Кушымта

**Кереш**

Киез итекләргә ихтыяҗ өзлексез арта. Моңа, минемчә, «халыкның картаюы» да ярдәм итәдер, чөнки киез итекләр-өлкәннәрнең иң яраткан аяк киеме. Икенче яктан, кешеләр зур шәһәрләрнең фатирларыннан, шау-шулы кала тормышыннан качып, коттеджларга күчә. Анда исә итекләр өйдә, ишегалдында һәм юлда йөрү өчен уңайлы. Балалар киез итекләренә дә ихтыяҗ арта. Совет чорыннан калган заводлар, нигездә, аякка гаять уңайсыз булган кара һәм соры киез итекләр эшләп чыгара, ә хәзерге вакытта сыйфатлы итеп басылган ак, төсле,

чигүле һәм аппликацияле зур үлчәмле киез итекләргә дә, балалар киез итекләренә дә ихтыяҗ зур.

Заманча киез итекләр чыгару өчен кечкенә производстволар булдыру-кече эшмәкәрлек өчен перспективалы юнәлеш.

Йоннан киез итекләр эшләп чыгаруның актуальлеге, беренче чиратта, бу төр аяк киеменең, традицион рәвештә, безнең салкын кышларда иң җылы һәм уңайлы булуы белән бәйле. Киез итекләр җитештерү процессы зур чыгымнар таләп итми һәм тауар тиз арада һәм югары бәягә сатыла. Җәйге вакытта паласлар, букчалар, машина өчен келәмнәр, сувенир продукциясе, җиңсез тәнҗылыткычлар һәм башка кием-салым сату сәүдәсе дә яхшы бара.

**Проект идеясе:** өлкән сыйныфлардагы мәктәп укучыларына авыл җирлегендә дә акча эшләү мөмкинлеге биргән җитештерү комбинатларын ачу мөмкинлеген аңлату. Бу хезмәт өчен таләп ителгән финансны барлау; халык шөгыле булып исәпләнгән итек басу хезмәтенә мәхәббәт тәрбияләү.

**Проектның проблемасы**: итек басу һөнәренең нинди авырлыклары бар? Авыл җирлегендә итек басып акча эшләп буламы?

**Цель**: киез итек басу эшмәкәрлегенең эффективлыгын ачыклау. **Задачи:** киез итекләр басу процессын өйрәнү; чыгымнар күләмен һәм тотылган чыгымнарның каплану дәрәҗәсен бәяләү.

**Гипотеза:** минем уйлавымча, зур чыгымнардан башка гына, авыл җирлегендә файдалы да, җылы да булган киез итекләр басу һәнәрханәсе ачып була.

**Проекттан көтелгән нәтиҗә**:

1. Яңа эш урыннары барлыкка китерү;
2. Халыкны сыйфатлы аяк киеме белән тәэмин итү;
3. Эшсез кешеләрне эшкә урнаштыру мөмкинлеген булдыру;
4. Сәламәтлекне саклау.

Әлеге төр эшмәкәрлек эшчәнлеген үстерү идеясен гамәлгә ашыру өчен эшне башлап җибәрүгә зуп кертемнәр таләп ителми. Киез итекләргә ихтыяҗны арттыручы факторлар:

- кышкы чорда зәмһәрир суыкларның булуы;
- киездән ясалган аяк киемнәренә моданың кире кайту тенденциясе;

Минемчә, киләсе елларга фараз ясасаң, аларга ихтыяҗ елдан-ел арта гына барачак.

## Төп өлеш

Мин әти-әнием туган авылга бик еш кайтам. Балтач районында, бар яктан таулар белән әйләндереп алынган, шәһәрдән ерак урнашкан, балалар бакчасы, мәктәбе булган зур авыл ул. Халкы күбрәк район үзәгендәге завод тармагында эшләсә дә, ата-бабадан калган һөнәр-терлекчелек һәм бакчачылык төп керем чыганагы булып тора. Терлек-туар асрарга

да бик маһир минем авылдашларым. Бөтен тирә-күрше авылларда малларны бетергән вакытта, бездә исә һәр хуҗалыкның үз сыеры, үз кышлавы, сарыгы, кәҗәсе, сирәк булса да, аты бар. Урман, кырларның күп булуы печән, саламга кытлык тудырмый. Колхозлар бетеп, җирләргә хуҗа булган инвесторлар да эшләгән авылдашларга саламлата, бодайлата ярдәм итәләр.

Авылда, терлекчелек һәм бакчачылыктан тыш, умартачылар һәм итекчеләр дә бар. Татар кешесен гомер гомергә кәсебе ашаткан. "Һөнәрле-үлмәс"-ди татар халык мәкале. Димәк, халык, финанс яктан нинди генә авыр хәлдә калса да, ачтан үлмәячәк.

Мине күршемдә дә данлыклы һөнәр иясе, Ярыйәхмәт абзый яши. Начар яшәми пенсионер абзый: ике катлы йорты, рәсәйнеке булса да, машинасы... Ул-даны тирә-як районнарга таралган итекче. Аның баскан итекләренә ихтыяҗ зур булганлыктан, һөнәрле абзыеңның авылда дәрәҗәсе зурдан. Беркемнең дә кышкы салкыннарда киез итексез, пимасыз каласы килми. Хәтта, әйтергә кирәк, итекче абзый, физик яктан бөтен авылдашларны итекле итеп өлгерә дә алмый. Ел әйләнәсе эшләсә дә... Димәк, авылда җылы итек-пимага кытлык бар.

Һәм мин, бу төшемле һөнәр турында мәълүмат тупларга булдым. Сораулар куп иде... Итек сату файдалымы? Авылдашлар бу продукциягә мохтаҗмы? Бу авылда тагын шундый ук һөнәрханә булдыру финанс ягыннан отышлымы? Проек эшемдә, танылган итекче Ярыйәхмәт абзый белән булган сөйләшүләрне дә, үзгәртмичә, куеп бардым.

Киез итек басарга чималың булмаса, нинди генә зур, заманча һөнәрханәң булу да, данлыклы итекче булуын да ярдәм итми. Димәк, чимал булып хезмәт итүче сарык йөны кирәк. Кәҗә йоны да, куян йоны да түгел, нәкъ менә, сарык йоны.

**Республика буенча статистика**

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Факт | Елларга фараз | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| Сарык саны | Мең баш | 360 | 358 | 355 | 350 | 349 | 348 | 346 |
| Сарык йоны | центнер | 1080 | 1074 | 1065 | 1050 | 1047 | 1044 | 1038 |

Республика буенча, сарык үстерү елдан-ел кимүгә бара. 2022 нче елда, сарык саны Республикабызда 349,5 мең баш исәпләнә. Бу исә, 2012 нче ел белән чагыштырганда, 3% ка кимрәк дигән сүз. 3% ка кимү-бу күп түгел. Димәк, сарык йоны белән киләчәктә проблемалар булмаячак. Ә безнең авылда, һәр хуҗалыкта 20-25 әр баш итеп асрыйлар ул бөдрәбашларны.

“-Ярыйәхмәт, абзый, авыл хуҗалыкларында нинди токымлы сарыкларга күбрәк өстенлек бирелә?

-Олан, авылда 4 төр токымлы сарык асрала: “прекос”, “әлдебай”, “роман” һәм “Татарстан”. Шуның хәтле затлы исемнәр арасыннан бары “Татарстан” токымлы сарык йоны итек басарга уңайлырак.”

Димәк, “Татарстан”-шәп! Үзебезнеке узебезнеке инде.

Һәр сарык бер елга 3-4 кг йон бирә. Димәк, һәр хуҗалык, якынча 60 кг сарык йоны ала. Ә авылыбызда 212 хуҗалык исәпләнә, җәмгысе 12.700 кг йон алына дигән сүз. 130 центнер сарык йоны.

Проектның смета бәясе: 200 000 сум.

Проектны финанслау чыганагы:

- Компаниягә нигез салучының үз акчалары.

- Республиканың эшкуарлыкка ярдәм фонды акчасы.

- Банк кредиты.

Һәр эшкә план (смета) төзегәндә, күпме продукция китәчәген исәпләү таләп ителә. Мондый эштә дә миңа бу хезмәткә үз гомеренең 50 елдан артык өлешен багышлаган итекче Ярыйәхмәт абзый ярдәм итте.

“-Ярыйәхмәт бабай, бер итек басар өчен, якынча ничә кг йон кирәк?

-Улым, итегенә карап инде, ир кешенекенә, 1 кг 200 гр, катыннарныкына-1 кило чамасы, ә оланнарга 500 гр да җитә. “

**Продукциянең кыскача тасвирламасы:**

Безнең киез итек басу компаниябез “Йон итек-киез итек” дип аталачак, чөнки Лениногорский районында “киез итек” атамасы “йон итек” дип йортелә.

Безнең “Йон итек-киез итек» компаниясе табигый материаллардан басылган продукция тәкъдим итә. Кышкы чорда киез итекләргә ихтыяҗ үсү сәбәпле, товарны сатып алу да арта.

Җитештерелгән тауарның ассортименты ир-атлар өчен (27-32 үлчәм), хатын-кызлар өчен (24- 26 үлчәм), балалар өчен (15-23 үлчәм) киез итекләрдән һәм кыска пималардан тора. Киез итекләр җитештерү өчен 100 %лы табигый сарык йоны кулланыла. Аның да көз көне кыркылганы хуплана.

Әзер йоннан (кул белән язылган, чистартылган) авырлык буенча продукция чыгу:

| Итекләр | 1 пар итек өчен йон күләме | Җитештерелгән итек (парларда) |
|---|---|---|
| Ир-ат итеге | 1 кг 200 гр | 1 пар |
| Хатын-кыз итеге | 1 кг | 1 пар |

| | | |
|---|---|---|
| Балалар итеге | 500 гр | 1 пар |
| Ир-ат пимасы (кыска) | 1 кг | 1 пар |
| Хатын-кыз пимасы (кыска) | 900 гр | 1 пар |

“ - Ярыйәхмәт бабай, сарык йоны авылыбызда ничә сум тора?

- Сыйфатына карап, олан. Язгы йонның бәясе түбән инде аның, 20-30 тәңкә булыр. Аны итек басу эшендә куллансаң, итекне җәя. Ә менә көзге йон тыгызрак да, тупасрак та була. Шуңа бәясе дә килосы-150-200 тәңкә чамасы тора.”

Чимал бәясенә бәйле рәвештә, эшләп чыгарылган тауарның үзбәясе һәм базар бәясе:

| Итекләр | 1 пар итекнең үзбәясе | Базар бәясе. |
|---|---|---|
| Ир-ат итеге | 240 сум | 1000 сум |
| Хатын-кыз итеге | 200 сум | 900 сум |
| Балалар итеге | 100 сум | 700 сум |
| Ир-ат пимасы (кыска) | 200 сум | 800 сум |
| Хатын-кыз пимасы (кыска) | 180 сум | 690 сум |

## 1.1 Теоретическая часть проекта

Һәр яңалык минем өчен кызык. Миңа күзәтүләр алып барырга, тәҗрибәләр ясарга бик ошый. Ничек инде, эрләнмәгән, юылмаган сарык йоныннан киез итек басарга була?! Мин үз эшемнең планын төзедем һәм тикшеренү эшемне башлап җибәрдем.

Нәрсә соң ул киез итек?

Мин китапханәгә юл тоттым. Андагы сүзлекләрдә түбәндәге аңлатма бирелгән: киез итек-төрле хайван йоныннан басып эшләнгән йомшак аяк киеме.

Интернет челтәренә мөрәҗәгать иткәч, беренче тапкыр хайван йоныннан аяк киемнәрен күчмә төрки бабаларыбыз баса башлаганны белдем. Русларга әле ул бары 16 нчы гасырларда гына килеп җиткән (гәрчә, руслар киез итекләрне “русские валенки” дип атасалар да...)

Киез итекләрнең татар кешесе тормышындагы роле.

Киез итек — татар кешесенә иң кирәкле, иң кадерле нәрсә. Җирдәге көзге ләпек кату белән, кышкы зәмһәрир суыкларда һәм язга чаклы рәхәтләнеп киелә торган алыштыргысыз аяк киеме. Үз тазалыгының кадерен белгәннәрнең аякларыннан өстенә кәлүш кидерелгән киез итек язын да бик соң салынган. Аяклары сызлаган карт-коры җәен дә киез итек яки ката өстерәгән.

Бер пар киез итек авылда еллар буе гына түгел, дистәләгән еллар буе хезмәт иткән: тишелә торган, олтан салына торган, олтаны тишелә торан, яңа олтан өстәлә торган.

Аңлаган кеше өчен олтан салганга гына киездекнең бәясе төшмәгән — олтанлысы тагын да җылырак, тагын да җайлырак. Карт-коры, бала-чагадан башлап, бригадка эшкә йөргәннәр дә киез итексез булдыра алмаган. Фермада эшләгәннәр исә киез итекләренең өстеннән оек кидереп куйган — болай иткәндә ул пычранмаган һәм озаккарак җиткән. Һәркемнең кешелеккә чыгарга итек-бәтинкәсе бармы-юкмы, ә чүпрәккә төрелгән, көя төшмәсен өчен эченә сабын кисәге салынган киез итеге, әлбәттә, булган. Кунакка барганда киездекнең яки фитр итекнең тузан да кунмаган ак төстәгесе яки карга канатыдай чем карасы аякларга кып итеп киеп куелган. Ак йон белән кара йон кушылып басылган соры киездек тә менә дигән булган! Бала-чага табаны бозга катканчы тау шуган. Табанда боз, ә аяклар җылыда!

Соңгы елларда киез итек модасы яңадан керә башлады.

**Киез итекләрнең сәламәтлеккә тәэсире**

-сарык йоны дымны яхшы сеңдерә һәм парга тиз әйләндерә, җылы чыгармый һәм шулай итеп салкын тиюдән саклый, мускул һәм буын авыруларыннан булыша;

-йон ланолинга бай, ревматизм, радикулит һәм башка мускул һәм буын авыруларын булдырмый, шулай ук яраларны һәм сөяк сынган урыннарны дәвалауны тизләтә;

-киез итекләр мускул-скелет системасы авырулары вакытында бик файдалы, чөнки мондый аяк киеменең табаны деформацияләнми, өстәвенә, аяк киеме гөмбә авыруларын булдырмый;

-киез итекләр нерв киеренкелеген, аякларда ару һәм авырлык хисен, аркадагы авыртуны җиңеләйтә ала;

-ялантәпигә итек киеп йөрү кан әйләнешен яхшырта.

Без киез итекләрнең файдалы үзлекләрен белдек. Алар җылытып кына калмыйлар, дәвалыйлар да. Киез итекләр кеше сәламәтлегенә файдалы йогынты ясый. Киез итекләр аякларны туңдырмаска мөмкинлек бирә. Аякны җылыда саклый. Массаж эффекты бирә, аяклардагы арыганлыкны бетерергә ярдәм итә.

**Базар потенциалы турында гомуми мәгълүмат**

«Йон итек-киез итек» » компаниясе, уңайлы, җылы һәм комфортлы киез итекләр җитештерүдәге өстенлекләренә таянып, 2024 нче елның уртасына ук татар киез итекләрен җитештерү, сату һәм сатып алу өлкәсендә лидерлык позициясен алырга ниятли.

Безнең компания көндәш компанияләрдән  төрле яшьтәге сатып алучының зәвыгы буенча басылган  киез итекләрнең бай  коллекциясе булу белән аерылып торачак.

Инде бер елдан соң без продукция җитештерүне 50% ка, продукция сыйфатын 70% ка, итек бәяләрен 30% ка арттырырга планлаштырам.

2 елдан соң чыгарылган продукцияне сатудан керем үсеше, чыгымнарны исәпкә алып, 600 000 сум тәшкил итәчәк.

Шулай итеп, компаниянең максатлары булып, җитештерүне һәм продукция ассортиментын киңәйтү, яңа базарларга чыгу һәм 4 ел эчендә үз кибетләренең филиалларын ачу тора.

Компания 2-3 елдан соң сыйфатлы киез итек җитештерү өлкәсендә танылган базар лидеры булырга тиеш.

**Тармактагы эшләр торышын анализлау**

**Проектның иҗтимагый файдасы.**

“Йон итек-киез итек» компаниясе эше оештырган вакытта халыктан йон сатып алу башкарылачак, бу эшсез халыкның гаилә бюджетына керемнәр өстәүгә хезмәт итәчәк. Өстәмә эш урыннары булдырылачак.

**Гомуми ихтыяҗларга тасвирнамә:**

Әлеге предприятиене ачу өчен 200 000 мең сум акча кирәк. Бу кертем компания хуҗасының акчасы (үз акчалары) булачак. Кертемнең төп суммасы 5 елга 200 000 сум күләмендә банк кредиты алыначак, алга таба аена 5 000 мең сум күләмендә түләнеләчәк. Елга -60 000.

**Көчле һәм көчсез якларны анализлау:**

| **Көчле яклар:** | **Кимчелекләр:** |
|---|---|
| 1. Конкуренциянең булмавы; | 1. Акча җитмәү; |
| 2. Өстәмә эш урыны оештыру. | 2. Җиһаз кытлыгы; |
| | 3. Базарда эш тәҗрибәсе җитеп бетмәү (сәүдә); |
| | 4. Конкуренциянең барлыкка килү куркынычы. |

Киез итек җитештерү уңышлы үссә, бу өлкәдә җитештерүне киңәйтү планлаштырыла. Бу яңа нокталарны ачу, башка торак пунктларда җитештерү нокталарын ачу белән аңлатыла.

**1.2 Практическая часть проекта**

“-Ярыйәхмәт бабай, киез итек басар өчен, сарык йоны гына җитми бит әле. Эшне башлар җибәрер өчен, нинди җиһазлар кирәк булыр икән?

-Олан, итек басар өчен, әлләни күп нәрсә кирәкми. Элек заманнарда бу хезмәтне үтәргә бары һәр үлчәм өчен калыплар, кайнар су, өтәр өчен ачык ут һәм киптерергә җылы бина (мәсәлән мунча) җитә иде. Ләкин күп күләмдә кул көче хезмәте таләп ителә иде. Хәзер исә техника заманы. Күп хезмәтне заман техникасына ышанып тапшырырга була. Бу исә куп вакытны янга калдыра, процессны тизләтә. Итек басу өчен җиһазларга килгәндә, кул

белән йонны язып (аралап) утырмас өчен, йон язу станогы, тибрәнүле кыскыч (вибрирующий пресс) кирәк. Улым, шушы җиһазларны булдырсаң, эшең җайга китәчәк.”

Безнең лицеебызга шәһәр бизнесменнары еш очрашуларга киләләр. Алар бертавыштан, бизнес ачып җибәргәндә, җиһазларның “энә-җептән төшкәнен” түгел, ә “кулдан” (инде кулланылышта булганны) алырга диләр. Чөнки бизнес-бик катлаулы шөгыль. Я “китә” ул, я, руслар әйтмешли, “борын белән” каласың. Бөтенләй “нульдә» калмас өчен, җиһазларыңны “юк” бәягә сатып җибәрәсең.

Интернет челтәрендә йон язу станогының яңасы 600 000 сум тора, ә аны “авито” сату-алу сайтында яхшы хәлдәгесен 100 000 - 150 000 сумга алып була. Ә тибрәнүле кыскычның яңасы 25 000 сум тора, ә “авито”да 7000-8000 сум, калып 300 сум тора, кер юу машинасы- 30 000 сум.

Киез итекләр җитештерүне башлап җибәрергә түбәндәге җиһазлар кирәк (кушымта):

| № | **Җиһаз исемлеге** | **Бәясе** |
|---|---|---|
| 1 | **Итек басу җайланмалары:**<br>- йон язу станогы<br>- тибрәнүле кыскыч<br>- кер юу машинасы | <br>100 000<br>7 000<br>30 000 |
| 2 | Рычаглы сузгыч җиһазы («крокодил») | 4 000 |
| 3 | **Итекләр өчен калыплар**<br>Ир-атларныкы 2 х 500<br>Хатын-кызларныкы 2 х 400<br>Балаларныкы 2 х 300 | <br>1 000<br>800<br>600 |
| | Нәтиҗә | 143 000 |

Киез итекләр басу өчен бары яхшы сыйфатлы сарык йоны кирәк.

Беренче яртыеллыкта чималга киткән чыгым:

| Төр | Итекләр саны (парларда) | Чыгым (кг) | Чыгымнар нәтиҗәдә кг | 1 кг йон бәясе | Чыгым суммасы |
|---|---|---|---|---|---|
| Ир-атлар киез итеге | 50 | 1 кг 200 гр | 60 кг | 200 | 12 000 |
| Хатын-кызлар киез итеге | 50 | 1 кг | 50 кг | 200 | 10 000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Балалар киез итеге | 50 | 500 гр | 25 кг | 200 | 5 000 |
| Ир-атлар пимасы | 50 | 1 кг | 50 кг | 200 | 10 000 |
| Хатын-кызлар пимасы | 50 | 900 гр | 45 кг | 200 | 9 000 |
| Нәтиҗә: | 250(пар) | | | | 46 000 |
| Буяу | 250 | 0,04 | 10 | 300 | 3 000 |
| Ягулык (утын) | | | | | 3 000 |
| Тулаем нәтиҗә: | | | | | 52 000 |

Икенче яртыеллыкка чыгым:

| Төр | Итекләр саны (парларда) | Чыгым (кг) | Чыгымнар нәтиҗәдә | 1 кг йон бәясе | Чыгым суммасы |
|---|---|---|---|---|---|
| Ир-атлар киез итеге | 80 | 1 кг 200 гр | 96 | 200 | 19 200 |
| Хатын-кызлар киез итеге | 80 | 1 кг | 80 | 200 | 16 000 |
| Балалар киез итеге | 80 | 500 гр | 40 | 200 | 8 000 |
| Ир-атлар пимасы | 80 | 1 кг | 80 | 200 | 16 000 |
| Хатын-кызлар пимасы | 80 | 900 гр | 72 | 200 | 14 400 |
| Нәтиҗә: | 400(пар) | | | | 73 600 |
| Буяу | 400 | 0,04 | 16 | 300 | 4 800 |
| Ягулык (утын) | | | | | 4 500 |
| Тулаем нәтиҗә: | | | | | 82 900 |
| Электр энергиясе: 12 ай x 500 | | | | | 6000 |
| Нәтиҗә: | | | | | **83 500** |

Бер ел өчен керем.

| Бер елда җитештерелгән киез итекләр | Киез итек бәясе | Сумма (сумнарда) |
|---|---|---|
| Ир-ат итекләре (130 пар) | 1000 | 130 000 |
| Хатын-кыз итекләре (130 пар) | 900 | 117 000 |
| Балалар итекләре (130) пар | 500 | 65 000 |
| Ит-ат пимасы (130 пар) | 900 | 117 000 |
| Хатын-кыз пимасы (130 пар) | 800 | 104 000 |
| Барысы | | 398 000 (сум) |

Эшмәкәрлек эшчәнлеге шәхси эшмәкәрлек дип теркәлә.

## 1.3 Керемнәр һәм чыгымнарга фаразлар

| № | Күрсәткечләр | Агымдагы елдагы эшчәнлек суммасы |
|---|---|---|
| 1 | Керем (сатылганнан соң) | 398 000 |
| 2 | Сатуның үзбәясе (себестоимость) | 135 500 |
| 2.1 | Чимал чыгымы | 135 500 |
| 2.2 | Ялланып эшләүчеләргә түләү | - |
| 2.3 | Ялланып эшләүчеләрне социаль тәэмин итү һәм пенсия-иминият взнослары | - |
| 2.4 | Ремонт | 10 000 |
| 2.5 | Калган чыгымнар, шул исәптән: | |
| 2.5.1 | Чит берләшмәләрнең хезмәте өчен (аренда, элект чыгымы һ.б) | 6 000 |
| 2.5.2 | Транспорт чыгымы | 25 000 |
| 2.5.3 | Бина арендасы | - |
| 2.5.4 | Кредит | 60 000 |
| 2.5.5 | Реклама чыгымы | 10 000 |
| 2.5.6 | Иминият чыгымы | 10 000 |
| 6. | Чиста керем | 141 500 |

## Йомгак

Төрле әдәбиятны, интернет чыганакларын, үткәрелгән эксперимент нәтиҗәләрен өйрәнү нәтиҗәсендә без түбәндәге нәтиҗәләр ясадык.

Киез итек җитештерү өчен башлангыч чыгымнар: **256 500** сум. Рентабельлелек- 40%, тотылган чыгымнарның тулысынча каплану вакыты – 10 ай.

Киез итекләрдән тыш, келәмнәр, жилетлар, дәвалау пояслары, паласлар, табан астына салына торган киезләр һәм башка төрле тауарлар җитештерелә ала.

Нәтиҗә: Әйтергә кирәк, киез итек җитештерү белән бәйле мондый бизнес рентабельле, ләкин күп көч һәм капитал таләп итә.

Киез итекләр- хайваннарны һәлак итмичә генә алына торган, табигый чималдан ясала торган бердәнбер аяк киеме.

Киез итекләр-аяклар өчендә, сәламәтлек өчен дә файдалы аяк киеме. Аларны кисәң, кышның зәмһәрир салкыннары да куркыныч түгел.

Шулай итеп, минем гипотезам исбатланды: киез итек-өй шартларында да басып була торган иң файдалы һәм гади аяк киеме. Киләчәктә, мин бу бизнес-планымны тормышка ашырачакмын. Әлегә әле бу һөнәрнең нечкәлекләренә күршем Ярыйәхмәт абзыйдан өйрәнергә дә өйрәнергә. Мин инде аларда тансык кунакка әйләндем.

Киез итек басучы, балта остасы яисә башка һөнәр иясе булсынмы, үзеннән соң килгән буынга осталыгын мирас итеп тапшырганда гына халыкның гасырлардан килгән рухи байлыгы юкка чыкмас дип ышанасы килә.

## Кулланылган әдәбият исемлеге

1. Морева. Е.О. Валенки – валенки.// Маруся. - 2009 .- №1.- стр. 8-9

2. Ожегов С.И. и Шведова Н.Ю. Толковый словарь русского языка. – М.: Азбуковник, 1999.-994 стр.

3. Орлова Н.С, Боровик К.П. Я познаю мир: История вещей: Энциклопедия. М.: ООО “ Фирма “Издательство АСТ”,1998.-512 с.

4. Чаликова Д.К. Валенки русские // Наука и жизнь. - 2005.

- N 12. - С. 110-113.

*Идиятуллина Ильвина, 5 сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы "Адымнар-Әлмәт "полилингваль гимназиясе" муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчесе: Локманова Алисә Өлфәт кызы, туган тел һәм әдәбият укытучысы*

**Исемең матур, кем куйган?**

**КЕРЕШ**

Тел, сүз, исем-фамилия милләтнең йөзе, тылсымлы могҗизасы һәм сакчысы. Һәркемгә үз исеме — күңеленә иң якын, ин кадерле исем-сүз.

*Гомәр Саттар-Мулилле*

Кыз бала исемендә йолдыз балкышы яки чәчәк нәфислеге, ир-ат исемнәрендә кылыч чыңы һәм китап акылы чагылсын!

*Рәсүл Гамзатов*

Бала туды. Дөньяга яңа кеше килде. Өйгә, гаиләгә яңа ямь, юаныч, куаныч, бәхет өстәлде. Шуның белән бергә яңа туган сабый ата-анасына өстәмә мәшәкатьләр дә китерде. Аларның иң беренчесе – балага исем кушу. Аңа нинди исем бирергә? Бу сорау һәрбер ата-ананы, баланың өлкән туганнарын, кардәш-тумачаларын уйландыра, борчый. Чөнки исем кешегә бер генә мәртәбә бирелә, һәм ул аның гомерлек юлдашына әверелә. Һәр кеше үз исеменә шулкадәр күнегә ки, ул аның туган теленең иң якын, иң газиз, иң кадерле сүзе булып тоела. Исем кешегә гомерлеккә кушыла. Татар халкы элек-электән исем кушуга зур җаваплылык белән караган. Яңа туган сабыйга кушу өчен исем эзләгәндә, ул исемнең җиңел әйтелешле, яхшы мәгънәле һәм аһәңле булырга тиешлеген истә тоту зарури. Балага исем кушу – бик җаваплы, зур һәм мөһим вакыйга. Кешенең исеме аның бөтен язмышын хәл итәргә мөмкин. Үзебезнең һәм әйләнә-тирәбездәге кешеләрнең исемнәре нәрсәне аңлата, һәркем дә үз исеменең мәгънәсен беләме, дигән сорауга җавап эзләп, проект эшебезнең **темасын** “Исемең матур, кем куйган?” дип атадык. Хәзерге көндә нинди генә яңа яңгырашлы, төрле, кызыклы исемнәр юк! Аларны барлау, классификацияләү эшен башкарганда, бу теманың һәр чор өчен дә **актуаль** икәнлегенә төшендек. **Проект эшебезнең максаты:** гимназиядәге 5-6нчы сыйныф укучыларының исемнәренең мәгънәләрен ачыклау.

Максатка ирешү өчен, түбәндәге **бурычлар** куелды:

1. 5-6нчы сыйныф укучылары арасында анкета уздыру.
2. Иң популяр кыз исемнәрен ачыклау.
3. Иң популяр малай исемнәрен билгеләү.
4. Кыз һәм малай исемнәре арасында татар һәм рус исемнәрен ачыклау.
5. Укучыларның үз исемнәренең мәгънәсен белү-белмәвен билгеләү.

Фәнни эшебездә өлешчә эзләнү, тикшеренү, чагыштыру, анализ кебек **метод-алымнарны** файдаландык.

Әлеге тема буенча эшләгәндә, татар исемнәренең мәгънәсе, килеп чыгышы, тарихы турында мәгълүмат Гомәр Саттаров хезмәтләреннән алынды. Билгеле булганча, ул – Казан ономастика мәктәбенә нигез салучы, татар исемнәре белгече, күренекле тел галиме.

## ТӨП ӨЛЕШ

### БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. ОНОМАСТИКА ҺӘМ АНТРОПОНИМИКА ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ

Дөньяда һәр әйбернең, предмет, күренешнең исеме, атамасы була. Безнең әйләнә-тирәбездәге һәр нәрсәнең үз исеме, үз атамасы бар. Телдәге әлеге исемнәр, атамалар ике зур төркемгә бүленә. "Бер төрдән булган әйберләрнең барсы өчен уртак, гомуми атамасы— аларның күмәклек (уртаклык) исемен (мәсәлән, *кеше, шәһәр, елга, агач, таш, урман, урам, базар* һ. б.), бары тик берсен генә белдергәне —шәхси, ялгызлык исем барлыкка китерә (мәсәлән, *Алсу, Айназар, Айдар, Идел, Зөя, Казан, Саратов, Арча, Балтач, Саба, Бишбалта, Болак, Ташаяк* һ. б.). Ялгызлык исемнәренә кеше, ыруг, кабилә, халык; мифологик образлар һәм аллалар; йорт хайваннары; төрле географик объект-лар; күк җисемнәре; китап, газета-журналлар, предприятие һәм учреждение исемнәре; төрле әйбер, товар атамалары һ. б. керә". [3: 5].

"Барлык төр ялгызлык исемнәренең килеп чыгышын, үсешен, ясалыш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү белән тел белеменең **ономастика** (грекча «исем кушу сәнгате» мәгънәсендәге сүздән) дигән махсус тармагы шөгыльләнә". [3: 9]. Ономастиканың ике зур бүлеге бар – *топонимика* һәм *антропонимика.* Топонимика барлык географик атамаларны, төшенчәләрне (топонимнарны) өйрәнә.


Һәрбер телдә дә кешеләргә эндәшкәндә, мөрәҗәгать иткәндә кулланыла торган сүзләр – антропонимик категорияләр була. "Антропоним термины (грекча *антропос* — «кеше» һәм *онома* – «исем» сүзләреннән) кешеләрне атау өчен хезмәт итә торган исем, отчество, фамилия, кушамат һәм псевдоним төшенчәләрен аңлата һәм билгеле бер телдә кешеләрне конкрет атау берәмлекләрен белдерү өчен кулланыла (мәсәлән, Закир – исем, Куштан – кушамат, Шакирович – отчество, Бакиров – фамилия, Тиктормас — псевдоним һ. б. – болар барсы да антропонимнар). Татар телендә кешегә эндәшү, атап мөрәҗәгать итү категорияләренә исем, кушамат, ата исеме (отчество) һәм фамилия керә. Бу категорияләрнең килеп чыгышын, төзелеш һәм кулланылыш үзенчәлекләрен, үсеш-үзгәреш закончалыкларын ономастиканың антропонимика дигән бүлеге өйрәнә. **Антропонимия** – теге яки бу телдәге кеше исемнәре, кушаматлар, отчество һәм фамилияләрнең тулаем җыелмасының аталышы". [3: 9]

Һәр чорның үз популяр исемнәре була. Бүгенге көндә татарлар арасында иске татар исемнәре белән бергә чит телләрдән кергән исемнәр дә киң кулланыла.

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. ИСЕМНӘР БУЛА ТӨРЛЕ...

Бәби туа җиргә аваз салып,
Кеп-кечкенә, ләкин ул – кеше!
Елау, көйсезләнү, йоклау гына
Әле аның бар белгән эше.
Шул кешегә матур исем кирәк,
Аның булсын тирән мәгънәсе.
Шушы исем аңа гомерлеккә!
Истә тотсын әткә-әнкәсе!
Шушы исем белән яшәп, кеше
Үрләр яулый, таный, таныла.
Исем мөһим кеше язмышында,
Һәркем салсын моны аңына.

Кеше исемнәренең бай тарихы бездә зур кызыксыну уятты. Безнең яшьтәшләр арасында нинди исемнәр популяр булуын ачыкларга теләп, 5-6нчы сыйныф укучылары арасында анкета уздырдык. Барлыгы 153 кеше анкета тутырды. Исемнәр арасында татар, рус һәм интернациональ дигән төркемнәр аерып чыгардык. Барлыгы 79 татар исемле бала катнашкан. Рус исемлеләр – 47. 27 укучы интернациональ исем йөртә.




Анкетада катнашучылар: 89 кыз һәм 64 малай.




Аларны тикшергәч, шундый нәтиҗәләр ясалды. Кызлар исемнәре арасында татар исеме йөртүчеләр – 44, рус исемлеләр – 24, интернациональ исемле кызлар – 21.




Кызлар арасында популяр исемнәр:

- Әминә (татар исеме) – 4;
- Виктория (рус исеме) – 4;
- Карина (интернациональ исем) – 5.


Малайларның 35е татар исеме йөртә, рус исемлеләр – 23, интернациональ исемле 6 малай бар.




Иң популяр малай исемнәренә тукталсак, шуны күрербез:

- Әмир (татар исеме) – 7.
- Артем (рус исеме) – 3.

Анкетада катнашучыларның күбесе, ни кызганыч, үз исемнәренең мәгънәсен белми. Алар – 82 укучы (54%). 71 укучы (46%) үз исеменең мәгънәсен белә.




ЙОМГАК

Балага исем сайлау, исем кушу – бик җаваплы эш, чөнки бала аннары гомер буе шул исеме белән яши. Шуңа күрә бу эшне уйлап, җитди итеп башкарырга кирәк. Балага исем кушканда, аның мәгънәсенә игътибар итү зарур.

Һәр чор өчен популяр исемнәр була. Бүгенге көндә “Адымнар – Әлмәт” күптелле гимназиясендә 10-13 яшьлек балалар арасында кыз исемнәреннән Әминә, Карина, Виктория исемнәре популяр. Малайлар арасында Әмир, Артём исемнәре еш очрый.

Исемнәр төрле-төрле. 153 укучы арасында иң күбе – татар исемнәре (79). Икенче

урында – рус исемнәре (47). 27 укучы интернациональ исем йөртә. Ни кызганыч, укучыларның күбесе үз исеменең мәгънәсен белми. Анкетада катнашучыларның бары тик 46% гына үз исеменең мәгънәсен белә. Проектны без бик зур кызыксыну белән эшләдек. Эзләнә, иҗади фикер йөртә торгач, исем кушу тарихы, исем мәгънәләренең нинди бай хәзинә икәнен аңладык. Эш барышында әдәби китаплардан, сүзлекләрдән файдаландык, интернет аша күп мәгълүмат тупладык. Проект эшен эшләгәндә, без

- эзләнергә;
- бирелгән эшкә җаваплы карарга;
- куелган сорауларга җавап табарга өйрәндек.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Татарча-русча кеше исемнәре һәм фамилияләре сүзлеге. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2006 ел.

2. Гомәр Саттар-Мулилле “Татар исемнәре ни сөйли?”. – “Раннур” нәшрияты, 1998 ел.

3. Гомәр Саттаров “Татар исемнәре”. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2019 ел.

4. Интернет ресурслар.

*Карамов Гадел, 6 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «29 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе " муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкче: Якупова Венера Бәдертдин кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Эчтәлек

Кереш
Беренче бүлек.
Роберт Миңнулин шигырьләрендә һөнәр атамалары
Икенче бүлек.
Һөнәр атамаларының лексик төрләре һәм ясалышы
ЙомгакКушымта
Әдәбият

Кереш

2023 нче елда яраткан шагыйребез Роберт Миңнуллинга 75 яшь тулган булыр иде.
Иҗатына багышланган сыйныфтан тыш уку минутларында, дәресләрдә Р.Миңнуллинның

күңелле шигырьләрен укыйбыз. Татар теле дәресләрендә аның шигъри теленнән грамматик кагыйдәләргә туры килгән мисалларны эзлибез. Тупланган күзәтүләр фәнни тикшерү эшендә дәвам итте.

Эшнең темасы "Шагыйрь иҗатында һөнәр атамалары" дип исемләнде.

Фәнни эшнең максаты – Роберт Миңнулин шигырьләрендәге һөнәр атамаларын өйрәнү.

Эшнең бурычлары:

1. Роберт Миңнулин шигырьләрен уку,
2. шигырьләрдә кулланылган һөнәр атамаларын туплау,
3. лексик төрләргә аеру һәм ясалышы буенча анализлау.

Эшнең фәнни яңалыгы. Бу фәнни эшне эшләгәндә Р.Миңнуллин иҗатына багышланган күп китаплар, мәкаләләр карадык. Аларда шигырьләрне төрле яктан тикшергәннәр. Ә менә һөнәр атамалары кулланган шигырьләре хакында мәкаләләр юк. Шуңа нигезләнеп, бу эштәге тәүге фәнни эзләнүләрне яңалык итеп тәкъдим итәбез. Һөнәр атамалары төзелешен модельләштереп анализлыйбыз.

Эшнең чыганагы – Р. Миңнуллинның "Күчтәнәч" һәм "Сөенсеннәр әле сабыйлар!" дигән китаплары. Алардан 377 шигырь укып тикшерелде. Шигырьләрдәге һөнәр атамалы тупланды. 22 шигырьнең эчтәлеге һөнәр атамалары белән бәйле булуы ачыкланды.

Фәнни эш кереш, төп өлеш, йомгак, кушымтадан тора. Беренче бүлектә Р. Миңнулин шигырьләрендә һөнәр атамалары тупланды. Кушымтада нәтиҗәләр таблицасы ясалды. Икенче бүлектә әлеге атамалар лексик төрләргә аерылды һәм ясалышы буенча модельләштерелде. Нәтиҗәләр йомгакта тәкъдим ителде.

Беренче бүлек.

Роберт Миңнулин шигырьләрендә һөнәр атамалары

Роберт Миңнуллин шигырьләре кечкенә һәм урта яшьтәге балаларга тәкъдим ителә. Аларда балалар тормышы кызык итеп сөйләнә. Күп шигырьләре балалар теленнән сөйләтелә. Ул балалар бик шук, тиктормас һәм искиткеч хыялыйлар. Мисалга, бер малай күктәге Айны югалткан. Эзли торгач, аны Иделдән "тапкан". Айның судагы шәүләсенә карап, "кереп, Айны елгадан алып чыксам, күккә ничек менгезим икән" дип баш вата.

Әһә, таптым, дусларым,
Нигә озак уйларга? –
Биреп җибәрәм Айны
Космонавт абыйларга! - дип уйлап таба малай. ("Космонавт абыйлар")

Космонавт образы берничә шигырьдә кабатлана. "Айга очтык!" шигырендә космонавт булуның авырлыгы сөйләнә. Ракетага утыралар, ә ракеталары очып китә алмый. Файдалы нәтиҗәләр ясала: "шулай да космонавт булу авыр икән, малайлар!" – диелә эчтәлектә.

“Кайтабыз ла җиләктә” шигырендә балалар арып җиләктән кайталар. Акрын атлап кайтканда вакыт озак үтә. Баланың эче пошып, “бу вакыт аралыгында космонавтлар инде Айдан да кайтып җитәрләр иде,” – дип уфтана. “Үч итәм!” шигырендә малай билет алмый, юлдашы Галләм аны “куян” дип үрти. Малай үч планы кора: үсеп космонавт булгач, ул Галләмгә кул гына изәп китәчәк. Үч итәсе килсә дә, малайның өметләре ак: Космонавтлар отрядына мине алмый калмаслар, Кирәк булачак бит әле Аларга да алмашлар. (“Үч итәм!”)

“Кем буласың?” шигырендә малайга шул сорауны бирәләр. Малайның очучы буласы килә. Ә икенче бер шигырь “Буласым килми космонавт” дип атала. Минем бабай да, әти дә космонавт булмаган, менә мин дә Айга очмыйм; анда берүзем нишләп йөрим, дип фикерли малай. Мондый “хыялый” һөнәрләр исемлеген дәвам итеп, “МИ- 8 А” шигыреннән – конструктор, “Капитан булачакмын” шигыреннән – капитан, “Туп тибәргә яратучы малай турында кечкенә әкият” шигырендәге – футболчыны санап күрсәтергә мөмкин.

“Табышмак-шигырь”дә Р.Миңнуллин табышмак җавабын күп һөнәрләр белән чагыштырып таптыра: нәкъ циркач шикелле стенада йөри ул, космонавт шикелле җиһанда йөри ул, водолаз шикелле суда да йөри ул, дип, санап китә.

Галәм белән бәйле хыялый шигырьләренең берсе “Астронавт абыйга хат” дип исемләнгән. Шигырь тугыз яшьлек баланың теләге итеп язылган һәм астронавтка юлланган:

Бомбаларны ракетага
Төяп китмәссез микән?
Шуларны Марска яки
Айга илтмәссез микән?
Ятсыннар шунда тутыгып,
Бернигә кирәксезгә,
Астронавт абый! Бу хакта
Уйларга кирәк безгә! (“Астронавт абыйга хат”)

“Тырышам” шигырендә малай игенче булып эшләгән әтисе кебек тырышуын сөйли. Ул комбайнчы әтисенә һәм абыйсына шөрепләр борыша, үзе бик тырыша. “Кирәк!” дип исемләнгән шигырь эчтәлеге игенченең хезмәтен зурлый. Һәркемгә дә ипи кирәк, космонавтка да, юллар салучыга да, тайгада эшләүчеләргә, сезгә дә, безгә дә, дип саналып китә. Шигырьдәге нәтиҗә бик матур: Шуңа да игенчене Хөрмәт итәргә кирәк. (“Кирәк!”)

“Кем нәрсә тарта” шигырендә “Тегермәнче минем әти, тегермәндә ул он тарта” дип, малай үзенең тегермәнче әтисе турында сөйли. “Бакча белән хушлашу” шигырендә тәрбияче, укытучы һөнәрләре турында әйтелә. Чыгарылыш бәйрәмендә тәрбияче апа балаларны

елый-елый озата. Бала “ник укытучылар да балалар бакчасында гына  укытмыйлар икән” – дип уйлана.
“Безнең гаилә” шигырендә милиционер хезмәте телгә алына. “Әтием тәртип ярата, ул бит милиционер” дип таныштыра  үз гаиләсе белән лирик герой. Икенче бер бала малайларга мөрәҗәгать итә, әнисенең доктор булуын әйтә: “Малайлар, юкка сез Доктордан куркасыз. Бик әйбәт ул димен, Әни бит ул минем!”
“Күрше абый” шигырендә урам себерүче хезмәте турында сөйләнә. “Ялт иттереп куя ул урамның бөтен төшен” –  ди, аның турында бала. Бик каты бураннарда да күрше абый кар көри. Урам себерүчеләр тырышып эшләгәнгә, шәһәр кешеләренә бик чиста һәм йөрергә уңайлы.
Роберт Миңнуллинның шигырьләре гади генә түгел. Ул балалар теле белән, күп очракта, малай исеменнән сөйләнелә. Ә менә  “Кадерле малай” шигырендә автор Алмаз үссен өчен, Алмаз уңайлы яшәсен өчен кемнәр тырышып эшләгәнен санап китә. Шигырьдә игенче, савымчы, укытучы, тегүче, төзүче, клоун (артист) һөнәрләре турында сөйләнә.
Күп һөнәрләр турында тагын бер шигырь “Малайлар сөйләшә” дип аталган. Бу шигырь диалог итеп бирелә. Малайлар кем булачаклары хакында бәхәсләшәләр. Кайсы берсе батыр солдат, космонавт, хоккей спортындагы капкачы Третьяк, начальник булам дип мактана. Санап кителгән һөнәрләрдән корыч коючы, чуен коючы, аучы, кибетче, итче, комбайнчы бар. Бер малай күз бууучы булачагы турында әйтә. Роберт Миңнуллин шигырьләре балаларга матур итеп җиткерәсе вәгазь, өйрәтү сүзләре  белән тәмамлана. Бу шигырьдә дә бер малай азактан гына әйтеп куя:

– Ә миңа әни, үскәч,

Куша Кеше булырга! (“Малайлар сөйләшә”)

“Яшәгән, ди, Тылсынчы” шигырендә агачтан, таштан сыннар иҗат итүче сынчы турында сөйләнелә. “Кызык кеше” шигырендә  автор үзе хакында яза. Үзенең шагыйрь  булып эшләгәнлеген әйтә.  Иҗади һөнәрләрдән “Малайлар сөйләшә” шигырендәге” Рудольф Нуриев кебек биюче”не дә өстәп куярга мөмкин.

Беренче бүлеккә нәтиҗә.

Р.Миңнуллин язган  377 шигырь һөнәр атамалары кулланышына тикшерелде.  Барлыгы 22 шигырьдә һөнәр атамалаы кулланылган.  Аларда 39 һөнәр телгә алына. Иң еш кабатланганы – космонавт. Барлыгы 30 һөнәр төре кулланылган (кушымта).

Икенче бүлек

Һөнәр атамаларының   лексик төрләре һәм ясалышы

Р. Миңнуллин иҗатындагы һөнәр исемнәре арасында саф татарча сүзләр – иң күбесе. Татар сүзләреннән очучы, игенче, юл салучы, тегермәнче, тәрбияче, укытучы, урам

еберүче, савымчы, төзүче, тегүче, корыч коючы, аучы, итче, кибетче, биюче, сынчы һөнәр атамалары тупланды. Күргәнебезчә, бу атамаларның күбесе сүз тамырына кушымча ялганып ясалган. Кушымча – сүзнең төп яки грамматик мәгънәсен үзгәртә торган иң кечкенә кисәге. Ә ясагыч кушымча – сүзнең тамырына яңа лексик мәгънә өсти торган кисәк. [2.4].

Татар телендә һөнәр атамалары арасында тамыр + сүзьясагыч кушымча моделе бик еш кулланылган. Бу үрнәктә ясалган һөнәр атамалары күп. Алар арасында тамырлары исем сүз төркеменә караган төрләр шактый. Предметны белдергән исем + чы/че кушымчасы моделендә:

Иген + че = игенче

Тегермән + че = тегермәнче

Ит + че = итче

Кибет + че = кибетче

Сын + чы = сынчы

Исем фигыль – үтәүче заттан аерылган эш-хәрәкәтнең атамасын (исемен) белдерә торган затланышсыз фигыль формасы. Ул үз эчтәлегендә исем һәм фигыль билгеләрен йөртә [2.87]. Исем фигыль төрләренә кушымча ялганып ясалган модельдәге һөнәр атамалары да күп. Шундыйлардан:

Очу + чы = очучы

Укыту + чы = укытучы

Савым + чы = савымчы

Төзү + че = төзүче

Тегү + че = тегүче

Тезмә сүзләр ирекле сүзтезмә үрнәге буенча ясалалар [2.26]. Сүзләрне тезү юлы белән ясалган һөнәр атамаларына шартлы модель төзик. Мисалга:

исем * исем фигыль + сүзьясагыч кушымча = һөнәр атамасы

Корыч коюю + чы = корыч коючы

Урам себерү + че = урам себерүче

Юл салу + чы = юл салучы

Нәтиҗәдә, тезмә исемнәр барлыкка килгән.

Шигырьләрнең эчтәлеге балалар, балачак хыяллары, аларның сөйләме белән бәйле.

Шуның өчен, аларда космонавт, капитан, футболчы кебек һөнәрләр еш кулланыла.

Андыйлар арасында рус һәм чит телдән кергән алынма сүзләр күп.

Космонавт, капитан, астронавт, водолаз, циркач, доктор, клоун, конструктор – алынма сүзләр. Алар тамыр сүзләр булып кулланышка кергән, сүзьясагыч кушымчалар өстәлми.

Шигырьләрдә еш очраган игенчеләр турында Роберт Миңнуллин да бик матур итеп яза. Игенче белән беррәттән, комбайнчы сүзе дә кулланылган. Комбай – чит телдән кергән техник сүз. Ул иген игә торган машина төренең атамасы. Комбайн сүзенә татар кушымчасы ялганып, һөнәр атамасы ясалган. Бу сүзгә модель төзегәндә, аның алынма тамырлы икәнен күрсәтергә дә мөмкин:

Алынма исем + чы = һөнәр атамасы

Комбайн + чы = комбайнчы

Шигырьләрнең берсендә милиционер сүзе очрый. Хәзерге полиция хезмәткәрләрен элек милиционер сүзе белән атаганнар. Элекке елларда язылган әдәби әсәрләрдә, халык телендә ул сүзне еш очратырга мөмкин. Милиционер сүзе, шулай ук, чит телдән алынма. Роберт Миңнуллин шигырьләрендә балаларча, шул ук вакытта, шигъри фантазияләр еш кулланылган. Һөнәрләр турында язылган ике әсәрендә автор үзе уйлап тапкан сүзләр очрады. Бик кызыклы һөнәр турында “Тәгәрмәчле яңгыр” шигырендә сөйләнә. Малай үзенең абыйсының эше турында сөйли. Ул кырларда су сиптерә. “Минем абый – яңгырчы” дип горурлана малай. Яңгырчы дип аталган һөнәр иясе юк. Бу шигырьдә автор Р.Миңнуллин балалар телендә яңа сүз ясаган. Су сиптерүче “мелиоратор”, ә авыл хуҗалыгының бу өлкәсе мелиорация дип атала [1.379].

“Яшәгән ди , Тылсынчы” шигырендә шагыйрь бик оста сынчы турында сөйли. Аның иҗатын бик матур тасвирлый, эшләгәнен, хәрәкәтләрен тылсымчы белән чагыштыра. Үзе шунда ук, “сыннар ясагач, тылсымчы түгел, ә - Тылсынчы “ дип нәтиҗә дә чыгарып куя. Әлбәттә, тылсынчы, яңгырчы сүзләре Роберт Миңнуллинның иҗатында гына кулланылган сүзләр. Алар махсус һөнәр атмалары түге. Автор бу сүзләрне балаларга аңлату, исендә калдыру өчен генә уйлап тапкан.

Бүлеккә нәтиҗә.

Сүз ясалышы ягыннан әлеге һөнәр атамаларын исем + чы/че кушымчасы; исем фигыль + чы/че кушымчасы; исем * исем фигыль + сүзьясагыч кушымчасы модельләренә аердык. Роберт Миңнуллин шигырьләрендә кулланылган һөнәр атамалары арасында саф татарча сүзләр, рус һәм чит телләрдән алынмалар һәм бер кулланыштан төшеп калган сүз очрады.

Йомгак

Роберт Миннулин шигырьләрендәге һөнәр атамаларын өйрәнү максаты белән язылган “Шагыйрь иҗатында һөнәр атамалары” дип исемләнгән фәнни эшкә Роберт Миңнулин шигырьләрен уку, алардагы һөнәр атамаларын туплау, аларны лексик төрләргә аеру һәм ясалышы буенча анализлау максаты куелды. Фәнни эшнең яңалыгы итеп, Р.Миңнуллин

шигырьләрен һөнәр атамалары белән бәйле өйрәнүләр һәм модельләштереп анализлауны тәкъдим иттек. Беренче бүлектә шигырьләрдән һөнәр атамалары туплау эше, икенче бүлектә атамаларның төрләре һәм ясалышлары ягыннан анализ бирелде. Кушымтада эш өчен чыганак-таблица төзелде.

Фәнни эшкә түбәндәге нәтиҗәләр ясалды:

1. Роберт Миңнуллин балалар өчен бик үтемле шигырьләр язган. Араларында балаларның үз телләрендә һөнәр ияләренең эшләрен, үзенчәлекләрен өйрәткән, тырышып эшләргә, үз һөнәреңне сайларга юнәлеш бирә торганнары күп. Фәнни эш барышында 377 шигырь укылды. 22 шигырьдә 39 һөнәр атамасы телгә алынган. Кабатланганнарыннан тыш, 30 һөнәр төре турында язылган.
2. Һөнәр атамалары арасында космонавт – иң еш кулланылган. Ул 7 шигырьдә телгә алынган. Игенче һөнәре атамасы 4 шигырьдә очрый.
3. Һөнәр исемнәре арасында очучы, игенче, юл салучы, тегермәнче, тәрбияче, укытучы, урам себерүче, савымчы, төзүче, тегүче, корыч коючы, аучы, итче, кибетче, биюче, сынчы кебек сүзләр саф татарча яңгырашка ия. Космонавт, капитан, футболчы, астронавт, водолаз, циркач, доктор, клоун, конструктор кебек чит һәм рус телләреннән кергән алынмалар күп. Куллануда төшеп калган “милиционер” сүзе табылды. Автор үзе “яңгырчы”, “тылсынчы” сүзләрен иҗат иткән.
4. Сүз ясалышы ягыннан Р.Миңнуллин шигырьләреннән җыелган һөнәр атамаларын исем + чы/че кушымчасы; исем фигыль + чы/че кушымчасы; исем * исем фигыль + сүзьясагыч кушымчасы модельләренә аердык.

КУШЫМТА

| Һөнәрләр | Шигырь исемнәре |
|---|---|
| космонавт | “Космонавт абыйлар” |
| космонавт | “Айга очтык!” |
| космонавт | “Кайтабыз ла җиләктән” |
| космонавт | “Үч итәм!” |
| очучы | “Кем буласың” |
| космонавт | “Буласым килми космонавт” |
| конструктор | “МИ- 8 А” |
| капитан | “Капитан булачакмын” |
| футболчы | “Туп тибәргә яратучы малай турында кечкенә әкият” |
| космонавт | “Табышмак-шигырь” |

| | |
|---|---|
| водолаз | |
| циркач | |
| астронавт | “Астронавт абыйга хат” |
| игенче | “Тырышам” |
| комбайнчы | |
| космонавт | “Кирәк!” |
| игенче | |
| юл салучы | |
| тегермәнче | “Кем нәрсә тарта” |
| “яңгырчы” (мелиоратор) | “Тәгәрмәчле яңгыр” |
| тәрбияче | “Бакча белән хушлашу” |
| укытучы | |
| милиционер | “Безнең гаилә” |
| доктор | “Доктор” |
| урам себерүче | “Күрше абый” |
| игенче | “Кадерле малай” |
| савымчы | |
| тегүче | |
| укытучы | |
| төзүче | |
| клоун | |
| корыч коючы | “Малайлар сөйләшә” |
| аучы | |
| кибетче | |
| итче | |
| комбайнчы | |
| биюче | |
| сынчы | “Яшәгән, ди, Тылсынчы” |
| шагыйрь | “Кызык кеше” |

Әдәбият

Чыганакла:

Миңнуллин Р.М. Кучтәнәч: шигырьләр җыентыгы / Р.М. Миңнуллин – Казан: Мәгариф, 1995. – 159 б.

Миңнуллин Р.М. Сөенсеннәр әле сабыйлар!: шигырьләр җыентыгы / Р.М. Миңнуллин – Казан: Мәгариф, 2002. – 335 б.

Кулланылган әдәбият


1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге : өч том да. / Икенче том. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1979. – 379 б.
2. Харисова Ч.М. Хәзерге татар теле: морфемика, сүз ясалышы, морфология / Ч.М.Харисова // морфемика, сүз ясалышы, морфология. – Казан: КФУ, 2014. – 112Б.



*Каримов Айнур, 5 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы 18 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитэкче: Д.Р.Загидуллина татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


**Абдула Алиш батыр да, язучы да**

**Кереш**

Татар халкының горурлыгы булган җәлилчеләр һәм аның көрәштәшләре үрнәгендә яшь буынны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү эше дәвам итә. Икенче бөтендөнья сугышы тәмамлануга 79 ел үтсә дә, Абдулла Алишның иҗаты бүген дә әһәмиятен югалтмый: үлемсез әсәрләре кешелекне уяулыкка чакыра, сугыш уты кабызучыларга каршы көрәшкә өнди.

Тикшерү эшемнең темасы “Алиш язучы да, батыр да” дип билгеләдем.
Максатым Абдулла Алишның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү.

**Бурычлары:**

- Абдулла Алишның тормыш юлында булган якты истәлекләрне барлау;

-язучы иҗатына күзәтү ясау, аның әдәбиятка килү шартларын, иҗат үзенчәлекләрен билгеләү;

- язучы, шагыйрь һәм фронтовик А.Алиш иҗатына кыскача күзәтү ясау.

Өйрәнү объекты булып А.Алишның “Язучы да Алиш, батыр да” Абдулла Алиш турында истәлекләр.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: Абдулла Алиш – үзенең Ватанга тугрылыгы, чын ирләргә батырлыгы белән генә түгел, каләм очыннан тамган гыйбрәтле сүзләре, ничәмә-ничә буын балаларын тәрбиятләгән әкиятләре белән дан яуган шәхес.

**Балачакның якты мизгелләре**

Алишев фамилиясен беренче булып әтисе Габделбари йөртә башлый. Ул бу фамилияне нәсел шәҗәрәсендәге иң ерак бабасы Алиш (Галиша) хөрмәтенә дип, яратып сайлап алган. Алишның әтисе Габделбари Алишев, өйләнгәннән соң, төп йортта яшәп кала. Бик матур алма-чия бакчасы үстерә, умартачылык белән шөгыльләнә. Әнисе, Газизә Әхмәтсафа кызы, Шонталы авылында мулла гаиләсендә туган. Гыйлемле, изге күңелле, шигъри җанлы, шигырь һәм бәетләр чыгарырга һәвәс булган ул.

Алладан сорап алган ир бала 1908 нче елның 15 нче сентябрендә Габлуллаҗан туа. Габдул кечкенәдән үк әкиятләр, төрле мәзәкләр ярата.

Ул укуга да бик һәвәс була, халык авыз иҗаты белән мавыга. Язган шигырь-бәетләрен, күзәтүләрен дәфтәренә язып бара.

Кечкенә-кечкенә китапчыклар булып чыккан "Герман сугышы бәетләре"н күңелдән ятлый, юлдан-юага бармакларын йөртеп "укып", тыңлаучы әби-апаларны елатканы әле дә күз алдында, дип искә ала бертуган апасы.

Нәни чакта уйнаган уены да гел герман сугышы булган. Казаннан Гаптулга яңа киемнәр алып кидергәннәр, уенчыклар алганнар. Уенчыклар арасында бөке белән ата торган агач мылтык та булган. Урамга чыгып балаларга мактанып, күрсәтеп йөргән. Беркөнне кыр үрдәкләренең йөмыркаларын алып кайткан. Әтисе шунда: "Нигә алып кайттың боларны, улым? Син тимәсәң, шул йомыркалардан матур-матур үрдәк бәбкәләре чыгар иде", дип аңлаткан һәм аларны кире урыннарына илтеп куярга кушкан. Гапдул аларны шул көнне ук ояларына илтеп кайткн һәм шул коннән сн кош йомыркаларына тими башлаган.

Абдулла бик теләп һәм тырышып укый, алдынгылар рәтендә була. Мәктәптә җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Ул әдәбият, драма, спорт түгәрәкләренә йөри. Аның малайлык, яшьлек еллары агымсу кебек тиз үтеп китә.

**Балалар әдәбияты остасы**

Аз сүзле, ягымлы карашлы Алиш журналист булып та эшли. Ул балаларның дусты, балалар әдәбияты остасы буларак таныла. Алиш балаларны һәм балалар әдәбиятын бик ярата.1939-1940 нчы елларда ул балалар өчен гаять үзенчәлекле, тормыш белән бәйләнгән әкиятләрен бер-бер артлы иҗат итә. А.Алишның "Ана әкиятләре" китабы 1940-1941 нче елларда ике телдә басылып чыга. Әкиятләрен иҗат иткәндә, ул үзен шагыйрь итеп тә таныта. Аның теле халыкчан, шигъри, музыкаль,әсәрләрендә эчке рифмалар тулып ята. Кыска җөмләләрдә олы, тирән фикерләр әйтелә. Ә болар барысы да аны прозадагы шагыйрь итеп күрсәтәләр.

А.Алишның кечкенәләр өчен язылган хикәяләре дә бик кызыклы. "Чуар тавык", "Әбиләргә кунакка", "Утлы йомырка" кебек кыска, җыйнак кына эшләнгән миниатюр

парчаларында балаларны шатландырырлык, гыйбрәт алырлык никадәр йөрәк җылысы һәм эчке мәгънә бар! Ул балалар аңларлык сүзләрне эзли һәм таба, балаларның аңына үтеп керә, аларны мавыктыра белә.Алишның балалар психологиясен аңлап, аларның үзенчәлекле тел белән иҗат итүенә сокланмый мөмкин түгел.Абдулла Алиш әсәрләрен укыганда, тере Алиш, үзенә таләпчән һәм тыйнак язучыбыз, балаларның сөекле дусты күз алдыбызга килеп баса.

Абдулла Алишның искиткеч хикәяләрен, күңелгә ятышлы әкиятләрен балалар бүген дә яратып укыйлар. Әлбәттә, ул шулай булып калыр да. Еллар аларны үтмәсләндермәс, бизәген уңдырмас. А.Алиш – бүгенге һәм киләчәк буыннарның тәрбиячесе булып кала.

**Язучы да Алиш, батыр да**

1941нче елның июне. Радио куркыныч хәбәр китерә: фашистлар Германиясе илебез территориясенә юлбасарларча бәреп керә.

Тиздән Алишны Кызыл Армия сафына алалар. Берничә атна Казан янындагы хәрби лагерьда тотканнан соң, 11 нче августта аны фронтка җибәрәләр.

Муса Җәлил белән иңгә-иң торган, фашизмга каршы аяусыз көрәш алып барган унбер батыр арасында Абдулла Алиш аерым урын алып тора. Аны җәлилчеләр “Мусаның уң канаты “ дип йөрткәннәр. Мусаның күптәнге дусты буларак та, ышанычлы,нык ихтыярлы кеше буларак та ихтирам иткәннәр. Алишның тоткынлыктагы героик көрәше һәм тормышы турында шактый бай мәгълүматлар бар.

Аны 1942 нче елның азагында Краков лагереннан Седльцега күчергәннәр. Аннары аны Вустрау лагерена алып киләләр. Бу ябык лагерьда махсус сайлап алынган әсирләр генә була. Монда Алиш үзенең якын дуслары Рәхим Саттар, Муса Җәлил белән очраша. Шул көннән башлап, алар тормышында оешкан төстә яшерен көрәш чоры башлана. Бераздан Алиш белән Саттарны Берлинга “Идел-Урал” газетасына күчерәләр. А.Алиш редакциядә җитәрлек контроль булмаудан файдаланып, бергенә материал да бастырмый, Тукай, Такташ, Каюм Насыйри кебек атаклы татар язучылары турында мәкаләләр язу белән чикләнгән.

Безнең өчен, яисә, хәзерге буын балалары өчен җәлилчеләр турында искиткеч материаллар бар. Мәсәлән, миңа, Алишның Мусаны ирекккә чыгару өчен тырышып йөрүләре зур яңалык булып тора. Гомумән, язучы Рафаэль Мостафин язмалары белән танышканда, минем өчен барысы да искитәрлек вакыйга булды. Абдулла Алиш, Берлинда йөргәндә, кечкенә генә бакалея кибетендә татарга бик тартым булган кеше очратып сүз куша. Бу кеше - кибетнең хуҗасы – чыннан да, Хафиз исемле татар кешесе булып чыга. Ул Беренче бөтендөнья сугышы вакытында әсир төшеп, өйләнеп, Берлинда төпләнеп калган икән. Сөйләшеп, дуслашып китәләр. Соңыннан, Мусаны да Берлинга күчергәч, алар шунда – аулакта очрашалар.

Беренче батальон, кораллы восстание күтәреп, безнең якка чыккач, Алиш канатланып йөри, бу турыда листовка-өндәмәләр чыгара. “Аталы-уллы” исемле шигырь яза, әсирләрне дә үз артыннан иярергә чакыра.

1943нче елның май башында Рәхим Саттар берничә кешене үзе белән ияртеп качып китә.Яшерен оешма аны фронт сызыгы аша үтеп, безнең командование белән элемтә урнаштыру өчен җибәрә. Ләкин бу төркем фронт сызыгы аша үтә алмый,һәлак була. Алиш, Муса һәм яшерен оешманың башка әгъзалары артыннан да күзәтү көчәя.

Алишның кулга алынуы болай була. 1943 нче елның август башларында аны милли комитетлар артыннан күзәтүче немец офицеры Людерзен янына чакырып алалар. Шул китүдән ул әйләнеп кайтмый.Бераздан аның төрмәдән язган хатын алалар. Алиш үзенең һәм иптәшләренең кулга алынуын хәбәр итә. Аларны хөкем итәргә җыеналар. Туган илгә исән кайта алучыларга, әнисенә, хатынына, балаларына, барлык туганнарына сәлам әйтергә куша, барысына да бәхет тели. Аеруча сагынып, улларын искә ала.

Бу фәнни эш белән шөгыльләнгәндә, мин тагын бер кызыклы фактка тап булдым. 1944 нче елның 28 нче гыйнварында Абдулла Алиш гаиләсенә, туганнарына хат яза. Ул хатны төрмәдән Алиш белән бергә утырган Бельгия патриоты Эмиль Мэйзон алып чыга һәм Казанга юллый.

Хат белән бергә Э.Мэйзон үзендә сакланган соңгы истәлек әйберне – кечкенә пакет-конверт җибәрә.

**Хатлар тагын килер кебек**

Вахит Хаков – күренекле галим, филология фәннәре докторы. Абдулла Алиш турында язган истәлекләреннән.

Казан Кремле каршындагы мәйданга бик еш киләм. Герой – шагыйрь Муса Җәлилнең мәгърур сынына карыйм да, аның белән беррәттән, Абдулла Алиш та басып тора кебек була. Һәм Җәлилнең “Дуска” дигән шигыре искә төшә:

Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда...

Алишка багышлап язылган бу шигырьне мин тыныч кына укый алмыйм. Чөнки минем күңелемдә үсмер чакның изге хисләрен уяткан кеше – Алиш иде.

Сугышта дошман кулына эләгеп, башыннан бик күп хәлләр кичергән язучы абыебызны без еллар буе сагынып көттек. Әмма ул кайтмады.

Алишның утыз өченче елда язгын “Берлин” хикәясе дә минем бик исемдә. Бәлкем, хәтерлисездер, газета сатучы немец малае Карл турында яза ул. Пионер Гәрәй аны төшендә

күрә, һәм алар сөләшеп китәләр... Немец малае фашистларның вакытлыча гына баш булып торуларын әйтә.Аларны урыннарыннан барыбер очырачаклар, ди. Гәрәй дә нәкъ шулай уйлый. Көрәшнең каты булачагын да белә...

Гәрәй төшендә күргәннәрне Абдулла Алишка өнендә күрергә туры килә.”Берлин” дигән хикәя язган Алиш Берлин төрмәлләрендә утырыр дип, ул чакта кем уйлаган!

Ә менә хәзер шуларның барсын уйлыйсың.... Һәм мин үземнең балачакларымнан тагын бер урап кайтам. Абдулла Алишның миңа үз кулы белән язып салган хатларын киредән укып карыйм.

Алиштан килгән бу хатларны мин әдәбият укытучысына да күрсәтә идем. Сабый чакның бу минутлары гомердә онытылмас. Алар мине рухландыра, һаман каядыр чакыра, дәшә төсле тоела иде.

**Йомгаклау**

Сугыштан соң да Алиш иҗаты күп еллар буе Муса Җәлил күләгәсендә калып килә. Җәлил – зур талант иясе, дөнья күләменә чыккан шагыйрь. Ләкин Алиш шигырьләре дә зур әһәмияткә ия. Ул шигырьләрнең һәр юлы Туган илгә, Хәрби антка, халыкка тугрылык белән сугарылган.

Әгәр Алиш шигырьләрен Муса Җәлилнең шул чорда язылган шигырьләре белән чагыштырсак, аларның гаҗәеп дәрәҗәдә аваздаш икәне күренә. Алар икесе дә бер төрле уйлаган, икесе дә җиңү көне киләсенә һичшиксез ышанган һәм шул көнне якынайту өчен тырышкан. Тормышларының соңгы мизгелләрендә дә алар үз ирекләре турында түгел, бәлки Туган ил азатлыгы турында уйлаган:

Әйтсәләр дә барып тор син диеп,
Дөньяның иң рәхәт җиренә.
Әйтер идем: кирәк түгел, дип,
Кайтам мин дип Туган илемә.

Алиш каләме белән язылган бу юллар да Муса Җәлилнең “Моабит дәфтәрләре”ндәге шигырьләре шикелле нык ихтыяр көче, күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтә алырлык патриотик хис белән сугарылган.

“Алиш язучы да, батыр да“ исемле фәнни эшемне Мәхмүт Хөсәеннең күңелгә үтеп керә торган шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә.

Язучы да Алиш, батыр да,
Яшен булып яуда яшьнәгән!
Ил алдында тик бер тапкыр да,
Мин-батыр, дип гайрәт чәчмәгән.
Ия булган тыйнак холыкка,

Ядкарь итеп исемен язмаган.

Ил-анасын кара коллыкта

Күңелендә йөрткән, назлаган.

Бик авырын юлның сайлап ул,

Кыю кичкән үлем даласын…

**Кулланылган әдәбият**


1. ”Мәгариф” журналы. №5, 2013нче ел.

2. Татар балалар әдәбияты: Урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку ярдәмлеге / Л.И. Минһаҗева, И.Х. Мияссаравова. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2003. – 351 б.

3. Язучы да Алиш, батыр да: Абдулла Алиш турында истәлекләр. – Казан: Мәгариф, 2001. – 199 б. : рәс. б-н.



*Мингәрәев Рияз, 7 нче сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Каенлы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*

*Җитәкчеләр: Гарипова Лилия Рәүф кызы,*

*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*

*Гарипов Расим Фаиз улы, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*


**Халкыбызның батырлыгы мәңгелек!**

**КЕРЕШ**

Туган як! Туган җир! Туган туфрак! Туган төбәк! Һәрбер кеше өчен нинди газиз, тирән мәгънәле сүзләр! Алар һәркем йөрәгендә яши һәм вакытлар үтү белән тагын да байый, тулылана, ачыграк төс ала . Туган якның бай тарихы һәм культурасы, табигате һәм көнкүреше-болар барысы да кече яшьтән үк балалар тормышының бер кисәгенә әверелә. Безнең аңыбызда һәм тойгыларыбызда чагылган таныш урыннар, акрынлап Ватан образын күзалларга ярдәм итә. Туган якны өйрәнү халык культурасының гасырлардан килгән традицияләрен, халыкның зур һәм матур эшләренә хөрмәт хисләре тәрбияләүдә туган якны

өйрәнүнең мөмкинлекләре аеруча зур. Минем дә киләчәк буын өчен игелекле эш башкарасым килде һәм, иң кулае дип, фәнни-эзләнү эше язуны сайладым. Туган төбәк тарихын өйрәнгән вакытта, мин тагын бер нәрсәне аңладым. Бары тик туган як, гаилә, урам, авыл, мәктәп, халкың тарихын белсәң генә, Бөтендөнья һәм Ватан тарихын тиешле дәрәҗәдә үзләштерергә мөмкин

Эзләнү эшенең актуальлеге "Илен белмәгән- игелексез, халкын белмәгән- холыксыз, нәселен белмәгән- нәсәпсез",- дип халык юкка гына әйтмәгән. Кешелекнең иң югары кыйммәткә ия булган сыйфатларыннан берсе, мөгаен, Туган иленә, төбәгенә, йортына булган тирән мәхәббәттер. Һәр кеше бик кечкенәдән үзенең кем икәнлеген, ә иң мөһиме, аның үзенә генә хас тормыш юлы булганлыгын һәм иртәме-соңмы үз тормышы өчен җавап бирергә кирәклекне аңлый башлый. Ә моның өчен үз барлыгыңны, аның тарихи килеп чыгышын аңлау кирәк. Соңгы елларда туган телне,туган якны өйрәнүгә игътибар артты.Күпләр чын-чынлап үзләренең барлыгын аңларга: белеп булган барлык бабаларын эзләп табарга тырышалар. Бу – бик күп вакыт сорый торган, катлаулы, четерекле, шул ук вакытта кызыклы һәм бик саваплы эш.

**Гипотеза**

Бары тик үз халкының тарихын, гореф-гадәтләрен, танылган кешеләрен белгән халык кына азатлык һәм бәйсезлектә яшәргә хокуклы. Мин урам исемнәрендә Каенлы авылының гына түгел, ә, бәлки, илнең тарихы чагыла дип уйлыйм.

**Максат**

-Каенлы авылында үзәк урамнарның берсе булган- Татарстан урамы турында мәгълүматлар туплау;

- Татарстан урамының горурланырлык батыр ул-кызларын искә алу;
- әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү.

**Бурычлар**

- урамның тарихы белән танышу;
- геройларның биографиясен өйрәнү;
- эзләнү эшенең нәтиҗәсе белән укучыларны таныштыру;

-укучыларны, укытучыларны һәм әти-әниләрне патриотик традицияләрне дәвам итәргә өндәү.

**Эзләнү методлары**: әдәбият өйрәнү; китапханәгә бару; интернет челтәрендә мәгълүмат җыю; укытучы консультациясе; мәгълүматларны эшкәртү; презентация әзерләү һәм эшне яклау.

**Эзләнү эшенең эчтәлеге һәм нәтиҗәсе**: тема сайлау; эзләнү эшенең планын төзү; белешмә әдәбият белән танышу; интернет челтәрендә мәгълүмат җыю;җыелган мәгълүматны анализлау; эшне йомгаклау, нәтиҗә ясау; эшне яклау.

**Фәнни эшнең практик әһәмияте**: әлеге хезмәтне сыйныф сәгатьләре, сыйныфтан тыш чаралар үткәргәндә кулланырга мөмкин.

**Тикшерү объекты** - авыл урамнарын, авылыбызның исемен еракларга танытучы батыр якташларыбыз турында мәгълүматларны өйрәнү,.

**Тикшерү методы** – системалы анализ ясау.

**Эшнең төзелеше**. Тикшерү кереш, төп өлеш, йомгаклау һәм әдәбият исемлегеннән тора.

## II ТӨП ӨЛЕШ

### БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК. АВЫЛЫМ УРАМНАРЫН КАБАТ-КАБАТ УРАДЫМ...

Авыл урамнары буйлап узганда без аларның исемнәре турында күп очракта уйламыйбыз да. Ә уйлап карасаң, һәр урам үзе бер тарих. Тарихны без онытмаска тиеш. Үткәнен оныткан кавемнең киләчәге юк икәнне истә тотып, мин Каенлы авылының тарихы, анда яшәгән кешеләр турында таныштым. Мине бигрәк тә 4 гасырлык тарихы булган Каенлының урамнары, аның тырыш халкы кызыксындырды.

Каенлы авылының якынча 400 еллык тарихы бар. Авыл тарихчылары фаразлавынча, авылга нигез салучылар Казан ханлыгы Руська кушылганнан, ягьни 1552 елдан соң, корылык елларында Мамадыш районы Кече Сөн авылыннан килеп мул сулы Зәй елгасы буена урнашканнар. Бу тирәләр катнаш урман булган. Күченеп килүчеләр агачларны төпләп җир эшкәрткәннәр, терлекчелек белән шөгыльләнгәннәр.Тирә - юньне чолгап алган урманнарда каен агачлары күбрәк үскәнгә, авылга Каенлы исеме бирелгәндер дигән фикер яши.

Авылда җиде урам бар. Татарстан, Ленин, Интернациональная(Дуслык), Восточная(Көнчыгыш),Заречная(Инеш аръягы), Мәктәп исемле урамнарга, әлбәттә, халык телендә әле дә кулланыла торган урам исемнәре: Дию Сөләйманы урамы, Җүләрләр урамы, Котылдык урамын да табарга була Каенлыда”[2-52]

Татарстанның һәр авылында Татарстан, Ленин исемле урамнар бихисап. Авылыбызның иң озын урамы булган Татарстан урамы белән сезне дә таныштырам. Сүз башымда урамыбыз гына түгел, ә авылыбыз, районыбызга яхшы ук таныш булган мәгариф ветераны, үзешчән шагыйрь, ике китап авторы Саимә апа Сөләймmanagованың “Урамым-Татарстан” шигыреннән юллар китерергә булдым.

Безнең урамга исемне
Белмим, кем сайлап куйган?
Татар булгач, татар булыйк,

Татарча яшик, туган.

Гүзәл урамның берсе ул,

Тарихы тирән аның:

Кемнәр яши, кемнәр киткән,

Кемнәр күтәргән данын![ 2]

Әйе, кемнәр генә яшәмәгән бу урамда?!

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК. КЕМНӘР ГЕНӘ ЯШӘМӘГӘН БУ УРАМДА!

### 1.Алар Җиңү яулаганнар!

Бөек Ватан сугышында җиңү өчен гомерләрен дә кызганмаган, батырлыклары белән дөньякүләмендә билгеле булган каһарманнар арасында Дан орденнарының тулы кавалеры исеменә лаек булган 48 татарстанлының берсе - Ибраһимов Гариф Ибраһим улы- Каенлыда, нәкъ менә Татарстан урамында туып үскән.

Гариф абый Кызыл Армия сафларына алынып ике айдан соң Бөек Ватан сугышы башлана. Авылдашыбыз ил өстенә ябырылган афәтнең беренче көннәреннән Җиңү таңына хәтле зур батырлыклар күрсәтә. Румыния җирләрендә фашистларга каршы һөҗүмнәрдә Гариф Ибраһимов иң оста мәргән-снайпер булып таныла.1944нче елның маенда III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Шул ук елның август аенда Яссы шәһәрен азат иткәндәге батырлыгы өчен II дәрәҗәле Дан орденына тәкъдим ителә. Кыю солдат Г. Ибраһимовның күкрәгенә чираттагы I дәрәҗәле Дан ордены 1945 нче елның июнендә Германиянең үз җирендәге каты сугышлардан соң тагыла.

Сугыштан соң Гариф абый Украинага хәрби хезмәтен дәвам итү өчен җибәрелә һәм шунда яшәп кала, тормыш кора, пенсия яшенә кадәр хәрби заводта эшли. Герой якташыбыз туган ягына кунакка кайтканда мәктәп укучылары белән очрашуларда катнашты. Авыл мәктәбендә Гариф Ибраһимовка багышланган Дан почмагы бар, ә туып - үскән нигезендә истәлек тактасы эленгән. Каһарман якташыбыз турында Киевта дөнья күргән Б. Дубровның “Солдатская слава”, Мәскәүдә бастырылган “Кавалеры ордена Славы трех степеней”, Казанда әзерләнгән “Дан орденының тулы кавалерлары”, энциклопедияләрдә, М. Мингазовның “Солдат даны” китапларында кызыклы мәгълүматлар бирелгән. Авылдашларыбыз арасында шундый мәртәбәле бүләк иясе булуы күңелдә хаклы рәвештә зур шатлык хисләре уята![ 3 ]

Гомәров Габдрахман Гомәр улы 1924 елда Каенлы авылында туа, шунда үсә. 1942 елның мартында 18 яшендә сугышка алына. Новосибирск тирәсендә өйрәнүләрдән соң аларны фронтка озаталар. Фронтта комсомолга керә. Төньяк-көнбатыш фронтта сугыша, Белоруссия, Латвия, Литва, Көнбатыш Пруссияне дошманнан азат итүдә катнаша. Сугыш вакытында күрсәткән батырлыклары өчен күп кенә бүләкләр ала: II дәрәҗә Ватан сугышы

ордены, III дәрәҗә Дан ордены,I дәрәҗә Дан ордены; медальләр: “За боевые заслуги”,“За взятие Кенигсберга”,“За победу над Германией”.

1947 елның мартына кадәр хәрби хезмәттә була. Аннан кайткач: 1949 елдан авыл советы секретаре, 1953 елдан авыл советы председателе. 1957 елдан лаеклы ялга чыкканчы эчке эшләр органнарында участок инспекторы булып эшли.

Сугыш һәм мәгариф ветераны, матбугат активисты, авыл тарихы елъязмачысы Шәрәфиев Фәхри Шәйхи улы да Татарстан урамда 1907нче елда туып, шунда үсә, гомер кичерә. Тормыш иптәше Мәүлиха белән өч кыз, бер ул үстерәләр. Яшьтән авыл тормышында актив катнаша. Каенлының беренче комсомолы була. 1926нчы елда Алабуга педагогия техникумына укырга керә. Аны тәмамлагач, Каенлыга кайта. Урта педагогик белем алып гомере буе (41 ел педагогик стажы) авыл балаларына физика, математика фәннәреннән белем бирә. Берничә ел мәктәп директоры булып эшли. Бөек Ватан сугышы башланганда урта мәктәптә директор булып эшләгән чагы була. 1942нче елның мартында сугышка алына. 3 ел да 8 ай сугышта булып, ике тапкыр каты яраланып, 1945нче елның ноябрь башында авылга әйләнеп кайта һәм яңадан 1953нче елга кадәр мәктәп директоры вазыйфасын башкара башлый. Фәхри абый – яңалыклардан хәбәрдар. Кирәк тапканнарын көндәлегенә язып бара. Хәтере яхшы. Янәшә-тирәдә дә бердәнбер фотограф ул булгандыр. Беренчеләрдән велосипедны да ул ала, беренче радио тыңлаучы да авылда ул була. Авыл тарихыннан бай материал туплый. Вафатыннан соң кызлары кулъязмаларны “ Каенлы авылы тарихы” исемле китап чыгарды. 1996 елда 89 нчы яшендә вафат була.[3]

Ульданов Камил Әхмәтгәрәй улы Каенлы авыл җирлегендә исән булган бердәнбер сугыш ветераны да шушы Татарстан урамында яшәде.

Камил абый Каенлы авылында Әхмәтгәрәй белән Зөләйха гаиләсендә туа, җиде класс тәмамлый. Алга таба да укыган булыр иде, Кызыл Чапчак урта мәктәбенә барып та карый, тик сугыш башланып укуын ташларга туры килә аңа. Камил абый сугышка 1943 нче елны 17 яшендә алына. Ерак Көнчыгышта, Славянка гарнизонында хезмәт итә ул. Артиллериядә разведчик, орудие командиры була. Күкрәген Ватан сугышы ордены, “Японияне җиңгән өчен”, “Кореяне азат иткән өчен” һәм башка бик күп медальләр бизи. Туган авылына ул 1950 нче елда гына әйләнеп кайта. Казанда киномеханик белгечлегенә укып кайтып беркадәр унберләп авылга кино хезмәте күрсәтә. Соңрак тракторда, комбайнда эшли. Соңгы елларын кочегар булып эшләп лаеклы ялга чыга.

Камил абый күргәннәрен хәтер төпкелендә сакласа да, алар турында искә төшерергә яратмады. Камил Ульданов 2022 елда 96 яшендә вафат булды.

### 2.Сугыш балалары - тарих яралары

Татарстан урамында яшәп ятучы тыл ветераннары белән дә таныштырып китәм.

Ульданов Сәүбән абыйның кызы Асия 1927нче елның 9 нчы апрелендә дөньяга килә. Каенлы җидееллык мәктәбен тәмамлагач, Чистай медицина техникумын тәмамлый. Укып бетергәч, Ташлык, Түбән Чаллы, Кызыл Чапчак авылларында берничә ел авыл фельдшер-акушерка булып эшли. Аннан соң туган авылына кайтып, 40 елдан артык Каенлы һәм Кече Җирекле авыллары халкына медицина хезмәте күрсәтә. Тыл һәм хезмәт ветераны орден-медальләр алмаса да, авылның иң хөрмәтле ак әбисе. Нинди авыр елларда эшләгән ул. Карлы-буранда, яңгырлы көннәрдә сазга батып, көн дими, төн дими авырулар янына ашыккан. Ат арбаларында, трактор чаналарында авыруларны Ширәмәт больницасына илткән. Күпме балаларга дөньяга килергә булышкан ул, “кендек әбисе” булган. 44 ел эш стажы булган Асия апага авыл халкы бүген дә рәхмәт укый. 96 яшьлек Асия апа Ульданова исән-сау, кызының кадер-хөрмәтендә туган йортында яшәп ята.

Сөләйманова Саимә Сабир кызы Каенлы авылында 1931нче елда колхозчы гаиләсендә туа. Саимә апа туган авылында җидееллык мәктәпне, Кызыл Чапчакта урта мәктәптә укый. 1950нче елда Алабуга дәүләт укытучылар институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Укуны тәмамлагач, Яңа Чишмә районында, Шәңгәлче, Колмакчы һәм 43 ел Каенлы мәктәбендә балаларда туган телгә мәхәббәт уята. Саимә апа үзен борчыган сорауларга җавап итеп шигырьләр яза, авыл тарихын барлый, дин тарихыны белән кызыксына, мәктәп укучылары белән очрашуларга йөри. Балалары, Саимә апаның күңелендә йөрткән шигырьләрен туплап, “Әй, Каенлым, Каенлым”, “Зәй сулары ага тора” исемле ике китап чыгардылар.

Хезмәт һәм тыл ветераны бүгенге көндә Каенлыда яшәвен дәвам итә.

## ЙОМГАКЛАУ

Туган ягым татар халының күренекле шәхесләрен онытмый, якташларны һәрвакыт зурлый һәм истә тота. Туган нигез, гаилә һәм төбәк тарихын өйрәнеп, андагы горурланырлык вакыйгаларны,авылыбызны үстерүгә өлешләрен керткән Татарстан урамында туып үскән күренекле шәхесләр тарихын җентекләп тикшереп кенә үзеңдә патриотик гражданлык хисе тәрбияләргә мөмкин дип уйлыйм. Киләчәктә дә мин бу тикшерү-эзләнү эшен дәвам итәргә уйлыйм, тагын да тулыландыра алырмын дип ышанып калам. Эзләнү эшенең нәтиҗәсе белән иптәшләремне таныштырырмын; укучыларны, укытучыларны һәм әти-әниләрне патриотик традицияләрне дәвам итәргә өндәрмен. Халкыбызның батырлыгы мәңгелек!

## КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЧЫГАНАКЛАР

1.Сөләйманова С.С. “Әй, Каенлым, Каенлым.” – Казан: Милли китап, 2009.

2. Сөләйманова С.С. “Зәй сулары ага тора” – Түбән Кама: “Гүзәл”тип., 2013, 132б

3. Шәрәфиев Ф.Ш. “Каенлы авылы тарихы” – Казан: “Сүз”нәшрияты, 2009,153б

*Мусина Камилә, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Нәби Дәүли исемендәге Базарлы Матак гимназиясе МБГББУ дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкче: Сафина Лилия Гавас кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Эчтәлек

I. Кереш
II. Үргәагарым –газиз туган җирем
1. Үргәагар авылының килеп чыгышы һәм тарихы
2. Авылымда дин һәм мәгърифәт
3. Бөек Ватан сугышы авылым тарихында
4. Тикшеренү эшләре кысаларында башкарылган эшләр
III. Йомгаклау
IV. Кулланылган әдәбият

Кереш

Һәр кешенең өзелеп сөйгән туган ягы бар. Минем туган ягым - Татарстан Республикасының Әлки районы Үргәагар авылы. Авылым Актай һәм Кече Чирмешән елгаларының субүләренә,урман-дала зонасына урнашкан. Ул табигатьнең бик матур почмагында урнашкан.

Үргәагарымның борынгыдан килгән тарихы, йөз елдан артык эшләп килгән, үзгәреш чорларында да сакланып калган, эшчәнлеген туктатмаган, биек манаралы , милләтебез төсенә –яшелгә буялган агач мәчете, эш сөючән халкы бар. Кызганычка каршы, авылыбызда яшәүчеләр елдан –ел кими, Үргәагарарымда бушап калган өйләр саны да арта бара.

Мин авылым тарихын, аның топонимнарын тирәнрәк өйрәнергә булдым, чөнки ул кыйммәтле материал булыр һәм киләчәк буыннарга да тапшырылыр дип уйлыйм. Һәркем үзенең туган җиренең тарихын белергә тиеш дип саныйм.

Фәнни-тикшеренү эшемнең максаты:

-Үргәагар авылының тарихын, топонимнарын өйрәнү.

Максатымнан чыгып, бурычлар билгеләдем:

- төрле чыганаклардан материал туплап,Үргәагар авылының тарихы белән танышу;

- авылымның бүгенге тормышын , табигатен күзәтү,күзәтүләремне чагылдырган фото һәм видеоматериаллар туплау;
- авылдашларым белән очрашып, алардан үземне кызыксындырган сорауларга җавап алу;
- тупланган барлык материалны системалаштыру.

Тикшеренү объекты:

Татарстан Республикасы Әлки районы Үргәагар авылы, ягъни аның географик урыны, топонимнары, кешеләре, анда эшләп килүче төрле структуралар.

**ТӨП ӨЛЕШ**

## 1. Үргәагар авылының килеп чыгышы һәм тарихы

Үргәгар авылы Актай һәм Кече Чирмешән елгаларының субүләренә, урман-дала зонасына урнашкан. Авылдан көньякта "Зур урман", "Умарталык", "Кырык чат", урманнары ямьләнеп тора. Аны шулай ук көнчыгыштан "Зариф", "Албут" урманнары, төньяктан "Актай", ә көнбатыштан "Кечкенә урман" уратып алган .

Үргәгар уңдырышлы кара туфракка ия булган кырлар, болыннар һәм балкаларга бай.Авыл табигатендә антропогенлыктан битәр,чын табигыйлык өстенлек алып тора.

Бүгенге көндә Яңа Үргәгарның элеккеге урынында борынгы зират тора. Хәзерге авылдан төньякта иске авыл урыны һәм аның зираты бар. Аны Иске авыл дип йөртәләр. Шуны әйтеп үтәргә кирәк: Үргәгар борынгы Биләр-Болгар юлы өстендә.

Авылның "Үргәгар" дигән исеменә карата төрле риваятьләр бар. Шуларның берсенә тукталып үтәм.Озак кына гомер кичергән карт белән карчык бервакыт инеш буена төшкәннәр, имеш. Сүз ара сүз китеп, болар бәхәскә кергәннәр, ди. Бәхәс тә юк-бар сәбәптән чыга:элеге инеш үргә агамы, әллә түбәнгәме. Карт әйтүенчә – түбәнгә, карчык әйтүенчә – үргә таба ага. Бәхәс барышында карчык ничектер инешкә егылып төшә һәм агым аның гәүдәсен агызып китә. Әлеге фаҗига нәтиҗәсендә авылга Үргәгар исеме бирелгән имеш.

Авыл атамасының килеп чыгышы турында фәнни мәгълүматлар юк. Әлеге атама бәлки Үрге (югары) һәм Әгер (авыл) сүзләреннән килеп чыккандыр.

Үргәгар авылының ике өлеше ике исем йөртә: көньяктарак урнашканына – Иске Үргәгар, ә төньяк юнәлештәге өлешенә – Яңа Үргәгар диләр.

Иске Үргәгар авылы төзелү, ягъни беренче гаиләләр килеп урнашу вакыты XVIII гасыр урталары була. Яңа Үргәгар авылы төзелә башлау вакыты 1814нче еллар дип фикер йөртелә (Мәктәп укучыларының 1967 нче елда язылган "Авыл тарихы" дигән

альбомда шулай диелгән). Ләкин әлеге фактларны дәлилләүче бернинди дә дәлил табылмады.

Галим Марсель Әхмәтҗанов  сүзләренә караганда, Иске Үргәгардагы беренче гаиләләр XVII гасырда ук Рязань өлкәсеннең Питрәскә дигән мишәр авылыннан килгәннәр. Кызгнычка каршы, әлеге фактны да раслаучы дәлил-мәгълүматлар әлегә юк.

Яңа Үргәгарның элеккеге кешеләре хәзерге урыныннан 4 километр төньякта Яңа Чаллы авылы кешеләре белән ике арадагы елга буенда яшәгәннәр. Елганың икенче ягында бераз көнчыгыштарак керәшен авылы булган (бу авыл борынгыдан таралган һәм исеме дә билгесез). Бу  ике авыл халкы үзара тынышмыйча, юк-бар сәбәпләрдән тавыш чыгарып, ызгышып яшәгәннәр. Кешеләр үлеме, терлекләр кырылуы һәм йортлар яну белән барган бу ызгышларны юк-бар сәбәпләрдән чыккан диеп булмый. Төп сәбәп булып сөрү җирләре, көтү җирләрен бүлешә алмау торган.

Нәтиҗәдә, хәзерге Яңа Үргәгар авылы халкы ул урыннан күчеп китәргә була. Күчү мәсьәләсен хәл итү өчен Иске Үргәгарлылардан рөхсәт алганнар.

Яңа урында куе урман булган. Менә шул урман эченә Бәшир исемле кеше беренче булып күчеп килгән.Бәшир турында бернинди дә мәгълъмат юк. Шулай да әлеге кеше князь Мостафиннар нәселеннән булуы ихтимал[1]. Ә инде әлеге князь Мостафиннар нәселе XVII гасырда Яңа Чаллы авылының беренче гаиләләре  булуына дәлил мәгълүматлар билгеле[2].

Шулай Бәшир бер ялгызы гына яңа урында кыш чыга, ә икенче елны башка кешеләр дә кешеләр дә күчеп килгәннәр. Алар урманны чистартып, көнбатыштан көнчыгышка таба өйләр төзегәннәр. Күченеп килгән авыл Яңа Үргәгар диелгән.

Татарстан Республикасының торак пунктлары турында чыгарылган белешмәдә Иске Үргәгарга XVIII гасырда, Яңа Үргәгарга XVIII гасыр уртасында нигез салынганлыгы әйтелә[3]. Әлеге  мәгълүматларның кайдан алынганлыгы билгесез.

Авылның шул вакытларда барлыкка килүенә бәлки ышаныргадыр да.

Ләкин, нишләптер авыл тарихы турындагы чыганаклар XIX гасырдан башлана. Кызганычка каршы, XVII-XVIII гасырларда Үргәгар авылы тормышын тасвирлаучы бернинди чыганаклар да, дәлил-мәгълүматлар да юк. Шуңа күрә әлеге эш тә авылның тарихы XIX гасыр вакыйгаларын тасвирлау белән башлана.

Революциягә кадәр Яңа һәм Иске Үргәгар авыллары Казан губерниясының Спас уезды Мораса волостена кергәннәр.Спас өязе 1,2 нче станнардан торган.Үргәгар авыллары 2 нче станның составында булганнар. Өяздә бердәнбер Спас шәһәре булган. Станның үзәге Базарлы Матакта урнашкан[4].

Бүгенге көндәге кебек үк, авыл халкы тулаем татарлардан торган.Авыл үзе Спас шәһәреннән 45 чакрым, ә Базарлы Матак 5 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бу чорга караган авыл крестьяннарының шөгыльләре турында берничә сүз. Промысел белән шөгыльләнүче саны алай бик күп булмаган.
Иске Үргәгар авылында өч мич салучы булган. Миччеләр күп вакыт җәй көне кыр эшләреннән бушаган арада күрше-тирә авылларга йөргәннәр.

Яңа Үргәгарда ике балта остасы булганлыгы билгеле. Балта эше белән һәр крестьян да шөгыльләнә алган бит. Алар өй тирәсендәге эшләрдә халыкка эшләп бераз гына булса да акча эшли алганнар. Әлеге акча әлбәттә өстәмә доход буларак, игенчелек белән шөгыльләнүдән бушаган арада эшләгән өчен түләгән.

Тагын бер шөгыль: баш киеме тегү. Үргәгар авылында бер генә ир-ат үз өендә баш киеме теккән. Шулай ук, Яңа Үргәгар авылында фосфор шырпылары ясаганнар. Моңа фосфорның һәм агач материалларның каян алынганлыгы билгесез. Эшкә үсмерләр һәм олы кешеләр ялланганнар. Аз санда булса да, хатын-кызлар катнашканнар. Эшчеләр составында хуҗаның гаиләсеннән дә ике ир-ат булган. Ләкин шырпыларның сыйфатлары бик түбән булган. Шулай да, җитештерелгән шырпылар базарларда һәм ярминкәләрдә сатылганнар. 1000 шырпы өчен бердән алып ике ярым тиен түләгәннәр. Предприятенең хуҗасы Зәйдеханов бер елга 100 сум керем алган.

Шулай итеп, губерниядә капитализм үскән саен, авылларда да промышленность барлыкка килә.

Россиядә капиталистик тәртипләр урнаша барган саен, татар дөньясында да әкренләп уяну, җанлану процессы көчәя. Шул ук вакытта сыйнфый мөнәсәбәтләр дә кискенләшә бара. Реформадан соңгы 40 ел эчендә Казан губернасында крестьяннарның 250дән артык чыгышы булган. 1878 – 79 еллрда Спас, Чистай, Казан, Тәтеш, Мамадыш өязләрендәге татар крестьяннарының чуалышлары бөтен Россия күләмендә зур вакыйгалардан саналган. Крестьяннар нидән канәгать булмаганнар, кемгә каршы һәм нәрсә өчен көрәшкәннәр икән соң?

Әйтеп үтелгән аяныч вакыйгаларга кадәр чукындырылган татар крестьяннары күпләп үзләренең диннәренә кайта башлыйлар; 1878 елгы ачлык; 1877 – 1878

еллардагы рус-төрек сугышының нәтиҗәләре; милли изүнең көчәюе – болар барысы да татар крестьяннарының тормышын түзә алмаслык дәрәҗәгә китергәннәр. Халыкның нәфрәтен шартлатырга бер генә очкын кирәк була.

Ә инде XIX гасырның 70 елларында булып узган крестьян чыгышларына төп сәбәп булып 1878 елда Казан губернасына рус чиновниклары төзеп җибәргән “Авыл халкы үтәргә тиешле йөкләмәләр” исемле бер эш кәгазе (инструкция) тора. Бу күрсәтмәдә авыл халкы хисабына янгын куркынычсызлыгын көчәйтү буенча кайбер чаралар каралган була. Мәсәлән, авыл капкалары янына багана утыртып, аңа беркетелгән тактага авылның русча исемен, хуҗалыклар санын, күпме халык яшәвен язып кую, ә авыл уртасындагы колгага янгын чыга калганда кешеләр чакыру чаң урнаштыру таләп ителә. Халык исә моны, руслар безне тагын чукындырырга җыеналар икән,дип аңлый. Шуның өстенә әлеге инструкция губерниянең руслар яшәгән авыллар өчен төзелгән һәм татар крестьяннарының милли, дини үзенчәлекләре истә тотмаган.

Шулай итеп, яңа инструкция рус патшаларының электәге төрле мәрхәмәтсезлекләрен, мәчет-мәдрәсәләрне җимертүләрен, көчләп чукындыруларын яңадан искә төшергән, халык күңеленә шом салган. Әлеге сәясәтне тормышка ашыру барышында финанслау да татар халкының җилкәсенә салына. Инструкция авыл хуҗалыгы эшләре тәмамлангач, көз көне тәкъдир ителергә тиеш булса да, аның турындагы хәбәрләр халыкка ел башында ук тарала.

Крестьян фетнәләре 1878нче елның көзендә Спас өязенең татар авылларында башланып китә. Крестьяннар яңа инструкцияне үтәүдән бөтенләй баш тартканнар, ә Мораса волосте Иске Үргәгар авылындагылар стан приставына һәм олыс старосталарына янаганнар. Инструкциягә килгәндә, ул авыл халкының ачуын чыгарган. Авыл җәмгыяте үзләренең арасыннан ике кешене сайлап, 200 сум акча җыялар һәм үтенеч белән Петербургка җибәрәләр, ләкин җибәрелгәннәр бернигә дә ирешмичә кире кайтып җитәләр. Ә инде “өстәгеләр” инструкцияне үтәүне таләп итәләр. Шул вакытта крестьяннар күрсәтмәләрне үтәүдән бөтенләй дә баш тарталар.

Кулга алулар башлана, кайбер крестьяннар авылдан качырга мәҗбүр булганнар. Чуалышлар һаман да дәвам итәләр. Крестьяннар үз каралты-куралары страховать итүдән баш тарталар, агачлар утыртмыйлар, янгын сарайларына түләүдән баш тарталар. Авыл старостасының хәтта мөһерләрен дә тартып алалар. Шул вакытта полиция органнары крестьяннарны янаулар һәм кыйнаулар белән буйсындырырга уйлыйлар. Иске Үргәгардан Рамазан станына чакырылган ике крестьянны үтергәнче кыйныйлар, ә бу исә халыкның ачуын тагын да чыгара. Иске Үргәгар авылының

халкына полиция десятнигы Абдулла Насыровның тәэсире зур булган. Ул муллага исправникка баруны авыл җыены исеменнән кул куеп йөрүне катгый рәвештә тыйган.

1878нче елның октябреннән Яңа Үргәгарның крестьяннары яңа инструкция турындагы хәбәрне ишетүгә, үзләре арасыннан Сәлахетдин Фәхретдинов исемле кешене сайлыйлар, 90 сум акча җыялар һәм үтенеч белән аны да Петербургка җибәрәләр. Өч атнадан бернигә дә ирешмичә әйләнеп кайтуга, ул авыл җыенын олыс идарәсенә каршы котырта башлый. Шул ук вакытта аның туганы Ногман Фәхретдинов һәм крестьян Мохтар Багиров күрше авылларының халкын үзләре белән чыгыш ясарга өндәп йөргәннәр.

Крестьяннар волость һәм өяз чиновникларына гына түгел,хәтта губернаторга да буйсынырга теләмәүләрен белдергәннәр.

1878 елның 4 ноябрендә Казан губернаторы Н.Я.Скарятинның эчке эшләр министры А.Е.Тимашевка язган донесениесендә Иске һәм Яңа Үргәгар авыллары да телгә алына[5]. Әлеге документта да крестьян чыгышларының барышы ачык сурәтләнә.

1879 нчы елның февралендә Яңа Үргәгарда булып үткән тагын бер вакыйганы әйтеп үтәргә кирәк. Авыл җыенына полиция десятнигы һәм янгын старосталарын сайларга тәкъдим итәләр, ләкин крестьяннар моны эшләүдән баш тарталар. Шуның өстенә,авыл җыены, полиция приставын авылдан куарга ирешәләр. Монда инде крестьяннар моны эшләүдән баш тарталар. Шуның өстенә, авыл җыены полиция приставын авылдан куарга ирешәләр. Монда инде крестьяннарның көрәшләре бердәм рәвештә булган.Яңа Үргагар авыл җәмгыяте түбәндәге карарга киләләр:

1. Үзләре арасыннан беркемне дә бирмәскә;
2. Сорау алуга бармаска;
3. Җирләрнең бер өлешен сатырга;
4. Судка эләккән крестьяннарны яклаучыны шул җир саткан акчага ялларга.

Үргагар авылларында барган эре чуалыш-чыгышларны үзенең монографиясендә Ю.И.Смыков ачык сурәтли һәм вакыйгаларга анализ ясый.

Ул авылларда барган вакыйгаларның һәркайсын аерым алып сүрәтли.

Әлеге периодта булып узган көрәштә күбрәк үзаңның һәм бердәмлекнең көчәюе сизелә.Әгәр 1878нче елның татар крестьяннары тарафыннан узган хәрәкәтләрдә дини төсмер чагылса,1879нчы елгы чыгышларда социаль максатлар күздә тотыла.Татар крестьяннарының 1878-1879 еллардагы баш күтәрүе – милли азатлык хәрәкәтендә бер вакыйга.

## 2. Авылымда дин һәм мәгърифәт

Халыкның үсешендә, бердәмлегендә, чыдамлыгында, рухи тормышында, әлбәттә, диннең әһәмияте һичшиксез зур.

Үргәгар авылының халкына,татар халкына хас булганча, бердәм булырга өндәүче һәм рухи дөньяны баетучы диннең йогынтысы булган. Моңа мәхәлләсе инде XIX гасырда ук барлыкка килгән мәчет ярдәм иткән.

Беренче мәчет Иске Үргәгар авылында салына. 1833нче елның 4 нче декабреннән мәчетнең имам-хатибы булып Фәхретдин Галләмшин торган. Революциягә кадәр шулай ук Мортаза Сәгетдинов, аннары Ризаэтдин Мозаффаров авыл имамнары булып билгенәләр.

1905 нче елның 13 июнендә Иске Үргәгар авыл җәмгыятеннән сайланган крестьян Гадиулла Сафин һәм мулла Хабибрахман Сиразетдинов авылда икенче мәчетне төзү өчен Казанга барып халыктан акча җыярга рөхсәт алалар. Ләкин губерния хакимияте генә моңа зур игътибар бирми.

Мәчетне төзергә рөхсәт 1905 елның 19 июлендә бирелә. Әлеге мәчет ул вакытта Спас өязендә икенче була.

Манара башындагы аеннан һәм калай түбәсеннән кала, бөтен җире милләтебезнең яшел төсенә буялган әлеге мәчет Абдулла Мансуров исемле кешенең проекты буенча халык акчасына салына (проект авторы турында мәгълүматлар юк).

Совет власте елларында республикабызда нибары 17 мәчет калган булган. Спас, Әлки, Алексеевск районнарының өчесенә бер мәчет сакланып кала. Ул да булса Әлки районының Үргәгар авылы мәчете. Әлеге мәчет авылның үзенә күрә бер символы булып тора. Әлбәттә, ирек заманына җиткәнче аңаниләр генә күрергә туры килми.

Ә бит Совет чорына кергәндә авылда барлыгы өч мәчет булган. Аларның беренчесе – алда искә алынган Иске Үргәгар авылы мәчете, ә искесе Яңа Үргәгар авылында 1916нчы һәм 1924нче елларда төзелгәннәр.Әлеге күренеш Үргәгарның Әлки районы авыллары арасында үзенчәлеген күрсәтеп тора.Чөнки бер авылда өч мәчет булу ул вакытларда бик сирәк очраган. Тагын бер фактка игътибар бирергә кирәк: өченче мәчет 1924 нче елда салына. Ә бит Совет власте урнашканнан соң 7 еллап вакыт үткән була. Моннан нәтиҗә: димәк, авылның рухи тормышы ул вакытта бик нык һәм югары дәрәҗәдә була.Ләкин коллективизация елларында дин йортларын ээәрлекләү һәм юк итү башлана. 1916 һәм 1924 нче елларда төзелгән мәчетләрнең манараларын кисеп ашлык саклау өчен кулланалар. Соңрак сүтеп мәктәп бинасын зурайтып салалар.

Яңа Үргәгар мәчетләре сүтелгәч, халык айнygандай була. Ил күләмендә булса да бу эшнең законнан тыш икәнлеген аңлыйлар. 1952 нче елда укымышлы кешеләр

җыелышып, ничек булса да 1905 нче елгы Иске Үргәгар мәчетен коткарып калырга карар кылалар. Җыелышта шушы елларда муллалык итүче Бикмулла бабай, ике кулын күтәреп, “Мәчет без –картларныкы, безгә калсын”, – дигән сүзләр белән чыгыш ясый. Җыелышка Казаннан бер вәкил (исем-фамилиясе мәгълүм түгел) килгән була. Ул: “Картлар, җыелып исемлегезне төзегез һәм бер кешегезне Казанга җибәрегез. Анда ни дисәләр, шул булыр,” – диеп кайтып китә. Укымышлы кешеләр Һави улы Габдулланны сайлыйлар. Габдулла үз дигәненә ирешә, Казанга барып,мәчетне калдырырга рөхсәт алып кайта. Шуннан соң әлеге мәчет нинди генә заманнарда да тукталмыйча эшләп килә. Сагызы агызылмаган нарат бүрәнәләрдән буралган ике катлы мәчет халыкка 100 елдан артык хезмәт итүенә карамастан, тышкы якта бүген дә бик нык, төзек күренә. Ләкин ирек заманына җиткәнче аңаниләр генә күрергә туры килми.

Властьлар Үргәгар авылы мәчетен берничә тапкыр ябып карыйлар. Урта бүлмәсен ашлык саклау урынына әйләндерәләр. Ләкин авылның аксакаллары, тәрәзәне ишеккә әверелдереп булса да, бер көнне дә калдырмый мәчеткә намаз укырга килүләрен дәвам итәләр.1937 елда Үргәгар мулласы Бикмулла хәзрәтне нардомга (бүгенге авыл советы) чакырып, сорау алалар, корал эзләгән булып, өйләренең астын-өскә китереп тентү оештыралар. Мәчетнең халык акчасына төзелгән булуына шәһадәтнамә һәм мәчеткә кагылышлы башка язулар тентүчеләр кулына эләкмичә, Коръән-кәрим эчендә хәвеф-хәтәрсез сакланып кала. Бикмулла хәзрәт “Халык дошманы” булып 1943 нче елгача төрмәдә тотыла. Аннан котылып кайткач, авылдашлары үтенеченә ризалашып, муллалыгын дәвам итә.

Әйе, мәчет исән кала. Тагын бер нәтиҗә: димәк, тирә-күршедәге бик күп башка татар авылларына караганда Үргәгарда яшәүче мөэмин-мөселманнар мәчетләрен саклап, тагын да зуррак үҗәтлек күрсәткәннәр.

Мәчеткә 2005 нче елның 18 июлендә 100 яшь тулган. Анда бер гасырдан артык бер дә тукталмыйча намаз укылган һәм укылып килә, Рамазан айларында һәр көнне бабайлар тәравих укыйлар, гает бәйрәмнәрендә авылда яшәүче яисә авылдан читтә яшәүче бабайлар, барлык ир-атлар иртәнге намазга киләләр, һәр көнне манарасыннан бишәр тапкыр азан яңгырый.

Әлки төбәгендә ярты гасырдан артык берүзе моңаеп утырган Үргәгар мәчете хәзер ялгыз түгел инде. Аны тирә-ягындагы татар авылларының һәрберсендә соңгы елларда төзелгән мәчетләр (район үзәгендә – өчәү) үз уртасына алып саклап торалар кебек.

Алда язып үтелгәннәрдән күренгәнчә, авыл үзенең төрле үзенчәлекләре башка авыллардан аерылып торган. Авылда дин, аерып әйткәндә, мәчетләр ярдәмендә рухи дөньяны үстерү белән беррәттән белем бирүгә дә зур игътибар бирелә.

Авылның белем бирү өлкәсендә елдан-ел үзгәрешләр була.

Революциягә кадәр Иске Үргәгарда (1906) һәм Яңа Үргәгарда (1916) мәчетләр каршында инде ике мәдрәсә булган. Анда төрле елларда төрлечә 70-тән 80-гә кадәр бала сабак алганнар. Беренче мәдрәсәдә белемне Әсәдулла шәкерт, Гобәйдуллин Сибгәтулла, Хәлиулла, Хабибуллин Шәһидуллалар, ә икенче мәдрәсәдә Исмагилов Гариф, Гобәйдуллин Гайнуллалар бирәләр.

Авыл мәдрәсәләрендә ир балалар укыганнар, ә кыз балалар абыстайга йөреп сабак алганнар. Мәдрәсәләр генә түгел, хәтта абыстайлар да балаларга дини белемнәр генә түгел, ә дөньяви белемнәр дә өйрәткәннәр.

1919 елларда җәдит укуы булган. Бу уку Иске Үргәгарда Садыйк Сафасы исемле кешенең өендә алып барылган. Анда Низамова Мәбсүсә әби укыткан. Ул авылда сабак алганнан соң 1908 елдан Чистай, Казан, Ижбуби мәдрәсәләрендә, Уфада укып беренче разрядлы укытучы исемен алып чыга, төрле җирләрдә укытып йөри. Аның истәлекләренә караганда, ул Габдулла Тукай белән бергә мәдрәсәдә укыган.

1920 –1925 елларда авылга “Йолдыз” исемле бер газета килә. Атнаның бер көнендә шул газетаны мәктәптә кычкырып укыганнар.

1919 елның ахырында “РСФСР халкы арасында наданлыкны бетерү турында” махсус карар кабул ителә. Әлеге карардан соң олы яшьтәге кешеләрне укырга-язарга өйрәтә башлыйлар һәм аларга “грамоталы” дигән язу бирәләр. Бу эшне Үргәгар авылында активлар, комсомоллар һәм укытучылар оештырганнар. Укыту иртәнге җидедән унга кадәр барган.

Үргәгар мәктәбенең элеккеге бинасы 1929 елда салына башлаган. Ул вакытта әле башлангыч мәктәп кенә була.

Башлангыч мәктәпне тәмамлаган укучылар Алпар мәктәбенә укырга киткәннәр. 1935 елдан башлап балалар Яңа Чаллы тулы булмаган урта мәктәбенә дә бара башлаганнар. Ул елларда Үргәгарда мәктәп мөдире Югары Әлки авылыннан Хафиз исемле кеше булган. Кызганыч, әлеге кешенең фамилиясе билгесез. 1932 – 1938 елларда мәктәп мөдире булып Абдул Салманы авылыннан Хәсәнов Салих эшләгән (милләтчелек вакытында кулга алынган).

Утызынчы еллар уртасында илдә җиде еллык гомуми мәҗбүри белем бирү бурычы куела.

1939 – 1940 елларда Үргәгарда җидееллык мәктәп ачыла. Мәктәпнең беренче директоры Көек авылыннан Нотфуллин Харис була, ул сугышка киткәч – Кузнецов. Әлеге кеше турында мәгълүматлар эзләү нәтиҗәсе уңышсыз тәмамланды. 1942 – 1946 елларда мәктәп мөдире Гыйләҗева Зөләйха була. Сугыш елларында укыту бик кыен

була. Язарга кәгазь, ягарга утын булмый. Укытучыларга авыл халкы арасында да бик күп эшләргә туры килә. Мәктәп биналары салкын, уку-язуга әсбәпларны әйтеп торасы да юк. Халык – фәкыйрь, җәйдән – кышка, кыштан – җәйгә киемне алыштырырга да мөмкинлек юк вакыт.

Шул елларда укытучылар агитаторларга әйләнәләр. Һәрбер укытучыга берәр бригада бүлеп бирәләр. Шулай ук укытучыларга урак урырга, амбарга йөрергә туры килә. Шулай итеп, Бөек Җиңүне яулауда укытучылар зур өлеш кертә. Сугыштан соң 1946 елның декабреннән 1950 елның язына кадәр директор булып Арсланов Мөбәрәкша эшли.

1950 елның августында мәктәп директоры итеп Гатауллин Мәхмүт Хисмәт улы билгеләнә. Ул мәктәптә эшләү дәверендә зур эшләр башкара. Мәктәп бер-берсеннән ерак урнашкан өч бинадан торган була (1929 елда салынган мәктәп, Яңа Үргәгардагы ике мәчет). Шуңа күрә балаларны ике сменада укытырга туры килгән. Бу биналарны бер урынга җыеп урнаштыру кирәк булган. Яңа директор мәктәп биналарын бер урынга күчереп салу эшен башлый.

1951 елда Яңа Үргәгар мәдрәсәсен тулысынча күчереп интернат салалар. Шулай итеп, дәүләт ташламаларга бара. Әлеге бинада ике башлангыч класс укыган. 1955 елдан ул интернат булып эшли башлый. Монда Ташбилге һәм Биктимер авылларыннан килеп йөрүче укучылар торган. Бүгенге көнгә кадәр күрше авыл балалары торган әлеге интернат бинасында балалар бакчасы эшләп килде.

1952 – 1954 елларда мәктәпкә Яңа Үргәгарның ике мәчетеннән тагын ике бинаны ялгап салалар.

1961 – 1962 елларда мәктәп сигезъеллык дип атала башлый. 1965 – 1966 уку елында озайтылган көн группасы эшли башлый. Үргәгар мәктәбендә беренчеләрдән булып кабинет системасы кертелә һәм укыту-тәрбия эшләрен нәтиҗәле башкару өчен кабинетларны җиһазлау эшләре башлана.

1983 – 1993 елларда мәктәп директоры Аглиуллина Саимә Фәсих кызы эшләгән. Күп еллар мәктәпнең укыту бүлеге мөдире булып эшләгән җитәкчегә яшь коллективны методик яктан чыныктыру максаты белән мәктәп реформасын тормышка ашыру, үзгәртеп корулар буенча күп эшләргә туры килә: лабораторияләр ясау, укыту-тәрбия эшен җитәкчелек һәм контрольлек итүдә Казан мәктәпләре тәҗрибәсе кертү, укучылар үзидарәсен “ДК” системасында оештыру, һ.б.

1987 елдан мәктәп тулы булмаган урта мәктәп дип йөртелә башлады һәм алты яшьлекләрне беренче класска кабул итү өчен шартлар тудыру өстендә эшләде.

1990 – 1991 уку елында мәктәп директоры Сафиуллин Әсхәт Самат улы билгеләнә. Шул елдан ук тулы булмаган урта мәктәптән урта мәктәп ясый яшь энергияле җитәкче. 2003 елның беренче сентябрендә авылның бизәге булып яңа мәктәп ачыла. 2013нче елда исә Үргәагар мәктәбе Нәби Дәүли исемендәге гимназиянең структур подразделениесе итеп калдырыла. Бүген мәктәптә бары тик башлангыч сыйныф укучылары гына белем ала.

### 3. Бөек Ватан сугышы авылым тарихында

Бөек Ватан сугышы авылым Үргәагарга да кагылмый узмаган. Яу кырларында авылымның 92 ир –егете башын салган. Мин аларның исемлеге белән танышып чыктым һәм үз эшемнең битләренә теркәп куйдым.

Сугышта һәлак булганнар исемлеге:

| № п\п | Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме |
|---|---|
| 1 | Абдрахманов Әхмәтгәрәй |
| 2 | Абдуллин Сәетгали |
| 3 | Әгълетдинов Борһан Әгълетдин улы |
| 4 | Әгълетдинов Кирам Әгълетдин улы |
| 5 | Әхмәтвәлиев Хафиз |
| 6 | Әхмәтов Солтан Әхмәт улы |
| 7 | Бәдретдинов Ислам Бәдретдин улы |
| 8 | Билалов Садретдин Билал улы |
| 9 | Вәлиев Зинәт Хәмәтгали улы |
| 10 | Вәлиев Нургали Хәмәтгали улы |
| 11 | Гибадуллин Галимулла Хәбибулла улы |
| 12 | Гайнуллин Миңнегали Шайдулла улы |
| 13 | Гайнетдинов Нургали Гыйлман улы |
| 14 | Галиев Әхсан |
| 15 | Галиев Салих |
| 16 | Галиев Сәлимҗан |
| 17 | Гараев Нәҗип |
| 18 | Гараев Сәмигулла |
| 19 | Гатауллин Сәмигулла Гайнулла улы |
| 20 | Гафиятуллин Хәйдәр Нургата улы |
| 21 | Гыйбатов Корбан |
| 22 | Гыйләҗев Нургаяз Гыйләҗ улы |

| | |
|---|---|
| 23 | Гыйматдинов Гарәф |
| 24 | Гөбәйдуллин Габдрахман Сәүбән улы |
| 25 | Җаббаров Минтаһир Җаббар улы |
| 26 | Закиров Әхтәм Заһит улы |
| 27 | Кәлимуллин Мәҗидулла |
| 28 | Мәрдегаләмов Мәгъдәм Мансур улы |
| 29 | Минһаҗев Галимулла Гәрәй улы |
| 30 | Мингалиев Нургали Миңгәрәй улы |
| 31 | Мингараев Нургали Миңгәрәй улы |
| 32 | Минсафин Касыйм Мостафа улы |
| 33 | Мөфтиев Марат Гарәф улы |
| 34 | Мифтахов Марат |
| 35 | Мусин Камил Әсәд улы |
| 36 | Мостафин Исмәгыйль Мостафа улы |
| 37 | Насыбуллин Галимулла Насыбулла улы |
| 38 | Насыбуллин Шамил Насибулла улы |
| 39 | Низамов Азат Шәйхетдин улы |
| 40 | Низамов Миңһаҗ Низаметдин улы |
| 41 | Низамов Нуртдин Шәйхетдин улы |
| 42 | Низамов  Таһир Сәлах улы |
| 43 | Нуртдинов Корбан |
| 44 | Рәхимҗанов Хәсән Рәхимҗан улы |
| 45 | Рәхматуллин Султан Рәхмәтулла улы |
| 46 | Рәхмәтуллин Шафигулла Рәхмәтулла улы |
| 47 | Садыйков Гайфулла Хәйрулла улы |
| 48 | Садыйков Ярулла Хәйрулла улы |
| 49 | Сәйфетдинов Галәлетдин Борһан улы |
| 50 | Сәйфетдинов Гарәф Гаяз улы |
| 51 | Сәйфетдинов  Нуриәхмәт Гайнетдин улы |
| 52 | Сәйфетдинов Нурмөхәммәд |
| 53 | Сәлахов Сахип Кашап улы |
| 54 | Сәлахов Таһир |
| 55 | Сафин Бадретдин |
| 56 | Сафин Гәрәй |

| | |
|---|---|
| 57 | Сафин Ибраһим Хәмәтсафа улы |
| 58 | Сибгатуллин Самат |
| 59 | Сибгатуллин Харис |
| 60 | Сөнгатуллин Галим Сөнгатулла улы |
| 61 | Сөнгатуллин Шафигулла |
| 62 | Туктамышев Әхәт Хәмәтгали улы |
| 63 | Төхвәтуллин Г.Х. |
| 64 | Фарукшин Кәлимулла Ф. |
| 65 | Фәйзуллин Галимулла М. |
| 66 | Фәйзуллин Кариб Гарифулла улы |
| 67 | Фәйзуллин  Фәсах Сәмигъ улы |
| 68 | Фәсахов Гарәфетдин Фәсах улы |
| 69 | Фәсахов Зыятдин Әгъләүтдин улы |
| 70 | Фәтхетдинов Шәрәфетдин Фәтхетдин улы |
| 71 | Хәбибуллин Сәмигулла Вазыйхулла улы |
| 72 | Хаҗипов Абдрахман Хаҗип улы |
| 73 | Хәйдәров Гата Хәйдәр улы |
| 74 | Халиков Нургали Нуртдин улы |
| 75 | Хафизов Мөхәммәт |
| 76 | Хафизов Харис Хафиз улы |
| 77 | Шәдиев Нуртдин Вәлиәхмәт улы |
| 78 | Шаһитов Галимҗан Шаһит улы |
| 79 | Шәйдуллин Идрис Шәйдулла улы |
| 80 | Шәйхетдинов Игълам Борһан улы |
| 81 | Шаммазов Әдһәм Галимҗан улы |
| 82 | Шәрәфетдинов Әсәд Шәйдулла улы |
| 83 | Шәрәфетдинов Харис З. |
| 84 | Шарипов Гасыйм Газзетдин улы |
| 85 | Шәрифуллин Шәрифулла |
| 86 | Шимбазов Әгдәм Галимҗан улы |
| 87 | Яруллин Мәҗидулла Кирам улы |
| 88 | Яруллин Мотыйгулла Әсәдулла улы |
| 89 | Хәретдинов Хәмзә Хәйретдин улы |
| 90 | Шәйдуллин Әхмәтгәрәй |

| | |
|---|---|
| 91 | Шәйдуллин Шәриф Шәйдулла улы |
| 92 | Мингалиев Харис |

Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исемен алган Исхаков Зиннәтулла Гыйниятулла улы безнен авылда туган. 1944нче елның 25нче октябренә каршы төндә икенче Украина фронты составындагы 53 нче армиягә караган 1 нче гвардия һава десанты дивизиясенең 13 нче гвардия һава десанты полкы командиры подполковник Исхаков Зиннәтулла искиткеч кыюлык һәм батырлык күрсәтә. 1945нче елның 24нче мартында аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Сугыштан соң Зиннәтулла Гыйниятулла улы армиядә хәрби хезмәтен дәвам итә. 1950нче елда Хәрби академияне тәмамлый. Ленин ордены һәм ике Кызыл Байрак ордены, III дәрәҗә Суворов, Александр Невский, Кызыл Йолдыз орденнары һәм күпсанлы медальләр белән бүләкләнә.

1958нче елның 5нче июлендә герой авылдашыбыз вафат була. Советлар Союзы Герое Зиннәтулла Гыйниятулла улы Исхаков хөрмәтенә Үргәагар мәктәбе каршысына һәйкәл куелган.

## 4. Тикшеренү барышында башкарылган эшләр

Туган авылымның тарихын, топонимнарын өйрәнүнең башлангыч этабында мин авылымның урман- кырларында, елга –күл, чишмә буйларында булдым, фотолар ясадым. Елның иң гүзәл чоры җәй фасылы булганга күрә, бу эшемне мин җәен башладым, фотосурәтләремдә дә шул чор чагылыш таба.

Аннан соң шул фотоларымны алып үземнең дәү әнием Кәүсәрия Габдуллаҗан кызы Мусина янына киттем. Дәү әнием 1939нчы елда Үргәагар авылында туган. Гомеренең башыннан алып бүгенге көнгә кадәр туган авылыбыздан китмәгән, шунда сугыш вакытының ачлыкларын, ятимлек газапларын татып үскән. 15 яшеннән үк колхоз фермасына эшкә кергән, башта бозаулар караган, аннары савымчы булып эшләгән. Хезмәттәшләре арасында уңганлыгы, булганлыгы белән аерылып торган, җитәкчеләр тарафыннан макталып эшләгән, аның турында газеталарга да язганнар.

Дәү әнием авылыбыз, аның тарихы турында күп кенә мәгълүмат сөйләде миңа. Эшемдә чагылыш тапкан күп материалларны аның сөйләве буенча һәм басма чыганаклардан алып яздым. Әле топонимнарның барысы турында да сөйләп бетермәде ул миңа, эшемне хәзер дә дәвам итәм.

Дәү әниемнән урманнарның исемнәре турында сораштым. Ул миңа Зур урман дип аталган урманның биләп торган мәйданы буенча, чынннан да, зур булуын, шуңа күрә халык

шундый исем биргәнлеге турында сөйләде. “Кырык чат урманында кырык рәткә тезелеп, төз, биек булып агачлар үскән,шуңа күрә урман Кырык чат урманы дип атала икән. Әлеге урманнан ерак та түгел, Умарталык урманы бар. Кайчандыр ул урман аланында колхоз умарталыгы урнашкан булган, урман исеме дә шуннан килеп чыккан,”- дип аңлатма бирде дәү әнием.

“Яңа Чаллы белән Үргәагар авыллары арасында Иске йорт дип йөртелә торган урын бар икән, анда бик борын заманнарда авыл булып, аның кешеләре сугыш вакытында үлеп беткән, каберләре шул авыл урынында һәм Иске йорт изге урын булып санала,” – дип сөйләде дәү әнием.

Авылыбызда мәгърифәт , мәдрәсә, мәктәпләр турындагы мәгълүматны мин лаеклы ялдагы укытучылар Зилә Вәҗит кызы Сафиуллинадан һәм Рамилә Нуретдин кызы Җәләловадан язып алдым. Зилә апа - 1990нчы елдан 2013нче елга кадәр Үргәагар мәктәбендә директор булып эшләгән Әсхать Самат улы Сафиуллинның тормыш иптәше, үзе дә гомере буе шул мәктәптә балалар укыткан. Аңарда төрле елларда төшерелгән мәктәп бинасы, элеккеге укытучылар сурәтләнгән фотолар күп булып чыкты. Шул альбомнарны актара –актара, миңа күп мәгълүмат сөйләде ул. Рамилә апа да күп еллар балаларга математика фәненнән белем биргән, директор урынбасары булып эшләгән, Рамилә апа да авылым, мәчетләр, мәктәпләр турында рәхәтләнеп сөйләде.

Бөек Ватан сугышының яу кырларында ятып калган авылдашларымның хөрмәтенә авыл уртасына һәйкәл куелган. Һәлак булганнарның исемлеген мин Үргәагар авыл җирлеге башлыгы сәркатибе Энҗе апа Фәттаховадан алдым. Исемлектә булган күп кенә батырларыбызның инде авылыбызда туганнары да калмаган икән.

Мәчетебез исә үзе җанлы тарих, анда булып, мин фотолар ясадым, иске фотоларның күчермәсен алдым, намазга җыелган бабайлар белән әңгәмә корып кайттым.

## Йомгаклау

Авылым тарихын өйрәнүне бер тикшеренү эше кысаларында гына тәмамлау мөмкин түгел. Әле аның топонимнарын аерым алып өйрәнәсем килә. Бу юнәлешне инде мин башлап җибәрдем. Үземнең дәү әнием Мусина Кәүсәрия Габдуллаҗан кызы белән әңгәмә үткәрдем. Аңа үземне кызыксындырган берничә соравымны бирдем. Ул сорауларыма бик рәхәтләнеп җавап бирде.

Шулай итеп, мин куелган максатыма ирештем:

- төрле чыганаклардан материал туплап,Үргәагар авылының тарихы белән таныштым;
- авылымның бүгенге тормышын , табигатен күзәтеп чыктым,күзәтүләремне чагылдырган фото һәм видеоматериаллар тупладым;
- авылдашларым белән очрашып, алардан үземне кызыксындырган сорауларга җавап алдым;

- тупланган барлык материалны системалаштырдым.

Нәтиҗәләр:

1. Әлки районының Үргәагар авылы табигатьнең урман-кырларга, чишмә –күлләргә бай урынына урнашкан, топонимик атамалар кеше исемнәренә, географик урынга, топонимнар тирәсендә урнашкан объектларга бәйле рәвештә барлыкка килгән;
2. Үргәагар авылы халкы күрше –тирә авылларда яшәгән халыклардан дингә, мәгърифәткә мөнәсәбәте буенча аерылып тора;
3. Авылда элек-электән игенчелек төп кәсеп булган, шул ук вакытта мич чыгаручы, балта остасы, баш киеме тегүче, шырпы ясаучы кебек һөнәр ияләре дә яшәгән;
4. Борынгы заманнардан алып 21нче гасыр башына кадәр Үргәагарда бары тик татарлар гына яшәгән, соңгы елларда авылга башка милләт кешеләре дә кайтып урнашты.

Кулланылган әдәбият:

1. “Атамалар ни сөйли”: - Казан, 2000.- 180 бит.

2. Ил Газиз “Әллием, бәллием...”: очерклар.- Казан: Мәгариф, 1996. - 348 бит.

3. “Населенные пункты Республики Татарстан”: Краткий справочник.- Казань, 1997. –390 с.

4. “Список селений Казанского уезда”- Казань: типография И.Н. Харитонова, 1910. – 72 с.

5.Фаттахова З.Н.” Авылыбыз горурлыгы “//Әлки хәбәрләре.1995-13нче апрель.

*Низамова Диана, 7 нче сыйныф,*
*Әлки муниципаль районы Нәби Дәүли исемендәге*
*Базарлы Матак гимназиясе МБГББУ дәүләт*
*бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкче: Әһлиуллина Лилия Шәүкәт кызы, татар*
*теле һәм әдәбияты укытучысы*

Эчтәлек

I. Кереш

II. Төп өлеш

1. Әлки районы Иске Камка авылы тарихы
2. Авылның табигате
3. Иске Камка авылының тарихи урыннары
4. Бөек Ватан сугышы елларында авылым кешеләре

III. Йомгаклау

IV. Кулланылган әдәбият

## КЕРЕШ

Мин Әлки районы Базарлы Матак авылында яшим. Татар әдәбияты дәресләренең берсендә укытучым бик мавыктыргыч итеп үзенең туган авылы турында сөйләде. Аның туган авылы – Әлки районында урнашкан Иске Камка авылы икән. Иске Камка... Мин уйга калдым. Дәрес беткәч укытучым янына килеп минем эти – әниемнең дә шушы авылда туып-үсүләре турында әйттем. Укытучым миңа җавабында: “Беләм, Диана, синең тамырларың да Иске Камка авылыннан. Ә этиең белән әниеңә мин татар теле һәм әдәбияты фәннәрен укыттым,”- диде, - Иске Камка синең дә туган авылың ул. Ә аның тарихын белү, өйрәнү – һәркемнең изге бурычы. Син туган авылың турында ниләр беләсең? Әйдә, эзлән, өйрән Иске Камка авылы турында”.

Авылым тарихын өйрәнү максатыннан фәнни-тикшеренү эше башкарырга булып мин өйгә ашыктым. Әниемә үземнең теләгемне җиткердем, ул да мине хуплады. Эшемнең темасын «Туган җирем-изге җирем» дип куйдым. Максатым – туган җирем , Әлки районы Иске Камка авылы тарихын өйрәнү, танышу. Бүгенгесе көндә бу тема актуаль дип саныйм, чөнки район составына кергән зур авыллар белән беррәттән минем туган авылым Иске Камканың да дәрәҗәсе бер булуын күрсәтәсем килә, аның турында, үткәне, киләчәге турында киләчәк буын да белергә тиеш дип уйлыйм.

Максатымнан чыгып, үз алдыма түбәндәге бурычларгы куйдым:

1.Әлки районы Иске Камка авылы турында төрле чыганаклардан материаллар эзләп табу, алар белән танышу;

2. Иске Камка авылының табигатен күзәтү;

3.Өлкән буын кешеләре белән сөйләшеп,сорашулар үткәрү, истәлекләрен язып алу.

4. Истәлекле урыннар турында мәгълүмат туплау;

5. Бөек Ватан сугышы елларында авылдашларым.

## ТӨП ӨЛЕШ

1. Әлки районы Иске Камка авылы тарихы.

Кече Чирмешән суы ярына тезелешеп утырган авыллар байтак. Аларның кайберләре шактый зур, икенчеләре кечерәк. Авыллар арасында Иске Камка авылы үзенең бай табигате белән аерылып тора.

Россиядә Камка исемен йөртүче авыллар берничә төбәктә бар. Камка авылының берсе Нижгар өлкәсе Сергач районында Пьяна елгасы буенда урнашкан. Икенчесе Сатис елгасы буенда мордва авылы – Комкино. Кече Чирмешән елгасы буенда Татарстан Республикасының Әлки районында Иске һәм Яңа Камка исемле мишәр авыллары урнашкан. Өч төбәктә урнашкан авыллар үзара тарихи бәйле. 17 нче гасыр ахырында камка атамалы мишәр авылы Кече Чирмешән елгасы буенда барлыкка килгән. Авыл халкы

арасында яшәп килгән риваятьләр буенча, атаманы тагучы Камка әби авыл урнашачак урынны күргәч, сокланып: “Менә ул Камка!” - дип әйткән имеш. Аны Камка әби дип олылап искә ала булганнар. “Камка” – көнчыгыш халыклар арасында киң кулланыла торган нәфис, бизәкле ефәк тукыма. Бизәкләрдә яфраклар, үсемлекләр сурәтләнә торган булган.Ул ефәкне болгарлар киң таратканнар.

Камка атамасы шактый күп очрый һәм дәрәҗәле тарихи чыганакларда еш искә алына.

С. Мельниковның 16-17 нче йөзләргә караган үтенечләр, әмерләр һәм патша фәрманнары тупланган “Акты исторические и юридические и древние царские грамоты Казанской и других соседственных губерний” дип аталган җыентыгында Түбән Новгород өлкәсендәге Камка һәм Әлки районындагы Камка авылларыныа караган язмалар бар.

Рәсми документларда (“Арзамамасские поместные акты” дигән документлар җыентыгында) шул атамалы авыл 1611 нче елда телгә алына.

Иске Камканың кайчан барлыкка килүе турында рәсми мәгълүматлар юк. Әмма фикер йөртү өчен фактлар аз түгел. Беренче факт – Камка атамасы. Бу сүзне атама итүчеләр Булгар кешеләре булырга тиеш. Чөнки “камка” сүзе аларның яшәеш өчен җайлы урын табу максаты турында сөйли. Мишәрләрнең бер өлеше борынгы Болгар, Биләр, Бүлемер шәһәрләре тирәсеннән килгәнлекләре турында түбәндәге факт сөйли: 17 нче гасырның ахырында Чирмешән буйларына мишәрләр барып утыралар. Шулар арасында Камка татарлары да була. Урнашырга ризалык сорап язган мөрәҗәгатьләрендә бу мишәрләр “без үзебезнең борынгы җирләребезгә кайтырга телибез, анда безнең изге кешеләребезнең каберләре,” – дип язалар.

Икенче дәлил: 17 нче гасырның ахырында Чирмешән буйларына күчеп утырган Камка кешеләре борынгы бабалары Пьяна елгасы буеннан килеп утырулары турындагы риваятьне хәтерлиләр.

Иске Камка авылы янында археологлар борынгы болгар чорларына мөнәсәбәтле шәһәр һәм ике авыл хәрәбәсе билгеләгәннәр. Иске Камка авылы янында элек шәһәр булган. Бу турыда тарихчы С.М. Шпилевский язган.

Иске Камка авылы янында “Кала тавы (валы)” дигән урын бар. Тарихчы – археологларның тикшеренүеннән язмалар буенча “Кала сазы” дип аталган сазлыктан 9-10 метр биеклектә урнашкан шәһәрчек булган биредә. Шәһәрчекнең көнъягында 220 метр озынлыктагы ике вал барлыкка килә. Көньяк валның уртасында елгага төшә торган авышлык бар, әйтерсең шул урында җир убылган. Күзаллауларга нигезләнгән фактлар буенча бу-җир асты юлы булуы мөмкин. “Кала сазы”дип йөртелә торган урын шәһәрчек булып чыга, димәк. Ул һәряклап вал белән әйләндереп алынган. Әлеге валларның биеклеге төрлечә. Көньягында тышкы валларның биеклеге 1-2 метр гына, ләкин төп валның биеклеге

4-5 метрга җитә. 9-10 метрга җиткән урыннары да бар. Шәһәрчекнең мәйданы 800 метр. Шәһәрчекнең төньягында тәбәнәк кенә ике каланча тора. Әлеге каланчалар саклану йөзеннән куелган.

Иске Камка Чирмешән елгасы буенда тигез җиргә урнашкан. Чирмешән – тарихи атама. Болгар дәүләте яшәешенең аерым чорларында башкала хезмәтен үтәгән шанлы Биләр шәһәре шул елга янында чәчәк аткан. Чирмешән исеме төрле тарихи чыганакларда искә алына. 921-922 нче елларда Идел – Кама  Болгарстанына Багдад Фадлан язмаларында ул Җәрәмсан, рус елъязмаларында Черемисан, Әлки районы Ташбилге авылы янында табылган кабер ташында Чәримсан рәвешендә бирелгән. Апас районында да Зөя елгасының кушылдыгы – Чирмешән елгасы бар. Шагыйрь Габделҗаббар Кандалый үзенең иҗатында Чирмешән суларын искә ала.

Авылның аксакаллары сөйләве буенча, авылның оешу тарихы элекке Алатыр өязенең Пьяна суы ярына урнашкан Камка авылы белән бәйләнешле(хәзерге Түбән Новгород өлкәсе Сергач районындагы Камка авылы).  Түбән Новгород өлкәсендәге Камка авылының кайбер нәселләре , йомышлы татарлар сыйфатында, Кама аръягындага ныгытмаларны саклау өчен, патша  хөкүмәте тарафыннан шушында китереп утыртылганнар.

Авылда берничә нәсел кешеләре яшәп килгән.

Беренчесе – Нәмай нәселе. Икенчесе- Урманчеевлар, өченчесе – Тукай, дүртенчесе – Бакнәй нәселе. Тукай нәселенең  шәҗәрә чылбырындагы исемнәр: Тукай -  Туктый – Ибраһим – Нигъмәтулла (Нәмай), - Мөхәммәтша – Галим – Хәйдәр – Дәүләтша – Мирзагабдулла – Җәүдәт – Раиль – Динар. Бу нәсел бик зур. Нәсел дәвамчысы Раиль абый Дәүләтшин хәзергесе вакытта гаиләсе белән район үзәгендә яши.

Сергачтагы Камка белән Әлки районындагы Камка авылында яши торган халыкның көнкүрешләре, рухи тормышлары, күп кенә гореф-гадәтләре бер-берсеннән аерылмый:  кыз бирү, туй итү һәм башкалар.

Соңрак бу Камкадан Яңа Камка авылы аерылып чыккач, халык Камка атамасы алдына “иске” сүзен куша, документларда бу авыл рәсми рәвештә Иске Камка дип атала башлый.

А. Артемьев китабында Иске Камка һәм Яңа Камка авыллары телгә алынган.Кече Чирмешән елгасы ярына утырган Иске Камкада 152 хуҗалыкта 481 ир-ат һәм 479 хатын-кыз яшәгән, мәчет эшләгән.

Риваятьләргә караганда Иске Камка авылыннан берничә чакрым еракълыкта гына урнашкан Карамалы авылы да Камка авылыннан аерылып чыккан дигән фикерләр яши. Камка белән Карамалы авылы арасында “Котылдык” дигән калкулык бар. Камка авылыннан аерылып чыккан берничә гаилә шушы урында урнашкан һәм ул урынны шулай атаганнар. Соңыннан ул Карамал дип атала башлаган.

Иске Камка авылы халкы буйсынмас, баш иməүчəн булган, патша хөкүмəтлəре тарафыннан китерелгəн кəгазьлəрнең асылына төшенмичə, тамга салмаган. Динне хөрмəтлəп, тырышып эшлəгəннəр. 1878 нче елның 4 нче ноябрендə Казан губернаторы Н.Я.Скарятинның эчке эшлəр министры А.Е. Тимашевка Казан губернасының Спас өязе Мораса волостендагы чуалыш-болганышлар турындагы язуында татар авыллары Иске Алпар, Яңа Алпар, Иске һəм Яңа Үргəагар, Карамалы, Татар Мулла авыллары искə алына. Анда каралты – кураларны янгыннан саклау максатыннан, аларны иминиятлəштерү бурычы куелгач, халыкның бик нык борчылуы, чуалышлар башланып китүе турында языла. Алар, безне чукындырырга телилəр, христиан диненə чыгарырга телилəр дип уйлап, авыл тирəсенлəге урман-агачларны кисеп ташлыйлар.

2. Иске Камка авылының табигате.

Иске Камка авылының уң як читеннəн, болыннар буйлап Чирмешəн елгасы ага. Тирə-юне, нигездə тигезлеклəрдəн, табигый болынлыклардан тора. Халык телендə аларның Мулла чалуы, Кое чирəме, Мəүлəшə болыны, Прогон һəм башка исемнəре бар. Əлеге болынлыкларда карлыган, кура җилəге, гөлҗимеш, балан бик күп булган. Хəзер исə боларның исемнəре генə тарих булып калган.

Иске Камка тирəсендə елга-инешлəр, чишмə-кизлəүлəр, күл һəм сазлыклар бихисап. Инеш-күллəр тирəсендə камышлар,күллəрендə төнбоеклар үсеп утыра. Елга-инешлəр суларын Кече Чирмешəнгə куалар. Елга-күллəрнең атамалары авылның үткəн тарихын күзалларга ярдəм итə. Суларын Кече Чирмешəнгə илтə торган Аю аланы чишмəсе атамасы бу тирəне аюлар яратканны сөйли. Югары урман, Мəүлəшə урманы, Урыс урманы, Карамал урманы атамаларыннан аңлашылганча, бу тирəлəр урманнарга бик бай булган. Урман булган җирдə дым күп була, димəк сазлыклар да булмый калмый. Кала сазы, Əнҗерə сазы, Мүкле саз һəм башкалар. Дəү əнием сүзлəре буенча Мүкле саздан элек халык мүк йолкыган, йорт салганда аны бүрəнə араларына салып калдырган.

Елга-күл, чишмə атамаларының исемнəре дə үзенчəлекле. Аленка елгасы, Сафа күле, Урман елгасы, Чуаш елгасы, Ермак елгасы, Кизлəү чишмəсе, Яким күле, Җəлəй елгасы, Мəрхəбə тавы. Бу атамалар теге яки бу күлəмдə авылымның үсеш тарихын ачыкларга ярдəм итə. Чуаш елгасы, Урыс урманы дигəн атамалар Иске Камка авылы халкының рус һəм чуваш халкы белəн күрше булып яшəүлəрен күрсəтеп тора.

Авыл халкының тормышында Чирмешəн елгасы зур роль уйнаган. Дəү əнием сүзлəре буенча, авыл халкының тормыш-көнкүреше əлеге елга белəн бəйлəнгəн булган. Авыл халкы балыгын да тоткан, суын ташып мунча да яккан, мал-туарын да сугарган, каз-үрдəген дə коендырган, җəен – кышын керен дə чайкаган.

3. Авылымның истəлекле урыннары.

Иске Камка авылында өч мәчет булган дип сөйлиләр. Беренчесе 1868 нче елда, икенчесе 1876 нчы елда, өченче мәчет 1890 нчы елда төзелә. Ләкин алар берсе сакланып калмаган. 1993 нче елда авылның иң калку урынында төзелгән мәчет - авылым горурлыгы. Манарасыннан һәр көн саен намазга чакырып азан яңгырый. Кичләрен тирә-якка нур чәчеп торучы утлары белән мәчет бинасы авылымны бизәп тора.

Авылга килеп кергән кешеләрне авыл башында зиратлык каршы ала. Зиратлык эчендәге каберлекләр төзек һәм чистартылган.

1925-26 нчы елларда Иске Камкада башлангыч мәктәп төзелгән. Дүртеллык мәктәпне тәмамлаган укучылар Алпар мәктәбенә укырга киткәннәр. Беренче укытучылар Фазлыев Шамил, Фазлыева Мщсфия апалар булган. Утызынчы еллар уртасында илдә җидеелык гомуми мәҗбүри белем бирү бурычы куела һәм 1949-1950 нче елларда мәктәп җидееллык булып үзгәртелә. Мәктәп директоры булып Садыков Абдулхаким Фәсих улы эшли. 1960-61 нче елларда мәктәп сигезъеллык дип атала бшлый. 2000 нче елда унберьеллык мәктәп эшли башлый.

2003-2004 нче елда иске мәктәп сүтелеп, янәшәсенә яңасы төзелә. Ике катлы мәктәп авылга килгән кешеләрне сәламләп тора. 2009 нчы елдан мәктәп башлангыч мәктәп итеп исәпләнә. Биредә балалар бакчасы, җирле үзидарә, китаханә, медпункт урнашкан.

Бөек Ватан сугышына Иске Камка авылыннан барлыгы 150 ир-егет киткән. Шуларның туксаны туган җирләренә кире әйләнеп кайта алмый, ил өчен барган көрәштә һәлак була. Утыз кеше каты яраланып, инвалид булып кайта.

Һәр авылда тарихи истәлек булып сугышта һәлак булган авылдашларга куелган һәйкәлләр авылның уртасында тора. Иске Камка авылында куелган әлеге һәйкәл мәктәп укучылары тарафыннан чистартыла, җәен тирә-юне чәчәкләргә күмелә. Яз көне Җиңү көнендә бирегә авыл халкы сугышта һәлак булган авылдашларын искә алырга җыела.

Иске Камка авылында бүгенгесе көндә 83 йорт бар, 259 кеше яши. Авыл халкында 50 җиңел автомашина, 13 йөк машинасы, 20 трактор бар. Авыл телефон элемтәсе, газ, су белән тулысынча тәэмин ителгән. Биредә эшләү һәм муллыкта яшәү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Кешеләр күпләп терлек асрыйлар. Дүрт фермер хуҗалыгы эшләп тора. Авылга асфальт юл кергән, авыл яшьләрен тораклы итү программасы буенча 3 өй төзелгән.

4. Өлкән буын кешеләре белән сөйләшү, сорашулар үткәрү, истәлекләрен язып алу максатыннан мин видеоязмалар эшләдем..

Авылымның өлкән буын вәкиле Рушания апа белән заклап сөйләшеп утырдык. Колхозлашу еллары турында әнисеннән ишеткән истәлекләре белән уртаклашты ул.

Китапханәче булып эшләүче әнием миңа эшне башкару өчен авыллар тарихын чагылдырган китаплар, газета- журнал материаллары сайларга булышты.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алия Илмир кызы туган авылымнан чыккан күренекле шәхесләр турында сөйләде. Әлки районының горурлыгы булган фронтовик шагыйрь, язучы, якташым исемен йөрткән гимназиядә белем алуым белән горурланам мин.

ЙОМГАКЛАУ

Эзләнү эшем барышында мин алдыма куелган бурычларымны үтәдем.

“Әллием, бәллием...” дип аталган очереклар җыентыгы, Илгазизнең “Мизгелләр елъязмасы” документаль китабы, Фирдәвес Гарипованың “Рухи башкалабыз” китабы, интернет чыганаклар белән таныштым. Авылымның өлкән буын, урта буын кешеләре белән очрашып әңгәмә кордым. Авыл китапханәсендә булдым.

Һәм мин шундый нәтиҗәгә килдем: Туган авылым Иске Камканың тарихы мавыктыргыч, халкының даны еракларга таралган. Минем эшем белән танышкан кешеләр авылым турында шактый мәгълүматлар белерләр дип уйлыйм. Мин киләчәктә бу эшемне дәвам иттерергә, тагын да күбрәк материаллар тупларга уйлыйм.

*Сабурова Аделя, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы "Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен 23 нче Түбән Кама мәктәбе" дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Шакирова Суфия Шамил кызы, туган теле һәм әдәбиятыукытучысы*

**Татар сәхнә әсәрләрендә Муса Җәлил образы**

**Кереш**

Тарихта югалмаска туган исемнәр, югалмаска туган җырлар бар. Шуларның берсе – Муса Җәлил. Муса Җәлил исеме дә халкыбыз тарихына якты легенда булып кереп калды, шуңада аның шәхесенә һәм иҗатына булган кызыксыну беркайчан да тынмый.

Муса Җәлил – фаҗигале язмышлы шәхес, әмма нинди генә кыен шарларда яшәмәсен, өмет нурын сүндермәгән, изге теләкләрен халкына, киләчәк буыннарга васыять итеп калдырган.

Кешелек сыйфатлары белән дә ул гаҗәеп шәхес. Тоткынлыкта 791 көн уздыруга карамастан, рухи яктан сынмаган, фашистлар алдында баш имәгән, илен сатмаган. 1943 елның июнендә үлемгә хөкем ителеп һәр сәгате, минуты белән әҗәл көткәндә дә иленә, халкына тугры булып кала белгән. Шуңа да Җәлил батырлыгын белгән төрле милләт вәкилләре үлемне җиңгән шагыйрь дип әйтәләр.

Муса Җәлилнең гомерен батырлык юлы дип атап булыр иде. Моңа шагыйрь махсус әзерләнеп килмәгән, билгеле. Ул аның яшәү рәвеше, тормышы белән бәйле. Аның бөтен тормышы – халыкка һәм туган илгә хезмәт итүнең, чын намус һәм керсез күңел белән яшәүнең үрнәге.

Җәлил – татар халкының горурлыгы, йөз аклыгы һәм намусы, чөнки ул татар халкын бөтен дөньяга танытты һәм  татар мәдәниятында аерым урын алып тора.

Патриот - шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнгән хезмәтләр әз түгел. Бөек әдипнең тормыш юлын һәм иҗатын хәзер безнең илдә генә түгел, Россиядән читтә дә өйрәнәләр. Бөтен дөньяны таң калдырган бөек шәхеснең һәр адымы кешелек өчен кадерле булуы табигый хәл булып тора.

Нәтиҗә ясап, шуларны әйтергә кирәк, Җәлилнең данлы тормыш юлына, иҗади уңышларына багышланган меңнәрчә гәзит хәбәрләре, йөзләрчә журнал, фәнни җыентыкларда басылган мәкаләләр, күпсанлы китаплар, романнар, пьесалар, повестьлар, кинофилмьнар, телевизион һәм театр спектакльләре, музыкаль әсәрләр, рәсемнәр һәм башкалар иҗат ителде.

Әмма никадәр М.Җәлил иҗатына, аның шәхесенә игътибар күп булса да,  М.Җәлил образын гәүдәләндергән әсәрләргә гомуми күзәтү ясаган, системалы һәм тулы итеп тикшергән хезмәтләр юк. Шуңа күрә бу тема актуаль булып кала бирә. Фәнни – тикшеренү эшенең максаты булып татар сәхнә әсәрләрендә М.Җәлил образының бирелешен тикшерү тора.

Куелган максатны тормышка ашыру барышында түбәндәге бурычлар билгеләнде:

1. Муса Җәлилнең Бөек Ватан сугышы елларына гомуми күзәтү ясау.
2. Муса Җәлил образын яктырткан татар сәхнә әсәрләрен барлау.
3. Шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү максатыннан чыгып эшләнгән сәхнә әсәрләренә күзәтү ясау.

Тикшерү объекты булып «Моабит дәфтәре» кинофильмы, ”Ана бәйрәме” мультфильмы, ”Муса Җәлил” турында документаль фильм, Нәҗип Җиһановның “Җәлил” операсы һәм Фәнәвил Галиевнең “Җырларым” музыкаль спектакле билгеләнде.

Тикшерү предметы – билгеләнгән әсәрләрдә Муса Җәлил образы, аның бирелеше.

Тәкъдим ителгән чыгарылыш эше структур яктан керештән, төп өлештән, йомгак һәм кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

## II.Төп өлеш

### 2.1. *Муса Җәлил Бөек Ватан сугышы елларында.*

Муса Җәлил дөньяның һәр мәдәниятле кешесенә дә билгеле шәхес ул. Аны фашизмга каршы көрәштә гадәттән тыш батырлык күрсәткән патриот шагыйрь дип беләләр.

1941 елның июль аенда М. Җәлил армиягә алына. Башта ул Казан гарнизоны хәрби частендә рядовой кызылармеец булып хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге политработниклар әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә фашист гаскәрләре якынлашкач, курслар

Татарстанның Минзәлә шәһәренә эвакуацияләнә. 1941 елның декабрендә курсларны тәмамлагач, өлкән политрук М. Җәлил Мәскәү аша фронтка китә (февраль, 1942), Ул Төньяк-көнбатыш фронтта чыга торган «Отвага» исемле газетаның алгы сызыктагы хәрби корреспонденты итеп билгеләнә. 1942 елның июнендә Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, аларның часте чолганышта калып, М. Җәлил каты яраланган хәлендә дошман кулына эләгә. Шул көннән патриот шагыйрьнең фашист тоткынлыгындагы газаплы һәм героик тормыш этабы башлана.

М. Җәлил һәм җәлилчеләрнең, яшерен оешма төзеп, фашизмга каршы алып барган героик көрәше, каһарманлыклары турында дистәләрчә китаплар - романнар, повестьлар драма әсәрләре һәм поэмалар язылган, кинофильмнар төшерелгән. Иң мөһиме: Җәлил һәм аның иптәшләре ахыргы сулышларына кадәр ватан алдында тугрылыклы булып калалар һәм фашизмга каршы көрәштә тиңдәшсез рухи ныклык, батырлык үрнәге күрсәтәләр.

1944 елның февраль аенда Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә Дрезденда
суд була. Фашистик хәрби суд аларны, «дәүләткә каршы җимерү эше» алып
баруда гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25 августында

Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилченең гомере өзелә.

### 2.2. Муса Җәлил образын яктырткан татар сәхнә әсәрләрен барлау.

Сугыш елларында әдәбият дөньясы зур югалтуларга дучар була һәм мондый шагыйрьләрнең тормышы да, иҗаты да батырлыкка әверелгән легендага әйләнә. Шуңа күрә әдәбиятта бердән, әлеге шәхесләрнең батырлыгын күрсәтергә булса, икенчедән, аларны шундый сыйфатлары белән киләчәк буыннарга шагыйрь һәм гражданлык үрнәге итеп мәңгеләштерү бурычы килеп баса. М.Җәлилгә багышланган әсәрләр шулар рәтеннән була.

Мондый әсәрләр арасында М.Җәлилгә багышланган беренче әсәрләрдән булып Н.Исәнбәтнең «Муса Җәлил» (1956) исемле трагедиясе һәм Р.Ишморатның «Үлмәс җыр» (1955-56) дип аталган героик драмасы тора. Боларда М.Җәлилнең дошман тылында күрсәткән батырлыгы һәм төрмәдә уздырган соңгы көннәре тасвирлана.

«Соңгы төн» (И.Юзеев), «Моңлы бер җыр» (Т.Миңнуллин) әсәрләре – М.Җәлилнең яшьлек чорын, сугыш кырында күрсәткән каһарманлыгын сурәтләү ягыннан кыйммәтле

сәхнә әсәрләре. Шулай ук, «Кызыл ромашка» телевизион фильмы, «Кызыл ромашка» һәм «Ана бәйрәме» мультипликацион фильмы, «Моабит дәфтәре» кинофильмы, «Муса» исемле дүрт серияле телевизион спектакль, Муса Җәлил турында документаль фильм шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү максатыннан чыгып эшләнгән чаралар булып торалар.

Муса Җәлил дөньяның һәр мәдәниятле кешесенә дә билгеле шәхес ул. Аны фашизмга каршы көрәштә гадәттән тыш батырлык күрсәткән патриот шагыйрь дип беләләр. Җәмгыятьтә солдат-патриот каһарманлыгына карата булган игътибар әдәбият, сәнгать өлкәсендә дә үзенең көчен югалтмый. Сугыш вакыты эзләре буенча бик күп сәхнә әсәрләре барлыкка килә. Монда төрле конфликт ситуацияләрдә җиңүче характерының үзенчәлекләре ачыла. Муса Җәлил исеме сатылмас намус, нык ихтыяр һәм Ватанга мәхәббәт символы булып тора. Муса Җәлилнең гражданлык һәм иҗади каһарманлыгы чын мәгънәсендә легендар булып китте.

### 2.3. Шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү максатыннан чыгып эшләнгән сәхнә әсәрләренә күзәтү.

#### 2.3.1. «Моабит дәфтәре» кинофильмы.





«Моабит дәфтәре» кинофильмы 1967 елда “Ленфильм” киностудиясендә төшерелә. Режиссёры – Леонид Квинихидзе, төп рольләрне Пётр Чернов (Муса Җәлил), Әзһәр Шакиров (Абдулла Алишев), Рифкать Бикчәнтәев (Шәфи Алмаз) уйный.

Кинонын экраннарга чыгуы бик зур вакыйга була, татарлар турында да әйткәч, халкыбыз өчен бер горурлык хисе туа. Аны районнарда да күрсәтәләр. Фильмда татар көйләре дә яңгырый, Сабан туе күренешләре, татар авыллары да сурәтләнә. Әлеге күренешләрне Муса Җәлилнең кызы (Люция Җәлилова) әзерләгән була. Люция Җәлилова фильмны төшерү процессында үзе дә катнашкан. “Мин ВГИКның С.А.Герасимов факультеты студенты идем. Мине әлеге картинага диплом алды практикасына режиссёр ассистенты итеп җибәрделәр. Натура съёмкалары Литва, Побраде, Каунас һәм Вильнюста узды. Миңа хәрби әсирләрнең Едлинодагы лагерьда концерт Эпизодын эшләү бурычы йөкләнде. Үз эшемә энтузиазм белән алындым. Әтинең дусты, композитор Җәүдәт Фәйзи миңа туган илгә багышланган татар җырларын табарга булышты”, - дип искә ала Люция Җәлилова.

Абдулла Алиш ролен уйнаган, Г.Камал театры артисты Әзһәр Шакиров: “Моабит дәфтәре” дигән кино төшерәбез, дигәч, аптырап калдык, чөнки режиссёры яшь иде. Картинаның бик озак төшерелгәнен хәтерлим. Фильмда бик күп солдатлар катнашты. Фильмның соңгы кадрлары бик ошады. Кешеләрне душта юалар, башларын чабарга алып барганда да йөзләре нурлы. Бу кадрлар миңа нык тәэсир итте, тетрәндерде...”

### 2.3.2.”Ана бәйрәме” мультфильмы.



2006 нчы елның 15 нче февралендә танылган герой-шагыйрь Муса Җәлилнең 100 еллык юбилее уңаеннан Казанда “Ана бәйрәме” дигән анимацион фильмның презентациясе була. 17 минутлык фильмның нигезенә Муса Җәлилнең 3 шигыреннән алынган сюжет урнаштырылган. Бу – “Ана бәйрәме”, “Кызыл ромашка”, “Сандугач һәм чишмә”. Бу сюжетларны сугыш, мәхәббәт һәм табигать темалары берләштерә.

Фильм өстендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары һәм Казан дәүләт техник университетының студентлары эшли.

Фильм Татарстанда һәм Россиядә генә түгел, ә чит илләрдә дә DVD язмасында таралыш таба. Без дә бу фильм белән таныштык. Минемчә, “Ана бәйрәме” фильмы патриотик яктан көчле әсәр.

### 2.3.3. “Муса Җәлил” турында документаль фильм.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы заказы буенча Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыруга юнәлтелгән Дәүләт программасы кысаларында эшләнгән "Гасырларда калыр батырлык" дип исемләнгән герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗатына багышланган методик әсбап чыга. Бу әсбапта Муса Җәлил турында документаль фильм урнаштырыла. Документаль фильмда сеңлесе Хәдичә Җәлилованың истәлекләренә нигезләнгән материаллар, кызы Чулпан Җәлилованың хәтирәләре, “Моабит дәфтәре”ннән алынган шигырьләрдән өзекләр китерелә.

### 2.3.4.Нәҗип Җиһановның “Җәлил” операсы.



Нәҗип Җиһановның "Җәлил" операсы беренче тапкыр 1957 елны Татар опера театрында куела, шул ук елны ул Мәскәүдә, Ленинградта тәкъдим ителә. Соңрак исә Советлар Берлегенең Зур театрында, ә 1960 елда Праганың милли опера сәхнәсендә башкарыла.

Нәҗип Җиһанов операны “Моабит” дәфтәре кайтканнан соң яза, спектакль күренешләре дә шагыйрьнең “Моабит” дәфтәрендәге шигырьләренә нигезләнгән. Гомумән, опера эчтәлеге II Дөнья сугышы вакыйгалары белән бәйле. Бирედә Совет хәрбиләре, фашистлар күрсәтелә. Җәлилнең сугыш кырындагы батырлыгы, әсирлеккә төшүләре, үзе әйтүенчә, "пистолеты хыянәт итүләре" тасвирлана. Шулай ук кызы Чулпан, хатыны Әминәгә кагылышлы күренешләр бар. Ахырдан исә шагыйрьнең соңгы васыяте үтәлүе, дусты Андреның “Моабит” дәфтәрен кайтаруы күрсәтелә.

Әминә Җәлилова кызы Чулпан белән Җәлилнең шигырьләрен укый.

Кайбер күренешләрдә исә киноларда төшә торган, махсус тәрбияләнгән этләр дә катнаша. Опера заманча компьютер графикалары белән бик үзенчәлекле эшләнелгән.

Опера татар, рус, алман, итальян телләрендә башкарыла.

**2.3.5.Фәнәвил Галиевнең “Җырларым” музыкаль спектакле.**




“Җырларым” (“Песни мои”) музыкаль спектакль М. Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышлана. Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрында үзе язган сценарий буенча Татарстанның атказанган артисты Фәнәвил Галиев куйган “Җырларым” музыкаль спектакле каһарман шагыйрь Муса Җәлил батырлыгына мәдхия булып яңгырый. Анда Җәлилнең шигырьләре, аның кызы Чулпан һәм хатыны Әминәгә язган хатлары, көндәлек язмалары һәм шагыйрь биографиясендәге хәлиткеч вакыйгалар искә төшерелә.

Сәхнәдә яңгыраган татар халык җырлары спектакльне бизәп кенә калмыйча, туган иленнән ерακта тоткынлыкта тилмереп яшәгән шагыйрьнең хисләрен күрсәтәләр.

**III.Нәтиҗәләр.**

Без татар сәхнә әсәрләре үрнәгендә М.Җәлил образының бирелешен анализландык. Бу максаттан Муса Җәлилнең Бөек Ватан сугышы елларына гомуми күзәтү ясадык, Муса Җәлил образын яктырткан татар сәхнә әсәрләрен барладык, шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү максатыннан чыгып эшләнгән сәхнә әсәрләренә тукталдык. Фәнни –

тикшеренү эше барышында «Моабит дәфтәре» кинофильмы, ”Ана бәйрәме” мультфильмы, ”Муса Җәлил” турында документаль фильм, Нәҗип Җиһановның “Җәлил” операсы һәм Фәнәвил Галиевнең “Җырларым” музыкаль спектаклен карадык. Муса Җәлил турында Рафаэль Мостафин, Гази Кашшаф, Ю.Королько, К.Симонов кебек шәхесләрнең дә эзләнү эшләре алып баруын ачыкладык һәм шагыйрь образы һәрвакыт үзәктә булган дигән нәтиҗәгә килдек.

Әлеге сәхнә әсәрләре турында укыгач, фильмнарны карагач, Муса Җәлил образы турында түбәндәгеләрне әйтергә була:

- Муса Җәлил исеме сатылмас намус, нык ихтыяр һәм Ватанга мәхәббәт символы булып тора.
- Җәлил һәм аның иптәшләре ахыргы сулышларына кадәр Ватан алдында тугрылыклы булып калалар һәм фашизмга каршы көрәштә тиңдәшсез рухи ныклык, батырлык үрнәге күрсәтәләр.
- Фәнәвил Галиевнең “Җырларым” музыкаль спектаклендә Муса Җәлил образы “яшьлек анты”на тугры калган кеше буларак бирелә. Әйтерсең, 13 яшьлек чагында ук ул үзенең язмышын, үлемсезлеккә илтәчәк гомерен билгеләп куйган.
- “Моабит дәфтәре” кинофильмын, “Муса Җәлил” турында документаль фильмны һәм Фәнәвил Галиевнең “Җырларым” музыкаль спектакленә уртак чишелеш хас – Муса Җәлил гомере палач балтасыннан өзелә.

Карап киткән һәр сәхнә әсәрендә бер-берсенә охшаган тагын бер үзенчәлек – Муса Җәлилнең якын кешеләре я сәхнә әсәрен тормышка ашыруда катнашкан, яисә алар үзләре герой ролендә (Люция Җәлилова – “Моабит дәфтәре” кинофильмы, Хәдичә Җәлилова һәм Чулпан Җәлилова - “Муса Җәлил” турында документаль фильм, Әминә Җәлилова кызы Чулпан белән - Нәҗип Җиһановның “Җәлил” операсы).

Шулай итеп, шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү ягыннан эшләнгән әлеге сәхнә әсәрләре Муса Җәлил образын ачуда мөһим урын алып торалар.

## IV. Кулланылган әдәбият исемлеге


1. Гасырларда калыр батырлык. Интерактив методик әсбап. ООО “Мастер” 2006 ел.
2. “Мәгърифәт” гәзите. 18 февраль, 2006 ел.
3. “Мәгариф” журналының 2 саны, 2006 ел.
4. Мостафин Р.  Муса Җәлил эзләре буйлап.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1968ел.
5. Мостафин Р. Җәлилчеләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1988 ел.
6. Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. Казан:Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2004 ел.
7. Интернет материаллары

*Талипова Мәликә, Малыгина Злата , 7 нче сыйныф, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүче 10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкче: Хакимова Рәмзия Риф кызы, татар теле һәм әдәбияте укытучысы*

## Чалып чигү-крест белән чигү-безенең гаиләнең традициясе

Кереш

2023 елның 22 ноябрендә РФ Президенты Владимир Путин указга кул куйды, аның нигезендә 2024 ел-Гаиләне яклау, традицион гаилә кыйммәтләрен саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен популярлаштыру максатларында 2024 нче елны Гаилә елы дип игълан итте. Гаилә елында традицион гаилә кыйммәтләрен саклауга аерым игътибар биреләчәк. Аларга мәхәббәт, тугрылык, хөрмәт, үзара аңлашу һәм ярдәм итү керә. Бу кыйммәтләр ныклы һәм бәхетле гаилә нигезе булып тора. Ныклы гаилә - җәмгыятьнең тотрыклылыгы һәм чәчәк атуына нигез салучы.

Кадрия Идрисова: “Без балаларны милләтебезнең телен, гореф-гадәтләрен, нигезен саклый торган итеп тәрбияләргә тиешбез”-ди. – Без, хатын-кызлар, тормышка чыгарга, балалар табарга бурычлы. Аларны милләтебезнең телен, гореф-гадәтләрен, нигезен саклый торган итеп тәрбияләргә тиешбез. “Ак калфак” – Бөтендөнья татар конгрессының беренче съездында ук оештырылган хатын-кызларның төп оешмасы. Бүгенге вазгыятьтә халкыбыз белән эшләүнең иң отышлы чарасы – йолаларыбыз, гореф-гадәтләребез аша халык күңеленә керү. Безнең оешма эшчәнлегенең төп таяну нокталары – күчмә утырышлар, “Калфак туйлары”, яшүсмерләр, яшьләр белән эшләү, – диде ул.

https://tatar-congress.org/yanalyklar/kadriya-idrisova-bez-balalarny-milletebeznen-telen-goref-gadetleren-nigezen-saklyy-torgan-itep-terbiyalerge-tieshbez/

Без еш кына "гаилә традицияләре", "гаилә кыйммәтләре" дигән сүзләрне ишетәбез. Нәрсә соң бу? Традиция-ул тарихи формалашкан һәм буыннан буынга тапшырыла торган гореф-гадәтләр, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Ул шәхси индивидуальлекне күрсәтә, гаиләнең ниндидер рухын тапшыра.

Минем татар теле укытучым һәм сыйныф җитәкчесе Рәмзия Рифовна беркөнне сыйныфка чиккән сөлгеләрен алып килде. Миңа алар бик ошады. Әнисе дә чиккән, әбисе дә чиккән, бәйләгән эшләрен күрсәтте. Ул мине кул эшенә рухландырды. Минем дә үземнең гаиләнең традицияләре турында сөйлисем килде.

Миннән гаиләмдә нинди традицияләр барлыгын сорагач, мин гаилә бәйрәмнәрен дә, урманга уртак походларга да чыгуны, өстәл артында баянга кушылып җырлар җырлаганыбызны әйттем. Гаиләмдә нинди үзенчәлекле традиция бар микән дип уйлап та куйдым. «Әлбәттә, гаиләдә күмәк,бергәләп эшли торган эш!», - дип уйладым. Ул безнең чигү белән мавыгу!

Безнең гаиләдә барлык хатын-кызлар чигүне бик яраталар. Мин чигәргә бик яратам, һәм минем бу эш төре турында куберәк беләсем килә.

Тема: крест белән чигү- безнең гилә традициясе.

Эшнең максаты: гаиләдә кул эшенең бер төре буларак крест белән чигүнең үзенчәлекләрен һәм үсеш тарихын, аның гаиләне берләштерүдәге ролен өйрәнергә.

Тикшеренү объекты: крест белән чигелгән картиналар һәм сөлгеләр

Тикшеренү предметы: крест белән чигүне үстерү үзенчәлекләре һәм тарихы, аның гаилә традицияләренә йогынтысы.

Тикшеренү гипотезасы: крест белән чигү гаиләне берләштерергә сәләтле яхшы гаилә традициясе булып тора, һәм мондый традицияне башка гаиләләрдә дә яңартырга кирәк.

## 2. Төп өлеш.

### 2.1 Крест белән чигүнең барлыкка килү тарихы

Чигү барлыкка килүе тарихы гасырлар эченә кереп китә. Бу сәнгать төре борынгы мәдәният чорына карый. Ул кием әзерләгәндә беренче атлам-беренче төеннәр барлыкка килү белән тыгыз бәйләнгән. Төрле вакытларда тегү өчен чигү өчен материал булып хайваннарның тамырлары да, җитен җепләре дә, киндер, мамык, йон, ефәк тә хезмәт иткән. Чигү өчен корал башта таш шило, аннары бронза яисә корыч энә булган.

Кеше күптәннән инде табигатьнең матурлыгын да, үзенең хисләрен шартлы билгеләр һәм бизәкләр белән күрсәткәннәр: турыдан-туры һәм дулкынлы сызыклар, тәреләр, квадратлар, өчпочмаклар, ромблар, түгәрәкләр белән дә тапшырганнар. Славяннарда билгеләр-символлар бик күп булган, һәм алар барысы да күз тиюдән саклаганнар,уңыш китергәннәр . Аларны киемнәргә чиккәннәр, алар бәладән саклаганнар һәм өйгә бәхет китерә дип ышанганнар. Күлмәк якасы, итәге, киндер, сөлге, ашъяулык, җәймәләргә чиккәннә. Гади билгеләр-символлардан катлаулырак орнаментлар төзелгән. Еш кына аларда кош сурәтләре ясаганнар. Шулай итеп, аккош кыз-кәләшне, тугрылыкны гәүдәләндергән. Тавык һәм үрдәк хезмәт сөючәнлек һәм уңдырышлылык символлары булып саналган. Ир белән хатынның тугрылык һәм бәхетле гаиләнең символы-зәңгәр төс булган. Шулай ук ир-ат һәм хатын-кыз фигураларын, көнкүреш рәсемнәрен дә чиккәннәр.

Чигү белән нигездә хатын-кызлар шөгыльләнгән. Кызлар элек 5-6 яшьтән чигәргә өйрәнгәннәр. Һәр кыз туган-тумачасына һәм хөрмәтле кунакларга махсус чиккән

сөлгеләр бүләк иткәннәр. Сабантуйларда беренче килгән атка бәйләгәннәр,егетләрне армиягә озатиканда чигүле кулҗяулыклар биргәннәр.

Чигү белән капланган киемнең мәйданыннан һәм бизәкнең яктылыгыннан хатын-кызның яше билгеле булган. “Кияүгә күптән түгел генә чыккан яшь кенә бер хатынның күлмәге иң матуры иде”-дип әйтелә “Әлдермештән Әлмәндәр” спектаклендә. Мондый күлмәкләр кызыл җепләр белән чигелгән һәм катлаулы бизәкләр белән чигелгәлектән башкалардан аерылып торган. Өстенә костюм кигән яшь хатын-кызлар шулай ук алъяпкыч, сарафан итәге яки итәк итәген-биби итәкләрне бизәгәннәр. Бала туган саен хатын-кыз костюмында бизәкләр саны кимегән, төсләр коңгыртлана, ә баш киеме тыйнакрак һәм гадирәк булган.

Монахлар һәм аксөякләр үз эшләрен бәрхет һәм алтын җепләр, энҗе һәм асылташлар белән чиккәннәр.

18 гасыр башында чигү сәнгате крестьян кызларының гадәти шөгыленә әверелә. Эш өчен материаллар арзанрак булган , әмма гади кызлар чын шедеврлар тудырганнар.

Крест белән чигү 19 гасырда аеруча нык үскән. Чигү күпкә уңайлырак һәм кызыклырак була башлаган: текстиль сәнәгате үсеш алган, яңа, чигү өчен уңайлы тукымалар, җепләр барлыкка килгән, чигүнең төсле схемалы журналлар чыгарыла башлаган.

2.2 Эш өчен кораллар һәм җайланмалар

Чигү өчен материалның калынлыгына карап сайлана. Калын канва буйлап калын җепләр, йон җепләр (мәсәлән, диван megендәрләре, келәмнәр) белән чигәргә була, нечкәрәк тукымага чигү өчен мамык-җеп,нечкә җепләр эрләү кирәк. Мин күбрәк мулине кулланам.

Аларны бүген кибетнең теләсә кайсы тегү бүлегендә сатып алырга була. Чигү җепләрен буяу өчен буяулар зур тотрыклылыкка ия ,шуңа күрә кер юу вакытында бу җепләр тукыманы кырмыйлар һәм буямыйлар,төсләре чыкмый,йокмый.

Энәләр - тегү өчен төп корал. Озынлыгы һәм калынлыгы буенча алар чигелә торган тукыманың калынлыгына һәм җепнең калынлыгына карап сайланалар. Зур колагы булган кыска энәләрдән файдаланырга киңәш итәм: җеп җиңелрәк үтә.

Уймак тукыманы тишәргә ярдәм итә һәм бармакны тишүдән саклый. Аны уң кулның урта бармагына кияләр.

Линейка яки сантиметрлы тасма - төрле үлчәү эшләре өчен кирәк.

Качыларның зуры (тукымаларны кисү өчен) һәм кечкенәләре (эшче җепнең ахырын һәм башка вак эшләрне кисеп бетерү өчен) булу мөһим.

Киерге тукыманы тарттыру өчен кулланыла .Тартылган тукыма буенча эшләү җиңелрәк, чигү дә пөхтә һәм матуррак була. Сатуда металл, агач һәм пластмасса бoжра бар.

Тукыманы кечерәк бөжрага куялар, тукымага зуррак бөжра салып бөжралар арасына кыстыралар. Шул ук вакытта тукыманың буй һәм аркылы җеп буенча тигез дәрәҗәдә тартылуын күзәтергә кирәк.

Тукымалар. Чигү өчен төрле тукымалар - җитен, киҗе-мамык, йон, ефәк, катнаш туры килә. Крест һәм башка җөйләр белән чигү өчен киндер үрелешле тукымалар куллану яхшырак ,аларда җепләрне санау,йөртү җиңел. Канва буенча чигү бик уңайлы - квадратларга ясалган рәсемле тукымалар. Канва тыгыз һәм сирәк тишекле була. Сирәк тишекле канваны, теләсә кайсы башка тукыма буенча чигү өчен, разметкалы челтәр итеп кулланырга мөмкин..

Крест белән чигү техникасы.

Үзебез чигә торган рәсем схемасын билгелибез. Бизәкләрне карыйк. Интернетта алар шулкадәр күп! Рәсем күләмен билгелик.Вертикаль горизонталь буенча күзләр санын саныйбыз. Канва кырыйларын, яки солге кырыйларын җеп белән тегәбез яки флизелин кулланабыз. Аннан соң канвада үзәкне билгелибез. Моның өчен тукыманы урталай бөклибез, аннары горизонталь буенча һәм үзәкне билгелибез. Киергене рәсем үлчәме буенча сайлыйбыз. Кечкенә түгәрәккә канва салабыз һәм өстән зур түгәрәк белән басабыз.Барлык крест белщн чигелгән өлешләр дә тигез һәм пөхтә булырга тиеш.Чигүдән соң эшне юарга һәм үтүкләргә кирәк. Рамга куярга мөмкин.

3. Анкета

Әлеге теманы тикшереп, мин уйга калдым: башка гаиләләрдә крест белән чигү традициясен үстереп буламы?

Анкетаның максаты: сыйныфташларымның гаиләләрендә нинди традицияләр булуын һәм алар арасында чигүнең нинди роль уйнавын ачыклау.

Анкетада минем сыйныфтагы кызлар катнашты.

1. Гаиләгездә нинди традицияләр бар?

2. Гаиләгездә уртак эшләр бармы?

3. Сез чигүнең нинди төрләрен беләсез?

4. Әниегез яки әбиегез чигү белән шөгыльләндеме?

5. Алар хәзер чигәләрме?

6.Уртак кул эше кешеләрне берләштерергә, аларны дустанә итәргә мөмкин дип саныйсызмы?

7.Сезгә крест белән чигелгән әйберләр ошыймы?

8. Сез крест белән чигә беләсезме?

9. Сез крест белән чигәргә өйрәнергә телисезме?

Мәгълүматларны эшкәрткәндә түбәндәге нәтиҗәләр алынды:

Кызларның җаваплары:

1. Яңа елны каршы алу традициясе, туган көөнәргә бергәләп җыелу, җәй көне шашлыкка чыгу,туганнар белән бергәләп урам әйләнү, шәһәр карау, өстәл артында баянга кушылып җырлар җырлау, бергәләп ашарга пешерү, дөнья гизү, угачлар утырту традицияләре.

2.Азалия-җимлекләр эшләгән, Самира- бергәләп шарф бәйләгәннәр, Злата-яңа елга бизәү әйберләре эшләгәннәр.

3. Крест белән яки крестиклап,чалыштырып чигү төрләрен беләләр.

4. Барлык кызлар да әниләре белән бергәләп чиккәннәр.

5. Барлык кызлар да бүген дә чигү белән мәвыгалар.

6. Барлык кызларны да уртак кул эше кешеләре берләштерә, аларны дустанә итәргә мөмкин дип саный.

7. 6 кызга гына крест белән чигү ошый.

8. 3 кыз бөтенләй крест белән чигә белми.

9. 3 кыз да крест белән чигәргә өйрәнергә телиләр.

Нәтиҗә: гаилә эше заманча гаиләләрдә гадәти шөгыль түгел, әмма хәзер дә крест белән чигүче өлкән буын вәкилләре бар. Димәк, чигүнең бу төре онытылмаган һәм эш тәҗрибәсен яшь буынга тапшырырга мөмкин. Минем сыйныфташларымның да крест белән чигәргә өйрәнү теләге бар.

Мин сезгә үземнең берничә эшемне күрсәтеп китәсем килә.

Нәтиҗә:

Минем эшемнең максаты: гаиләдә кул эшенең бер төре буларак крест белән чигүнең үзенчәлекләрен һәм үсеш тарихын өйрәнү, аның гаиләне берләштерүдәге ролен өйрәнү иде.

Тикшеренү объекты: крест белән чигелгән картиналар һәм сөлгеләр,мендәрләр.

Йомгаклау

Шулай итеп, үткәрнелгән тикшеренү нәтиҗәләре шуны күрсәтте:

1) Крест белән чигү тарихы гасырлар эченә кереп китә. Чигү белән кием-салымны,сөлгеләрне,мендәрләрне бизәгәннәр. Алар матурлык биргәннәр, төрле көчләрдән саклаганнар.

2) Чигү белән шөгыльләнү өчен крест-канвага бүленгән махсус тукыма, шулай ук энәләр, җеп-мулине, бөжралар кулланыла.

3) Минем гаиләнең традициясе– крест белән,чалыштырып чигү. Ул мине әнием, әбием белән якынайта. Бергә утырганда җырлар да җырлыйбыз,сөйләшәбез.

4) Кайбер сыйныфташларымның гаиләләрендә бу эш төре онытылган диярлек, әмма кызлар аны торгызырга телиләр.

Без тамырдан килгән гореф-гадәтләребезне беркайчан да онытмаска тиеш Аларны барлап,саклап үзебезнең балаларга да тапшырырга тиеш.

Кулланылган әдәбият

1.Миронова Т. В., Ермакова С. О., Доброва Е. В. Вышивка крестом. Большая коллекция узоров. – М.: ООО ТД « Издательство Мир книги», 2009

2. 4.Чижик Т. Б. Учим детей вязать и вышивать: Приключения Ниточки и иголочки/ Серия 2 Мир вашего ребёнка». – Ростов н/Д: «Феникс», 2004.

3.Журналы «Вышиваю крестиком» №11, №12, №13 2013 г.

4. Электрон сайтлар:

**youtube.com**›h

**mtsz.tatarstan.ru**

**sfk-mn.ru**

**tatar-congress.org**

*Усманова Мәликә, Алиева Айгөл, 8 сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «37 нче күп профильле лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Усманова Рузилә Рәшит кызы, Хәнәфиева Ләйсән Фәйзехан кызы, туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## Акча дигән хикмәт бар

### Кереш

Үзган ел бакчабызда бәрәңге алганда без иске акчалар таптык. Алар күгәреп беткән һәм пычракка буялган иделәр. Бу тиен акчалар бездә кызыксыну уятты һәм без аларның килеп чыгышын өйрәнә башладык. Музейда, китапханәдә, интернетта материаллар белән танышканда, акчалар кеше тормышында шактый зур урын алып торуын күрдек. Әби-бабаларыбызның аларга карашы халык авыз иҗатында да чагыла. Бүгенге тормышыбызда да алар белән гел эш итәргә туры килә. Кая гына барсак та, нәрсә генә алырга теләсәк тә акчасыз булмый. Акчаны эшләп табу өчен бик күп көч куела, шуңа күрә аның кадерен белергә, саклап тотарга өйрәнергә кирәк, аңа табынырга, бөтен нәрсәдән дә өстен куярга ярамый. Шуңа күрә дә без сайлаган тема **актуаль** дип уйлыйбыз.

Акчалар беренче тапкыр кайчан барлыкка килгән соң? Без тапкан тиеннәр акчалар кайсы вакытларга карый? Халкыбызның акчаларга карашы нинди булган? Бу сорауларга

җавап бирү өчен без эзләнү-тикшеренү эшебезне башлап җибәрдек. Димәк, безнең **максатыбыз:** акчаларның килеп чыгышын, халкыбызның аларга мөнәсәбәтен, кеше тормышында тоткан урынын өйрәнү.

Төп сорауга җавап бирү өчен, без үзалдыбызга берничә **бурыч** куйдык:

1. Акчаларның барлыкка килү тарихы белән танышырга.
2. Табылдыкларыбыз турында мәгълүмат җыярга.
3. Акча, тиен сүзләре кергән татар халык мәкаль-әйтемнәрен тупларга.
4. Бу темага кагылышлы халык ышанулары белән танышырга.

Эзләнү эшенең **төп предметы** акчаларның тарихыбызда, халык иҗаты әсәрләрендә тоткан урыны

**Эзләнү объекты:** акчалар

**Эзләнү методлары:** эзләнү, анализлау, чагыштыру, системага салу.

## 1 бүлек

### 1.1 Акчаларның барлыкка килү тарихы

Акча - кешелекнең иң бөек ачышларының берсе. **Акча – теләсә нинди башка товарга һәм хезмәт күрсәтүгә алмаштырырга мөмкин.** Табигатьтә аңа охшаш әйбер юк. Безнең күбебез акча турында бик аз белә. Күбрәк белер өчен без элек нинди акчалар булуын ачыкладык. Борынгы заманда акчалар булганмы? Бик күп еллар элек акчаның нәрсә икәнен дә белмәгәннәр. Ул моннан 7 мең ел элек туган. Борынгы кешеләр тау куышларында яшәгәннәр, җәнлек тиреләреннән киенгәннәр, табигать нәрсә бирсә, шуны ашаганнар. Кешеләр кирәкле үсемлекләр үстерергә, тимер сугарга, тукыма тугырга өйрәнгәннәр, күп кенә хайваннарны үзләренә ияләштергәннәр. Кемдер үсемлек үстерергә һәм тукыма тукырга, аяк киеме тегәргә оста булган, кемдер йорт төзегән. Кешеләр эшне үзара бүлә башлаганнар. Берәүләр ауга йөргән, икенчеләр терлек үрчеткәннәр, өченчеләр чәчкәннәр, урганнар; дүртенчеләр тимер койганнар һәм башкалар… Кешеләр бер-берсе белән үзара әйберләр алмашканнар. Алар үзләре җитештергән товарларны башкаларныкы белән алыштыра башлыйлар. Чөнки ул заманда сатып алырга акчалар булмаган. Ләкин әйбер бәяләре төрлечә булганга, сәүдә эшендә гел кыенлыклар чыгып торган. Мәсәлән, атны 2 капчык ашлыкка, арбаны - сарыкка алыштырганнар, леопард тырнагыннан ясалган муенсага бер көймә яисә ике үгез сораганнар. Бер сарыкка ике балта яисә дүрт чүлмәк белән түләгәннәр.

Күбрәк төрле товарлар барлыкка килгән саен аларны алмашу кыенлашкан. Беренче акчалар барлыкка килгән. Ләкин акча ролен каурыйлар, хәтта кипкән балык та уйнаган. Мондый товар-акчалар бик җайсыз булган, чөнки алар бозылырга мөмкин, озак саклап булмаган. Диңгез әкәм-төкәме кабырчыклары бозылмаганнар да, йөртү өчен дә

җиңел  булганнар. Аларны тишеп бер җепкә төзгәннәр, муенса кебек ясап йөрткәннәр. Мәсәлән, бер үгез өчен шундый 1000 кабырчык санап биргәннәр.

Күп еллар үткән, тимер акчалар килеп чыккан. Алар да хәзерге акчалардан нык аерылып торганнар. Алар төрле формадагы таяк, бөҗралар булганнар. Борынгы Русьта металл акчалар - көмеш коелмалар-гривналар булган. Әгәр әйбер кимрәк торса, гривнаның бер өлешен чабып өзгәннәр. Кисәкне "рубль" дип йөрткәннәр.Ул русчадан  "рубить"- "чабарга" дигәнне аңлаткан .

Иван  IV заманында сөңге тоткан җайдак сурәтләгән акчалар чыгарганнар. Тиен – КОПЕЙКА (копье-сөңге сүзләреннән килеп чыккан). Шулай итеп тимер акчалар барлыкка килә. Аларны анда төрле символлар - дәүләт гербын  төшергәннәр.  Ләкин аларның да җитешмәгән ягы булган. Алар авыр булганнар һәм күп урын биләп торганнар, мәсәлән, Ломоносов, императрицадан 2000 премия алгач, аны кесәсенә салып кайта алмаган - премия 3 тоннадан артык булган! Ә бу - үзе бер машина. Чит илләрдә сату-алу белән шөгыльләнгән байлар өчен шулкадәр авыр йөк йөртү җайсыз була.

Кешеләр кәгазь акчалар уйлап чыгарганнар. Һәр илнең үзенең аерым тәңкәләре һәм кәгазь акчалары бар. Мәсәлән, Россиядә – сум (рубль), АКШта, Канадада, Австралиядә  - доллар, Европаның күпчелек илләрендә  евро кулланышта.

Герб, башка сурәт, портрет төшерелгән ягы йөзе **аверс** дип, икенче ягында  аның бәясе язылган **реверс** дип атала. Башка язулар **легенда** дип йөртелә.

### 1.2. Безнең табылдыкларыбызның тарихлары

Акчалар тарихы белән кызыксына башлавыбыз юкка гына түгел. Узган ел бакчабызда бәрәңге алганда берничә иске акчага юлыктык. Алар күгәргән, балчыкка буялган иде. Бу акчаларның тарихы безне кызыксындырды.  Без үзебезнең табылдыкларыбыз белән күбрәк танышу өчен интернетка һәм музейга мөрәҗәгать иттек.



Иң иске табылдыгыбыз - 1771 елны чыккан полушка. Ул  Екатеринбургта сугылган. Аның номиналы ¼ тиен. Бакырдан эшләнгән. 4 миллион ярым данәдә чыгарылган. Акчаның аверсында Екатерина патшабикәнең исемен чагылдырган  "I" хәрефе (императрица) һәм II саны сурәтләнгән. Өстә император таҗы рәсеме ясалган һәм як-ягына "17" ,"71" саннары язылган. Акчаның реверсында ат өстендәге Георгий Победоносецның аждаһаны җиңүен сурәтләнгән рәсемен күрәбез. Астарак тасма белән "ПОЛУШКА"  билгесе.

Бу тиен акча 1857 елда ясала. Аверсында Александр патшаның таҗы рәсеме һәм "А" дигән язу бар. Реверсында уртада "КОПЕЙКА" сүзе, аның астында 1857 дип, аннан да астарак Е.М. (Екатеринбург монетасы) дип язылганны күрәбез.




1870 елгы 2 тиенлек акча Санкт-Петербург һәм Екатеринбург шәһәрләрендә сугылган. Кайсы шәһәрдә сугылган булуын астагы язуы күрсәтә: СПБ һәм Е.М. Екатеринбургта 24 млн. экземпляр акча кулланышка чыкса, Санкт-Петербургта 200 мең штук. Санкт-Петербург каласында чыккан тиен акчалар бүгенге көндә раритет булып исәпләнә. Бу акчалар 1867 елгы тиеннәр үрнәгендә сугылган. Акчаның бер ягының уртасында Россия империясенең дәүләт гербы ясалган. Герб өстендәрәк патша таҗы рәсеме. Аверс ягында Мәскәү, Казан, Польск, Киев, Владимирск шәһәрләренең шул чордагы герблары сурәтләнгән. Реверсында "2 копейка" дигән язуны укыйбыз. 2 санының ике ягында йолдыз рәсемен күрергә була. Аскарак үсемлек рәсеменнән түгәрәк орнамент ясалган, аннан да аскарак "С.П.Б." (Санкт-Петрбург) хәрефләре язылган.

1877 елгы 2 тиенлек акча 1867 елгы акчалар үрнәгендә бакырдан сугылган. Тиеннең аверс ягында уртада Россия империясенең дәүләт гербы рәсеме. Ике башлы бөркет, өстәрәк патша таҗы бу акчаны бизи. Шулай ук астарак "МЕДНАЯ РОССІЙСКАЯ МОНЕТА" дигән язу бар. Реверс ягында нокталардан ободок ясалган, аның уртасында "2 КОПЕЙКИ" дип язылган. 2 санының ике ягында йолдыз рәсеме сурәтләнгән. 1877 саны язылган һәм имән, лавр яфраклары белән бизәлгән.




1880 елда чыгарылган 20 тиенлек акчалар 500 пробалы көмештән сугылган. Акчаның аверсында Россия империясенең гербы сурәтләнгән. Герб өстендә патша таҗының рәсеме чагылыш тапкан. Реверсында уртага "20" саны, аның астына "КОПЕЕК" дип язылган. "20" санының ике ягында да йолдызлар, өстендә патша таҗы ясалган. Астында "1880" саны, тагы да астарак "С.П.Б." хәрефләре язылган.

1910 елгы 1 тиенлек тә безнең табылдыгыбыз. 1910 елда чыгарылган 1 тиенлек 1867 елда чыккан тимер акчалар үрнәгендә чыгарылган. Санкт-Петербург акча сугу йортында бакырдан ясалган.



1922 елда Петроград акча сугу йорты 50 тиенлек акчалар чыгара. Алар 900 пробалы көмештән эшләнгән. Авырлыгы 10 грамм, диаметры 26 мм булган. Аверсында герб ясалган һәм «Пролетарии всех стран, соединяйтесь!» дип язылган. Реверсның уртасында “50” дип язылган йолдызны күрәбез. Бу РСФСР гербы сурәтләнгән соңгы акчалар була. Соңрак СССР гербы ясалган тиеннәр чыга башлый.





1932 елда Ленинград акча сугу йорты әйләнешкә күп кенә тимер акчалар чыгара. 20 тиенлекләр нумизматлар арасында зур кызыксыну уята, чөнки аның биш төре бар. Шунысы да кызыклы, аның төгәл тиражы билгеле түгел. Аның аверсында СССР гербы ясалган һәм «Пролетарии всех стран, соединяйтесь!» дип язылган. Реверсында чүкеч тоткан кеше сурәтләнгән һәм 20 тиен дигән язу бар. Тиеннең авырлыгы 3 грамм, диаметры 22 мм





Бөек Җиңүнең 20 еллыгына багышлап 1 сумлык юбилей акчалары чыгарыла. Мондый акчаларның берничә төре ясала. Күп кенә нумизматлар колекциясендә бу тәңкәләр очрасалар да, алар аз санлы акчалар рәтендә йөриләр. Бөек Җиңүнең 20 еллыгына багышланган тәңкәнең авырлыгы 10 граммга якын, диаметры 31 мм. Акчаның аверсында СССР гербы ясалган һәм “ОДИН РУБЛЬ” дип язылган. Шулай ук нокталардан матур итеп түгәрәк сызылган. Реверсында Совет солдатына куелган Берлин шәһәрендәге һәйкәл рәсемен күрергә була.

**1.3. Акча, тиен сүзләре мәкаль һәм әйтемнәрдә**

Бу тиен акчалар турында өйрәнү безгә бик кызыклы тоелды. Бүгенге тормышыбызны акчалардан башка күз алдына да китереп булмый. Алар, кая гына барсак та, нәрсә генә сатып алырга теләсәк тә кирәк. Әби-бабаларыбызның акчаларга булган карашларын белер өчен, без халык авыз иҗатына мөрәҗәгать иттек. Тикшерү барышында без акча, тиен сүзләре кергән мәкаль-әйтемнәр, ышанулар күп булуын белдек.

Иң беренче чиратта, мәкаль һәм әйтемнәр китабын карап чыктык, чөнки аларда ана телебезнең матурлыгы, төгәллеге, байлыгы гәүдәләнә. Без акча, тиен сүзләре кергән 163 мәкаль һәм әйтем таптык. Бу мәкальләрне эшебезнең кушымта бүлегендә урнаштырдык. Акча, муллыкны кем генә яратмый икән. Тик ул байлык ничек килүенә һәм кулланылуына карап, кемгәдер бәхет, кемгәдер киресенчә газап китерә. Халкыбыз мәкальләренән күренгәнчә, байлык бер айлык кына булырга мөмкин, кешене газапларга салуы да ихтимал икән.

*Акча, кысып тотсаң - үлә, йомшак тотсаң - очып китә.*

*Акчаны тоту рәхәт, калдыгын санау кыен.*

*Хәрәм акча кесә тишә.*

*Тиен тәңкәне җыя, тәңкә тиенне җуя.*

*Акча башны ашый.*

*Акча беткәч, ахмак та кесәсен карый.*

*Акча, ничек килсә, шулай китәр.*

Әгәр кеше, акыллы фикер йөртеп, маңгай тире тамызып, дөрес юл белән табылган акчасының кадерен белеп яши икән, байлыгының бәрәкәте дә була.

*Акчага сат, акчага сатылма.*

*Акчаны юләр дә таба, аны тота белергә кирәк.*

*Тирләмичә акча табылмый.*

*Акчаң булса, тота бел.*

*Акчасы акның йөзе ак.*

*Акча кесәдә түгел, башта.*

Шулай итеп, әби-бабаларыбыз, туры юлдан барып, намус белән эшләп тапкан байлыкның кадере булуын, ә җиңел килгән акчаларның бәхет китермәвен әйтеп калдырырга теләгәннәр.

### 1.4. Акчага, байлыкка кагылышлы халык ышанулары

Кулланышка акчалар килеп керү белән халык арасында аларга кагылышлы ышанулар да барлыкка килгән. Акчага, байлыкка кагылышлы халык ышануларын бүгенге көндә дә еш ишетергә мөмкин.

*Чәйнек сызгырып кайнаса – акча керә.*

*Сул кул кычытса – акча керә; уң кул кычытса – акча чыга.*

*Кич кешегә акча бирсәң, бәхет китә.*

*Сумканы идәнгә куярга ярамый, акчаң булмый.*

*Өстәлдән ипи валчыкларын кул белән сыпырып алырга ярамый, акчасызлыкка китерә.*

*Чәй эчкәндә чынаякта көбекләр булса, акча,байлык керә.*

*Өй эчендә сызгырырга ярамый, акчаң булмый.*

*Кич белән идән себерергә ярамый,акчаң чыга.*

*Акчаны уң кул белән бирергә, сул кул белән алырга кирәк.*

Ышанулар - халык күңеленең көзгесе, халыкның уй-теләкләрен, хыял-өметләрен, шатлык-куанычларын гәүдәләндергән әсәрләр. Кеше тормышында нинди генә вакыйгалар булмый. Һәрбер вакыйганы халык алдан ук нәрсәгәдер юрарга тырышкан, күп мәртәбәләр сынаган. Бабаларыбыз якты киләчәккә, байлыкка, муллыкка өметләнгән.

### Йомгаклау

«Акча дигән хикмәт бар» исемле бу эзләнү эшебез өстендә без шактый гына эзлекле эш башкардык. Музейда, китапханәдә булдык, интернетта мәгълүматлар җыйдык, әби-бабаларыбызның мирасы булган мәкаль-әйтемнәр, халык ышанулары белән таныштык. Акча, тиен сүзе кергән мәкаль-әйтемнәрне, ышануларны язып алып тупладык.

Үткән тарихка сәяхәт кызыклы да, катлаулы да эш. Эзләнү эше нәтиҗәсендә без акчаның кешелекнең иң бөек ачышларының берсе булуын белдек. Терек табигатьтә аңа охшаш әйбер юк. Без һәрдаим акчалар белән эш итсәк тә, чынбарлыкта безнең күбебез акча турында бик аз белә. Акчаны табу өчен күп көч куела, шуңа күрә аның кадерен белергә, саклап тотарга өйрәнергә кирәк. Шул ук вакытта акча кешеләрне җинаятькә тартырга, көнләшү, саранлык хисе тудырырга мөмкин икәнен онытырга ярамый.

Димәк, акчаны үз хезмәтең белән эшләп табарга өйрәнергә кирәк. Акчаны саклап тотарга, эшләп табу һәм тотуны намусың белән генә киңәшеп эшләргә тиешбез. Акча – ул кәгазь генә, ә ул яхшылык алып киләме, әллә начарлыкмы - анысы

кешенең акчага карашыннан тора. Дөньяда бернинди акчага да сатып алып булмый торган әйберләр дә шактый күп: сәламәтлек, бәхет, эти-әниләребезнең исәнлеге. Шушы кыйммәтләрнең кадерен белеп яшәргә язсын.

**Кулланылган әдәбият**


1. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. - Казан, "Мәгариф", 1997.
2. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр.-Казан, Тат.кит.нәшр.,1987
3. Гөлбакча. Балалар бакчалары өчен хрестоматия. - Казан: ТКН, 1990. - 254 б.
4. Интернет-ресурслар


***Кушымта***

**Татар халык мәкаль һәм әйтемнәре**

1. Акча җимеше түгел, бакча җимеше.
2. Ярлы булырга акча кирәкми.
3. Акча бакчада үсми.
4. Акча бакыр, санарга такыр.
5. «Акча» дигәнне чукрак та ишетә.
6. Хәрам акча кесә тишә.
7. Чын алтын уттан курыкмый.
8. Юк бул, ярлы бул, кулыңда акчаң булсын.
9. Явым белән җир күгәрер, акча белән ир үңгәрер.
10. Үз акчасы булмаган кеше кесәсендәген санар, ди.
11. Һәр ялтыраган алтын түгел.
12. Акча бездә бер букча, ефәк бездә мунчала.
13. Акчам юк — акылым юк.
14. Акчасын биргән, патшасы үлгән.
15. Анда акча бетсә, коеда су бетәр.
16. Ат башыдай алтын бирсәләр дә кирәкми.
17. Безгә ике тиен — бер акча.
18. Бездәге акчаны тавык та чүпләп бетермәс.
19. Бер акчага йорт та ала, сыер да ала, дөягә дә күз сала.
20. Бер тиен биреп сөйләтеп булмас, ике тиен биреп туктатып булмас.
21. Бер тиен белән керәләр, ярты тиен белән чыгалар.
22. Күзеңә кырып салырга сукыр бер тиен дә юк.
23. Сиңа биргән акчаны багор белән су төбеннән эзләргә.
24. Тишекле бер тиен кебек әйләнеп кайту.
25. Үз бер тиене бер тиен.

26. Акча кадере - беткәч беленер.
27. Акча, кысып тотсаң - үлә, йомшак тотсаң - очып китә.
28. Акча күргәч күзең тонмасын.
29. Акча күрсә, фәрештә юлдан таяр.
30. Акча санаганны ярата.
31. Акча таш астында, таш аждаһа башы астында.
32. Акча тиеннән, сарык бәрәннән үсә.
33. Акчага арыслан сөте дә табып була.
34. Акчага сат, акчага сатылма.
35. Акчалының кулы уйный, акчасызның күзе уйный.
36. Акчалының эше күп, бакчалының ашы күп.
37. Акчаны зурлыйм дип үзеңне хурлама.
38. Акчаны тоту рәхәт, калдыгын санау кыен.
39. Акчаның күзе юк.
40. Акчасы барның сүзе уң, акчасы юкның сүзе соң.
41. Акчасыз торып була, икмәксез торып булмый.
42. Бер тиен акча белән мунча салып булмый.
43. Бер тиен кергән баеган, бер тиен чыккан бөлгән.
44. Берәү акча таба, берәү янчык тага.
45. Ике тиен чыгармый бер тиен кермәс.
46. Ишек йөрткән тупсадыр, эшне йөрткән акчадыр.
47. Кесәңдә йөз мең булса, әтәчкә атланып очып була.
48. Мал колыннан үсә, акча - тиеннән.
49. Тамчы-тамчы күл була, тиен-тиен сум була.
50. Тиген килгән тәңкәдән тир чыгарган тиен артык.
51. Юк акчага янчык текмә.
52. Акча бездә күп түгел, кирәгенә юк түгел, килә тора, китә тора, кирәгенә җитә тора.
53. Акча безне тапмый, без акчаны табабыз.
54. Күзеңә кырып салырга сукыр бер тиен дә юк.
55. Сиңа биргән акчаны багор белән су төбеннән эзләргә.
56. Базар акчаны ярата.
57. Агачак кан тамырда тормый, чыгачак акча янчыкта тормый.
58. Ак акча кара көн өчен.
59. Акча аккош: муенын суза да оча.

60. Акча акчаны таба.
61. Акча алача түгел, өйдә суга алмассың.
62. Акча байныкы, янчык тайныкы.
63. Акча бакчада үсми.
64. Акча бакыр, санарга такыр.
65. Акча барда бар да дус та, бар да яр.
66. Акча башны ашый.
67. Акча белән җүләр дә байый.
68. Акча белән шайтанны да мәчеткә кертеп була.
69. Акча беткәч, ахмак та кесәсен карый.
70. Акча булса, гакыл табылыр.
71. Акча гарипкә тансык.
72. Акча калада кала.
73. Акча кадере — беткәч беленер.
74. Акча кадерен бай белер.
75. Акча кесәдә түгел, башта.
76. Акча кешегә акыл бирә.
77. Акча кешене кешегә ят итә.
78. Акча кешене сикертә.
79. Акча кошы кулдан төшми, кулдан-кулга оча.
80. . Акча күн ягы белән килә, иләк ягы белән китә.
81. Акча күргәч күзең тонмасын.
82. Акча күрсә, фәрештә юлдан таяр.
83. Акча күңел аздыра.
84. Акча — көчсезгә көч, телсезгә — тылмач.
85. Акча, ничек килсә, шулай китәр.
86. Акча санаганны ярата.
87. Акча санаудан туймый, ди.
88. Акча саранны таный.
89. Акча тапканчы исәп тап.
90. Акча тау аркылы юл сала.
91. Акча таш кистерә.
92. Акча тиеннән, сарык бәрәннән үсә.
93. Акча чыкканны ир туймас, тир чыкканны тире тоймас.
94. Акча чыкмый, акча керми.

95. Акча эт түгел — хуҗаны танымый.
96. Акча өчен мулла да намаз боза.
97. Акчага арыслан сөте дә табып була.
98. Акчага мохтаҗ кешегә акыл өйрәтмә.
99. Акчага сат, акчага сатылма.
100. Акчалы сайланыр.
101. Акчалының кулы уйный, акчасызның күзе уйный.
102. Акчалының эше күп, бакчалының ашы күп.
103. Акчалының җаны ике, акчасызның — бер.
104. Акчаны бирәү дә суга атмый.
105. Акчаны зурлыйм дип үзеңне хурлама.
106. Акчаны табуы мең бәла, саклавы ике мең бәла.
107. Акчаны, юлдан тапсаң да, санап ал.
108. Акчаны юләр дә таба, аны тота белергә кирәк.
109. Акчаның дуслыгына ышанма, авыргач та сине ташлый.
110. Акчаның күзе юк.
111. Акчаның күзенә ак төшкән.
112. Акчасы акның йөзе ак.
113. Акчасы барның сүзе уң, акчасы юкның сүзе соң.
114. Акчасы булса, букчасы булыр.
115. Акчасы күп — залим кеше, акчасы юк — галим кеше.
116. Акчасыз торып була, икмәксез торып булмый.
117. Акчасыз эш пешми, ярмасыз бәлеш пешми.
118. Акчасыз ялга туймас, акчалы йокыга туймас.
119. Акчасызның кулы кыска.
120. Акчасын биргәннең сыбызгысы уйнар.
121. Акчаң беткәнгә кайгырма, көчең белән эшең бетмәсен.
122. Акчаң булмаса, кесәң ертыклыгыннан ни зыян.
123. Акчаң булса бер букча, җан тынычлыгы юк ла.
124. Акчаң булса, тота бел.
125. Акчаң булса сөярләр, акчаң беткәч төярләр.
126. Акчаң киттеме дип сорамыйлар, эшең беттеме дип сорыйлар.
*127.* Алты акчам бар — ат алырмын, җиде акчам бар — җир алырмын
128. Ике тиен чыгармый бер тиен кермәс.
129. Тиен — агачтан агачка, тиен кулдан-кулга сикерә.

130. Тиен тәңкәне саклый.

131. Тиен тәңкәне җыя, тәңкә тиенне җуя.

132. Тирләмичә акча табылмый.

133. Эш акчада, гөл бакчада.

134. Юк акчага янчык текмә.

135. Юк бул, ярлы бул, кулыңда акчаң булсын.

136. Явым белән җир күгәрер, акча белән ир үңгәрер.

137. Үз акчасы булмаган кеше кесәсендәген санар, ди.

138. Һәр ялтыраган алтын түгел.

139. Акча бездә бер букча, ефәк бездә мунчала.

140. Акча бездә күп түгел, кирәгенә юк түгел, килә тора, китә тора, кирәгенә җитә тора.

141. Акча безне тапмый, без акчаны табабыз.

142. Акча керсә, уч табанын үбүчән.

143. Акчам юк — акылым юк.

144. Акчасын биргән, патшасы үлгән.

145. Анда акча бетсә, коеда су бетәр.

146. Ат башыдай алтын бирсәләр дә кирәкми.

147. Бездәге акчаны тавык та чүпләп бетермәс.

148. Бер тиен биреп сөйләтеп булмас, ике тиен биреп туктатып булмас.

149. Бер тиен өчен җан сата.

150. Акча бирсәң — аза, кием бирсәң — туза, яхшылык итсәң — барысыннан да уза.

151. Үз акчасы булмаган кеше кесәсендәген санар, ди.

152. Безгә ике тиен — бер акча.

153. Хәрам акча кесә тишә.

154. Акча таш астында, таш аждаһа башы астында.

155. Малай кулына акча керсә, көчек сатып алыр.

156. Юк акчага янчык текмә.

157. Хәзрәтеңә хәзер акча, җитмәгәненә бакыр акча.

158. Акчаны чөйгән саен кошлы ягы төшмәс.

159. Акчаның башы — аһ , соңы — чаһ .

160. Акча аккош: муенын суза да оча.

161. Акча — санаулы, акчалы — танаулы.

162. Акча белән җүләр дә байый.

163. Кешенең мең тәңкәсеннән үз бер тиенең яхшы.

*Фәзуллина Илина, 7 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре «Адымнар - Түбән Кама «полилингваль гимназиясе " муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Ялалова Зөлфия Фаел кызы,*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**ЭЧТӘЛЕК**

КЕРЕШ
I БҮЛЕК. Төп өлеш
1.1 Нәрсә ул шигырь, нинди шигырьләр була?
1.2 Шигырь төзелеше
II БҮЛЕК. Практик өлеш
2.1 Үзем иҗат иткән шигырьләр
ЙОМГАКЛАУӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

**Кереш**

**“Шигырьне язалармыни? Шигырь белән яшиләр...**
**дөресрәге, ул үзе җаныңда бер изге зат булып яши.**
**Аңа бернинди аерым вакыт та, махсус шартлар да**
**кирәкми “ –дип язган Хәсән Туфан.**

Аның белән килешмичә мөмкин түгел.Мин шигырьләр укырга бик яратам. Шигырьләргә карата булган мәхәббәтем балачактан килә. Кечкенә чактан ук матур шигырьләр тыңларга ярата идем. Үсә төшкәч аларны үзем укырга, ятларга өйрәндем.Сонрак, күңелемә якын шигырьләрне өйрәнеп, бик күп шигырь конкурсларында катнашып, призлы урыннарга лаек булдым.

Гадәттә, шигырьләр хикәяләрдән кыскарак була. Шушы кыска гына шигырьләрдән дә авторның уйларын, сөйләгәннен һәрвакыт ачык күз алдына китерергә момкин. Шигырьләр кешеләрне елаталар да, юаталар да, тәрбиялиләр дә. Шигырьләрне прозага караганда өйрәнү җиңелрәк. Беркөнне күңелемдә шундый уй туды.Кызык, шигырьләр язарга өйрәнеп буламы икән? Шигырьләрне нәрсә үзенчәлекле итә? Мин, шигырьләрнең уртак яклары бармы-юкмы, дип, тикшеренүне үткәреп, шигырь язарга өйрәндем.

**Тикшеренү эшенең максаты**: шигырьләрнең ничек тууын белергә, аларның нинди кагыйдәләр буенча язылуын ачыкларга.

**Тикшеренү эшенең бурычлары:**

1. Шигырьләрнең нәрсә икәнен, нинди шигырьләр булуын ачыкларга;

2. Шигырь төзелешен өйрәнергә;

3. Шигырь иҗат итеп карарга.

**Тикшеренү эше барышында башкарылган эшләр**:

- энциклопедия, фәнни белешмә, төрле авторларның шигырьләрен тикшерү, тема буенча әдәбиятны укыдым; үзем шигырьләр иҗат иттем.

**Фәнни эшнең структурасы**: Фәнни эш керештән, төп өлешнең ике бүлегеннән, йомгаклау һәм кулланган әдәбият исемлегеннән тора.

## I БҮЛЕК. Төп өлеш

### 1.1 Нәрсә ул шигырь, нинди шигырьләр була?

Нәрсә ул шигырь? Шигырь ничек туа? Кем соң ул шагыйрь? Үземнең тикшерү эшемне әлеге сорауга җавап эзләүдән башладым. Әлбәттә, әлеге сорауга җавап табар өчен фәнни китаплар,энциклопедияләр укыдым.

Шигърият-сүзләрнең гади сөйләмгә хас булмаган рәвештә ритмы, яңгырашы буенча билгеле бер тәртипкә китерелгән хәле. Сүзләрне шундый хәлгә китерүгә нигезләнгән нәфис әдәбиятның бер тармагы.Шигърият үз эченә лирика һәм лиро-эпик әдәби төрләрне берләштерә. Шигырь - тезмә формага салынган, сүзләр, иҗекләр ритм таләбенә ярашлы итеп урнаштырылган әдәби әсәр.

Шагыйрь - шигырь язучы, шигърият белән шөгыльләнүче кеше. Ул хис- тойгыга бай кеше. Шигырь язу өчен хис- тойгы кирәк. Хис- тойгылар нинди булырга мөмкин? Патриотизм, соклану, ярату, горурлану, бәхет, сагыш, шатлану, югалту, мәхәббәт, нәфрәт - болар кешеләрдә була торган хис-тойгылар. Нәкъ менә әлеге тойгылар гүзәл шигырьләр иҗат итәргә мөмкинлек бирә дә инде.

Шигырьләр нинди булалар соң? Алар күләменә карап кечкенә һәм зур булырга мөмкин. Шулай ук шигырьләр темалары, язылу стильләре белән дә бер-берсеннән аерылып торалар.Шагыйрьләр шигырь язганда кулланыла торган, иң еш очрый торган темалар алар: «Туган ил”, “Мәхәббәт һәм нәфрәт”, “ Сугыш һәм тынычлык”, “Ел фасыллары”, “Табигать”, “Ярату”. Тагын шигырьләрдәге кайбер кагыйдәләрне белү бик мөһим:

### 1.2 Шигырь төзелеше.

Шигырь төзелеше- ритмик яктан оешкан һәм үлчәмгә салынган, шигъри сөйләм системасы. Шигырь – строфа,рифма, ритм, үлчәмнән тора.

Нәрсә ул строфа? Строфа - ритм ярдәмендә оешкан тезмәләр бәйләме. Татар шигыре, нигездә, 2, 4, тезмәле строфалардан тора. Сирәк кенә 5, 6, 7, 8 тезмәле строфалар да очрый.

Рифма нәрсә ул? Ритмик төзелеше бердәй тезмәләр ахырында аваздаш кабатлаулар яки охшаш яңгырашлы сүзләр. Рифма 2, 3, 4, 5 тезмәне бербөтенгә әйләндерә.

Нинди рифма төрләре бар?

Татар сүзләренең нечкә һәм калын әйтелешенә карап, рифма:

- Нечкә әйтелешле, калын әйтелешеле
- Рәдифле
- Катлаулы (вакыт белән – йакут берлән, һәр ягы – тау ягы),
- Гади (тамчысы – илһамчысы, театр – император)
- Төгәл (мәйдан – кайдан, уйнатадыр- уйлатадыр)
- Ябык
- Ачык
- Омонимик

Ритм – нәрсә ул? Ритм - сөйләм берәмлегенең тигез вакыт аралыгында кабатланып, чиратлашып торуы.

Шулай ук, сүрәтләү чаралары, троплар һәм стилистик фигуралардан башка да матур әдәи әсәрләр тудыруы мөмкин түгел. Тагын шуны билгеләп үтәргә мөмкин: шигырьдә текст җөйләре рифма белән чикләнгән, сүзләр ирекле түгел, бәлки ритм тудырырлык итеп урнаштырыла һәм сайлана, ритм бәрмә һәм басымсыз иҗекләрнең чиратлашып барлыкка килә, авторның тормышы, тәэсирләре, уйланулары шигырьләр язуга сәбәп булып тора, автор укучының хыялында образлар тудыра, рәсем-тәэсирле чаралар ярдәмендә кәефне тапшыра, һәр шигырьнең дә шигъри сөйләм билгеләре юк, шигырь кагыйдәләрен аерып күрсәтергә һәм белергә мөмкин, ләкин бу белемнәр чын шагыйрьләр кебек шигырь иҗат итәргә мөмкинлек бирми, бары тик ярдәм генә итәләр.Димәк, шигырь язу өчен мәгънәгә дә,эчтәлеккә дә,үлчәмгә дә, сүрәтләү чараларына да игътибар итәргә кирәк.Минемчә шигырь язу түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш: шигырьләр шигырь төзелешенә туры китерелеп язылырга тиеш. Ритм, рифма структураларын һәр язылган шигырьдә саклануы мөһим. Әмма рифма төзибез дип шигырь мәгнәсенә туры килмәгән һәрбер сүзне кулланып язу бик урынсыз. Рифма куллану бик зур осталык таләп итә, шуның өчен күбрәк шигырьләр укырга, даими язышып торырга кирәк. Ләкин ритм, рифма гына шигырь ясамый әле, һәрбер шигырьдә автор үз хисләрен, фикерен әйтеп бирергә тиеш, шул ук вакытта һәрбер шигырь укучыга нindидер яңалык әйтеп бирергә тиеш. Чын йөрәктән чыккан шигырь генә башка йөрәкләрне тетрәндерә ала һәм уйланырга мәҗбүр итә ала. Шушы таләпләргә туры килгәндә генә шигырь укучылар күңеленә хуш килер.

## II БҮЛЕК ПРАКТИК ӨЛЕШ

### Туган тел

Төн утырып шагыйрь шигырь язды.
Чираттагы булды «Туган тел»
Күңеленнән генә әйтеп куйды,
Әй, син, кеше, аның кадрен бел.
Күңеленнән генә шундый сүзләр,
Кат- кат түгелде дә, түгелде.
Ә каләме һаман яза бирде.
Бүлмә эче нурга күмелде.
Иң зур теләк, иң зур ышанычы
Туган теле атсын гел чәчәк.
Татар теле мәңге бетмәячәк,
Аннан тора алгы киләчәк!
Шулай уйланыла- уйланыла,
Соңгы сүзләр төште кәгазьгә.
Чын күңелдән ышанды яшь шагыйрь
Татар теле яшәячәгенә.
И туган тел, и матур тел диеп,
Күпләр әле сөйләп йөрерләр.
Шундый телне башка халыклар да,
Үз итәрләр, якын күрерләр.
Төн утырып шагыйрь шигырь язды.
Чираттагы булды «Туган тел»
Күңеленнән генә әйтеп куйды.
Әй, син, кеше, телнең кадрен бел!

### Туган телем

Сорасалар, кем ул укытучың,
Күрсәтүчең җирне, илләрне?
Зур горурлык белән туган телем
Кабатлармын синең исемне.
Сорасалар, кем ул тәрбиячең
Үстерүчең назлы гөлләрне?
Татар телем булды гомер буе

Уятучым язгы бөрене.

Сорасалар, зур шатлыгың нидә,

Дөнья күрү, илләр гизүме?

Башым иеп тыныч кабатлармын:

“Саклый алсам туган телемне!”

Ялкынланып шулчак әйтермен мин

Татар телем-моңлы бишегем.

Син укыттың, бирдең тәрбияне,

Ачтың миңа дөнья ишеген.

**Әниемә**

Бар рәхмәтем, бар хөрмәтем, Чиксез ярату сиңа.

Тәүге көннән багышладың, Күңел җылыңны миңа.

Төн йокыңны йокламыйча, Бишек җырын көйләдең.

Үсә төшкәч, әкиятләр, Хикәяләр сөйләдең

Син һәрвакыт миңа, әни, Карадың өмет белән Ышанычың аклар өчен Булган көчемне түгәм.

Өмет уты сүнгән чакта, Маяк булдың син миңа

Бар рәхмәтем, бар хөрмәтем, Сиңа, әнием, тик сиңа.

**Ак каен**

Ак шәл ябынган, ак бөдрә каен

Басып тора мәктәп юлында.

Барганда да моңсу каршы ала,

Кайтканда да шул ук булып кала.

Ниләр булды сиңа, ак бөдрә каен

Нигә шулай моңсу торасың?

Шундый матур, зифа буең белән

Елмай, елмай син, каен!

**Шырпы белән уйнама**

Бер авылда яшәгән ди,

Бик тыңлаусыз бер малай.

Шырпы белән ул уйнаган

Тәртипсез булган шулай.

Менә беркөнне булай

Шырпы белән уйгаган,

Әтисенә күренмим дип,

Салам артына качкан.

Салам дөрләп янып киткән,

Малай бик нык курыккан!

Әтисенә әйткән аннан:

“Бүтән уйнамыйм алай!”

**Апама**

Апам минем терәгем Апам минем яклаучым Апам минем киңәшчем Җил -давылдан саклаучым Мин дә терәк булырмын Апам сиңа һәрвакыт Нинди генә мизгелдә дә Табармын сиңа вакыт.

**Габдулла Тукай**

1. Күпме еллар үткән, сулар аккан

   Киткәнең синең бу җирдән.

   Еллар сине аерса да бездән,

   Сагына сине, Тукай, бар галәм!

2. Һәркемгә дә язылмагандыр ул,

   Синдәгедәй моңлы язмышлар.

   Бар кеше дә, синдәй булсын иде,

   Кабатланмасыннар ялгышлар.

3. Җырлап киттең безнең аралардан,

   Илаһи бер моң, сер булып.

   Синең гомерең, әйтерсеңлә, Тукай,

   Күктә ялтыраган бер йолдыз.

4. Шагыйрь булып туган соң син, Тукай

   Күпме шигырь, әсәр язгансың.

   Туган илең, татар теленә син

   Мәңге тугъры булып калгансың.

5. Синең гомерең, синең язмышың ул

   Мирас, маяк булыр яшьләргә!

   Еллар үтәр, килер алар сиңа

   Һәм таяныр синең киңәшләргә.

6. Ышан, Тукай, халкың онытмас сине!

## Йомгаклау

Тикшеренү барышында мин әдәби чыганаклар, белешмә әдәбияты белән таныштым, гамәли эш башкардым һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килдем: шигырьләр шигырь төзелешенә туры килеп язылырга тиеш. Ритм, рифма структураларын һәр язылган шигырьдә саклануы мөһим. Әмма рифма төзибез дип шигырь мәгнәсенә туры килмәгән һәрбер сүзне кулланып язу бик урынсыз. Рифма куллану бик зур осталык таләп итә, шуның өчен күбрәк шигырьләр укырга, даими язышып торырга кирәк. Ләкин ритм, рифма гына шигырь ясамый әле, һәрбер шигырьдә автор үз хисләрен, фикерен әйтеп бирергә тиеш, шул ук вакытта һәрбер шигырь укучыга ниндидер яңалык әйтеп бирергә тиеш. Чын йөрәктән чыккан шигырь генә башка йөрәкләрне тетрәндерә ала һәм уйланырга мәҗбүр итә ала. Шушы таләпләргә туры килгәндә генә шигырь укучылар күңеленә хуш килер дип уйлыйм.

Тикшернү эше барышында алган белемнәр миңа шигырьләрне яхшырак аңларга, туган телемнең матурлыгын һәм байлыгын тоярга ярдәм итәчәк.

Шигырьләр язу теләгем сүрелмәде, гәрчә мин моның җиңел түгеллеген аңласам да.

Киләчәктә дә талантлы шагыйрьләрнең шигырьләрен укырмын һәм янәшәмдә булган матур күренешләр, кызыклы вакыйгалар яңа иҗат җимешләре тудырырга ярдәм итәр дип уйлыйм.

## Кулланылган әдәбият


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: ―Мәгариф, 2007.
2. Әдәбият белеме сүзлеге. Төзүчесе: А.Г.Ахмадуллин.—Казан: Тат. китап нәшр., 1990.
3. Бариева Э. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть. // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда.− Казан: Тат. китап нәшр., 1989.− Т.4.
4. Галиуллин Т. Хәзерге шигърият // Мирас. – 1996. – № 7-8.



*Фәсхетдинова Диләрә, 11 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре*
*Муса Җәлил исемендәге «1нче гимназия»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү*
*учреждениесе*
*Җитәкчесе: Хәйруллина Гөлназ Рәшит кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


## «Чәкчәкле сәйлән» проекты

### Эчтәлек


| | |
|---|---|
| 1. | Кереш |

| | |
|---|---|
| 2. | ЮНЕСКО мәдәни мирас сагында |
| 2.1. | Татарстанда ЮНЕСКО объектлары: нәрсә карарга һәм ничек барып җитәргә |
| 3. | «Акыл фабрикасы»нда чәкчәк рецептын ЮНЕСКО объекты итү турында фикерләштеләр... |
| 3.1. | Чәкчәктә тарихның чагылышы |
| 3.2. | Күрсәтмәлек-китап |
| 3.3. | Әй Болгарым, сиңа тарта уйларым |
| 3.4. | Зөя – утрауда салынган кала |
| 3.5. | Утларыңа, Казан, карыйм кат-кат |
| 4. | Йомгаклау |
| 5. | Кулланылган әдәбият |


## КЕРЕШ

**Бурыч**: татар мәдәниятенә кызыксынуны арттыру, мәдәни мираска ихтирам тәрбияләү.

**Максат**: Рәсәйдә һәм чит илдә татар мәдәниятен пропагандалау; үсеп килүче буында аңа карата мәхәббәт уяту; мәдәни объектларга карата сакчыл караш үстерү.

**Тикшерү объекты**: ЮНЕСКОга кергән мәдәни мирас, милли ризык – чәкчәк.

**Актуальлек:** татар халкының милли ризыгы чәкчәк ашап була торган әйбер генә түгел, ә тулы бер мәдәният. Аның аркылы без Татарстанга килгән кунакларга үзебезнең милли мәдәниятнең бер кисәген биреп җибәрә алабыз.

**Гипотеза**: проект белән танышканнан соң, Татарстан кунакларында, туристларда мәгълүмат арта, Татарстан һәм татар халкы белән кызыксыну уяна.

## ЮНЕСКО МӘДӘНИ МИРАС САГЫНДА

ЮНЕСКО Берләшкән Милләтләр Оешмасының мәгариф, фән һәм мәдәният мәсьәләләре буенча учреждение булып тора һәм бу өлкәләрдә халыкара хезмәттәшлек аша тынычлык урнаштырырга омтыла. ЮНЕСКО программалары 2015нче елда БМО Генераль Ассамблеясе тарафыннан кабул ителгән 2030нчы елга кадәрге чорга көн тәртибендә билгеләнгән тотрыклы үсеш максатларына ирешүгә ярдәм итә.

Оешма тарафыннан игълан ителгән максатлар — дәүләтләр һәм халыкларның мәгариф, фән һәм мәдәният өлкәсендәге хезмәттәшлеген киңәйтү хисабына тынычлыкны һәм иминлекне ныгытуга ярдәм итү; гаделлекне һәм законлылыкны саклауны, Берләшкән Милләтләр Оешмасы уставында игълан ителгән кеше хокукларын һәм төп ирекләрен бөтен халыклар өчен, раса, җенес, тел, ориентация яки дин аермасысыз тәэмин итү.

Оешма 1945нче елның 16нчы ноябрендә оештырыла, аның штаб-фатиры Парижда, Франциядә урнашкан. Хәзерге вакытта оешмада 193 әгъза-дәүләт, 2 күзәтүче-дәүләт һәм тышкы сәясәт өчен җаваплы булмаган 10 ассоциацияләнгән әгъза-территория бар. 182 әгъза дәүләтнең Парижда оешма каршында даими вәкиллеге, шулай ук 4 даими күзәтүче һәм хөкүмәтара оешмаларның 9 күзәтү миссиясе бар. Оешма составына дөньяның төрле өлешләрендә урнашкан 60тан артык бюро һәм бүлекчә керә. Оешма эшчәнлеген үз эченә алган мәсьәләләр арасында: мәгариф проблемалары; милли мәдәниятләрне өйрәнү һәм милли кадрлар әзерләү; социаль фәннәр, геология, океанография һәм биосфера проблемалары.

1948нче елдан оешма «ЮНЕСКО Курьеры» журналын чыгара, хәзерге вакытта ул ун телдә чыга һәм онлайн рәвештә иректе рәвештә кулланыла.

Эшчәнлекнең төп юнәлешләре биш программа секторында:

- мәгариф,
- табигый фәннәр,
- социаль һәм гуманитар фәннәр,
- мәдәният,
- коммуникация һәм мәгълүмат.

Шулай ук барлык юнәлешләрнең бер өлеше булган берничә төп тема бар. ЮНЕСКО эшчәнлегенең төп принцибы кешеләр арасында аралашу чаралары санын үстерү һәм арттыруга ярдәм итү һәм бу чараларны үзара аңлашуга һәм бер-берсенең тормышы турында ышанычлырак һәм камилрәк белемнәргә ирешү өчен куллану.

Хәзерге вакытта оешмада 193 әгъза дәүләт, 11 ассоциацияләнгән дәүләт һәм 2 күзәтүче Дәүләт (шулай ук 10 халыкара күзәтүче оешма) бар. Лихтенштейннан тыш, БМОның барлык әгъзалары ЮНЕСКО әгъзалары булып тора. БМОда тулы хокуклы әгъзалыктан аермалы буларак, ЮНЕСКО әгъзасы халыкара танылган дәүләтләр булырга тиеш түгел. Мәсәлән, ЮНЕСКО әгъзалары булып Кук утраулары, Ниуэ һәм өлешчә танылган Палестин автономиясе тора, ул бары тик БМО күзәтүчесе генә. 2017нче елның 12нче октябрендә АКШ һәм Израиль ЮНЕСКОдан чыгу турында белдерәләр, үз карарларын оешманың Израильгә каршы позициясе белән мотивлаштыра. ЮНЕСКО уставына ярашлы, бу илләр оешманың тулы хокуклы әгъзалары булып 2018нче елның 31нче декабренә кадәр кала. Бу көннән соң АКШ оешма эшендә күзәтүче дәүләт буларак катнашуын дәвам итә.

## ТАТАРСТАНДА ЮНЕСКО ОБЪЕКТЛАРЫ: НӘРСӘ КАРАРГА ҺӘМ НИЧЕК БАРЫП ҖИТӘРГӘ

Татарстан – бай тарихлы төбәк. Республика территориясендә ЮНЕСКОның өч Бөтендөнья мирасы объекты бар: Казан Кремле, Болгар шәһәренең археологик комплексы, Зөя утравындагы Успение соборы.

Татарстанда ЮНЕСКО исемлегенә беренче булып **Казан Кремле** керде.

Бу 2000нче елда Австралиянең Кэрнс шәһәрендә ЮНЕСКОның XXIV сессиясендә булды. Моның өчен өч критерий нигезләнгән: Казан Кремле дәвамлылык һәм мәдәни төрлелек күрсәтә. Үзенең бөтен яшәеше дәвамында төбәкнең сәяси хакимияте үзәге булып тора һәм рус һәм татар мәдәнияте бердәмлеген тәкъдим итә. Бу безнең көннәргә кадәр килеп җиткән Идел буе татарларының бердәнбер ныгытмасы, Казан Кремле архитектурасында төрле чорлардагы татар һәм рус архитектурасы үзенчәлекләре бар.

Кызык, Кремльне ЮНЕСКОга кертү белән бәйле иң зур катлаулылык тарихи һәйкәл территориясендә хәзерге мәчет булу белән бәйле. Бу факт дөрес һәм логик нигезләүне таләп итә. Кол Шәриф мәчетен төзү сәяси сәбәпләр белән аңлатыла. Казанда 1552нче елда шәһәрне Явыз Иван гаскәрләре яулап алганда һәлак булган Рус сугышчыларына һәйкәл бар. Ә менә шәһәрне яулап алган вакытта һәлак булган татарларга багышланган мемориаль объект булмаган. Төзелгән мәчет бу мәсьәләдә тигез хокукларга ирешергә мөмкинлек бирә, шуңа күрә ул үз шәһәрен саклаган һәм һәлак булган имам Кол Шәриф хөрмәтенә аталган. Моннан тыш, Кол Шәриф ул вакытта шәһәр территориясендә урнашкан үзәк мәчетнең башлыгы була. Нәкъ менә аның кыяфәте хәзерге мәчеттә торгызылган.

ЮНЕСКО исемлегендә номеры: 980

Объект турында язма ЮНЕСКО сайтында: https://whc.unesco.org/en/list/980

## БОЛГАР

Ул 2014нче елда Доха шәһәрендә (Катар) ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән. Болгар Идел буе Болгариясенең борынгы башкаласы, монда 922 елда ислам рәсми дин дип игълан ителгән. Бу Русь чукындыруыннан 66 ел алдарак булган.

Болгар ЮНЕСКО тарафыннан саклана, чөнки ул төрки, фин-угор, славян мәдәниятләре һәм традицияләренең үзара йогынтысы һәм кушылуының ачык мисалы. Бу шул исәптән сакланып калган корылмалар архитектурасында да чагылыш таба; традицияләр һәм ышанулар дәвамлылыгы урыны 922нче елдан ул бөтен Евразиядә Исламның иң төньяк таралу ноктасы буларак билгеле булган мөселман үзәге.

Шунысы игътибарга лаек: беренче заявкада Болгарның Идел буе болгарларының уникаль объекты булуына басым ясала, әмма экспертлар башкача фикер йөрткәннәр: Болгар анда сакланган Болгар мәдәнияте белән генә түгел, ә төрле чорлардагы берничә цивилизация эзләре белән дә кыйммәтле.

ЮНЕСКО исемлегендә номеры: 981

Объект турында язма ЮНЕСКО сайтында: https://whc.unesco.org/en/list/981

**ЗӨЯ ШӘҺӘРЧЕГЕ**

Бу Татарстан территориясендә ЮНЕСКОның өченче объекты (2017нче елда Краков шәһәрендә (Польша) ЮНЕСКОның 41нче сессиясендә игълан ителгән). Төп аргументлар түбәндәгечә: Успенский соборы – Евразиядәге эре сәяси процессларның, шул исәптән Явыз Иван җитәкчелегендәге рус дәүләтенең көнчыгышка киңәюенең ачык шаһиты. Собор архитектурасы христиан һәм мөселман үзенчәлекләрен, ә рәсеме православие һәм Көнбатыш Европа традицияләрен күрсәтә. Собор фрескалары – XVI гасырның фрескалы Көнчыгыш рәсем сәнгатенең тулы сакланып калган ансамбленең сирәк үрнәге. Кызык, башта ЮНЕСКОга кертү өчен Успений соборын түгел, ә утрау-шәһәрчекнең бөтен территориясен әзерләгәннәр, әмма экспертлар сессия узганчы ук әлеге гаризаны хуплау мөмкинлегенә шикләнәләр. Сәбәбе: утрауда тарих белән бәйле булмаган күп кенә заманча корылмалар бар, һәм утрау үзе дә башта утрау булмаган, Куйбышев сусаклагычы төзелгәннән соң XX гасыр уртасында гына барлыкка килгән. Шуңа бәйле рәвештә, гариза Успенский соборы һәм монастыре итеп үзгәртелә.

ЮНЕСКО исемлегендә номеры: 1525

Объект турында язма ЮНЕСКО сайтында: https://whc.unesco.org/en/list/1525

**«АКЫЛ ФАБРИКАСЫ»НДА ЧӘКЧӘК РЕЦЕПТЫН ЮНЕСКО ОБЪЕКТЫ ИТҮ ТУРЫНДА ФИКЕРЛӘШТЕЛӘР...**

«Акыл фабрикасы» белем бирү форумының бер чарасында чәкчәк ясау рецептын ЮНЕСКО объекты итү буенча киңәшләр яңгырады. Казанның «Смена» заманча мәдәният үзәгендә «Акыл фабрикасы» белем бирү форумының «Мәдәният һәм урбанистика» темасына багышланган чаралар үтә. Шуларның берсе – «Шәһәрнең үзенчәлегенә яңача караш» темасына оештырылган воркшоп. (Воркшоп — инглизчәдән workshop — остаханә, практик юнәлешле өйрәтү чарасы). Башта лекторлар мәдәнияткә бәйле шәһәрне ничек җиһазландырып булуын аңлатты. Алар Казандагы «Чәкчәк» музее, Татар хатын-кызлары турында экскурсия, үз эченә Кыйссаи Йосыф турындагы операны алган экскурсия хакында фикерләште. «Чәкчәк музее» җитәкчесе Алинә Казанда урнашкан музей турында сөйләде. Әлеге музейның туристлар арасында популяр булуын, аларда экскурсиядән тыш чәкчәк ясау буенча мастер-класслар оештырылуын да әйтте. Тыңлаучылар белән фикер алышу башлангач, бер ханым «Чәкчәк ясау рецептын ЮНЕСКОга кертү буенча берәр эшләр алып барыламы?» — дип сорады. «Бу эшләр инде күптәннән алып барыла, тик ЮНЕСКОда әлегә бу фикерне кабул итмиләр. Бәлки, без чәкчәк турында фильм төшергәч, без аның ашап була торган әйбер генә түгел, ә тулы бер мәдәният икәнен күрсәткәч, аларның фикере

үзгәрер», — диде музей җитәкчесе. Алар үзләренең YouTube каналы өчен чәкчәк турында фильм төшерергә тели.

Соңыннан лекция тыңлаучыларга үзләренең проектларын булдыру турында фикер алышырга тәкъдим иттеләр. Аларны өч төркемгә бүлделәр, шулай итеп, «Акыл фабрикасы» лекцияләренә килгән кешеләр үзләре дә төрле проект идеяләрен тәкъдим итеп карады.

“Акыл фабрикасы”ндагы фикерләшүне күргәннән соң, “Чәкчәкле сәйлән” проекты күз алдыма килде. Бу икеяклы файда бирә: беренчедән, татар халык милли ризыгы популярлаша, икенчедән, ЮНЕСКОга кергән мәдәни объектлар турында мәгълүмат бирелә.

## ЧӘКЧӘКТӘ ТАРИХНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

**Чәкчәк** — татар халкының бәйрәм ризыгы, камыр ашы. Эрбет яки урман чикләвеге зурлыгында кисәкләп, кайнап торган майда пешерелә һәм кайнар бал белән катырыла. Туй өчен чәкчәк зур итеп ясала, өстенә вак-вак кәнфитләр куела. Камырны токмач шикелле кисеп ясалган төре – "Бохар кәләвәсе" дип атала.

Чәкчәк – милли татар ризыгы, шулай ук башкортларның, казакларның һәм кыргызларның милли ризыгы; бу баллы камырдан ясалган татлы ризык. Чәкчәк-татар халкының мөһим матди булмаган мирасы. Ул үзенең якты төсе белән кояшны, ябыштырылган формасы белән татар халкының кунакчыллыгын, дуслыгын һәм бердәмлеген символлаштыра дип санала.

Бер версия буенча, чәкчәк беренче тапкыр Урта Азиянең күчмә халыкларында барлыкка килгән. Легенда буенча, ул Идел буе Болгарстанында барлыкка килгән. Болгар ханы улының туенда өстәлдә моңарчы күрелмәгән сыйлар булуын таләп итә: ул озак бозылмаска, җигүле атта ашау өчен уңайлы булырга, шул ук вакытта, чит ил кунаклары сокланырлык һәм озак истә калырлык итеп тәмле булырга тиеш. Аш-су осталары озак бәхәсләшкәннәр, ахыр чиктә, бер көтүченең хатыны ханга бал белән мул итеп сугарылган он һәм йомыркадан ясалган токмач бүләк иткән. Хан сынап карый һәм елый. Ул үзенең варисына хатыны белән мөнәсәбәтләренең бер массада бер-берсенә ябыштырылган чәкчәк кисәкләре кебек нык булуын һәм аларның тәм-томнарында булган борчак зурлыгындагы төш кадәр балалары булуын теләгән.

Чәкчәк – традицион туй ризыгы, ул башка тантаналы очракларда да әзерләнгән. Аны әзерләү традициясе булган: кызлар камырны тәгәрәткәннәр һәм кискәннәр, кияүдә булган яшь хатын-кызлар кыздырганнар, ә иң өлкән буын бал белән катырган һәм әзер ризыкка форма биргән. Чәкчәк гадәттә зур яссы тәлинкәдә тау кебек өелгән.

Татарстанның төрле районнарында чәкчәкне төрлечә пешерергә мөмкиннәр. Казан артындагы районнарда «чикләвекләр» еш кына кечкенә һәм озынча булса, Татарстанның

көньяк-көнчыгышында алар шактый зур була. Кайвакыт бавырсак формасында яки түгәрәк була.

Чәкчәк якынча 90 көн саклана. Аны кисеп, яисә кечкенә кисәкләрен аерып ашыйлар. Чәкчәк бик калорияле, шуңа күрә аны кечкенә күләмдә ашарга кирәк. Балның күп булуы аркасында, аз күләмдә чәкчәк бик файдалы.

Хәзер чәкчәк – көндәлек ризык, аны Татарстанның азык-төлек кибетләрендә табарга мөмкин. Чәкчәк сувенир бизәлешендә киң таралган.

Дөньядагы иң зур чәкчәк Казанда 2018нче елда Футбол буенча дөнья чемпионаты ачылышына әзерләнгән иде. Ул футбол тубының яртысы формасында булган. Тупның диаметры 2,6 м, биеклеге 2 метр, теркәлгән авырлыгы 4026 килограмм тәшкил итә.

2019нчы елда «Изге Болгар җыены» бәйрәмендә Болгарга 250 кг авырлыктагы мәчет рәвешендә чәкчәк алып киләләр һәм теләгән һәркемгә бушлай тараталар. Бу чәкчәкне Әлмәт икмәк заводы булдырган. Чәкчәккә 1 меңгә якын йомырка, 50 кг бал, 60 кг он һәм 200 литр көнбагыш мае киткән.

Милли ризык буларак чәкчәкне һәм мәдәни мирасларны кушу идеясе миндә “Акыл фабрикасы” фикерләрен укыганнан соң туды. Татарстанга килгән кунакларга, туристларга милләтебезнең “мәдәни кисәге”н биреп җибәрү өчен бу бик әйбәт күчтәнәч булып тора. Шартлы рәвештә өч кисәккә бүленгән чәкчәктә ЮНЕСКОга кертелгән өч мәдәни объект урын ала. Килгән кунаклар тәмле чәй ризыгы белән генә тукланып калмыйлар, ә шул ук вакытта мәгълүматлы да булалар. Әлеге “тарихлы чәкчәк”не туристлар күп була торган урыннарга, киоскларга тәкъдим итәргә кирәк.

Проектта тәкъдим ителгән чәкчәк нигезендә Татарстан флагының өч төсе ята. Бу төсләр чәкчәкне шартлы рәвештә өчкә бүлә. Чәкчәкнең өске өлешендә ЮНЕСКО эмблемасы урнаштырылган. Бу эмблема чәкчәкнең тарихка кагылышын, мәдәни мирасны үз эченә алганны күрсәтә. Бизәлешкә килгәндә, мастика ярдәмендә ЮНЕСКОга кертелгән объектларның кечкенә макетлары урнаштырыла. Сатып алучы чәй ризыгы белән генә чикләнми, зур тарихка да күз сала. Шулай итеп, Рәсәйдә һәм чит илдә татар мәдәнияте турында мәгълүмат тарала, үсеп килүче буында аңа карата мәхәббәт уяна, мәдәни объектларга карата сакчыл караш үстерелә.

## КҮРСӘТМӘЛЕК-КИТАП

Туристларга күрсәтмәлек булсын өчен, кечкенә китап эшләнелде. Анда ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән өч объект турында мәгълүмат булдырылды. Казан Кремле, Зөя утрау-шәһәрчеге, Болгар шәһәре турында кыскача гына белешмәлек урнаштырылды. Тел барьерын үтү максатыннан, барлык язмалар да өч телдә: татар, рус, инглиз телләрендә бирелде. Күзаллау киңрәк булсын өчен, әлеге объектларның рәсемнәре дә урын алды. Әлеге

китапчык чәкчәктәге тасмага беркетелә. Өч объект турындагы мәгълүмат түбәндәге рәвештә бирелә:

| | |
|---|---|
| Казанский Кремль – уникальный комплекс археологических и архитектурных памятников разных исторических периодов, гармонично сочетающий в себе черты татарской и русской культур. Введен в список ЮНЕСКО в 2000 году.<br><br>Казан Кремле – татар һәм рус мәдәниятләре үзенчәлекләрен гармонияле берләштергән төрле тарихи чорларның уникаль археологик һәм архитектура һәйкәлләре комплексы. ЮНЕСКО исемлегенә 2000нче елда кертелгән.<br><br>The Kazan Kremlin is a unique complex of archaeological and architectural monuments from different historical periods, harmoniously combining the features of the Tatar and Russian cultures. Listed by UNESCO in 2000. |  |

| | |
|---|---|
| Свияжск – город с богатой историей. На его территории расположено огромное количество культовых православных сооружений. Введен в список ЮНЕСКО в 2017 году.<br><br>Зөя – бай тарихлы шәһәр. Аның территориясендә күп православ гыйбадәт |  |

| | |
|---|---|
| корылмалары урнашкан. ЮНЕСКО исемлегенә 2017нче елда кертелгән.<br><br>Sviyazhsk is a city with a rich history. On its territory there is a huge number of religious Orthodox buildings. Listed by UNESCO in 2017. | |

| | |
|---|---|
| Городище Болгар – самая главная историческая достопримечательность, которая занесена в список ЮНЕСКО и находится под охраной. Введен в список ЮНЕСКО в 2014 году.<br><br>Болгар шәһәрчеге – ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән һәм сак астында торучы тарихи истәлекле урын. ЮНЕСКО исемлегенә 2014нче елда кертелгән.<br><br>The ancient settlement of Bolgar is the most important historical landmark, which is included in the UNESCO list and is under protection. Listed by UNESCO in 2014. |  |

Боларның нәтиҗәсе буларак, татар мәдәниятенә кызыксыну арта, мәдәни мираска ихтирам тәрбияләнә.

## ӘЙ БОЛГАРЫМ, СИҢА ТАРТА УЙЛАРЫМ

Тарихлы чәкчәкнең бер өлешендә Болгар турында мәгълүмат урнаштырылган. Болгар Татарстанның көньяк-көнбатышында, Иделнең сул як ярында урнашкан. Беренче тапкыр Ибн Фадлан кульъязмасында XX гасырда телгә алынган. X-XII гасырларда Идел Болгары дәүләтенең башкаласы Идел-Урал буйларында Исламны кабул итүнең беренче урыны, XIII гасырда Алтын Урданың беренче башкаласы, нигез салу урыны.

Борынгы Болгарны нигез салу вакыты төгәл ачыкланмаган. 922нче елда Идел Болгары илбашы Алмыш җитәкчелегендә Болгар шәһәре халкы Ислам динен кабул итә.

1236нчы елда Бату хан җитәкләгән татар-монгол гаскәре Болгар шәһәрен басып ала, Көнбатыш явыннан кайтканда Бату хан Болгар шәһәрен басып алынган бар җирләрнең башкаласы итеп сайлаган, нәкъ анда яңа Алтын Урда дәүләтенә нигез салынган. Соңрак Бату хан дәүләт башкаласын далаларга якынрак, көньякта күчерә һәм Сарай-Бату шәһәргә нигез сала.

Алтын Урдада чуалышлар вакытында Болгар шәһәре Аксак Тимер, соңрак ушкуйниклар тарафыннан басып талана. XV гасырда бик җимерелә һәм үз йогынтысын югалта, ил үзәге Казанга күчерелә.

Заманча Болгар тарихы Болгарлар авылыннан башлана. Революциягә кадәр Казан губернасының Спас өязе эчендә булган. Куйбышев сусаклагычы төзү вакытында Куйбышев

| | |
|---|---|
| Татарстан – регион с богатой историей. На территории республики находятся три объекта всемирного наследия ЮНЕСКО.<br><br>Татарстан – бай тарихлы регион. Аның территориясендә ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән 3 объект урнашкан.<br><br>Tatarstan is a region with a rich history. There are three UNESCO World Heritage Sites on the territory of the republic. | |

шәһәре су астында кала. Шәһәр халкы һәм хакимияте 1953–1956нчы елларда Болгарлар авылына күчә. 1957нче елда авылга Куйбышев исеме бирелә һәм ул ТАССР Куйбышев районының үзәге булып санала. 1991нче елда шәһәргә Болгар исеме бирелә. 2010нчы елда шәһәрдә туристик үзәк төзү башлана.

Район үзәгеннән көнчыгышта Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы урнашкан. X–XII гасырларда биредә Идел-Чулмандагы Болгар дәүләте башкаласы урнаша. Болгар янында мәчетләр, мавзолейлар, мунчалар сакланган. Биредә торак, һөнәрчелек, сәүдә кварталлары да булган.

**ЗӨЯ – УТРАУГА САЛЫНГАН КАЛА**

Чәкчәкнең икенче ягында Зөя Утрау-шәһәрчеге урын ала. Зөя үзенең үзенчәлеген – Ак таш гыйбадәтханәләрнең алтын гөмбәзләре, сәүдәгәр йортлары белән бизәлгән нәфис

манаралары булган борынгы рус шәһәрчегенең кыяфәтен саклап кала алган. Су белән һәр яктан уратып алынган әкият утравы сәяхәтчеләрне магнит кебек җәлеп итә. Бервакыт Изге, чишелмәгән серләр белән тулы Зөя җиренә аяк баскан кеше утрауны могҗизалы шәһәргә әйләндереп, аны каплап торган ниндидер югары, какшамас атмосфераны мәңгегә хәтерендә саклаячак.

Зөянең төп энҗесе - Успение соборы, ул Успение монастыре ансамбленә керә, XVI гасырда нигезләнгән. Соборны 1556нчы елдан 1560нчы елга кадәр Псков осталары төзегән. Собор интерьерында XVI гасырның икенче яртысында XVII гасыр башында 1 мең квадрат метрдан артык мәйданлы стена фреска рәсемнәренең тулы циклы, XVI-XVII гасыр иконалары белән иконостас сакланган. Архитектураның сәер детальләре Успение соборына һавалылык, җиңеллек бирә. Безнең алда билгесез рәссам картинасыннан төшкән әкияти йорт бар кебек тоела.

Төзелгәннән соң ук Успение соборы эчке һәм тышкы яктан буялган. Кызганычка каршы, гыйбадәтханәнең тышкы рәсеме сакланмаган. Ләкин Соборның эчке бизәлеше онытылмас тәэсир калдыра һәм бервакыт авыр ишек ачкан һәм борынгы гыйбадәтханәнең гөмбәзләре астында калган һәркемнең хәтерендә озак кала. Фрескаларның искиткеч, фантастик дөньясы үзенең гүзәллеге белән дулкынландыра, алардан ерак борынгылык җилфердәтә. Билгесез останың кайгыртучан куллары аларга тормыш өргән, кешеләрнең газаплары, хыяллары, шатлыклары һәм кичерешләре аларга ят түгел кебек тоела.

Талантның гадәти булмаган көче белән борынгы рәссамнар безгә Аллаһы йортының эчке бизәлешенең мәһабәт матурлыгын җиткерә алганнар. Зөя фрескаларының әһәмиятен бәяләү авыр, чөнки бу безнең көннәргә кадәр тулысынча диярлек сакланып калган бердәнбер стена рәсемнәренең тулы циклы.

## УТЛАРЫҢА, КАЗАН, КАРЫЙМ КАТ-КАТ

Чәкчәкнең өченче ягында Казан Кремле бизәкләре урын ала. Шартлы өч өлешнең дә нигезен Татарстан флагы төсләре тәшкил итә.

Кремль калкулыгында кешеләр бик борынгы заманнарда ук яши башлаганнар. Бу территориядә табылган иң беренче табышлар мезолит чорына карый. Керамика, бораyланган сугыш балтасы җимерекләре һәм башка табылдыклар бу җирлекне бронза чорында ук үзләштерү турында шаһитлык бирә.

Казанның барлыкка килүе Көнчыгыш Европа шәһәрләренең гомуми тарихи фонында, аерым алганда, Идел буе Болгарстаны дәүләте барлыкка килгән вакытта була.

Казан Кремле татар һәм рус мәдәниятләре үзенчәлекләрен гармонияле берләштергән төрле тарихи чорларның уникаль археологик һәм архитектура һәйкәлләре комплексы. Кремль Казан шәһәренең мәңьеллык тарихы символы булып тора.

Объект шәһәр үзәгендә Казанка елгасының сул ярында урнашкан һәм 13,45 гектар территорияне били.

Казан Кремле территориясендә Россиянең иң эре мәчетләренең берсе-Кол Шәриф, Благовещен соборы, Сөембикә манарасы, Татарстан Республикасы Президенты резиденциясе, шулай ук тарихи комплекслар: Спас-Преображенский монастыре, Юнкер училищесы, Пушка ишегалды, таш диварлы һәм манаралы саклагыч корылмалар һәм төбәк тарихын ачучы башка һәйкәлләр урнашкан.

Казан Кремле федераль әһәмияттәге тарихи һәм мәдәни мирас объекты һәм Татарстан Республикасының аеруча кыйммәтле мәдәни мирас объекты булып тора.

2000нче елда Казан Кремле ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы объектлары исемлегенә кертелгән.

## Йомгаклау

“Чәкчәкле сәйлән” проекты милли ризык — чәкчәк белән ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән өч объектның бергә үрелүен тәшкил итә. Әлеге эш белән танышканнан соң, туристларда мәгълүмат артса, Татарстан һәм татар халкы белән кызыксыну уянса, хезмәтебез актуальлеген исбатлады дигән сүз. Әгәр без проектыбыз аша кемдәдер кызыксыну уята алдык икән, димәк, без максатыбызга ирештек. Рәсәйнең ЮНЕСКО исемлегендә булган 31 объекты белән беррәттән Татарстанның йөзек кашы саналган Казан Кремле, чал тарихлы Болгар, маҗаралы Зөя утрау-шәһәрчеге кертелгән икән, бу чын мәгънәсендә горурлык булып тора. “Акыл фабрикасы” тәкъдим иткәнчә, киләчәктә чәкчәк тә, бәлки, 32нче объект  булып теркәлер?.. Татар халкының мәдәни үзәге булган Казанда да, сувенир булып киткән чит илдә дә чәкчәк ЧӘКЧӘК булып кала.

## Кулланылган әдәбият

1. Мухитов Р.К., Новицкий А.И. Республика Татарстан: памятники истории и культуры. Каталог - справочник. Казань, 1993.

2. Пискарев В.И., Сафронова И.В., Фокеева И.М., Сабитова З.Х. Историко-культурное наследие народов Татарстана: древний город Болгар и остров-град Свияжск: учебное пособие для общеобразовательной школы / В.И. Пискарев, И.В. Сафронова, И.М. Фокеева, З.Х. Сабитова; науч. ред. В.И. Пискарев. - Казань, 2012. - 87 с.

3. Татар дөньясы = Татарский мир / авт.-сост.: Г.Ф. Габдрахманова, Э.М. Галимова, Д.Ф. Загидуллина, И.Л. Измайлов, А.Р. Салихова, А.Г. Ситдиков, Л.М. Шкляева.- Казань: Издательство "Заман", 2020.- 392 с.: ил.

4. Татар милли ашлары = Татарская национальная кухня / под общ. ред. Л.Р. Фазлеевой, А.В. Тимирясовой. - Казань: Изд-во "Заман", 2020.- 392 с.; ил.

5. Татарская кухня. - К.: Стар, 2004. - 120 с.: ил.

6. Фокеева И.М. Историко-культурное наследие народов Татарстана: древний город Болгар и остров-град Свияжск. Методические рекомендации / И.М. Фокеева. Науч. ред. В.И. Пискарев.- Казань: Татарское Республиканское издательство "ХӘТЕР", 2012. - 40 с.

Электрон чыганаклар:

https://www.tripadvisor.ru/Attractions-g2442886-Activities-Bolgar_Republic_of_Tatarstan_Volga_District.html

https://kazantravel.ru/attractions/kazanskiy-kreml/

https://www.tripadvisor.ru/Attractions-g4366473-Activities-Sviyazhsk_Republic_of_Tatarstan_Volga_District.html

*Фәйзуллина Лилия, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан республикасы Түбән Кама муниципаль районы "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләре: Әхмәтҗанова Т.Ф., Әхмәтова М.И. туган тел һәм әдәбият укытучылары*

## Укытучым- сезгә рәхмәтем (хикәя)

Сигезенче сыйныф укучысы Лилия мәктәпне гел яхшы билгеләргә генә тәмамлар мөгаен, чөнки ул классташлары арасында иң үрнәк, алдынгы укучы. Әнә, ишектән килеп керүе генә булды, иптәшләре үзен әйләндереп үк алдылар. Яудыралар гына сорауларын... “Синең алгебрадан икенче эшең ничек килеп чыкты,”, “Татар теленнән барлык сүзләрне дә кулланып яза алдыңмы иншаны,” һәм башкалар, фәлән-фәсмәтән... Җавап кына биреп өлгер!

Җиткән, гел миңа гына баш эшләтергә димәгән, бүген дәресләрдә ял итәчәкмен, бер көн укытучыны тыңламый утырганнан әллә ни булмас, дигән карарга килде Лилия. Аңламаса, кайткач, үзлектән укып, асылына төшенер әле. Янәсе, укытучы да китаптагы

кагыйдәләргә таянып кына аңлата ич инде аларга дәресне!.. Әйе, Лилия бик нык ялгыша иде...

Дәресләр Лилия өчен бик күңелле үтте бүген, җаны ни теләде – шуны эшләде, әллә ниләр турында хыялланып утырды. Дөресен генә әйткәндә, үзенә үзе ял оештырды ул бүген. Беренче дәрес алгебра иде. Ул 9 нчы класс кызы Алсу биргән “Истәлек дәфтәре” н тутырып утырды. Укытучы апа берни сизмәде дә ахры, дәрес буе яңа тема аңлатуы белән мәшгуль булды. Рус телендә әллә ни ял итеп булмады – диктант яздылар. Хезмәт, физик культура дәресләрендә баш эшләтергә туры килмәде. Шулай да укып була икән бит, дигән фикергә килде кыз һәм үзенең әлеге “ачыш”ына сокланып, горур атлап өенә кайтып китте. Өйдәгеләр Лилиянең кәефе әйбәт булуын чираттагы “5”ле билгесе алу белән бәйләделәр, кызларының шундый ялгышлык кылуын белмәделәр.

Лилия бер көнне өйгә кәефсез кайтты. Беркем белән дә исәнләшмәде, гадәттәгечә елмаюы да йөзеннән качкан иде. Әнисе ашарга чакырды – чыкмады. Әлфия апа кызының бу халәтен ишектән кереп, бер күтәрелеп карауга ук сизгән иде инде. “Кызым, ни булды сиңа, – дип эндәште Әлфия ханым. “Юк, әнием, берни дә булмады, аппетитым качкан бүген каядыр”, - дип җавап кайтарды кыз. Әнисе:“Аппетит болай гына качмый ул, сөйлә әниеңә барысын да, бәлки, булыша алырмын,” – дигәч, Лилия сөйләми булдыра алмады. Ул бүген алгебрадан “2”ле билгесе алып кайткан иде. Аның ни өчендер үзенә түгел, ә укытучысына ачуы килә иде. “Әни, ничек инде гел яхшы билгеләргә генә укучыга начар билге куеп була! Мин Гөлия Айратовнага үпкәләдем, башка укучыларга караганда өстенрәк күрергә тиештер инде ул мине, бүтән бернинди олимпиадаларга да бармыйм! Мәктәп данын яклап йөргән булам бит әле тагын”, - дип ярсынды кыз.

Әлфия апа кызының ялгышуын аңлады һәм тиз арада газиз баласын әлеге хаталы фикерләрдән арындырырга тырышты. “Кызым, нишләвең бу, алай ярыймы инде, синең начар билге алуыңда укытучының гаебе бармы икән? Бәлки, син ул аңлатканда тыңламыйча утыргансыңдыр, исеңә төшер әле. Бигрәк яратып өйрәнә идең бит ул фәнне, укытучысын да ярата идең.” Лилия үзенең ярсуы басылуын сизә башлады, чыннан да, үзенә “лаеклы ял” үткәргән көнне Гөлия Айратовна аларга нәкъ шул теманы аңлаткан иде бит. Ә ул, кайткач укып, бу темага үзе төшенергә уйлаган иде. Тик өйдә берничә кабат укыса да, нечкәлекләренә төшенеп бетә алмады. Ярар, кирәге чыкмас та, бәлки, дип, бу турыда онытты. Ә Гөлия Айратовна бүген шушы темага үзлектән эш эшләтте. Лилия әнисенә боларның барысын да сөйләп бирде.

Ана кеше баласын бүлдермичә тыңлады һәм үзенең киңәшләрен бирергә булды. “Кызым, син хәзер үзеңнең ялгышыңны аңладың булса кирәк. Укытучыга үпкәләү – зур хата булыр, ул сиңа начар билге куеп бик дөрес эшләгән. Әгәр сине өстен күреп, билгеңне

тиешлесеннән арттырып куйган булса, син хатаңны аңламый да калыр идең. Чын укытучы барлык укучыларга да бертигез карый, кемнең кайсы өлкәне аңлап бетермәвен дә сизә. Ул бары тик сине шул рәвешле сынап кына караган. Иртәгә үк укытучыңнан гафу үтен һәм әлеге теманы яңадан аңлатуын сора, кызым. Укытучылар – иң галим кешеләр, дип юкка гына җырлар да язмаганнар!”

Лилия әнисе белән тулысынча килешеп, иртән, Гөлия Айратовнадан ничегрәк гафу үтенергә икәнлеген уйлый-уйлый, мәктәбенә ашкынды. Дәрес башланырга тагын 20 минутлап вакыт калган иде әле. Менә коридорда һәрвакыттагыча тыйнак һәм пөхтә итеп киенгән, уйчан йөзле Гөлия Айратовна күренде. Ул, әйтерсең лә, һәр адымын үлчәп, уйлап атлый. Шундый салмак кына, барысы белән дә ихлас күңелдән елмаеп исәнләшеп килә... Лилиянең йөзенә кызыллык йөгерде, аңа үзе өчен бик оят иде. Ничек ул шундый кешенең дәресен тыңламыйча утыра алган да, ничек итеп шундый кешегә үпкә белдерә алган!

Менә Гөлия Айратовна Лилия янына килеп җитте. Кызның үзен көтүен күзләреннән укып өлгергән иде инде ул. “Лилия, син мине көтәсең, бугай, “ – диде ул йомшак кына. Лилия каушап калды һәм: “Ә, әйе, сезне көтәм, вакытыгыз бармы,” – диде. Гөлия Айратовна ризалыгын белдереп баш какты һәм укучысын үз кабинетына өндәде.

“Йә, ни йомыш, Садыйкова,” – диде ул кырысрак булырга тырышкандай. “Гөлия Айратовна, зинһар өчен, мине гафу итегез! Мин сезнең фәннән “2”ле алырга тиеш түгел идем. Бер көнне сезнең ни аңлатканыгызны тыңламыйча утырдым, шуның бәласе бу!” – диде Лилия көч-хәл белән.

Укытучы:” Эх Лилия, әлбәттә гафу итәм. Мин синең ул дәрестә бөтенләй икенче нәрсә белән шөгыльләнеп утыруыңны бик тиз сиздем. Күзләрең тактада булса да, уйларың белән син еракта идең. Ләкин минем фәнемне беркемгә дә көчләп укытасым килми. Укучылар белем алырга теләп укыганда гына рәхәт бит укытуы. Шуңа күрә, мин бернинди кисәтү дә ясамадым. Үз хатагызны үзегез аңлагансыз икән, мин бик шат! Теләсәң, дәресләрдән соң калып, бу теманың нечкәлекләрен аңлатып бирә алам.”

Лилия шатланып риза булды. Югыйсә, бу тема әллә ни кыен да түгел икән! Китаптан да шуны ук укыды, ләкин аңламады бит Лилия! Күрәсең, укытучы булып туарга кирәктер! Аңлата белү сәләте теләсә кемгә бирелми икән шул! Бик зур рәхмәт сезгә, укытучым!

Бу вакыйгаларга инде берничә дистә еллар үтте. Ә хәтердә әле һаман бүгенгедәй сакланган икән... Лилиянең дә кызы бүген яраткан фәненнән “койрык” алып кайткан. Үзе зирәк бала да кебек! Ләкин ул кызына ничек ярдәм итәргә кирәк икәнен белә иде! Рәхмәт, рәхмәт сезгә, укытучым! Мине генә түгел, баламны да тәрбияләргә ярдәм итәсез бит!!!

*Хәбибуллина Әминә, 8 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе:Халикова Нурсинә Дәлиф кызы, Фатхуллина Гүзәл Фәһим кызы, туган тел һәм әдәбияты укытучылары*

## Фатих Кәрим –рухы сынмас шагыйрь

### Кереш

Гамьсезгомер өчентумадым мин,
Ялкынланып яшәү-теләгем,
Шаулы шигъри хисләр диңгезләр
Дулкынчысы минем йөрәгем. [1]

**Ф.Кәрим**

**1941 нче елның 22 нче июнендә немец-фашист илбасарлары безнең илебезгә басып керделәр. Халкыбыз, бердәм булып, дошманга каршы көрәшкә күтәрелде.**

**Яшь-яшь егетләр, язучылар, шагыйрьләр туган җирләрен саклау өчен, фронтка киттеләр. Алар арасында Фатих Кәрим дә бар иде.**

Фатих Кәрим. Еш уйланам мин бу шәхес турында. Сугышка кадәрге тормышы хакында шактый беләм кебек: автобиографик язмасы да, истәлекләре дә, хатлары да бар. Дәрестән тыш әдәби чаралардаФатих Кәримнең тормыш юлы, иҗаты, гаиләсенә, иҗатташ дусларына язган хатлары, Ләйлә ханымның әтисе турында язган истәлекләре белән таныштык, мине ялкынлы да, моңлы да, үз Туган иленең патриоты булган шагыйрь язмышы кызыксындырды: минем аның турында күбрәк беләсем килде һәм эзләнә башладым ...

Тетрәндерде дә, сокландырды да мине Фатих Кәримнең язмышы. Шуңа күрә фәнни эшемдә бу бөек шәхеснең тормыш юлын өйрәнеп, еллар, тарихның авыр сынаулары, тормышның кырыс рәхимсезлеге аны ничек кенә сынаса да, аның рухы сынмавын, нинди генә хәлдә дә, нинди генә шартларда да олы җанлы, рухи яктан көчле, корычтай ихтыярын кешеләргә үрнәк итеп куйган; үз халкына рухи көч бирерлек әсәрләр язуларын бәян итүгәигътибарымны җәлеп иттем.

Максат:

- Патриот шагыйрь Фатих Кәримнең тормышын, иҗатын өйрәнү.

- Әдип әсәрләрендә туган иленә булган җылы хисләренең, мәхәббәтенең фашист илбасарларына каршы көрәштә тиңдәшсез корал булуын ачыклау.

- Илебезнең фаҗигале үткәне,Бөек Ватан сугышы турында күзаллауны тирәнәйтү.

Бурычлар:

1. Фатих Кәримнең иҗатына якынаю өчен аның әсәрләрен уку.

2. Фатих Кәрим иҗаты турында материалларны мөмкин кадәр гамәли куллану.

3. Туган илгә, туган җиргә мәхәббәт, патриотик хисләр тәрбияләү.

Бу тикшеренү эшенә әзерләнгәндә, бик күп китаплар, газета-журнал материалларына мөрәҗәгать иттем.Фатих Кәримнең шигырьләрен, хикәяләрен һәм аның турында язылган истәлекләрне укып бу шәхеснең олуг зат булуына булуынаышандым.

## Төп өлеш

## Фатих Кәрим – рухы сынмас шагыйрь

Фатих Кәрим үзенең иҗаты белән Бөек Ватан сугышына кадәр үк билгеле булса да, аның иҗаты сугыш чорында аеруча көчле яңгырый.

Шагыйрь 1941 нче елның 30 нчы декабрендә, хатынын, ике кызын калдырып, сугышка китә. Сугыш шагыйрь өчен фашист белән йөзгә-йөз очрашу түгел, аның иҗат фронты да була.

Бер минут та башка тынгы бирми,
Окоп почмагында утырам.
Аламын да, куен дәфтәремне
Янып, җыр язарга тотынам, - [2]

дип яза шагыйрь "Кереш җыр" шигырендә.

Әнә шулай сугыш вакытында унга якын поэма, баллада, йөзләгән шигырьләр, 2 повесть һәм бер пьеса иҗат итә. 1943 елда "Мәхәббәт һәм нәфрәт" исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыгын, "Разведчик язмалары" повестен, "Моң һәм көч" шигырь җыентыгын нәшер итә.Тормыш иптәше һәм балаларына матур эчтәлектәге хатлар язып тора.Бу әсәрләрендә шагыйрь явыз дошманны җиңү өчен бөтен көчне тупларга кирәклеген таләп итеп чыга.

Фәтих Кәрим Бөек Ватан сугышы фронтларында зур батырлыклар күрсәтә.Сугыш дәвәмендә ул ике тапкыр каты яралана, ләкин,шуңа карамастан,сафтан чыкмый,яңадан сугышка омтыла.Ватанны дошманнан азат итү аның намус эшенә әверелә.Батырлыгы өчен ул куп тапкыр язма котлаулар ала,фронтта рядовой солдаттан взвод командиры дәрәҗәсенә күтәрелә.**Аныңча, яшәүнең бөтен матурлыгы - үз Ватаныңны бөтен нәрсәдән дә югары куеп, аны саклап, коллыктан коткарып, антына тугры булып калуда.**

**Юлбасарлар таптый җиребезне,**

**Ватан сугышына мин китәм.**

**Менә - балам.Син әнкәсе аның,**

**Балабызны тотып ант итәм:**

**Синең өчен, шушы балам өчен,**

**Нәселем өчен, Туган ил өчен,**

**Мылтык тотып баскан җиремнән**

**Бер адым да артка чигенмәм, -** [3]

**дип яза Фатих Кәрим "Ант" шигырендә.**

Фронт давылында кайнаган шагыйрь катлаулы вакыйгаларга чын бәя биргән. Үзе разведчик та булгач, дошманның тыныч халыкны аяусыз кыруын, һәлак ителгән сабыйларның фаҗигасен башлап күрергә туры килгән аңа. "Гөлсем", "Партизан хатыны", "Үлем уены" поэмалары үзе күргән, үзе кичергән вакыйгалар тәэсирендә язылган әсәрләр.

"Үлем уены" поэмасы - шундый реалистик әсәрләрнең берсе. Еллар узган саен, фашистларга каршы халкыбыз алып барган героик көрәш киләчәк буыннарга легенда итеп сөйләнер. Бу көрәштә балалар да читтә калмаган. Алар, үзләренә хас җитезлек, самимилек, зирәклек һәм тапкырлык күрсәтеп, җиңүгә зур өлеш керткәннәр.

Әсәрнең герое - 12 яшьлек Әхтәм. Ул - фронтның алгы сызыгында. Монда һәр минут, һәр секунд шыксыз үлем сагалый. Әхтәм малайларга хас наянлыгы белән үлем уены оештыра: немец снайперы белән бермә-бер алышка чыга. Кем кемне җиңәр? Әхтәмнең хәйләсе күңел кылларын кузгата, аңа теләктәшлек, горурлык хисләре уята.

Герой үзенең тапкыр хәйләсендә ялгышмый:

Тишек котелок -

Аның ашы юк;

Фашист гәүдәсе -

Аның башы юк.

Нәни солдатның йөзендә елмаю - канәгатьләнү һәм җиңү билгесе. Әмма тынычланырга ярамый: фронтта җиңү үлем белән янәшә йөри.

Минемчә, Әхтәм - чын солдат. Ул - тапкыр һәм батыр малай. Әхтәм кебек малайлар да Бөек Җиңүгә үз өлешләрен керткәннәр. Мине Әхтәмнең батырлыгы сокландыра.

"Үлем уены" поэмасы - балаларның рухын чагылдыра торган иң матур әсәрләнең берсе. Нәни солдатның җиңү шатлыгы укучы күңеленә дә күчә. Ул, җыр кебек җиңел укылып, хәтердә тирән уелып кала торган әсәр.

“Партизан хатыны” поэмасында шагыйрь партизан хатыны образы аша хатын-кызларның авыр сугыш елларындагы сабырлыгын, сафлыгын, намуслы булуларын гәүдәләндерә. Партизан хатыны туган җиренә, иренә тугрылыклы булып кала. Мәнсез немец партизан хатынына әйтеп-аңлатып булмый торган фаҗига китерә: ул, сабыйның күкрәгенә хәнҗәр кадап, ана кулыннан каерып ала. Бу хәл ананы тетрәндерә, ул баласына таба үрелә. Аның күзләрендә – үч, ачу. Никадәр авыр булса да, хатын сатылу хурлыгына төшми, намуслы үлемне сайлый, төнбоеклар арасында, улы янында җан бирә.

Әйе, батырлык җиңү китерә, куркаклык - хурлыклы сыйфат, шуңа күрә Фатих Кәрим батырларны мактый. Фәтих Кәрим Бөек Ватан сугышы фронтларында зур батырлыклар күрсәтә. Сугыш дәвамендә ул ике тапкыр каты яралана, ләкин, шуңа карамастан, сафтан чыкмый, яңадан сугышка омтыла. Ватанны дошманнан азат итү аның намус эшенә әверелә. Батырлыгы өчен ул куп тапкыр язма котлаулар ала. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Фатих Кәримгә I дәрәҗә Ватан сугышы ордены бирелә. Фронтта рядовой солдаттан взвод командиры дәрәҗәсенә күтәрелә.Ул - командир, аның кул астында күпләгән солдатлар. Алар - яшьләр. Киләчәк - алар кулында. Менә шуның өчен шагыйрь иң кыен җиргә үзе омтылды. Туган илгә аның яшәү рухытулы хатлары, шигырьләре кайтты.

Сугыш араларында никадәр күп әсәрләр иҗат иткән шагыйрь тыныч елларда нинди генә җәүһәрләр бирмәс иде! Тик гомере кыска булган икән шул. Нинди үкенеч, сугыш бетәргә ике ай ярым калганда ул батырларча һәлак була.

Үләм икән, үкенечле түгел,  
Бу үлемнең миңа килүе.  
Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен  
Сугыш кырларында үлүе, - [4]  
дип яза шагыйрь.

**Йомгаклау**

Фатих Кәрим поэзиясе –якты,саф һәм патриотик тойгылар поэзиясе.Ул бай,күпьяклы һәм үзенең күләме,сыйфаты белән татар совет поэзиясендә иң күренекле урыннарның берсен тота.Фатих Кәрим һәм Муса Җәлил исемнәре татар совет әдәбиятының иң мактаулы исемнәре итеп әйтеләләр.

Бүгенге көндә минем милләтем — Фатих Кәриме, Муса Җәлиле булган бөек милләт ул. Алар безнең горурлыгыбыз, кешелек дәрәҗәбез.

Дошманга ялкын сибүче  
Җил булып барсам иде,  
Тәвәккәллек, батырлыкта

Җыр булып калсам иде, -

дип яза Фатих Кәрим "Теләк" шигырендә.

Димәк, Фатих Кәрим шигырьләренең барысы өчен уртак тема - батырлык. Фашистларның ерткычлыгын, вәхшилеген фаш итү, туган илгә бирелгәнлек, илебезнең җиңеп чыгачагына тирән ышаныч.

Кешедә өмет, теләк, ихтыяр, рухы көчле булганда,яшәү дә матур булачак. Аларның һәркайсының тормышы - үзенә күрә батырлык.

Эш барышында алдыма куйган максат һәм барлык бурычлар да чишелде. Мин фәнни-тикшерү эшем буенча әдәбият кулландым, архив материаллар тупладым; массакүләм информация чараларын файдаландым; фотоматериаллар җыйдым һәм үземә шундый нәтиҗә ясадым. Бүгенге көндә дә бөек язучыларыбызның сугышчан батырлыклары яшь буынны тәрбияләүдә зур роль уйный, уйнаган һәм уйнаячак.

Эшемнең барышында гипотеза тулысы белән расланды.

Эшемне төгәлләп шуны әйтергә кирәк: бүген без яшь буын ветераннарыбызга, өлкән буын кешеләренә иътибарлырак, итагәтьлерәк булырга тиеш. Шуңа күрә без үзебездән шундый тәкъдим кертәбез: эзләнүләр нәтиҗәсендә тупланган хезмәтемне туган якны өйрәнүдә һәм әдәбият дәресләрендә тәрбия эшендә материал буларак кулланырга мөмкин.

**Кулланылган әдәбият**


1.Кәрим Фатих/Илең турында уйла:Шигырьләр,поэмалар, балладалар-Казан: Татар.кит.нәшр., 1989-191 бит.

2. Гыймадиева Н.С. Әдәбият дәреслекләре буйлап/Казан: Яңаалиф нәшрияты/ 2006-124 бит.

3. Галиуллин Т. Халык шагыйре /Т. Галиуллин// Мәгариф.- 2000.-№12,- Б.12-14.
4.Гыйльманов Г. Вөҗданы саф булып калды табигать һәм халкы каршында.../ Г.Гыйльманов// Мәгърифәт.- Казан, 2009.

5.Җәләлиева М.Ш., Әдһәмова Г.М. VI класста әдәбият дәресләре / М.Ш.Җәлә-лиева, Г.М.Әдһәмова.- Казан: Татар. кит., 1981

6. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих/ Д. Ф.Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов,- Казан: Мәгариф,2004

7.Кәрим Фатих.Кыр казы: Шигырьләр,поэмалар.- Казан:Татар.кит. нәшр.,2004-143б.

8.Кашапов Г. Шагыйрьне сагыну /Г. Кашапов// Авыл таңнары,- Аксубай,1981

9.Ф.Кәримнең тууына 100 ел//Мәйдан.-2009

10.Мәҗитов З. Үлемсезлек/ Кәрим Фатих// Кыр казы:Шигырьләр,поэмалар.-Казан: Татар.кит.нәшр., 2004-143б.

*Хайруллина Ясмина, 11 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "22 нче Гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Аменова Эльмира Зуфаровна, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Эчтәлек**

Кереш
Төп өлеш.
1. Иштирәк  авылы турында мәгълүмат
1.2 Революция һәм гражданнар сугышы елларында
1.3. Колхозлашу елларында
1.4 Өч сугыш батыры
1.5 Советлар Союзы Герое – Калимулла Якупов
Йомгаклау
1. Авылның бүгенгесе
Кулланылган әдәбият
Кушымта- Презентация.

**Кереш**

Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк диләр. Бу сүзләр белән мин килешәм. Кем генә булмасын, олы кешеме, кечеме, ул үзенең тарихын белергә тиеш. Фәнни эшебезнең темасын да шуннан чыгып сайладык.

Безнең эшебезнең темасы – «Үткәннәргә күз салып, тарихны барлыйбыз..» дип атала. Теманың актуальлеге – кеше үзенең туган җиренең, туган төбәгенең тарихын, үткәнен һәм бүгенгесен белергә, аны киләчәк буынга да тапшырырга тиеш. Чөнки үткәнеңне белмичә, киләчәкне күз алдына китереп булмый.

**Фәнни эшнең максаты:** Иштирәк авылының тарихын өйрәнү. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

-бу өлкәгә караган әдәбият белән танышу;

-Иштирәк авылына экскурсия;

-авылның атаклы кешеләре белән очрашу;

Өйрәнү **объекты**: туган як тарихы.

Тикшерү **предметы**: Иштирәк авылы.

Тикшерү **гипотезасы**: туган авылыңның тарихын белми торып, үз илеңнең лаеклы гражданины була алмыйсың.

Тикшерү **методикасы:**

1. Эш барышында төрле чыганаклардан файдаланылды.
2. Авыл китапханәсенә бару.
3. Өлкән кешеләр белән очрашып фикер алышу.

Иштирәк авылының килеп чыгышы хакында төрле карашлар язылган.

Беренчесе - авылда ике милләт халкы яшәүгә бәйле. «Иш»+ «тирәк» булып.

Икенче караш тирәк агачлары елга буенда күпләп үсә. Агачлар да бер-берсенә терәк булып торалар.

Өченчесе һәм дөрес дип табылган караш – ул бу як җирләренең Нугай ханы Иштерәк биләмәләре составына керүе.

Иштирәк – Советлар Союзы герое Калимулла Якуповның туган җире.

Иштирәк – Гыйләҗева Таибә әбинең туган җире. Ул Бөек Ватан сугышына 4 улын, 1 оныгын, 2 киявен озаткан. Кызганычка каршы алар барысы да һәлак булганнар.

Иштирәк – ул ике халыкны берләштергән авыл. Кыргызлар һәм татарлар бербөтен булып яшиләр.

Иштирәк – күренекле язучылар һәм шагыйрьләрнең туган җире. Җәмилә Әхтәмова, Рафис Сәлимҗанов, Хөсәен Җәгъфәр, Рәфкать Муллин.

Иштирәк- язучы Нур Баянның яшәгән һәм эшләгән җире.

Иштирәк – калын урманнар, чиста, зәңгәр күлләр авылы.

## Төп өлеш

### 1. Иштирәк авылы турында мәгълүмат.

Авыл моңнарын җырлап.
Күз күреме җитмәс ераклыкка,
Сузылып киткән авыл кырлары.
Гомерлеккә отып алды күңелем,
Шул кырларда шыткан җырларны.
Аяз күкле туган авылым белән
Горурланам һәрбер урында.
Чылтыр чишмәләре тыңлап туймас,
Көй чыгара аның турында.

(Х. Җәгъфәр)

Тарихта авылларның, шәһәрләрнең, күпчелек очракта, шуларга нигез салган, беренче килеп утырган кеше исеме белән аталган булуы билгеле. Иштирәк авылының исемен дә

тирәк агачы белән бәйләп, терәк булып яшәүдән килеп чыккан дип аңлатучылар күп булган. Шунысы кызык: Татарстанның көнчыгыш якларында Иштирәк исемле биш авыл барлыгы билгеле. Аларның берсе- Әлмәт районында.Икенчесе- Мөслим районында, Мөслимнән 2 чакрым ераклыктагы Ольгина авылы. Элек бу авыл Иштирәк дип аталган. XIX гасырда авыл тирәсендә бакыр табылгач,бакыр эретү заводы ачыла. Бу җирләрнең хуҗасы Петербургта яшәүче княгиня Хощинская була. Ольга исемле кызы тугач, авылны Ольгина дип үзгәртә. Өченчесе- Ютазы районында, дүртенчесе - Балтач районында, бишенчесе - Лениногорск районында. Пермь өлкәсенең Уинский районында да Иштирәк авылы бар. Димәк, Иштирәк ул кеше исеме, һәм ул билгеле дә. XV- XVI гасырларда бу якларда нугай йортының күчмә халыклары күпләп күчеп йөргәннәр. Аларның Зәй буйларына килеп утыруын дәлилләгән документлар бар:

-Герберштейн С.Записки о Московии.-М:Изд-во МГУ, 1988.

-Трепавлов В.В. История Ногайской Орды.-М: Восточная литература, 2002.

Олы Нугай Урдасы идарәчесе Дин Әхмәт Бәк(1598-1600) улы Иштирәк морза, урыс гаскәрләре ярдәмендә, Ырыс Морзаның фетнәчел улларын җиңеп, Олы Нугай тәхетенә утыра һәм Нугай Урдасының күпчелек өлешен берләштерә. Иштирәк бәк вакытында Олы Нугай Урдасы көнбатышка Дон елгасы буйларына хәтле киңәя, ә көнчыгышта хәзерге Пермь өлкәсенә кадәр җитә. 1619 елда Иштирәк бәк үлгәннән соң Нугай Урдасы таркала һәм дәүләт буларак юкка чыга.Шулай итеп, Татарстанның (элекке Казан ханлыгының) көнчыгыш яклары Иштирәк Бәкнең биләмәлере була. Авыл исеме чынлап та Иштирәк Бәк белән бәйләнгән. Ә шулай да, Иштирәк исеменең ничә елдан соң авыл исеменә әверелүе ачыкланмаган.Татар энциклопедиясендә Иштирәк авылы турында түбәндәге мәгълүмат бирелә: «Иштирәк авылы Тукай районында Чаллы шәһәреннән 30 км көньяк-көнбатыштарак Аулаш елгасының югары агышы буенда урнашкан. 2020 елда 574 кеше (татарлар) яши. Халыкның төп шөгыле- кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1678 елдан Бачкеева Пустошь буларак мәгълүм. Революциягә кадәрге чыганакларда Алансу исеме белән дә искә алына. XVIII йөздә – XIX йөзнең беренче яртысында халкы дәүләт крестьяннары катлавына керә. Бу чорда халкының төп шөгыльләре – игенчелек һәм терлекчелек, шулай ук умартачылык, балта эше һәм мич чыгару тарала. XIX йөздә авылда бакыр кою заводы эшли. 1870 елгы мәгълүматлар буенча, авылда мәчет, мәктәп, су тегермәне була. XIX йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1002,5 дисәтинә тәшкил итә.» Иштирәк авылы төзелүе турында төгәл хәбәр юк, ләкин хәзер кешеләр күмелми торган бик иске зиратлар сакланган. Хәзерге вакытта Иштирәк авылында ике зират бар: берсе - Атау дип атала торган өлешендә, авылның көньягыннан кергәндә сул якта кала. Андагы иске ташлар зиратта күмелә башлаган кешеләрнең үлү еллар XVII гасыр азагы, XVIII гасыр

башына каравын раслый. Икенче зират Кыргыз очыннан кергәндә сул якта кала. Мондагы кабер ташлары XIX гасыр башына карый. Иске зиратларга килгәндә, авылның иң борынгы зираты – Туганаш күпереннән 2-3 км көньяктарак, Арслан сазлыгы башланганчы, хәзерге Иштирәк-Кәрәкәс юлыннан 1 км урманга таба булган, ни кызганыч, алтмышынчы елларда аны трактор белән сөргәннәр.Тагын бер иске зират – Кыргыз очында Әһли күленең көньягында, ул хәзерге вакытта койма белән әйләндереп алынган, аны Иске кыргыз зираты дип тә йөртәләр.

Иштирәк авылында ике мәчет исәпләнгән, һәр мәхәлләнең үз мулласы булган. Атау очының Мартыш тыкрыгындагы беренче мәчет 1670 елларда салынган. 1931 елларда мәчет бинасы-башта авыл советы, аннан күп еллар дәвамында клуб вазифасын үти. Аны XX гасырның 80 нче елларында сүтәләр, соңрак аның урынында таштан мәчет төзелә. Икенче мәчет Кыргыз очында була, ләкин мәчетнең төгәл кайсы елны салынганлыгы билгеле түгел. 1918-1919 елларда авылларда мәчет әһелләренең эшчәнлеге тыела. Әмма ул елларда мәчетләрне ватмыйлар. Манараларын кисеп, колхоз амбарлары, клублар итү 1929-1930 елларда башлана. Кыргыз мәчетенең ябылу вакыты да билгеле. 1939 нчы елда аның манарасын кисеп, 1-2 елдан мәчетнең үзен сүтеп, Иштирәк дүртъеллык мәктәбе итеп күчереп салалар.

Иштирәк авылы 1708 елда – Казан губернасы Минзәлә өязе Шәңгәлче волостена; 1744 елда Оренбург губернасы Минзәлә өязе Шәңгәлче волостена; 1870 елда Уфа губернасы Минзәлә өязе Шәңгәлче волостена; 1920 елда – ТАССРның Минзәлә контоны Афанас волостена; 1922 елда – Чаллы кантоны Афанас волостена; 1930 елның 10 августыннан – Чаллы районына; 1972 елның 1 ноябреннән – Зәй районына кергән. Ә 1977 елның 26 декабреннән Иштирәк авылы – ТАССРның Тукай районы составында.

Иштирәкнең көнбатышы кыргыз очы дип йөртелә. Ни өчен ул Кыргыз очы дип аталган? 1736 елда Иштирәк авылына Каракалпактан кыргыз кешеләре көченеп килә. 11 кешедән торган бер кабилә хәзер Иштирәк авылы урнашкан урынның көнбатышына килеп чыга һәм шунда гомерлеккә урнашып кала. Аңа кадәр бу кыргыз кабиләсе Зәй районы Бигеш һәм Кәрәкәс авылы арасындагы Амар дип аталган елга – ерым буена килеп урнашкан була. Ләкин анда озак яшәргә туры килми, Бигеш халкы аларны куып җибәрә. Куылган кыргызлар, Иштирәк авылының югары очына килеп урнашалар. Аларга «Керәч тавы» өстендәге чәчүлек җиренең бер өлешен бүлеп бирәләр. Кыргызлар Иштирәк халкы белән күп вакытлар аралашмаган, үзләренең гореф – гадәтләре булган, көнкүреш үзләренчә алып барылган. Кыз бирү һәм килен алу кебек якынлык булмаган. Иштирәк авылының матур табигате, урман һәм болыннары булу сәбәпле, хәтта бирегә Мәскәүдән дә килеп ял иткәннәр. Кыргызлар шул ял итүчелар өчен кымыз хәзерләгәннәр һәм аларны ашамлык белән тәэмин итеп торганнар, ат һәм терлек белән сәүдә иткәннәр. Иштирәк халкы белән

кыргызлар арасында элемтә йомшак була. Алар дәүләттән җир сорыйлар һәм бер вакытны аларга дәүләт Керәч тау башыннан җир кисеп бирә. Ул вакытта җирләрне киртә белән әйләндереп ала торган булалар, кыргызлар да шулай эшли. Иштирәк авылы ярым феодал стройда яши. Ярлы крестьяннар байларга әйберләтә ясак түләгәннәр, бик авыр тормышта яшәгәннәр. Ел саен бик күп кешеләр, балалар ачлыктан, төрле авырулардан үлгәннәр. Бу вакытта муллалардан башка хәреф танучы булмаган. Авылда ике мәчет, 2 зират булган. Шулай ук 2 староста, 2 мулла булган. 1861 нче елда крепостнойлык бетерелгәч, реформа була. Авылда катлаулар аерылып чыгу көчәя. Муллалардан тыш берничә сәүдәгәр, подрядчик була. Авыл буржуазиясе үсеп чыга. Алар баеп авыл халкын эксплуатациялиләр.

**1.2 Революция һәм гражданнар сугышы елларында.**

Революция еллары авылны бераз читләтеп үтә, революцион агышлар булмый. Иштирәк авылы административ яктан Чаллы волосте, Минзәлә өязе, Уфа губернасы составына керә. Революция һәм гражданнар сугышы елларыннан соң, авылда зур үзгәрешләр була. Бу якларда гражданнар сугышы 1919 елга кадәр бара. 1921 нче елгы ачлыкта авыл халкы бик кырыла. Яз көне чәчелгән орлыклар тишелеп чыкмый, чунки яңгыр яумый. Төп ризык булып алабута кала. Ата-аналары ачлыктан үлгән балалар өчен Иштирәктә ятимнәр йорты ачыла. Бу ятимнәр йортында шушы авылдан Муса абый да яши. Әтиләре Исмәгыйлев Юныс Афанаста волость секретаре булып эшли, ләкин ул тифтан үлеп китә. Әниләре биш бала белән ялгыз кала. Коточкыч ачлык башлана. Әниләре атларын бер капчык ярмага сатып җибәрә. Ашарга берни калмагач, 2 баласын ятимнәр йортына бирә. Мондый язмышка дучар булган гаиләләр бик күп була. Ләкин балалар арасында тиф авыруы тарала, көненә 4-5 бала үлә башлый. Бу авыруга каршы көрәшә алмау сәбәпле, ятимнәр йортын ябалар. Балаларны Яр Чаллыга алып китеп военкомат йортына урнаштыралар. Аларны чит илгә алып китәргә исемлек төзелә. Исемлектә абыйсы белән Муса абый да була. Чит илгә китүдән баш тартып, алар таң алдыннан качалар, авылга кайталар. 1921 елда авылда 7 кеше үтерелә. Байлар коткысына бирелгән кешеләр Минзәләдән ат урлап кайталар. Тикшерүчеләр Гыймранов Ситдыйк йортыннан ит табалар. Ситдыйк үзе кача, аны таба алмагач ачудан хатынын үтерәләр. Мостафин Хасанша «Исән калдырыгыз», дип ялынуга карамастан, терелэй күмелә. Аның хатынын, тагын 5 кешене һәм бер баланы ат арбасына бәйләп, алдан казып куелган чокырга тере килеш күмәләр. Бу вәхшилекне карап торсыннар өчен, ярты авылны көчләп куып алып менгәннәр.

Авылны калдырып, читкә чыгып китүчеләр дә була, күбесе Урта Азия ягына китә. Афзалхатип Әмирханов үз туган авылы Иштирәктән, Шәңгәлче һәм Кушай авылларыннан барлыгы 150 кеше җыеп, Чаллы пристаненда пароходка төяп, Сәмәркандка алып китә. Шушындый болганчык вакыйгалар белән авыл 1928 нче елларга килеп җитә.

## 1.3 Колхозлашу елларында.

1928 нче елда колхозлашу алдыннан авылда Машинное товарищество төзелә. Аның җитәкчесе Мансуров Газиз була. Ул русча укый белгән, алдынгы фикерле кеше һәм тырышлыгы, җитезлеге белән күпләрдән аерылып торган. Шушы товарищество нигезендә 1930 елда колхоз оештырыла. Колхозлашу еллары шулай ук бик катлаулы була. Колхозга керүчеләр үзенең аты, сыеры яисә ашлыгы белән керергә тиеш була. Бер кергәннән соң, кешеләр колхоздан кире чыгалар, бары 12 генә хуҗалык кала. Иштирәк халкы белән Кыргызлар арасында элемтә революциядән соң да начар була. Зур булмаган авылда ике авыл советы: Каракалпак һәм Иштирәк авыл советы, ике зыярат һәм ике мәчет була. Бу советлар 1930 нчы елның 1 маенда бетерелеп, бер авыл Советына берләштерелә. 1932 нче елда колхоз ныклап төзелә башлый. Авылда Конная товарная ферма төзелә. Анда яхшы айгырлар асрыйлар. Тарихи язмаларга караганда, ул атлар Мәскәүдә парадта да катнашалар. Ат парадын Ворошилов үзе кабул итә. Колхозга иң башлап 12 сыер кайта һәм сыер фермасы салына. 1937 елгда сыерлар башы 50 җитә. Шулай ук сарык фермасы, тавык фермасы төзелә. Фермаларда эш механикалаштырылмаган була. Хатын-кызлар җәй көне коедан, кыш көне бәкедән 25 әр көянтә су ташыйлар. Малларны туйдыру эшләре дә кул белән башкарыла. Фермага ут кертелмәгән була. Кешеләр фермада кул фонарьлары белән эшлиләр. Шулай итеп якын тирәдә беренче булып монда «Трактор» колхозы оеша. Бу исем белән 1930 нчы елда район газетасы чыга башлый. Аны кыргызлар мәчетендә бастыралар. Бастыру җайланмасын Казаннан китерәләр. Газетаның редакторы булып язучы Нур Баян эшли. Ул Чаллыга партия чакыруы буенча килә. Еш кына ул авыллар буйлап йөри һәм Иштирәк авылында Аюпов Сөләйман гаиләсендә туктый. Сәламәтлеге начарлану сәбәпле 1932 нче елның августыннан алып ноябрьга кадәр авылда яши һәм эшли, кымыз эчеп сәламәтлеген ныгыта. Моннан ул гаиләсе белән Казанга күчеп китә. Озакламый авылда беренче трактор, беренче автомобиль барлыкка килә. Беренче тракторист Мухаметшин Габдулла була. Ул 1932 нче елда эшли башлый. Беренче автомобильгә Магдануров Хаматша утыра. Шул елларда «Трактор» исеме белән район газетасы чыга башлый.Аны авылдагы Кыргыз мәчете бинасында бастыралар. Ул вакытта дүртъеллык башлангыч мәктәп тә шунда була. Газетаның редакторы итеп язучы Нур Баян билгеләнә.Типография җайланмаларын Казаннан китерәләр. Нур Баян 1932 елда, кымыз эчеп сәламәтлеген ныгыту өчен Иштирәккә килә. Ул Сөләйман Аюпов йортында яши. Сөләйман абыйның үзе турында да газетага язып чыга.

Район карары буенча 1953 елда «Трактор» «Чкалов» исемендәге колхозга кушыла. 1970 елны «Бүләк» совхозы төзелә. Совет власте урнашып кына килә, хуҗалыкны аякка бастыруда авырлыклар аз булмый. Шуңа карамастан илебез киләчәк буынның аң-белеме

турында кайгырта. Беренче мәктәпләр салына, Иштирәк авылында да яңа мәктәп салынып бетә. Бу 1926 нчы ел була, ә 1927 нче елда укулар башлана. Мәктәп ул вакытта башлангыч мәктәп кенә була. 1927 нче беренче укытучы Әлиев Зәки укытырга килә. Яшь укытучы коридорга беренче булып радио керттерә. Бернәрсә дә аңламаган халык радиога ышанмый. Башта укучыларга гарәп, 1929 елдан латин, 1939 елдан соң рус алфавитын укытканнар. Мәктәп 1937 елда җидееллыкка, 1960-61 елны сигезьеллыкка әйләнгән. Ниһаять, 1983-1984 уку елында мәктәп 320 урынлы типовой бинага күчерелә. 1984-1985 уку елында мәктәп урта мәктәп, ә 2014 нче елда тулы булмаган урта мәктәп итеп үзгәртелә.

### 1.4 Өч сугыш батыры.

Авылда шулай ук өч сугышта катнашкан Әхматша бабай да яшәгән. Ул 1893 елда Уфа губернасы, Минзәлә өязе, Афанас волосте, Иштирәк авылында туган. 100 яшьтән артык яши ул. Ишле гаиләдә 9 бала тәрбияләнә. Әти-әниләре артык озын гомер яшәмәсәләр дә, берничә туганы 90 яшькә җитеп үлә. 18 яшендә Әхматша барлык кеше күңеленә «Герман сугышы» дип кереп калган Бөтендөнья сугышына китә. Сугышта өч ел буе ни генә күрми ул. Бик каты яралангач, Чернобыль госпиталендә дәвалана. Сугыш революция белән алмашына. Ул аны Владимир губернасы Ковров шәһәрендә каршылый.

1918 елның октябре. Гражданнар сугышы. 10 кеше белән бергә Әхматша Хөснетдиновны Кызыл Армиягә алалар. Әхматша бабай дүртенче Панков отрядында сугыша. Соңыннан бу 242 нче Идел буе полкына әверелә. Полк Минзәлә, Бирск, Златоуст,Чиләбе шәһәрләрен азат итә. 242 нче полк составында Әхмәтша Хөснетдинов Курганга, Украинага кадәр бара. Шунысы кызык: аның сөйләгәннәре барысы да документлар белән раслана.Чаллы шәһәре музеенда ул хезмәт иткән партизан трядына кагылышлы документлар бар.

1941 ел. Ил тарихына Бөек Ватан сугышы булып кереп калган бу яуга, авылдашлары белән бергә, Әхмәтша бабай да китә. Аңа 46 яшь була. Өч ел 40 көн сугышкан Әхмәтша Хөснетдинов «Кызыл Йолдыз», «Беренче дәрәҗәдәге Бөек Ватан сугышы ордены», «За отвагу», «За боевые заслуги» медальләре белән бүләкләнә. Ул бишенче гвардия танк дивизиясендә танкист-десант була. Карпат буйларындагы Сухот елгасын кичкәндә каты яралана, пуля йөрәгенә тимичә 2 сантиметр гына кала. Бу сугышта ул үзенең ике улы белән катнаша, өчесе дә исән калып авылга кайталар. Әхматша бабай гомере буена вакыйгалар давылында кайнаган кеше. Курыкмыйча төрле эшләргә барып тотынган. Бөтен осталыгын, энергиясен колхоз эшенә багышлаган. Күп еллар «Трактор» күмәк хуҗалыгын җитәкләгән, ферма мөдире, авыл Советы рәисе, гади колхозчы, җыеп әйткәндә һәрчак эштә булган. 104 яшькә җиткән, хөрмәт, ихтирам казанган.

## 1.5.Советлар Союзы Герое – Калимулла Якупов.

Бөек Ватан сугышы еллары да авыл тарихында тирән эз калдырган. Күпме генә вакыт үтсә дә, халык хәтерендә Бөек Ватан сугышы илебез тарихында иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр. Сугышның беренче көннәреннән үк авылның егет-кызлары Ватанны сакларга күтәрелгән. Иштирәк авылыннан да 319 кеше сугышка алына. Ватанын саклап, яу кырында ятып калганнар арасында Иштирәкнең 171 каһарманы бар...

Сугыш елларында Татарстанның 200 дән артык егет һәм кызы Советлар Союзы Герое дигән югары мактаулы исемгә лаек булган. Шулар арасында Калимулла Якупов та бар. Советлар Союзы Герое, «Кызыл Йолдыз», «Сугышчан Кызыл байрак» орденнары кавалеры Калимулла(Николай) Якупов 1920 нче елда Чаллы районы Иштирәк авылында дөньяга килә. Гаиләдә алар дүрт бала үскәннәр. Кәлимуллага 13, иң кече балага 2 яшь булганда Якуповлар гаиләсенә кайгы килә. Урманга агач кисәргә баргач, өсләренә агач авып, әти-әниләре вафат була. Шулай итеп дүрт бала ятим кала. Балалар бик авырлык белән үсәләр, хәтта хәер сорашырга да туры килә. Шулай да бик тәрбияле булалар алар. Кәлимулла мәктәптән соң Чистай медицина колледжына укырга керә, чөнки биредә 3 тапкыр бушлай ашаталар, тулай торактан урын бирәләр. Күпчелек руслар яшәгән Чистайда аның исеме Николай була. (Кайбер документларында Николай (Кәлимулла) дип язылган. – З.Г.) 1939 елда колледжны тәмамлагач, Кама Тамагы районы Клярино авылына эшкә китә. Шул ук елны егетне Кызыл Армиягә алалар. Ул Совет-фин сугышында һәм совет гаскәрләренең Көнчыгыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссиядәге азат итү походларында катнаша. Кайда гына булса да, үзен чын ирләрчә кыю тота.

Илебезгә фашист илбасарлары һөҗүм иткәч, Кәлимулла Бөек Ватан сугышына китәргә карар кыла. 1941 елдан Уфада оешкан 58нче кавалерия полкының медицина пункты фельдшеры була. Шул елның июлендә фронтка китә. Хәрби фельдшер буларак, ул Башкорт кавалерия дивизиясенең 275 нче кавалерия полкы составында Сталинград сугышында катнаша. Бик күп яралыларның гомерен саклап кала.

Медицина хезмәтенең гвардия өлкән лейтенанты К.Я. Якупов 1943 елның 27 сентябренә каршы төндә Нивки авылы янында Днепрны кичкәндә геройлык үрнәкләре күрсәтә:балыкчы көймәсендә, дошман уты астында, 27 тапкыр Днепр елгасын кичеп, плацдармга сугыш кирәк-яраклары китерә һәм яраланганнарны алып чыга. Нәтиҗәдә, 74 солдат һәм офицерның гомерен саклап кала.

СССР Югары Советы Президиумының 1944 елның 15 гыйнварындагы «Кызыл Армиянең генераллар, офицер, сержант һәм рядовой составына Советлар Союзы Герое исемен бирү турында»гы Указы нигезендә, «Немец илбасарлары белән көрәш фронтларында Командованиенең хәрби бурычларын үрнәктөстәүтәгәне өчен «Советлар Союзы Герое»

исеменә һәм «Алтын Йолдыз» медаленә, Ленин орденына лаек була. 1946 елдан медицина хезмәте подполковнигы запаска чыга. 1949 елда Казанда республика партия мәктәбен тәмамлый. Һәм язмышын Чулман буендагы гүзәл шәһәребез белән бәйли. Элеватор тавында авторотада эшли. Аннары «Камдорстрой» трестында идарә башлыгы урынбасары булып эшләп, лаеклы ялга чыга.
Якуповлар гаиләсе ГЭС бистәсендә яшәгән. 2018 елның 30 августында Яр Чаллы шәһәренең Җиңү паркындагы «Геройлар аллеясы» мемориаль комплексында бюсты ачылды. 2007 елдан Яр Чаллы шәһәрендәге бер урам аның исемен йөртә.

**Йомгаклау.**

**1.Авылның бүгенгесе.**

Эзләнү барышында мин шундый нәтиҗәгә килдем: чыннан да, төптән уйлап сайлаганнар Иштирәк авылы урынын.
Милләтне яшәтүче көч ул – татар авыллары һәм аның халкы.Авылның киләчәген аның күренекле шәхесләре, талантлы кешеләре, уңган-булган халкы тәэмин итә.

Иштирәк авылы бер ягыннан җиләккә, чикләвеккә бай урман белән уратып алынган, чишмәле тау астында, елга ярында урнашкан. Табигать туган ягыбызны елгалар, күлләр белән бик юмарт бүләкләгән. Ишкәй буа-күл авылның аерылгысыз өлеше булып тора. Ул – авылда яшәүчеләр һәм килеп йөрүчеләр өчен бик матур ял итү урыны булып тора. Шаярып кына аны авыл «диңгезе» дип йөртәләр. Авылның икенче горурлыгы – Керәч тау. Икенче төрле – Кызыл тау. Күп еллар дәвамында авыл халкы бу тау балчыгын кирпеч сугуда файдаланган. Халык бу балчыкны «керәч» балчыгы дип йөртә. Башка тау һәм калкулыклардан керәч тау төсенең кызыл булуы белән аерылып тора. Аның чагыштырма биеклеге 250 метр. Тау итәгеннән бормаланып чишмә ага.Бөтен бу матурлык табигатьне яратучыларны үзенә тарта. Җәй көне тау итәгендә милли бәйрәм «Сабан туе» үткәрелә. Кыш көне бу чаңгыда йөрү өчен менә дигән урын булып тора. Авыл бөтен яктан диярлек урманнар белән уратып алынган. Урманда кырмыска оясы гөжләвен күзәтергә, урманның шаулаганын, елгаларның челтер-челтер акканын тыңларга була. Монда катнаш урманнарга хас үсемлекләр үсә. Яз һәм җәй көне фиалка, умырзая, хуш исле ландыш чәчәк аткан вакытта бик чуар төсле җәймә барлыкка килә. Урманда меңъяшәр имән, ак тузлы чибәркәй каеннарны, кояшка таба сузылучы нарат, чыршы, усакларны күрергә була. Тагын анда юкә, өрәңге, карагай, тирәк һәм башка төр агачлар, куаклар үсә. Фаунасы да төрле. Аеруча промысел төрләре аерыла: поши, кыргый кабан, куян, тиен, төлке. Кошлар сайравыннан башка бу урманны күз алдына китереп тә булмый. Тукран, күке, сыерчык һәм башка кошлар урманны бик яраталар.

Авыл уртасында фашистлар Германиясен җиңүчеләргә багышланган һәйкәл тора. Һәйкәл янында Бөек Ватан сугышы ветераннары утырткан аллея-парк.

Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, ике мәчет эшли. Мәктәптә «Туган якны өйрәнү» музее бар.

Авыл тарихының бер өлеше булып Вагыйз абыйның Йорт-музее тора. Шәһәребездә танылган табиб-отоларинголог Вагыйз абый Сәйфуллинның Тукай районы Иштирәк авылында урнашкан йорты, беренче карашка, бернәрсә белән аерылып тормый. Ләкин бусагадан атлап керүгә, шунда ук үткәнгә эләгәсең. Гадәти булмаган йорт-музейда совет чорыннан сакланып калган көнкүреш техникасы, һәм савыт - сабадан башлап популяр машиналар коллекциясенә кадәр бар. Йорт-музей Вагыйз абыйның әти-әнисе йорты янында урнашкан. Ул борынгы әйберләрне җыю белән 19 елдан артык шөгыльләнә. Музей ишегалдында биш совет машинасы һәм уннан артык мотоцикл белән башлана, алар арасында атаклы Иж, Урал, Минск. Өстәвенә, бөтен техника хәрәкәттә. Ишегалдында янгын насосы, тукыма станогы һәм үткән гасырларның күп кенә башка көнкүреш һәм хуҗалык әйберләре тора. Йортның фасады СССР чоры орденнары һәм значоклары белән бизәлгән. Йорт эченә кергәч, кунаклар беренче эш итеп пионер бүлмәсенә эләгәләр. Йөзләгән китаплар киштәләргә җентекләп урнаштырылган. Стеллаж буйлап бер-берсенә дистәдән артык төрле самавыр тора. Янәшәдә басма һәм тегү машиналары, проигрывательләр, күмер тимерләре. Диварда борынгы фотоаппаратлар коллекциясе бар. Ашханә дә музей итеп яраклаштырылган. Диварларның берсе сәгатьләр белән капланган. Бүлмә уртасында өстәлдә сары төстәге битләр белән, Труд, Родина, Правда газеталары ята. Шулай ук монда Ленин белән Сталинның чыгышлары язылган пластинкалар җыелмасын күрергә мөмкин (теләсәң, аларны рәтләп торган борынгы патефонда тыңларга мөмкин). Музейның алтын фондында тавыш яздыру аппараты, телевизорлар, фотоаппаратлар, Радио Серенада РЗ 308, Сириус м һәм башкалар саклана.

Бүгенге көндә авылның хәле бик аянычлы, чөнки авылга бетү куркынычы яный. Калын урманнарны кисеп, Иштирәк авылыннан 4-5 км. ераклыкта гына «Түбән Кама Нефть эшкәртү заводы ябык акционерлык җәмгыяте» 2008-2016 елларда үзенең нефть эшкәртү һәм нефтехимия заводлары комплексы объектларын төзеде. Ничә гасырлык тарихы булган авыл зыян күрә, юкка чыгарыла. Җир йөзендә бары ике нәрсә үлемсездер: истәлек һәм хәтер, диләр. Истәлекләрне ничек саклавыбыз, үткәннәрне хәтердә ничек тотуыбыз исә бүген безнең нинди кешеләр булуыбыз турында сөйли торгандыр. Ватанпәрвәрлек – үз илеңә, туган җиреңә, халкыңа, табигатькә, милли традицияләргә, мәдәнияткә мәхәббәт ул.

Гүзәл җирем минем,
Зәңгәр күзле җирем.

Күзләремә карыйсың моң белән.

Чәчәкләренң ямен

Саклар кеше мәңге – мәңгегә!

**Кулланылган әдәбият**


1. Арсланов Л. Ш. Казаков Е. Г. Финны, угры и самодийцы в восточном Закамье. Елабуга, 1993.
2. Гыймадиева Н. С. Имтиханнар өчен сочинениеләр. Казан, 2003.
3. Җәгъфәров Х. Адаштырмас мине юлларым. Казан, 1997.
4. Җәгъфәров Х. Эх, бер урап гомер юлларын. Казан, 2003.
5. Казыйханов В. С. Әхлак дәресләре. Яр Чаллы, 1998.
6. Мәктәп һәм колхоз буенча елъязма – альбом. Тукай районы, Иштирәк авылы, 1958.
7. Рифә Рахман. Татар телендә 100 сочинение. Казан, 2001.
8. Сәйфуллин В.С. Туган авылым Иштирәк.Казан, 2020.
9. Сәйфуллин В.С. Туган авылым Иштирәк. Икенче китап. Казан, 2023.
10. Хафизов Ә. Туган авылым – данлы Эзмә. Казан: Сөембикә, №11, 2004.
11. Җәгъфәров Х. Алданмасын, дуслар, күңелегез. Казан, 2006.

«Туган як» – 25 гыйнвар, 1996 ел., 25 апрель, 1996 ел., 6 июнь, 1996 ел.

12 сентябрь, 1996 ел., 22 ноябрь, 2005 ел.

11. «Якты юл» – 25 июль, 1996 ел., 13 март, 1997 ел.,19 сентябрь, 2000 ел



*Хәйретдинова Әлфинә, 10 нчы сыйныф,*

*Татарстан республикасы Әлки муниципаль районы Нәби Дәүли исемендәге Базарлы Матак гимназиясе муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе*

*Җитәкчесе: Сафина Лилия Гавас кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


Эчтәлек


Кереш

Ташбилге авылы

1.Ташбилге авылының килеп чыгышы һәм тарихы

2.Авылның күренекле кешеләре

Йомгаклау

Кулланылган әдәбият

Кушымталар

I. Кереш

Илебездә бай тарихлы торак пунктлар бик күп.. Ташбилге авылы башкалардан тарихы, анда туып –үскән күренекле кешеләре, табигатенең гүзәллеге, халкының укымышлы, дини булуы белән үзенчәлекле.

Мин шул Әлки районында урнашкан Ташбилге авылында яшим. Авылымның тарихы, халкының тормыш –көнкүреше белән кызыксынам.

Ташбилге авылы тарихын, аның топонимнарын тирәнрәк өйрәнергә булдым, чөнки ул кыйммәтле материал булыр һәм киләчәк буыннарга да тапшырылыр дип уйлыйм. Һәркем үзенең туган җиренең тарихын белергә тиеш дип саныйм.

Фәнни-тикшеренү эшемнең максаты:

-Ташбилге авылының тарихын, топонимнарын өйрәнү.

Максатымнан чыгып, бурычлар билгеләдем:

- төрле чыганаклардан материал туплап,Ташбилге авылының тарихы белән танышу;
- авылымның бүгенге тормышын , табигатен күзәтү,күзәтүләремне чагылдырган фото һәм видеоматериаллар туплау;
- авыл кешеләре белән очрашып, алардан үземне кызыксындырган сорауларга җавап алу;
- тупланган барлык материалны системалаштыру.

Тикшеренү объекты:

Татарстан Республикасы Әлки районы Ташбилге авылы, ягъни аларның географик урыны, топонимнары, кешеләре, анда эшләп килүче төрле структуралар.

II.Ташбилге авылы

1.Ташбилге авылының килеп чыгышы һәм тарихы

Әлки муниципаль районы Ташбилге авылы җирлеге район үзәге Базарлы Матактан 8км ераклыкта урнашкан.
Ташбилге авыл җирлеге составына Ташбилге һәм Урта Биктимер авыллары керә. Җирлекнең административ үзәге – Ташбилге авылы. Ташбилге авыл җирлеге Әлки муниципаль районының Базарлы Матак, Яңа Үргәгәр, Иске Кората, Түбән Әлки авыл җирлекләр территорияләре белән чикләшә. Авыл җирлеге территориясе буйлап Актай елгасы ага. Ул Кама елгасына коя. Җирлек җир асты суларына бай.

Авыл җирлеге территориясенең мәйданы – 4083,43 га, шуның 3722,7 гектары авыл хуҗалыгы җирләре.

Ташбилге авылы янында археологлар борынгы болгар чорларына мөнәсәбәтле авыл хәрабәләре, соңгы болгар чорына караган кабер ташлары булган зират һәм акча хәзинәсе тапканнар.

Д.А.Корсаков җыентыгында күрсәтелгәнчә, Ташбилге авылында 92 ясаклы татар яшәгән. А.Артемьев мәгълүматларына караганда, Актай суы ярына утырган бу авылдагы 137 хуҗалыкта 411 ир-ат һәм 395 хатын-кыз көн күргән, авылда бер мәчет эшләгән. Авылда шулай ук татарлар, руслар, чувашлар яшәгәне билгеле.

Ташбилге авылы заманасында бик күренекле авыл булган. Тарихчы-археолог Һарун Йосыпов бу авыл зиратында XIII-XIV йөзләргә мөнәсәбәтле кабер ташы язмалары тапкан.

Ташбилге авылы оешу турында мондый легенда-риваять бар. Аны Татарстанның Спас районы ташбилге авылында 1928нче елда тарихчы галим Сәед Вахидов язып алган. Әлеге риваять “Татар халык иҗаты” җыйналмасының “Риваятьләр һәм легендалар” томына урнаштырылган. Бөек Болгар Аксак Тимер тарафыннан тар-мар ителгәч, Мөслим баба һәм аның кардәш кабиләсе Актай елгасы буена утыра һәм авыл кора. Бу авылга Таш Билге дигән исем бирәләр. Бу турыда татар халык иҗатының “Риваятьләр һәм легендалар” томында язылган.

Мөслим баба бик галим һәм йөрәкле кеше булган. Аның игътибары Шәһри Болгарның олуглары каршында да зур булган. Шәһри Болгар ханы да Мөслим бабаны олылый, хөрмәт күрсәтә торган булган.

Таш Билгедә моннан берничә йөз еллар алда Мөслим баба нәселеннән Хисаметдин Шәрәфетдин углы (Хисаметдин бине Шәрәфетдин Болгари- Мөслими) дигән галим яшәгән. Ул “Тәварихы Болгария” (“Болгар тарихы”) китабының авторы. Хисаметдин хәзрәт күп җирләр гизгән, күп илләрдәге галимнәрдә укыган бер кеше булган. Ул китап язган, шәкертләр тәрбия кылган. Аның мәдрәсеннән зур галимнәр чыккан.

Хисаметдин хәзрәтнең һәм аның бабасы Мөслим бабаның үзенең дә каберләре Таш Билге авылының Изгеләр өсте басуы дип йөртелә торган кырның Озын алан тау башы дигән тау өстендә. Аларның каберләре һәм кабер ташлары дәүләт саклавында булган тарихи һәйкәл буларак теркәлгәннәр.

Хәзерге вакытта Олы Мөхәммәт дигән шул замандагы икенче бер зур галимнең кабер ташы гына ачык танырлык булып калган.

Билгеле булганча, 1552 елда Казан ханлыгы Явыз Иван тарафыннан яулап алынганнан соң, Казан шәһәре, ханлык җирендәге бистәләр һәм авыллар тар-мар ителә. Халыкның күбесе үтерелә, бер өлеше бүтән урыннарга күчеп китә. Бу калдырылган урыннарга башка милләт вәкилләре, аерым алганда, рус, чуваш, удмурт, йомышлы татарлар (мишәрләр) һ.б. килеп утыра. Таш Билге авылы урынына башка милләт вәкилләре килеп урнашу Чулман аръягында патша хөкүмәте төзегән ныгытмалар белән бәйләнешле һәм ул, нигездә, Казан ханлыгы яулап алынгач, XVIII йөзләрдә була.

1913 елда Таш Билге авылында хәзинә – XIV гасырга караган 500 көмеш тәңкә табыла.

Сәид Габделмәннан улы Вахиди үзенең “Рухи мирас” дигән очерклар җыентыгында Ташбилге авылы тарихы турында үзенең әтисе сөйләгәннәрне язып чыккан. Әтисенең сүзләре: “Без кечкенә вакытта Ташбилге бөтенләй урман эчендә булган. Игенне урман эчләрендәге зур-зур аланлыкларда үстергәннәр. Һәр аланда умарталык өчен бүленеп алган урыннар булган. Бу аланлыкларда бик күп чикләвек агачы үскән, халык көзен шул чикләвекләрне олау –олау шәһәргә илтеп сатып, акча эшли торган булганнар. Авыл урамнары бик тар булган, кара-каршы килүче җигүле атлар көчкә-көчкә генә үткәннәр. Өйләрнекалын бүрәнәләрдән салганнар, өй түбәсен дә такта белән япканнар. Халык хуҗалык тирәсендәге зур эшләрне өмәләр оештырып башкарган.Халык бик дус яшәгән, кичләрен урамда чирәм өстенә җыелып кич утыра булганнар. Урманнарда аюлар күп яшәгән. Авылдан ерак түгел, Изгеләр басуы янында Аю аланы дип аталган урынның барлыгы моның дәлиле. Авыл халкы гореф –гадәтләрне саклаган, дин кануннарын үтәргә тырышкан.

Ташбилге авылындагы “Изгеләр өсте” дип йөртелә торган иске каберлекләр болгарлар заманыннан калган, ул каберлекләрне Ташбилге кешеләре генә түгел, якын тирәдә урнашкан татар авылларының халкы да ихтирам итеп, анда килгәннәр, зыярәт кылганнар.

Ташбилге авылында укымышлы кешеләр күп булган, укый –яза белмәгән кешеләр булмаган диярлек. Һәрбер өйдә кулъкитаплар, Һәфтияк, Коръән саклангaн. Язуга бик оста кешеләр китаплар күчереп язып,башкаларга сатканнар, шулай акча эшләгәннәр. Ташбилге авылының мәһшүр хәзрәте Сафа Габбасовның көтепханәсе ул чорда Спас контонында иң бай көтепханә булып саналган. Ләкин авылда бер-бер артлы зур янгыннар була, халыкның өендә сакланган китаплары янып юкка чыга. Сафа хәзрәтнең дә йорты, каралты –куралары янып бетә, бер генә китабын да чыгара алмыйлар”.

Тикшеренү барышында мин авыл кешеләре белән әңгәмәләр уздырдым. Авыл китапханәсенә барып, басма чыганаклар белән таныштым.

Китапханәче булып күп еллардан бирле Абдуллина Розалия Җәүдәт кызы эшли. Розалия апа миңа Ташбилге тарихы турында күп кенә мәгълүматлар сөйләде:

“Ташбилге авылының инеше актачы, аның ярында Изгеләр өсте, яки Яхшылар өсте. Ул каберлекләргә күмелгән кешеләр –Ташбилге халкының борынгы бабалары. Алар барысы да ислам динендә булганнар. Шуңа күрә тирә-як халкы аларны хөрмәт белән зыярәт кыла, анда килеп нәзер –ниязлар әйтәләр.. Ул каберстанда үскән печәнне чапмыйлар. Хәтта ташбилгенең үзендә яшәүче руслар, чувашлар да бу урынга ихтирам белән карыйлар”,

Изгеләр өстендәге ике каберне мин дә күп тапкырлар күргәнем бар. Ул каберлекләргә яңа чардуганнар ясатып куйганнар. Ташларда язулар гарәф хәрефләре белән

язылган. Мин аларны фотога да төшереп кайттым. Җәй көннәрендә эти-әнием белән дә ул каберлекләр янына барабыз.

Розалия апа менә тагынниләр сөйләде: “Ташбилге кешеләре шәһре Болгарга, Бүләргә зыярәткә йөрүне изге эш дип саныйлар. Болар –Ташбилге халкы өчен изге урыннар, борынгы бабаларыбыз яшәгән урыннар. Болгар белән Бүләргә баруны алар Хаҗга бару кебек кабул итәләр.

Ташбилгенең “Атау” дип йөртелә торган өлешендә борын –борыннан бәрәңге бакчаларын сукалаганда, искедән калган акчалар, зәркәннәр, төймәләр, беләзек һәм йөзекләр, иске йозаклар, иске ураклар табылып килгән.

Ташбилгедә Урыс күле дип йөртелә торган күлне тирәнәйтү өчен казыганда, шуннан зур гына бер бакыр казан табылган.

Озын алан тавының битендә, Озын алан чокырындабик күп чүлмәк ватыклары, элгәреге тәңкәләр табылган, шуңа күрә Ташбилге авылы халкы Болгар ханлыгы заманнарында бу урыннарда кечкенә генә бер шәһәр булган дип уйлый”.

Тикшеренү алып барганда, Әлки районы Нәби Дәүли исемендәге Базарлы Матак гимназиясендә укытучы булып эшләүче Абдуллина Илшадия Абдулла кызы белән дә сөйләштем. Илшадия апа үзенең дә олы улының тарих белән, археология белән кызыксынуы турында сөйләде. Ул да иске акчалар, чүлмәк ватыклары тапкан булган икән. Илшадия апа миңа Ташбилге авылының табигате турында, атамалар турында сөйләде: “Ташбилге авылы кара туфраклы тигезлекләргә урнашкан. Авылыбыз тирәсендә, бигрәк тә Актай елгасы яларында торф запасы күп. Климаты –уртача континенталь.Авылның тирә –ягы урманнар, күлләр, чишмәләр белән әйләндереп алган.

Көньяк- көнчыгышында “Руша урманы”, көньягында –Зур урман”, көньяк –көнбатышында “Сыерчык кушы” урманы, Аю аланы. Авылның төньягында “Кыргый өрәңге” посадкасы, көнчыгыш якта “Нарат” посадкалары матур булып үсеп утыра.

Авыл тирәсендә чишмәләр дә күп. Исемнәре, кызганычка каршы, онытылган. Сыерчык кушы алдында тау астыннан саф сулы чишмә агып чыга. Икенче бер чишмә “Ырсай аланы”ннан агып төшә. Авылдан 4 км ераклыкта табылган чишмәне ташбилге авылы кешесе Ситдыйков Исмәгыйль абый төзекләндергән, шуңа халык аны хәзер “Исмәгыйль чишмәсе” дип йөртә”.

Ташбилге авылы халкы тырышлыклары, уңганлыклары белән аерылып тора. Бүгенге көндә дә авыл гөрләп яшәп ята. Ташбилгедә барлыгы 417 кеше яши, шуларның 386сы татарлар, 24 рус , 7 чуваш.

Авылдагы йортлар барысы да төзек. Авыл уртасында мәһабәт бина –яңа гына төзелгән мәдәният йорты. 1998нче елда авылдагы торак йортларга газ кертелгән.

Ташбилгедә беренче мәчет 1849нчы елларда төзелә, икенчесе -1881нче елда. Ләкин ул мәчетләр совет власте елларында җимерелеп юкка чыгарыла. 1991нче елда яңа мәчет төзелә.

Авылда иң беренче рус –татар башлангыч мәктәбе 1912нче елда ук ачыла. Бүген инде Ташбилге авылы кечкенә генә авыл, аның үзендә мәктәп ябылды. Укучылар Базарлы Матак гимназиясенә йөреп укыйлар.

V. Күренекле кешеләре

Алда күрсәтеп үткәнчә, Ташбилге халкы укымышлы булган. Чыгышы белән Ташбилгедән булган күренекле шәхесләр дә шактый. Шуларның берсе - Сәид Вахиди.

Сәид Габделмәннан улы Вахиди 1887нче елның 31нче маенда Казан губернасының Спасс өязе Таш Билге авылыда туган. Туган авылының һәм Иске Рәҗәп авылының мәдрәсәләрендә укыганнан соң, 1905 елдан Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала. 1911 елда укуын тәмамлый һәм туган ягында балалар укыту белән шөгыльләнә башлый. Башта Уразлы мәктәбендә эшли, соңрак Мамадыш якларына китә. 1912 елда туган авылы Ташбилгедә мәктәп ачтыруга ирешә.[2]

Авылларда укытучы булып эшләгән елларда татар тарихына караган кульъязма әсәрләрне туплый башлый. Күп кенә язма китаплар һәм документлар туплый. Шул исәптән, Казан ханлыгы чорына караган социаль-юридик документлардан берсе булган Сәхип-Гәрәй хан ярлыгын таба.

Совет чорында Сәет Вахиди кульъямалар эзләү эшен дәвам итә. 1925 һәм 1930 елларда үзе җыйган сирәк һәм уникаль кульъязмалар байлыгын Казан университетының китапханәсенә бүләк итә.

Казанда Үзәк татар музеенда Көнчыгыш кульъязмалары бүлеген җитәкли, Казанның төрле югары уку йортларында белем бирә.

. 1928 -1930нчы елларда Спасс һәм Әлки районнары авылларының һәрберсенә экспедецияләр оештыра, авылларда туплаган материаллар, язган хезмәтләре Татарстан Республикасы музейларында саклана. Ул аларны китап итеп бастырып чыгарырга өлгерми кала. Репрессияләр чоры корбаны. 1937нче елда гаепсезгә кулга алына , төркичелектә һәм бәйсез татар дәүләте төзергә җыенуда гаепләп ,1938нче елның 5нче гыйнварында атып үтерелә, 1958 елның 9 гыйнварында Сәет Вахиди тулысынча аклана, гаепсез дип табыла.

2018нче елның 7нче сентябрендә Әлки районы тарихында беренче тапкыр галим-археограф, мәгърифәтче, репрессия корбаны Сәет Вахидны зурлап искә алу чаралары булып үтә.

2017нче елның маенда Сәет Вахидиның тууына 130 ел була, Казанда ул соңгарак калып булса да билгеләп үтелә - Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты октябрь аенда Сәет Вахидига багышланган фәнни-гамәли конференция уздыра, “Рухи мирас. Эзләнүләр һәм табышлар” сериясеннән аның җыентыгын чыгара, ахырда конференция материаллары да аерым китап булып басылып чыга. Сәет Вахидиның иҗатын һәм тормышын яктыртуда “Мәдәни җомга” газетасы да зур өлеш кертә - әле сентябрь аенда ук язучы, тарихчы Фәүзия Бәйрәмованың “Атылган галим” дип аталган язмасы, ә ноябрь аенда журналист Хәмзә Бәдретдиновның “Үзен гаепле дип танымаган” дип аталган күләмле һәм җентекле хезмәте басылып чыга. Ә менә Сәид Вахидиның туган якларына язучы, тарих фәннәре кандидаты Фәүзия Бәйрәмова 2018нче елда килә һәм халык белән очрашулар уздыра. Бу очрашуларда шулай ук Сәет Вахидиның ерак туганы, үзе дә Әлки районының Абдул Сәлман авылында туып-үскән, хәзер Түбән Кама шәһәрендә яшәүче, туган төбәге турында күп хезмәтләр язган, Әлки районының Мактаулы гражданы Мансур Ганиев та катнаша.

Тарихчылар белән беренче очрашу район үзәге Базарлы Матак бистәсенең С.М.Лисенков исемендәге туган як тарихын өйрәнү музеенда булды. Очрашуда Әлки районы хакимият башлыгы урынбасары Рәшит Билалов, музей директоры Мария Платонова, шулай ук Базарлы Матак, Алпар, Түбән Әлки, Карга, Яңа Чаллы, Иске Чаллы, Бибай Чаллысы, Үргәагар, Юхмачы, Әхмәт, Иске Матак, Иске Тахталы, Түбән Кәчи, Хузангай авылларыннан татар теле һәм тарих укытучылары катнаша. Фәүзия Бәйрәмова аларга Сәет Вахиди, аның хезмәтләре, тормышы һәм язмышы турында сөйли, галимнең Мирасханә тарафыннан чыгарылган юбилей җыентыгын бүләк итә. Ул шулай ук музейга Сәет Вахиди белән бәйле конференция материалларын, газета язмаларын да тапшыра, үзенең “Татарская Мать Чингиза Айтматова” дип аталган китабын бүләк итә.

Очрашуда катнашкан төбәк тарихын өйрәнүче Мансур Ганиев музейга Сәет Вахидиның шәҗәрәсен бүләк итә, аның мөгаллим һәм музей хезмәткәре буларак нинди зур эшләр башкарганын сөйли.

Хисаметдин әл-Мөслими – бөек тарихчы, “Тәварихы Болгария” (Болгар иле тарихы) исемле китап авторы (1902). Күренекле сәяхәтче, күп илләрдә белем алган. Ул күп фәнни хезмәтләр язган, үзенең дәвамчыларын хәзерләгән, мәдрәсәдә шәкертләр укыткан. Ул укыткан шәкертләр арасыннан күп кенә күренекле галимнәр чыккан.

Максудов Таһир Хәбибрахман улы (12.10.1922 – 15.09.2010) – Бөек Ватан сугышы инвалиды, атказанган укытучы, Ватан алдындагы хезмәтләре өчен “Батырлык өчен”, “Сталинград оборонасы өчен”, “Сугышчан казанышлар өчен”, “Германияне җиңгән өчен” медальләре, 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, күп санлы Почет грамоталары белән

бүләкләнгән. Галәветдинов Габделхәй Нуретдин улы (05.07.1920- 04.05.2008)- Бөек Ватан сугышы инвалиды, Ватан алдындагы хезмәтләре өчен “Батырлык өчен”, ”Сугышчан казанышлар өчен”, “Германияне җиңгән өчен” медальләре, 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләнгән.

Әхмәдиев Әгъзам Гарәфетдин улы (09.06.1932)- авылның почетлы гражданины, хуҗалык һәм партия эшчесе.

Халиков Фазыйл Вакиф улы ( 28.12.1928-06.09.2009) – Татарстан АССР ның атказанган механизаторы.

Латыйпов Рифкать Хәбир улы (25.03.1932 – 23.06.2018) - Ленин ордены кавалеры.

Хәсәнов Солтан Сәлах улы (09.01.1948) – Татарстан АССР ның атказанган агрономы.

Вахитов Каюм Шәйхаттар улы (15.03.1923-17.06.1993) – Татарстан АССР ның атказанган механизаторы.

## Йомгаклау

Ташбилге авылы тарихын өйрәнүне бер тикшеренү эше кысаларында гына тәмамлау мөмкин түгел. Әле аның топонимнарын аерым алып өйрәнәсем килә. Бу юнәлешне инде мин башлап җибәрдем.

Шулай итеп, мин куелган максатыма ирештем:

- төрле чыганаклардан материал туплап,Ташбилге авылының тарихы белән таныштым;
- авылның бүгенге тормышын , табигатен күзәтеп чыктым,күзәтүләремне чагылдырган фото һәм видеоматериаллар тупладым;
- авыл кешеләре белән очрашып, алардан үземне кызыксындырган сорауларга җавап алдым;
- тупланган барлык материалны системалаштырдым.

Нәтиҗәләр:

5. Әлки районының Ташбилге авылы табигатьнең урман-кырларга, чишмә –күлләргә бай урынына урнашкан, топонимик атамалар кеше исемнәренә, географик урынга, топонимнар тирәсендә урнашкан объектларга бәйле рәвештә барлыкка килгән;
6. Ташбилге авылы халкы күрше –тирә авылларда яшәгән халыклардан дингә, мәгърифәткә мөнәсәбәте буенча аерылып тора;
7. Авылда элек-электән игенчелек төп кәсеп булган, шул ук вакытта мич чыгаручы, балта остасы, умартачы, китап күчереп язучы һөнәр ияләре дә яшәгән;

## Кулланылган әдәбият исемлеге

1. Гарипов Ф.Г. «Рухи башкалабыз: Мщшёър татар авыллары» - Казан: Мщгариф, 2005 -247 б.

2. Духовное наследие: поиски и открытия/ под ред. И.Г.Гумерова. – Казан: ИЯЛИ, 2017 – Выпуск 4 -280 с.
3. https://alkeevskiy.tatarstan.ru/tat/Tashberdino.htm
4. https://tatfrontu.ru/tt/cards
5. https://ru.wikipedia.org/wiki/Тяжбердино
6. https://ru.wikipedia.org/wiki/Вахидов,_Сайид_Габдульминанович
7. https://msu.tatarstan.ru/index.htm/news/205188.htm
8. https://tt.wikipedia.org/wiki/Сәет_Вахиди#cite_note-4
9. https://vk.com/wall471163719_6
10. https://alki-rt.ru/news/ya%D2%A3alyiklar/lki-rayony-tarikhynda-berenche-tapkyr-set-vakhidny-zurlap-isk-alu-charalary-bulyp-tte-foto

*Хәсәнова Асылъяр, 4 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Мөслим гимназиясе " МБМУ (мәктәп-электрон белем бирү компетенциясе үзәге)*
*Җитәкчесе: Хәсәнова Миләүшә Кәшбетдин кызы, башлангыч сыйныфлар укытучысы*

Эчтәлек

Кереш ……………………………………………………………………............ 3
Төп өлеш ........................................................................................................ 4
1. 1. “Кушамат - ябышкак исем”......……………………………………............... 4
1.2. “Кушаматлар тарихы” ни сөйли?……….........……………………….......... 5
Йомгаклау ........………………………….....................................................................14
Әдәбият исемлеге ………………………………………………………............. 15

**Кереш**

Безнең Вәрәшбаш авылында бик күп еллар мәктәптә укытучы булып эшләгән, бүгенге көндә авылыбызның мөхтәрәм кешесе – абыстае булып хезмәт күрсәтүче Тәзкирә апа Низамиева яши. Ул мәктәптә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укыткан һәм балаларга төпле белем бирү белән беррәттән авыл тарихын туплаган. Бу тарихи елъязмалар компьютерда җыелып, минем әниемнең ярдәме белән, китапчыклар (брошюра) булып бастырылды. Алар авылдагы “Туган як” музеенда саклана.

Музейга кергән саен? мин аларга гел игътибар итә идем. Бигрәк тә “Кушаматлар тарихы” дигәне үзенә җәеп итте. Шуңа күрә дә бу китапчыкның эчтәлеге белән кызыксына башладым.

Фәнни-эшнең темасы: “Кушамат - ябышкак исем”

Фәнни-тикшеренү эшенең максаты: Мөслим районы Вәрәшбаш авылы кешеләренә бирелгән кушаматларының килеп чыгышын өйрәнү.

Бурычлары: Вәрәшбаш авылында яшәүче кешеләргә бирелгән кушаматлар тарихы белән танышып, аларның килеп чыгышын өйрәнү, ачыклау, нәсел кушаматларын барлау `һәм алар турында башкалага да җиткерү.

Тикшерү объекты: Вәрәшбаш авылында яшәүче кешеләргә тагылган кушматлар.

Тикшерү методы: кушаматлар (татар антропонимикасы) [3] буенча фәнни әдәбиятны уку, авылдагы кушаматларны өйрәнү, анализлау.

Фәнни эшебезнең актуальлеге: кушаматлар тарихы белән танышып, нәсел чылбырын өйрәнү.

**Төп өлеш**

**1. “Кушамат - ябышкак исем”**

“Авыл җирендә һәр кешенең диярлек кушаматы бар. Бу бик үк әдәпле гамәл булмаса да, кайчакта файдасы да тия. Бигрәк тә авылда бер үк исемдәге кешеләр күп булганда.

Кушаматлар кайчан барлыкка килгәндер, анысы хәзергә билгесез. Шунысы бәхәссез, аларда халкыбызның үткәне чагыла. Авылдашларыбызның үткәненнән бер йотымын гына булса да, сезгә дә тәкъдим итәбез” – дип башлап җибәрә Тәзкирә әби үзенең язмасын.

Бу китапчык белән танышканчы, мин өйдә әти белән әнинең сөйләшкәндә кулланган “сәер” сүзләренә игътибар иткәнем бар иде. Алар: “Диюләргә кереп чык әле, Борчак кызына әйттем инде, бүген Бөкене күргән идем, Җен Фәритенә шалтыратып белеш” кебек аңлаешсыз исемнәр белән аралашалар. Ә баксаң, бу сүзләрләрнең мәгънәсе шушы китапта икән. Безнең авылда кушаматсыз яшәүчеләр сирәктер. Хәтта, кайберләре сорап та тормыйча тагылган кушаматлар. Тигәнәк кебек килеп ябышкан да, мәңгелеккә берегеп калган. Үпкәлә, гарьлән, кимсен, сөен, шатлан – башкаларның анда бер эше дә юк. Ул гына түгел әле, кушамат синең нәсел ыруыңа да ябышып кала.

“Кушамат” сүзе – ике сүз кушылу юлы белән ясалган: кушама (“кушма”) + ат (“исем”). Кешенең рәсми төп исеменә кушым, өстәмә ат (исем) дигән мәгънә белдерә. Кушамат терминының икенче өлеше борынгы төрки “ат” сүзеннән гыйбарәт булуы да, аның бик күптәннән барлыкка килеп, төп исемгә өстәмә атау категориясе буларак кулланылуын раслый. Билгеле булганча, иске татар телендә “ат” сүзе “исем” мәгънәсендә йөргән.

Авылда кушамат ияләренең күбесе инде гүр ияләре, фамилияләре дә онытылып бара, ә менә кушаматлары: кушамат артына яшеренгән төс-кыяфәтләре, буй-сыннары, хәтта сөйләнгән кайбер сүзләре һаман да истә аларның. Гомумән, авылда яшәүче халык кушаматларга шулкадәр күнеккән, хәтта бу алар өчен табигый күренеш буларак кабул ителә. Кешегә кушыла торган кушаматларның этимологиясе борынгы заманнарга барып тоташа. Аларның кайберләрен бөтенләй аңлатып булмый. Нәсел һәм шәхси кушаматларның нигезендә кешенең тышкы кыяфәте, нинди дә булса гадәте, кимчелеге, яраткан шөгыле һәм характер үзенчәлеге ята. Авыл халкы кечкенә генә территориядә яшәсә дә, анда көн күрүче һәрбер кешененең үзенә генә хас, берсеннән-берсе кызыклы кушаматлары бар. Бүгенге фәнни-тикшеренү эшендә дә шуларның берничәсенә тукталып китәсе килә.

**2. “Кушаматлар тарихы” ни сөйли?**

Низамиева Тәзкирә әбинең “Кушаматлар тарихы” китапчыгында 50 гә якын кешенең кушаматлар тарихы тупланган. Аларның һәрберсенең үзенчәлекле һәм кызыклы тарихы бар. Тарихи елъязмаларны ничек бар, шулай тәкъдим итәбез, чөнки автор хокукларын бозарга хакыбыз юк.

***Бай Галимҗан.***

*Авылның иң оста рәссамы. Безнең авылга ул 1962- 1963 нче елларда кайтты. Чыгышы белән Иске Вәрәш авылыннан. Безнең авылга күчүенең тарихы болай. Галимҗан абзыйның сеңелесе Фәрдәнә (ата бер, ана башка) безнең авылның Идрисов Марсель исемле кешесенә кияүгә чыкты. Фәрдәнәнең әнисе дә безнең авылга күчеп килде, чөнки бик карт иде. Галимҗан абый Магаданнан үги әнисе Маһираван әби янына кайтты. Бик бай кайтты. Авылда беренче телевизор алучы да ул булды. Бөтен авыл халкы аларга телевизор карарга йөрде. “Моның кешеләре каян килеп чыга соң ?”- дип, авыл өлкәннәре телевизорның артларын карап йөри торган булганнар. Гомумән, ул елларда Галимҗан абзыйның өе клуб хезмәтен үтәде. Ә Магаданга ул ипи карточкалары ясаган өчен эләгә. Сугыш (1941-1945) вакытлары була ул. Сталинны ишәккә атландырып ясаган, шуның өчен кулга алганнар дигән сүзләр дә йөри халык арасында. Галимҗан абзый гаҗәеп оста рәссам иде.*

*Бервакыт Әмирҗан абый Дәүләтшин (укытучы) мондый вакыйга сөйләде. Мөслимдә Кузьма Иванов исемле бик оста рәссам бар, Әмирҗан абзыйларның туганы инде ул. Шул Кузьма белән Галимҗан абзый бәхәсләшеп киткәннәр. Кем 10 минут эчендә Ленин рәсемен ясый ала? Галимҗан абзый 4-5 сызык сызган да, 2 минут эчендә Ленин башын ясап та куйган. Менә шундый талант иясе кеше иде ул Галимҗан абзый. Гомер буе өйләнмәде, ялгыз яшәде. 2009 нчы елда Мөслимдәге картлар йортында вафат булды.*

*Вәрәшбаш авылының исемен тарихка калдырган шәхес тә әле ул. Мәскәүнең геология музеенда "№163 Вәрәшбаш" исемле метеорит саклана, бу күк ташын да Галимҗан абзый тапкан һәм бер кечкенә кисәген (10 кг) Мәскәүгә җибәргән иде. Менә шундый кеше иде инде ул Мәһдиев Галимҗан абый.*

*Бай кушаматы тагылып калуның сәбәбе – авылда Галимҗаннарның өчәү булуында. Икенчесе –Камали Галимҗаны, бабасы Камалиев булганга шулай атыйлар, өченчесе –Ахун Глимҗаны. Ахунҗанов фамилиясеннән бозып ясалган.*

Таш турында сүз киткәч, "Астроном Расих" турындагы кушамат тарихын да кертәбез инде.

***Астроном Расих***

*1983 елда Бүратау чокыры янындагы басуда Хуҗин Дәүләт белән Мәһдиев Галимҗан җир эшкәртәләр икән. Шунда культиватор калаклары арасына кара төстәге шактый зур таш килеп кысыла. Галимҗан абзый бу ташны алып ташламакчы була, ләкин нигәдер күңеленә шик төшә, чөнки таш культиватор калагынаябышып тора икән, ягъни магнит кебек. Галимҗан абзый моны өенә алып кайта. Дусты Гарипов Расих бу ташны ватып, Мәскәүгә СССРның Фәннәр Академиясенә җибәрергә тәкъдим итә һәм алар шулай эшләгәннәр дә. Ташны посылка итеп салу, Фәннәр Академиясенең адресын табу эшләре артыннан Гарипов Расих йөргән. Озак көттерми Мәскәүдән телеграмма һәм акчалата бүләк килеп төшкән. Бу таш метеорит икән һәм ул СССР Фәннәр Академиясенең метеоритлар бүлегендә "№ 106 Вәрәшбаш" исеме астында теркәлеп тә куелган.*

*Ташның ватканнан калган өлеше дә бар бит әле. "Бездә тагын бар әле ул", - дип телеграмма суккан Расих Мәскәүгә. 2-3 көн дә үтми, Мәскәүдән килеп төшәләр Вәрәшбашка һәм теге кисәкне дә алып китәләр. Шулай итеп икенче метеорит та "№ 163 Вәрәшбаш" исеме астында теркәлә. Галимҗан абзый бу ташны ваткан вакытта өч кисәккә ярылганын әйтә, ләкин өченче кисәкне таба алмыйлар. Соңыннан гына исенә төшә Галимҗан абзыйның. Ул аны яңа йорт салу өчен казыган фундаментына салган икән бит. Моннан берничә ел элек Мәскәү студентлары килеп, ул фундаментны актарып карадылар, ләкин таш табылмады. Галимҗан абзый ул вакытта бик каты авырып, картлар йортында яши иде инде. Йортын салып керергә насыйп булмады аңа, ә дусты Расих вафат булган иде инде. Шулай итеп өченче кисәк метеорит эзсез югалды. Ә Расихка кушамат шушы вакыйгадан соң тагылды.*

*Бездә таш та гади түгел,*
*Күктән төшкән метеорит.*
*Акчаң бетсә, сер итеп әйтәм,*
*Мәскәвенә төяп илт!*

*(И.Хафазетдинова, автор-башкаручы).*

*Шундый хикмәтле, талантлы кешеләр яши безнең авылда. Мәктәп музеенда шушы метеоритны тапкан өчен Галимҗан абыйга һәм Расихка җибәрелгән мактау грамотасы саклана.*

"Күршеләр, туганнан да кадерле кешеләр"- ди миңа әни. Ә безнең күршедә "Дию"ләр яши. Өйдә тоз бетсә дә, берәр әйбер кирәк булса да: "Диюләргә кереп чыкмыйсыңмы? Бәлки аларда бардыр...." дип, әни безне күршеләргә кертеп җибәрә. Кем соң ул Дию диярсез? Хәзер танышып китик әле.

***Дию ( Язарга рөхсәт алынды).***

*Ирекле авылы кешесе Гарипов Хамидулла абыйга бирелгән кушамат бу. Бик эшчән, озын буйлы, киң җилкәле, чибәр кеше иде Хәмидулла абый. Кушаматны хатыны Икълимә апа тапкан. Физик эшне умырып эшләгәнгә тагылган инде ул. Салам төяргә барса, бер арба саламны ике генә күтәреп салган, эскертләүгә барса, бер чүмәлә печәнне өч чатлы агач сәнәк белән эскерт башына очырган. "Дию пәриеме әллә син, ник шул кадәр күтәрәсең", - ди икән хатыны Икълимә апа. Шуннан киткән инде ул "Дию" гә әйләнеп. Хәмидулла абыйның кече улы Рафис сөйли: "Безнең әтинең бер генә кайгысы бар иде. "Нигә төн була икән ул, күпме эш эшләнмичә кала бит", - дип уфтана иде", - ди. Менә шундый эшчән, оста гармунчы иде Хәмиулла абый. Үзенә охшап балалары да эшчән, талантлы булдылар. Алда язылган "Астроном" кушаматлы Расих та аның улы, мәрхүм инде, яшьли китеп барды. Шигырьләр язучы, әллә ничә төрле уен коралында уйный белүче иде. Төп йортта яшәүче кече улы Рафис та оста гармунчы иде. Әтиләре мәрхүм булгач, "Дию" кушаматы аңа, аның балаларына тагылып калды. Бүгенге көндә дә, аларны шулай дип йөртәләр.*

*Рафисның дүрт баласы да талант ияләре. Үзләре шагыйрь, үзләре җырчы, үзләре музыкант алар. Кече кызы Алсу музыка училищесында белем алып, "Яңа дәвер" группасын оештырды. Казанда "Арыслана" псевдонимы белән концертлар куеп йөрде. Бүген Сочида яши. Олы кызы Айгөл бассейнда тренер булып эшли. Бер улы диңгезче, берсе Яр Чаллыда яши.*

*Бер истәлек.*

*Тукайның 100 еллыгына сочинениеләр конкурсы игълан иттеләр. Гариповларның икесе дә бу конкурста катнашып, призлы урыннар алдылар. Язмалары Казанга, республика ярышында катнашты, алар грамоталар белән бүләкләнделәр. Шул Гариповларның Рамил дигәне сочинениесен болай тәмамлаган.*

*- Алай да үлеп котылдың әле, Тукай абый. Бу кадәр әче телең белән сине барыбер атып үтергән булырлар иде", - дигән. СССР таркалган чорлар бу. Радионы ачасыңмы, телевизорнымы гел үтереш турында сөйлиләр. Шуңа ишарәләгәндер инде. Язманы*

*төзәтмәдек, шул килеш Казанга китте. Районнан килгән комиссия членнары (сочинениеләргә бәя куючы комиссия инде) гына көлеп: "Теге егетегезне күрсәтегез әле", - диләр иде. Менә шундый талантлы балалар үстерделәр Рафис белән Фәндәрия. Фәндәрия үзе дә бик талантлы, эшчән килен булды. Кул эшләренә, аш-суга бик оста, турларыннан үтеп китсәң, һәрвакыт чип-чиста итеп юылган дүрт-биш бау кер эленеп торыр ишегалларында.*

Әйе, чыннан да бик яхшы кешеләр безнең "Дию" күршеләребез. Һәрвакыт йөрешеп торабыз, эшләребез дә, ашларыбыз да уртак безнең.

Кушаматлы кешеләр чыннан да күп икән бездә. Диюе булгач, Җене дә калмас инде. "Җен Фәрит дип йөртә торганы да булган, анысы минем әтинең дусты. Ләкин ул бүген исән түгел инде, ләкин әти аның турында бик кызыклы вакыйгалар сөйли. Җор телле булган ул "Җен абый".

Алдагы кушамат тарихы белән танышуны дәвам итик әле.

***Борчак Расих.***

*(Язарга рөхсәт алынды)*

*Җәйге эссе көн, койма кырындагы күләгәдә 3-4 яшьлек малай уйнап утыра. Авылның электригы Расих үтеп бара. Теге бала:*

*- Исәнме, Борчак абый,- дип сәлам бирә.*

*-Әй, малай, кем әйтте сиңа мине борчак дип, Расих абыең булам мин ,- ди икән электрик. Бәләкәй малай курка калган.*

*-Бәй, әти дә, әни дә сине борчак диләр бит ,- ди икән шәрә малай.*

*Шушы урында бер истәлек сөйләп китәсе килә. Бер төркем бала-чага, басу каравылчысыннан качып кына борчак ашарга киттек. Борчакның каешланып җитешкән чагы бу, бик тәмле чагы. Туйганчы ашадык борчакны. Меңкаран чишмәсенә төшеп су эчтек. Бераздан эчебез авырта башлады. Ике көнсез бетмәде бу авырту. Бөтенебезне "күбенгән борчак" дип үрти башладылар. Бераздан онытылды бу кушамат. Ләкин Расихка ябышып калды. Кыска буйлы һәм шактый таза гәүдәле булган өчен аңа "Борчак" кушаматы тактылар. Кушамат тагуга иң беренче олы кешеләр сәбәпче бит, балалар шулардан үрнәк ала.*

Бүре –ерткыч җанвар. Аның турында элеке әбиләр бик куркып сөйлиләр. Әбиләр сөйләве буенча, элек ат саклау гадәтләре булган. Шул ат көтүләренә бик еш булмаса да, бүреләр һөҗүм ясаган. Без хакта Галимҗан Ибраһимовның "Алмачуар" [1] хикәясендә дә укып беләбез. Димәк, "Бүре" кушаматы каты бәгырьле, усал характерлы кешеләргә тагылган. Безнең авылда алар өчәү булганнар икән. Безнең "Бүреләр" нинди икән, танышып китик әле.

***Бүреләр.*** *Бүре Дәүләт. Бүре Нурмый. Бүре Нәһия.*

*Бүре кушаматы иң беренче Дәүләт абзыйга тагылган. Сугыштан соңгы авыр еллар. Дәүләт абзыйның берсеннән-берсе кечкенә 8 баласы бар. Аларның тамакларын туйдырасы, өс-башларына юнәтәсе бар. Колхозчыларның "таякка" эшләгән еллары бу. Бер көн эшлисең – бер таяк сызыла, ике көн эшлисең – ике таяк. Шул рәвешчә ел буе. Икмәк суккач, таякларны саныйлар. Бер таяк башына 200, яки 300 грамм икмәк бүләләр. Менә шулар белән 10 җанны асрарга кирәк. Колхозчыларның эшләсәң дә шул бер таяк, эшләмәсәң дә шул бер таяк дип йөргән заманнары. Күбесе эшләмичә, күренеп кенә китү ягында. Көн буе күләгәдә ял итеп ятсалар да була. Ә Дәүләт абзый алай эшли алмый. Аңа балаларын үстерергә кирәк. Абзыең бригадир әйткән эшкә бара, әйтик, салам эскертләргә ди. Үзенә тиешлесен һич туктамыйча эшли-эшли дә, кайтып китә икән бу. Бер ыргытканда эскерт башына бер чүмәлә (кечерәк бер ат йөге кадәр) саламны ыргыта иде, дип сөйли замандашлары. Шундый көчле кеше була ул. Өендә итек баса (ул эшнең дә остасы иде), яки урманга китеп зелпе тамыры җыя. Зелпе агачының тамыр кабыгыннан каучук ясаганнар. Шул кабыкны урманчыга (лесник) тапшырып, азмы-күпме акча алган, яки кемгә дә булса бура бураган, өй салган. Бригадир да, колхоз рәисе дә моның холкын сындыра алмаганнар. Авылда яшәргә мөмкинлек тә бирмәгәннәр һәм ул Чаллы якларына китеп, бер лесхозга эшкә урнаша. Гаиләсен дә шунда алып китте. Лаеклы ялга чыкканчы шунда эшләп, күрше авылга кайтып төпләнде. 90 яшенә тикле мал асрап яшәде.*

*Кече малае сөйләгәннәрдән:*

*-Әти белән печән чабарга киттек. Мин бер-ике покос чабам да, ял итеп алам, ә ул һич туктап тормыйча 5 сәгать буе печән чапты. Яше 86 да, күзе дә юньләп күрми, югыйсә. Менә шундый үзенчәлекле үҗәт холкы өчен тагылгандыр инде ул кушамат.*

*Ә алда телгә алынган Нурмый абый һәм Нәһиягә ул кушамат ни өчен тагылды икән? Бәлки аларның да холыкларында Дәүләт абзый холкы белән аваздаш яклар булгандыр.*

Кушаматлар кешеләр белән булган вакыйгаларга таянып та тагылган. Шундыйлардан бер тарих....

***Муканет Райхан***

*Вәрәшбашның мал табибы ул Райхан. Сыерың чирләп киттеме, бозавыңның аягы авыртамы, сарыкларыңның күзенә ак төшкәнме, гомумән, малда нинди авыру бар, бөтенесенә Райхан кирәк. Шуның өчен аларның ишек юлы бер дә ябылып тормый. Капкаларының һәрвакыт ачык булуының сәбәбе дә бар. Райхан бер кешене дә кире какмый. Эш коралларын күтәреп хәзер килеп җитә. Авыл кешесе өчен бик кирәкле һөнәр иясе ул. Әле алай гынамы соң?! Бер карауда малыңның чирен әйтеп бирә, тиешле дәвасын куллана. Шуның өчен авыл халкы бик рәхмәтле Райханга.*

*Ә кушаматның тарихы болай. СССР заманнарында булган вакыйга инде бу. Һәр колхозчы башына 2 ц дан артык икмәк бирмиләр. Малларга фураж юк. Бер абзый сыер чирли дип Райханны чакыра. Райхан сыерга бер карау белән:*

*- Абзый, сыерыңда “муканет” чире бит, - ди.*

*Бер дә ишетелмәгән сүз булганга күрә абзый аптырап кала.*

- *Нинди чир соң ул, аны ничек дәвалыйлар?- ди.*
- *Мука нет чире бу, абзый, он юк дигән сүз була,- ди Райхан.*

*Билгеле инде абзый фураж юнәтеп, сыерына тәрбия күрсәтә башлый.*

*Муканет кушаматы Райханга шулай тагыла.*

Ул кушамат тагу безнең гаиләне дә урап узмаган. Мәсәлән, минем әтинең әтисен (бабайны) “Быгыйм Таһир” дип йөрткәннәр. “Карт бабайны “Бакыр Кәшби”, җизнәй абыйны “Шомбай”, әтиемне “Амню” (Алмаз исемле), әниемне “Миләш” (Миләүшә исемле) дигәннәр. Боларның да һәрберсенең үз тарихы, үз кыйссасы бар. Алдагы кушамат әниемнең әнисе, минем ерак әбиемнеке, танышып китик әле.

**Гармунчы Мәмдүдә (Мәмүч)**.

*Хатын-кыз булганга аптырамагыз. Без яшь чакта бердәнбер*

*гармунчы кыз иде ул. Кайчакта гармунчы егетләрне үпкәләтеп ташлыйбыз һәм алар клубта бездән үчләрен алалар. Бөтенесе сүз берләшәләр дә, безгә гармун уйнамыйлар, биетмиләр, җырлатмыйлар. Шундый чакларда безне Мәмдүдә коткара. Аны без кычкартып кына “Мәмүч” ди торган идек. Гармунын күтәреп килә дә, әй сыздыра башлый иде бию көйләрен. Рәхәтләнеп бии идек тә, аннан урам әйләнергә чыгып китә идек. Мәмдүдә гармун уйный, ә без җырлыйбыз. Безгә Кәшбетдин дә иярә, чөнки ул Мәмдүдәнең сөйгәне. Озакламый алар өйләнешteләр, бик талантлы 5 бала үстерделәр. Олы кызлары Фәйрүзә 6 нчы класста чакта ук, гел “5” легә генә укыганы өчен Артекка путевка (юллама) белән бүләкләнде, дөнья күреп кайтты. Бердәнбер малайлары Фирдәвес - безнең авылда ике югары белем алган егетләрнең беренчесе, (икенчесе Кирамов Рәшит), математик, тарихчы, ягъни “аяклы энциклопедия”, Рус Шуган урта мәктәбе (чиста рус мәктәбе) директоры. Кече кызлары Миләүшә авылда төпләнде. Ул да югары белемле, мәктәптә завуч булып эшләде. Иптәше Алмаз белән 2 ул, 1 кыз үстерделәр. Миләүшәнең эчтәлекле, хәзерге заман проблемаларын яктыртып язылган хикәяләре, мәкаләләре газета-журнал битләрендә гел басылып торалар. Кызларының берсе Мөслимдә, икесе Казан янындагы бер поселокта яшиләр.*

*Мәмдүдә белән Кәшбетдин икесе дә бик җор телле, кешегә ярдәмчел, гади кешеләр булдылар. Гап-гади генә сүзне дә алар кызык итеп сөйли беләләр.*

***Бер истәлек.*** *Яңа ел алдыннан чыршы алып кайталар болар. Ә чыршыларны кисәргә ярамый, күрсәләр штраф салалар. Күрше малае кергән дә боларга, “Чыршы каян алдыгыз?”- дип сорый икән.*

*- Баздан алып чыктык без аны, былтыргы чыршыны ташламыйча, сулы банкага утыртып, базга төшереп куйган идек, шуны алып чыктык та бизәдек, - дигән Кәшбетдин.*

*Бу малай ышанган инде, үзе дә шулай эшләгән, тик нигәдер аның чыршысы бик тиз корыган.*

***Тагын бер истәлек****. Бервакыт Кәшбетдин Акмалетдин абзыйларга кергән. Аларның карлыганнары бик шәп икән.*

*- Безнең карлыганнар кортлап бетте, сезнеке ничек әйбәт соң?- дип сорый икән Кәшбетдин.*

*- Бәй без аңа кайнар су сибәбез бит, - ди икән Акмал абзый.*

*Кәшбетдин дә кайткайткан да, кайнар су сипкән, ә карлыганнарның яфраклары бөтенләй каралып, коелып төшкәннәр. Бу Акмалны ничек кызык итәргә соң инде? - дип, уйланып йөри башлаган бу һәм җае да чыккан. Бервакыт, баз ясау өчен, Акмалетдин абзыйга имән өрлекләр кирәк булган, “Миндә бар ул, төшеп ал,”- дигән бу. Тегесе трактор яллап, төшкән боларга, ә Кәшбетдин берни булмагандай: “Бәй, ул имәннәр киселмәгән бит әле, урманда үсеп утыралар,” – ди икән. Менә шулай итеп ачуын кайтарган ул.*

*Мәмдүдә дә юктан да кызык табып йөри торганнардан. Терлекчелектә эшләгәндә бер төркем терлекче хатынны Башкортстанга берничә көнлек ялга җибәрәләр. Барып төшәләр болар, кибетләрдә йөреп, кирәк-яраклар, балаларга өс-башлар алалар. Аларны бер кунакханәгә урнаштыралар. Икенче көнне иртән-иртүк бер хатын тора да, боларны уятып йөри икән. Имеш: “Торыгыз, бу кадәр ничек йоклый аласыз?”. Шулчак, Мәмдүдә башын калкыткан да: “Ят тизрәк, хәерче тавыгы кебек, таң тишегеннән кеше көлдереп йөрмә!” – дигән. Изрәп йоклап яткан хатыннар да, бу сүзне ишетеп, уянып киткәннәр һәм тыела алмыйча көлә башлаганнар. Шулай итеп, йокылары да ачылып беткән.*

*Ире дә, хатыны да килешкән, җор телле, булганына шөкер итеп яши белүче кешеләр иде алар.*

**Йомгаклау.**

Авылыбыз кешеләренә тагылган кушаматлар тарихын өйрәнеп, мин үз авылым кешеләре турында күбрәк белдем. Әле алай гына да түгел, узган гасырда кешеләрнең ничек яшәве турында да бик күп мәгълүмат алдым. Кешеләрнең ничек итеп басуда хезмәт куюлары, ничек итеп терлек асраулары белән таныштым.

Хәзерге вакытта кешегә кушамат белән эндәшү искелек калдыгы булып кына саналмый, киресенчә кешеләр аны дөрес аңлап, кабул итмиләр. Бик каты үртәлеп, хәтта

сугышып та китәргә мөмкиннәр. Мәсәлән, сыйныфташлар арасында бер-берсенә ямьсез сүзләр әйтү күренеше даими кабатланып тора. Бу кешеләр арасында аралашуның аз булуы һәм шаяра белмәү билгесе. Мәсәлән, минем исемем Асылъяр [2], районда бердәнбер исем. Башка милләт балалары аны дөрес итеп әйтә дә алмыйлар, миңа күп очрак: “Асыя, Айсылу диләр. Ә сыйныфташ кызларым нишләптер: Асылкар диләр. Ә авылда дус кызларым, “Хасанка” дип йөртәләр. Мин моңа үпкәләмим, чөнки нәселемдә кушамат булган икән, мин дә алардан калышмаска тиеш.

Менә шуның өчен мәктәптә барлык укучылар арасында исемнәрне бозып әйтү, кушамат белән эндәшү, үчекләү, үртәү, телләшү кебек ямьсез күренешләргә каршы системалы көрәшергә кирәк. Алга таба без бу эшебезне дәвам итәчәкбез, чөнки ачыклыйсы кушаматларыбыз бик күп әле.

**Әдәбият исемлеге**

1. Ибраһимов Г.Г. Алмачуар – Г.Г.Ибраһимов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1992.

2. Сатаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? – Г. Ф. Сатаров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

3. Сатаров Г. Ф. Татар антропонимикасы – Г. Ф. Сатаров. – Казан: Ун – т нәшер., 1990.

*Хасаншина Азалия, 5 нче сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "38 нче Лицей" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчеләр: Хилазова Динара Хафизовна, Хуснутдинова Лейсан Аслахетдиновна, татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Заманча татар модасы – нәрсә ул?**

Кереш

**<u>Теманың актуальлелеге</u>** Мин үзем татар мәдәнияты һәм әдәбияты белән рухланам, туган халкыма хөрмәтем, аңа мәхәббәт һәрчак минем белән. Глобальләшү бер халыкны башкалардан аерып торган нәрсәләрне — тел, традиция, халыкның мәдәни үзенчәлекләрен саклауны аз кайгырта. Бу мода өлкәсенә да кагыла. Тик татар модасына ихтыяҗ бармы? Гомумән, заманча татар модасы — ул нәрсә?

**Татар халкы һәрвакыт матур киенергә яраткан. Әмма бүген инде без милли рәсемле, милли төсмерле киемнәрне бик сирәк очратабыз түгелме?** Милли киемнәр китапта, гаилә бәйрәмнәрендә, фольклорда һәм сәхнәдә чагылып кына чикләнмиме?

Телевизор экраннары, мода журналлары һәм интернет аша агылып торган Көнбатыш һәм Америка культурасы бездә дә үз кагыйдәләрен кертә. Ничек киенергә, нәрсә тыңларга, нәрсә карарга өйрәтә. Көнбатышка охшарга тырышып, без үзебезнең борынгы тарихлы, меңнәрчә еллар яшәгән культурабызны онытабыз түгелме? Күпкырлы һәм искиткеч кыйммәтле татар культурасын барлыкка китерүдә ничәмә-ничә гасырлар буе күпме буыннар, күпме кабатланмас талантлар үз көчен куйган бит. Татар модасы бүген бармы? Милли киемнәр бүген дә актуаль булып торамы? Шушы сораулар белән кызыксынып, үзебезнең лицейның татар теле укытучылары белән без тикшерү эше башкарырга уйладык.

**Тикшерү эшебезнең максаты:** Татар милли киемнәренең бүгенге заман модасында актуаль булуын тикшерү.

Максатыбызга ирешер өчен без түбәндәге бурычларны күз алдыбызга куйдык:

1. Татар милли киемнәрнең тарихына күзәтү.
2. Түбән Кама шәһәрендә “Рамус молл” сәүдә үзәгендә ачылган “Милли киемнәр” кибетенең җитәкчесе Рамилә Гарипова белән очрашу һәм әңгәмә кору.
3. Социаль челтәрләрдәге татар милли киемнәр тегү белән шөгыльләнүче остазларны ачыклау, алар белән сөйләшү.
4. Татарстан Республикасында чыга торган татар газета-журналларны барлап, татар милли иемнәр турында язылган мәкаләләрне уку һәм анализлау.

Тикшерү эшен башкарганда эзләнү, тарихи күзаллау, тасфирлау, классификацияләү, әңгәмә, интервью, чагыштыру, анализлау **метод һәм алымнары** кулландык.

2.1. Заман белән кием янәшә ... Татар милли киемнәрнең тарихына күзәтү

Бүгенге заман модасы күбесенчә Көнбатыштан килә. XX гасыр башларында татар җәмгыяте дә Европа модасы белән кызыксына башлый.

Европа модасы татар милли киеменә нинди үзгәрешләр кертә соң? Гасырлар буе яшәгән туника сыман өлгеләр дә заманча үзгәреш кичерә. Күлмәкләрне бил өлешендә тарайтып, итәккә таба киңәйтебрәк тегәләр. Юбкалар да шундый фасонда була. Күлмәкнең күкрәк өлешендә уем ясалмый, кокетка модага керә. Камзуллар да традицион төсмерен югалта, билен нык кысып, кыска итеп, жилетка охшатып тегәләр аларны. Шароварлар һәм авыр хәситәләр, изү һәм күкрәкчәләр дә модадан чыга. Модада модерн юнәлеше, ягъни заманча һәм актуаль төсмер өстенлек ала. Андый кием гадилеге һәм нәфислеге белән аерылып тора. Артык бөрмәләр һәм балитәкләрдән азат, билләп тегелгән күлмәкләр, гади генә кофта һәм юбкалар. Алар янына камзул, изү һәм башка өстәмә бизәнү әйберләре инде кирәк булмаган. Алдынгы карашлы, демократик җәмгыять кызлары әнә шундый заманча стильдә киенгән.

Җәмгыятьтә дә үзгәрешләр күзәтелгән — хатын-кыз «дөньяга чыга» башлаган: беренче хатын-кыз адвокатлар, актрисалар, рәссамнар барлыкка килгән.

Әмма, аңа карап, кешеләр үзләренең чыгышын онытмаган әле. Милли культура да үсүен дәвам иткән, традицион костюм элементлары да эзсез югалып калмаган. Мәсәлән, кечкенә декоратив чәч каптыргычы рәвешен алган калфакларны кызлар яратып кигән. Өйдән чыкканда, калфак өстеннән шәл япканнар. Чәчләрнең сихри көченә инану югалмаган, димәк, аларны яшереп йөртү зарур саналган. Чулпыларны да XX гасырның 30 нчы елларына кадәр тагып йөргәннәр.

Бизәнү әйберләренең күбесе, кулланыштан чыгып, бик озакка сандык төпләренә яшерелгән. Хәситә, яка чылбыры, изү, авыр алкалар — әнә шундыйлардан. Европа модасы яңа бизәнү әйберләре — хәзергечә әйтсәк, бижутерия — пыяла һәм арзанлы таштан муенса, гади алка һәм беләзек, брошка ише әйберләр тәкъдим иткән.

Күп кызлар заманча аяк киемнәренә күчсәләр дә, үкчәле һәм очлы башлы күн читекләр, бәрхет туфлиләр әле дә модадан төшмәгән. Йомшак табанлы читекләрне күбрәк өлкән яшьтәге хатын-кызлар кигән.

Чигү, аппликация, алтын җепле декоратив бизәкләр популярлыгын югалта барган. Ир-атлар киеме дә европалашкан. Ирләр кимендә озын кара казакин һаман да популяр булып кала. Билләп тегелгән, утыртма якалы озын тышкы кием ул. Түбәтәй дә үзенең әһәмиятен югалтмый. Ул, махсус бер символ, этник билге буларак, татар кешесенең милли үзенчәлеген билгели. Аны кигән кеше, әйтерсең лә, еерактан ук: «Мин — татар!» — дип кычкырып тора.

Костюмда социаль, этник үзенчәлекләр, яшь аермасы күренми. Җәмгыятьнең демократияләшүе, анда Европа идеаллары үтеп керү киемдә дә чагылыш таба. Кием дә демократик төсмер ала, гадиләшә, уңайлылана.

Телевизор экраннары, мода журналлары һәм интернет аша агылып торган Көнбатыш һәм Америка культурасы бездә дә үз кагыйдәләрен кертә. Ничек киенергә, нәрсә тыңларга, нәрсә карарга өйрәтә. Көнбатышка охшарга тырышып, без үзебезнең борынгы тарихлы, меңнәрчә еллар яшәгән культурабызны онытабыз. Юкса, күпкырлы һәм искиткеч кыйммәтле татар культурасын барлыкка китерүдә ничәмә-ничә гасырлар буе күпме буыннар, күпме кабатланмас талантлар үз көчен куйган бит. Бу хакта онытырга хакыбыз юк.

2.2. Түбән Кама шәһәренең “Рамус молл” сәүдә үзәгендә ачылган “Милли киемнәр” кибете җитәкчесе Рамилә Гарипова белән интервью.

- Рамилә апа, исәнмесез, “Татар бизәкләре” кибетен ачарга Сезне нәрсә этәрде? Максатларыгыз нинди?

- Исәнмесез, Азалия, мин озак еллар буе балалар бакчасында тәрбияче булып эшләдем. Аннан соң заказга кош теле пешерә башладым. Шул чакта башыма бер уй килде: ник әле татар алкаларын алкаларын үзем ясап карамасака? Кирәкле әйберләргә интернеттан заказ биреп, аларны үзем ясап, социаль челтәрләр аша сата башладым. Соңрак, Түбән Камада “Татар бизәкләре” дигән кибет ачтым. Бу кибеттә мин калфаклар, изүләр, милли бизәкле алкалар, яулыклар, милли киемнәр сатам.

- Бүгенге көндә милли киемнәрне сатып алучылар күпме?

- Күбрәк бизәнү әйберләре: алкалар, беләзекләр, сумкалар сатып алалар. Аларны көндәлек тормышта да кулланалар. Ә менә киемнәрне гаилә бәйрәмнәрендә, сәхнә өчен татар тәрбиячеләре-укытучылары ала. Шулай ук, кибетемдә милли бизәкле шоперлар, футболкалар еш кулланылышта.

- Сезнең уйлавыгызча, бүген “татар модасы төшенчәсе” бармы? Ничек уйлыйсыз, Сезнең башкарган эшегез киләчәге бармы?

- Минемчә, милли мода бүген чын мәгънәсендә яңарыш кичерә. Хәзер берәү дә калфак яки алъяпкыч такмаячак, ләкин тегелештәге милли киемне стильләштерергә, шул ук вакытта төп элементларны саклап калырга була. Шул рәвешле милли әйбер модага кереп китәргә мөмкин.

2.3. Социаль челтәрләрдәге татар милли киемнәр тегү белән шөгыльләнүче остазлар

Соңгы елларда Казан – күзгә күренеп татарлык үрнәгенә әйләнде. Милли кием киючегә, шундый ук алка, түштамга, муенса тагучыга хәзер бармак төртеп күрсәтмиләр, бәлки кызыгып калалар. Хәер, татар дизайнерлары күп бездә һәм алар ниләр генә ясамый!

Әдәгез аларның кайберләре белән танышып үтик:

Алия Әсләмова аксессуарлар ясау белән 7 ел шөгыльләнә. Кибет ачуына 6 ел. Ә милли бизәнү әйберләрен ясауга 4 ел элек керешә. Аның коллекциясендә 6 серия бар.

– Милли бизәнү эшләнмәләренә кызыксынучылар бар. Бигрәк тә бу яшьләр арасында модага кереп бара диимме соң? Бу безнең үзебез өчен дә ят өлкә һәм ул үсешкә этәрә, – ди Баулы кызы Алия. Аксессуарларның бәясенә килгәндә, болайрак: зур алкалар 300-500, ә кечкенәсе 200 сум тора. Брошканы да 200 сумнан алырга була.

– Бер серияне ясау өчен бер ай вакыт китә, – ди дизайнер. –Мәсәлән, агачтан ясалган “Матур кыз” серияле брошкалар. Шулай ук бездә балчыктан ясалган, милли бизәкле колье, йөзек тә бар.

Телевидение экраннары аша яхшы таныш Адилә Һадиева хәзер Мәскәүдә яши һәм “Орнамент by Adelya Khadieva” проектының авторы булып тора.

Башка проектлардан аермалы буларак, Адилә беренчеләрдән булып тукыма ясаган кеше. Күпчелек дизайнерлар чигү яки батик, аппликация ысулын куллана. Ә Адилә татар бизәген тукымага төшергән. Аның коллекциясендә бүген 4 төрле тукыма бар. Шулай итеп, ул – милли тукымадан беренче кием тегүче. Бүген Адилә Һадиева коллекциясендә блузка, күлмәк, кардиганнар бар. Ярты ел элек аксессуарлар да барлыкка килде. Татар орнаментлы бердәнбер чокер да анда гына. Егетләр дә, балалар өчен дә ассортимент сорыйлар икән. Сатып алучының таләпләре - сыйфат, модалы, табигый тукыма, очсыз. Татар дизайнерларына кыен, без бит миллионлы тиражлар белән сатмыйбыз. Сату бәясе шуңа да кыйммәтрәк. Халык очсызны көтә. Мондый шартларда татар дизайнерларына эшләве читен, – ди ул.

"Bella Kareema" мөселман киемнәре ширкәте хуҗабикәсе Диләрә Садриева. Мөселман хатын-кыз киемнәре тегүче хатын-кыз дизайнерларның барлыкка килүе гаҗәп хәл түгел, чөнки ислам динен кабул итүчеләр саны көннән-көн арта. Гадәттә, сәүдә үзәкләрендә ислам дине таләпләренә туры китереп киенү өчен бик күп эзләнергә кирәк. Бу күп вакыт һәм чыгымнар таләп итә. Ә без әлеге процессны җиңеләйтәбез. Күлмәкләребез инде таләпләргә туры китерелеп тегелгән. Безнең мөселман хатын-кыз сурәтен купшы, зәвыклы, горур, ихтирамлы итеп күрәсебез килә. Бүгенге көндә фикерле, интеллектуаль булу модада. Шуңа да безнең киемнәребез дөньяга үз карашы булган, үз бәясен белгән хатын-кызларга юнәлгән. Ә алар үз чиратында рухи кыйммәтләре, яшәү рәвеше, фикер йөреше һәм тышкы кыяфәте белән ислам диненә карата уңай фикер тудыра", ди ул.

«Татарча Casual» проекты җитәкчесе Айгөл Сингатуллина татар милли киемнәргә ...... Рухи кыйммәтләрне, мәдәниятны һәм телләрне глобальләштерү заманында, үзеңнең тамырларыңны белү һәм аларны саклап калырга тели. Милли кыйммәтләрнең-киемнәрнең китапта, сәхнәдә чагылуы белән генә чикләнмичә, мәктәп өчен дә, уку йорты өчен дә, эш өчендә, ял өчен дә, хәтта өй өчен дә милли төсмерле уңайлы киемнәр булуын тели. Татар бизәкләренең матурлыгын дөньяга да күрсәтәсе килә. Татар лаләләренең бөтендөньяга танылган «пейсли» принты кебек матурлыгы бар дип саный ул.

Түбән Камада яшәүче оста кул иясе Рамилә Гарипова : “Бер мәлне милли бизәкле картиналар ясый башладым. Шуннан соң, нигә әле милли киемнәр киеп йөрүче татар кызларына алкалар эшләмәскә, дип уйладым. Күптән түгел кул эшләре белән «Оста куллы гүзәл затлар» бәйгесендә катнашып, җиңү дә яуладым. Алкаларның детальләрен заказ белән кайтартам. Аннары инде матур бизәкләр белән ясап куям. «Татар бизәкләре» дигән төркем алып барам. Үзебезнең миллилекне саклыйсым килә. Кешеләргә файдалы булсын, дим. Борынгы җырларыбызны табып куям, милли киемнәр, чигү үрнәкләре белән таныштырам. Алкаларны яратып алалар, – ди ул. – Киләчәккә планнарым зурдан. Түшлек, хәситәләр

тегәсем килә. Күңелдә бер теләк – телебез дә, миллилегебез дә, гореф-гадәтләр дә югалмасын иде, - ди.

Татар киемнәре җитештерудә иң популяр кибетләрнең берсе “Татарча casual” кибете. Аның хуҗабикәсе Алисә Сингатуллина 5 ел инде халкыбызны заманча милли кием һәм аксессуарлары белән куандыра. Чын күннән сумкалар, татар орнаментлары белән чигелгән күлмәкләр, футболкалар, спорт киемнәре, кофталар – барысы да зәвык белән эшләнгән.

Бу кибет Татарстанда иң популяр кибетләрнең берсе. Интернет челтәрләрендә аны дә бик тиз табырга була. Шулай ук Айла Нуруллинаның “Остазлар STORE” кибетен беләбез. Ул милли бизәкле сумкалар иҗат итә.

“Rezeda Suleyman” – заманча итеп тегелгән күлмәкләр гүзәл хатын-кызларыбызның мәхәббәтен яулады.

“Сәлам” Татар кибетендә алъяпкычлар, яулыклар, футболкалар, мендәр, хәтта штораларга кадәр тегәләр. Резеда Әглиуллинаның милли бизәнү әйберләре бигрәк тә яшьләргә бик хуп килде.

Татарстан Республикасында чыга торган татар газета-журналлары татар милли киемнәрнең бүгенге көндә актуальлелеге турында

Казан Федераль университетының “Дарелфенүн” газетасында 2015нче елның 26 августында чыккан “Миллилек брендка әйләнерме?” басмасында милли мода бүген чын мәгънәсендә яңарыш кичерә, дип язалар. Татар нәкыше кабат көнкүрешкә кайта! Шунысы куандыра: дәүләт заказы нигезендә башкарылган эш түгел бу. Әлеге шаукымның башында, беренче чиратта, тынгы белмәс яшьләр тора. Егет-кызларның милли тамырларга тартылуы аларның шәхси мавыгулары белән аңлатыла. Берәүләр үз гардеробында татар орнаментлары белән бизәлгән киемнәрне күрергә теләсә, икенчеләре – әлеге продукцияне уйлап табып, милли мода турындагы хыялын гамәлгә ашырырга омтыла. Интернеттагы «vkontakte.ru» сайты кысаларында гына тәкъдим ителүдән башланып киткән татар кияме проектлары, аларның дизайнерлары хәзерге көндә зур тизлек белән популярлык казана, - дип яза.

“Сөембикә” хатын-кызлар өчен әдәби-нәфис журналының 2015нче елның 29нчы апрель санында “Көндәлек киемнәрдә милли төсмер” исем астында чыккан мәкаләсендә “Калфакларны көн дә тагып йөреп булмыйдыр. Ә менә башны каплаучы такыяларны көзен дә, язын да, җәен дә киеп була! Модельерларыбыз әлеге баш киемен көндәлек тормышыбызга кертеп җибәрсәләр иде. 2002 елның август аенда чыккан Ялкын" журналында Диләрә Сөләйманова болай дип яза: XX гасыр башында шәһәрдә яшәүче татар хатыны европача күлмәк киеп, милләтен кечкенә генә калфак белән белдереп куя алган.

Авыл җирлегендә этнокомпонент озак вакыт сакланып килгән, ә шәһәрдә тормыш тизәюенә бәйле рәвештә этнокомпонентлар көндәлек тормыштан тиз киткән. Тик кызыксынуы булган кешеләрнең татар милли мотивлар катнашкан берәр элемент, бизәк, бизәнү әйберләре калган.

“Инде” интернет газетасы “Татар модасы — нәрсә ул?” мәкаләсендә “Милли кием төшенчәсе Казан татарларының кием комплектына карата кулланыла», дип яза. «Инде» сораштыруында катнашкан белгечләрнең бер өлеше «заманча татар модасы» төшенчәсе бөтенләй юк яки аның элементлары: алка, брошка һәм башка бизәнү әйберләре, өс киеменә төшерелгән орнамент, күн мозаикалы сумкалар гына бар дип саныйлар. Ә кайбер белгечләр аны мөселман киеме белән бәйле, ә бу бөтенләй дөрес түгел диләр. Икенчеләре шопер, свитшот, милли бизәк төшерелгән күлмәк, бизәнгечләр, осталар әзерләгән читек — болар бар да заманча татар модасы булуына ышаналар. Белгечләрнең яртысы татар модасының популярлыгы көннән-көн арта дип уйлый, чөнки кешеләргә үз асылын белдертү мөһим һәм бу модага әйләнә. Ләкин хәзер конкурентлыкка сәләтле татар модасын булдыра алган яшь дизйнерлар юк дип белдерәләр. Шулай ук татар модасы популяр түгел, ләкин аны танытырга теләүчеләр күп, тик аңа ихтыяҗ түбән, хәзерге заман мәдәнияте киресенчә тиз үзгәрүчән һәм көчле, шуңа күрә ул һәрчак популяррак булачак, дип әйтүчеләр дә бар.

Татар модасының популяр булмавы — күп очракта дизайнерларга кагыла торган мәсьәлә, алар халык алырга теләгән милли төсмерле коллекцияләр тудырмыйлар. Әгәр бу әйберләр чыннан да зәвыкълы, кызыклы булса, халык аларны чыннан да алыр иде. Тик матди мөмкинлекләр кирәк. Шул ук күн мозаика эшләнмәләрен җитештерү күп көч таләп итә, бәясе дә очсыз түгел.

Гади һәм уңайлы, шул ук вакытта милли колориты булган киемгә кызыксыну артканга күрә, дизайнерлар татар стиле белән экспериментлар уздыра. Кыйбат булмаган ярымкыйммәтле ташлар, агач кебек табигый материаллар; шулай ук пластик, полимер балчык кебек синтетик материаллар кулланганга күрә, милли мотивларда эшләнгән алка, йөзек, беләзек тагучы кызларның саны арта. Ләкин, кул эшенең бәясе кыйбат булганга, күн мозаикалы сумка яки аяк киемен бөтен кеше дә ала алмый. Шул ук вакытта яшьләр арасында хәзер әйберләрне кастомизацияләү, кроссовка яки джинсовкага татар бизәкләрен төшерү — мода индустриясендә яңа нәрсә.

Йомгаклау

Шулай итеп, нәтиҗә ясыйбыз: милли мода бүген чын мәгънәсендә яңарыш кичерә. Ә элеккегене, «иске»не, яңартып, популярлаштырып, бүгенге трендка әйләндереп буламы? Белгечләр билгеләгән төп проблемалар: максатчан аудиториянең тарлыгы, татар колориты булган эшләнмәләргә ихтыяҗның азлыгы, әйбер җитешерүнең үзбәясе югары

булуы, продуктны дөрес итеп таныту проблемасы, яшь һәм сәләтле дизайнерлар аз булуы. Татар киемен җитештерүчеләрнең беренче проблемасы — әйбер җитешерүнең үзбәясе югары булу. Күпчелек очракта халык аз бәягә кыйммәт булып күренгән әйбер алырга тели. Татар дизайнерларның киемнәре масс-маркетта юк, чөнки алар эшне андый күләмле масштабларда алып бара алмыйлар,чөнки ул табыш китерми. Татар киемнәре җитештерүчеләрнең икенче проблемасы — ул максатчан аудиториянең тар булуы. Моңа татар модасы белән кызыксынган һәм мондый киемне сатып ала алырдай матди мөмкинлекләре булган татарлар карый. Татар модасын үстерү өчен нишләргә кирәк соң? Барлык белгечләрнең дә диярлек фикерләре бер ноктада кисешә: татар дизайнерларына дәүләт программалары кирәк. Тик ярдәм һәрвакытта матди яктан гына түгел, бу коллекцияләрне тәкъдим итәрдәй фестивальләр оештыру да, уку йортларын тәмамлаганнан соң эш урыннары белән тәэмин итү дә булырга мөмкин. Икенче вариант — җирле дизайнерларга ташламалы урыннар белән сату мәйданчыгы булдыру. Хәзер милли кием җитештерә торган профессиональ ательелар һәм тегү осталары да барлыкка килде. Тик төрле зәвыкъне, бигрәк тә яшьләр модасын тәэмин итәр өчен алар гына җитми. Белгечләр фикеренчә, яшьләргә ярдәм күрсәтүдән башларга кирәк. Татар дизайнын таныткан очракта, бәлки, Zara кебек эре брендлар татар бизәкләре, орнамент, өлгеләре белән кызыксынып, үз киемнәрен җитештерүдә кулланыр. Минемчә, хәзер берәү дә калфак яки алъяпкыч такмаячак, ләкин тегелештәге экспериментлар ярдәмендә милли киемне стильләштерергә, шул ук вакытта төп элементларны саклап калырга була. Шул рәвешле милли әйбер модага кереп китәргә мөмкин.

Кулланылган әдәбият исемлеге һәм интернет-ссылкалар:


1. “Сөембикә” журналы.Казан. № 11-2023 02/11/23.Издательство: Филиал ОАО «Татмедиа» «Редакция журнала «Сююмбикэ»
2. «Татарская народная одежда». Татарское книжное издательство. Казань, 1997 ел.
3. Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах «Түгәрәк уен» 3/ 2020
4. Экономическое положение сельского населения Заказанья (XIX – начало XX века): сборник документов и материалов / сост., автор предисловия, примечаний, научно-справочного аппарата Х.З. Багаутдинова. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2022. – 596 с.
5. https://kpfu.ru/mediacenter/gazeta-39darelf1139nyn39/millilek-brendka-1241jl1241nerme-144452.html
6. https://luiza-m.narod.ru/smi/tarih/04-zaman.htm
7. https://tatar-congress.org/yanalyklar/milli-kiemner-brendka-everele/

8. https://xn--j1ahfl.xn--p1ai/library/tatarskaya_natcionalnaya_odezhda_181150.html
9. http://senior-danif.narod2.ru/clients/kiemnr_m_bizn_iberlre/
10. http://tt.wikipedia.org/wiki/
11. https://syuyumbike.ru/news/photoreportaj/kndlek-kiemnrd-milli-tsmer
12. https://kpfu.ru/mediacenter/gazeta-39darelf1139nyn39/millilek-brendka-1241jl1241nerme-144452.html

*Хөрмәтуллина Айзилә, 7 сыйныфы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының "38 нче Лицей" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Житәкчеләре:Нуриәхмәтова Римма Закирян кызы, Фәйрузова Инзилә Айрат кызы татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

## "Язучы-педагог Галимжан Вәлиев иҗатында хат җанры-"өчпочмаклы солдат хатлары"

### Кереш өлеш

Тарих тәгәрмәче алга тәгәри

Фронт хатларын әгәр бергә җыйсаң,
Торыр иде мең-мең томнардан.
Булыр иде бәлки хаталары,
Булмас иде әмма бер ялган.
Ул хатларда егет хыяллары,
Тере сүзе, тере сөйләше,
Әниләрнең көне-төне укып,
Өмет булып тамган күз яше.
Солдат хатын әгәр бергә җыйсаң,
Туар иде моңа кадәре
Һич булмаган, һәм булмаячак
Җан тетрәткеч йөрәк әсәре...

(Риф Мифтахов)

Хатлар... Өчпочмаклы солдат хатлары. Аларда сугышның тетрәндергеч авазы. Без ул авазны аңларга тиешбез. Яшәүнең ямен, гомернең кадерен белү өчен.

Әй, дустым! Кара тирә - ягыңа. Яныңда туганнарың, дусларың, якташларың, ватандашларың. Бәхет телә син аларга. Һәр елмаюлы карашны шундый ук җылы караш каршыласын. Бер - береңә изгелектән бөек эшләр башла. Һәр көнебез изгелек белән тусын. Туган яктан читтә булган туганнар, дусларга изге көннәр генә телик.

Минем дә киләчәк буын өчен игелекле эш башкарасым килде һәм, иң кулае дип, фәнни-эзләнү эше язуны сайладым. Илһам чыганагы, яшәргә көч һәм дәрт бирүче күңел маягы булган туган авылыбыз, әби - бабайларыбыз, ата - аналарыбыз тарихы турында өйрәнгәндә, баштан төрле уйлар кичте. Шуларны башка укучылар күңеленә дә җиткерәсем килде.

Гомер уза, еллар үтә. Тарих тәгәрмәче алга тәгәри. Кешелек ашыга-ашыга киләчәккә атлый. Тик бер генә мизгелгә артка карыйк әле, халкыбыз нинди дәвер, чорлар аша үтте икән? Һәр халык үзенең традицияләре, гореф-гадәтләре белән бай. "Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк",- диләр. Дөрес сүзләр. Туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, укучыларга патриотик тәрбия бирүдә туган якның тарихын өйрәнү зур әһәмияткә ия.

Туган төбәк тарихын өйрәнгән вакытта, мин тагын бер нәрсәне аңладым. Бары тик туган як, гаилә, урам, авыл, мәктәп, халкың тарихларын, аларның көнкүрешен, нәрсә белән шөгыльләнгәннәрен белсәң генә, Бөтендөнья һәм Ватан тарихын тиешле дәрәҗәдә үзләштерергә мөмкин.

Туган нигезе, гаиләсе һәм төбәгенең тарихын өйрәтеп, андагы горурланырлык вакыйгаларны, күренешләрне кечкенәдән сеңдергәннән соң гына балаларны патриотик гражданнар итеп тәрбияләргә мөмкин дип уйлыйм.

Шулай итеп эзләнү - тикшеренү эшенең **төп максаты:**

- Халык азатлыгы өчен башларын салган якташларымның Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән батырлыклары белән таныштыру,
- Армиядән, фронттан кайткан хатларны – сугыш елы шаһитарын тикшерү һәм кешелеккә җиткерү
- Хатлар аша яшь буында патриотик тәрбия уяту.

Максаттан чыгып түбәндәге бурычларны үтәргә уйладым:

- Бөек Ватан сугышы чорында хатларның әһәмиятен билгеләү;
- армиядән, фронттан кайткан хатларны тикшерү һәм аларга карата үз мөнәсәбәтләребезне ачыклау;
- Туган иле, туган җире өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнарыбызга карата горурлану һәм кызыксыну хисе тәрбияләү;

**Теманың актуальлеге**

Бу уку елында бөтен ил белән Җиңүне каршылаганда, сугыш эченнән кайткан, яу кырында башын салган сугышчыларның хатлары белән танышу.

Куелган максат һәм бурычлардан чыгып, эшебезне шундый планда төзедем.

Ул кереш, төп һәм йомгаклау өлешләреннән, кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

1. Өчпочмаклы солдат хатлары.

2. Мәктәпнең “ Туган якны өйрәнү” музей - почмагында тарихи эзләнүләр.

3. Галимҗан абый Валиевка багышланган почмак.

3. “Солдат хатлары” җыентыгында язылган фронттан килгән хатлар.

Эзләнү эше туган якның, туган авылның, туган мәктәпнең тарихын өйрәнү, аны буыннан буынга саклап калдыруда һәм укыту-тәрбия эшендә зур ярдәм итәр дип уйлыйм.

**Төп өлеш**

Хатлар. Хатлар...

Без бүген кечкенә кәгазь битләренә язылган сугыш хатирәләрен искә алырбыз.

Хатлар. Хатлар... Өчпочмаклы, ак, зәңгәр яки ал конверлы,читенә кыр почтасының тәртип саны куелган. Әллә ничә төрле кулъязма, төрле төстәге карандашлар, төрле телдә язылган. Бу хатларда бер генә теләк: ”Җиңүгә ышаныч!”.

Солдат хатлары. Күз алдыгызга китерегез: кыска гына ял вакытында солдат окопта яки блиндажда, кәгазен калай савыт төбенә яки тез башына куеп, хат яза. Дошманга булган ачы нәфрәте дә, сугыш авырлыгы, яраларының сызлавы, иптәшләренең һәлак булу кайгысы-барысы да шушы хатка сыеп беткән. Бу кечкенә генә кәгазьдә дошманны чигендереп алган шәһәрләр һәм авыллар турында да сөйләнә. Солдат язылып беткән хатын бик пөхтәләп, өчпочмаклап төрә, адресын яза һәм кыр почтасына илтеп сала. Шулай ул, иң изге теләкләрен әйтеп, гаиләсенә сәлам хаты җибәрә. Солдатлар ут эчендә. Кайберләре, искиткеч батырлык күрсәтеп, сугыштан исән чыга, ә кайберләре, дошман белән соңгы сулышына кадәр көрәшә. Ә хат, канатлы кош кебек, ерак-еракка “оча”. Ул фронтчының ялкынлы сүзләрен туган иленә, гаиләсенә, якын кешесенә житкерә.

Солдат хатлары, гадәттә, гади карандаш белән язылганнар, кайберләре, еллар үтү белән, танымаслык хәлгә килгән. Бу хатларның тагы бер кимчелеге: аларның күбесе гарәп хәрефләре яисә яңалиф белән язылганнар. Бик күп хатлар вак, хәтта чамадан тыш вак хәрефләр белән төрле кәгазьләргә язылган.

Сугыш елларында, ут эчендә йөрүче бабаларыбыз, абыйларыбыз өйдәгеләре белән даими рәвештә хат язышып торган. Бу хатлар солдатларның фронттагы тормышын,

аларның уй-хисләрен, омтылышларын, кайгыртучанлык тойгыларын ачык күрсәтә. Болар - истәлекле, әдәби кыйммәткә ия хатлар...

Хатның эчтәлеген яңа кәгазьгә төшерү - энә белән кою казуга тиң. Чөнки хатлар бик таушалган, каләм белән язылганнарының хәрефләре җуелган, кайбер урыннары бөтенләй өзелгән. Хатлар гарәп, латин һәм кириллица графикасында язылган. Бу язмаларны укыганда зур дулкынлану кичерәсең. Алар үткән дәһшәтле сугыш елларын күз алдына китерә, тарихны онытмаска, тыныч тормышның кадерен белергә өнди.

Хатларның эчтәлеге белән танышкач, күзгә ташланган беренче нәрсә шул: хат авторлары үзләренең барлык якыннарына, берсен дә читтә калдырмаска тырышып, сәлам юллыйлар. Билгеле, аларның кош теледәй генә хәбәрләрен, күпме кеше тилмереп көтеп тора.

Мәктәбебездә эшләп килүче, “ Туган якны өйрәнү” музеенда, узган ел, Галимҗан Валиевка багышланган почмак булдырдык. Бу почмакта аның китаплары, язмалары,шәхси әйберләре, фотосүрәтләре, көндәлекләре урын алган.

Шул вакытта “Солдат хатлары” дип исемләнгән җыентыкка күзем төште. Кулыма алып укырга туры килде. Монда армиядән, фронттан килгән хатлар язылган һәм сугышчылар турында күбрәк беләсе килү теләге артты. Кем соң ул Галимҗан Валиев? Мин сезгә аның турында да сөйләп китәрмен.

**Галимҗан Вәлиев олы кешелеклелек сыйфатларына ия булган кеше**

Галимжан Вәлиев халык мәгарифе отличнигы, атказанган укытучы, Татарстан Язучылар берлегенң шәрәфле(почетлы) әгъзасы, Хезмәт ветераны, ветеран – педагог һәм язучы. Ул Түбән Кама шәһәрендә, 36 нчы микрарайонда яшәде. Саваплы иманга, игелекле әхлакка сусаган, үткәнебез, бүгенгебез, киләчәгебез хакында уйланучы тынгысыз җанлы кеше иде. Әгәр исән булса, 21 нче гыйнварда 100 яшь тулган булыр иде.

Ни өчен мин менә Галимҗан Вәлиевның иҗатын өйрәнергә керештем?. Беренчедән, аның турында бик аз кеше белә. Минемчә, аның кебек күренекле һәм талантлы кешеләр киңрәк даирә кешеләренә билгеле булырга тиеш. Икенчедән, тумышы белән безнең районнан булмаса да, ул безнең шәһәребездә яшәп иҗат итте.

Өченчедән, Галимҗан Вәлиев олы кешелеклелек сыйфатларына ия булган кеше.

Дүртенчедән, бу язучының китапларын укып, без гыйбрәт алырга тиеш, алардагы акыллы киңәшләрне, фикерләрне үз тормыш тәҗрибәбездә кулланырга тиеш дип уйлыйм мин.

Аның китаплары ярдәмендә мин үзем дә кайбер күнекмәләрне тәрбияләдем – хат язарга өйрәндем.  Хәзер бит безнең тормыштан цивилизация хат язуны кысрыклап чыгарды. Ә Галимҗан Вәлиевның китапларында бик матур хат үрнәкләре белән таныштым.

Хәзер мин бераз Галимҗан абый Вәлиевның тәрҗемәи хәленә тукталып китәм. Ул 1921 нче елның 21 нче гыйнварында Минзәлә районының Күзкәй авылында туган. Әтисе – Шакирҗан, әнисе Бибихәдичә Вәлиевләр дин кануннарын үтәп яшәгәннәр. “Әти Корьәнне бик кадерли, ап-ак ситсага төреп бикле сандыгында саклый. Безгә тоттырганы юк. Хәтта әнинең дә укыганнары юка догалыклар гына”- иде дип искә ала Галимҗан ага.

Ул урта белемне Күзкәй мәктәбендә ала. Мәктәпне бары тик “5” ле билгеләренә генә тәмамлый. Мәктәптә уку елларында матур әдәбият белән дә кызыксына, рус язучыларының әсәрләрен яратып укый.

Г.Вәлиев Казан Дәүләт университететының физика – математика факультетын тәмамлый.

Кешеләрнең  дөрләп янган сыман күзгә ташланып торганы да, тыйнак һәм тыныч кына үз эшенә бирелеп зур хезмәт куйганы да бар. Менә шундый күзгә бәрелеп тормаса да, зур эш башкаручы, Галимҗан Вәлиев шундый кеше. Тормышта сынала – сынала, үр арты үр, кыя арты кыя яулый, милләтебезнең бу газиз баласы.

Г.Вәлиев мәктәптә укыган елларда яшьләр арасында көндәлекләр алып бару киң таралган булган. 2004 нче елда бу китапның дәвамы булып Г.Вәлиевнең “Сугыш еллары көндәлекләре” исемле китабы чыга. Бу китап Җиңүнең 60 еллыгына багышлап чыгарыла. Шулай ук Бөек Ватан сугышына багышланган “Яшьлегебез сәхифәләре” исемле китабы да дөнья күрә.

Көндәлек – ул ышанычлы хәтер сакчысы булу белән бергә, күңел һәм акыл юлдашы, сердәш, юанычы да. Анда башкалар белән, хәтта якын дусларың  белән  уртаклаша – сөйләшә алмаганнарны язасың. Бу китап сугышка кадәр язган көндәлекләр,  хатлар, истәлекләр, кайбер документлар ярдәмендә тулылындырылган. Г.Вәлиев монда тарихи чынбарлык, шул чордагы авыл мәктәбе эшчәнлеген, яшьләрнең уй – хыялларын, омтылышларын,  иҗтимагый – сәяси хәлне чагылдыруны максат итеп алган. Ә үзенә  авыру сәбәпле сугышта катнашырга туры килми.

Галимҗан ага үзенең хәләл җефете  Мәрьям белән биш бала тәрбияләп үстерә. Хәзерге көндә аларның өчесе илнең төрле почмакларында хезмәт итә. Җиде оныкларыннан бер фәннәр кандидаты, ике фәннәр докторы бар. Мәрьям апа үзе дә татар теле укытучысы булган.

2011 нче елда Түбән Кама шәһәренең 19 нчы мәктәбендә Галимҗан ага Вәлиевның юбилеена багышланган әдәби – музыкаль кичә үткәрелде.  Кичәдә муниципаль районы һәм шәһәр башлыгы Айдар Метшин, Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге рәисе Рөстәм Ганиевнең Рәхмәт хатлары, истәлекле бүләкләре тапшырылды. Кичәне Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Илһам Хисматуллин алып барды.

Галимжан ага Вәлиевның “Солдат хатлары” китабы да, Бөек Җиңүнең 55 еллыгына багышланган. Бу китапта сугыш алды көндәлекләре һәм хатлардан өзекләр тупланган. “Солдат хатлары” дип кемнәрнеңдер сугыш кырларыннан язган, эчтәлегендә хәрби батырлыклары тасвирланган хатларны гына атыйлар. Ә Галимҗан ага уйлавынча, кешенең армиягә чыгып китеп юлдан язылган беренче хәбәре үк, эчтәлеге нинди булуга карамастан, “Солдат хаты” дип саналырга тиеш ди. Әнә шул гадәти хатларыннан башлап танышмыйча, солдатның үткән юлын, тулы тормышын, кичерешләрен, хезмәтенә карашын, бәясен, эчке дөньясында туган үзгәрешләрен күзалларга мөмкин түгел.

“Телевидение бөтенләй булмаган, ә радиоалгыч авылда бер генә урында булган һәм газеталар сирәк кешегә килгән ул елларда, фронт белән тылны бәйләүче төп чара - хатлар иде,” - дип искә ала Галимҗан ага.

Бу китапта Г.Вәлиевның сабакташларыннан, укытучыларыннан, туганнарыннан, хезмәттәшләреннән килгән хатлар урын алган. Г.Вәлиев архивында алар 300дән артык.. Фронттан килгән хатларның бер өлеше сугыш күренешләрен сүрәтләгән рәсемнәр, дошманны тизрәк җиңүгә, тылда тырыш хезмәткә багышланган өндәмәләр, шигырь куплетлары белән бизәлгән әзер форма – кәгазьләргә, открыткаларга язылганнар. Ә кайберләре һәм күпчелеге гади дәфтәр(хәтта китап) битләренә, плакат кисәкләренә, әйбер төрү кәгазьләренә һәм башкаларга язылган.

Сугыш елларындагы хатларны өчпочмаклап, төреп, ябыштырмыйча җибәргәннәр. Бу, беренчедән, конверт белән тәэмин итү мөмкинлеге булмаудан, икенчедән хәрби цензураның эшен җиңеләйткән. Ул елларда сугышка алынучыларның күпчелеге 4-7 еллык белемле, унъеллыгы белән сирәк, хәтта бөтенләй булмаган. Авыллардан армиягә алынучыларның күпчелеге аңа кадәр үз районы эченнән ерак юлларга чыкмаган, русча юньләп сөйләшә һәм яза белмәгән, үз телендә дә грамоталылыгы чамалы булган кешеләрдән торган. Шунлыктан, бу кимчелек кайбер хатларда ачык чагылган. Беренче хатлар күбрәк юл мәшәкатьләрен, табигать күренешләрен сүрәтлиләр, сагынудан, ямансулаудан, туклану җитмәүдән, кием – салымнан зарланалар.

Билгеле инде, яңа тәртипләргә күнегә төшкәч хат – хәбәрләрнең эчтәлеге дә үзгәрә бара. Армия таләпләренең каты булырга тиешлеген солдатлар үзләре дә хуплыйлар, төрле белегечлекләргә өйрәнүләрен, тазару – ныгуларын, белем ягыннан алга китешләрен күрсәтәләр. Башта русча белмәүдән кимсенүчеләрнең кайберләре соңга таба тулысынча русча язуга күчкәннәр.

Сугыш эчендә йөрүчеләрнең хатлары аз сүзле, дошманны күралмау, тизрәк җиңү, туган илгә кайту теләге белән сугарылган.

“Ләкин сакланган хатларны бер җыентыкка туплап бетерү мөмкин түгел. Монда “Солдат хатларының” бер өлеше генә урын алган. Бу җыентык гасырыбызның иң дәһшәтле елларын чагылдырган һәм яшьлекләрнең дошманны җиңүгә багышланган яки корбан булган фидакарьләрнең изге истәлеге буларак кабул ителсен иде”,- дип яза Галимҗан Валиев.

Берничә хатка тукталып китәрбез.

**Ситдыйков Госман Ситдыйк улының хаты.**

Минзәлә районында туган.1940 елда армиягә алына, танк училищесын тәмамлый, сугышларда катнашып яралана.Сугыштан исән кайтучы солдат.

**27.08.41**. Хөрмәтле дустым! Синең хатыңны 26 нчы августта кич алып укыдым, кайбер урыннарын укыганда кычкырып көлдем,  андагы хәлләрне күз алдына китерерлек итеп язгансың, рәхмәт.

Үземнең тормыш турында берничә сүз. Минем нинди училищеда укуым сиңа билгеле инде. Зур танкларны йөртәбез. Броня бик калын, үлем эзләүче шашкан пулялар безнең белән шаяра алырдай түгел.Танк эчендә барганда сөйләшеп булмый, чөнки аңлашылмый, ә күрше танк командирлары белән радио аша бәйләнешкә керәбез.

Безнең укулар һәм өйрәнүләр бара. Чират – соңга табарак булачак. Мин кая гына китсәм дә, сиңа хат язармын.Шулай ук синең хатыңны түземсезлек белән көтеп калам, мине онытма.Танк училищесын отличного бетердем, Хәрби Академиягә керергә план корып куйган идем инде.Үземнең булдыра алу дәрәҗәмне бу мәктәптә тагын бер кат сынап карадым.

Авылда нихәлләр бар? Тәмам. Кичке проверка башланды. Хуш! Госман.

Тагын бер хатка тукталасым килә.

Укытучысы – Суфиев Харис Әхмәт улының хаты. 1912 елда Минзәлә районы Калморза авылында туа. Армиягә алына , сугышта катнаша. Күп кенә медальләр белән бүләкләнгән.

13-14.10.39.  Иптәш Вәлиев! Сиңа һәм барлык 10 класс укучыларына миннән, ягъни сезне биш ел укыткан укытучыгыз Суфиев Харистан кайнар сәлам. Укуыгызны уңышлы тәмам итүегезне көтеп калам.

Уку ул – яшьлек еллары өчен совет дәүләте биргән иң зур хокук. Сез анда шат күңел белән тыныч укыгыз, ә без монда Совет илен, Ватаныбызны чит этләрдән саклау өчен хәзерләнәбез.

Сез урта белемне тәмам итү белән монда киләчәксез һәм армия тормышы сезгә тагын бер мәктәп булачак. Монда чыннан да мәктәп: укыйсың, белем аласың, ныгыйсың, тазарасың.

Сезгә минем теләк: яхшы укыгыз, комсомол оешмасы яхшы эшләсен, укучылар оешмалары яхшы эш алып барсын.

Кызык сезнең тормыш, укучылар, бик күңелле. Укыган вакытлар сагындыра икән ул, кадерен белегез. Дәфтәрдән карау, әйтеп тору, ятлап уку – бернәрсәгә дә ярамый торган эшләр. Ятламагыз, ә өйрәнегез.

Ә мин сезгә шатлык һәм матур көннәр телим. Хәзер дә сез шат, көннәрегез матур, киләчәгегез тагын да күңеллерәк булыр. Укытучыларның сүзен тыңлагыз, укытучы – сезнең командирыгыз ул, хөрмәтләгез, кадерләгез, якын итегез.

Хушыгыз! Элеккеге укытучыгыз Х.Суфиев. Хатымны кичә башлап бүген тәмам иттем.

Адресым: Свердловская область, г.Н.Тагил.

Тагын бер хатка тукталасым килә.

Вәлиев Маһиҗан Шакирҗан улы. Галимҗан Вәлиевның бертуган абыйсы.

19.11.41**.** Үзем исән – сау. Ун-унбиш көн саен хатлар салып торсам да, сездән ала алмыйм. Килгәннән бирле көннәр, Донбассның сугыш кырларында үтә. Днепр тирәләрендә август аенда язган хатыгызны алган идем. Шуннан соң юк. Ворошиловградтан киткәндә телеграмма һәм биш йөз сум акча җибәргән идем. Ихтимал, алгансыздыр.

Моңа кадәр көннәр төрлечә узды, бик авыр чаклар булды, барлык әйберләрне, хәттә кулдагы перчаткаларны да югалттым. Карточкалар альбомы бигрәк тә җәл, сезгә җибәрмичә ялгыштым. Тиз генә миңа бер пар перчатка белән бер пар йон оекбаш җибәрегез әле, бер килеп җитәр. Көннәр суыта башлады.

Картадан Горловка дигән шәһәрне табыгыз әле, мин хатны шуннан якын гына урыннан язам.

Анда укулар туктамагандыр дип беләм. Монда фронттан кырык – илле километр тирәләрендә тормыш гадәттәгечә бара.

Хәзергә хушыгыз. Адресым: Полевая почта 585, 274 ОЗАД

Сәлам белән Маһиҗан. Көньяк фронт.

09.05.45**.** Сезнең барчагызны да сугыш бетү һәм дошманны җиңү белән котлыйм. Шулай итеп, дүрт ел буе канкойгыч каты сугыш безнең җиңү белән тәмамланды. Дөрес, күпләргә һәм безгә дә иң якын кешеләрне, агай – энеләрне югалтырга туры килде. Нишлисең бит, сугыш шунсыз булмыйдыр инде ул.

Үзем дүрт ел буе окопларда, сугыш кырларында йөрсәм дә, бәхеткә каршы, исән калдым. Моңа шатланырга да ярыйдыр.

Хәзергә хушыгыз. Озакламый очрашуны теләп, абыең Маһиҗан. Болгария.

**Йомгаклау**

Хатлар….Хатлар …… Якын кешеңнең һәр хәрефе, һәр иҗеге кадерле. Хатлар - йөрәк тарихы. Күпме серләр саклый алар. Яралы җаннарга шифа, тулган күңелләргә дәва – ул хатлар. Ана хатлары... Бала хатлары... Кайгылы хатлар, борчулы хатлар, җавапсыз хатлар да бихисап. Хатларның төп мәгънәсе йөрәкләрне җылытуда бит... Әйдәгез, күңел җылыбызны бер-беребезгә хатлар аша җиткерик.

Телевизор карау, компьютерда уйнау вакытын киметеп, кулыбызга ак бит алып, якын кешеләребезгә хатлар юллыйк.

Җир йөзендә сугышлар башка кабатланмасын. Яшь егетләрнең гомере вакытсыз өзелмәсен, ата-аналар кайгы яше түкмәсен иде. Кеше бу дөньяга иҗат итү, Җирне матурайту өчен яратылган. Сугыш утлары сәясәтчеләрнең гаебе белән кабына. Алар шуны белеп торсын: без – тынычлык яклы!  Һәрчак куанычлы хәбәрләр генә килеп торсын. Тормышта нинди генә авырлыклар килсә дә, бу дөньяга нигә килгәнегезне онытмагыз. Без бу дөньяга вак- төякләрдән, юк-бар ыгы-зыгылардан өстен булып яшәргә килдек. Яшәү- дөньяны ярату ул.

Сугыш елларында фронттан хат килү чиксез зур шатлыкка әйләнгән. Бу аналарга улларының, иренең исән-сау икәнлеген аңлаткан. Ләкин, ни аяныч, кемнәрнеңдер газизләре өчен ул хат соңгысы булган.

Әйе, бу сугыш илебезгә күпме кайгы-хәсрәт, күпме күз яше китереп, күпме сабыйны ятим калдырды, бәхеттән мәхрүм итте. Шулай булуга карамастан, Ватанга булган мәхәббәт, тыныч, бәхетле киләчәккә ышаныч барысыннан да көчле булып, Бөек Җиңүгә китерде.

Без бәхетле чорда яшибез, якты мәктәпләрдә укыйбыз, белем алабыз, үзебез яраткан эш белән шөгыльләнәбез. Җир йөзендә сугышлар кабатланмасын, алга таба да тыныч, мул, матур тормышта яшәргә язсын иде безгә!

Бай тарихлы авылымның үткәнен өйрәнеп, киләчәктә ялгышларны кабатламаска, күңелсез вакыйгалардан гыйбрәт алырга, уңышка илткәннәреннән үрнәк алырга һәм якты киләчәк төзергә мөмкин икәнлегенә инандым.  Бу эшем үлгәннәрнең каберен, исәннәрнең кадерен белергә кирәклегенә төшендерде, һәркемдә үзенең туган ягы, гаиләсе, урамы, авылы, мәктәбе, халкы тарихларына карата кызыксыну уяткандыр дип уйлыйм.

Сугышның тере шаһитлары булырдай шушындый хатларны кадерләп саклаган, китап итеп бастырган Галимҗан Вәлиевнең хезмәте югары бәяләнә, аңа кадер – хөрмәт арта.

Мин шуны аңладым: бүгенге көндә бу тема бик актуаль, чөнки безнең буынга сугышны үз күзләре белән күргән кешеләрнең истәлекләрен барлау көннән-көн авырая, аларның сафы елдан-ел кими бара.Шуңа күрә без сугыш истәлекләрен, хикәяләрне ветераннарның үзләреннән яки балаларыннан булдыра алган кадәр күбрәк язып калырга

тиеш. Бу китап безгә,бүгенге буынга, сакларга һәм киләчәк буынга тапшырылырга тиешле васыять.

**Кулланылган әдәбият исемлеге.**


1. Валиев Г.Ш.Солдат хатлары.Яр Чаллы типографиясе, 2000ел.
2. Валиев Г.Ш.90 яшь.Түбән Кама, 2011ел.
3. Валиев Г.Ш. Сугыш еллары көндәлеклре, Түбән Кама , 2004 ел
4. Гаилә архивы.
5. Тәбән Кама районы 19 нчы урта мәктәбенең музее материаллары
6. Татарстан тарихы.Төп мәктәп өчен уку әсбабы.-Казан.-Тарих, 2001
7. Хәтер.Татарстан Республикасы,Казан, Хәтер китабы нәшр.,1996.
8. Физәлия Дәүләтгәрәева, Солдат хаты”. Сөембикә журналы, 2018



*Шәйхетдинова Ләйсән, 8 нче сыйныф,*

*Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин районы 31 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе*

*Җитәкчеләре: Сташенко Юлия Михайловна, педагог-организатор, Гайнуллина Ләйсән Магсумовна, туган татар тел укытучысы*


**Габдулла Баттал. Акланган исем.**

Мы были большими, как время,
Теперь мы в легендах прославленных дней.
Теперь мы в граните и в бронзе,
Теперь мы в поэзии и в прозе…
Мы в безмолвье могильных камней.

**Роберт Рождественский**

Эзләнү эшенең максаты: Муса Җәлилнең көрәштәше Абдулла Баттал турында мәгълүмат җыю, бу геройның биографиясен , холык үзенчәлекләрен белү.

Эзләнү эшенең бурычлары:

1. Г.Батталовның барлык гаилә әгъзалары турында белү
2. М. Җәлилнең көрәштәше – Г.Батталов биографиясен тулысынча ачу
3. Җәлил көрәштәшләре исемнәренең ничек мәңгеләштерелүе турында белү

Куелган бурычларга түбәндәге тикшеренү методлары файдаланылды:

1. Сораштыру, интервью алу.
2. Документаль басылып чыккан һәм басылмаган чыганакларга анализ.

3. Алынган фактларга чагыштырма анализ.

Эзләнү объекты: Батталовлар гаиләсе

Эзләнү предметы: Габдулла Батталов.

Гипотеза: үз гаиләсенең тарихын һәм аның әгъзаларының ил биографиясенә керткән өлешен игътибар белән өйрәнсәң, М.Җәлилнең мәктәп әдәби музеенда мәгълүмат урнаштырсаң, әйләнә-тирәдәгеләрнең гаиләләре һәм туганнары тарихына кызыксыну уяначак.



Тикшеренүнең теоретик әһәмияте: әлеге тема буенча материалны өйрәнү, анализлау һәм системалаштыру. Тикшеренүнең гамәли әһәмияте сыйныф сәгатенә, тарих, җәмгыять белеме дәресләрендә, ОДНКНР һәм үзлегеңнән белем алу дәресләрендә нәтиҗәләрне һәм нәтиҗәләрне файдалану мөмкинлеге белән билгеләнгән. Үткәрелгән тикшерү яшүсмерләрне патриотик тәрбияләүне пропагандалауга ярдәм итә.

**Кереш**



Мин - Шәйхетдинова Ләйсән, мин 31 нче мәктәпнең 8 нче сыйныф укучысы. 60 ел инде безнең мәктәптә Советлар Союзы Герое Муса Җәлил исемендәге әдәби музей эшли. Мин “Кызыл ромашка” музей активы әгъзасы булып торам: район һәм республика конкурсларында, тикшеренү конференцияләрендә катнашам, экскурсияләр үткәрәм. Мөһим даталар алдыннан безнең мәктәптә төрле юнәлештәге күп кенә чаралар уза. Муса Җәлилнең туган көненә һәм үлем даталарына аерым мөнәсәбәт. Мәктәптә фәнни конференцияләр, китап укучылар конкурслары, музейда экскурсияләр һәм кызыклы очрашулар уза.



Шундый чараларның берсендә безгә фашистлар әсирлегендә яшерен көрәш буенча М. Җәлилнең көрәштәше Габдулла Батталның бертуганы Фуат Батталның улы - Фәрит Баттал килде. Фәрит Фоат улы Муса Җәлилнең барлык көрәштәшләре турында мәгълүмат җыю эше турында сөйләде. Балалар Фәрит Фоатовичның хикәясе ярдәмендә бу геройларның биографиясенә "күз салдылар". Фашистлар сугышы шартларында героик көрәш турында күп кенә яңа фактлар белдек. Минем өчен Фәрит абый Фоат улының,

Габдулла Батталның якташым икәнен белү бер дә көтелмәгән хәл иде. Габдулла Баттал Татарстан Республикасы Алексеевск районында туып-үскән . Минем әти-әнием Алексеевск районыннан. Якташым Габдулла Баттал турында эзләнү-тикшерү проекты эше язарга булдым. Мин үз эшемне мәгълүмат эзләүдән башладым.

## I бүлек Батталовлар гаиләсе

Батталовлар гаиләсе Спас өязендә Олы Тигәнәле авылында яшәгән, хәзер ул Алексеевск районы. Вазыйх һәм Нурдидә Батталовлар гаиләсендә 5 малай һәм бер кыз туган. Кешенең шәхесе һәм холкы гаиләдә туплана. Аларның әтисе Вазыйх абый бик тырыш кеше иде. Ул һөнәре буенча табиб булган, ләкин шул ук вакытта кешеләргә сәгать төзәткән. Язучы Туфан Миңнуллин бер тапшыруда болай ди : «Балаларын да хезмәтне яратырлык итеп тәрбияләгән. Ул беркайчан бер сүзне ике тапкыр кабатламаган. Барлык балалары да иҗади, тәртипле кешеләр булып үскәннәр”. Авылдашлары үз йортлары янында чишмә агуын сөйлиләр. Яшь кызлар су алырга килгәннәр. Баскыч төбендә еш кына абый-энеле Батталлов энеләре утыра торган була. Кем гармун да уйнаган, кем җырлаган. Су алырга килгән кызлар аларны рәхәтләнеп күзәткәннәр, сокланганнар.



Галимзян Батталов


Иң олы абыйлары Батталов Галимҗан Вазыйх улы гражданнар сугышында катнашкан. Казанны белочехлардан сакладган. Казанда бухгалтер булып эшли. Бөек Ватан сугышына чакырылган. Хатыны Әминәгә соңгы хат Чуваш АССР Шумерль станциясеннән җибәрелде. Хезмәт урыны шулай да билгесез кала. Гаиләсе аның үлеме турында хәбәр ала. Ул Мәскәү янындагы сугышта бомбага тоту астына эләккән. Тол хатыны Әминә 1983 елда үлгән.

Салих Батталов - Бөек Ватан сугышы елларында хәрби очучы, язучы, публицист, СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Кызыл Йолдыз ордены Кавалеры. Чистай мәдрәсәсендә укыган. 1929 елда Оренбург очу училищесын тәмамлый. Ә Бөек Ватан сугышы елларында Тын океан флотының авиация частьларында хезмәт итә. Салих Батталның беренче шигыре 1924 елда Мәскәүдә «Рабочий» газетасында басылып чыга. Шул вакыттан аның шигырьләре матбугатта күренә башлый. Туган телдә шигырь җыентыклары чыга. Пьеслары татар театрлары сәхнәсенә куела. "Һава океанында" очерклар китабы, "Лётчик" романы дөнья күрә. Салих



Салих Батталов

Батталның күп кенә сугыш шигырьләре аның "Ватан-ана" җыентыгына кергән. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән.



Мөбарәк Баттал

Өченче абыйсы - Батталов Мөбарәк, гобойчы, педагог, ТАССРның атказанган артисты. 1937 елда Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка техникумын тәмамлый. 1941 елда Мәскәү консерваториясен тәмамлый. 1941 елдан 1971 елга кадәр ул татар дәүләт опера һәм балет театры артисты булып тора. Татар музыка сәнгатенең күренекле эшлеклеләре белән бергә чыгыш ясый. Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Фәридә Яруллина, Александр Ключарёв һәм татар халык көйләре әсәрләрен башкара. Бөек Ватан сугышында катнашты. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, III дәрәҗә Дан ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән.

Кече энесе Фуад Батталов 1920 елның 25 декабрендә туган. 1937 елда Казан музыка училищесына укырга керә. 1940 елның сентябрендә Тын океан флотына чакырыла. Активист һәм агитатор була. Җитди йөкләмәләр үти. Күп кенә хәрби частьларда сәхнә матбугатының редколлегия әгъзасы була. 1946 елның декабрендә Тбилисиның Нахимов хәрби-диңгез училищесына күчерелә. 1949 елның ноябрендә беренче категория запасына демобилизацияләнә. 1950-1981 елларда Казан электротехника заводында "Зөя" татар җитештерү берләшмәсендә инженер-конструктор булып эшли. Японияне җиңгән һәм Германияне җиңгән өчен медальләр белән бүләкләнгән.



Фуад Батталов

## II часть Габдулла Баттал

Кызылармеец, Җәлилнең көрәштәше Габдулла Батталов турында тәфсилләбрәк сөйлисем килә. Гади крестьян гаиләсендә туган малай Муса Җәлил белән яшерен группа составында элемтәче була һәм 1944 елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә газаплы үлем белән үлә. Абдулла Баттал - Габдулла Вазыйх улы Баттал - 1916 елның 1 маенда туган. Ул исән калган алты баланың бишенчесе иде. Габдулла абыйларының берсенә дә охшамаган. Бөтенесе кара чәчле, кара күзле, кара кашлы, ә ул - аксыл йөзле, салам чәчле, зәңгәр күзле, сипкелле. Габдулла юмор хисле, күңелле, ачык булып үсә. Ул елларда азык-төлек белән авыр була, һәм ата-аналар азык-төлекне экономияле тота. Өч-дүрт яшьлек Габдулла, кунак килгән саен, өстәлгә иң тәмле ризыклар куела торган булган. Ул өйдән чыгып барганда, берәүне очратып шаяртып: «Әти сине

кунакка чакыра», - ди. Бер дә шикләнмәгән әти кеше кунакны ачык йөз белән каршы ала, иң тәмле  сый белән сыйлый һәм, билгеле, сыйлауның бер өлешен Габдулла белә.

Авыл мәктәбенең җиденче сыйныфын тәмамлагач, Габдулла колхозда эшли; Чистайда урта мәктәпне тәмамлый; әтисе буларак, Донбасстагы шахтада эшли. Абыйсы Салих үрнәгендә рухланып, Габдулла хәрби хезмәт турында хыяллана башлый һәм аның очучы фуражкасын киеп йөри. Салихтан алган будёновкадагы зәңгәр шлемы йолдызы белән урамга чыкканда, кызлар игътибар үзәгендә була. Бу будёновкада ул 1930 елда югары уңыш өчен алынган күчмә байрак астында колхозчылар төркеме белән фотога төшә. Абдулланың бу фотосурәтеннән зуррак сурәте классик сурәткә әйләнә; хәзер аны төрле плакатларда һәм, әлбәттә, Казан Кремле янындагы барельефта күрәләр.

1937 елда аны армиягә чакыралар. Габдулла Казан Кремлендә хезмәт иткән, үз теләге белән кече командирлар курсына - «Татар-башкорт хәрби мәктәбе»нә юлланган. Шул вакыт аның белән бәхетсез бер хәл була. Ул фабрикада азык-төлек өчен складка барганда, Банковская урамында - хәзерге Җәлил урамында, Болакка якынрак, ат машиналардан курыкты да, чаптырып китә. Габдулла тәгәрмәч астына эләгә, аягын имгәтә. Хезмәткә яраксыз дип танылгач, ул туган авылына кайта һәм клуб мөдире булып эшли. Бу эш аның күңеленә хуш килә. Ул үз тирәсенә яшьләрне җыя, мәдәни-агарту эшен җайга сала. Атна саен диярлек клубта концерт яки спектакль куела, анда Габдулла конферансье яки артист, яки укучы-декламатор булып катнаша; ул баянда виртуозларча уйный.

Район газетасына бик теләп  лирик шигырьләр яза. Сугыш башланыр алдыннан Габдулла берничә ай район газетасы редакциясе хезмәткәре булып эшләгән. Габдулла күп укый, бигрәк тә Такташ поэзиясен ярата, аны яттан белә. Аның кулдан ясалган дәфтәрләре - шигырь җыентыклары шактый күп була.  Батталның  әнисе дини карашлы кеше буларак  аның дәфтәрләрендәге барлык рәсемнәрне яндырган; мөгаен, дәфтәрләрен дә шул ук язмыш көткән.




Габдулла бик  сүзгә , тәнкыйтькә оста була. Колхозда нинди җитешсезлек күрсә, шундый кызулык белән «Г.Баттал» дип язып куя. Галимҗанның энесе аны сүгә торган була: “Син язасың, ә җаваплар минем янга килә, ничек тә башкача кул куй... Шуннан соң Габдулла «А. Баттал»

имзасын куя да «А. Баттал» дип кул куя. Шулай итеп, Абдулла дигән исем белән тарихта кала. Казанга килгәч, Габдулла, гадәттә, Ләйләнең апасында туктала торган була. Ул «үлем карточкасын» тутырганда әсирлектә дә яшәү урыны дип Казанны атаган, ә әти-әнисе исеме урынына апасы һәм аның ире Гарифның исемен күрсәтә. Ул моны әнисенә авырлык тумасын өчен эшләгән - аның үлеме турындагы хәбәр ишетелми торсын өчен шулай эшли. Абдулла Баттал балаларны бик ярата, алар гел аның тирәсендә әйләнәләр. Ул аларны урманга алып бара . Аларга шигырьләрдә укый . Агачлар, үсемлекләр, чәчәкләр турында экиятләр сөйли.

1938 елда Хәдичә исемле бер кызга өйләнә. Кызганыч, кызлары Рәисә ике яшькә дә җитмичә үлеп китә. Сугыштан соң Абдулланың абыйсы - Фоат тегермәндә Хәдичәне очрата. «Бәхетле гомер чыкмады бит...» - дип елап җибәрә. Соңрак, әнисеннән символик рөхсәт сорап, ул икенчесенә кияүгә чыккан. Икенче иреннән җиде бала таба. Соңгы елларында Хәдичә балаларында яши һәм 2003 елда вафат була.

1.Сугыш


Бөек Ватан сугышы башлангач, Абдулла сугышка омтыла һәм үз дигәненә ирешә. Кызганычка каршы, аның ничек әсирлеккә эләгүе билгеле түгел. Әсирлектә Абдулла Гайнан Кормаш җитәкләгән яшерен төркем составына керә, элемтәче вазифаларын үти. Кормаш, Хәсәнов һәм Солтанбәков белән берлектә антифашистик листовкалар тарата. Хыянәтче аркасында яшерен группа фаш ителгәч, аның барлык әгъзалары, 1943 елның 10 августыннан башлап, кулга алына. 1944 елның 25 августында Абдулла Баттал төркемнең ун иптәше белән гильотинада сигезенче булып җәзалап үтерелә.

2. Сугыштан соң

Сугыштан соң бер генә туганы да, әлбәттә, Җәлил иптәшләренең Ватанга хыянәт итүләренә ышанмаган, ә чит кешеләр имеш-мимешләргә бик җиңел ышана башлыйлар. Пишет Фәрит Фуат улы Баталов «Минем этием - ул вакытта заводта мастер булып эшләүче Фуат Батталов артыннан: «Менә дошман дошманының туганы!» - дигән пышылдауларны ишетә; аны дәүләт бүләкләренә тәкъдим ителгән исемлектән сызып ташлыйлар. Энесе турында хыянәтче буларак даими искә алу этисенең характерының начараюына китерә һәм, ахыр чиктә, аның сәламәтлеген какшатты дип саныйм."-ди.

3.Аноним хат

1990 елның мартында Фуада Батталовка аноним хат белән газета китерәләр. Ул 1969 елда Төркиядә үлгән тарихчы Габделбари Баттал турындагы «Татарстан яшьләре» газетасында басылган мәкалә була. «Баталов, сезнең абыегыз үлем җәзасына дучар ителгән, ул исән, ул фашист, сатлык... Син Абдулладан да начаррак (кечкенә хәрефтән исеме Ф.Б.), сезне хөкем итәргә кирәк...»- һ.б.диелә.






Фәрит Фуатович Баталов бу турыда «Язуыннан һәм хаталарыннан без анонимканы ем язын белдек: ул 15 ел элек безнең туганыбызга әверелгән кеше булып чыкты. Һәм аның улы безнең фикеребезне раслады. Өч ел ярым вакыт үткәч, бу туганым, ни сәбәптәндер, әтинең үлүе турында, шелтәләп, безгә шалтыратты, без аңа бу кайгылы вакыйга турында хәбәр итмәдек, янәсе. Мин: «Улыгызның белүе дә җитә», - дидем дә трубканы куйдым.”ди

4.Озак көтелгән барельеф

Җәлил һәм аның белән бергә җәзаланган көрәштәшләренең исемнәре әлегә кадәр яктыртылмый, без моны гаделсезлек дип санайбыз. Бик еш массакүләм мәгълүмат чараларында без «иптәшләр төркеме» яки «Җәлил көрәштәшләре» дип ишетәбез. Җәлил турындагы мәкаләләрен һәм китапларын язып кына калмаган Рафаэль Мостафин аңа үзенең иҗади талантын багышлаган, гомере буе Мәскәүдә Советлар Союзы Геройлары исеменә «җәлилчеләр» исемен бирергә тырышкан. Кире кагулар күп булды, ахыр чиктә аларның истәлеген урамнарга, поселокларга һ. б. ларга бирү белән мәңгеләштерергә карар кылдылар. Ә 1994 елда, Кормаш төркемен җәзалауга 50 ел тулгач, Муса Җәлил һәйкәле янында аның сугышчан иптәшләре исемнәре белән барельефлар ачыла.

1999 елда туган авылы Абдулла Баттал урамнарының берсенә авыл советы карары белән аның исеме бирелгән (анда шулай ук Салих Баттал һәм Муса Җәлил урамнары да барлыкка килгән); 2003 елның 8 маенда авылда инде булган туган якны өйрәнү музееның яңа бинасын тантаналы ачу була, анда Батталовлар гаиләсенә зур урын бирелгән. 1990 елның 5 маенда СССР президенты Михаил Горбачев Указы белән курмашчы-подпольщиклар үлгәннән соң I дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнәләр. Ел ярымнан соң Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, бу Указны үтәп, әлеге орденнарны геройларның туганнарына тапшыра. Ә 2005 елда аларга "Бөек Җиңү" орденнары тапшырыла. 2015 елда Казанның яңа урамнарының берсе шәһәр администрациясе карары белән «Братьев Батталовлар» исеме - язучы Салих һәм подпольщик Абдулла Баттал хөрмәтенә бирелә.

1917нче елда М.А.Евстафьева җитәкчелегендәге музей активы Габдулла Батталның туган ягында Зур Тигәнәле авылында булдылар, балалар Салих Батталов исемендәге туган якны өйрәнү музееның кызыклы экспозициясе белән танышалар, анда музей җитәкчесе “Олы юлда Тигәнәле” китабын бүләк итә, без аны музейда саклыйбыз.

## Йомгаклау

Башкарылган эш нәтиҗәсендә без бөтен мөмкин булган материалны өйрәндек - тарихи, биографик, автобиографик. Без Абдулла Батталның туганнан туган энесе - Фәрит Фуатович Баталов белән очраштык, ул безнең эш нигезенә кергән кызыклы һәм файдалы мәгълүмат белән уртаклашты, "Имеш әсирлегендә" фильмнарын карадык. Абдулла Баттал (реж. Р. Юзаев) "Соотечественики" программалары циклыннан ТНВ һәм ""Батталлар о" каналында реж. Ф. Баталов (2006), башка мәгълүмат белән дәреслекләрдә һәм истәлекләр китапларында танышканнар. Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре, шул исәптән Габдулла Баттал да, төрле методлар белән фашист баскыннары белән көрәшкән яшерен оешма төзи алганнар. Җәлилче Батталның сугышчан юлы авыр, сынаулар белән тулы иде, һәм ул безнең өчен - яңа буын батырлыгы үрнәге булып тора. Тикшеренү эшен язганда без җыйган бөтен мәгълүмат Хәтер альбомы нигезен тәшкил итә, ул яңа исемнәр, фактлар, фотосурәтләр белән тулылана һәм безнең мәктәптә саклана.

## Кулланылган әдәбият:


1. «Герой-шагыйрьнен көрәштәше» /З. Низаметдинов// Кызыл тан- 2014 г. с. 4.

2. «Жизнь моя песней звучала в народе» /З. Гилемханова //Туймазинский вестник- 2010г.- № 35- с.5.

3. «Олы юлда Тигәнәле» » /Б.Г.Шәйхетдинов// «Суз» Казан. 2006 -№ 162-163 (24527)- с. 92

4. М. Джалиль «Моабисткая тетрадь», «Комсомольская правда, Директ-Медиа», 2015 г., 240 с.


## Интернет -чыганаклар


**1.Сайт «Братья Баттал»** http://battalovlar.ru/

2. «Бессмертный барак. Книга Памяти. Муса Джалиль»// https://bessmertnybarak.ru/article/kaznen_v_plenu_musa_dzhalil/,

3. «Уфа-гид. Очерки. Соратники Джалиля» //https://ufa-gid.com/ocherki/soratniki-dzhalilya.html,

4. Электрон дәреслек «История Германии», т.2 //http://www.k2x2.info/uchebniki/istorija_germanii_tom_2_ot_sozdanija_germanskoi_imperii_do_nachala_xxi_veka/p5.php#metkadoc4

*Яковлева Карина, 9 нчы сыйныф,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының “инглиз телен тирәнтен өйрәнү белән 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*Җитәкчесе: Нургатина Р.Р.,татар теле һәм татар әдәбият укытучысы*

**Модалы чалбар (М.Җәлилгә ияреп)**

Минем чибәр апам бар,
Исеме дә бик матур.
Аның нурлы йөзен күреп,
Барлык кеше шаккатыр.
Уңган, булган Гөлүсә апам
Зәвык белән киенә.
Яши бирә бу дөньяда
Ул үзенең көенә.
Апам милициядә
Күп еллар хезмәт итә.
Районлагы һәр кеше
Апамны хөрмәт итә.
Беркөн апам иртә таңнан
Кабалана эшенә.
Нидер булыр кебек бүген,
Шулай керә төшенә.
Машинаның педаленә
Баса, тиз очсын диеп,
Хәрап булган икән бүген
Үкчәле туфли киеп.
Үкчәсе чалбар балагын,
Апамның тишеп керә.
Җәлилнең Хәдичәсе күк
Шулай (и)теп йөри бирә.
Кызлар, соңга калмагыз,

Үкчә киеп йөрмәгез.

Тагын әллә ни тишеп,

Мода дия күрмәгез.

**Аш-су остасы ДиләӘни эштә минем диеп**

Аптырап тормый Дилә.

Пешерә дә бирә сиңа

Нәрсә ашыйсың килә.

Йомырка да кыздыра,

Токмачын да пешерә.

Кулы кулга йокмый аның,

Ничек кенә өлгерә.

Интернетта ни күрсә дә,

Әзерләргә тотына.

Аш-су белән мавыгып,

Дәрес кенә он(ы)тыла.

Шаурма да ясый белә,

Креветкалар кыздыра.

Аш-су бүлмәсен күреп,

Әни генә туздыра.

Савыт-сабаларны юу

Ансы кала әнигә.

Тәмле-тәмле ризыклардан

Өлеш чыга әтигә.

Күзләр тия күрмәсен

Диләнең кулларына.

Бары иманлы затлар

Очрасын юлларына.

**Туган авылым – Җөри**

Туган авылым-Җөрием

Киң кырлар, болыннарың.

Үзенә җәлеп итә

Чабышкы колыннарың.

Тау астыннан ага “Тәпи” чишмә,

Изге диләр аның суларын.

Горурлана табигатең белән

Синдә туган кыз һәм улларың.

Сандугачлар җыр сузалар

Тарлау инеш буенда.

Төрле милләт күңел ача

Җөри сабан туенда.

Зур шәһәрләрдә яшибез,

Күңел тарта авылга.

Җылы, якты, матур бит ул,

Хәтта кышкы давылда.

**Машиналы әни**

Ничек итсә итте әни

Машиналы булды ул.

Юлга әнием чыкты,

Дустым, игътибарлы бул!

Таныклыгын күптән алды,

Кагыйдәләрне белми.

Әтием өйрәткәннәрне

Колагына да элми.

Янга, артка карамый,

Әнием алга чаба.

Штраф килсә, түләми,

Мең төрле сәбәп таба.

Машиналар кычкыртса да,

Әни игътибар итми.

Юлларны кистереп йөри,

Исе дә аның китми.

Әти машина төзәтә,

Штрафны түли әти.

Руль артында элдерә,

Кагыйдә бозып әни.

**Песине эзләдек**

Авылыма кайткан чакта,

Песиемне калдырмыйм.

Урамда, тычкан эзләтеп,

Хәлдән аны тайдырмыйм.

Җылы мендәрләрдә генә

Йоклатам аны сөеп.

Сыйпап кына торам аны,

Йомшагым минем диеп.

Песине без өйдә тоттык,

Чыгармадык урамга.

Туңар дидек, өшер дидек

Салкын ачы буранда.

Инде яллар үттеләр,

Китер чаклар җиттеләр.

Мәктәпкә дә барасы,

Рәхәт көннәр беттеләр.

Киткән чакта песине

Эзләп тә таба алмыйбыз.

Кем чыгарды урамга?

Шуны без аңламыйбыз.

Әти-әни, ике әби

Киттек песине эзләп.

Урам буйлап аптырашып

Йөрибез песи күзләп.

Озак эзләдек песине,

Көрткә биш тапкыр чумдым.

Йон итектән кар керде,

Юешләндем мин, туңдым.

Арып-талып, бергәләп
Инде өйгә дә кердек
Шунда аптырашта калдык,
Гаҗәеп бер хәл күрдек.
Песиебез өйдә икән,
Йоклаган бездән качып.
Эндәшмәгән исеменә,
Яткан почмакта посып.

## Ипи үзең алырсың

Авылда күршебездә
Ялгыз бер абзый тора.
Авыр эшең булса әгәр,
Син аннан ярдәм сора.
Беркөн Дилә, Мәдинәгә
Абзый мөңлеген бирде.
Миңа ипи, колбаса
Алып кайтыгыз диде.
Үзләренә шоколад
Алырга рөхсәт итте.
Дилә белән Мәдинә
Абзыйны кызык итте.
Сок, шоколад, чупа-чупс-
Барсын кызлар алганнар.
Ипи кайтмады дигәч,
Аптырашта калганнар.
Җыеп кайтканнар кызлар,
Хәйран гына калырсың.
-Сдачага, күрше абый,
Ипи үзең алырсың.

## Түләп алыш

Икешәр телефонлы
Бигрәк текә әтием.

Куй шул телефоныңны дип

Ачулана әнием.

Нишләсә дә, кая барса,

Телефоннар кулында.

Ничек кенә яшәгәндер

Ул интернет югында.

Балыкка да, гөмбәгә дә

Телефонсыз ул бармый.

Көне-төне интернетта,

Армый да, әти талмый.

Бер телефонны шулай

Бәкегә дә озатты.

Балыклар телефонын

Әтинең бик ошатты.

Телефонын урманда да

Әти югалтып кайтты.

Нишләргә миңа хәзер дип,

Аптырап барып ятты.

Телефоннарын табып,

Безгә хәбәр бирделәр.

Тапкан табышны түләп

Алыш хәзер диделәр.

Әти үз телефоннарын

Яңадан сатып алды.

Телефон тарихлары

Күңелгә кереп калды.

**Уеннан уймак**

Әнием матур булам дип,

Беркөн укол ясатты.

Җыерчыклары бетсен дип,

Витаминнар кадатты.

Әни аптыраштa калды,

Күзе əллə нишләде.

Тарта, сикерə туктамый

Берəр кортмы тешлəде.

Атна узды, айлар узды,

Бетми күзе тартуы.

Ашау йокмый, йокы керми,

Эх, газапның артуы.

Хəзер миңа нишлəргə дип,

Әни табибка китте.

Уйламыйча башкарган эш

Әнине хəрап итте.

Биткə керткəн даруларны

Кире чыгару кирəк.

Акчаны да җилгə ату

Була инде бу димəк.

Дəрес булды əнигə

Башка укол димəде.

Башыннан кичкəннəрне

Дусларына сөйлəде.